АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова**

# ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА

Издание 2-е, дополненное

В трех томах

**Том I**

Казань
2015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ

Тулыландырылган 2 нче басма

Өч томда

**I том**

Казан
2015

**УДК 811.512.145'36**
**ББК 81.2Тат-2**
**Т 12**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Фәнни редактор –** филол. фән. докт., проф. **Ф.М. Хисамова**

**Рецензент –** филол. фән. докт., проф. **К.Р. Галиуллин**

**Т 12** **Татар грамматикасы:** өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 512 б.
ISBN 978-5-93091-192-3

«Татар грамматикасы» татар теленең фонетик һәм грамматик системасын тасвирлап, аңлатып бирүне үз эченә ала. Бу хезмәт татар әдәби теленең төрле стильләреннән алынган бай фактик материалны хәзерге грамматик казанышларга таянып анализлау җирлегендә язылды. Ул башлыча тасвири һәм норматив грамматика, ләкин анда тарихи, чагыштырмалы (тугандаш телләрне чагыштыру), контрастив (тугандаш булмаган телләрне чагыштыру), диалекталь һәм стилистик грамматика элементлары да урын алды. Беренче томда «Фонетика», «Фонология», «Просодика», «Графика һәм орфография», «Орфоэпия», «Морфемика», «Морфонология» һәм «Сүзьясалыш» темалары карала.

Хезмәт тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-192-3**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2015

# КЕРЕШ

«Татар грамматикасы» татар әдәби телендәге графика, орфография, морфемика, орфоэпия, сүзьясалыш, морфология һәм синтаксис фәненең хәзерге торышын тасвирлауны максат итеп куя. Хезмәтнең төп бүлекләрен язганда, әһәмиятен күздә тотып, грамматикага шулай ук татар теленең фонетика, фонология, просодика, интонация кебек тармаклары турындагы мәгълүматлар да кертелде.

Академик грамматика – телнең лингвистик казанышларын исәпкә алып, аларны гомумиләштереп, зур фәнни югарылыкта норматив һәм тасвирлама планда язылган хезмәт ул. Хәзерге татар әдәби теленең грамматик төзелешен фәнни тасвирлау норматив тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр белән бергә алып баруны максат итеп куя.

*Грамматика* сүзе ике мәгънәдә кулланыла: ул телнең төзелешен һәм шул төзелешне өйрәнә торган фәнне белдерә. Татар грамматикасы буенча хезмәтләрдә озак еллар буе, грамматика фәне морфология һәм синтаксистан тора, дип аңлатып килделәр.

Тел белеменең сүзьясалыш (словообразование) тармагы тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгән булу сәбәпле, XX гасыр ахырларына кадәр морфология эчендә каралып килде. Академик грамматиканың 1993 елда чыккан русча вариантында сүзьясалыш беренче мәртәбә грамматиканың, синтаксис, морфология бүлекләре белән янәшә, аерым өченче бер бүлек итеп бирелде. Бүгенге көндә сүзьясалыш тел белемендә мөстәкыйль тармак буларак үсеш алды.

Сүзьясалыш – лексикология белән грамматика фәннәрен үзара бәйли торган тармак. Бер яктан, ул лексик составның яңа сүзләр белән

баю юлларын өйрәнә, икенче яктан, сүзнең ясалу ягыннан төзелешен тикшерә.

Татар теленең беренче грамматикаларына лексикология кертелгән һәм кыска гына тасвирланган була. Хәзерге көндә татар лексикологиясе төрле юнәлештә шактый җентекле өйрәнелде, аның үзенең фразеология, ономастика, семасиология кебек мөстәкыйль бүлекләре үсеп чыкты. Шуны истә тотып, татар теленең сүзлек составын мөмкин кадәр тулы, фәнни яссылыкта яктырткан «Татар лексикологиясе» мөстәкыйль хезмәт буларак эшләнде.

Телдәге авазлар составын, аларның кулланылыш үзенчәлекләрен, сөйләгәндәге тавыш хәрәкәтен өйрәнә торган фонетика, фонология һәм просодика фәннәре рәсми рәвештә грамматика эченә кертелми, ләкин болардан башка телнең төзелешен аңлату кыен булганлыктан, академик грамматикалар язганда, фонетика, фонология, просодика, интонация фәннәре дә читтә калдырылмый.

Тел белеменең графика һәм орфография, орфоэпия дигән мөстәкыйль бүлекләре дә рәсми рәвештә грамматика фәне эчендә каралмый, ләкин, гамәли максатлардан чыгып, алар академик грамматикада урын ала.

XX гасыр ахырында татар тел гыйлемендә морфемика һәм морфонология дигән мөстәкыйль бүлекләр барлыкка килә. Морфемика – ул сүзнең мәгънәле кисәкләрен тәшкил иткән морфемаларны өйрәнә һәм сүзьясалышы, морфология һәм синтаксис фәннәренә кереш хезмәтен үти, аларны үзара тоташтыра. Морфонология исә морфемалардагы авазларның сөйләм барышында үзгәрүләрен өйрәнә, ул фонология, сүзьясалыш һәм морфология фәннәре арасында тора, аларны үзара тоташтыра.

Димәк, татар теленең академик грамматикасы үз эченә тел белеменең фонетика, фонология, просодика, графика һәм орфография, орфоэпия, морфемика, морфонология, сүзьясалыш, морфология һәм синтаксис тармакларын ала.

Үз чоры өчен тулы дип саналган татар академик грамматикаларын язу тарихына килгәндә, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин.

XIX гасырда татар теленең үзенчәлекләрен фәнни яссылыкта тикшерә башлаган хезмәтләр дөнья күрә. Алар арасында татар грамматикасына нигез салучы галимнәрнең берсе И. Хәлфиннең грамматикасы аеруча игътибарга лаек (Хальфин И. Азбука и грамматика татарского

языка с правилами арабского чтения. Казань: Типография Казан. ун-та, 1809. 106 с.). Г. Фәезханов, К. Насыйри кебек галимнәрнең хезмәтләрендә тел белеме турындагы мәгълүматлар тагын да тулыландырыла (Фәезханов Г. Татар теленә кыскача гыйльми сарыфы. Казан, 1887. 316 б.; Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан: Казан. тип. ун-та, 1895. 86 с.).

XX гасыр башында Җамал Вәлиди, моңа кадәр тел белеме өлкәсендә булган барлык казанышларны гомумиләштереп, татар теле грамматикасын яза (Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы. Казан: Милләт, 1919. 175 б.), 1923–1925 елларда Г. Ибраһимов җитәкчелегендәге коллектив тарафыннан язылган «Гамәли тел сабаклары» дип аталган грамматика басылып чыга (Гамәли тел сабаклары: III кисәк. Казань: Тип. имени «Камиль Якуб», 1923–1925). Алга таба Г. Алпаров хезмәтләре игътибарга лаек (Алпаров Г.Х. Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты, 1926. 164 б.). Ләкин бу китаплар академик планда түгел, ә мәктәп дәреслеге буларак төзелгәннәр.

Татар теленең академик грамматкасына нигез булырдай хезмәтләр узган гасырның икенче яртысыннан күренә башлый. Биредә мисал итеп М.З. Зәкиев хезмәтен китерергә мөмкин (Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис. Казан: КДУ нәшрияты, 1958. 243 б.).

Шулай ук Х.Р. Курбатов, В.Н. Хангилдин һәм К.С. Сабиров кебек галимнәрнең татар телен фәнни яссылыкта тикшергән хезмәтләре дөнья күрә (Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956; Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. Морфология һәм синтаксис. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 642 б.; Хәзерге татар әдәби теле. Лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 300 б.).

Татар теленең беренче академик грамматикасы Н.Б. Борһанова, М.З. Зәкиев, Х.Р. Курбатов, А.М. Латыпов, Л.Т. Мәхмүтова, К.С. Сабиров, М.А. Сәгыйтов, Д.Г. Тумашева, В.Х. Хаков, Ф.Й. Йосыпов тарафыннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнә (Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология. М.: Наука, 1969. 380 с.; Современный татарский литературный язык. Синтаксис. М., 1971. 310 с.).

1993–1995 елларда татар тел гыйлемен югары дәрәҗәгә күтәргән, телнең барлык үзенчәлекләрен бөтен нечкәлекләре белән яктырткан

3 томлы академик грамматиканың рус телендәге варианты басылып чыга (Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. 1. 583 с.; Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. 2. 397 с.; Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. Т. 3. 576 с.). Әйтергә кирәк, татар теленең русча язылган бу академик грамматикасы күп кенә башка төрки телләрнең шундый грамматикаларын язу өчен үрнәк булып тора.

Мәгълүм булганча, 1994 елның июль аенда Югары Совет «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» кабул итә. Әлеге Программа нигезендә 1998–2002 елларда академик грамматика томнары татар телендә дөнья күрә (Татар грамматикасы: 3 томда. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1998. Т. 1. 283 б.; Татар грамматикасы: 3 томда. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. Т. 3. 512 б.; Татар грамматикасы: 3 томда. М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. Т. 2. 448 б.). Әлеге «Татар грамматикасы» хәзерге (милли) татар әдәби теленең, фонетик һәм грамматик төзелешен тасвирлауны үз эченә ала. Ул татар әдәби теленең төрле стильләреннән алынган бай фактик материалны хәзерге грамматик казанышларга таянып анализлау җирлегендә язылган. Шул ук вакытта «Татарская грамматика» исеме астында русча өч томда чыгарылган академик хезмәтнең татарча эшкәртелгән һәм баетылган вариантын тәшкил итә. «Грамматика»ның беренче томындагы «Сүз башы», «Кереш», «Грамматиканың төп төшенчәләре», «Морфемика» бүлекләре – М.З. Зәкиев; «Фонетика», «Фонология», «Просодика» бүлекләре – Х. Сәлимов; «Графика һәм орфография», «Орфоэпия» бүлекләре – Х. Курбатов; «Морфонология» темасы – М.З. Зәкиев һәм Д. Сәлимова; «Сүзъясалышы» бүлеге Ф. Ганиев тарафыннан язылган. Исемнәр, терминнар һәм кушымчалар күрсәткечен Э. Кадыйрова төзегән.

Өч томлык академик грамматика тюркологлар арасында югары бәяләнә, аны төзүчеләрдән дүрт авторга Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге бирелә.

Татар тел белеме, югарыда искәртелгәнчә, бер урында гына тормый. Ул һәрвакыт үсештә. Соңгы елларда татар телен функциональ яктан тасвирлаган хезмәтләр дөнья күрде. Бу өлкәдә Ф.А. Ганиев хезмәтләре билгеле (Функциональная грамматика татарского языка. Казань: Пропаганда, 2015. 276 с.). Шулай ук бүгенгесе көндә Татар-

стан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан татар әдәби теленең тарихи грамматикасы эшләнә. Югарыда телгә алынган «Татар лексикологиясе»нең I томы басмага әзерләнә.

Сезнең игътибарга тәкъдим ителгән «Татар грамматикасы» 1998–2002 елларда дөнья күргән «Грамматика»ның тулыландырылган икенче басмасы булып тора. Яңа басмада «Фонетика» бүлеген – Ф.М. Хисамова, «Орфография» бүлеген – И.Б. Бәширова, «Язу тарихы»н – Р.Ф. Мирхәев, «Морфонология» өлешен – Д.Ә. Сәлимова, «Сүзъясалышы» бүлеген А. Гайнетдинова редакцияләп, тулыландырдылар. Морфемалар күрсәткече – Л.Г. Хәбибуллина, терминнар күрсәткече – Г.С. Хаҗиева-Демирбаш, исемнәр күрсәткече Ч.Р. Хаҗиева тарафыннан редакцияләнде.

Хезмәт тел күренешләрен тасвирлама һәм норматив, чагыштырмалы (башка төрки телләр белән чагыштырылган) һәм контрастив (рус, инглиз, немец һ.б. тугандаш булмаган телләр белән чагыштырылган) яссылыкта яктыртуны максат итеп куя. Төп бурычларының берсе – телне грамматик тасвирлауны норматив тәкъдимнәр белән бергә үреп бару. Биредә теоретик мәсьәләләрне һәм фактларны фәнни системага салу күренеше норматив бурычлар белән берлектә алып барыла. Мәсәлән, хезмәттә сүзьясалыш мөмкинлекләренең, синтаксик конструкция төрләренең кайсылары хәзерге әдәби телдә кулланыла, кайсылары вариатив булып тора, кебек сорауларга җавап бирелә.

«Грамматика» киң катлам укучыга аңлаешлы телдә язылган, сирәк кулланылыштагы терминнар хезмәтне артык чуарламый, кулланылган яңа терминнарга аңлатмалар биреп барыла.

«Татар гарамматикасы» татар теле белән кызыксынган, шулай ук белемнәрен тирәнәйтергә омтылган укучылар һәм тел белгечләре өчен тәкъдим ителә.

# 1. ФОНЕТИКА

Тел белемендә фонетика предметы артык киң аңлатыла. Аңа телдәге барлык аваз чараларын да, авазлар белән хәрефләр арасындагы бәйләнешләрне дә кертәләр, ягъни бирегә фонология дә, просодика да, графика да кертеп карала. Бу хезмәттә исә, яңа грамматикалар традицияләренә нигезләнеп, «Фонетика», «Фонология», «Просодика» бүлекләре мөстәкыйль рәвештә бирелә. Шуңа бәйле рәвештә «Фонетика» бүлегендә карала торган мәсьәләләр дә чикләнәләр.

Фонетика – тел белеменең бер бүлеге, ул авазларны, аларның кушылмаларын, аваз үзгәрешләрен өйрәнә.

Галимнәр татар теленең аваз төзелеше белән XVIII гасырда ук кызыксына башлаганнар. Россиядә беренче тапкыр басылган, гарәп хәрефләре кулланып С. Хәлфин тарафыннан төзелгән иң беренче татар әлифбасында ук инде татар теленең авазлары турында кайбер мәгълүматлар табып була. Аның артыннан И. Гиганов, И. Хәлфин, А. Троянский, Г. Мәхмүдовларның хезмәтләре дөнья күрә. Ләкин алар барысы да укыту максатларыннан язылган булалар, һәм аларда төп игътибар русларга татар теле грамматикасын өйрәтүгә юнәлгән була, бу грамматикаларга исә әлифба өйрәтүгә бәйле рәвештә фонетика бүлеге дә кертелә.

Татар фонетикасы буенча иң беренче фәнни мәгълүматлар К. Насыйриның «Кыскача татар грамматикасы»нда күренәләр. Анда аваз чиратлашулары, авазларның үзара тәэсир итешүләре, сүз басымы кебек мәсьәләләр карала. Шул ук авторның «Әнмүзәҗ» исемле икенче хезмәтендә исә авазларны төркемләүнең кайбер принциплары да бәян ителә. Аңа кадәр булган хезмәтләрдә татар телендә өч кенә сузык аваз бар дип танылса, К. Насыйри татар телендә ун сузык аерып чыгара, аларның язуда гына өч хәреф белән белдерелүләрен искәртә. Г. Нугайбәк, Г. Алпаров, Җ. Вәлидиләр тарафыннан соңрак төзелгән дәреслекләрдә авторлар төп игътибарны авазларны төркемләүгә юнәлтәләр.

В.В. Радловның «Төньяк төрки телләр фонетикасы» төрки телләрнең аваз төзелешен чагыштырып өйрәнү өлкәсендә зур әһәмияткә ия була. Анда татар фонетикасының да бик күп мәсьәләләре тикшерелә: татар теленең авазлары башка төрки телләр белән чагыштырып бирелә, кайбер авазларның кулланылыш закончалыклары ачыклана, сингармонизм һәм басым мәсьәләләре тикшерелә. В.В. Радлов татар телендә 11 сузык һәм 23 тартык аваз саный.

Г. Алпаровның 1926 елда басылган «Шәкли нигездә татар грамматикасы» исемле китабы татар авазларын чын фәнни нигездә тасвирлап бирүче хезмәт булып тора. Анда авазларның артикуля-ион характеристикалары, аваз үзгәрешләре, ассимиляция, сингармонизм, иҗек төзелеше, басым, орфоэпиянең кайбер мәсьәләләре аерым-аерым карала.

Шушы чорда В.А. Богородицкийның хезмәтләре белән татар фонетикасында эксперименталь тикшеренүләр башлана. Казанда Россиядәге иң беренче эксперименталь фонетика кабинетын оештырып, В.А. Богородицкий татар теле буенча искиткеч эксперименталь-фонетик тикшеренүләр үткәрә. В.А. Богородицкийның хезмәтләрендә сүзләрдәге тон хәрәкәте тасвирлана, авазларның озынлыгы һәм көче карала; беренче мәртәбә, эксперименталь мәгълүматларга нигезләнеп, татар һәм рус телләренең авазлары чагыштырып бирелә; сүздәге урынына бәйле рәвештә авазларның озынлыклары, тавыш югарылыгы үзгәрү кебек нәтиҗәләр ясала, сингармонизмның төп үзенчәлекләре күрсәтелә. В.А. Богородицкий җирле кадрлардан экспериментalistлар әзерләү өлкәсендә дә зур эш башкара.

В.А. Богородицкийның идеяләрен аның шәкерте Г. Шәрәф дәвам итә. Аның хезмәтләре бездә генә түгел, чит ил лингвистларына да яхшы мәгълүм. «Татар теле авазларының палятограммалары» исемле хезмәтендә Г. Шәрәф авазларның артикуляция үзенчелекләрен тикшерә. «Татар сузыкларының сонор озынлыклары» дип аталган икенче хезмәтендә автор В.А. Богородицкий башлаган эшне дәвам итә, кимографик язмаларның графикларына таянып, төрле фонетик позицияләрдә авазларның озынлыклары ничек үзгәрүен билгели, басымның һәм иҗек төренең аваз озынлыгына тәэсирен ачыклый.

Р. Шакированың «Хәзерге татар теле фонетикасына кереш» исемле китабы татар теленең авазларын тасвирлаучы беренче монографик хезмәт булып тора. Биредә беренче тапкыр авазлар фонологик яктан

карала башлыйлар, аваз үзгәрешләренең төрләре билгеләнә, интонациянең кайбер мәсьәләләре яктыртыла. Ләкин монда фонетик фактлар ишетүгә генә нигезләнеп аңлатылалар, Г. Шәрәф һәм башка фонетист-эксперименталистларның тикшеренүләре искә алынмый. Соңрак шул ук автор югары уку йортлары өчен язылган татар теле дәреслегенең «Фонетика» бүлеген әзерли. Анда инде ул авазларның классификациясенә җитди төзәтмәләр кертә.

Татар теленең фонетик системасын өйрәнүдә Ф.Г. Исхаковның хезмәтләре дә зур урын били. Бу автор татар теленең фонемалар системасына төгәллекләр кертә, татар телендәге сүз басымының закончалыкларын тикшерә.

Беркадәр өзеклектән соң татар фонетикасында эксперименталь ысулларны Ү.Ш. Байчура куллана. Аның «Татар теленең аваз төзелеше» исемле монографиясе, тел белгечләре фикеренчә, фонетистлар таяна алырлык, чын мәгънәсендә фәнни чыганак булып тора. Теоретик яктан караганда, хезмәтнең беренче кисәге аеруча кызыклы. Анда фонемаларны аерып алу критерийлары бирелә, шулар нигезендә татар теленең фонемалар составы ачыклана. Рентген сурәтләре һәм палатограммалар ярдәмендә татар теленең вокализмы һәм консонантизмы тасвирлана. Эксперименталь мәгълүматларга нигезләнеп, татар авазлары чуваш, хакас, казакъ һәм башка телләрнең авазлары белән чагыштырыла. Хезмәтнең икенче кисәгендә аваз үзгәрешләре, тартыкларның акустик билгеләре, сүз басымының үзенчәлекләре кебек мәсьәләләр карала. Ахырда рентгенограммалар, палатограммалар, кимограммалар, таблицалар, схемалар рәвешендә бай иллюстратив материал бирелә.

Ә.Ш. Әфләтуновның «Хәзерге татар теленең фонетикасы» исемле зур булмаган хезмәте дә игътибарга лаек. Биредә кыскача гына формада авазларга характеристика бирелә, позицион аваз үзгәрешләре тасвирлана, интонация мәсьәләләре карала.

1969 елда рус телендә басылган «Хәзерге татар әдәби теле» исемле китапта да татар теленең фонетик системасы тулы гына яктыртылган. Бу китапның «Фонетика» бүлеге Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан төзелгән.

Татар фонетикасының зур булмаган, ләкин шактый тулы тасвирламасы «СССР халыкларының телләре» исемле җыентыкта да бар, «Та-

тар теле» бүлеге, шул исәптән аның фонетикасын тасвирлау М.З. Зәкиев тарафыннан эшләнгән.

«Төрки телләрнең тарихи-чагыштырма грамматикасы. Фонетика» исемле хезмәттә дә татар фонетикасының күп мәсьәләләре яктыртылган. Анда татар теленең вокализмы буенча А.А. Юлдашев китергән мәгълүматлар аеруча кызыклы. Дөрес, авторларның татар теленең фонемалар системасын билгеләүдәге кайбер фикерләре белән килешеп бетеп булмый, аның каравы бу хезмәт татар теленең тарихи фонетикасын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Татар фонетикасына багышланган иң соңгы хезмәтләрдән Х.Х. Сәлимовның тикшеренүләрен атарга була. Автор, беренче мәртәбә спектраль анализ методын кулланып, татар вокализмын тикшерә, алынган мәгълүматларга таянып, татар сузыкларын акустик яктан тасвирлый, аларны рус һәм кайбер төрки телләрнең авазлары белән чагыштыра, комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләренең төрләрен ачыклый. Шул ук автор тарафыннан татар теленең беренче орфоэпик сүзлеге төзелә, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен фонетика буенча кулланмалар языла.

Татар фонетикасына күпмедер өлеш керткән чит ил лингвистларыннан Н. Поппены атарга була. Ул үзенең инглиз телендә басылган китабында татар теленең фонетик системасын инглиз, швед, норвег, немец, гарәп телләре белән чагыштыра.

Татар фонетикасының кайбер аерым мәсьәләләре төрле хезмәтләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, татар һәм рус телләренең фонетик системаларын чагыштыру, В.А. Богородицкийдан ук башланып, Р.С. Газизов, З.М. Вәлиуллина, Ф.С. Фасиев, Ә.М. Ахунҗанов хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Д.Х. Бакеева хезмәтләрендә татар һәм инглиз телләренең фонетик системалары чагыштырыла. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча Л. Җәләй башлаган тикшеренүләрне Л.И. Яфаров һәм В.Х. Хаков дәвам итә. Диалекталь фонетика буенча бик кызыклы күзәтүләр Л. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Д.Г. Тумашева, Ф.Й. Йосыпов, Г.Ф. Саттаров тарафыннан ясала. Татар теленең графикасы, орфографиясе, орфоэпиясе мәсьәләләре Л. Җәләй, Х. Курбатов, Б.М. Мифтахов хезмәтләрендә яктыртыла.

Шулай итеп, татар фонетикасы хәзерге заман лингвистикасының казанышларына һәм бай традицияләренә таянып үсә бара.

## 1.1. ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АВАЗ ТӨЗЕЛЕШЕ

Авазлар системасы ул бик катлаулы күренеш, һәм аны өч аспекттан чыгып карарга кирәк.

Аваз берәмлекләренең ясалуы сөйләм органнары белән идарә итүче үзәк нерв системасының функциясе булганга күрә, авазлар кеше организмы эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе буларак каралалар. Бу – артикуляцион (яки биологик) аспект. Икенчедән, табигатьтәге теләсә нинди тавыш кебек үк, сөйләм авазлары да нинди дә булса җисемнең тирбәнүе нәтиҗәсендә барлыкка киләләр, ягъни физик күренеш булып торалар, млнысы аларның акустик (яки физик) аспекты була. Һәм, өченчедән, алар төрле мәгънәви берәмлекләрне (сүз, морфема, һ.б.) оештыралар, ягъни аралашу, фикерләребезне белдерү өчен хезмәт итәләр, моннан исә аларның өченче иң мөһим аспекты – лингвистик (яки функциональ) аспекты килеп чыга.

Тел белемендә сөйләм авазларын язуда күрсәтү өчен орфографик язудан беркадәр аерыла торган махсус язу системасы кулланыла. Бу язу фонетик транскрипция дип атала. Биредә кулланыла торган транскрипциядә татар алфавиты хәрефләре файдаланыла, аларга кайбер хәрефләр һәм тамгалар өстелә. Транскрипцияләнүче сүзләр, яки аларның аерым өлешләре, шулай ук аерым авазлар – квадрат җәяләр, ә фонемалар туры җәяләр эченә алына. Сузыклар һәм тартыклар өчен түбәндәге хәрефләр өстәлә: [қ], [ғ] – увуляр тартыклар, [ʿ] – бугаз тартыгы «һәмзә», [$^{т}$ч] – аффрикат [ч]. Тагын түбәндәге диакритик тамгалар өстәлә: тартык авазны белдерүче хәрефнең уң ягында өстәге өтер тартыкның нечкәлеген белдерә, мәсәлән, [т’], [р’]; хәреф өстендәге горизонталь сызыкча сузыкның һәм тартыкның озынлыгын белдерә, ә [ō], [ы̄], [ē] тамгалары өстәвенә аларның рус теленнән кергән сузыклар икәнлегенә ишарә ясый; аваз хәрефенең уң як өстендәге кечкенә хәрефләр аларның дифтонгоид булып әйтелүен күрсәтәләр, мәсәлән, [у$^{w}$], [и$^{й}$], [а$^{э}$]; сүзләр арасына юл астына куелган дуга бер фонетик сүз тәшкил итүче ике сүзнең кушылып әйтелүен белдерә, мәсәлән, [ба$^{о}$р‿инде]; кыек сызык (/) – тексттагы синтагма чикләрен, ике параллель сызык (//) җөмлә чикләрен күрсәтә.

## 1.2. АВАЗЛАРНЫҢ АРТИКУЛЯЦИОН БИЛГЕЛӘРЕ

Кешенең сөйләм аппараты түбәндәге органнардан тора: тын алу органнары (үпкәләр, бронхлар, трахея), тавыш ярылары урнашкан бугаз; тамак, авыз һәм борын куышлыклары, йомшак һәм каты аңкау, альвеолалар (теш казналары), тел, кече тел, тешләр, иреннәр. Тартыкларның һәм сузыкларның артикуляцион билгеләре бер-берсеннән бик нык аерыла.



1 нче рәсем.
—— [и], - - - - [у]

Хәзерге татар әдәби телендә тугыз сузык аваз бар. Алардан башка бары рус теленнән кергән алынма сүзләрдә генә тагын өч сузык аваз кулланыла: [а], [ә], [у], [ү], [о], [ө], [ы], [е], [и],[ы̄], [ō], [ē]. Бу сузыклар рәт (телнең горизонталь хәрәкәте буенча), күтәрелеш (телнең вертикаль хәрәкәте буенча), иренләшү буенча аерылалар.

Рәт буенча сузыклар алгы рәт сузыкларына – [ә], [ү], [е], [ө], [и], [ē] һәм арткы рәт сузыкларына – [а], [у], [о], [ы], [ы̄], [ō] бүленәләр. Алгы рәт сузыкларын әйткәндә, тел авыз куышлыгының алгы өлешенә килә, ә арткы рәт сузыкларын әйткәндә, артка таба тартыла (1 нче рәсем).

Күтәрелеш буенча сузыклар югары күтәрелеш – [и], [у], [ү], [ы̄], урта күтәрелеш [о], [ө], [е], [ы], [ō], [ē] һәм түбән күтәрелеш [а], [ә] сузыкларына бүленәләр. Югары күтәрелеш сузыкларын әйткәндә, тел йомшак аңкауга таба күтәрелә, ә түбән күтәрелеш сузыкларын әйткәндә, киресенчә, түбәнгә таба төшеп тора (2 нче рәсем).



2 нче рәсем.
—— [и], - - - - [е],
. . . . . [ә]

Иреннәрнең катнашуы буенча сузыклар и р е н л ә ш к ә н – [у], [о], [ү], [ө], [ō] һәм и р е н л ә ш м ә г ә н – [а], [ә], [ы], [е], [и], [ē], [ы̄] сузыкларга бүленәләр. Беренчеләрен әйткәндә, иреннәр түгәрәкләнеп алга таба сузылалар, ә икенчеләрен әйткәндә, авазның ясалышына актив катнашмыйлар.

Сузыкларның артикуляцион классификациясе 1 нче таблицада бирелә.

*1 нче таблица*

| Күтәрелеш | Рәт | |
|---|---|---|
| | Алгы | Арткы |
| Югары | [и] [Ү] | [ы̄] [У] |
| Урта | [е] [ē] [Ө] | [О] [ы] [Ō] |
| Түбән | [ә] | [а] |

Искәрмә. Зур хәрефләр белән иренләшкән сузыклар белдерелә.

Хәзерге татар әдәби телендә егерме алты тартык аваз бар. Алынма сүзләрдә һәм диалектларда тагын биш тартык аваз очрый – [ц], [$^{т}$*ч*], [щ], [в], [х].

Тартык авазларга артикуляцион классификация ясаганда, аларның ясалу урынына, ысулына һәм тавыш ярыларының эшчәнлегенә игътибар итәләр.

Тартыкларны ясалу урыны буенча төркемләгәндә, үпкәдән килүче һава агымына сөйләм аппаратының кайсы урынында тоткарлык ясалу күздә тотыла. Бу яктан тартык авазлар түбәндәге төркемнәргә бүленәләр:

– и р е н - и р е н тартыклары ([б], [п], [м], [w]), аларны әйткәндә, аскы һәм өске иреннәр бер-берсенә таба хәрәкәт итәләр (3 нче рәсем);

– и р е н - т е ш тартыклары ([ф], [в]), аларны әйткәндә, аскы ирен өске кискеч тешләргә таба хәрәкәт итә (4 нче рәсем);



3 нче рәсем



4 нче рәсем

– т е л а л д ы тартыклары ([т], [д], [н], [с], [з], [ч], [ж], [ш], |щ], [л], [р], [ц], [ж]) бу авазларны әйткәндә, телнең алгы өлеше өске тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә (5 нче рәсем);



5 нче рәсем



6 нчы рәсем

– т е л  у р т а с ы тартыгы [й], аны әйткәндә, телнең уртасы каты аңкауга таба күтәрелә (6 нчы рәсем);

– т е л  а р т ы тартыклары ([к], [г], [х’], [ң’]), алар ясалганда, телнең арткы өлеше йомшак аңкауга таба күтәрелә (7 нче рәсем);

– к е ч е  т е л тартыклары, яки увуляр тартыклар, ([қ], [ғ], [х], [ң], болар ясалганда, кече тел белән телнең арткы өлеше бер-берсенә якынаялар (8 нче рәсем);



7 нче рәсем



8 нче рәсем

– й о т к ы л ы к тартыгы, яки фарингаль тартык [h], йоткылык стеналарының тараюы һәм шулар аша көчле итеп һава өреп чыгару юлы белән ясала;

– б у г а з тартыгы, яки л а р и н г а л ь тартык [ʿ] «һәмзә», бу аваз бугазда тавыш ярыларының йомылуы һәм кисәк кенә ачылып китүе нәтиҗәсендә ясала.

Ясалу ысулы, ягъни һава агымына тоткарлыкның ничек ясалуына карап, тартыклар йомык, өрелмәле, ярымйомык һәм калтыраулы булалар.

Өрелмәле (фрикатив) тартыклар ясалганда, сөйләм аппаратының берәр урынында тарайган урын, ярык була; һава агымы шул ярыкның стеналарына ышкылып үткәндә, турбулентлы һава өермәсе нәтиҗәсендә аваз барлыкка килә. Өрелмәле тартыклар бер фокуслы ([ф], [в], [с], [з], [х], [г], [w], [h], [ж], [ʿ], [й]) һәм ике фокуслы ([ш], [щ], [ж]) булалар. Бер фокуслыларны әйткәндә, һава агымы бер генә тарайган урын (фокус) аша үтә (9 нчы рәсем), ә ике фокуслылар берьюлы ике урыннан һава өрелеп чыгу нәтиҗәсендә ясалалар (10 нчы рәсем).



9 нчы рәсем



10 нчы рәсем



11 нче рәсем

Йомык тартыклар ясалганда, сөйләм органнарының берәрсе тулысынча йомыла һәм үпкәдән килүче һава агымы тәэсирендә кисәк кенә ачылып китә. Әгәр йомылу тулысынча ачылып китсә, саф йомык тартыклар ([п], [б], [т], [д], [к], [ķ],[г], [ʿ]) ясалалар. Әгәр йомылудан соң өрелү этабы башланып, сөйләм органнары шуннан соң гына ачылып бетсәләр, аффрикат тартыклар ([ц], [$^{т}$ч]) барлыкка килә.

Я р ы м й о м ы к тартыклар ясалганда, сөйләм аппаратының бер урынында йомылу була, шул ук вакытта икенче бер урында һава үтү өчен урын кала. Ярымйомык тартыкларны әйткәндә, һава борын аша үтсә, аларны борын тартыклары дип ([м], [н], [ң]) атыйлар; әгәр телнең очы өске тешләргә тиеп, һава агымы телнең ян-ягыннан үтсә, ян-як тартыклары дип ([л]) атыйлар.

К а л т ы р а у л ы тартыкларны әйткәндә телнең очы югарыга күтәрелә һәм һава агымы тәэсирендә калтыранып тора, шулай итеп [р] тартыгы ясала (11 нче рәсем).

Тавыш ярыларының катнашу-катнашмавына карап, тартыклар яңгырау һәм саңгырау булалар. Саңгырау тартыкларны (№1, [с], [х],[h], [п], [ч], [т], [к], [ш], [к.], [ц], [ч], [щ], [ʿ] әйткәндә, тавыш ярылары

тибрәнмиләр тавыш катнашмый; ә яңгырау тартыкларны ([б], [д], [в], [w], [з], [ж], [җ], [г], [ғ], [р], [н], [ң], [й], [л]) әйткәндә, тавыш ярылары тирбәлеп тавыш чыгаралар. Татар телендәге тартык авазларның артикуляцион характеристикалары 2 нче таблицада күрсәтелгән.

*2 нче таблица*

<table>
<tr><td colspan="2" rowspan="4">Ясалу ысулы</td><td colspan="6">Ясалу урыны</td><td rowspan="4">Кече тел (увуляр)</td><td rowspan="4">Йотклык (фарингаль)</td><td rowspan="4">Бугаз (ларингаль)</td><td colspan="2" rowspan="4">Акустик аспект</td></tr>
<tr><td colspan="2">ирен</td><td colspan="4">тел</td></tr>
<tr><td rowspan="2">ирен-ирен</td><td rowspan="2">ирен-теш</td><td colspan="2">тел алды</td><td rowspan="2">тел уртасы</td><td rowspan="2">тел арты</td></tr>
<tr><td>тел-теш</td><td>тел-аңкау</td></tr>
<tr><td rowspan="3">йомык</td><td rowspan="2">саф.</td><td>б</td><td></td><td>д</td><td></td><td></td><td>г</td><td></td><td></td><td></td><td rowspan="7">шаулы</td><td>яңг.</td></tr>
<tr><td>п</td><td></td><td>т</td><td></td><td></td><td>к</td><td>қ</td><td></td><td></td><td rowspan="3">саңгырау</td></tr>
<tr><td>аффр.</td><td></td><td></td><td>(ц)</td><td>($^{т}$ч)</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2" rowspan="3">өрелмәле</td><td></td><td>ф</td><td>с</td><td>ч<br>ш<br>(щ)</td><td></td><td>(х)</td><td>х</td><td>һ</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>(в)</td><td>з</td><td>җ<br>ж</td><td></td><td></td><td>г</td><td></td><td></td><td rowspan="6">яңгырау</td></tr>
<tr><td>w</td><td></td><td></td><td></td><td>й</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2" rowspan="2">ярым-йомык</td><td>борын</td><td>м</td><td></td><td>н</td><td></td><td>ң’</td><td>н</td><td></td><td></td><td rowspan="3">сонор</td></tr>
<tr><td>ян-як</td><td></td><td></td><td>л</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">калтыраулы</td><td></td><td></td><td></td><td>р</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Искәрмә. Җәяләр эчендә күрсәтелгән тартыклар – алынма сүзләрдә һәм диалектларда гына очрый торган авазлар.

## 1.3. АВАЗЛАРНЫҢ АКУСТИК БИЛГЕЛӘРЕ

Акустик яктан сөйләм авазларының түбәндәге билгеләрен күрсәтергә була: тон һәм шауның катнашу дәрәҗәсе, тавышның югарылыгы, көче, тембры һәм озынлыгы.

Т о н – тигез озынлыктагы даими тирбәнешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән тавыш. Тон (яки тавыш) чыганагы булып тавыш ярылары хезмәт итә. Ш а у – сөйләм органнарының ритмик булмаган, тәртипсез тирбәнешләре нәтиҗәсе, шулай ук ул һава агымының сөйләм аппаратында ышкылуы, шартлавы аркасында да туарга мөмкин.

Авазның ю г а р ы л ы г ы тавыш ярыларының тирбәнешләр санына бәйле була һәм герцлар белән үлчәнә; герцлар күбрәк булган саен, тавыш югарырак дигән сүз. Авазның көче, яки интенсивлык тавыш ярылары тирбәнешләренең амплитудасына бәйле, ул децибел дигән берәмлек белән үлчәнә. Авазның озынлыгы авазны әйтү өчен сарыф ителгән вакытка бәйләнгән. Аваз озынлыгы миллисекундлар белән үлчәнә. Авазның тембры тавыш ярыларының аерым өлешләре тирбәнүдән туган өстәмә тоннарга (обертоннарга) бәйле була.

Акустик яктан сузык һәм тартык авазлар тон һәм шауның катнашу-катнашмавы белән аерылалар. Сузык авазлар, нигездә, бары тоннан гына торалар, ә тартыкларны әйткәндә шау да катнаша.

**Сузык авазларның акустик характеристикалары.** Кайбер телләрдә сузыкларның озынлыгы фонологик роль башкара, ягъни озын һәм кыска сузыклар сүзләрнең мәгънәләрен аера алалар. Татар телендә сузык авазларның озынлыклары андый роль уйнамый. Шулай да микъдари озынлыклары буенча татар теленең сузык авазларын ике төркемгә бүлеп була: чагыштырмача кыска ([о], [ө], [ы], [е]) һәм чагыштырмача озын сузыклар ([а], [ә], [у], [ү], [и), [ō], [ы̄], [ē]).

Дөрес, эксперименталь тикшеренү нәтиҗәләре буенча, бу ике төркем сузыкларының озынлыклары арасында аерма зур түгел. Ләкин татар теленең вокализм системасына ([ō], [ы̄], [ē]) алынма сузыкларын да кертеп караганда, әлеге аерманың әһәмияте арта, чөнки [о] һәм [ō], [е] һәм [ē] фонемаларын аеручы бердәнбер дифференциаль билге ул – озынлык. Өстәвенә чагыштырмача кыска сузыклар редукциягә дә бик җиңел биреләләр.

Сузык авазларның икенче бик әһәмиятле акустик характеристикасы ул – тембр, яки аларның формант структурасы. Тамакта, тавыш ярыларында барлыкка килгән тавыш, сөйләм органнары аша үткәндә, аваз булып формалаша. Тамак, авыз, борын куышлыклары резонатор функциясен башкаралар – кайбер ешлыктагы тирбәнешләрне көчәйтәләр, икенчеләрен исә зәгыйфьләндерәләр. Резонаторлар тарафыннан көчәйтелгән ешлык өлкәләре формантлар дип аталар. Формантлар һәм формантара өлкәләрнең җыелмасы сөйләм авазларының спектрын барлыкка китерә. Авазның спектрында берничә формант була, тик лингвистика өчен беренче ике формант аеруча әһәмиятле,

ә калган формантлар сөйләүченең индивидуаль үзенчәлекләрен һәм башка билгеләрен генә чагылдыралар. Ә беренче ике формант белән авазның артикуляциясе арасында турыдан-туры бәйләнеш бар: беренче формант – F1 телнең күтәрелеше белән бәйләнгән, тел югарырак күтәрелгән саен, беренче формант түбәнрәк ешлыкларда урнашкан була, һәм, киресенчә, түбән күтәрешле сузыкларның беренче форманты югарырак ешлыкларда була. Мәсәлән, түбән күтәрелеш сузыгы [ә] нең беренче форманты F1=400–640 гц, ә югары күтәрелеш сузыгы [и] нең Fl=240–350 гц. Икенче формант телнең горизонталь хәрәкәте белән бәйле. Тел алгарак килгән саен, икенче формантның ешлыгы зурая, ә арткы рәт сузыкларын әйткәндә, киресенчә, икенче формант түбәнрәк ешлыкларда була. Мәсәлән, арткы рәт сузыгы [а] авазының икенче форманты F2=780–1100 гц, алгы рәт [ә] авазында F2=1670–2400 гц.

Формантларның мәгълүматлары нигезендә авазларга классификация ясарга, бер телнең авазларын икенче телнекеләр белән чагыштырып карарга, төрле аваз үзгәрешләрен күзәтергә мөмкин. Татар сузыкларының формант ешлыклары 3 нче таблицада бирелә.

*3 нче таблица*

| Сузык аваз | F1 | F2 |
|---|---|---|
| [а] | 460–700 | 780–1100 |
| [ә] | 400–640 | 1670–240 |
| [у] | 240–400 | 520–750 |
| [ү] | 230–350 | 1240–1950 |
| [ol | 340–550 | 780–1160 |
| [ө] | 270–440 | 1290–2160 |
| [ы] | 370–580 | 990–1380 |
| [е] | 310–500 | 1700–2650 |
| [и] | 240–350 | 2100–3000 |
| [ы][1] | 300 | 1480 |
| [ō] | 500 | 780 |
| [ē] | 440 | 1800 |

**Тартык авазларның акустик характеристикалары.** Акустик яктан тартык авазлар тон һәм шауның катнашу дәрәҗәсе буенча аерылалар. Бу яктан тартыклар шаулыларга һәм сонантларга бүленәләр. Сонант (яки сонор) тартыкларны әйткәндә тон, шауга караганда, күбрәк катнаша, бу яктан алар сузыкларга якын торалар. Татар телендә сонантлар җидәү: [р], [м], [й], [н], [ң], [w], [л]. [й] һәм [w]сонантларын кайвакыт ярымсузыклар дип тә йөртәләр.

Шаулы тартыкларны әйткәндә, шау тонга караганда күбрәк катнаша, яки алар бары шаудан гына да торырга мөмкин. Болар – [б], [п],

[1] Алынма сузыкларның формантлары Г. Фант буенча бирелә.

[в], [ф], [д], [т], [з], [с], [ж], [ш], [ж], [ч], [$^{\text{т}}$ч], [щ], [г], [к], [ғ], [қ], [ц], [х], [һ], тартыклары. Шаулы тартыклар саңгырау да яңгырау да булырга мөмкин. Яңгырау тартыкларны әйткәндә, тон катнаша, ә саңгырауларда – юк. Яңгырау тартыкларга сонантлар да керә (12 нче рәсем).

Сузыклар кебек үк тартык авазлар да төрле позициядә төрле озынлыкта әйтеләләр. Бу яктан караганда, [щ] фонемасы турында аерым әйтеп үтәргә кирәк. Рус фонетикасында бу фонеманы [ш] дан аеручы дифференциаль билгеләр итеп беренчесенең палаталь һәм озын булуы күрсәтелә. Татар телендә тартыкларның палатальлеге фонематик роль башкармый, шулай булгач, [щ] ның озын булуы аны [ш], [ч] өрелмәле тартыкларыннан аеручы бердәнбер билге булып кала.




12 нче рәсем.
– тон, – шау

#### 1.4. ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АВАЗ ТЕЗМӘЛӘРЕ

Татар телендә авазлар торле комбинацияләрдә килеп, төрле-төрле төзелмәләр барлыкка китерә алалар. Шул ук вакытта байтак кына чикләүләр дә бар. Аларның кайберләре сүз эчендә генә була, икенчеләре исә татар теленең үз сүзләрендә генә, кайберләре алынма сүзләрдә генә була ала.

Аваз төзелмәләрен түбәндәге тәртиптә карыйлар: сузыклардан торган төзелмәләр, сузыклар белән тартыклардан торган төзелмәләр һәм тартыклардан торган төзелмәләр.

**«Сузык + сузык» төзелмәләре.** Татар теленең үз сүзләрендә «сузык + сузык» тибындагы төзелмәләр очрамый диярлек[1]. Ләкин алар алынма сүзләрдә (*аут, какао, трио* һ.б.) һәм фонетик сүз эчендә (ә фонетик сүзләргә басымлы һәм аңа ияреп килгән басымсыз сүздән

[1] *Тау, дәү, куак, чүәк, сөюе* тибындагы сүзләр «сузык + сузык» төзелмәсенә мисал була алмыйлар, чөнки икенче компонент «у», «ү» булган очракларда бу хәрефләр [w] авазын белдерәләр: [та$^{\text{о}}$w], [дәw]. Ә [у], [ү] авазлары беренче компонент булганда, алар [w] элементы белән дифтонгоид булып әйтеләләр һәм әлеге тартык аваз элементы сузыкларга кушылырга мөмкинлек бирми: *куак* [ку$^{w}$ақ], *сөюе* [сөйү$^{w}$е] һ.б.

торучы кушылмалар да кирә) әгәр беренче сүз сузык авазга тәмамланып, икенчесе сузыкка башланса, шактый еш очрыйлар: *эшлә әле, кара инде.* Мондый очраклар сандхи дип аталалар. Сандхи вакытында өч төрле күренеш күзәтелә.

1. Ике сузыкның берсе төшеп кала (э л и з и я күренеше). Бу хәл бертөрле сузыклар очрашканда еш күзәтелә: *бара алмый* [ба$^{о}$ра́лмый], *түлә әле* [тү́ләле]. Компонентларның берсе чагыштырмача кыска сузык булганда да элизия күренеше була: *юкмы әллә?* [йу́кмәллә]. Очрашучы сузыкларның беренчесе [у], [ү], [и] авазлары булса, элизия булмый, чөнки, югарыда әйтелгәнчә, сүз ахырындагы [у], [ү], [и] авазлары дифтонгоид булып әйтеләләр, һәм аларның ахырындагы [w] яки [й] элементлары сузык авазларга кушылырга мөмкинлек бирмиләр, сузыклар икесе дә әйтеләләр: *ки инде* [ки́$^{й}$инде], *ку әле* [ку́$^{w}$әле]. Икенче төрле әйткәндә, биредә [у$^{w}$у], [ү$^{w}$ү], [ү$^{w}$а] һәм шуңа охшаш типтагы төзелмәләр килеп чыга.

2. Сузыклар төзелмәсе ике сузыкның синтезы булып та иштелергә мөмкин. Ике сузыкның билгеләре кушылып китә, ә суммада кайсы сузыкның билгеләре өстенлек итүе төрле шартларга бәйләнгән була. Беренчедән, төзелмәнең икенче сузыгы, беренчесенә караганда, көчлерәк йогынты ясый. Икенчедән, арткы һәм алгы рәт сузыклары очрашканда, арткы рәт сузыкларының билгеләре өстенлек итә. Өченчедән, киң һәм тар сузыклар очрашканда, урта күтәрелеш сузыклары барлыкка килә. Мәсәлән, *коры үлән* [ҡорулә́н] һ.б.

3. Әгәр төзелмәнең беренче компоненты [а], [ә] авазлары, икенче компоненты [у], [ү], [и] авазлары булса, соңгылары [w] яки [й] сонантлары булып әйтеләләр, ә төзелмә үзе [аw], [әw], [ай], [әй] тибындагы ялган дифтонг булып иштелә: *бара икән* [барайкә́н], *күрә иде* [күрә́йде] һ.б.

**Сузыкларның дистантлы төзелмәләре.** Татар телендә янәшә сузыкларның төзелмәләре белән бергә күрше иҗекләрдәге сузыкларның бергә килә алу закончалыклары да зур роль уйный: икенче иҗектәге сузык – беренче иҗектәгесенә, өченче иҗектәгесе икенче иҗектәгесенә һ.б. бәйләнгән була.

1. Төп закончалык – сузыкларның рәт буенча ярашулары, ягъни калган иҗектәге сузыкларның рәте беренче иҗектәге сузыкның рәтенә бәйле була. Бу турыда, ягъни сингармонизмның бер төре булган рәт

гармониясе турында алдарак, позицион аваз үзгәрешләре бүлегендә сүз булыр.

2. Сүзнең беренче иҗегендә татар теленең барлык сузыклары да кулланыла. Икенче иҗектәге сузыкның беренче иҗектәге авазга ничек бәйле булуы 4 нче таблицада күрсәтелгән.

*4 нче таблица*

| 2 иҗек | 1 иҗек | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | [а] | [ә] | [у] | [ү] | [о] | [ө] | [ы] | [е] | [и] |
| [а] | + | | + | | + | | + | | |
| [ә] | | + | | + | | + | | + | + |
| [у] | + | | + | | + | | + | | |
| [ү] | | + | | + | | + | | + | + |
| [о] | | | | | + | | | | |
| [ө] | | | | | | + | | | |
| [ы] | + | | + | | | | + | | |
| [е] | | + | | + | | | | + | + |
| [и] | | + | | + | | + | | + | + |

Таблицадан күренгәнчә:

а) [а] [у] сузыклары – барлык арткы рәт сузыкларыннан соң килә алалар;

б) [ы] сузыгы [а], [у], [ы] сузыкларыннан соң килә ала, ә [о] сузыгыннан соң кулланылса, ул иренләшә һәм [о] авазы белән чиратлаша: *борын* [бо-ро́н), [е] авазының кулланылышы да шуңа охшашлы, әлеге сузык [ә], [ү], [е], [и] авазларыннан соң килә ала, ә [ө] сузыгыннан соң кулланылса, ул да [ө] авазы белән чиратлаша: *ботен* [бөте́н];

в) [о] сузыгы икенче иҗектә бары [о] авазыннан соң, [ы] ның иренләшүе нәтиҗәсендә генә очрый, ә [ө] авазы да бары [ө] дән соң гына, [е] нең иренләшү нәтиҗәсе буларак кына кулланыла ала;

г) саф татар сүзләренең тамырларында сузыкларның күрше иҗекләрдә бергә килә алулары тагын да ныграк чикләнгән, [у] һәм [ү] сузыклары тамырның икенче иҗегендә бөтенләй кулланылмый диярлек. Аларның [а] һәм [ә] сузыкларыннан соң сирәк кенә килә торган очраклары (*матур, аю, бәллүр* һ.б.) чыгарма гына була ала. [и] сузыгы да икенче иҗектә бик сирәк, анда да [е] һәм [ә] сузыкларыннан соң гына кулланыла: *әти, әби, черки* һ.б.

3. Өченче иҗектәге сузыкларның беренче иҗектәгеләргә бәйлелеге югарыда күрсәтелгән закончалыкларга туры килә. Ә өченче иҗектәге сузыкларның икенче иҗектәгеләргә бәйлелеге бүтәнчәрәк, һәм ул 5 нче

*5 нче таблица*

| 3 иҗек | 2 иҗек | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | [а] | [ә] | [у] | [ү] | [о] | [е] | [ы] | [е] | [и] |
| [а] | + | | + | | + | | + | | |
| [ә] | | + | | + | | + | | + | + |
| [у] | + | | | | + | | + | | |
| [ү] | | + | | | | + | | + | |
| [0] | | | | | + | | | | |
| [ө] | | | | | | + | | | |
| [ы] | + | | + | | | | + | | |
| [е] | | + | | + | | | | + | + |
| [и] | | + | | | | + | | + | |

таблицада күрсәтелгән. Таблицадан күренгәнчә, яңа чикләүләр өстәлә:

а) [у], [ү] сузыклары икенче иҗектә очрасалар, алар инде өченче иҗектә килә алмыйлар:

б) саф татар сүзләренең тамырында өченче иҗектә кулланылучы сузыклар тагын да азрак. Болар [а], [ә], [ы] һәм [е] сузыклары, өстәвенә алар рәтләренә бәйле рәвештә [а], [ы] һәм [ә], [е] сузыкларыннан соң гына кулланыла алалар: *карчыга, багана, тиглнәк, бәрәңге, караңгы, шикелле, сыерчык* һ.б.

**Тартыклар белән сузыклардан торган төзелмәләр.** Бу төрдәге төзелмәләр ике яклы булалар: «тартык+сузык» һәм «сузык+тартык» төзелмәләре. Биредә ике моментны истә тотарга кирәк: беренчедән, татар телендә сузык авазның тартыкларга тәэсире тартыкларның сузыкларга тәэсиреннән көчлерәк; икенчедән, сузыкларда иң зур үзгәрешләрне аларга кадәр килгән тартыклар ясый. Шуңа бәйле рәвештә сузыклар белән тартыкларның бергә килә алуына иң беренче чикләүне күрсәтергә кирәк: алгы рәт сузыклары янында – тартыкларның бары йомшак (палаталь) вариантлары гына, ә арткы рәт сузыклары янында тартыкларның каты (веляр) вариантлары гына килә ала. Чыгармалар бары ике сүз чигендә, кушма сүзләрдә һәм алынмаларда гына очрый – тартык авазның бер күршесе – алгы рәт сузыгы, икенчесе арткы рәт сузыгы була ала. Мәсәлән, *ит ашый, бик олы*, *китап* һ.б.

Төзелмәләрнең төрләрен тикшерү шуны күрсәтә, «тартык+сузык» тибындагы төзелмәләр «сузык+тартык» тибындагылардан күбрәк. Беренчеләре – 200 ләп, икенчеләре 180 ләп төрдә очрыйлар. Шунысын әйтергә кирәк, күп телләрдә «тартык+сузык» тибындагы иң гади артикуляр комплекслар сөйләмнең төп элементлары булып торалар, бу исә төрле типтагы иҗекләрнең кулланылу активлыгына да бәйләнгән була.

Татар телендә ТС («тартык+сузык») тибындагы иҗекләр СТ тибындагы иҗекләрдән ун тапкыр активрак. Шуның өстенә кайбер тартыклар ([б], [д], [ж], [г], [ғ]) «сузык + тартык» комбинациясендә үзләреннән соң сузык аваз яки [р] сонанты килсә генә очрыйлар. Мәсәлән, *таба, шадра, биегрәк, тугыз* һ.б.

Тартыкларның да сузыкларның да бергә килә алу дәрәҗәсе шактый нык аерыла.

Ике төрдәге төзелмәләрдә дә катнашу дәрәҗәсе буенча иң активы булып [ә] сузыгы тора. Ул [әҗ] дән башка барлык комбинацияләрдә килә ала. Шулай ук [а], [у], [и] сузыклары да барлык төзелмәләрдә дә диярлек очрыйлар. Әгәр сузыкларны төрле төзелмәләрдә кулланылу активлыклары буенча тезеп чыксаң, [ә], [а], [и], [у], [ө], [ы], [е], [о], [ү] рәте килеп чыга. Шунысын әйтергә кирәк, төрле комбинацияләрдә иң еш очрый торган [ә], [а], [и], [у] авазлары – татар теленең иң «контрастлы» сузыклары: түбән һәм югары күтәрелештәге иң алгы рәт сузыклары [ә] һәм [ и], иң арткы рәттәге түбән һәм югары күтәрелеш сузыклары [а] белән [у].

Татар теленең түбәндәге тартык авазлары барлык сузыклар белән һәм ике төрдәге төзелмәдә дә килә алалар: [п], [т], [з], [с], [ч], [ш], [р], [м], [н], [л]. Ә [б], [д], [ж], [ғ], [х], [й] тартыклары «тартык + сузык» тибындагы төзелмәләрдә генә барлык сузыклар белән дә килә алалар, [җ], [w], [ʿ] тартыклары белән исә сузыклар бик санаулы комбинацияләрдә генә очрыйлар: *аждаһа, җирәбә, а*[wы]*з, м*[āʿ]*май, мәс*[ʿә]*лә* һ.б. [г], [к] тартыклары гадәттә, алгы рәт сузыклары янында киләләр, ә арткы рәт сузыклары янында алынма сүзләрдә генә очрыйлар: *Камал, Шакир, гармун, зимагур* һ.б.

Шунысын әйтергә кирәк, ирен тартыклары, тел алды тартыклары, сонантлар сузык авазлар белән төрле комбинацияләр төзүдә башкалардан активрак катнашалар.

Әгәр төзелмәләрне сүзләрнең морфема төзелешләренә нисбәтән карасаң, түбәндәгеләр күренә:

1. Саф татар сүзләренең тамыры башында «тартык + сузык» төзелмәләре бик күп очрый, «[ң] + сузык» һәм «[ʿ] + сузык» төзелмәләре генә була алмый. Бу позициядә [б], [п], [д], [т], [с], [ч],[ш], [ж], [м], [н] тартыклары барлык сузыклар белән дә килә ала. [ф], [з], [г], [ҡ], [х], [һ], [й], [к], [г] тартыклары да барлык сузыклар белән диярлек ком-

бинация төзи алалар, [фү], [фө], [зү], [ғү], [ғе], [ке], [һү], [йи], [ко], [кы], [го], [гы] төзелмәләре генә була алмый, [л] тартыгы [ли] төзелмәсендә бөтенләй очрамый, башка комбинацияләрне, нигездә, аваз ияртемнәрендә һәм алынмаларда барлыкка китерә: [лы]*гырдау,* [лү]*с-лүс,* [лә]кин, [лө]*гать,* [ло]*кман,* [ла]пас һ.б. Шунысы кызык, төрле позицияләрдә сузыклар белән күп төрле комбинацияләр төзи торган [р], [w] сонантлары бу позициядә бик сирәк, нигездә, алынма сүзләрдә генә очрыйлар: [рә]*хим,* [рө]*хсәт,* [ри]*зык,* [wа]*кыт,* [wө]*җдан* һ.б.

Сүз тамырының башында [жа], [жү], [жо], [жы], [же] төзелмәләре очрамый, башка сузыклар белән комбинацияләре алынмаларда һәм аваз ияртемнәрендә күзәтелә: [жә]*лләү,* [жу]*лау,* [жи]*рәбә* һ.б.

2. Саф татар сүзләренең тамыры башында «сузык + тартык» төзелмәләрендә татар теленең барлык сузыклары да очрый. Дөрес, аларның активлык дәрәҗәсе төрлечә була. [а], [ә], [и] сузыклары барлык тартыклар белән диярлек бергә килә алалар, [әж], [аг], [ак], [и ], [иw] төзелмәләре генә очрамый, [у] да шактый актив, ул [уд], [уж], [уг], [ук], [уш] төзелмәләрен генә хасил итә алмый, [е] сузыгы катнашында ясала торган төзелмәләр иң азы, алар унау гына: [эт], [эз], [эч], [эш], [эһ], [эн]ә, [эл], [эс]се, [эр]*бет,* [эң]*гер.* [ү], [ы], [о], [ө] сузыклары бу позициядә 13–16 төзелмәдә күзәтеләләр.

Әйтергә кирәк, тамыр эчендә һәм морфемалар чигендә төрле төзелмәләр төзи торган күп кенә сузыклар сүз башында шундый ук комбинацияләрдә очрамыйлар. Мәсәлән, [ак], [үд], [үм], [об], [од], [оғ], [оқ], [оң], [өб], [өп], [өд], [өк], [өг], [өх], [ып], [ыф], [ыт], [ыж], [ый], [еф], [ек] һ.б.

Сузыклар белән тартыклардан торган төзелмәләрнең бер группасын аерым карарга кирәк. Болар – сузык аваздан һәм [й], [w] сонантларыннан торган төзелмәләр, икенче төрле әйткәндә, «ялган дифтонглар». Шунысын да әйтергә кирәк, татар телендә ике сузыкның бер иҗектә килүе, яки фонема ролен башкаручы чын дифтонглар юк, һәм югарыда әйтелгән төзелмәләрне еш кына дифтонглар дип атыйлар. Әлеге төзелмәләрдә, ягъни дифтонгларда, башта сузык, аннан [й] яки [w] сонанты килергә дә, киресенчә дә булырга мөмкин. Алдан сонантларның берсе, аннан сузык аваз килсә, ягъни авазлар тонның артуы, күтәрелүе тәртибендә урнашсалар, әлеге төзелмәләр – күтәрелмә дифтонглар дип, киресенчә урнашсалар, төшерелмә дифтонглар дип

аталалар. Күтәрелмә дифтонглар барысы 12: [йа], [йә], [йу], [йү], [йы], [йе], [йо], [йө], [wa], [wә], [wы], [we]. Төшерелмә дифтонглар 8: [ый], [ай], [әй], [уй], [ой], [өй], [aw], [әw]. Сүз ахырында әйтелә торган [у], [ү], [и] сузыкларын да төшерелмә дифтонгларга кертеп була, чөнки аларның ахырында да сонант элементлары ишетелә: [у$^{w}$], [ү$^{w}$], [и$^{й}$]. Татар теленең диалектларында [ыw], [еw], [оw], [өw], [ей] кебек тагын берничә төшерелмә дифтонг очрый.

Боларга өстәп, «сонант+сузык+сонант» тибындагы төзелмәләрне аерым күрсәтергә була, аларны трифтонглар дип йөртәләр. Татар әдәби телендә алар 8: [йаw], [йәw], [wай], [wәй], [йый], [йий], [йу$^{w}$], [йү$^{w}$]. Диалектларда аларга [йыw], [йеw], [йоw], [йай], [йәй] трифтонглары да өстәлә.

«Тартык + тартык» төзелмәләре. Иң элек шунысын билгеләп үтәргә кирәк, татар теленең фонетик үзенчәлеге буенча, сүз башында ике тартык янәшә килә алмый. Бу татар теленең үз сүзләренә карый. Шул сәбәп буенча татар теленә элегрәк кергән алынмаларның башында ике тартык булса, аларның йә алдына, йә уртасына протетик сузык аваз өстәп кабул ителгән: *стол* > *өстәл, крупа* > *көрпә* һ.б.

Мондый төзелмәләрнең сүз ахырында кулланылуы да бик чикле. Болар – кайбер сонантларның [т] тартыгы белән килгән очраклары ([рт], [лт], [нт], [йт]) һәм кайбер аваз ияртемнәрендә, йә образ ияртемнәрендә бик сирәк кенә очрый торган берничә төзелмә: *вы*[шт], *гө*[рс], *дө*[ңк], *пы*[рх]һ.б.

Ә инде сүз эчендә, бигрәк тә морфемалар чигендә тартыклар бик күп төрле комбинацияләрдә очрыйлар, аларның саны – 280 ләп. Шулай да тартыкларның янәшә килә алуларында яңгыраулык-саңгыраулык, ясалу урыны һәм башка билгеләр буенча төрле чикләүләр бар.

1. Сонантлардан гайре яңгырау тартыклар саңгыраулар алдында килә алмыйлар, андый позициядә килгән тартыклар саңгырау парлары белән чиратлашалар: *күзсез* > *кү*[сс]*ез, шөбһә* > *шө*[пһ]*ә, таҗчык* > *та*[чч]*ык* һ.б.

2. Ассимиляция нәтиҗәсе буларак, җанлы сөйләмдә тартыкларның тагын кайбер комбинацияләре була алмый:

а) [к], [г], [қ], [ғ] тартыкларыннан алда килә торган [н] тартыгы кече тел тартыгы [ң] яки аның тел арты варианты [ң’] белән чиратлаша (*тынган* > *ты*[*ңғ*]*ан, инкяр* > *и*[ң’к]*яр* һ.б.);

б) [б], [м] ирен-ирен тартыкларыннан алда килә торган [н] авазы ирен-ирен тартыгы [м] белән чиратлаша (унбер > *у*[мб]*ер* һ.б.;

в) [н], [м], [ң] борын тартыкларыннан соң килә торган [л] авазы борын тартыгы [н] белән чиратлаша (*төнлә* > *тө*[нн]*ә, тыңла* > *ты*[ңн]*а* һ.б.).

Калган тартыкларның бергә килә алуларын матрица рәвешендә күрсәтеп була (6 нчы таблица). Таблицадан күренгәнчә, компонентларның берәрсе сонант булган төзелмәләр аеруча күп, аларда сонор тартык башта да, ахырда да бер үк дәрәҗәдә еш очрый.

Бу типтагы комбинацияләр барлык төзелмәләрнең 45% ын тәшкил итәләр.

Шулай ук «Саңгырау тартык + саңгырау тартык» төзелмәләре дә шактый күп төрле: *та*[пк]*ыр, а*[тс]*ыз,* а[чт]ы һ.б.

«Яңгырау шаулы тартык + яңгырау шаулы тартык» төзелмәләренең күләме шактый чикләнгән: *ту*[зб]*аш, а*[жд]*аһа, мо*[ғҗ]*иза, та*[җд]*а* һ.б.

Ә инде «саңгырау шаулы тартык + яңгырау шаулы тартык» төзелмәләре гомумән бик аз очракларда гына, алынма сүзләрдә һәм кушма сүзләрдәге тамырлар арасында гына күзәтелә: *әли*[фб]*а, ма*[тб]*угат, а*[кб]*ур, ша*[һз]*әдә* һ.б.

*6 нчы таблица*

| II | I | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | б | п | w | ф | м | д | т | з | с | ч | җ | ш | ж | л | р | н | й | г | к | ғ | қ | х | ң | һ | ʼ |
| б | | | + | + | + | | + | + | + | | + | + | | + | + | | + | | + | | + | + | + | | |
| п | | + | | | + | | | | | | | | | + | + | | + | | | | | | | | |
| w | | | + | | | | | | | | | | | + | + | + | + | | | + | + | | | | |
| ф | | | + | + | + | | | | | | | + | | + | + | + | + | | | | | | | | |
| м | | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | + | + | + | + | | + | | + | + | + | + | + | + | + |
| д | | | + | | + | | | + | | | + | | + | + | + | + | + | | | | + | + | + | | |
| т | | + | | + | + | | + | | + | + | | + | | + | + | + | + | | + | | + | | | + | + |
| з | + | | + | | + | | | + | | | | | | + | + | + | + | | | | | | | | |
| с | | + | + | + | + | | + | | + | + | | + | | + | + | + | + | | + | | + | + | + | + | + |
| ч | | + | + | + | + | | + | | + | + | | + | | + | + | + | + | | + | | + | + | + | | |
| җ | | | | | | | | | | | | | | + | + | + | + | | | + | | | | | |
| ш | | + | + | | + | | | | | | | | | + | + | + | + | | | | + | + | | + | |
| ж | [ж] тартыклардан соң килә алмый | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| II | I | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | б | п | w | ф | м | д | т | з | с | ч | җ | ш | ж | л | р | н | й | г | к | ғ | қ | х | ң | һ | ʼ |
| л | + | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | + | + | + | + | | + | | + | + | + | + | + | + | + |
| р | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | |
| н | + | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | + | | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | + | + |
| й | | + | | + | | + | | | + | | | + | | + | + | + | + | | | | + | + | | + | |
| г | | | + | | + | | | + | | | | | | + | + | | + | | | | | | + | + | |
| к | | + | + | + | + | | + | | + | + | | + | | + | + | | + | | + | | | | + | | |
| ғ | + | | + | + | + | | | + | | | + | + | + | + | + | | + | | | | | | + | + | |
| қ | | + | + | + | + | | + | | + | + | | + | | + | + | | + | | | | + | | + | + | |
| х | | | + | | | | | | + | | | | | + | + | | + | | | | | | | | |
| ң | [ң] тартыклардан соң килә алмый | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| һ | | | | | + | | | + | | | | + | | + | + | + | + | | | | | | | | |
| ʼ | | | | | | | | | + | | | | | | + | | | | | | | | | | |

Шунысын да әйтергә кирәк, ике бер үк төрле тартык очрашканда алар бер озын тартык булып әйтеләләр: *иссә* > *и*[с̄]*ә, атта* > *а*[т̄]*а* һ.б.

**«Тартык + тартык + тартык» төзелмәләре.** Саф татар сүзләренең башында да, ахырында да өч тартык аваз янәшә килә алмый. Алар бары тамыр һәм кушымча арасында, анда да [рт], [лт], [нт], [йт] төзелмәләре янында килгән кайбер тартыклардан гыйбарәт булалар. Мондый төзелмәләр утызлап. Өченче компонент була ала торган тартыклар: [т], [с], [ч], [к], [ң], [р], [л], [м], [н]. Мәсәлән, ә[йтч]е, *та*[ртс]*а, сө*[ртк]*ән, ка*[йтқ]*ан, ка*[ртл]*ач, та*[ртм]*а, ә*[йтм]*ә, кө*[ртл]*ек* һ.б.

### 1.5. ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АВАЗ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ

Билгеле булганча, кешеләрнең сөйләме аерым авазларның билгеле бер тәртиптә тезелеп килүе генә түгел, ә аларның бер-берсенә ялганып туктаусыз агышы. Сөйләм агымында нинди аваз белән янәшә булуына, нинди фонетик шартларда килүенә карап, авазлар төрле үзгәрешләр кичерәләр.

Сәйләмдәге аваз үзгәрешләрен, ни сәбәпле булуларыннан чыгып, икегә бүлеп карыйлар: комбинатор үзгәрешләр – алар авазларның

бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка киләләр; позицион үзгәрешләр – болары авазларның сүздәге урынына, позициясенә мөнәсәбәтле рәвештә туалар.

Комбинатор үзгәрешләр үзләре өч төрле булалар: а с с и м и л я ц и я , ягъни авазларның бер-берсенә охшашланулары; а к к о м о д а ц и я , ягъни авазларның бер-берсенә җайлашулары; д и с с и м и л я ц и я , ягъни авазларның охшашсызланулары.

Ассимиляция һәм диссимиляция бертөрле авазлар арасында, ягъни сузыклар белән сузыклар, тартыклар белән тартыклар арасында бара. Аккомодация сузыклар белән тартыклар арасында бара.

Ассимиляцияне, иң элек, икегә бүлеп карыйлар: сузыклар ассимиляциясе һәм тартыклар ассимиляциясе. Төрле аспектлардан чыгып, ассимиляция тагын түбәндәгечә төркемләнә:

а) тәэсир итешүнең юнәлеше буенча бүленеш: әгәр аваз үзеннән соң килгән авазга тәэсир итеп, аны үзенә охшашландырса – т у р ы , яки прогрессив ассимиляция (*төнлә* > [төннә́]), әгәр үзеннән соң килгән аваз тәэсирендә үзе аңа охшашланса, к и р е , яки регрессив ассимиляция (*унбер* > [умбе́р]) дип атала;

б) тәэсир итешүнең нәтиҗәсе буенча бүленеш: әгәр аваз икенче аваз тәэсирендә үз билгеләрен югалтып, үзенә тәэсир иткән авазның билгеләрен алса – тулы ассимиляция (*көтеп* > [кө̆тө́п]), әгәр бер аваз икенчесенә берәр билгесе белән генә (рәт, ясалу урыны һ.б.) охшашланса, өлешчә ассимиляция (мәсәлән, ясалу урыны буенча: *алдынгы* > [а°лды̆ңғы́]) дип атала.

Тулы ассимиляция вакытында ике бертөрле аваздан бер озын аваз гына да калырга мөмкин: *күзсез* > [күс̄е́с];

в) авазларның янәшәдәшлеге буенча бүленеш: әгәр авазлар янәшә торып тәэсир итешсәләр, – янәшә, яки контактлы ассимиляция ([умбё́р]), бер яки берничә аваз аша торып тәэсир итешсәләр, арадаш, яки дистактлы ассимиляция ([кө̆тө́п]) дип аталалар.

Сузыклар ассимиляциясе ике очракта күзәтелә – сингармонизмга бәйле рәвештә һәм сандхи очракларында.

Сингармонизм, яки сузыклар гармониясе – барлык төрки телләр өчен дә диярлек (чуваш һәм үзбәк телләреннән башка) характерлы билге. Сингармонизмның ике төре бар – рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Рәт гармониясе – сузыкларның рәт буенча охшашлану-

лары, җайлашулары: әгәр сүзнең беренче иҗегендә арткы рәт сузыгы булса, калган иҗекләрдә дә сузыклар арткы рәттә була һәм киресенчә. Мәсәлән, *башкаручыларыбыз, үткәрмәделәр* һ.б. Бу күренешне тулы, өлешчә, арадаш ассимиляция дип карап була.

Түбәндәге очракларда рәт гармониясе сакланмый:

а) алынма сүзләрдә (*имтихан, галим, телефон, кофе*);

б) кушма сүзләрдә (*өчаяк, төнбоек, Илдус, Гөлнар*);

в) кайбер зат алмашлыкларында (*миңа, синңа*);

г) кайбер кушымчалар аркасында (*көлсу, улмыни*).

Татар телендә ирен гармониясенең эчтәлеге шуннан гыйбәрәт: әгәр сүзнең беренче иҗегендә иренләшкән [о], [ө] сузыклары булса, шуннан соңгы иҗекләрдә килүче [ы], [е] сузыклары иренләшеп, [о], [ө] булып әйтеләләр: *кол-ы* > [қоло́], *көт-еп* > [кө̆тө́п]. Монысын туры, тулы арадаш ассимиляция дип карарга мөмкин. Шунысын искәртергә кирәк, иренләштерү тәэсире икенче иҗектә генә көчле була, калган иҗекләрдә әлеге күренеш шактый зәгыйфьләнә. Иренләшкән [у], [ү] сузыкларының мондый ассимилятив үзлекләре булмый.

Этимологик яктан бер тамырга кайтып кала торган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр сингармоник параллельләр дип аталалар: *аз-әз, акрын-әкрен, бавыр-бәгырь, ана-әни, бәгланыш-бәйләнеш, чыкылдау-чекелдәү* һ.б.

Алынма сүзләр татар теленә кергәндә еш кына сингармонизмга буйсындырып кабул ителгәннәр: *скатерть > эскәтер, бревно > бүрәнә, мәкъсат > максат, дәстрүмал > тастымал* һ.б.

Сингармонизмның табигатен еш кына төрле сөйләм органнарының инертлыгы, «ялкаулыгы» белән аңлаталар. Тарихи яктан карагандa, алгы рәт сузыкларының активлашу тенденциясе турында да фикерләр бар. Моны телдәге экономия принцибы белән, алгы рәт сузыкларын әйтүнең җайлырак булуы белән аңлаталар.

Сандхи очракларында сузыкларда була торган үзгәрешләр турында сүз булган иде. Бары түбәндәге фактларны гына өстәргә була:

а) сандхи очракларында туры ассимиляция дә, кире ассимиляция дә күзәтелә, ләкин, экспериментлар күрсәтүенчә, регрессив ассимиляция көчлерәк чагылыш таба;

б) тулы ассимиляция дә, өлешчәсе дә булырга мөмкин; тулы ассимиляция нәтиҗәсендә еш кына озын аваз барлыкка килә (*чиста эш*

> [чистāш]), өлешчә ассимиляция нәтиҗәсендә «синтезланган» аваз барлыкка килә (*күзе очлы* > [күзө̆чло́]);

в) рәт буенча төрле сузыклар очрашканда, арткы рәт сузыклары көчлерәк тәэсир итәләр, иренләшкән һәм иренләшмәгән сузыклар очрашса – иренләшмәгәннәр, чагыштырмача озын һәм чагыштырмача кыска сузыклар очрашса, чагыштырмача озыннары «көчлерәк» булып чыга.

Татар телендә тартыклар ассимилляциясенең барлык төрләре дә очрый: туры (*көнләр > көннәр),* кире (*әнкәй* > [әңкә́й]), тулы (беренче мисал), өлешчә (икенче мисал). Тартыклар ассимиляциясенең тагын ике төрен аерып карарга кирәк: ясалу урыны буенча охшашлану һәм акустик охшашлану. Ясалу урыны буенча охшашлануга б о р ы н ассимиляциясе (борын тартыклары күршесендә кайбер тартыкларның борын тартыклары белән чиратлашуы, мәсәлән, *көнләр* > *көннәр*)*,* и р е н ассимиляциясе (ирен тартыклары күршесендә кайбер тартыкларның ирен тартыклары белән чиратлашуы мәсәлән, *унбиш* > [умби́ш]) к е ч е т е л , яки тел арты ассимиляциясе (тел арты яки кече тел тартыклары янәшәсендә [н] тартыгының [ң] яки [ң’] авазы белән чиратлашуы, мәсәлән, [әңкәй], [а°лды̆ңғы́]).

Акустик ассимиляция – тартыкларның яңгыраулык-саңгыраулык буенча охшашланулары. Ул ике төрле чагылыш таба:

а) саңгырау тартыклар тәэсирендә кайбер яңгырау тартыклар саңгыраулашалар: *тозсыз* [тŏссо́с], *таҗсыз* [та°чсы́с] һ.б. Моның нәтиҗәсендә кайбер кушымчаларның саңгырау тартыкка тәмамланган сүзләргә өстәлә торган яңа вариантлары барлыкка килгән: *-ты/-те, -та/-тә, -ка/-кә* һ.б.;

б) яңгырау тартыклар тәэсирендә кайбер саңгырау тартыклар яңгыраулашалар. Әдәби телдә бу күренеш беркадәр чикләнгән, бары [р] сонанты тәэсирендә [п], [к], [к] тартыкларының яңгыраулашуы гына күзәтелә: *ак-рак > аграк, сирәк-рәк >сирәгрәк, күп-рәк > күбрәк* һ.б. Диалектларда бу күренешнең бүтән очраклары да күзәтелә: *аж бар,* әд. *аш бар; ад бирде* әд. *ат бирде; көяндә,* әд. *көянтә* һ.б.

Диахроник һәм синхроник ассимиляцияне дә аерып карарга кирәк. Диахроник ассимиляция – ул тарихи процесс, аның нәтиҗәсендә, авазлар чиратлашып, яңа кушымчалар барлыкка килгән: *урман-лар > урманнар, баш-да > башта, күп-дән > күптән* һ.б. Диахроник

ассимиляция язуда да чагылыш таба. Синхроник ассимиляция – җанлы сөйләмдә авазларның охшашлануы: *тотып* >[тото́п], *тозсыз* > [тоссо́с], *унбер* > [умбе́р] һ.б.

Синхроник ассимиляция сөйләм стилендә орфоэпик норма буларак кабул ителә, ләкин язуда чагылыш тапмый.

Диссимиляция, яки охшашсызлану – азрак таралган күренеш. Күбрәк ул гади сөйләмдә, алынма сүзләрнең әйтелешендә чагылыш таба, сүздә татар теле өчен авыррак әйтелешле булган берәр аваз берничә мәртәбә кабатланса, ул авазларның берәрсе икенче, җиңелрәк әйтелешле аваз белән алыштырыла: *директор* > [диле́ктыр], *коридор* > [кылиду́р] һ.б.

Диалектларда бу хәл татар теленең үз сүзләрендә дә күзәтелә: *арырак* > *арлак, шашу* > *чашу* (ике фокуслы авыр артикуляцияле [ш] җиңелрәк [ч] белән алышынган). Диалектларда диссимиляция нәтиҗәсендә авыр әйтелешле аваз төшеп тә калырга мөмкин: *барырга* > *барыга, эчерергә* > *эчерегә* һ.б.

Диссимиляция туры да (*арырак* > *арлак*), кире дә (*секретарь* > *секлетарь*); янәшә дә (*зуррак* > *зурлак*), арадаш та (*шашкан* > *чашкан*) булырга мөмкин.

Диссимиляция нигездә тартык авазларга хас, ләкин *бүтүн* > *бөтен, тукуз* > *тугыз, рус* > *урус* > *урыс* тибындагы тарихи күчешләрне дә, мөгаен, сузыклар диссимиляциясе дип карап була торгандыр, чөнки югарыда әйтелгәнчә, сүз тамырында ике иҗектә [у] сузыгының килүе татар теле өчен хас күренеш түгел.

Диссимиляция, ассимиляциядән аермалы буларак, нормалаштырылмаган сөйләмгә (гади сөйләм, диалектлар, балалар сөйләме) хас һәм гадәттә орфоэпик норма буларак кабул ителми.

Аккомодация, нинди авазлар арасында булуына карап, сузыклар һәм тартыклар аккомодациясенә бүленә. Сузыклар аккомодациясе булганда янәшәдәге тартыклар тәэсирендә, сузыклар шуларның артикуляциясенә җайлашалар; тартыклар аккомодациясе булса, киресенчә, тартыклар үз янәшәсендәге сузыкларның артикуляциясенә җайлашалар.

Тартыклар аккомодациясе түбәндәгечә чагылыш таба: а) алгы рәт сузыклары янында тартыклар палатальләшәләр, йомшак әйтеләләр, ә арткы рәт сузыклары янында велярлашалар, каты әйтеләләр. Мәсәлән, [та$^{о}$л] сүзендә веляр, каты [т], [л] әйтелә, ә *тел* сүзендә алардан нык

кына аерыла торган палаталь, йомшак [т’], [л’] әйтелә. Палатальләшкән тартыкларның йомшак, «нечкә» булып ишетелүе менә нәрсәдән килеп чыга: аларны әйткәндә, тел әлеге тартыклар күршесендәге нечкә, алгы рәт сузыкларын әйткәндәге торышка якыная, шуның нәтиҗәсендә авыз резонаторы тарая, тон күтәрелә, югары, «нечкә» тавыш эффекты туа. Рус телендәге палаталь тартыклар белән чагыштырганда, татар телендәге тартыклар азрак «нечкәрәләр», палатальләшәләр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, татар әдәби телендә тартык авазның палатальлеге күршесендәге алгы рәт сузыгына бәйле булса, диалектларда ул мөстәкыйль билге дә булырга мөмкин: [ката] – [кат’а] – *кайта;* [барам] – [бар’ам] – *бәйрәм.*

б) әгәр [к], [қ], [п] тартыкларына тәмамланган сүзләргә сузык авазга башланган кушымча ялганса, ике сузык арасында калган әлеге тартыклар, шул сузыклар тәэсирендә яңгыраулашалар, мәсәлән, *ак-а > ага, түк-ә > түгә, төп-е > төбе* һ.б.

Шунысын да искәртергә кирәк, морфема эчендә сузыклар арасында «яңгыраулашмаган» [ң], [к], [п] тартыклары да очрый: *акыл, ике, апа* һ.б.

в) иренләшкән сузыклар күршесендә тартыклар иренләшеп әйтеләләр. Тартыкларга бигрәк тә үзләреннән соң килгән сузыклар нык тәэсир итә. Мәсәлән, [туп] сүзендәге [т] авазы [тын] сүзендәге [т] дан үзенең шактый нык иренләшеп әйтелүе белән аерылып тора. Бу регрессив аккомодациянең сәбәбе шунда: сөйләм органнары, [т] авазын әйткәндә үк, шуннан соң килә торган [у] сузыгын әйтергә әзерләнеп торалар.

Сузыклар аккомодациясе турында сөйләгәндә, иң элек шуны истә тотарга кирәк, тартыкларның үзләреннән соң килгән сузыкларга тәэсире үзләренә кадәр килгәннәренә тәэсиреннән көчлерәк, ягъни сузыкларның прогрессив аккомодациясе регрессив аккомодациядән көчлерәк.

Сузыклар аккомодациясе түбәндәгечә чагылыш таба:

а) ирен тартыкларыннан соң килгән сузыклар иренләшебрәк әйтеләләр. Мәсәлән, [ба$^{о}$р], [па$^{о}$р] сүзләрендәге [а] авазы [о] га охшаш әйтелә. Ирен тартыкларының күршесендәге сузыкларның иренләшүе – күп телләргә хас күренеш. Акустик яктан ул сузык авазның барлык форманталары да түбәнрәк ешлыкларга күчү белән характерлана. Артикуляцион яктан түбәндәгечә аңлатыла: иреннәр актив артикуля-

ция торышыннан нейтраль хәлгә кайтып өлгермиләр, һәм әлеге «иренләшү» төсмере шуннан соң килгән сузыкта да саклана;

б) тел алды тартыкларыннан соң килгән арткы рәт сузыклары, алгырак рәткә күчеп, нечкәрәк булып әйтеләләр. Акустик яктан бу күренеш сузык авазның икенче формантасы күтәрелүдә чагыла. Артикуляцион яктан ул шуның белән бәйләнгән: тел алды тартыгын әйткәндә тел югары – алгы позициядә була һәм сузык авазны әйтә башлаганда әле нейтраль торышка күчеп өлгермәгән була. [ж], [ч],[й] тартыкларыннан соң килә торган сузыкларның икенче форманталары иң югары була, димәк алар чагыштырмача иң алда әйтеләләр. Бу сузыкларның башлангыч этаплары аларның алгы рәт парларына охшаш ишетелә: [ж$^{е}$ыр], [ч$^{ү}$ук,], [й$^{ә}$ар] һ.б.

Сәбәбе – инде әйтелгәнчә, бу тартыклар белән алгы рәт сузыклары артикуляцияләренең якын булуында (13 нче рәсемне кара). Моңа охшаш күренешләр башка төрки телләрдә дә күзәтелә.



13 нче рәсем.
—— [е], - - - - [ж]

в) кече тел һәм тел арты тартыкларыннан соң килгән алгы рәт сузыгы арткырак рәттә һәм югарырак күтәрелештә әйтелә. Бу сузыкларның башлангыч өлешләре һәм яңгырашлары үзләренең формант структуралары белән арткы рәт парларына охшаган булалар: [қ$^{а}$әнәг$^{а}$ә́т], [х$^{о}$өрмә́] һ.б.

Увуляр тартыклардан соң килүче [и] авазы [ый] дифтонгы кебек ишетелә: [қ$^{ы}$ймә́т], [ғ$^{ы}$йле́м] һ.б. Шунысы кызык, татар орфографиясе кагыйдәләре буенча бу сузыклар язуда үзләренең калын парларын белдерүче хәрефләр аша биреләләр: [күwә́т] *куәт,* [қөдрә́т] *кодрәт,* [қәнәгә́т] *канәгать* һ.б.

Тел арты тартыклары да аналогик рәвештә тәэсир итәләр, аларның сузыкларны артка тарту көче генә азрак була;

г) борын тартыкларыннан соң килгән сузыклар «борынлашып» әйтеләләр. Акустик яктан бу беренче формантаның түбән төшүендә һәм спектрда борын тартыкларында була торган өстәмә форманта пәйда булу белән тәкъбир ителә.

Артикуляцион яктан исә болай аңлатыла: борын тартыгын әйткәндә, йомшак аңкау түбән төшкән була, үзеннән соң килә торган сузык-

ны әйткәндә дә ул әле күтәрелеп бетми, һәм тавышның бер өлеше борын аша үтә, өстәвенә сузык аваз таррак та килеп чыга (14 нче рәсем).

Шуның нәтиҗәсе буларак, беренче формантаның ешлыклары түбәнәя. Бу күренеш тә күп кенә телләрдә күзәтелә;



14 нче рәсем.
—— [н], - - - - сузыклар

д) шунысы күптән мәгълүм: күршесендәге тартык авазның йомык яки өрелмәле булуы сузык авазның сыйфатына да тәэсир итә. Йомык аваз күршесендәге сузык авазның спектры компактлырак була, бу, иң элек, беренче формантаның югары булу нәтиҗәсе. Йомык тартык күршесендәге сузыкларның шулай түбәнрәк күтәрешле булуы белән аңлатыла: йомык тартыкларны әйткәндә кискен һава этәрелеше барлыкка килә, нәтиҗәдә аскы теш казналары, өрелмәле тартыкларны әйткәндәгегә караганда, түбәнгәрәк төшеп китәләр. Бу исә күрше сузык авазның артикуляциясендә дә чагылыш таба;

е) яңгырау тартыктан соң килә торган сузык аваз (бигрәк тә аның башлангыч этабы), саңгырау тартык күршесенә караганда, югарырак күтәрелештә була. Сәбәп, күрәсең, сөйләм аппаратының киеренкелек дәрәҗәсендәдер. Һәр телдә дә яңгырау тартыклар саңгыраулардан көчсезрәк була. Саңгырау тартыкның көчлерәк артикуляция белән әйтелүе шуннан соң килә торган сузыкның киңрәк булуын тәэмин итә. Шунысы да бар, яңгырау тартыктан соң килә торган сузыкның озынлыгы саңгырау тартык күршесендәге шундый ук сузыкның озынлыгыннан һәрвакыт зуррак була.

Татар теленең диалектларында һәм гади сөйләмдә, гадәттә, ассимилятив һәм диссимилятив тенденцияләргә нигезләнгән тагын берничә комбинатор аваз үзгәреше очрый. Боларга метатеза, ягъни авазларның урыннары алмашыну күренешен кертергә була. Мәсәлән, *яңгал*, әд. *ялган*; *мәптек*, әд. *мәктәп*; *азбар* әд. *абзар* һ.б. Мондый үзгәрешләргә диэреза, ягъни сүз составыннан авазлар төшеп калу, протеза, эпентеза кебек аваз өстәлү күренешләрен дә кертергә була. Мәсәлән, а) диэреза: [т], [м], [г] алдыннан [л] ның төшеп калуы – *бумый,* әд. *булмый; иткән,* әд. *илткән;* [л] яки [н] дан соң [н] ның төшеп калуы – *анан,* әд. *аннан; елы,* әд. *елны;* б) протеза: [р] яки [л] алдыннан

[о], [ы] яки [е] өстәлү – *эрәхмәт,* әд. *рәхмәт; ылампы,* әд. *лампа; Оркыя,* әд. *Рокыя;* сүз башындагы [ы], [е], [и] алдына [й] өстәлү – *йертә,* әд. *иртә; йыргак,* әд. *ыргак; йерлә,* әд. *эрлә;* в) эпентеза: [н] дан соң [г] яки [г] өстәлү – *сеңгел,* әд. *сеңел, яңга,* әд. *яңа, уңгай,* әд. *уңай;* [т] алдына [р] өстәлү – *кечерткән,* әд. *кычыткан, кортлау,* әд. *котлау* һ.б.

Позицион үзгәрешләр сузыклар өлкәсендә дә, тартыклар өлкәсендә дә күзәтелә. Бу үзгәрешләр, нигездә, өч факторга бәйле була: авазның сүздәге урыны (башы яки ахыры), нинди типтагы иҗектә булуы, басымлы яки басымсыз позициядә булуы.

Тартыкларның позицион үзгәрешләре, нигездә, аларның сүздәге урынына бәйле була. «Аваз тезмәләре» дигән бүлектә әйтелгәнчә, татар сүзләренең башында да, ахырында да ике тартык янәшә килә алмый (сүз ахырындагы [рт], [лт], [нт], [йт] – чыгармалар), шуңа чит телдән кергән алынма сүзләрнең башында яки ахырында тартыклар булса, ул сүзләрнең әйтелешен җиңеләйтү өчен өстәмә сузык аваз кушыла. Өстәмә сузыкларның урынын билгеләү өчен тартыкларның әйтелеш ысулларына нигезләнгән шартлы диаграмма кабул итәргә кирәк (15 нче рәсем). Әгәр алынма сүзнең башында тартыклар □▭ рәвешендә урнашкан булсалар, сузык аваз бу тартыкларның алдына өстәлә һәм бу күренеш п р о т е з а дип атала, мәсәлән, *стол > өстәл, шляпа > эшләпә* һ.б. Әгәр алынма сүздә (башында яки ахырында) тартыклар ▭□ рәвешендә урнашкан булсалар, сузык аваз тартыкларның арасында өстәлә, һәм бу күренеш э п е н т е з а дип атала, мәсәлән, *крупа > көрпә, книга > кенәгә, шарф > шарыф* һ.б. Әгәр алынма сүзнең ахырында тартыклар □▭ рәвешендә урнашкан булсалар, сузык аваз сүзнең ахырына өстәлә, бу күренеш исә э п и т е з а дип атала, мәсәлән, *банк > банкы, Омск > Омыски, пропуск > пропускы.*




15 нче рәсем

Кайвакыт бу тартыкларның берәрсе төшеп кала, ягъни диэреза күренеше күзәтелә. Мәсәлән, *артист > артис, корабль > кораб, скатерть > эскатер* һ.б.

Шунысын искәртергә кирәк, тартыкларның кайбер позицион үзгәрешләре (*өстәл, эскатер, көрпә* һ.б.) орфоэпик һәм орфографик норма буларак кабул ителәләр, икенчеләре исә (*шарыф, пропускы* һ.б.) җанлы сөйләмдә генә очрыйлар.

Диалектларда һәм гади сөйләмдә генә очрый торган тартыклар протезасы да позицион аваз үзгәрешләренә карый. Мәсәлән, *крант,* әд. *кран, хәтлек,* әд. *хәтле, көлтке,* әд. *көлке* һ.б.

Сузыкларның сүздәге урынына бәйле үзгәрешләре аеруча дүрт сузыкта ачык күренә. Болар – [а], [ә], [о], [ө] сузыклары.

Татар лингвистларының бик күптәннән күзәтүләре дә, соңгы елларда үткәрелгән катлаулы эксперименталь-фонетик тикшеренүләр дә шуны күрсәтә; [а] авазы сүз башында нык иренләшеп әйтелә, сүзнең ахырына таба аның иренләшүе кими бара, өстәвенә аның палатальлеге арта төшә, ягъни сузык аваз нечкәрә бара. Бу, борынгы төрки телдә, басымның сүз башында булуы белән бәйләнгән, дип исәпләнә.

[ә] авазның формант структурасындагы үзгәрешләр сүз башыннан ераклашкан саен бу авазның күтәрелеше арта баруы, ә рәтенең арткарак күчә баруы хакында сөйлиләр.

[о] һәм [ө] авазларының сүз ахырына таба иренләшүләре кими бара, [о] авазында бу аеруча ачык күренә.

Позицион үзгәрешләрнең тагын бер төре – редукция сүз басымы белән бәйләнгән. Билгеле булганча, татар телендә сүз басымы – күләм-көч басымы, ягъни сүз басымының табигатен беренче чиратта басымлы сузыкның озынрак булуы, икенче чиратта көчлерәк булуы билгели. Диалектларда басымлы сузык махсус көе белән дә аерылырга мөмкин. Бу турыда алдагы бүлекләрдә аерым сүз булыр. Басымсыз иҗекләрдә сузыклар зәгыйфьләнәләр, ягъни редукция күренеше була. Татар телендә күләм редукциясе күзәтелә, ягъни басымсыз сузыклар сыйфатларын үзгәртмиләр, бары күләмнәрен генә югалталар – кыскарак әйтеләләр.

Редукциягә чагыштырмача кыска сузыклар, аларның да сонантлар күршесендәгеләре аеруча тиз бирешәләр. Редукция тулы һәм өлешчә була. Өлешчә редукция – сузык авазның кыскарак әйтелүе, ул, гадәттә, ябык иҗекләрдә була: *кулында* [кулындá], *күренде* [күрĕндé] һ.б. Тулы редукция – сузык авазның бөтенләй төшеп калуы, ул, гадәттә, сонант күршесендәге чагыштырмача кыска сузык басымсыз

ачык иҗеккә туры килгәндә күзәтелә: *борыны* [бŏрно́] *күңеле* [күңле́] һ.б.

Редукция күренеше – җанлы сөйләмгә хас, сирәк кенә язуда да чагылыш таба: *халык – халкы, шигырь – шигъри* һ.б.

Сузык авазларның сүздәге урынына бәйле үзгәрешләренең тагын бер төре – апокопия, ягъни сүз башындагы яки ахырындагы сузык авазның төшеп калуы. Апокопия гадәттә алынма сүзләрдә күзәтелә. Мәсәлән, *минута > минут, газета > газет > гәҗит, квартира > квартир >фатир.* Диалектларда бу күренеш татар теленең үз сүзләрендә дә очрый (*тәрәзә > тәрәс, багана > паган*)*,* шулай ук кушымчалар ялгаганда да булырга мөмкин (*кеше – кешләр, цабата – цабатлар*). Сүз башындагы сузыкларның апо-копиясе нигездә диалектларда гына очрый. Мәсәлән, *марта,* әд. *умарта, ят,* әд. *оят, яр* әд. *ияр* һ.б.

Авазларның иҗек төренә бәйле үзгәрешләре турында сөйләшкәнче, татар теленең иҗек төзелешен ачыклап китәргә кирәк. Иҗек – сөйләмнең иң кечкенә әйтелеш берәмлеге, аның элементлары акустик актан да, артикуляцион яктан да бик тыгыз береккән булалар. Татар телендә иҗекнең мәҗбүри элементы булып сузык аваз тора. Ул иҗекнең үзәген тәшкил итә. Сузыкка кадәр дә, аннан соң да тартык авазлар киләргә мөмкин.

Чын татар сүзләрендә алты иҗек калыбы кулланыла: **С**[1] (*и*)*,* **ТС** (*бу*)*,* **СТ** (*ут*)*,* **ТСТ** (*тук*)*,* **СST** (*әйт*)*,* **ТСST** (*карт*). Җанлы сөйләмдә, алынма сүзләрдә TSC(*плә-мә, гра-мыт*)*,* TSCT(*прән-нек, кләй*) тибындагы иҗекләр дә әйтелергә мөмкин. Биредә шунысын да истә тотарга кирәк, авазлар яңгырашлары белән аерылалар: иң көчле яңгырашлы авазлар – сузыклар (3 ле цифрасы белән билгеләнә), аннан – сонантлар (2) һәм минималь яңгырашлы авазлар – шаулы тартыклар (1). Татар теленең иҗек төзелеше закончалыклары буенча, иҗек ахырында ике тартык яңгырашлары кимү тәртибендә тезелеп килсәләр генә очрыйлар (*ант* – 321, *көрт* – 1321), ә иҗек башында ике тартык килү, яңгырашлары үсү тәртибендә тезелсәләр генә мөмкин (*клэй* – 1232, *гра* – 123). Бу принциплар бозылганда, алынма сүзләрдә протеза, эпентеза һ.б. күренешләр була.

[1] С — сузык, Т — тартык, S — сонант.

С тибындагы иҗекләрне – абсолют ачык иҗекләр, сузыкка тәмамланучы **TC, TSC** тибындагы иҗекләрне – ачык иҗекләр, тартыкка тәмамланучы **CT, TCT, TCST** тибындагы иҗекләрне ябык иҗекләр дип атыйлар. Кайвакыт сузыкка башланып, тартыкка тәмамланучы **CT, CST** тибындагы иҗекләрне ярымачык иҗекләр дип аерым карыйлар.

Статистик тикшеренүләр күрсәтүенчә, сөйләмдә төрле типтагы иҗекләрнең кулланылыш активлыгы төрлечә (7 нче таблица).

*7 нче таблица*

| C | CT | TC | TCT | CST | TCST | TSC | TSCT |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5,1 | 4,2 | 46,5 | 43,2 | 0,3 | 0,4 | 0,2 | 0,1 |

Ачык иҗекләр өч кенә төрле (**C, TC, TSC)** булсалар да, алар сөйләмдә кулланылучы иҗекләрнең яртысыннан артыгын алып торалар. Бу хәл ачык иҗекләрне әйтү җайлырак булудан туа. Шуңа күрә ябык иҗеккә тәмамланган сүзләргә сузыктан башланган кушымча ялганганда, сүзнең иҗек төзелеше үзгәрә; сүз ахырындагы тартык аваз икенче иҗеккә күчеп китеп, үзенең элеккеге иҗеген «ачып җибәрә» (*ат-а* > *а-та, төр-е* > *тө-ре* һ.б.). Түбәндәге факт та шуны раслый: компонентларының саны бер үк булса да, TC һәм CT тибындагы иҗекләрнең кулланылыш активлыклары нык аерыла – TC тибындагы иҗекләр CT тибындагылардан 10 тапкыр активрак.

Авазларның иҗек тибына бәйле үзгәрешләре турында сөйләшкәндә, беренчедән, шунысын белгеләргә кирәк, TC тибындагы иҗекләрдә CT тибы белән чагыштырганда аккомодация күренеше, ягъни сузыкларның тартыкларга тәэсире көчлерәк. Икенчедән, иҗек эчендә авазларның үзара тәэсир итешүләре төрле иҗекләрнең янәшә авазлары тәэсир итешүеннән көчлерәк. Өченчедән, ачык иҗектәге сузык авазларның озынлыгы ябык иҗектәге шундый ук сузыкларның озынлыгыннан 1,3–1,5 мәртәбә артык. Абсолют ачык иҗектәге сузыкның озынлыгы исә шундый ук позициядәге теләсә нинди тип иҗектә килүче шундый ук сузыкның озынлыгыннан һәрвакыт зуррак. Дүртенчедән, сүздә иҗекләр һәм авазлар саны арту сузыкларның озынлыгы кимүгә китерә.

Шунысын да күрсәтергә кирәк, сузыкларның позицион үзгәрешләренә кагылышлы фикерләр фонемаларның модификацияләренә генә кагыла.

Мәгълүм булганча, һәр телнең авазлар системасының үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Татар фонетикасына хас билгеләрнең берсе – татар телендә сузыкларга карап тартыклар вариантлашу күренеше. Мәсәлән: *баш – биш, начар – нәсер, син – сын, табын – түбән.*

Шунысын да искәртергә кирәк, рус телендә бу күренеш киресенчә чагылыш таба: тартыкларга карап сузыклар вариантлаша: *тан – тянет* (т'анет).

## 2. ФОНОЛОГИЯ

Югарыда әйтелгәнчә, фонетиканың өч аспекты була, һәм өченче иң мөһим аспект булып лингвистик, яки функциональ аспект исәпләнә. Авазларны аларның функцияләре ягыннан өйрәнү фонология дигән фәнне барлыкка китерә. Бу фәннең өйрәнү объекты – фонемалар[1], ягъни телдә сүзләрне төзү һәм бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итә торган, бүтән бүленмәүче иң кечкенә берәмлекләр.

**Сузык фонемалар составы.** Татар телендә тугыз фонема ([а], [э], [у], [ү], [о], [ө], [ы], [е], [и]) татар теленең үз сүзләрендә һәм өчесе ([о], [ы], [е]) алынма сүзләрдә кулланыла. Җиде фонема – көчле, ягъни теләсә нинди позициядә телнең башка берәмлекләре белән тәңгәл килми, ике фонема – көчсез. Болар [ы], [е]. Алар минималь дифференциация[2] позициясендә (алар өчен бу [о], [ө] фонемалары булган иҗекләрдән соң килү) алар үзләренең билгеләре буенча [о], [ө] фонемалары белән тәңгәл киләләр, монда фонемаларны «иренләшкән-иренләшмәгән» билгеләре буенча капма-каршы кую бетә, фонемаларның нейтральләшүе була.

Татар теленең сузык фонемаларына түбәндәге конститутив, ягъни даими, позициягә бәйле булмаган билгеләр хас: рәт, күтәрелеш, иренләшү һәм озынлык (8 нче таблица).

---

[1] Билгеле булганча, фонемаларга билгеләмә бирүдә, аларны аңлатуда фикерләре белән бер-берсеннән шактый нык аерыла торган берничә фонологик мәктәп яшәп килә. Татар теленең фонемалар составын билгеләгәндә, аларны дифференциаль билгеләргә аерганда без «Рус грамматикасында» («Русская грамматика», М., 1982) бирелгән, гомум кабул ителгән, законлаштырылган концепцияләргә таянабыз.

[2] Фонемалар бер-берсеннән иң аз дәрәҗәдә аерыла торган позициядә – максималь дифференциация позициясендә фонемалар бер-берсеннән бик нык аерылалар. Шуның күрсәтергә кирәк, татар теленең сузыклары өчен бу позицияләр авазның сүздәге урынына (башы яки ахыры) һәм янәшәсендәге авазларның сыйфатына нисбәтән билгеләнәләр.

Билгеле булганча, конститутив билгеләр чагыштырмалы һәм чагыштыргысыз булалар. Чагыштырмалы билгеләр – алар башка билгеләре бердәй булган ике генә булса да, фонемада табыла торган билгеләр. Чагыштыргысыз билгеләр – алар тагын ниндидер билгеләре булган бер генә фонемада табыла торган билгеләр. Конститутив чагыштырмалы билге дифференциаль билге дип атала. Дифференциаль булмаган билге артык була: фонема аңардан башка да билгеләнә ала. Мәсәлән, татар теленең үз сузыклары өчен озынлык – артык билге, алар калган өч билге белән дә тулысынча билгеләнәләр, аерылалар; [а] өчен иренләшү – артык билге, бу фонема «түбән күтәрелеш, арткы рәт» дигән ике билге белән тулысынча билгеләнә, чөнки шушы ук билгеләре өстенә «иренләшү» билгесе дә булган бүтән фонема юк. [а], [ә] фонемаларының – икешәр дифференциаль билгесе, [у], [ү], [и], [ы], [ө], [ы̄] фонемаларының – өчәр, [е], [о], [ē], [ō] фонемаларының дүртәр дифференциаль билгесе бар.

*8 нче таблица*

Сузык фонемаларның дифференциаль билгеләре

| Билге | Фонема | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| [а] | + | | | | + | | + | + | |
| [ә] | | + | | | + | | + | + | |
| [у] | + | | | | | + | | + | |
| [ү] | | + | + | | | + | | + | |
| [ы] | + | | | + | | | + | | + |
| [е] | | + | | + | | | + | | + |
| [о] | + | | | + | | + | | | + |
| [ө] | | + | | + | | + | | | + |
| [и] | | + | + | | | | + | + | |
| [ō] | + | | | + | | + | | | + |
| [ы] | + | | + | | | | + | + | |
| [ē] | | + | | + | | | + | + | |

[а] – арткы рәт, түбән күтәрелеш;

[ә] – алгы рәт, түбән күтәрелеш;

[у] – арткы рәт, югары күтәрелеш, иренләшкән;

[ү] – алгы рәт, югары күтәрелеш, иренләшкән;

[ы] – арткы рәт, урта күтәрелеш, иренләшмәгән;

[е] – алгы рәт, урта күтәрелеш, иренләшмәгән, кыска;

[о] – арткы рәт, урта күтәрелеш, иренләшкән, кыска;

[ө] – алгы рәт, урта күтәрелеш, иренләшкән;

[и]– алгы рәт, югары күтәрелеш, иренләшмәгән;

[о] – арткы рәт, урта күтәрелеш, иренләшкән, озын;

[ы| – арткы рәт, югары күтәрелеш, иренләшмәгән;

[е] – алгы рәт, урта күтәрелеш, иренләшмәгән, озын.

Искәрмәләр: 1 – арткы рәт, 2 – алгы рәт, 3 – югары күтәрелеш, 4 – урта күтәрелеш, 5 – түбән күтәрелеш, 6 – иренләшкән, 7 – иренләшмәгән, 8 – озын, 9 – кыска.

*9 нче таблица*

Татар сузык фонемаларының аллофоннары

<table>
<tr><th rowspan="2">Позиция</th><th colspan="11">Фонема</th></tr>
<tr><th>[а]</th><th>[ә]</th><th>[у]</th><th>[ү]</th><th>[и]</th><th>[ы]</th><th>[е]</th><th>[о]</th><th>[ө]</th><th colspan="2"></th></tr>
<tr><td>1. Абсолют сүз башында</td><td>[а$^{о}$]</td><td>[ә]</td><td>[у]</td><td>[ү]</td><td>[и]</td><td>[ы]</td><td>[е]</td><td>[о]</td><td>[ө]</td><td rowspan="2">позиц.</td><td rowspan="5">аллофоннар</td></tr>
<tr><td>2. Абсолют сүз ахырында</td><td>[а]</td><td>[ә]</td><td>[у$^{w}$]</td><td>[ү$^{w}$]</td><td>[и$^{и}$]</td><td>[ы]</td><td>[е]</td><td>–</td><td>–</td></tr>
<tr><td>3. Увуляр [k,], [х], [ғ] тартыкларыннан соң</td><td>[а]</td><td>[$^{а}$ә]</td><td>[у]</td><td>[$^{у}$ү]</td><td>[$^{ы}$и]</td><td>[ы]</td><td>[$^{ы}$е]</td><td>[о]</td><td>[$^{°}$ө]</td><td rowspan="3">комбинатор.</td></tr>
<tr><td>4. Тел алды [ч], [җ] тартыкларыннан һәм [й] дан соң</td><td>[$^{ә}$а]</td><td>[ә]</td><td>[$^{ү}$у]</td><td>[ү]</td><td>[и]</td><td>[$^{е}$ы]</td><td>[е]</td><td>[$^{ө}$о]</td><td>[ү]</td></tr>
<tr><td>5. [о], [ө] авазлары булган иҗекләрдән соң</td><td>[а$^{°}$]</td><td>[ә]</td><td>[у]</td><td>[ү]</td><td>[и]</td><td>[о]</td><td>[е]</td><td>[о]</td><td>[ө]</td></tr>
</table>

Аңлатмалар: 1. Абсолют сүз башы – татар теленең үз сузыклары өчен максималь дифференциация позициясе. Бары [а] фонемасы гына [а$^{о}$] аллофоны аша бирелгән. «Иренләшү» [а] фонемасы өчен дифференциаль билге булмаганга күрә, фонемаларның һәм аллофоннарның тәңгәл килүе күзәтелми.

2. Абсолют сүз азагында [о], [ө] фонемалары очрамый. Ә [у], [ү], [и] фонемаларының ахырына [w] яки [й] сонантлары өстәлә. Сүз ахырындагы [у], [ү], [и] фонемаларының ике фонемадан торуы фонологик яктан да, фонетик яктан да (бигрәк тә эксперименталь-фонетик тикшеренүләр аша) раслана.

3. Увуляр тартыклардан соң килүче алгы рәт сузык фонемалары бу сузыкларның арткарак күчкән вариантлары рәвешендәге аллофоннар аша биреләләр. Ә бу сузыкларның башлангыч өлешләре шул сузыкларның арткы рәт парлары белән тәңгәл килә: [қ$^{а}$әбе́р], [мәшғ$^{у}$ү́л] һ.б. Бу – аккомодация чагылышы.

4. Тел алды тартыклары [ч], [җ] һәм [й] тартыгыннан соң килүче арткы рәт сузыклары бу сузыкларның алгарак күчкән вариантлары рәвешендәге аллофоннар аша биреләләр. Ә бу сузыкларның башлангыч өлешләре шул сузыкларның алгы рәт парлары белән тәңгәл килә: [җ$^{е}$ыр], [й$^{Y}$ул] һ.б.

5. Бишенче позиция югарыда әйтелгән көчсез [ы], [е] фонемалары өчен минималь дифференциация позициясе, алар [о], [ө] фонемалары белән тәңгәл киләләр: *бот-ы* [бŏто́], *төп-е* [тӧбө́] һ.б.

Татар сузык фонемаларының күп төрле аллофоннары, ягъни сүздәге урынына бәйле (позицион аллофоннар), яки күршесендәге авазларга бәйле (комбинатор аллофоннар) рәвештә ачылучы аваз группалары бар (9 нче таблица).

**Тартык фонемалар составы.** Татар теленең үз сүзләрендә егерме биш тартык фонема кулланыла. Алардан башка алынма сүзләрдә тагын өч фонема ([ц], [щ], [в]) очрый, [з], [җ], [г], [ғ], [б], [д] фонемалары – «яңгырау-саңгырау» билгесе буенча көчсез фонемалар. Сүз ахырында һәм саңгырау тартыклар алдына (бу – алар өчен минималь дифференциация позициясе) алар [с], [ч], [к], [қ], [п], [т] фонемалары белән тәңгәл киләләр: *төз* [төс], *таҗ* [тач], *игътибар* [иқтиба́р], *шөбһә* [шөпһә́] һ.б.

[н] фонемасы – ясалу урыны буенча көчсез фонема, [б], [м] фонемалары алдында «тел алды – ирен» билгеләре нейтральләшә һәм [н] фонемасы [ң] белән чиратлаша: *төнге* [тӧ̆ңгө̀], *инкяр* [иңкә̀р], *тынган* [тй̆ңға̀н] һ.б.

Шунысын искәртергә кирәк, татар теленең тартык фонемалары өчен максималь дифференциация позициясе – сузыклар арасындагы позиция. Бу позициядә барлык тартык фонемалар да килә ала.

Тартык фонемалар өчен конститутив билгеләр – ясалу урыны, ясалу ысулы, тон һәм шауның катнашу дәрәҗәсе, озынлык (10 нчы таблица).

Димәк, татар телендә тартык фонемаларның конститутив билгеләре алтау. Әлбәттә, аларның бөтенесе дә һәр фонема өчен дифференциаль түгел.

Кайбер фонемаларны башкалардан аеру өчен бер билге дә җитә. [һ] – йоткылык, [ʿ] бугаз, [р] – калтыраулы, [й] – тел уртасы тартыгы,

кайберләре өчен ике билге җитә, [п] – ирен-ирен, саңгырау, [ф] – ирен-теш, саңгырау һ.б.; өченчеләре өчен – өч билге ([д] – тел алды, йомык, яңгырау); дүртенчеләре өчен дүрт билге кирәк була.

Алынма [в], [щ], [ц] фонемалары турында берничә сүз. [в] ның конститутив билгеләре (ирен-ирен, яңгырау) аның өчен дифференциаль була. [ц] ны башка фонемалардан аеру өчен аның «аффрикат» билгесен кертергә кирәк, шул билге аны [т] дан аера. [щ] фонемасы белән хәл катлаулырак. Рус фонетикасында аның ике билгесен күрсәтәләр: «палаталь», «озын». Палатальлек татар теле өчен фонематик билге түгел, шуңа «озынлык» билгесе генә кала. Бу билге [щ] фонемасын [ш] ның нечкә вариантыннан аера торган бердәнбер дифференциаль билге булып тора.

Татар телендә тартык фонемаларның аллофоннары турында түбәндәгеләрне әйтеп була:

1. Сүз башы позициясен максималь дифференциация позициясе дип атап була. Бу позициядә барлык тартыклар ([ң] дан башкалары) һәм аларның аллофоннары килә ала. [ж’] аллофоны бары *жирәбә* сүзендә генә очрый.

2. Барлык фонемаларның да диярлек икешәр аллофоны була – палаталь һәм веляр. Тартыкларның палаталь вариантларын белдерүче аллофоннар – бары алгы рәт сузыклары алдында очрыйлар. Шунысы да бар, палаталь һәм веляр вариантлар арасында аерма бик аз һәм ул мөһим дә түгел. Кайбер фонемалар өчен бу – минималь дифференциация позициясе, [ң] өчен «кече тел – тел арты» билгесе нейтральләшә һәм [ң’] тел арты аллофоны барлыкка килә. [к], [г] өчен «тел арты – тел уртасы» билгесе нейтральләшә һәм тел уртасы [к’], [г’] аллофоннары барлыкка килә.

3. Сүз азагы – парлы яңгырау-саңгырау тартыклар өчен минималь дифференциация позициясе. Бу позициядә әлеге фонемаларның саңгырау аллофоннары гына була ала. [җ], [б], [д], [ж], [в], [г] фонемаларының саңгырау аллофоннары алынма сүзләрдә генә була: *хаҗ* [хач], *клуб* [клуп] һ.б.

4. [м], [л], [р], [н] сонантлары алдында тартык фонемаларның һәм аллофоннарның иң күбе очрый, [л] алдында, мәсәлән, – [д], [г] фонемалары, [к] ның веляр аллофоны, [һ] ның палаталь аллофоны гына очрамый.

5. [ˤ], [җ], [х], [w], [h] алдында исә фонемаларның иң азы очрый. Мәсәлән, [н] алдында [с] һәм [р] ның палаталь аллофоннары ([мәсˤәлә], [җөрˤәт]); [җ] алдында [л], [р], [й] һәм [н] ның палаталь аллофоннары гына очрый: *калҗа, морҗа, хәнҗәр* һ.б.

6. [ң] алдында бер фонема да килә алмый, [ж] алдында тартыклар алынма сүзләрдә генә очрыйлар.

7. [х] ның тел арты аллофоны [х] һәм [ч] ның аффрикат аллофоны [$^{т}$ч] татар теленең диалектларында һәм рус алынмалларында гына очрыйлар: *химия, чек* һ.б.

*10 нчы таблица*

| Фонема | Билге | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
| [б] | + | | | | | | | | | + | | | | | | | + | + | | + | | | + |
| [п] | + | | | | | | | | | + | | | | | | | + | | + | + | | | + |
| [w] | + | | | | | | | | | | | | + | | | + | | + | | + | | | + |
| [м] | + | | | | | | | | | | | + | | | | + | | + | | | + | | + |
| [в] | | + | | | | | | | | | | | + | | | | + | + | | + | | | + |
| [ф] | | + | | | | | | | | | | | + | | | | + | | + | + | | | + |
| [д] | | | + | | | | | | | + | | | | | | | + | + | | + | | | + |
| [т] | | | + | | | | | | | + | | | | | | | + | | + | + | | | + |
| [ц] | | | + | | | | | | | | + | | | | | | + | | + | + | | | + |
| [с] | | | + | | | | | | | | | | + | | | | + | | + | + | | | + |
| [ч] | | | | + | | | | | | | | | + | | | | + | | + | + | | | + |
| [ш] | | | | + | | | | | | | | | | + | | | + | | + | + | | | + |
| [щ] | | | | + | | | | | | | | | | + | | | + | | + | + | | + | |
| [з] | | | + | | | | | | | | | | + | | | | + | + | | + | | | + |
| [җ] | | | | + | | | | | | | | | + | | | | + | + | | + | | | + |
| [ж] | | | | + | | | | | | | | | | + | | | + | + | | + | | | + |
| [л] | | | + | | | | | | | | | + | | | | + | | + | | + | | | + |
| [р] | | | | .+ | | | | | | | | | | | + | + | | + | | + | | | + |
| [н] | | | + | | | | | | | | | + | | | | + | | + | | | + | | + |
| [й] | | | | | + | | | | | | | | + | | | + | | + | | + | | | + |
| [г] | | | | | | + | | | | + | | | | | | | + | + | | + | | | + |
| [к] | | | | | | + | | | | + | | | | | | | + | | + | + | | | + |
| [қ] | | | | | | | + | | | + | | | | | | | + | | + | + | | | + |
| [ғ] | | | | | | | + | | | | | | + | | | | + | + | | + | | | + |
| [х] | | | | | | | + | | | | | | + | | | | + | | + | + | | | + |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| [ң] | | | | | | | + | | | | | + | | | | + | | + | | | + | | + |
| [h] | | | | | | | | + | | | | | + | | | | + | | + | + | | | + |
| [ع] | | | | | | | | | + | + | | | | | | | + | | + | + | | | + |
| Билге | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |

Искәрмәләр: 1 – ирен-ирен, 2 – ирен-теш, 3 – тел-теш, 4 – тел-аңкау, 5 – тел уртасы, 6 – тел арты, 7 – кече тел, 8 – йоткылык, 9 – бугаз, 10 – йомык, 11 – аффрикат, 12 – ярымйомык, 13 – бер фокуслы өрелмәле, 14 – ике фокуслы өрелмәле, 15 – калтыраулы, 16 – сонор, 17 – шаулы, 18 – яңгырау, 19 – саңгырау, 20 – авыз, 21 – борын, 22 – озын, 23 – кыска.

## ӘДӘБИЯТ


Аврутина А.С. Опыт реконструкции фонологии языка древнетюркских рунических памятников: дис. ... канд. филол. наук. СПб., 2005. 144 с.

Асылгараев Ш.Н. Синтагматическое членение татарской речи (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1968. 22 с.

Ахметьянов Р.Г. К вопросу о природе звуковых переходов в тюркских языках (о переходе г ~ z) // ВЯ. 1961. № 6. С. 128–129.

Ахметьянов Р.Г. Татарский язык в Волго-Камском языковом союзе: автореф. дис. … д-ра филол. наук. Казань, 1993.

Байчура У.Ш. Звуковой строй татарского языка (экспериментально-фонетический очерк). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1959. 184 с.

Барашков, П.П. Фонетические особенности говоров якутского языка. Сравнительно-исторический очерк. Якутск: Кн. изд-во. 1985. 182 с.

Баскаков Н.А. Историко-типологическая фонология тюркских языков. М.: Наука, 1985. 207 с.

Богородицкий В.А. Фонетика татарского языка в связи с другими тюркскими языками // Вестник научного Общества татароведения. Казань, 1926. С. 43–48.

Богородицкий В.А. Характеристика звукового состава в казанском говоре поволжско-татарского языка в соотношении с звуковою системою общерусского языка // Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. Казань: Татиздат, 1933. С. 22–33.

Богородицкий В.А Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. Казань: Татиздат, 1933. 156 с.

Бураев И.Д. Становление звукового строя бурятского языка. Новосибирск: Наука, 1987. 182 с.

Бурганова Н.Б. Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья // Источниковедение и история тюркских языков. Казань, 1978. С. 76−95.

Губайдуллина Г.Т. Татарская экспериментальная фонетика: истоки и этапы ее развития: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, АГНИ, 2011. 24 с.

Диалекты тюркских языков. Очерки / отв. ред. А.В. Дыбо. М.: Восточная литература, 2010. 533 с.

Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. М.: Наука, 2007. 262 с.

Дыбо А.В. Некоторые проблемы сравнительно-исторической фонетики башкирского языка (рукопись). М., 2012. 8 с.

Дыбо А.В. Семантическая реконструкция в алтайской этимологии. Семантические термины (плечевой пояс). М.: Школа «Языки русской культуры», 1996. 389 с.

Дыренкова Н.П. Грамматика хакасского языка, фонетика и морфология. Абакан, 1948.

Зиндер Л.Р. Общая фонетика: Учеб. Пособие. (2-е изд.). М.: Высш. шк., 1979. 312 с.

Ибрагимов Т.И. К определению состава фонем татарского языка // Языковые уровни и их взаимодействие. Казань, 1990. С. 143–151.

Иванов В.В. Историческая фонология русского языка. М. Просвещение, 1968. 360 с.

Исхаков Ф.Г. Об отдельных фонемах татарского языка // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч I. Фонетика. М.: Изд.-во Акад. наук СССР, 1955. С. 217–249.

Ишбулатов Н.Х. Современный башкирский язык. Фонетика (Учебное пособие). Уфа: Изд-во Баш. гос. университета, 1982. 40 с.

Касаткин JI.JI. Современная русская диалектная и литературная фонетика как источник для истории русского языка. М., 1999. 526 с.

Касаткин Т.Л. Современный русский язык. Фонетика: учеб. пособие для студ. филол. фак. высш. учеб. заведений. М.: Академия, 2006. 256 с.

Кечил-оол С.В. Типологическая специфика консонантизма сут-хольского говора в системе говоров и диалектов тувинского языка. Новосибирск: Сова, 2006.  362 с.

Киекбаев Дж. Г. Фонетика башкирского языка (опыт описательного и сравнительно-исторического исследования): автореф. дис. … д-ра филол. наук. М., 1959. 92 с.

Колесов В.В. Историческая фонетика русского языка: Учеб. пособие для вузов. М.: Высш. школа, 1980. 215 с.

Кошкаров А.Б. Фрикативные согласные в казахском языке (диахронический и синхронический аспекты): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Алматы, 1996. 45 с.

Кузьменков Е.А. Фонологическая система современного монгольского языка. СПб.: Изд.-во С.-Петерб. ун-та, 2004. 212 с.

Кулаев М.А. О звуках башкирского языка. Казань, 1928. 60 с.

Кулаев М.А. Основы звукопроизношения и азбука для башкир. Казань: Типография Императорского Ун-та, 1912. 22 с.

Левитская Л.С. Историческая фонетика чувашского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1966. 28 с.

Левитская Л.С. Историческая фонетика чувашского языка. Чебоксары: ЧГИГН, 2014. 320 с.

Мамедов А. Тюркские согласные: анлаут и комбинаторика. Баку: ЭЛМ, 1985. 208 с.

Мудрак О.А. К вопросу о палатализации начальных согласных в чувашском языке // Вопросы чувашской фонетики и морфологии. Чебоксары, 1987.

Мудрак О.А. Классификация тюркских языков и диалектов с помощью методов глоттохронологии на основе вопросов по морфологии и исторической фонетике. (Серия «Orientalia и Classica». Вып.23). М.: РГГУ, 2009. 186 с.

Раднаева Л.Д. Звуковая форма современного бурятского языка (теоретические и практические аспекты качественного и количественногоанализа): дис. ... д-ра филол. наук. СПб., 2004. 450 с.

Рамазанова Д.Б. К истории формирования говора пермских татар. Казань, 1996. 239 с.

Рассадин В.И. Очерки по исторической фонетике бурятского языка. М., 1982. 199 с.

Рыжикова Т.Р. Консонантизм языка барабинских татар: Сопоставительно-типологический аспект. Новосибирск, 2005. 269 с.

Рясянен М. Материалы по исторической фонетике тюркских языков. М.: Изд-во иностр. лит-ры, 1955. 222 с.

Садыкова З.Р. Говор оренбургских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 159 с.

Садыкова З.Р. Говоры оренбургских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1986. 25 с.

Салимов Х.Х. Просодическая система татарского языка: дис. ... д-ра филол. наук. Елабуга, 1999. 363 с.

Сарбашева С.Б. Фонологическая система туба-диалекта алтайского языка (в сопоставительном аспекте). Новосибирск: Сибирский хронограф, 2004. 244 с.

Севортян Э.В. Материалы по сравнительной фонетике турецкого, азербайджанского и узбекского литературных языков // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. 1 Фонетика. М.: Изд.-во Акад. наук СССР, 1955. С. 13–53.

Селютина И.Я. Введение в общую фонетику: Учеб. пособие. Новосибирск: Новосиб. гос. ун-т, 2008. 66 с.

Селютина И.Я. Звуковые системы языков народов Сибири: Учеб. пособие. Новосибирск: Новосиб. гос. ун-т, 2008. 48 с.

Смаилов Т.Х. Фонетические явления в слове современного казахского языка: дис. ... канд. филол. наук. Алма-Ата, 1984. 180 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Фонетика / под ред. Э.Р. Тенишева. М.: Наука, 1984. 484 с.

Сунгатов Г.М. Фонетическая система заболотного говора тоболо-иртышского диалекта сибирских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1991. 22 с.

Талипов Т. Фонетика уйгурского языка: (очерки исторического развития). Алма-Ата: Наука, 1987. 256 с.

Тенишев Э.Р. Избранные труды. Том 3. Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2011. 254 с.

Тумашева Д.Г. Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

Уртегешев Н.С. Малошумный консонантизм шорского языка (на материале мрасского диалекта). Новосибирск: Сова, 2004. 240 с.

Хайрутдинова Т.Х. Говор златоустовских татар. Казань, 1985. 15 с.

Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М.: Наука, 1978. 206 с.

Халиуллина А.Р. Графо-фонетические и морфологические особенности тюркоязычного письменного памятника XIV в. «Кысас Ал-Анбия» Насретдина Рабгузи: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 229 с.

Хисамитдинова Ф.Г. История башкирского языка: Материалы по исторической фонетике: учеб. пособ. Уфа: Башк. пед. ин-т, 1989. 84 с.

Хисамитдинова Ф.Г. Консонантные сочетания башкирского языка типа «сонорный + глухой смычный» в историческом освещении: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 1980. 22 с.

Хисамова Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв. Ч. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 152 с.

Чеченов А.А. Историческая фонетика карачаево-балкарского языка. М.: Ин-т языкознания РАН, 1996. 395 с.

Шараф Г. Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими (Отдельный оттиск из журнала «Вестник науч. общества татароведения». № 7. 1927). Казань, 1927. 40 с.

Шараф Г. Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русским // Вестник научного общества татароведения. 1927. № 7. С. 65–102.

Широбокова Н.Н. Историческое развитие якутского консонантизма. Новосибирск: Наука, 2001. 150 с.

Широбокова Н.Н. Отношение якутского языка к тюркским языкам Южной Сибири. Новосибирск: Наука, 2005. 269 с.

Щербак А.М. Сравнительная фонетика тюркских языков. Л.: Наука, 1970. 202 с.

Яруллина Л.И. Вокализм и консонантизм татарского языка, передача их на письме: XIX век и первая четверть XX в.: автореф. дис. … д-ра филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

Яфаров Л.И. Некоторые закономерные тенденции в фонетике татарского языка: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1955. 15 с.

Алпаров Г. Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан, 1925; 2 нче басма. Казан, 1926. 164 б.

Байчура Ү.Ш. Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре (Экспериментальфонетик мәгълүматлар буенча) // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. Казан, 1963. Б. 127–140.

Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 108 б.

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Тулыл. 2 нче басма. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 235–241 б.

Сәлимов Х.Х. Татар теле фонетикасы. Чаллы: Камаз нәшр., 1993. 31 б.

Хәкимҗан Ф. Татар әдәби теле: Фонетика. Югары уку йортлары студентлары өчен. Тулылан. 2 нче басма. Казан: ТДГИ, 2001. 108 б.

Хисамова Ф.М. Хәзерге татар теле фонетикасы. Татар филологиясе бүлеге студентлары өчен методик күрсәтмәләр. Казан, 1987. 44 б.

Һадиева Г.К. Хәзерге татар әдәби теле фонетикасы: уку-укыту кулланмасы. Казан: Казан ун-ты, 2012. 124 б.

Йосыпов Ф.Й. Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 160 б.

## 3. ПРОСОДИКА

Хәзерге тел белемдә просодика яки просодия дип сөйләмнең сусерсегмент, ягъни ритмик-интонацион үзенчәлекләре җыелмасын атыйлар. Суперсегмент берәмлекләргә фонемадан югарырак торган берәмлекләр керә. Гадирәк әйткәндә, сүзнең просодикасы ул – сүз басымы, ә җөмләнең просодикасы – синтаксик берәмлекләрнең интонациясе. Просодиканың компонентлары: 1) төп тон югарылыгы, 2) озынлык, 3) интенсивлык, 4) пауза, 5) тембр. Бу характеристикаларның кайберләре турында «Фонетика» бүлегендә, авазларның акустик билгеләренә бәйле рәвештә сүз булган иде.

**Сүз басымы.** Татар фонетикасын тикшеренүчеләрнең күпчелеге татар телендә сүз басымының чагыштырмача зәгыйфь булуын күрсәтәләр. Басымның табигате турында фикерләр аерыла: күпчелек галимнәр аны – экспиратор, ягъни көч басымы, дип; икенчеләре – квантитатив, ягъни күләм басымы, дип исәплиләр. В.А. Богородицкий исә басымсыз сузыкларның тон хәрәкәтендә дә аермалар таба.

Татар телендәге сүз басымының акустик табигатен экспериментальь тикшеренүләр һәм басым кабул итүне тикшерү өчен үткәрелгән аудиторлык анализлар түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә:

1. Татар теленең сүз басымын формалаштыруда һәм кабул итүдә нинди дә булса акустик билге абсолют өстенлек итә дип әйтеп булмый.

2. Татар телендә табигате белән чагыштырмача озын һәм чагыштырмача кыска сузыклар булганга күрә, сузыкның озынлыгы арту басымның даими компоненты була алмый. Ләкин бөтен сузыклары да бердәй озынлыкта булган сүзләрдә (ягъни бөтен сузыклары да йә чагыштырмача озын, йә чагыштырмача кыска) басым сүзнең соңгы иҗегендә булса, басымлы сузык басымсызларыннан һәрвакыт озынрак була.

Басымның көчәюе белән генә аерыла торган бер иҗекле омографларда (*а́л – сыйфат, а̋л – фигыль, а́т – исем, а̋т – фигыль*) ба-

сымның көчәюе сузыкның озынлыгы белән турыдан-туры бәйләнгән – боерык фигыльләрдәге сузыклар исемдәгеләрдән 1,3–1,5 тапкыр озынрак.

3. Интенсивлык белән басым арасында бәйләнеш тотрыксыз. Басым соңгы иҗектә булмаса (*алма, карама*), бу бәйләнеш ныграк була, аларда басымлы сузык һәрвакыт көчлерәк, интенсиврак. Аның каравы, бу очракларда басым белән озынлык арасындагы бәйләнеш югала.

Интенсивлыкны тикшергәндә тагын бер күренеш ачыла (бу күренеш кайбер башка телләрдә дә күзәтелә): сүздә сузыкларның чагыштырма интенсивлыгы күбрәк аларның сүздәге урынына бәйләнгән була – сузык сүзнең башындарак булган саен, ул интенсиврак була.

4. Озынлык һәм көч арасында түбәндәге бәйләнешләрне күрсәтергә була:

а) озынлык һәм көч арасында үзара компенсацияләүче мөнәсәбәт күзәтелә, ягъни басымлы сузыкның көче басымсызныкыннан азрак булса, басымлы сузык басымсызыннан озынрак була;

б) басымны кабул итүдә, ягъни ишетүдә озынлыкның һәм интенсивлыкның роле турында шуны әйтергә була: басым соңгы иҗектә булганда, төп рольне озынлык уйный, ә басым соңгы иҗектә булмаса, мәсьәлә ике яклы хәл ителә – әгәр басымлы сузык озынрак булса, басымның кабул ителүе интенсивлыкка бәйле була; дөрес, бу очракта басымны тоемлау беркадәр кыенлаша. Икенче төрле әйткәндә, басымны тоемлауда, кабул итүдә озынлыкның беркадәр приоритеты барлыгын күрсәтеп була.

5. Басым «көчәйгән» вакытта (*а́т – а̋т*), төп тонның югарылыгы 30–80 герцка күтәрелә. Күп иҗекле сүзләрдә исә, басымлы сузыкның тоны югарыдан түбәнгә таба хәрәкәт итә, ә басымсыз сузыкларда тон хәрәкәте башта түбәннән югарыга, аннан югарыдан түбәнгә таба була.

6. Спектраль анализ нәтиҗәләре буенча, сузык авазның формант структурасында, ягъни тембрында басымга бәйле үзгәрешләр ниндидер бер закончалык төсендә түгел, өстәвенә алар сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә генә. Бу исә татар телендә сүз басымы авазның сыйфатына бик аз тәэсир итүе турында сөйли. Бу хәл күп кенә төрки телләргә хас.

Татар телен, еш кына, басымы даими булган телләргә кертәләр, анда басым күпчелек очракта сүзнең соңгы иҗегенә төшә, дип

күрсәтәләр. Шул ук вакытта ул хәрәкәтчән басым: сүзләргә кушымчалар ялганганда, ул сүзнең азагына күчә бара: *а́т – атла́р – атлары́ – атларына́* һ.б.

Татар теленә элегрәк кергән сүзләр дә, татар теле законнарына буйсынып, басымнарының урынын үзгәрткәннәр: *бо́чка – мичкә́, де́готь – деге́т,* һ.б.

Соңгырак алынма сүзләр оригиналдагы басымны саклаганнар. Андый сүзләрдә басым соңгы иҗектә булмаса, кушымчалар ялганганда да, ул шул урынында кала (*а́втор – а́вторлар – авторларга* һ.б.); әгәр ул сүзләрдә басым соңгы иҗектә булса, кушымчалар ялганганда, ул сүз ахырына күчә бара (*телефо́н – телефонна́р – телефоннарыбы́з* һ.б.).

Татар теленең кайбер аффикслары басым кабул итмиләр һәм басымны үзләре аша «уздырмыйлар». Болар:

а) затланышлы фигыльләрдәге зат категориясе кушымчалары (III заттан башкалары ): *алга́нмын, алга́нсың, алга́нбыз, алга́нсыз, алы́рмын* һ.б.;

б) хәбәрлек кушымчалары (III заттан башка): *укучы́мын, укучы́сың, көчле́мен, баты́рсың* һ.б.;

в) юклык кушымчалары *-ма/-мә, -мый/-ми: а́лма, би́рмәгез, а́лмый, би́рмиләр* һ.б.

г) сорау кисәкләре (кушымчалары ) *-мы/-ме: алды́мы, күрделә́рме* һ.б.

д) хәл фигыль кушымчалары *-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче: а́лганчы, ки́ткәнче* һ.б.

е) рәвеш ясагыч кушымчалар *-ча/-чә: тата́рча, сине́ңчә* һ.б.;

Кайбер сүзләрдә басым даими рәвештә сүзнең беренче иҗегендә була:

а) II зат боерык фигыльләрдә: *а́тла, э́шлигез, у́тырыгыз* һ.б.;

б) сорау, билгеләү, юклык алмашлыкларында: *ка́йсы, нә́рсә, ни́гә, ба́рлык, һә́рбер, һә́ммә, бе́рнәрсә, һи́чкайчан* һ.б.;

в) теркәгечләрнең күпчелеге: *лә́кин, ә́мма, ба́ры, чө́нки, гә́рчә, я́гъни* һ.б.;

г) кайбер рәвешләр: *ба́йтак, га́ять, тә́мам, һа́мам, кө́чкә, хә́зер* һ.б. Шунысы да бар, соңгы ике группага кергән сүзләрнең күбесе – гарәп һәм фарсы алынмалары, һәм алар оригиналдагы басымнарын саклыйлар дияргә нигез бар.

Татар телендә кайбер сүзләрнең басымнары бөтенләй булмый, һәм алар, басымлы берәр сүз белән берләшеп, ф о н е т и к  сүз төзиләр.

Фонетик сүз ул, билгеле булганча, йә басымы булган бер сүз, яки басымлы сүзнең басымсыз берәр сүз белән сөйләм агымындагы кушылмасы.

Әгәр фонетик сүз составына керүче басымсыз сүз басымлы сүздән алда килсә, ул – п р о к л и т и к а  дип, басымы сүздән соң килсә, ул э н к л и т и к а  дип атала.

Проклитика сыйфатында булалар:

а) кайбер бүлүче һәм ияртүче теркәгечләр (*йә, яисә, яки, әгәр, гүя, ягъни): йә‿си́н, йә‿ми́н..; әгәр‿килсә́..; бе́з, ягъни‿кешеләр́...* һ.б.;

б) кайбер кисәкчәләр (*фәкать, тик, ни, әллә*): *ти‿си́н..; ни‿алга́, ни‿артка́; әллә‿ба́р, әллә‿ю́к* һ.б.

Энклитика сыйфатында булалар:

а) кайбер теркәгечләр (*ки, да/дә, та/тә, ни – ни*): *шундый‿яхшы́ ки.., килдем‿дә, алды́‿ни, а́лмады‿ни* һ.б.;

б) кайбер кисәкчәләр (*бит, ич, ла/лә, ләбаса, да/дә, ук /үк*): *тапты́м бит, ба́р‿ич, шу́л‿ук.., күрдé‌м‿ләбаса, эзләдé‌м‿дә, тапты́м‿да* һ.б.;

в) кайбер модаль сүзләр (*икән, кирәк, тиеш, соң*): *бара́‿икән > бара́йкән.., шу́л‿кирәк, табарга́‿тиеш* һ.б.;

г) кайбер ярдәмче фигыльләр: *килә́‿иде > килә́йде, эшли́‿тор.., кү́рмәгән‿бул* һ.б.;

д) кайбер очракларда мөстәкыйль сүзләр дә энклитика булып килергә мөмкин. Артыклык дәрәҗәсе ясый торган *ап-, ямь-, зәп-, көпә-, туп-, чалт-, шыр, җете, үтә, иң* кебек кисәкчәләр сыйфатлар һәм рәвешләр алдында килеп, үзләренә басым кабул итәләр, һәм бу вакытта алардан соң килә торган мөстәкыйль сүз, басымын югалтып, энклитикага әверелә: *а́п‿ак, кы́п‿кызыл, көпә́‿көндез, шы́р‿алангач, үтә́‿матур* һ.б.

Бу яктан постпозитив *гына / генә / кына / кенә* кисәкчәсе аеруча кызыклы. Фигыльләр, рәвешләр, сыйфатлар янында кулланылганда, бу кисәкчә, аларга чикләү төсмере бирә һәм, басымын югалтып, энклитикага әверелә: *ти́з‿генә, а́л‿гына, я́шь‿кенә* һ.б. Ә исемнәр, алмашлыклар, саннар янында килгәндә, бу кисәкчә аларны логик яктан аерып күрсәтү өчен хезмәт итә һәм, үзенә басым алып, алда

килгән сүзләрне проклитикага әверелдерә: *эт‿кенә́, шул‿гына́, бер‿генә́* һ.б.

Берничә иҗекле проклитика һәм энклитикаларда көчсезләнгән өстәмә басым була. (´) тамгасы белән күрсәтелә торган төп басымнан аермалы буларак, өстәмә басым (`) тамгасы белән күрсәтелә: *эшли́‿икә̀н* һ.б.

Өстәмә басым кушма сүзләрдә һәм күп иҗекле сүзләрдә дә булырга мөмкин.

Парлы сүзләрдә, гадәттә, төп басым – беренче сүзнең соңгы иҗегенә, өстәмә басым икенче сүзнең ахырына төшә: *бала́-чага̀, тиме́р-томы̀р, килә́-килә̀* һ.б.

Кушма сүзләрдә төп басым, гадәттә, соңгы иҗеккә төшә, ә беренче компонентның «иске» басымы урынында өстәмә басым тоемлана: *кара̀бода́й, ю̀лбаса́р, чы̀нбарлы́к* һ.б.

Ә тезмә сүзләрдә, гадәттә, барлык компонентлары да үзләренең төп басымнарын саклыйлар.

Гадәттә, сүз басымының ике фонологик функциясен аералар. Беренчесе – конститутив, ягъни сүзне таныту функциясе; бу – басым сүзнең мәҗбүри элементы булып тора, һәм басымны күчерү сүзне аңлашылмас хәлгә китерә, дигән сүз. Басымның мондый функциясе, гадәттә, ирекле басым булган телләрдә (мәсәлән, рус теле) күзәтелә һәм татар теле өчен ул хас түгел. Төрле стилистик максатлардан чыгып, яки эмфатик басым төшкәндә, татар сүз басымын теләсә кайсы иҗеккә күчереп була, һәм аңа карап нормаль аралашу процессы бозылмый.

Татар телендә басымның икенче фонологик функциясе күзәтелә. Бу – мәгънә аеру функциясе. Бу функция *алма́ – а́лма, кара́ – ка́ра, карама́ – кара́ма,* тибындагы омографларда ачык күренә. Мондый сүзләр шактый күп, һәм аларны түбәндәге төркемчәләргә берләштереп була:

а) *-ма/-мә* кушымчасы белән ясалган исемнәр һәм боерык фигыльнең юклык формасы: *басма́ – ба́сма, ташлама́ – ташла́ма* һ.б.

б) урын-вакыт килешендәге исемнәр, алмашлыклар һәм *-да/-дә/-та/-тә* кисәкчеләре белән килгән шул ук сүзләр: *малайда́ – мала́й да.., миндә́ – ми́н дә,* һ.б.

в) төрле фигыль формалары: *ата́ – а́та, үтә́ – ү́тә, ура́ – у́ра* һ.б.

г) кайбер очраклы омографлар: *хәе́р* (исем) – *хә́ер* (модаль сүз), *сө́ял* (исем) – *сөя́л* (фигыль), *яңа́* (сыйфат) – *я́ңа* (рәвеш) һ.б.

Басымның сүзләрне аера алу очраклары белән бергә басымның вариативлыгы дигән күренеш тә очрый. Бу – басымның бер үк сүздә төрле урында килә алуы. Вариантларның берсе норматив булырга, икенчесе гади сөйләмдә, яки диалектларда гына очрарга мөмкин.

Кайчак вариативлык семантик яки стилистик дифференциация белән дә бәйләнгән булырга мөмкин. Мәсәлән, *бүге́н, бые́л* сүзләрендә басымның соңгы иҗектә булуы норматив булып исәпләнә, ә сүз башына төшә торган вариатив басым бу сүзләрне логик яктан аеру өчен хезмәт итә: *бы́ел* (нәкъ менә бу елда)*, бү́ген* (нәкъ менә бүген). Яки саннардагы норматив сүз азагы басымы сүз башына күчсә, санау интонациясен барлыкка китерә (*бер, и́ке, өч, дүрт, биш, а́лты, җи́де, си́гез, ту́гыз...*). Фигыльләр кабатланганда, сүз башына төшә торган вариатив басым да мәгънәне көчәйтү өчен хезмәт итә: *та́рттым, та́рттым – тартып чыгара алмадым.*

Кайвакыт әдәби норма чикләрендә дә басымның тирбәлүе күзәтелә: бер сүз эчендә бернинди дифференциациясез басымның төрлечә төшү очраклары була. Алар төрле хезмәтләрдә, төрле авторларда һәркайсы норма буларак тәкъдим ителә. Мәсәлән, *укымаска́ – укы́маска, атта́й – а́ттай, филдә́й – фи́лдәй* һ.б. Күрәсең, мондый очракларда боларның берсенә өстенлек бирергә, икенчесен «куллану хата түгел» дип күрсәтергә кирәктер.

# 4. ИНТОНАЦИЯ

Интонация – ул сөйләмнең ритмик-мелодик агышы, сөйләмнең мәгънәле кисәкләрен аеру, синтаксик мәгънәләр белдерү, сөйләмгә субъектив мөнәсәбәт белдерү өчен хезмәт итә торган аваз чаралары җыелмасы.

Гадәттә, интонациянең ике аспектын күрсәтәләр. Беренчесе – коммуникатив аспект. Бу аспекттан татар интонациясенең берничә функциясен аерырга була:

а) сөйләм агымын оештыру һәм кисәкләргә бүлү функциясе. Бу – сөйләмне синтагмаларга, җөмләләргә, фразаларга бүлү;

б) әйтелеш типларын формалаштыру, аеру, җөмләнең коммуникатив төрләрен (хикәя, сорау, өндәү) аеру функциясе. Мәсәлән: *Ул кайтты. Ул кайтты? Ул кайтты!*

в) интонацион берәмлекләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тәгъбир итү функциясе – интонация җөмләне актуаль кисәкләргә бүлүдә катнаша. Мәсәлән, *Илдар киләчәк,* дигән җөмләдә логик басымның *Илдар* яки *киләчәк* сүзләренә төшүенә карап, төрле моментларга игътибар ителә – килүнең субъекты, яки килү факты ассызыклана.

Интонациянең икенче аспекты – эмоциональ аспект. Бу – эмоциональ мәгънәләр һәм төсмерләр белдерү; сөйләүченең эмоциональ халәтен, аның тыңлаучыга ничек тәэсир итү теләген белдерү; интонациянең модальлек белдерүе. Әйтик, *Илдар киләчәк* җөмләсе калган бөтен функцияләре сакланган хәлдә төрле төсмерләр белән (шатлану, борчылу, курку һ.б.) әйтелә ала.

Интонациянең иң мөһим компоненты булып мелодика, яки сөйләм көе тора. Бу – тавышның төп тоны түбән төшү, яки югары күтәрелү. Төп тонның хәрәкәт юнәлеше: тигез ——, төшүче ——\, күтәрелүче /——, төшүче-күтәрелүче __/, күтәрелүче-төшүче /—\ һәм катнаш /—__/ булырга мөмкин. Төшүче һәм күтәрелүче сызыкның түбәнге һәм югарыгы нокталары арасындагы аерма – интервал; еш-

лыкның арту яки кимү тизлеге, ягъни кәкре сызыкның күтәрелү яки төшү текәлеге интонация өчен мөһим роль башкара.

Мелодика татар телендә төрле функцияләр башкара. Пауза белән бергә ул сөйләмне синтагмаларга бүлә. Мәсәлән, *Без* (*түбәннән*) *тормышның төбеннән күтәрелдек* (16 нчы рәсем).




16 нчы рәсем

Бу җөмләдә синтагмалар арасында чикләр мелодик сурәттә «сынган» урыннар аша – югарыда калган сызыктан түбәннән башлана торган сызыкларга күчеш аша билгеләнә. Татар теленең күп синтагмаларына хас мондый мелодика, ягъни тонның сөйләм берәмлеге ахырына күтәрелеп калуы, тәмамлаган фикерне белдергәндә, сөйләмнең бер берәмлеге алдарак әйтелгән икенче берәмлек белән тыгыз семантик-синтаксик бәйләнештә булганда күзәтелә. Биредә мелодиканың икенче функциясе – сөйләмнең аерым кисәкләрен бәйләү функциясе дә чагылыш таба.

Мелодиканың чираттагы бик мөһим функциясе – җөмләнең коммуникатив төрен (хикәя, сорау һ.б.) белдерү. Мәсәлән, татар телендә сорау төп басым төшкән иҗекнең әйтелү тоны югары күтәрелү белән белдерелә. Гомуми сорауның төрле төрләрен белдерү өчен төп тонның югарыгы ноктасы, күтәрелүнең төгәлләнү дәрәҗәсе, күтәрелешнең текәлеге һ.б. хезмәт итә. Сорауның һәрбер төре башкаларыннан сорауның ахырына таба төп тон хәрәкәтенең күтәрелү һәм төшү сурәте белән аерылып тора.

Мелодика сүзләрне логик яктан аерырга да ярдәм итә. Мәсәлән, *Ат килә* җөмләсендә логик басымны иядән хәбәргә күчерү белән тонның хәрәкәт төре кискен үзгәрә – төшүчедән эзлекле рәвештә күтәрелүчегә әйләнә.

Интенсивлыкның төп функциясе – сөйләмнең аерым элементларын аеру. Ул интенсивлыкның көчәюе аша башкарыла. Интенсивлыкның артикуляцион корреляты булып – сөйләм органнарының киеренкелек дәрәҗәсе, акустик корреляты булып тавыш ярыларының тирбәлеш амплитудасы тора.

Татар телендә интенсивлык синтагма, яки фраза басымын барлыкка китерүдә катнаша. Моның өчен синтагмадагы берәр сүзнең басымы көчәйтелә. Интенсивлык сөйләмнең актуаль бүленешенә ярдәм итә, логик басым барлыкка китерә. Логик басым ул, контекст яки ситуация таләбеннән чыгып, басымлы сузыкның көчен арттыру аша берәр сүзнең басымын көчәйтү юлы белән барлыкка килә (*Илдӑ̋р киләчәк – Илда́р киләчә̋к*).

Интонация компоненты буларак озынлык турында сөйләшкәндә, аерым сүз һәм синтагмаларның башкалар белән чагыштырмача әйтелеш тизлеге, ягъни сөйләм темпы күздә тотыла.

Озынлык яки темпның төп лингвистик роле – сөйләм берәмлегенең мөһимлек дәрәҗәсен белдерү. Мәсәлән, татар телендә кереш сүзләр һәм кереш җөмләләр, туры сөйләмдәге автор сүзләре һ.б. чагыштырмача тизрәк әйтеләләр.

Темп мелодика белән бергә җөмләнең коммуникатив төрен белдерүдә катнаша. Мәсәлән, сорау җөмләнең төп басым төшкән иҗеге әйтелеш тизлегенең акрынаюы белән дә характерлана.

Темп сөйләмне синтагмаларга бүләргә дә ярдәм итә. Гадәттә, синтагмаларның беренче иҗеге – тизрәк, ә соңгылары акрынрак темпта әйтелә. Шушы нигездә синтагма чикләрендә темп контрасты барлыкка килә.

Җанлы сөйләмдә синтагматик басымлы сузыкның озынлыгын арттыру төрле эмоциональ төсмерләр тудыру өчен, ягъни эмфатик басым барлыкка китерү өчен хезмәт итә. Мәсәлән, *Ки-и-и-ил инде!* (үтенү, иркәләү); *Ки-и-ит моннан!* (ачулану, дорфалык) һ.б.

Интонациянең мөһим компонентларыннан берсе – пауза, яки тыныш. Фонетик яктан бу – тавышның туктап торуы гына түгел, мелодиканың кискен күчешләре, озынлык һәм көч контрастлары да сөйләмнең туктап алуы булып кабул ителергә мөмкин. Мәсәлән, *«Орлыклар вакытында чыга алмый калганнар»* дигән җөмләдә *«орлыклар»* һәм *«вакытында»* сүзләреннән соң паузалар бар кебек, ә экс-

перименталь анализ нәтиҗәләре ул урыннарда бернинди дә пауза булмавын күрсәтә. Бары ул сүзләрнең соңгы иҗегендәге сузыклар нык кына озынайган, ә *«вакытында»*, *«чыга»* сүзләренең беренче иҗегендәге сузыклар кыскарганнар, һәм шушы күренеш безгә пауза булып тоела. Уҗ – «ялган пауза», дип атала.

Паузаның төп функциясе – сөйләм агымын интонацион-мәгънәви кисәкләргә (синтагма, фраза) бүлү. Синтагмалар 90% очракта бер-берсеннән паузалар белән аерылалар.

Паузалар җөмләләрне дә бер-берсеннән аералар, кереш сүзләрне, эндәш сүзләрне аерырга мөмкинлек бирәләр. Гомумиләштерүче сүзләр белән тиңдәш кисәкләр арасында аеруча зур пауза була.

Кайбер очракларда пауза мәгънә аеру өчен дә хезмәт итә. Мәсәлән, *«Минә шул бабай / үләр алдыннан үзенә чакырды да / миңа бер уч тутырып / орлыклар бирде»* җөмләсендә паузаларның урынын үзгәртсәң, шул ук составтагы, сүз тәртибе дә шул ук булган җөмләнең синтагмаларга бүленеше үзгәрә, мәгънәгә дә үзгәреш керә: *Минә шул / бабай үләр алдыннан / үзенә чакырды да / миңа бер уч тутырып / орлыклар бирде.*

Паузалар сөйләм агымын кисәкләргә бүлү өчен генә хезмәт итеп калмыйлар, шул кисәкләр арасындагы бәйләнешләрнең характерын да билгелиләр. Мәсәлән, *«Болыт чыкты – яңгыр яумады»* җөмләсендә пауза тезүле бәйләнешне белдерүче чара булып тора. Паузалар җөмләләр арасындагы ияртүле бәйләнешне белдерүдә кушымчалар, бәйлекләр, теркәгечләр белән бергә дә катнашалар, ә соңгылары булмаганда, пауза җөмләләрне бәйләүче бердәнбер чара булып кала: *Шул вакыт күрәм / лампам эчендә май кими* (Г. Тукай).

Пауза төрле эмоциональ төсмерләр белдерүдә дә катнаша. Мәсәлән, *«Син... кайттың?»* җөмләсендә зур пауза мелодика белән бергә бик нык гаҗәпләнүне белдерә. Спонтан сөйләмдә паузалар көчле тәэсирләнү, нәрсәнедер әйтә алмау, әйтергә теләмәү аркасында да барлыкка киләләр; кайчак мондый паузаларадан соң сөйләм бөтенләй башка юнәлеш алырга мөмкин. Мондый паузалар – хезитация паузалары, дип атала.

Просодик тембрның акустик корреляты булып авазларның спектраль характеристикасы тора. Татар телендә тембр сөйләмнең гомуми эмоциональ төсмерен, аерым хисләрне белдергәндә чагылыш таба. Тембрның кайбер доминанталарын да атарга була. Мәсәлән, бөтен

авазларны да көчле иренләштерү балалар белән назлап сөйләшү төсмерен бирә: [ка$^{с}$ра с$^{ө}$ин а$^{о}$но / н$^{ө}$инди зур үск$^{ө}$ән]. Иренсезләштерү, киресенчә, усаллык, ачулануны белдерә. Тагын бер факт шушы фикерне раслый: статистик анализ күрсәтүенчә, татар телендә уңай хисләрне белдерә торган сыйфатларда иренләшкән сузыклар, «тискәре» сыйфатлардагыга караганда, 1,5–2 тапкыр күбрәк кулланылалар.

Мелодика, көч һәм озынлык белән бергә, тембр сүзне эмоциональ яктан аеру өчен, ягъни эмфатик басым тудыру өчен хезмәт итә. Мәсәлән, *«Ул әйбә-ә-әт кеше!»* җөмләсендә сузыкның характерлы тембры һәм төшүче-күтәрелүче мелодика ярдәмендә барлыкка килгән эмфатик басым *«әйбәт»* сүзен аерып күрсәтә һәм аңа лексик мәгънәсенә капма-каршы булган мәгънә бирә (*Беләм мин аның нинди әйбәт икәнен! Күрсәтте инде ул үзенең нинди әйбәт икәнен!* һ.б.).

Интонациянең компонентлары, сөйләм агымындагы төрле фонетик чаралар бик тыгыз бәйләнгән булалар, шул ук вакытта һәрберсенә аерым мәгънәви бурыч йөкләнгән була.

1. Төрле интонацион конструкцияләр мелодика, интенсивлык, озынлык һәм тембрның төрле күләмдә катнашуы аша ясалалар. Мәсәлән, татар телендә сорау мелодика һәм озынлык ярдәмендә барлыкка китерелә, ә көч һәм тембр – сорау өчен иррелевант билге. Боерык һәм тойгылы җөмләләр өчен интенсивлык һәм тембр иррелевант билгегә әверелә.

2. Татар сөйләмен синтагмаларга бүлгәндә, мелодика, темп һәм пауза актив катнаша. Ә синтагма яки фраза басымын барлыкка китерү өчен, инде әйтелгәнчә, шул сүзнең басымы көчәйтелә, шулай булгач, синтагма басымын төзүче компонентлар булып, сүз басымы компонентлары – озынлык, көч, тон югарылыгы хезмәт итә.

3. Эмфатик басымны барлыкка китерүдә һәм төрле эмоциональ-экспрессив төсмерләр белдерүдә интонациянең барлык компонентлары катнаша ала Дөрес, аларның чагыштырмалары төрлечә була.

Телнең интонацион чаралары синтаксик төзелеш белән тыгыз бәйләнештә булалар. Бу бәйләнешләр төрле синтаксик төзелмәләрне тасвирлаганда да каралалар.

ӘДӘБИЯТ


Абдулкасымова Г.Н. Интонационно-семантический анализ восклицательных речевых единиц в английском и узбекском языках (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Л., 1988. 15 с.

Абрамова И.А. Интонация предложения и просодия слова: дис. ... канд. филол. наук. Л., 1988. 192 с.

Алексеев И.Е. Типология структурно-коммуникативных и интонационных систем высказывания в якутском языке: автореф. дис. … до-ра филол. наук.Алма-Ата, 1994. 58 с.

Алексеева Т.И. Описание единиц просодии русского и болгарского языков: дис. ... канд. филол. наук. М., 1995. 184 с.

Антонова Д.Н. Фонетика и интонация. М.: Русский язык, 1988. 77 с.

Артемов В.А. Речевая интонация // Эксперментальная фонетика. Вып. 3. Минск, 1971. С. 12–43.

Асылгараев Ш.Н., Губайдуллина Г.Т. Истоки экспериментальной фонетики в татарском языкознании // Научный Татарстан. 2009. № 4. С. 31–38.

Вейсалова, Д.Ш. Просодия служебных слов в современном немецком и азербайджанском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Азерб. пед. ин-т. Баку, 1990. 22 с.

Виноградов В. В. Понятие синтагмы в синтаксисе русского языка // Вопросы синтаксиса современного русского языка. М., 1950. С. 12–24.

Виноградов В.А. Сингармонизм и фонология слова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1966. 22 с.

Геворошкин В.В. Звуковые цепи в языках мира. М.: Наука, 1969. 188 с.

Дахаматов А. К вопросу о функциях тюркского ударения // Советская тюркология. 1984. № 1. С. 65.

Дерба Л.В. Фонетика французского языка. М.: Изд-во лит-ры на иностранных яз., 1955. 304 с.

Дербилова Ж.И. Вариативность просодической структуры слова в различных коммуникативных типах предложений: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Л., 1980. 14 с.

Джафарова А.С. Акцентная структура слов в азербайджанском языке // Звуковые системы сибирских языков. Новосибирск, 1989. С. 20–23.

Джунисбеков А. Проблемы тюркской словесной просодии: автореф. дис. ... д-ра. филол. наук. Алма-Ата, 1988. 58 с.

Джунисбеков А. Просодика слова в казахском языке. Алма-Ата: Наука, 1987. 38 с.

Джунисбеков А. Сингармонизм в казахском языке. Алма-Ата: Наука, 1980. 76 с.

Добровольская Л.Я. Акцентные единицы в формировании просодической структуры фразы (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Минск, 1975. 29 с.

Дубовский Ю.А. Анализ-синтез-анализ просодии устного текста и его составляющих (экспериментально-фонетическое исследование): дис. ... д-ра. филол. наук. Минск, 1978. 325 с.

Ермоленко Г.И. Модальная семантика речевой просодии и ее метаязык (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Пятигорск, 1988. 18 с.

Жанабаева С.Б. Сингармонизм и просодия слова (экспериментально-фонетическое исследование на материале казахского языка): дис. … канд. филол. наук. Л., 1985.

Жунисбек А. Введение в сингармоническую фонетику. Алматы: Арыс, 2009. 108 с.

Зиязов Д.М. Интонация повествования в современном узбекском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Ташкент, 1969. 31 с.

Златоустова Л.В. Фонетическая структура слова в потоке речи. Казань, 1962. 155 с.

Златоустова Л.В. Фонетические единицы русской речи. М.: Изд-во МГУ, 1981. 105 с.

Златоустова Л.В., Потапова Р.К., Трунин-Донской В.Н. Общая и прикладная фонетика. М.: Изд-во МГУ, 1986. 304 с.

Зорк О.А. Изучение интонации на современном этапе некоторые задачи интонационных исследований // Иностранные языки в школе. 1970. № 4. С. 11–19.

Зорк О.А. Интонация // Крушельницкая К.Г. Очерки по сопоставительной грамматике немецкого и русского языков. М., 1961.

Ибрагимов Т.И. Вопросы интонационного синтеза татарской речи. Реконструкция ритмики письменного текста // Тр. Казан. шк. по компьютерной и когнетивной лингвистике TEL – 2008. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2009. – С. 123–128.

Ибрагимов Т.И. К проблеме реконструкции звучания письменного текста. Редукция кратких гласных в татарском языке // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия гуманитарные науки. Книга 3 / науч. ред. М.Х. Салахов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2009. С. 288–298 и др.

Интонация и фонология // Сб. науч. тр. Университета дружбы народов им. П. Лумумбы. М. 1980. 88 с.

Исхаков Ф.Г. Законы словесного ударения в татарском языке // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. 4.1: Фонетика. М.: Изд-во АН СССР, 1955. С. 329–332.

Краснова Т.А., Войтович И.К. Опознание интонации неродного языка в свете проблемы интерференции языковых единиц // Проблемы двуязычия и многоязычия в современных условиях. Йошкар-Ола, 1993. С. 54–56.

Курбатов Х.Р. Система татарской лингвистической стилистики и поэтики: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казан, 1992. 46 с.

Курбатов Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М.: Наука, 1978. 418 с.

Лахаматов А. Акцентуация речевого такта в русском и узбекском языках // Советская тюркология. 1985. № 5. С. 44–46.

Мамедов А.М. Контрастивно-типологический анализ просодики фонологических систем: автореф. дис. ... д-ра. филол. наук. Баку, 1990. 53 с.

Метлюк А.А. Взаимодействие просодических систем в речи билингва (теоретическое и экспериментально-фонетическое исследование): дис. д-ра. филол. наук. Минск, 1989. 308 с.

Сайхунов М.Р. Ритмо-темпоральные характеристики татарского языка в плане автоматического синтеза речи: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2010. 26 л.

Салимов Х. Х. Просодическая система татарского языка: дис. … д-ра филол. наук. Казань, 1999.

Сасевич В.Б. К типологии просодических систем // Исследование звуковых систем языков Сибири. Новосибирск: Наука, 1984. С. 173–187.

Сасевич В.Б. Слог в общем и дальновосточном языкознании // Теория языка. Методы ее исследования и преподавания. Л., 1981. С. 46–68.

Сасевич В.Б., Шабельникова Е.М., Рыбин В.В. Ударение и тон в языке и речевой деятельности. Л.: Изд-во ЛГУ, 1990. 68 с.

Сацнельсон С.Д. Фонемы, синдемы и промежуточные образования // Фонетика, фонология, грамматика. М., 1971. С. 46–64.

Семелева К.Н. Фонетическая реализация основных интонационных типов в условиях сингармонизма: дис. ... канд. филол. наук. Л., 1988. 218 с.

Сиекбаев Д. Г. Фонетика башкирского языка (Опыт описательного и сравнительно-исторического исследования): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1959. 46 с.

Сотлеев В.И. Акустические признаки чувашского словесного ударения // Советская тюркология. 1981. № 4. С. 57.

Сохнович Т.К. Роль просодических средств в дифференциации коммуникативных типов высказываний: автореф. дис. ... канд. филол. наук.Минск, 1975. 21 с.

Сривнова О.Ф. Некоторые особенности интонационной системы русского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1969. 13 с .

Темирова, А. Б. Просодический аспект фонологических систем (на материале кабардино-черкесокого и английского языков): автореферат дис. ... канд. филол. наук. М., 1992. 20 с.

Шалимов Х.Х. Вокализм барабинского диалекта татарского языка (экспериментально-фонетическое наблюдение) // Исследование звуковых систем языков Сибири. Новосибирск: Наука. Сиб. отд-ние, 1984. С. 17–22.

Ясаебекова С.З. Роль просодии в выражении обращенности речевых актов (экспериментально-фонетическое исследование на материале французского языка): автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1988. 18 с.

Яшбердин Э.Ф. Ударение и система гласных башкирского языка // Советская тюркология. 1980. № 5. С. 55–58.

Яшбердин Э.Ф. Эмфатическое ударение в башкирском языке // Фонетика языков сибири и сопредельных регионов. Новосибирск: Наука, 1986. С. 120–121.

Абдуллина Р.С. Тел һәм сөйләм берәмлеге буларак паузалар // Фән һәм мәктәп. 1997. № 9. С. 86–88.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1958. 243 с.

Зәкиев М.З., Асылгараев Ш.Н. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше // Совет мәктәбе. 1967. № 4. С. 31–35.

Кудашев Г.К. Татар телендә фонетик һәм морфологик үзгәрешләр // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Курбатов Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 164 с.

Сиекбаев Д.Г. Башкорт теленең фонетикасы. Өфе, 1958.

Сиекбаев Ж.Г. Хәзерге башкорт теленец лексикасы һәм фразеологиясы. Өфе: Башкорт. кит. нәшр., 1966. 276 с.

Кеңесбаев І.К., Мұсабаев Е. Қазіргі қазақ тілі. Лексика. Фонетика. Алматы: Қазмемоқупедбас, 1962. 315с.

# 5. ГРАФИКА ҺӘМ ОРФОГРАФИЯ

## 5.1. ГРАФИКА

**Графика турында гомуми төшенчә.** Язуда кулланыла торган барлык хәрефләрнең дә билгеле бер тәртиптә урнаштырылып бирелүе алфавит (әлифба) дип йөртелә. (Ул грек алфавитындагы беренче ике хәреф – «альфа» һәм «бета» исеменнән алынган.) Хәрефләрнең формасы һәм аларның телдәге авазларга ни дәрәҗәдә туры килүен тел гыйлеменең графика дигән бүлеге өйрәнә (*grāphikē* – грекча «рәсем төшерү»). Алфавиттагы хәрефләрне кулланып, сүзләрне дөрес язу орфография кагыйдәләре тарафыннан билгеләнә.

Телнең алфавит һәм орфографиясе әдәби телгә карап төзелә. Шуңа күрә анда әдәби телдә булмаган диалект һәм сөйләш үзенчәлекләре чагылдырылмый.

Татар язуы аваз-хәреф язуыннан гыйбарәт. Телдәге авазлар анда шартлы график билгеләр – хәрефләр белән билгеләнә. Хәзерге татар алфавиты 38 хәрефтән тора. Басма һәм кулъязма хәрефләрнең һәркайсының баш һәм юл хәрефе формалары бар:

Аа Әә Бб Вв Гг Дд Ее Жж Җҗ Зз Ии Йй Кк Лл Мм Нн Ңң Оо Өө Пп Рр Сс Тт Уу Үү Фф Хх Һһ Цц Чч Шш Щщ Ъъ Ыы Ьь Ээ Юю Яя.

**Алфавиттагы хәрефләрнең татар телендәге фонемаларга туры килеше.** Сузык фонемаларны билгеләү. Татар әдәби теленең *қ, ғ,w*авазларыннан башка барлык фонемалары өчен дә язуда аерым хәрефләр бар. Ләкин кайбер хәрефләр татар теленең үз фонемаларын гына түгел, рус теленнән яки аның аша бүтән телләрдән кергән башка төрле фонемаларны да белдерәләр. Бу очракта бер хәреф ике төрле фонема билгесе булып йөри.

Калын сузыклар – *а, о, у, ы, ый,* нечкәләре *ә, ө, ү, э – е, и* хәрефләре белән бирелә. Калын сузыкларны белдергән хәрефләр – сүзләрнең калын иҗекләрендә, нечкә сузыкны белдергәннәре нечкә иҗекләрдә языла.

*А* хәрефе *а* фонемасын белдерә: *ат, арба, чана; а* хәрефе шулай ук күп иҗекле сүзләрнең беренче иҗекләрендә – *а* фонемасы *о*-лаштырып әйтелгән очракларда да языла: *багана [ба$^{о}$ғана], баганалар [ба$^{о}$ға$^{о}$на-$^{о}$лар], бакчаларда [ба$^{о}$қча$^{о}$ла$^{о}$рда].*

*Йа, йу* дифтонглары *я, ю* хәрефләре белән бирелә: *ялкын, кыя, аяз, юл, баю, юа.*

*О, ө* хәрефләре татар теленең тар *ŏ, ө* фонемаларын белдерә һәм бер тамырлы сүзләрнең беренче иҗегендә языла; калган иҗекләрдә иренләштерелгән *ы̆$^{о}$, ĕ$^{ө}$* авазлары *ы, е* хәрефләре белән бирелә: *толым, солы, борылыш; көн, көндез, бөтенесе. О, ө* хәрефләре кушма сүзләрнең икенче тамырындагы беренче иҗектә дә саклана: *аккош, озынборын, Гөлйөзем, Миңлегөл.*

*Ы, е* хәрефләре татар теленең *ы̆, ĕ* фонемаларын белдерә: *ындыр, кыр, тары; кеше, белем, беренче.* Бу хәрефләр, югарыда күрелгәнчә, сүзнең икенче һәм аннан соңгы иҗекләрендә *ы̆$^{о}$, ĕ$^{ө}$* авазлары өчен дә языла. *Е* хәрефе *ĕ* фонемасы өчен сүз башында язылмый. Бу очракта *ĕ* фонемасы э хәрефе белән бирелә: *эш, эз, эзлә, эссе, элек.*

*Е* хәрефе сүз һәм иҗек башларында *йы – йе* әйтелешләрен белдерә: *ел, ерак, егет, каен, җәен, поезд, Ереван.*

*Ә, у, ү, и* хәрефләре *ә, у, ү, и* фонемаларын белдерә һәм сүзнең шул авазлары әйтелгән һәр урынына языла: *әрәмә, урам, бүлмә, ил, иген.*

Сүз һәм иҗек ахырында *у – ү* хәрефләре *w* фонемасын белдерә: *тау, дәү, яуда.*

*Ый* язылышы *и* фонемасының калын парына – *ы̆й* дифтонгына (кушык сузыгына) билге булып йөри: *ярый, уйный, сый.*

Югарыда күрсәтелгәннәрдән тыш, *а, о, у, ы, ый* хәрефләренең *к, г* хәрефләре янында *ә, ө, ү, ĕ, и* авазлары өчен язылу очрагы да бар. Бу очракта *а, о, у, ы, ый* хәрефләре шартлы рәвештә *к, г* хәрефләренең *к, г* түгел, бәлки *қ, ғ* фонемалары булып укылуын белдерә: *каләм [қәләм], табигый [табиғи], Гали [Ғәли].*

Әгәр андый иҗек тартык авазга бетсә, ул тартыктан соң нечкәлек билгесе куела. Нечкәлек билгесе тартыкның нечкәлеген түгел, *а, о, у, ы, ый* хәрефләренең *ә, ө, ү, ĕ, и* булып укылуын белдерә: *табигать [табиғәт], шагыйрь [шағир], сәгать [сәғәт], хакыйкать [хақикәт].*

Әгәр *қ, ғ* авазлары иҗек ахырында булып, аннан соң башка берәр тартык аваз килсә яки сүз шунда тәмамланса, *к, г* хәрефләренең

*қ, ғ* булып укылуын белдерү өчен *ъ* билгесе языла: *нәкъ, дикъкать, дәгъва.*

Рус теленнән яки аның аша башка телдән кергән сүзләрдә *о, ы, э – е* хәрефләре үзенә башка төрле фонемаларны – киң әйтелешле *ō, ы̄, ē* сузыкларын күрсәтә: *вагон, завод, роль, промышленность, посылка, эра, поэма, электр, тема, тезис.*

Алфавиттагы *я, ю* хәрефләре *и* авазы төсмере белән әйтелүче нечкә (палаталь) тартыклардан соң – *а, у* фонемаларын, сүз һәм иҗек башларында исә *йа, йу* авазларын белдерә һәм беренче очракта рус теленнән яки аның аша башка телдән кергән сүзләрдә генә, ә икенче очракта татар сүзләрендә дә кулланыла: *октябрь, отряд, революция, семья, бюро, июнь, юбилей; яз, югары. Я, ю* хәрефләре татар сүзләрендә шулай ук *йә, йү* әйтелешен дә белдерә: *яшь [йәш], җәя [җәйә], җәю [җәйү], юкә [йүкә].*

Т а р т ы к ф о н е м а л а р н ы б и л г е л ә ү. Татар телендә тартык авазларның калынлыгы-нечкәлеге сузыкларның нинди булуына ияргәнлектән, тартык фонемаларның калын һәм нечкә вариантларына икесенә бер генә хәреф алына. Мәсәлән, *б, л, н, р, т, с* хәрефләре *болын, тора, сора* сүзләрендә – бер үк тартык фонемаларның калын вариантларын, *бүлмә, төрә, сөрә* сүзләрендә нечкә вариантларын белдерә.

*Қ* һәм *к* фонемалары – *к* хәрефе белән, *ғ* белән *г* исә *г* хәрефе белән берләштереп бирелә: *канат [қанат һәм канат], карта [қарта һәм карта], агым [ағым], күбәләк, сәгать [сәғәт], хакыйкать [хақиқәт].*

Тартык фонемаларның яңгырау һәм саңгырау парлары татар алфавитында аерым хәрефләр белән бирелә: *б – п, в – ф, г – к, д – т, ж – ш, җ – ч, з – с, һ – х.*

Үзенчәлекле тартык – һәмзә (кнаклаут) *э, ь, ъ* хәрефләре белән күрсәтелә: *тәэмин, тәэсир, мәсьүл, Мәэмүн.*

*В* хәрефе татар сүзләрендә (сүз һәм иҗек башларында) *w* авазы өчен языла: *ватан, вакыт, дәвер, савыт, вәкил* (*wатан, wақыт, дәwер, саwыт, wәкил* укыла); рус теленнән кергән сүзләрдә һәм фамилия ясагыч *-ова, -ева* кушымчаларында *в* хәрефе ирен-теш тартыгын белдерә: *вагон, завод, взвод, Сәлимова.*

*Ц, щ* хәрефләре рус теленнән яки аның аша башка телдән кергән сүзләрдә генә языла: *циркуляр, цирк, щи.*

## 5.2. ОРФОГРАФИЯ

**Орфография турында гомуми төшенчә.** Орфография (грекча *orthos* ‘дөрес’ һәм *grāpho* ‘язам’ сүзләреннән) – гомум кабул ителгән, бердәм нормаларга салынган (унификацияләнтән) һәм һәркемгә мәҗбүри саналган практик язу системасы. Башкача әйткәндә, орфография – әдәби телнең фәнни нигезләнгән һәм дәүләт тарафыннан законлаштырылган язу кагыйдәләре җыемы. Кайда ничек әйтүләренә карамастан, сүзләрне әдәби телдәгечә дөрес һәм тиз укуны тәэмин итү – орфографиягә карата куелган төп таләп. Орфография сүзләрнең һәм кушымчаларның дөрес язылышын, сүзләрнең аерым яки кушылып язылуларын, баш хәрефләрнең кулланышын һәм сүз кисәкләрен юлдан юлга күчерүне билгели, аларны кагыйдәләштереп бирә. Орфография кагыйдәләренә шулай ук мәгънә аеру язылышлары (дифференциацияләнгән язылыш) да керә.

**Татар орфографиясенең төп принцибы.** Орфография төзүдә берничә принцип бар: фонетик, морфологик, тарихи-традицион һәм график принциплар. Бу принциплар, телнең фонетик-морфологик үзенчәлекләреннән чыгып, төрле телдә төрле дәрәҗәдә кулланыла. Әлбәттә, теориядә дә, практикада да иң яхшы, иң уңай дип танылганы – фонетик принцип. Чөнки сүздә нинди авазлар әйтелсә, шуларның үз график билгеләрен куеп язу ансат та, фонетик яктан төгәл дә. Сүз төрләнү һәм үзгәрү белән авазлары артык күп үзгәрүләргә, чиратлашуларга дучар булмаган телләрнең язуы өчен фонетик принцип, һичшиксез, төп нигез итеп алына. Хәзерге татар язуы, башлыча, шул принципка корылган. Татар әдәби телендә сүзләр ничек, нинди авазлар белән әйтелсә – шулай языла, бу безнең орфография өчен төп кагыйдә. Татар язуында бу кагыйдәнең тотрыклы үткәрелүе телебез өчен хас сингармонизм законын – калын сүзләрнең – калын сузыклар, нечкәләрнең – нечкә сузыклар белән генә әйтелүен (мәсәлән, *йортларның, чәчәкләрнең*) анык чагылдыруда гына түгел, күп очракта авазларның төрле-төрле комбинатор үзгәрүләрен, чиратлашуларын тулысынча бирүдә дә күренә. Мәсәлән: тамыр яки нигез азагындагы *қ, к, п* авазлары, сүзгә сузык яки сонор аваздан башланган кушымча ялгану белән, *г, г, б* авазларына әйләнә, һәм моны орфография дә кире какмый: *ак – агы, аграк, ефәк – ефәге, китап, китабы, туктап, туктабрак.* Күплек

кушымчасы *лар – ләр* борын авазларыннан соң *нар – нәр* формасын ала һәм шулай языла да: *урамнар, таңнар, үләннәр.* Нинди аваздан соң килүләренә карап, юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешләренең кушымчалары берничә төрле вариантта йөри – шулай ук бу төрлелек тә язуда күрсәтелә: юнәлеш килешендә – *атка, эшкә, бакчага, чирәмгә* (*ка – кә, га – гә*)*;* чыгыш килешендә – *аттан, эштән, бакчадан, чирәмнән* (*тан – тән, дан – дән, нан – нән*)*;* урын-вакыт килешендә – *атта, эштә, бакчада, чирәмдә* (*та – тә, да – дә*).

**Морфологик принципны куллану.** Сүз төрләнү белән, авазлары күп төрле чиратлашулар, комбинатор үзгәрешләр кичерә торган телләр (мәсәлән, рус теле) өчен фонетик принцип төп нигез була алмый. Бу телләрдәге аваз үзгәрешләренең һәм чиратлашуларының барысын да күрсәтә башласаң, бер үк тамырдагы сүзләр төрле очракта төрлечә язылыр һәм сүзнең мәгънәсен тиз генә аеру да бик үк мөмкин булмас иде. Шуңа күрә андый телләр өчен беренче чиратта морфологик принцип характерлы. Морфологик принцип сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язуны, сүз үзгәрү белән, алардагы аваз үзгәрешләрен күрсәтеп тормауны максат итеп куя. Билгеле, кайсы гына телдә булмасын, орфография бары тик бер генә принцип белән чикләнеп кала алмый. Фонетик принципка нигезләнгән татар язуына да урыны белән морфологик принцип кирәк булып чыга. Безнең орфографиядә бу принцип, башлыча, кайбер сүз яки кушымчаларны, аларның теге яки бу авазы билгеле позицияләрдә үзгәрүгә карамастан, бер генә формада язуга кайтып кала. Мәсәлән, *з, н, л* авазларына беткән сүзләрдә бу тартыклар, күрше авазга ияреп, *с, м, ң, н* булып әйтелсә дә, яки ике сүз чигендә янәшә сузыкларның берсе йотылса да, яисә сузыклар арасына туры килеп, саңгырау тартык яңгырауга әйләнсә дә, сүзнең (тамырның, нигезнең яки андагы кушымчаның) мәгънә ачыклыгы югалмасын өчен, бу үзгәрешләр язуда күрсәтелми; мәсәлән, *әнкәй, утынлык, унбер, буранлы* (*буранлы көн*) сүзләре *әңкәй, утынның, умбер, буранны* формасында түгел, язылганча бирелә. *Чакыру, исеме, сеңелесе* кебек сүзләрне, җанлы сөйләмдәгечә *чакру, исме, сеңлесе* рәвешендә *ы̆ – ĕ* авазларын төшереп калдырып түгел, бәлки тулысынча (сүзнең тамырын ватмыйча – *чакыр, исем, сеңел*) язу да морфологик принципка карый.

**Тарихи-традицион принцип.** Тарихи традицион принцип гадәттә телнең хәзерге фонетик-морфологик төзелеше белән тыгыз

бәйләнештә булмый. Инглиз һәм француз орфографияләре өчен, мәсәлән, шушы принцип хас. Бу телләрнең орфографияләре, моннан берничә гасыр элек төзелеп тә, телдә зур гына үзгәрешләр булуга карамастан, бүгенге көнгә кадәр шул хәлдә калган. Нәтиҗәдә җанлы әйтелеш белән язылыш арасында зур гына аерма килеп чыккан. Тарихи-традицион принцип шулай ук рус язуында да азмы-күпме сизелә (*рожь, мышь, идешь* кебек сүзләрдә, мәсәлән, *ь* билгесе шул принциптан чыгып кына куела). Татар телендә бу принцип бездә мең еллык традициясе булган гарәп язуында (иске имлада) төп урынны тоткан. Гарәп графикасы башта латин, аннан соң рус алфавитлары белән алмаштырылуга карамастан, гарәп һәм фарсы алынмаларының язылышында катгый рәвештә гасырлар буена дәвам итеп килә торган гарәп язуындагы төп принцип, ягъни гарәп һәм фарсы алынмаларының үз теле кагыйдәсенә буйсындырып язылышы нигездә саклана (сингармонизм ватыла һ.б.), ләкин орфографияләрне алмаштыру, алынмаларны җанлы сөйләмә әйтелешкә якынайту, татар авазларын белдерү өчен, гарәп графикасында да, латинда да кулланыла торган калын *къ,* калын *гъ, w* хәрефләрен юкка чыгару нәтиҗәсендә, гарәп-фарсы алынмаларының язылышы белән килә торган тарихи-традицион принципның безнең көннәрдә тулысынча саклана алмавы күзәтелә.Шуңа карамастан, безнең хәзерге орфография ул принциптан бөтенләй үк азат түгел. Аеруча моны без цифрлар, төрле шартлы билгеләр соңында килгән кушымчаларның сызыкча аша түгел, бәлки аерым язылуында, ул кагыйдәнең гарәп имласыннан алып, яңалиф орфографиясенә һәм аның аша рус графикасы нигезендәге яңа орфографиягә дә үтеп керүендә күрә алабыз; мәсәлән: *6 шар алма; 18 нче йорт; 11 нән 15 нә кадәр; 2% лы эремә; җылылык 20° тан югары.*

**График принцип.** График принцип хәзерге чорда барлык телләр өчен дә диярлек хас, ләкин татар орфографиясендә ул аеруча күзгә ташлана. Чөнки бездә рус теле аша кергән сүзләрнең байтагы, бигрәк тә терминнар, үзләренең тамыр һәм нигез өлешләрендә рус орфографиясендәгечә бирелә: *революция, комитет, профсоюз, геометрия, физика* һ.б.

**Дифференциацияләнгән язылыш.** Дифференциацияләнгән язылыш – орфография системасы өчен тулаем хас түгел, бәлки шуңа өс-

тәмә генә. Ул, язуда үзенә башка алым буларак, әйтелеше бер үк, ә мәгънәләре төрле сүзләрне (ононимнарны) бер-берсеннән аеру өчен кулланыла: сүзләр, мәгънәсенә карап, төрлечә языла, бертөрле укыла. Татар орфографиясендә бу алымның үзен генә куллану бөтенләй юк дияргә мөмкин. Моңа мисал итеп *байрак* һәм *баерак* сүзләренең язылышларын, соңгы сүздә *-рак* кушымчасы алдыннан *й* түгел, кагыйдәдән тыш *е* (*бай+ы+рак*) язылуын гына күрсәтергә мөмкин. Ләкин татар язуында бу алымнан файдалануның башка төрле чагылышы бар. Мәсәлән, дифференциацияләнгән язылыш орфография системасына кергән кушып һәм аерым язу алымы белән тыгыз бәйләнештә килә – билгеле очракларда ул алымны тулыландыра, шул нигездә сүзләрне кушып язу белән кушып язмау аша мәгънә аермалары белдерелә: *өч почмак – өчпочмак, өч аяк – өчаяк, биш бармак – бишбармак, ак сакал – аксакал.*

**Сүзләрне кушып, сызыкча аша (ярым кушып) һәм аерым язулар.** Кайбер яңа төшенчәләр бер сүз белән түгел, бәлки ике яки берничә сүздән төзелгән сүзтезмә белән белдерелә. Бу сүзтезмәләрнең компонентлары билгеле фонетик яки морфологик шартларда үзара бөтенләй кушылырга, икенчеләре яртылаш кына кушылырга, ә өченчеләре кушылмыйча язылырга мөмкин; шуңа карамастан, андый лексик берәмлек эченә кергән һәр кисәк үзенең аерым торгандагы мәгънәсен теге яки бу дәрәҗәдә югалткан була. Мондый лексик берәмлекләрне гадәттә кушма сүзләр дип йөртәләр. Орфография кагыйдәләрендә кушып, сызыкча аша (ярым кушып) һәм аерым язулар аларның шул төзелеш үзенчәлекләренең чагылышы булып тора.

Ясалышы ягыннан тулысынча бербөтен хәлгә килгән (аерым кисәкләренең фонетик-морфологик төзелеше үзгәргән яки бу очракта мөстәкыйль мәгънәләре җуелган) кушма лексик берәмлекләр кушылып языла.

Ике сүздән төзелгән лексик берәмлекләрнең билгеле фонетик-морфологик яки семантик шартларга туры килмәү сәбәпле бер бөтен була алмый торганнары сызыкча аша языла.

Бербөтен мәгънә аңлаткан, структурасы ягыннан гадәттәге сүзтезмәгә охшаган лексик берәмлекләр (тезмә сүзләр) аерым языла, мәсәлән: *үги ана яфрагы, кура җиләге, утыз өч.*

Кушып һәм сызыкча аша язуларның барлык сүз төркемнәре өчен дә түбәндәге гомуми кагыйдәләрен бирергә мөмкин.

Кушылып язылалар:

1) икенче компоненты (кисәге) хәбәр мөнәсәбәтендә килгән кушма сүзләр тулысынча яки өлешчә туры мәгънәләрен югалткан булалар: *Уразгилде, Килдеяр, Иштуган;*

2) беренче компоненты (кисәге) аергыч мөнәсәбәтендә килгән кушма сүзләр, бу очракта да компонентларның берсе яки икесе дә өлешчә һәм тулысынча үзләренең мәгънәләрен югалткан булалар: *өчпочмак, бишбармак* (ашамлык), *кызылканат* (әмма ирекле сүз-тезмәләр буларак алар аерым язылалар: *өч почмак, биш бармак, кызыл канат*), *терекөмеш, каражиләк, тегәрҗеп, һәркем, һәрчак, бертөрле;*

3) беренче компоненты (кисәге) тәмамлык мөнәсәбәтендә килгән кушма сүзләрнең беренче компонентлары үзләренең туры мәгънәләрен югалткан булалар: *җилкуар, юлбасар, илбасар, урынбасар, бозваткыч, башваткыч;*

4) нуль кушымчалы (беренче) изафәдән хасил булган кушма сүзләр: *сабантуй, сүзтезмә, күкебаш, ташкүмер, билбау;*

5) беренче компоненты кыскартылган, икенче компоненты тулысынча килгән кыскартылма сүзләр: *драмтүгәрәк, профхәрәкәт, райүзәк, пединститут.*

Бу кагыйдәләрнең чыгармалары бар: а) икенче компоненты ялгызлык исемен тәшкил иткән кушма ялгызлык исемнәрнең компонентлары: *Кече Әтнә, Олы Мәңгәр;* һәм б) беренче компонентлары нигездә аергыч мөнәсәбәтендә булган күп иҗектән гыйбарәт кушма исемнәр (*бакыр елан, таран балык, корбан балык*) аерым языла. Әмма шуны истә тотарга кирәк: мондый сүзләрнең компонентларын кушып язу тенденциясе дә күзәтелә һәм бу дөрес тә: *алакарга, каракарга.*

11 дән алып 19 га кадәр саннар кушып язылалар: *унбер, унике, унөч, ундүрт* һ.б.

Аерым язылалар:

1) исемнән, исем урынына килгән сүздән, иялтемнән шуңа өстәлгән фигыльдән гыйбарәт кушма сүзләр: *тәэсир итү, келт итү, тәэмин итү, келт-келт итү, шарт итү, гашыйк булу.*

Бу кагыйдәдән дә чыгарма бар: беренче компонент бер иҗектән торса, андый кушма фигыльләрнең компонентлары гадәттә кушып языла: *искитү, шаккату, күзаллау;*

2) хәл фигыль плюс модификацияләүче (ярдәмче) фигыльдән гыйбарәт тезмә фигыльләр: *укып чыгу, язып кую, кычкырып җибәрү, язып ташлау;*

3) икенче изафәдән барлыкка килгән кушма сүзләр: *аю табаны* (үсемлек), *куян колагы* (үсемлек), *су сыеры* (су хайваны), *күгәрчен күзе* (чәчәк), *бака яфрагы* (үсемлек).

Сызыкча аша язылалар: компонентлары тезүле бәйләнештә булган сүзләр, ягъни куш һәм куш-кабатлаулы сүзләр:

а) *савыт-саба, тәньяк-көнчыгыш, ата-ана, хатын-кыз, шак-шак, һау-һау;* б) термин өчен алынган шартлы билгеләр яки хәрефләр белән килгән цифрлар: *ЗИЛ-110, ТУ-104.*

Орфография кагыйдәләре җыентыгында шушы гомуми кагыйдәләрдән соң кушма сүзләрнең һәр сүз төркеме буенча дөрес язылышлары җентекләп күрсәтелергә тиеш. Чөнки һәр сүз төркеменең үзенең специфик үзенчәлекләре булып, аларның дөрес язылышы гомуми кагыйдәләргә һәр очракта да сыеп бетми.

Әлбәттә, дөрес язылыш белән җанлы тел күренешләре арасында тулы тәңгәллек, гомумән, бервакытта да булып бетми. Моның сәбәбе шунда, кушма сүзләр ясалышы күп төрле һәм дәвамлы процесс булып, орфография кагыйдәләре аларның хәзерге вакытта иң типикларын, иң нык формалашканнарын гына исәпкә ала. Кайбер кушма сүзләрнең дөрес язылышын бары тик орфографик сүзлекләрдә генә билгеләп үтү менә шуннан килеп чыга.

**Баш хәрефләр кулланышы.** Баш хәрефләр сөйләм төзелешенә һәм сүзнең ялгызлык исем булу-булмавына карап кулланыла.

Сөйләм төзелешенә караган кагыйдәләр күп түгел. Текст башындагы беренче сүз һәм алдагы җөмлә белән синтаксик бәйләнештә булмаган җөмләнең беренче сүзе баш хәреф белән башлана. Шулай ук шигырь юллары да, гадәттә, баш хәрефтән башлана.

Сөйләмнең кайсы урынында килүенә карамастан, ялгызлык исемнең беренче авазы баш хәреф белән языла. Ялгызлык исемнәргә, билгеле булганча, исем-фамилияләр, псевдонимлар, кушаматлар керә, мәсәлән: *Рәхимә, Чыңгыз, Хәмиди, Айдаров, Иделле, Күпер башы Сираҗи, Шомбай, Актырнак.* Күмәклек исемгә әйләнгән ялгызлык исемнәр юл хәрефе белән язылалар: *ом, ампер, форд, меценат, галифе, браунинг.*

Мәсәлләрдә һәм башка төрле әдәби әсәрләрдә күмәклек исем белән бирелгән персонаж атамалары да баш хәреф белән языла: *Сандугач, Кырмыска,Чикерткә, Аю, Карт.*

Баш хәреф белән шулай ук география, астрономия атамалары, территория, мөһим тарихи вакыйга, тарихи чор, тарихи документ, сәнгать һәм әдәбият әсәре, революцион бәйрәм һәм күренекле вакыйга һ.б. исемнәре языла: *Европа, Идел, Россия, Юпитер, Кырым, Татарстан, Октябрь, Яңа ел* (бәйрәм мәгънәсендә кулланылганда), *Бөек Ватан сугышы.* Махсус (астрономик) әдәбиятта *Җир, Ай, Кояш* сүзләре дә баш хәреф белән бирелә.

Берничә сүздән төзелгән катлаулы ялгызлык исемнәрнең кайсы сүзен баш хәреф, кайсын юл хәрефе белән язу гомуми кагыйдә белән генә түгел, бәлки конкрет очракларга кагылышлы кагыйдәләр белән – ул атамалар белдергән объектның иҗтимагый дәрәҗәсенә, аларның бердәнберме, әллә берничәме булуына һ.б.га карап билгеләнә. Шуңа күрә кайбер катлаулы ялгызлык исемнәрнең беренче сүзе генә, ә икенчеләренең һәр сүзе дә баш хәрефтән башлап языла: *Җидегән йолдыз, Яңа Кормаш, Беренче май* (*1 нче Май*), *Казан дәүләт университеты, Социалистик Хезмәт Герое.* Орфография кагыйдәләре җыентыгында бу очракларның һәркайсына аерым күрсәтмәләр бирелә.

Сүз кисәкләрен юлдан юлга күчерү. Татар телендә сүз кисәкләре юлдан юлга сүзнең иҗеккә бүленгән урыныннан күчерелә: *тө-зе-леш, бак-ча-чы-лар, кар-лы-ган, ок-тябрь.* Шуңа күрә сүзнең иҗек тәшкил итмәгән кисәген юл азагында калдырырга да, икенче юлга күчерергә дә ярамый: *октя-бръ* түгел. Ялгыз бер хәреф юл азагында калдырылмый, икенче юлга да күчерелми: *у-куы* яки *уку-ы, шу-а, а-бый* рәвешендә түгел. Төрле тамырлардан яки префикс, суффикс белән нинди дә булса тамырдан төзелгән сүзләрне шул кисәкләр арасыннан яки тамырның иҗеккә бүленгән урыныннан (мәгънә буталчылыгы чыгармый торган җирдән) күчерергә кирәк (алынма сүзләрдә): *парт-орг, проф-орг, про-грамма, Һинд-стан.*

## 5.3. ТАТАР ЯЗУЫ ТАРИХЫННАН КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТ

**Рун язуы.** Безнең ерак бабаларыбыз – борынгы болгарлар VII–VIII гасырларда Урта Идел һәм Кама буйларына күчеп утырганда ук инде аларның үзенчәлекле язулары – үз алфавитлары була. Бу алфавит фәнни әдәбиятта төрки рун язуы дип йөртелә. Рун язуы (*run* сүзе борынгы Скандинавия халыкларында ‘сер’, ‘серле’ дигән мәгънәгә туры килә) – төрки телләрнең фонетик-морфологик төзелешенә яхшы ук җайлаштырылган консонант язу системасы. Аның төп үзенчәлеге шунда, сүзләрнең калын яки нечкә сузык белән әйтелеше тартык аваз өчен нинди хәреф кулланылуга бәйле: калын сузык янында башлыча бер төрле тартык аваз хәрефе, нечкә сузык янында икенче төрле тартык аваз хәрефе язылa. Тагын шунысы да бар, *о* һәм *ө* сузыклары махсус аерым-аерым хәрефләр белән түгел, аларның икесе бер генә хәреф белән берләштерелеп бирелә. Тар *ы̆, ĕ* авазлары бары тик сүзнең беренче иҗегендә генә язылa, калган очракларда язылмый – алар һәм күп очракта башка сузык аваз хәрефләре дә сүз сөрешеннән аңлашылырга (әйтелергә) тиеш була. Төрки рун язуының үрнәкләре кайбер археологик казылмаларда – балчык чүлмәк, таш дивар, алтын яки көмеш савыт-саба өсләрендә, эпитафик һәйкәлләрдә – төрки халыклар яшәгән һәр урында диярлек табыла (Орхон-Енисей, Азов-Дон, Сент-Миклош язмалары һ.б.). Ул үрнәкләр арасында азмы-күпме график-орфографик аермалыклар да бар, ләкин нигезләре бер үк. Күрәсең, төрки халыкларның һәркайсында – төрле территорияләрдә, төрле кабиләләрдә һәм кабилә берләшмәләрендә – рун язуы төрлечәрәк рәвеш алган, төрлечәрәк камилләшкән яки ул ядкарьләрне башкарган кешеләрнең грамоталылык дәрәҗәсе дә бер үк югарылыкта булмаган. Ләкин теге яки бу иҗтимагый яки сәяси сәбәпләр аркасында төрки халыклар, – аерым алганда, безнең бабаларыбыз 922 елда Ислам динен кабул иткәннән соң, – ул язуны тора-бара ташларга мәҗбүр булганнар. Хәзерге көндә андый язулар безнең Идел–Чулман буйларында әледән-әле очраштыргалый. Менә шуларның кайберләре.

I. Татарстан Фәннәр академиясе археологы Евгений Казаков җитәкчелегендәге Идел буе Бөек Болгар дәүләтенең иң әүвәлге чорын тикшерү экспедициясе 1992 елда шифердан (коңгырт төстәге үзле балчыктан – сланецтан) ясалган берничә орчык башы табып ала (ул

орчык башлары сәүдә юлы белән Киев кенәзлегеннән китерелгән дип әйтәләр). Бу табылдыкларның урыны – Измир дигән авыл җирендә (Бөек Болгар дәүләтенең үзәгендәге Биләр шәһәреннән 100 км ераклыкта; Измир – Идел буе Болгар дәүләтенең X–XI гасырдагы баш сәүдә капкасы). Ул орчык башларының кайберләрендә рун язулары бар. Менә аларның эстамптан алынган күчерелмәләре һәм укылышлары:





| | | |
|---|---|---|
| i͜š | l͜d | k |

1 нче рәсем

Укыла сулдан уңга: *k*(*e*)*ldiš* = *Keldiš*. *Келдиш* – борынгы төрки телдә кеше исеме (*Килдеш* < *Килде-иш*). Литва татарлары телендә *килдиш-келдиш* сүзе ‘кәләш йортына килүче, кияү’ мәгънәсен белдерә [Саттаров Г.Ф., 1981, б. 107]. Шушы сүзгә нигезләнеп *Келдыш* фамилиясе ясалган [Баскаков Н.А., 1979].





| | | |
|---|---|---|
| u | t | s͜(a) |

2 нче рәсем

Укыла сулдан уңга: *s*(*a*)*tu* = *satu*.

Бу сүзнең төп мәгънәсе бүгенге татар әдәби телендә – ‘сату’.

Борынгы төрки халыкларда, билгеле бер ырымга бәйле рәвештә, ялгызлык исем буларак та кулланылган [Саттаров Г.Ф., 1981, б. 163].




3 нче рәсем

Укыла уңнан сулга: *jold*(*a*)*š* = *juldaš.* Төп мәгънәсе, хәзерге татар әдәби телендәге кебек үк, – ‘юлдаш’. Шул сүздән төрки халыкларда (татарларда, башкортларда һ.б.) Юлдашев фамилиясе ясалган.

II. 1992 елның гыйнвар аенда Татарстандагы Алексеевский районының Урман асты Шонталасы авылы урта мәктәп укытучысы Р.Р. Хөснетдинов Казан дәүләт педагогия институтына шул авылның корып барган елгасы буеннан бик борынгы әйберләр табылдыгын тапшыра. Ул табылдыкларның 1960 елда археолог һәм тарихчы Равил Фәхретдинов экспедициясе тарафыннан ачылган борынгы авыл урынында булганлыгы ачыклана. Урман асты Шонталасы дигән бу борынгы авыл (Идел буе Болгар дәүләтенең үзәге Болгар шәһәреннән көнчыгышка таба 140–150 км чамасы ераклыкта) шул исемдәге хәзерге авылдан төньяк-көнбатышка таба 1,5 км ераклыкта – Каркай елгасының уң як ярына урнашкан булган [Фахрутдинов Р.Г., 1975]. Ул вакытта алып кайтылган археологик табылдыкларның күбесе – Болгар дәүләтендә эшләнгән керамик савыт-саба ватык-сыныклары. Әмма укытучы Р.Р. Хөснетдинов 1992 елда techинститутка тапшырган ядкарьләрнең аеруча әһәмиятлесе – төрки рун язулы сарык бәкәле сөяге. Бу табылдык Татарстан Фәннәр академиясе археологы Петр Старостин карамагына килеп керә – ул аны шундагы архивка сакларга бирә. Ул сөяккә уңнан сулга таба бер ягыннан икенче ягына әйләндерә-әйләндерә очлы тимер кисәге белән ап-ачык итеп болай язылган – менә аның эстамп күчермәсе (4 нче рәсем).

Бу язуны бүгенге хәрефләргә күчерсәк, мондый сүз пәйда була: *quzn*(*a*)*čik=quznačik,* ягъни ‘кузначык’ (балалар уенында кулланыла торган кузна сөякләренең берсе – ‘кечкенә кузна’).

III. Тел галиме Вахит Хаков 1967 елны Татарстандагы Лениногорск районының Сараббиккул авылына экспедиция вакытында шул авылда төрки рун язулы таш табып ала. Ул таш шомартылган,




4 нче рәсем

өчпочмак рәвешендәрәк, соры төстә, озынлыгы 50–60 см, җиргә кереп торган өлешенең киңлеге 35–40 см, өскә тараеп сузылган биеклеге 40 см. Ташта мондый язу бар – менә аның кечерәйтелгән эстампы (5 нче рәсем):




5 нче рәсем

Биредә сулдан беренче зур (озын) билге –  (ул сәнәкне хәтерләтә) – нәрсәгә ишарәдер, әлегә билгесез (хәер, шундый ук зур билге хәзерге Кыргызстан җирендә табылган төрки рун язулы ташта да бар, бәлки ул гаскәр башлыгын белдергән билгедер) [Малов С.Е., 1959, с. 73 ]. Язуны шул зур билгедән соң сулдан уңга таба укыгач (рун язуларының кайберләре шулай да укыла), *süb*(*a*)*š*= *sübaš* сүзе, ягъни ‘гаскәр башлыгы’ (‘сәргаскәр’) дигән сүз килеп чыга.

IV. Археолог Петр Старостин 1977 елның октябрендә Хельсинки шәһәрендә В.И. Заусайлов коллекцияләре белән таныша. Ул археологик ядкарьләр XIX–XX йөзләрдә Кама (элекке исеме – Чулман) елгасы буеннан табып алынган һәм 1909 елда Финляндиянең Милли музеена сатылган була. Шул коллекцияләр арасында иң кызыклылары – ике кылыч. Каталогта күрсәтелгәнчә, ул борынгы кылычлар элекке Казан губернасының Лаеш өязендә (хәзерге Татарстанның Лаеш рай-

онында) килеп чыккан (археологлар раславынча, XI гасырда булган элекке Имән Кискә авылы җирендә). Бу кылычларның берсе бик нык тутыккан булса, икенчесе ярыйсы гына сакланган. Гомуми озынлыгы 101,5 см (тоткасы 9,2 см). Кыеклыкка авышуы зур түгел – 1,6 см. П.Н. Старостин әйтүенчә, андый кылычлар Идел буе Болгар дәүләте (шул исәптән – Биләр) казылмаларында да очрый [Старостин П.Н., 1988, с. 14–16]. Бу кылыч йөзенең тоткага якынрак урынында буе 13 см, киңлеге 1 см булган төрки рун язуы бар. Язуның башында һәм ахырында ✢ билгесе тора – ул борынгы төркиләрнең ниндидер шартлы билгесе яки үзенә бертөрле бизәк кенә. П.Н. Старостин ул язуны фотопленкага (негативка) төшереп алып кайта, – негативтан фотокәгазьгә күчергәч, анда уңнан сулга мондый сүзләр укыла (6 нчы рәсем): *Imän Kiskä üʐä bäkü alqyjš kiši küčlüš Čikügiŋ süŋüs q̆ylyčy,* ягъни ‘Имән Кискәнең баш бәге, шөһрәтле кеше, көчле Чикүгнең сугыш кылычы’. Менә шул язуның фотосурәте һәм андагы рун хәрефләренең халыкара транскрипция билгеләренә күчерелү схемасы:



6 нчы рәсем

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| i | š | i | k | š | qyj | l | a | kü | ă | b | zä | ü | kä | s | Ki | n | a | m | İ |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| ← | | čy | ly | qy | š | ŋü | ü | s | iŋ | g | kü | Či | š | ü | l | č | kü | | |

6 нчы [а] рәсем

V. Кама елгасының сул ягындагы Мурзиха авылы урынында башка бик күп төрле болгар табылдыклары (керамика, металдан эшләнгән кораллар һәм бизәнү-ясану әйберләре, муенсалар һ.б.) арасыннан археологик экспедициягә катнашкан Е.А. Беговатов биоконик рәвештәге




7 нче рәсем

төрки рун язулы орчык башы табып ала [Беговатов Е.А., 1988, с. 17–19]. Орчык башының бер ягына уңнан сулга таба *b(a)ğ(y)š,* икенче ягына *k(ü)bäz̧i* дип язылган, ягъни *bağyš kübäz̧i;* бүгенге телгә күчерсәк, ‘күз күрке’ дигән сүз килеп чыга (7 нче рәсем):

VI. Ком катнашмасы белән барлыкка килгән озынча түгәрәк, кулда йомарлап тотарлык зурлыктагы (аркылысы-буе 8×12 см, калынлыгы 1 см) таш кисәге 1958 елда хәзерге Мари Эл территориясенең Юрино поселогындагы суүткәргеч өчен траншея казыганда табып алына һәм археолог Альфред Хәсәновка тапшырыла. Күрәсең, бу таш учка йомарлап суга торган корал (кастет) булган (8 нче рәсем):



8 нче рәсем

Хәрефләр туры килеше менә мондый (9 нчы рәсем):




9 нчы рәсем

Укылышы – уңнан сулга: *Küç üz̧ä d*(*a*)*š*(*y*)*m = Киç üza dašym;* ягъни: ‘Көчкә каршы – ташым!’.

VII. 1884 елда Вятка губернасының Глазов өязендә (Идел буе Болгар дәүләтенең терәк пунктында) төрки рун язулы көмеш савыт сабы табып алына. Анда төрки рун язуының кагыйдәсенә туры китерелеп, һәр сүз саен диярлек, ике нокта (сүз арасын күрсәтү билгесе) куелган. Бу көмеш тотка сынган, шуңа күрә кайбер хәрефләр җитеп бетми (10 нчы рәсем):



10 нчы рәсем

Заманында моны П. Мелиоранский укып карарга тырыша, ләкин уңышка ирешә алмый [Мелиоранский П., 1901 (1902)]. Чынлыкта исә анда хәрефләр туры килеше менә мондый (11 нче рәсем):




11 нче рәсем

Уңнан сулга укылышы: *Q*(*a*)*ğu d*(*ä*)*g q*(*u*)*nča g*(*ä*)*lünčä q*(*a*)*wuš*(*u*) *g*(*ü*)*mü*(*š*)*i*= *Qağu däg qunča gälüňčä*(*gä*) *qawušu gümüši,* ягъни: ‘Қағу

дәг қунча гәлүнчәгә қаwышу гүмүши’; бүгенге телгә күчерсәк: ‘Ақ-қош кебек кенәз қызы киленгә қаwышу көмеше’ (‘кенәз кызы’ дигәнне белдергән *қунча* сүзе борынгы телгә кытай теленнән килеп кергән).

VIII. Хәзерге Татарстан Фәннәр академиясенең археология бүлегендә эшләгән Анна Кочкина 1983 елны Биләр шәһәрчеге җирендә казылмалар үткәргәндә керамик савыт тоткасы табып ала [Кочкина А.Ф., 1985, с. 80; Курбатов Х.Р., 1988, с. 18]. Ул савыт коңгырт-кызыл төстә (А. Кочкина – керамика белгече дә), анда уңнан сулга мондый сүз язылган (ахырда ике нокта, ягъни сүз азагын белдерүче билге): *ačytğ(a)n= ačytqan* ‘ачытқан’ (12 нче рәсем):



12 нче рәсем

Түбәндә – эстампның күчермәсе. Хәрефләр туры килеше менә мондый (13 нче рәсем):



| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | n | ğ ~ q | t | y | č | a |

13 нче рәсем

Керамик савытларның эчендә нәрсә икәнлеге хәзерге пыяла савытлардагы кебек күренеп тормаган, шуңа күрә анда нәрсә бар икәнлеген аның тышына язып куя торган булганнар. Андый савытлар заманында Казан шәһәр музеенда да сакланган. Бу турыда Э. Ленц мәкаләсендә дә әйтелә [Ленц Э., 1904, с. 101–102, 112] – шуларның берсендә уңнан сулга мондый язу укыла (14 нче рәсем): *ič(i)g su = ičig su,* ягъни ‘эчә торган су’.




14 нче рәсем

Руник язулы балчык савытның ватык кисәген 1987 елның сентябрендә Петр Старостин җитәкчелегендәге археологик экспедиция алып кайта. Аның раславынча, бу савыт кисәге V–VI гасырларга карый (бәлки соңрак чорныкы да булыр). Табылдыкның урыны – Каманың уң як яры кыясында, – Трой-Урай елгасы борынында, Татарстанның хәзерге Балык бистәсе районында [Старостин П.Н., 1988, с. 19] (15 нче рәсем):




15 нче рәсем

Тиз язу рәвешендә булган бу хәрефләр мондый ике сүзне белдерә (укылышы – уңнан сулга): *suly ič= Suly, ič!,* ягъни ‘Сулы, эч!’

IX. Татарстанның Мамадыш районы, Өчиле урта мәктәбе музеенда бакыр һәм аккургаш эремәсеннән (бронзадан) ясалган эче куыш статуэтка – монголоид йөзле ир кеше сыны сакланган. Аяк һәм кулларының пропорциясе бик үк дөрес түгел, әмма Будда рәсем сәнгатенчә югары зәвык белән ясалган. Кысынкы күзләре белән, аптырап, сул яккарак карап тора, башының арткы түбәсендә – кыска гына чәч толымы. Сынның биеклеге 16 см, нигез диаметры 14–16 см, башының диаметры 9–10 см, баш түбәсендә – дөрес түгәрәк рәвешендәге ачыклык, диаметры 7–8 см. Уң як һәм сул як җилкәсендә (кул башында) – төрки руник язулар. Ул язуларны Татарстан Фәннәр академиясенең текстологы һәм графист Нәҗип Исмәгыйлев күчереп алып кайтты [Исмагилов Н.Ф., 1988, с. 20] (16 нчы рәсем). Сынның уң як җилкәсендә *šätränči* ‘шәтрәнчи’ дип, сул җилкәсендә *šaxm*(*a*)*t* ‘шах һәм мат’ дип язылган (укылышы – уңнан сулга):




16 нчы рәсем

Бу язылганнарны бүгенге татар теленә күчерсәк, ‘Шәтрәнче. Шах һәм мат’ дигән мәгънәне алабыз. Бу сын берәр төрле Иран шахматы фигурасы, яки ул Иран шахматында («шәтрәнеч» – Иран шахматы) уйнаучыны юмористик рәвештә гәүдәләндерә.

Әйтеп үтелгәнчә, төрки рун хәрефләре төрле контекстта һәм төрле җирләрдә төрлечә рәвеш алган. Җитмәсә, ул язуларны башкарган кешеләрнең грамоталылык дәрәҗәсе дә (хәер, төрки рунда бердәм орфографик кагыйдәләр булды да микән әле) бер үк югарылыкта түгел. Шуңа күрә бер үк текстны һәм хәтта бер үк сүзне язганда да бер үк аваз өчен әле бер төрле, әле икенче төрле хәреф куллану очраклары күп. Нәтиҗәдә төрки рун графемалары бу территориядә болай, икенче территориядә тегеләй дип өзеп кенә әйтеп булмый (гәрчә андый омтылышлар махсус әдәбиятта очраса да). Инде төрлечә рәвеш алган (төрлечә сызык белән бирелгән) төрки рун графемаларының нинди төп авазларга (фонемаларга) туры килүен күрсәткән җыйналма таблицаны теркәп үтик (17 нче рәсем).

**Иске уйгыр язуы.** Уйгырлар – Үзәк Азиядә яшәүче борынгы халыкларның берсе. VIII–IX гасырларда алар үзләренең беренче дәүләтләрен төзиләр, соңрак Караханилар (IX–XIII гг.), Алтын Урда (XIII–XV гг.) дәүләтләренең идарә һәм мәгариф эшләрендә мөһим роль уйныйлар.

Галимнәр фикеренчә, уйгырлар тарафыннан барлыкка китерелгән алфавит үзенең тамырлары белән борынгы сәгъди язуына барып тоташа, ләкин аннан аермалы буларак, уйгыр текстлары уңнан сулга түгел, ә өстән аска язылганнар. Сәгъди алфавитындагы кебек үк иске уйгыр язуындагы күпчелек хәрефләрнең формасы аларның сүздә кайсы урында (башта, уртада һәм ахырда) килүенә бәйле рәвештә үзгәргән. [Малов, 1951, с. 105–106]. (18 нче рәсемне карагыз.)

Төрки рун хәрефләренең җыйналма таблицасы

| Төрки рун хәрефләре | Авазы (укылышы) | Төрки рун хәрефләре | Авазы (укылышы) |
|---|---|---|---|
|  | a, ä |  | kö, kü |
| | ä, é | | l |
| | yj, i | | m |
| | i | | n |
| | o, u | | ŋ |
| | ö, ü | | p |
| | b[1] | | r |
| | b | | s |
| | č | | š |
| | d | | t |
| | ğ | | z |
| | g | | lt |
| | j | | nt |
| | q | | nč |
| | qo, oq qu, uq | | rt |
| | qyj | | сүз арасы |
| | k | | |

17 нче рәсем

## Уйгыр алфавиты



| Язылышы | | | Авазы (укылышы) | |
|---|---|---|---|---|
| сүз башында | сүз уртасында | сүз ахырында | кириллица | латин |
| | | | а | a |
| | | | ä | ä |
| | | | ы, і | y, i |
| | | | о, у | o,u |
| | | | ö, ӱ | ö, ü |
| | | | п, б | p, b |
| | | | в | v, w |
| | | | Ҕ | γ |
| | | | k | q |
| | | | х | χ |
| (kä) | (kä) | | г, к | g, k |
| | | | д, т | d, t |
| | | | ж | ž |
| | | | з | z |
| | | | j | j |
| | | | л | l |
| | | | м | m |
| | | | н | n |
| | | | р | r |
| | | | с | s |
| | | | ш | š |
| | | | ч | č |

18 нче рәсем

Уйгыр язуы Идел–Урал төбәгендә яшәгән төрки халыклар тарафыннан да кулланылган. Аерым алганда, Алтын Урда чорында хан сараенда уйгыр хәрефләре белән рәсми документлар һәм хатлар төзелгән. Мәсәлән, безнең көннәргә кадәр Алтын Урда ханнары Туктамыш һәм Тимер Котлыгның ярлыклары килеп җиткән, ягъни хәзерге татарларның борынгы бабаларында уйгыр язуының кулланылышта булганлыгы тарихи документлар белән раслана [Курбатов Х., 1999, б. 13].

**Татарларда гарәп алфавиты.** Көнчыгыш илләре (фарсылар, гарәпләр һ.б.) белән фән, культура, экономика һ.б. мөнәсәбәтләргә керү нәтиҗәсендә X йөз башларында рун язуы гарәп язуы системасы белән алыштырыла. Илгә монгол яулап алучылары басып кергән бер чорда һәм билгеле катлауларда гарәп язуы белән бергә уйгур язуы да кулланыла. Гарәп язуы, татарларда мең елдан артык гамәлдә булып, соңгы елларда берничә мәртәбә үзгәртүләр кичерә. Иске имлага (иске орфографиягә) яңа имла һәм урта имла дигән төрләре килеп кушыла. Хәтта хәреф формаларын үзгәртү, гарәп хәрефләренә зур реформа ясау омтылышлары да күренә (Мөхәммәдзакир һәм Мөхәммәдшакир Рәмиевләр, Н. Харитонов проектлары, М. Идрисов, Г. Шәрәф һ.б. ларның баш шәкелләрне генә алып төзегән һәм гамәлгә дә керә башлаган хәрефләре).

**Гарәп язуы чорында орфография. Иске имла.** Фонетик һәм грамматик төзелеше буенча бөтенләй башка системадагы телгә – төрки телгә килеп кергән гарәп язуы озак еллар буе татар-болгарлар тарафыннан бернинди үзгәртүсез кулланыла. Тарихка ул чор «иске имла» (иске орфография) исеме белән кереп калган.

Бу язуда татар теленең тугыз сузыгы (монофтонгы) өчен нибары өч кенә хәреф була: ا хәрефе *а, ә, ы̆, и, ӗ* авазлары өчен дә, сүз башында килгән ﻳ , و хәрефләренең тулы сузык (*у, ү, и*) икәнен күрсәтү өчен дә языла: آنلار *анлар,* آط *ат,* اسم *исем,* ال *эл,* املاى *ымлай,* اورون *урын,* اورلعى *орлыгы,* ايكىُ ике. و хәрефе шулай ук берничә авазга йөри – *v, ү, w, в, о̆, ө, ы̆:* اورڎاسندا *уртасында,* آوز *аwыз,* واقت *вақыт,* جورط *йорт,* وچ *уч, үч, оч, өч.* ى (ﻳ) хәрефе *ый, и, й* авазларын белдерә, традиция буенча *ы̆ – ӗ* өчен дә язылып килә: جكتلار *егетләр,* اوازى *аwазы,* نى بولدى *ни булды,* ايته *әйтә,* ﻳغمور *яғмур,* ينكيل *йиңел,* يغلاى *йыглай,* يتم *йәтим.* ك , ج , ب хәрефләре *к, җ, б* авазларын гына түгел, *г, ч, п* ләрне дә белдерә: كمكه *кемгә,* بيچارا *бичара,* كوروب *күреп.* Тик соңга таба гына *г, ч,*

*п* авазлары өчен дә яңа билгеләр арттырыла – پ , گ , چ : كمچى *кәмәче,* كوپورچى *күперче,* چيشمه *чишмә,* كوگەرچون *күгәрчен. Ж, в* авазлары өчен ژ , ۋ хәрефләре өстәлә: اژداها *аждаһа,* دەغاۋار *договор,* ۋيرشوق *вершок.* Бу өстәмә хәрефләрнең күбесе фарсы язуыннан алына. *Ң* авазы башта نك, соңга таба ڭ хәрефе белән бирелә: آنينك *аның,* آڭ *аң.* Кайбер тартыкларга икешәр хәреф йөри: *т, с* авазлары калын сүзләрдә (сүзнең тамырында һәм нигезендә) ط, ص нечкә сүзләрдә, кушымчада ت, س белән языла: ناراط *нарат,* صو *су,* آطاسى *атасы.* Кайбер хәрефләр бары тик гарәп теленнән кергән сүзләрдә генә языла, чөнки гарәп сүзләренең үз орфографияләре сакланырга тиеш була – ث *ç,* ض *дъ,* ظ *зъ,* ذ *ʒ:* ذاكير *Закир,* ضرورت *зарурат,* مثلا *мәсәлән.* Сүзләрнең язылышында бердәм кагыйдә, ныклы тәртип булмый. Мәсәлән, *ы̆ – ĕ* сузыклары сүз уртасында күрсәтелми диярлек: آورلق *аwырлык̡,* سيكز *сигез.* Шулай ук башка сузыклар да бик якынча гына билгеләнә яки бөтенләй билгеләнми: قداق *қадақ,* قرا *қара,* چكمەن طونلى *чикмән тунлы.* Сузыкларның анык билгеләнмәве кайбер очракларда сүзләрне дөрес укуга комачау итә. Мәсәлән, اوچ сүзен дүрт төрле укырга мөмкин: *уч, үч, оч, өч.* Дөрес укылыш бары тик контекстта гына ачыклана. Гомумән, бер үк сүз төрле кеше һәм төрле нәшрият тарафыннан төрлечә языла, мәсәлән: *зур* – ظور, ضور, زور; *атлардан* – آطلردن, آتلاردن, آطلاردن; *сөйләдем* – سويلادم,سويلادوم, سولەدم, سيلەدم. Язылышта бердәмлек булмау ул чорда әдәби әйтелеш нормалары әле ныклап урнашып бетмәүдән дә килә: берәү بزلەر *безләр* ди, икенчесе بزدهر *бездәр* яки بذدهر *бездәр*, ди һәм шулай яза бирә. Татар язуы үзенең шушы хәлендә XX йөз башларына кадәр дәвам итә.

**Имла төзәтү.** XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында имла төзәтү хәрәкәте көчәя. Әлифба китапларының кайберләрендә сузыклар өчен өстәмә билгеләр кулланыла башлый (мәсәлән, 1893 елда Ш. Таһири, 1892 елда Г. Баруди, И. Сәйфуллин әлифбалары шулай басылып чыга). К. Насыйри үзенең «Әнмүзәҗ»ендә (1895) татар телендә сузыкларның, өч кенә булмыйча, ун икәнен күрсәтә, аларны махсус хәрефләр белән билгеләп үтә. Ләкин К. Насыйриның бу яңалыгы ул заманнарда әле башкалар тарафыннан гына түгел, аның үзе тарафыннан да тормышка ашырылмый кала. 1899 елда Уфада булып үткән «мәҗлес гыйльми» (гыйльми җыелыш) имла турында махсус карар чыгара. Ләкин карар гарәп хәрефләренең сафлыгын саклау, татар сүзләре өчен өстәмә хәрефләр арттырмау (*ŏ, ө, у, ү* авазларын «бер-берсеннән аер-

мак өчен, *уау* өстенә галәмәт куймаска») рухында була. Тик гамәлгә нык кереп киткән кайбер чигенешләргә генә ташлама ясала: *ә* авазы өчен сүзләрнең (башлыча, татар сүзләренең) ахырында ه – ە хәрефен язу, گ *г,* ڭ *ң* хәрефләрен куллануны законлаштыру, *мае – мәе* кушымчасын татар телендә әйтелгәнчә алу (*маз – мәз* түгел) һ.б. XX йөзнең бишенче-унынчы елларында имланы яңарту, камилләштерүгә «Йолдыз» газетасының мөхәррире һәм нашире Һади Максуди зур көч сала. Ул үзлегеннән алфавитка яңа бер хәреф – өске өтерле ۇ арттыра (*ŏ – ө* авазлары өчен): اوُز *өз,* سوُت *сөт,* قوُش *қош,* طوُى *той.* Шулай ук Уфа «мәҗлес гыйльми»ендә рәсми рәвештә кабул ителгән ه – ە (ә) хәрефеннән дә оста файдалана – аңа сүзнең азагында гына түгел, башында һәм уртасында да язылу хокукын бирә: ئەر *әр,* بەر *бәр,* بلەك *беләк,* كيله *килә.* Менә шул яңалыкларныүзенең газетасы, газетасына бушлай теркәлгән имла кагыйдәләре китапчыгы һәм үзе төзегән әлифбалары аркылы гамәлгә кертә. Шул рәвешчә, татар алфавитында сузык аваз хәрефләре бишкә җитә (و , ا , ى , ه , ۇ ) соңрак моңа тагын бер хәреф – *ы̆, ĕ* авазларын белдерү өчен өске өтерле ىٗ билгесе өстәлә. Бу елларда сүзләрне ни рәвештә – барлык төрки телләрдә дә бер үк формадамы, әллә һәр телнең үзенең әйтелешенчә язаргамы, дигән бәхәсләр йөри. Әйтелгәнчә, ишетелгәнчә язу дигәнне дә һәркем үзенчә аңлый. Берәүләр уенча, ул – кем ничек сөйли, кайсы төбәктә ничек сөйләнелә, шулай язу була; икенчеләре аны билгеле бер телнең әдәби әйтелешенчә язу дип аңлый. Бу соңгы дөрес карашны – татар язуы өчен Казан әдәби сөйләшен нигез итеп алуны Һ. Максуди болай формалаштыра: «Һәр сүзне, – ди ул, – әдәби авыздан ни рәвешле ишетелсә, шул рәвешчә язмалы, вә һәр сүзне кагыйдәгә ни рәвешчә язылмыш исә, шул рәвешчә укымалы» [«Йолдыз», 1906 ел, 15 февраль]. Матбугатта һәм аеруча 1915 елда Уфада җыелган имла һәм дәреслекләр киңәшмәсендә орфографик принциплар турында байтак фикер күтәрелә. Ахырда, кирәгенә һәм урынына карап, фонетик һәм морфологик принципларга тукталмакчы булалар. Ләкин әдәби телдә ишетелгәнчә дөрес язу, ягъни фонетик принципка нигезләнү өчен, алфавитта кайбер авазларны, аеруча сузыкларны, анык билгеләргә кирәк була. К. Насыйридан башлап, Г. Нугайбәк, М. Корбангалиев, Г. Алпаров һ.б. кайбер тел галимнәре татар телендә сузыкларның саны ун яки тугыз икәнен, ул авазларның барысын да аерым хәрефләр белән

билгеләргә кирәклеген күрсәтәләр, үзләренең әлифба китапларында бу принципны гамәлгә дә куялар. Ләкин моны рәсми рәвештә киң җәмәгатьчелектән кабул иттерә алмыйлар. Аларның теләкләре тик латин алфавитына күчкәннән соң гына тормышка аша. Орфографиядә бу юнәлеш тарафдарларын «унчылар», яки «яңа имлачылар» дип йөртәләр.

**Урта имла.** Имлачыларның зур бер төркеме алтычылыкны, ягъни сузык авазлар өчен алты гына хәреф алуны – урта имланы яклый. Алтычылыкның башы, югарыда күрелгәнчә, Һади Максуди эшчәнлегендә ята. Бу юнәлешне ныгытуга, законлаштыруга Г. Ибраһимов белән Г. Шәрәф зур тырышлык күрсәтә. Урта имлачыларның күбесе («гамәли алтычылар») татар телендә сузыкларның саны ун яки тугыз икәнен кире какмый. Ләкин ул сузыклар калынлыкта-нечкәлектә парлы булганлыктан, һәр парга берәр генә хәреф җитәр, тик *а* белән *ә* авазларына гына аерым-аерым хәрефләр булса булыр диләр: ا *а,* ه *ә,* و *у–ү,* ۇ *ŏ–ө,* ى *ый–и,* ىٗ *ы̆–ĕ.* Сузыклар өчен булган бу билгеләр 1915 елда Уфа киңәшмәсендә рәсми рәвештә раслана. «Имлада идеалымыз, – диелә карарда, – фонетика буенча һәр авазга бер хәреф тапмактыр. Ләкин бу көнгә ул әсасны гамәлгә кертү мөмкин булмаганга, хәзергә урта... имла белән язылган булу тиешлеген икърар кыйлабыз». Шуннан башлап урта имла татарларда гарәп алфавиты кулланылуның соңгы көннәренәчә үз көчендә кала. Тик аңа Октябрь инкыйлабыннан соң кайбер төзәтмәләр генә өстәлә (Совет хөкүмәтенең имла турындагы беренче декреты 1920 елның 19 декабрендә була). Ул төзәтмәләрнең иң әһәмиятлеләре – калын сүзләр алдында махсус калынлык билгесе ( ، ) кую, гарәп сүзләре белән йөри торган тартык аваз билгеләрен (ذ, غ, ص, ض, ط, ظ) алфавиттан чыгарып ташлау, башка телләрдән кергән сүзләрнең язылышын билгеле бер тәртипкә салу һ.б. Урта имла үзенең соңгы вариантында аваз белән хәрефләр туры килеше һәм аларның язылышы ягыннан шундый рәвешкә керә:

Сузыклар һәм ярым сузыклар: ا а, ه ә, و *у–ү–w,* ۇ *ŏ–ө,* ی *ый–и–й,* ىٗ *ы̆–ĕ.*

Тартыклар: ئ һәмзә, ب *б,* پ *п,* ت *т,* ج *җ,* چ *ч,* ح *х,* د *д,* ر *р,* ز *з,* ژ *ж,* س *с,* ش *ш,* ع *ғ,* ف *ф,* ق *қ,* ك *к,* گ *г,* ڭ *ң,* ل *л,* م *м,* ن *н,* ۋ *в,* ه *h,* ، *калынлык билгесе.*

Сүз башындагы сузык алдыннан һәмзә куела: ئاغاچ *ағач,* ئەرمە *әрмә,* ئۇزن *озын,* ئوزەك *үзәк,* ئیكی *ике.*

ٔ (*ы̆–ĕ*) хәрефе ябык иҗекләрдә язылмый, бары тик ачык иҗекләрдә генә языла. Сүзнең беренче иҗегендә исә ٔ хәрефе ачык иҗек булганда да, ябык иҗек булганда да язылмый: بل *бел,* بلمُنه *белеменә,* ترش *тырыш,* يازل *йазыл,* يازنُلا *йазыла,* بولك *бүлек,* بولنُگیُ *бүлеге,* ئش *эш,* ئندر، *ындыр.*

ؤ (*ŏ–ө*) хәрефе татар сүзләренең беренче иҗекләрендә генә языла. Башка иҗекләрдә – ачык иҗекләрдә ٔ язылып, ябык иҗекләрдә ٔ дә язылмый: ئۆزن، *озын,* ئۆزنُیُ، *озыны,* تۆزنُلنُشیُ *төзелеше.*

كیيم *кием,* تييش *тиеш,* سووىُ، *суы,* كيلووىُ *килүе* кебек сүзләр янәшә ике ي, و хәрефләре белән языла.

Сүз яки иҗек азагында килгән *п* авазы, шул сүзгә сузык аваздан башланган кушымча яки ярдәмлек сүз куеп карагач ничек әйтелсә, шулай языла (*п* әйтелсә پ, *б* әйтелсә ب) تابا *таба* – تاپ *тап,* قاراب ئالا *қараб ала* – قاراب *қараб;* ләкин: تاپشرا *тапшыра* – تاپشر *тапшыр.* Чит телдән кергән сүзләрдә د ,ب хәрефләре үзгәртелмичә языла: مەكتەب *мәктәп,* ئەحمەد *Әхмәт,* داكلاد *доклад.*

دا *да* – ده *дә,* دار *дар* – دەر *дәр,* داش *даш* – دەش *дәш,* دان *дан* – دەن *дән,* در *дыр* – *дер,* دق *дык* – دك *дек,* دڭ *дың* – *дең,* دم *дым* – *дем,* دىُ *ды* – *де,* داى *дай* – دەى *дәй,* لار *лар* – لەر *ләр* кушымчалары шушы күрсәтелгән рәвешләрдә языла: ئشدەن *эшдән,* كيتدیُ *китде,* ئارتدر *артдыр* (ئشتەن, كيتتیُ, ئارتتر түгел).

Бер үк хәрефләр белән язылып, калын да, нечкә дә укылуы мөмкин булган сүзләрне бер-берсеннән аеру өчен, калын әйтелгәннәренең алдына калынлык билгесе куела: تش *теш* – تش، *тыш,* ئۆچ *өч* – ئۆچ، *оч,* بول *бүл* – بول، *бул.* Ләкин ع, ق, ا хәрефләре белән килгән сүзләрдә, ул сүзләрнең калынлыгы шул хәрефләрнең үзләреннән беленеп торганлыктан, калынлык билгесе куелмый: بولاسیُ *буласы,* ئۆرلق *орлык.*

Рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр иске имладагы кебек үк үзгәртелеп язылмый – төп чыганактагы әйтелеш азмы-күпме саклана. Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр исә татарча әйтелештә бирелә.

**Татарстанда латин алфавитын кабул итү.** Гарәп алфавитының төрки һәм иран телләре өчен яраксыз булуын, аны башка алфавит белән алыштырырга кирәклеген төрки халыклардан беренче башлап XIX йөз урталарында бөек азәрбайҗан язучысы һәм драматургы Мирза Фатали Ахундов күтәреп чыга. Татарлар арасында латинчылык

хәрәкәтенең башлангыч яралгылары 1911–1912 елларда шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең «Идел» газетасында чыккан мәкаләләрендә чагыла. С. Рәмиев татар телендә сузыкларның барысы унбер булуын (аныңча, *йа* дифтонгы да мөстәкыйль сузык), тартыкларның калынлыгы-нечкәлеге шул сузыкларның нинди булуына карап йөрүен күрсәтә. Хәреф мәсьәләсенә килгәндә, гарәп хәрефләрен ташлап, латин алфавитына күчүне уңай дип саный һәм ул алфавитның татар теле өчен булган проектын да төзи. Ләкин бу чорда латин хәрефләренә күчү әле мөмкин булмый, моңа аеруча дин әһелләре һәм консерватив карашлы укымышлылар каршы була. Латин хәрефләре турында җитди уйланулар киң күләмдә бары тик Октябрь инкыйлабыннан соң гына башлана.

1920 елда Казанда татар-башкорт журналистлары конференциясе була. Конференциядә имла-хәреф мәсьәләләре турында да сүз кузгала, гарәп хәрефләрен бер шәкелгә калдыру белән генә тынычланмаска, латин алфавитына күчәргә кирәклеге әйтелә.

1924 елда Мәскәүдә төрле төрки халыкларның вәкилләре катнашлыгында яңалиф комитеты төзелә. Комитет латин хәрефләре нигезендә алфавит проекты хәзерли. Татар һәм башкортлар өчен булган проект «Эшче» газетасында игълан ителә. Казанда «Латин дусы» җәмгыяте барлыкка килә. Аның да үз проекты була. Латин мәсьәләсе 1926 елда Бакуда булып үткән Беренче тюркология съездында да күтәрелә. Съезд яңа алфавитның төрки телләр өчен һәрьяклап уңай икәнен билгеләп үтә. Төрки телләргә иң яраклы принцип – фонетик принцип, дип танылә. Әлбәттә, билгеле дәрәҗәдә морфологик принцип та искә алына. Гарәп һәм башка чит телләрдән (Европа телләреннән һ.б.) кергән сүзләр шулай ук фонетик принцип буенча язылырга тиеш була. Тюркология съездыннан соң ук Казанда элекке «Латин дусы» урынына «Яңалиф» җәмгыяте оештырыла. Аның төп максаты – «киң эшче-крестьян массасы арасында латин хәрефләре нигезендә төзелгән яңа татар әлифбасын тарату» була. Җәмгыять яңа алфавит һәм орфография проекты төзи һәм шул проект нигезендә әлифба китабы, махсус брошюралар бастырып тарата. Проектта сузыклар өчен ун хәреф алына. *Қ* белән *ғ* дан башка тартыкларның барысы да аерым хәрефләр белән билгеләнә. Латинчыларга гарәп алфавитын яклаучылар белән җитди көрәшергә туры килә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, латинчылык хәрәкәтен яклап һәм дәүләт органнарын, барлык

оешмаларны бу эшкә булышырга чакырып, махсус карарлар чыгара. Шуннан соң латинчылык хәрәкәте тагын да зуррак колач ала. Яңа алфавитны халыкка җиткерүдә 1927 елда чыга башлаган «Яңалиф» журналы да зур роль уйный. 1927 елның июнь башларында Бакуда төрки алфавитларны берләштерү (унификацияләү) буенча махсус конференция үткәрелә. Конференциядә Татарстан алфавиты проектына зур гына үзгәрешләр керә, кайбер хәрефләр яңалары белән алыштырыла (мәсәлән, *é, ó, ш, w* урынына *ь, ө, ș, v* алына), *қ, ғ* авазлары өчен дә аерым хәрефләр бирелә (*q, ɋ*). Нәтиҗәдә латин алфавиты шундый рәвешкә керә:

Aa Вв Cc Çç Dd Ee Әә Ff Gg Ɋɋ Hh Ii Jj Kk Ll Mm Nn Ņņ Oo Өө Pp Qq Rr Ss Şş Yy Tt Uu Vv Xx Zz Ƶƶ Ьь Ꙇj ьj.

1927 елның 3 июлендә Татарстан автономияле республикасы Халык Комиссарлары Советы үзенең махсус карары белән латин алфавитын татар теленең рәсми алфавиты дип игълан итә. Барлык мәктәп, матбугат һәм нәшрият 1930 елның 1 гыйнварына тулысынча яңалифкә күчеп бетә. Шул көннән башлап яңалиф Татарстанда йөз процент гамәлгә куелган дип исәпләнә.

1990 елларда Татарстанда латинга күчү мәсьәләсе яңадан күтәрелә. Күпсанлы бәхәсләрдән соң, 1999 елда татар алфавитының латин графикасы нигезендә яңа варианты кабул ителә, ләкин 2002 елда Дәүләт Думасы тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә кириллицадан кала башка язу системасына нигезләнгән алфавитларны рәсми рәвештә куллануны тыя торган канун кабул ителә.

**Латин алфавитына нигезләнгән орфография.** Латин алфавитына күчүнең беренче елларында орфография белән, башлыча, Г. Нугайбәк шөгыльләнә. Г.Нугайбәк яңа орфографиягә төп нигез итеп фонетик принципны ала. «Яңалиф белән язганда, – ди ул, – татар теле өчен бер генә кагыйдә булырга мөмкин: сүзләр аерым торганда ишетелгәнчә, һәр авазның үз тамгасы куела». Бу кагыйдә буенча, ике сүз арасында янәшә килгән сузыкларның берсе икенчесе тарафыннан йотылу (*қара алдым [қар‿алдым], бала үрдәк [бал‿үрдәк]*), кайбер сүз кисәкләренең кыскаруы (*алып бар [аппар]*) һ.б. шундый җанлы сөйләм очраклары язуда чагылдырылмый. Гарәп хәрефләре белән язгандагы кебек, ябык иҗекләрдә *ŏ, ө, ы̆, ĕ* сузыкларын төшереп калдыру, нинди генә булса да беренче иҗектә *ы, ё* ләрне язмау бетерелә, ягъни

сүздә ничә һәм нинди аваз булса, шуларның барысы да күрсәтелә: قولن *koln,* ئندر *ndr* түгел, *kolon, éndér.* Сузыклар калынлык-нечкәлектә парлы һәм аларның барысы өчен дә хәрефләр булганлыктан, ягъни орфография унчылык нигезенә корылганлыктан, калынлык билгесен куллануның кирәге калмый. Тарихи-морфологик принципка ияреп, *t, p* урынына *d, b* язу кире кагыла: *kitab, mindən* түгел, *kitap, minnən.* Сүзнең беренче иҗегендә *ŏ* яки *ө* авазы булса, аннан соңгы иҗекләрдәге иренләштерелгән *ы̆*[о]*, ĕ*[ө]авазлары да шул ук аваз хәрефләре белән бирелә (*ы̆, ĕ* авазларының хәрефләре белән түгел): *bolon, boloto, kóтóш* (‘болын’, ‘болыты’, ‘көмеш’). Башка телләрдән кергән сүзләр татарча әйтелешкә буйсындырыла: *peristen, aktif, kumsastaf* (‘пристань’, ‘актив’, ‘комсостав’).

Төрки телләрнең алфавитлары берләштерелеп, татар яңалифендә кайбер хәрефләр алыштырылгач һәм өстәлгәч тә әле орфография кагыйдәләре берникадәр вакыт шул ук нигездә кала. 1928 елның гыйнварында – Бөтенсоюз яңалифчеләренең беренче съездында (Казан) да әле аңа әллә ни зур үзгәрешләр кертелми. 1929 елның май аенда булып үткән орфография конференциясе инде аны нык кына какшата. Конференция, татар теленең үз сүзләреннән дә бигрәк, чит телләрдән кергән сүзләрне үз асылына кайтарып язу турында ныграк кайгырта. Шуңа күрә дә, конференциядән соң М. Фазлуллин белән С. Атнагулов тарафыннан төзелеп расланган орфография кагыйдәләрендә әйтелгәнчә, «татар теле орфографиясендә моңа чаклы кулланылып йөртелгән сингармонизм кагыйдәсе ташлана», телдәге андый кагыйдә реакцион закон, консерватор закон дип игълан ителә. Хәтта татар теленең үз сүзләрен дә читтән кергән сүзләр язылышына «ипләргә», буйсындырырга тырышыла. Мәсәлән, *stakan, stina, stap, standart, student* сүзләренең алдында *ы̆–ĕ* авазлары булмаган кебек үк, андый авазлар *rɑq, ŋɑɥrcaq, skək* (‘ыргак’, ‘ыңгырчак’, ‘эскәк’) сүзләрендә дә язылмый. *Ы̆ – ĕ* авазлары сүз урталарында да мөмкин кадәр кысрыклана: *krə, cɑa, srlь, srlaştrsn.* Нәтиҗәдә, *ь – е* хәрефләренең язылу-язылмавы бик буталчык хәлгә керә. *О – ө* хәрефләренең язылышына да чикләнү ясала: аңарчы ул хәрефләр тамыр һәм нигез сүзләрнең башыннан алып азаккы иҗекләренә кадәр кулланылса, хәзер инде алар тик беренче иҗекләрдә генә йөртелеп, калганнарында *ь – е* хәрефләре языла яки, *ь – е* нең язылу-язылмау кагыйдәсенә туры китерелеп, бөтенләй төше-

релеп тә калдырыла: *bo1ьn, bɵre, solь. U, y* хәрефләре сузык авазларны гына түгел, иҗек ахырында һәм сүз урталарында *w* ярымсузыгын да белдерә: *auьl, əyen, tau, bau, bauь, au, aua.* Сүз башында исә *w* авазы *v* белән бирелә: *vaqьt, vatan, Vaxit, Vəli.*

1933 елның җәендә мондый бик шартлы һәм ясалма кагыйдәләрнең *o – ɵ* язылышына караганыннан башкалары кулланыштан төшерелә. *Ь – e* авазлары фонематик әһәмияте булган һәр урында языла: *brqaq, btiqbrcaq, eskak, ence, esse, xahq, qilem. U, y* хәрефләре сузык авазларны гына белдерә: *avb, aven, tav, tavb, davb, daval, vəkil.*

Орфографиянең башка урыннары, кайбер аныкландыруларны гына искә алмаганда, элеккечә кала. *Ьj – i* хәрефләре калын һәм нечкә сүзләрдә алышынып йөри: *tьj – ti, arьj – eri, qajtmьj – kilmi;* ләкин *c, ç, ş, z, q, ɋ, x, h* тартыкларыннан соң һәрвакыт *i* хәрефе языла: *aşi, aci, çinaq, tabiɋi, tarixi, uqi, dahi.* Ике сузык янәшә килеп, *u, y* артыннан *v*, шулай ук *i* артыннан *j* авазлары ишетелгән кебек булсалар яки ишетелсәләр дә, алар язуда күрсәтелми: *alu – a1uь, kily – kilye, bii – biye, cualьş.* Сүз башыннан икенче аваз булып *i* яки бер сузык аша *j* килсә, башта һәрвакыт *ç* хәрефе языла: *çir, çəj, çɵj, çaj, çuj.* Калган очракларда *j* языла: *jьlda, jьş, jegerme, jykə, jan.* Тик кайбер сүзләр генә бу кагыйдәгә иярми: *çan, çəvap, çentekle, çь1ь, çətmə, çep, çylər.* Сүз һәм иҗек ахырында бер-берсе белән чиратлашып килгән тартык авазлар әйтелгәнчә, ишетелгәнчә языла: *kitap – kutabъ, məktəp – məktəbe, aq – aɋь.* Ләкин тамыр һәм нигез сүз азагында *ʐ, s, n* авазларының башка аваз йогынтысында булган үзгәреше язуда күрсәтелми: *qьʐ – qьʐsa, syʐ – syʐcən, rus – rusca, irtən – irtənge, un – unɋa, isən – isənme.* Тамыр яки нигез сүз эчендәге *m, ŋ* авазлары башка аваз хәрефләре белән алыштырылмый: *caŋɋь, sɵŋge, tombьjьq, jəkşəmbe.* Яңа бер төшенчә белдерү өчен берничә сүздән кушылып ясалган сүзләр бергә языла: *Aɋidel, Almata, jarqanat, terekɵmeş, hicber; ләкин: un ber, un tuɋьʐ* h.б. Кара-каршы мәгънәле яки кабатлаулы сүзләрдән оешкан кушма сүзләр, сүз алды кисәкчәләре h.б. сызыкча (дефис) аша языла: *çir-su, xatьn-qьʐ, urьnlь-urьnsьʐ, qьp-qьʐьl, japa-jalɋьʐ.* Рус теленнән кергән сүзләрдәге аңкаулашкан (палаталь) тартыклар өске өтер (апостроф) белән бирелә: *asfal't, moral', rol';* ләкин андый тартык аваз нечкә сузык янәшәлегендә килсә, өске өтер куелмый: *morale, role, oktəbr.*

Өске өтер шулай ук һәмзәне дә белдерә: *tə'min, ta'sir, mə'mə'.*

Рус теленнән яки аның аша башка телләрдән язу теле аша кергән сүзләр һәм бигрәк тә терминнар гомумән рус орфографиясендәге формаларга туры китереп языла: *kino, foto, komitet, auditoriə, poeζiə, elektr, boksjor, kooperatif, Odessa.*

Яңалиф орфографиясенең соңгы вариантында дөрес язу кагыйдәләренең төп үзенчәлекләре менә шундый. Әйтергә кирәк, бу кагыйдәләр татар әдәби телен стандартлаштыруда, аны ныклы бер нормага салуда зур роль уйный, татарча дөрес язуны уңайлаштыра, ныклы бер эзлеклелеккә китерә. Шуңа күрә ул кагыйдәләр, рус алфавитына күчкәндә дә, орфографиянең нигезенә салына һәм бу яктан соңыннан да артык зур үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**Татар язуын рус алфавитына күчерү.** Утызынчы елларның ахырында рус алфавитына күчү мәсьәләсе күтәрелә. Рус алфавиты рус теленнән яңа кергән сүзләрне аның үзендәгечә язарга мөмкинлек бирә, рус һәм татар телләрен өйрәнгәндә, әле бер, әле икенче алфавит өйрәнеп торудан коткара. Рус алфавитына күчү шуның белән аңлатыла.

Рус графикасын татар теленә яраклаштыруның беренче тәҗрибәләре моннан байтак элек – XIX йөз урталарында ук күренә. Бу елларда профессор Н. Ильминский татарлар өчен рус язуы нигезендә махсус алфавит төзи. Керәшен татарларында ул алфавит Октябрь инкыйлабыннан соң да, алар яңалифкә күчкәнгә кадәр дә саклана.

Яңалифтән рус графикасына күчүнең беренче варианты 1938 елның августында игълан ителә. Бу проект буенча татар теленең специфик авазлары өчен бернинди дә өстәмә хәреф алынмый. Алар *ъ, ь* билгеләре катышлыгындагы хәреф тезмәләре белән белдерелергә яки рус телендәге нинди дә булса охшашрак яңгырашлы аваз белән алыштырылырга тиеш булалар. Мәсәлән, *әни, үс, үсү, үсә, тәрәзә, өчен* сүзләрен *аьни, усь, усю, уся, тярязя, оьчен* рәвешендә язарга тәкъдим ителә. Мондый проект, әлбәттә, кире кагыла. Шуннан соң алфавитның азагына татар теленең үз авазлары өчен *ә, ө, ү, җ, ң, һ* хәрефләре өстәлә. Яңа алфавит һәм орфография 1939 елның 5 маенда рәсми рәвештә гамәлгә куела. Кулланылыш барышында кертелгән кайбер орфографик аныклаулар 1941 елның 10 гыйнварында раслана. Хәзерге көндә шул орфография белән эш ителә.

Ләкин кайбер специфик авазлар (*қ, ғ, w*) өчен аерым хәрефләр бирелмәү нәтиҗәсендә, татарча дөрес язуның артык катлаулануы

(мәсәлән, *қәрдәш, хәқиқәт, диққәт, сәғәт, карлығач* сүзләре *кардәш, хакыйкать, дикъкать, сәгать, карлыгач* рәвешендә языла) һәм башка кайбер җитешсезлекләр алфавит һәм орфографияне тагын бер кат карап чыгуны, төзәтүне таләп итә. Шул турыда соңгы елларда зур фикер алышулар, гыйльми тикшеренүләр алып барылды. Нәтиҗәдә, 1958 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тарафыннан, язуга *қ, ғ* хәрефләрен өстәп (мәсәлән: *аққош, сәғәт, кәғәз), w* авазын сүз азагында гына түгел, сүз уртасында да *у, ү* хәрефләре белән биреп (*қауын, дәүа, дәүер*) һәм башка камилләштерүләр дә кертеп, татар теленең тулы алфавит һәм орфография кагыйдәләре проекты төзелә һәм бастырып чыгарыла. Җентекле фикер алышулардан соң 1960 елда ул проектны Хөкүмәт комиссиясе кабул итә. Ләкин киң җәмәгатьчелек бу проектны хупламый – *w* авазы өчен мөстәкыйль хәреф булмауны зур кимчелек дип саный. 1987–1990 елларда татар әдәби теле өчен кириллицаны камилләштерү омтылышы тагын кузгала – алфавитка *қ, ғ* авазлары өчен генә түгел, *w* авазы өчен дә махсус хәреф бирелеп (башта *у,* соңра *v*), орфографиянең яңа проекты төзелә. Әмма җәмәгатьчелек инде бу юлы традицион «Яңалиф»не яңартып (аңа *w* хәрефен дә өстәп) гамәлгә куюны таләп итә. Яңартылган «Яңалиф»кә («Jaŋalif+w») нигезләнгән тулы орфография кагыйдәләренең тулы җыемы бу графика белән язарга теләүчеләр өчен Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында төзелеп «Ватаным Татарстан» газетасында (15 окт., 24 дек. 1993 ел; 18 март, 22 апр. 1994 ел) нәшер ителә [Курбатов Х., 1960].

Кирил нигезендәге татар алфавитына соңгы үзгәрешләр 1997 елның гыйнварында кертелә. Нәтиҗәдә ул түбәндәге рәвешкә керә:

Аа Әә Бб Вв Гг Дд Ее Ёё Жж Җҗ Зз Ии Йй Кк Лл Мм Нн Ңң Оо Өө Пп Рр Сс Тт Уу Үү Фф Хх Һһ Цц Чч Шш Щщ ъ Ыы ь Ээ Юю Яя.

## ӘДӘБИЯТ

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения. М.: Наука, 1979. 279 с.

Беговатов Е.А. Руническая надпись на пряслице с булгарского селища // Истоки татарского литературного языка. Казань: ИЯЛИ, 1988. С. 17–19.

Закиев М.З. Тюрко-татарское письмо (история, состояние и перспективы). М.: ИНСАН, 2005. 248 с.

Исмагилов Н.Ф. Надпись на бронзовой статутке // Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. 1988. С. 20.

Кононов А.Н. Грамматика языка тюркских рунических памятников VII–IX вв. Л.: Наука, 1980. 255 с.

Кочкина А.Ф. Рунические знаки на керамике Беляра // Советская тюркология. № 4. 1985. С. 75−80.

Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 139 б.

Курбатов Х.Р. Утилитарные и поэтические типы речи // Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. Казань : ИЯЛИ, 1988. С. 18–23.

Ленц Э.О глиняных сосудах с коническим дном, находимых в пределах мусульманского Востока // Записки Вост. отд. Имп. Рус. археол. общ-ва. 1904. Т. 15. Вып. 4. С. 101–102.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М.; Л.: Изд-во АН СССР. 1959. С. 73.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1951. 451 с.

Мелиоранский П. Два серебряных сосуда с енисейскими надписями // Записки Вост. отд. Имп. Рус. археол. общ-ва. СПб., 1901 (1902). С. 17–22, 72.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

Старостин П.Н. Надпись на глиняном сосуде // Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. 1988. С. 19.

Старостин П.Н. Сабля с рунической надписью из села Именьково Казанской губернии // Истоки татарского литературного языка. Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова КФАН СССР, 1988. С. 14–16.

Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань, 1975.

# 6. ОРФОЭПИЯ

## 6.1. ОРФОЭПИЯ ТУРЫНДА ГОМУМИ ТӨШЕНЧӘ

Әдәби телдәгечә дөрес әйтелеш кагыйдәләре орфоэпия (грекча *orthos* ‘дөрес’ һәм *epos* ‘сөйләү’ сүзләреннән) дип йөртелә.

Орфоэпия фонемаларның һәм аларның вариантларының нинди фонетик шартларда ничек әйтелүләрен билгели. Аңа шулай ук аерым сүзләрдәге, сүзтезмәләрдәге (яки сүз араларындагы) һәм хәтта кайбер грамматик формалардагы авазларның язудагыга туры килми торган әйтелеш очракларын күрсәтү дә керә. Димәк, орфоэпия, барыннан да бигрәк, авазларның дөрес әйтелешенә игътибар итә, сөйләмнең башка үзенчәлекләре, мәсәлән, интонация, пауза, сүз басымы, фраза басымы, логик басым, шулай ук дикция дә турыдан-туры аңа карамый (бу соңгылары һәркайсы үз урынында – фонетикада яки грамматикада өйрәнелә).

Әйтелештәге бердәмлек, ягъни сөйләмнең әдәби нормаларга нигезләнгән булуы сөйләгәнне тиз һәм дөрес аңлауга китерә, аның матурлыгын һәм аһәңлелеген ныгыта, шул нигездә телгә үзенең төп функциясен – аның аралашу чарасы булуын тулырак үтәргә мөмкинлек бирә. Сүзне ялгыш әйтү исә, ялгыш язу кебек үк, игътибарны сөйләмнең эчтәлегеннән читкә җибәрә һәм шуңа күрә сүз ярдәмендә аралашуга комачау итә.

Орфоэпия, дөрес язу кагыйдәләре белән берлектә, диалекталь һәм гади сөйләм (‘просторечие’) әйтелешләрен кире кага һәм халык арасында әдәби әйтелеш нормаларын урнаштыруны максат итеп куя.

Әдәби әйтелеш үзе төп ике төргә бүленә: я з м а - к и т а б и стиль һәм җ а н л ы  с ө й л ә м стиле.

Язма-китаби стиль сөйләмнең бик анык булуы таләп ителгән очракларда, мәсәлән, радиотапшыруларда (диктор сөйләмендә), доклад яки чыгыш ясаганда, лекция укыганда яки дәрес биргәндә, ягъни сөйләүче язма тел стильләренең берсе белән эш иткәндә кулланыла.

Җанлы сөйләм стиле, үзеннән-үзе аңлашылганча, кешеләрнең үзара сөйләшеп аралашуларында – диалогларда кулланыла.

Язма-китаби стильдә сүзләрнең барлык иҗекләре дә диярлек ачык әйтелә. Җанлы сөйләм стилендә, киресенчә, кайбер иҗекләрнең кыскаруы яки бөтенләй төшеп калуы күзәтелә. Авазларның (тартыкларның да, сузыкларның да) әйтелеше, аларның комбинатор үзгәрешләре исә һәр ике стильдә дә, нигездә, бер үк.

**Татар теле әдәби әйтелешенең тарихи нигезе.** Татар теленең әдәби әйтелеше Казан сөйләшенә нигезләнгән. Казан сөйләше, билгеле булганча, урта диалектка керә. Казан шәһәре, гасырлар буе татар халкының мәдәни үзәге булып килгәнлектән, башка диалект һәм сөйләшләрне дә үз әйтелешенә караткан. Шулай ук Оренбург һәм Уфа татарлары сөйләшләре дә әдәби телнекечә. Бу, һичшиксез, Казан белән ул шәһәрләр һәм аларның тирә-яклары арасында элек-электән үк мәдәни мөнәсәбәтләрнең тыгыз булу нәтиҗәсе.

Язма әдәби хатирәләр татар әдәби теленең XI–XIII гасырларда ук инде формалаша башлаганын күрсәтәләр. Әдәби әйтелеш, әлбәттә, соңрак барлыкка килгән.

1905 ел инкыйлабыннан соң татар әдәби әйтелеше турында җитди фикерләр күтәрелә башлый, чөнки бу елларда Россиянең төрле шәһәрләрендә (Казан, Оренбург һәм Уфа шәһәрләрендә генә түгел, Петербург һәм Самарада, Себер, Кырым һ.б. җирләрдә) күп төрле татарча газета-журналлар чыга башлый. Ул шәһәрләрнең кайберләрендә төрле диалект һәм сөйләш, хәтта төрле төрки тел вәкилләре яши. Нинди сөйләшне уртак әдәби тел итеп алу, матбугатны нindirәк телдә чыгару, сүзләрне ничек әйтү һәм ничек язу турында газета-журнал битләрендә зур бәхәс куба. Пантюркистлар төрек телен яки ул телгә бик якын торган Кырым телен («Тәрҗеман» газетасы телен) барлык төрки халыклар өчен дә уртак тел итеп алуны дәгъва итәләр, теге яки бу милләтнең (мәсәлән, татарларның) традицион әдәби яки халык телен, әдәби әйтелешен артта калган тел, урам теле дип атыйлар. Бәхәс кылучыларның икенчеләре исә Казан сөйләшен казакълар, кыргызлар, башкортлар һ.б. өчен үрнәк итеп куялар. Бу бәхәс Октябрь инкыйлабына кадәр диярлек дәвам итә. Инкыйлабтан соң һәр төрки халыкка үз ана телендә иҗат итәргә хокук бирелә һәм тарихы ерак гасырларга барып тоташкан, йөз еллар буе камилләшеп ныгыган татар әдәби теле,

татар әдәби әйтелеше дә үзенең тиешле урынын ала. Матур әдәбият, фәнни хезмәтләр, вакытлы матбугат һ.б. шул телдә языла, театр, радио һәм мәктәп шул әдәби әйтелеш белән эш итә.

**Әдәби әйтелешне бозып сөйләү очраклары һәм аның сәбәпләре.** Әдәби әйтелешне бозып сөйләү ике төрле сәбәптән килергә мөмкин: беренчесе – әдәби әйтелеш белән дөрес язылыш (орфография) арасында зур гына аерма булуда (сөйләүче авазларны әдәби әйтелешчә түгел, кәгазьдә язылганча әйтә); икенчесе – сөйләүче теге яки бу диалект вәкиле булып, шул диалект үзенчәлекләреннән арына алмый.

Гамәлдәге язуда татар әдәби теленең кайбер фонемалары, мәсәлән, *қ, ғ, w* аерым хәрефләр белән түгел, бәлки *к, г, в – у – ү* хәрефләре белән берләштереп бирелә. Шунлыктан еш кына очракта, аеруча мәктәп балалары телендә, әлеге специфик фонемаларны *к, г, в* авазлары белән алыштыру күзәтелә: мәсәлән, *қәләм, қәрдәш, сәғәт, қарлығач, қарлыған, сәнғәт, диққәт, хәқиқәт, шағир, шиғер, Ғөмәр, Шәмғун, Wағиз, wатан, wәкил, даwыл, дәwер* диясе урынга нәкъ язылганча – *каләм, кардәш, сәгать, карлыгач, карлыган, сәнгать, дикъкать, хәкыйкать, шагыйрь, шигырь, Гомәр, Шәмгун, Вагыйз, ватан, вәкил, давыл, дәвер* дип уку һәм сөйләү. Бу сүзләрнең кайберләрендә *қ, ғ,* w авазлары гына түгел, *ә, ө, ĕ, ү, и, т, н, р* авазлары да *а, о, ый, у, ыйй, ть, нь, рь* белән алыштырып әйтелә, чөнки язылышта шулай, һәм, киресенчә, орфография кагыйдәләрендә бирелгән аңлатмаларга (калын сузыклар янында тартыклар калын әйтелә дигән кагыйдәгә) ияреп, дөрес язылганны ялгыш уку, мәсәлән, *бокал, казак, Камал, вокзал, вагон* кебек сүзләрне *қ, ғ, w* авазлары белән *боқал, қазақ, Қамал, wақзал, wағуп* рәвешендә әйтү очраклары да бар.

Әдәби әйтелешне дөрес үзләштерү өчен, әлбәттә, язылыш белән әйтелеш арасындагы мондый аермаларны истә тотарга кирәк.

Әдәби әйтелешне һәр диалект вәкиле үз сөйләшенә хас булганча үзгәртә.

Себер татарлары *б, д, з, ғ,г, ж* авазларын *п, т, с, қ, к, ш* белән алыштыралар, чөнки көнчыгыш диалектында саңгырау тартыклар күбрәк кулланыла. Мәсәлән: *Кәмәләр пелән йөртем Сеснең йылға пуйларын* (Жыр). – ‘Көймәләр белән йөрдем Сезнең йылга буйларын’; *Тимерне қысқанта сух* – ‘Тимерне кызганда суқ’; *Песне үрәтеп утра мәңке* – ‘Ғөмер буйы безне өйрәтеп утыра’. Татар теленең үз сүзләрендәге

*җ* авазы, гадәттә, *й* белән, гарәп теленнән кергән сүзләрдәгесе – *ч* белән алыштырыла: *чаwап алалматым* – ‘җаwап ала алмадым’; *сескә парып читте микән* – ‘сезгә барып җитте микән’; *йиләк* ‘җиләк’, *йер* ‘җир’. Әдәби телдәге *ч* авазы урынына *ц* аффрикаты йөри: *кецек* ‘кечек’, *цәйнәү* ‘чәйнәү’; *Күлтән оллы кәмә пелән кицерәләр* – ‘Күлдән олы көймә белән күчерәләр’. Кайбер сүзләрдә *җ, ш* авазлары урынына да *ц* кулланыла: *җәцәп* ‘гәҗәп’, *цыгыртап* ‘шыгырдап’. *Ф* авазы – *п* белән, *х* авазы *қ* белән алыштырыла: *пайда* ‘файда’, *қәреп* ‘хәреф’, *қәтер* ‘хәтер’, *қатын* ‘хатын’, *қалық* ‘халық’. Гарәп-фарсы алынмаларындагы *һ, г*авазлары гомумән төшереп калдырыла: *Сайт* ‘Заһит’, *мәәр* ‘мәһәр’, *шәәр* ‘шәһәр’, *сәәт* ‘сәгәт’, *пәсе* ‘бәгзе’.

Кайбер тартыклар икеләтелә: *алтты* ‘алты’, *йетте* ‘җиде’, *оллы* ‘олы’, *қатты* ‘каты’. Шулай ук сузык авазларны куллануда да үзенчәлекләр зур. Мәсәлән, әдәби телдәге *у, ү* авазларын *о, ө* белән алыштыру: *оңай* ‘уңай’, *пос тоңса* ‘боз туңса’, *тоқта* ‘туқта’, *көңел* ‘күңел’; *өй* дифтонгын *ү* сузыгына әйләндерү: *сүләү* ‘сөйләү’, *үрәнү* ‘өйрәнү’; *у, ү, и* сузыкларын *ыw, ĕw, ей* рәвешендә әйтү: *сыw* ‘су’, *килеw* ‘килү’, *кейеw* ‘киү’, *тейиш* ‘тиеш’; *ә, и* сузыкларын бер-берләре белән алыштыру: *кәрәк* ‘кирәк’, *кәбән* ‘кибән’, *цисәк* ‘чәчәк’, *тирәс* ‘тәрәзә’ һ.б.

Көнбатыш диалекты вәкилләре (мишәрләр) өчен барыннан да бигрәк *қ, г*фонемаларын *к, г фонемалары* белән алыштырып сөйләү хас. Мәсәлән: *Казан каласы* ‘Қазан қаласы’, *Гимади* Ғимади’, *бага*-*на* ‘бағана’, *кимак* ‘қоймақ’. Кайбер сүзләрдә *г* авазы гомумән төшеп кала: *Али* ‘Ғәли’, *Минали* ‘Миңғәли’. Язма әдәби тел киң таралган хәзерге дәвердә *қ, г* фонемаларының көнбатыш диалекты вәкилләре тарафыннан тиз үзләштерелә алмавына ул авазлар өчен язуда мөстәкыйль хәрефләр булмау да комачау итә.

Әдәби телнең өрелмәле гади *ч* авазын мишәрләр кушма тартык ч [$т^ь ш^ь$] итеп әйтәләр: *$т^ь ш^ь ә т^ь ш^ь$ әк* ‘чәчәк’, *$ут^ь ш^ь$ ак* ‘учак’, *$т^ь ш^ь$ итән* ‘читән’. *Ч* авазын *с* белән алыштыру очраклары да бар: *цыбык* яки *сыбык* ‘чыбық’, *цыпцык* яки *сыпсык* ‘чыпчық’, *цәцәк* яки *сәсәк* ‘чәчәк’. *Җ* урынына *й* әйтелә: *йир* ‘җир’, *йәймә* ‘җәймә’, *йан* ‘җан’. Кайбер сөйләшләрдә *й* түгел, *з: зир* ‘җир’, *зил* ‘җил’. Шулай ук ‘җ’ нең үзен кушык тартык итеп әйтү дә очрый: *$д^ь ж^ь$ айлы* яки *$д^ь з^ь$ айлы* ‘җайлы’, *$д^ь ж^ь$ итте* яки *$д^ь з^ь$ итте* ‘җитте’, *$д^ь ж^ь$ ир* ‘җир’, *морд$^ь ж^ь$ә* ‘морҗа’.

Көнбатыш диалекты вәкилләре сузыклардан *а* авазын, бер иҗектә дә *о*-лаштырмыйча, ачык *а* авазы итеп әйтәләр: *кала* ‘қа$^{о}$ла’, *карама* ‘қа$^{о}$ра$^{о}$ма’, *бала* ‘ба$^{о}$ла’. *Ŏ – ө* авазларын *ы̆ – ĕ* белән алыштыралар: *сылы* ‘солы’, *йымыш* ‘йомыш’, *ырлык* ‘орлық’, *кен* ‘көн’, *гел* ‘гөл’, *йез* ‘йөз’; *у – ү* авазларының *ŏ – ө* яки *ы̆ – ĕ* рәвешендә әйтелеше дә юк түгел: *шылай* ‘шулай’, *шындый* ‘шундый’, *кеңел* ‘күңел’; *ай, әй, ой, ый, уй* дифтонглары *а, ә, и, у* сузыкларына әвереләләр һәм алар янында аңкаулашкан (*и* авазы төсмерен алган, ягъни татар әдәби теленең үз сүзләре өчен хас булмаган) тартык килә: *кат$^{ь}$ам* ‘қайтам’, *кар$^{ь}$ак* ‘қайрақ’, *кан$^{ь}$ар* ‘қайнар’, *бал$^{ь}$ык* ‘байлық’, *чән$^{ь}$и* ‘чәйни’, *ул$^{ь}$им* ‘уйлыйм’, *аби* ‘абый’, *кийаш* ‘қойаш’; *өй* дифтонгы *ү, ә, и* авазларының берсенә әйләнә: *ү* ‘өй’, *кү* ‘көй’, *сүли* ‘сөйли’, *үwә* ‘өйә’, *кийә* ‘көйә’, *кийенеч* ‘көйенеч’.

Әдәби әйтелешне бозып сөйләү башка диалект яки сөйләш вәкилләрендә дә күзәтелә. Мәсәлән, Касыйм татарлары *қ, к, ғ, г* тартыкларын бу очракта фонема булып килә торган һәмзә (кнаклаут) авазы белән алыштырып сөйлиләр: *’ыр’а* ‘қырға’, *та’ма’* ‘тақмақ’.

Урта диалектның Минзәлә сөйләшендә *с, з* тартыкларын теш арасы *ç, ʒ,* авазлары белән алыштырып әйтәләр: *қырмысқа* ‘қырмысқа’, *боʒаw* ‘бозаw’, *кыʒыл* ‘кызыл’ һ.б.

Әдәби телне ныграк үзләштергән саен, әдәби телдә сөйләүчеләр белән күбрәк аралашкан саен, сөйләүче телендә андый диалекталь күренешләр һәм үзенчәлекләр әкренләп югала бара.

Төрле диалект һәм җирле сөйләш шартларында әдәби әйтелешне урнаштыру, халык арасында әдәби әйтелеш культурасын күтәрү, аеруча яшь буынга әдәби әйтелешнең ныклы нигезләрен бирү, укучылар телендәге диалекталь әйтелешләрне бетерү өчен, мәктәп укытучыларының барысы да зур тырышлык күрсәтергә тиеш. Ләкин моның өчен, барыннан да бигрәк, укытучының үзенең әдәби әйтелешкә тулысынча ия булуы кирәк.

## 6.2. ТАТАР ӘДӘБИ ӘЙТЕЛЕШЕНЕҢ ТӨП КАГЫЙДӘЛӘРЕ

**Сузыкларның дөрес әйтелеше.**

1. Татар әдәби теленең үз сүзләрендә беренче иҗек калын сузыклы булса, башкалары да калын сузыклар белән, беренче иҗек нечкә сузыклы булса, башкалары да нечкә сузыклар белән әйтелә. Мәсәлән: *қыйа* (‘кыя’), *ындыр, озын, урамнар; чәчәк, күгәрчен, өзәңге.* Бары тик *миңа,*

*сиңа* сүзләре һәм калынлы-нечкәле сүзләрдән төзелгән кушма сүзләр генә (*билбаw* ‘билбау’, *көнчығыш* ‘көнчығыш’, *Ағидел* ‘Агыйдел’ һ.б.) бу кагыйдәдән чыгарма булып торалар.

Алынма сүзләр арасында йә калын (*мақсат* ‘максат’, *матбуғат* ‘матбугат’, *hawa* ‘hawa’, *пароход, аппарат* h.б.), йә нечкә генә (*сәғәт* ‘сәгать’, *қәләм* ‘каләм’, *ғәрәп* ‘гарәп’, *бәғзе* ‘бәгъзе’, *қәтғи* ‘катьгый’, *җәмғиәт* ‘җәмгыять’, *қәнәғәт* ‘канәгать’, *қәрдәш* ‘кардәш’, *хәқиқәт* ‘хәкыйкать’, *өстәл, эскәтер, эшләпә* h.б.) сузыклы сүзләр дә, калын һәм нечкә сузыклар белән әйтелә торган калынлы-нечкәле сүзләр дә (*дөнйа* ‘дөнья’, *иҗат, китап, физика, картина, машина* h.б.) булырга мөмкин.

2. *А* сузыгы сүзнең беренче иҗекләрендә *о*-лаштырып әйтелә. *О*-лаштыру беренче иҗектә көчле булып, азаккы иҗеккә таба кими бара. Басымлы иҗектә саф *а* әйтелә. Мәсәлән: *ба*$^{\text{о}}$*ла* ‘бала’, *ба*$^{\text{о}}$*ла*$^{\text{о}}$*лар* ‘балалар’, *ба*$^{\text{о}}$*ла*$^{\text{о}}$*ла*$^{\text{о}}$*рға* ‘балаларга’, *а*$^{\text{о}}$*лма*$^{\text{о}}$*ға*$^{\text{о}}$*члар* ‘алмагачлар’, *а*$^{\text{о}}$*лма*$^{\text{о}}$-*ға*$^{\text{о}}$*чла*$^{\text{о}}$*рға* ‘алмагачларга’, *қа*$^{\text{о}}$*ра*$^{\text{о}}$*ма* ‘карама’, *ка*$^{\text{о}}$*ра*$^{\text{о}}$*ма*$^{\text{о}}$*да* ‘карамада’.

3. *О, ө* сузыклары сүзнең беренче иҗегендә ачык әйтелеп, калган иҗекләрдә (аеруча кушымчаларда) бик аз гына үзгәрә: *болы*$^{\text{о}}$*н* ‘болын’, *болы*$^{\text{о}}$*ны*$^{\text{о}}$*ның* ‘болынының’, *солы*$^{\text{о}}$*сы*$^{\text{о}}$*ның* ‘солысының’, *орлы*$^{\text{о}}$*ғы*$^{\text{о}}$*ның* ‘орлыгының’, *бөре*$^{\text{ө}}$*сенең* ‘бөресенең’, *сөлге*$^{\text{ө}}$*сенең* ‘сөлгесенең’, *өрле*$^{\text{ө}}$*генең* ‘өрлегенең’. Кушма сүзләрнең икенче кисәгендәге беренче иҗектә *о, ө* авазлары булса, алар шулай ук ачык әйтелә: *озы*$^{\text{о}}$*нборы*$^{\text{о}}$*н* ‘озынборын’, *терекөме*$^{\text{ө}}$*ш* ‘терекөмеш’, *аққош* ‘аккош’[1].

4. Беренчесе – ачык иҗектән, икенчесе – ябык иҗектән торган (ләкин ябык иҗегенең башында яки ахырында сонор яки өрелмәле тартыкларның берсе булган) сүзләргә сузык аваздан башланган яки сузык аваздан торган кушымча ялганганда, сөйләшү стилендәге әйтелештә ябык иҗектәге *ы̆ – ĕ* авазы: 1) яки бик нык кыскара (*w, й* авазларыннан кала барлык тартыклар белән *р* тартыгы арасында): *йөгер → йөг*$^{\text{е}}$*рә, чақыр → чақ*$^{\text{ы}}$*ра, утыр → ут*$^{\text{ы}}$*ра,* ләкин: *дәwер → дәwре*, *бөйер → бөйре, қайыр → қайрам;* 2) яки бөтенләй төшеп кала (р авазыннан кала барлык тартыклар алдында): *сағын→сағнам, фиғел → фиғле, туғыз→туғзынчы, ачыл→ачла, wақыт→wақты, таwыш→таwшы, муйын→муйны, күңел→күңле.*

---

[1] Моннан соңгы мисалларда сүз яки сүз тезмәләренең дөрес әйтелешләре генә бирелеп, язылышлары күрсәтелми.

Ике сузык арасында әйтелгән *б* авазы, *ы̆ – ĕ* сузыгы төшү яки кыскару очрагында да, шул килеш саклана. Мәсәлән: *табын → табны, сибел → сиблә, қабын → кабна. Ы̆ – ĕ* авазы төшкәндә яки кыскарганда, *қщ, к* авазлары, кайбер сүзләрдә генә үзгәрешсез калып, күп очракта *ғ, г* авазларына күчә. Мәсәлән: *халық → халқы, қалық → қалқа, милек → милке,* ләкин: *мамық → мам$^{ы}$ғы, балық → бал$^{ы}$ғы, җелек → җел$^{е}$ге, қабық → каб$^{ы}$ғы.*

*Ы̆ – ĕ* сузыгының кыскаруы яки төшеп калуы башка кайбер очракларда да күзәтелә. Мәсәлән: *бары да йөгерә → бар‿да йөгрә, чәй эчеп утыра → чәй‿чеп утыра; Сез тағын шул турыда сөйлисез → ...шул турда.*

Ләкин шуны әйтергә кирәк, *ы̆ – ĕ* авазларын төшереп сөйләү гомумән алганда ирекле яки, тагын да дөресрәге, сөйләмнең ритмына, ритмик төркемнең (ритмик группаның) ничә иҗектән торуына, ничә иҗекне сыйдыра алуына бәйләнгән. Әгәр ритм таләп итсә, *ы̆ – ĕ* авазлары әйтелә, таләп итмәсә, әйтелми. Бу хәл аеруча шигъри сөйләм өчен хас. Мәсәлән, түбәндәге өзекләрнең беренчесендә *ы̆* авазы әйтелә (‘төн утырып’), икенчесендә – әйтелми (‘сулгып-сулгып’, ‘awру қызга’), чөнки дүрт иҗектән торган ритмик төркем беренче очракта ул сузыкны сыйдыра, икенчесендә – сыйдырмый:

*Төн утырып ¦ шагыйрь ¦ нәрсә язды?* |
*Нинди хисләр ¦ аны ¦ ярсытты?* |
(М. Җәлил, «Шагыйрь»)

*Кыз авырды, ¦ тәне ¦ ут шикелле,* |
*Сулыгып-сулыгып ¦ тибә ¦ йөрәге.* |
*Гаҗиз калды ¦ доктор, ¦ авыру кызга* |
*Бер дару да ¦ файда ¦ бирмәде.* |
(М. Җәлил, «Дару»)

5. Әгәр *р* авазы нинди дә булса тартыктан соң килсә (ләкин *w* яки *й* авазларыннан соң түгел), алар арасында, тулы стиль белән сөйләгән вакытта, гадәттә, йөгерек *ы̆ – ĕ* сузыгы әйтелеп китә (язуда ул күрсәтелми). Мәсәлән: *күк$^{е}$рәк, туф$^{ы}$рақ, аз$^{ы}$рақ, тиз$^{е}$рәк, киң$^{е}$рәк, ут$^{ы}$раw, күк$^{е}$рә, чүп$^{е}$рә, туқ$^{ы}$ран.*

6. Татар телендә бер генә иҗек тә саф сузыктан башланып әйтелми. Әгәр иҗек башында тартык аваз булмаса, андый иҗек: 1) яки

үзеннән алдагы сүзнең соңгы тартыгын үзенә ала: *йул өсте →йу-лөс-те, йафрақ оча → йаф-ра-ғо-ча, килеп ала → ки-ле-ба-ла;* 2) яки үзеннән алдагы сузыкка ялганып (үзеннән алдагы сузык белән бергә дифтонг яки дифтонгоид рәвешендә әйтелеп) килә: *бара әле → ба-ра‿ә-ле* (*«аә»* рәвешендә «йөздереп» әйтелә), *Бату әйтә → Ба-ту-*$^{w}$*әй-тә, барысы да үзендә → бар-сы-даw-зен-дә, йаза иде → йа-зай-де, ки әле → ки-*$^{й}$*ә-ле;* 3) яки, әгәр ике янәшә сүз бер ритмик басым белән әйтелсә, ике сүз арасындагы сузыкларның берсе икенчесе тарафыннан йотылып йә кыскарып, иҗек баштагы сүзнең соңгы тартыгыннан башлана: *алма ала → ал-ма-ла, йақты өй → йақ-төй, йаңа урам → йа-ңаw-рам;* 4) яки, бу шартларның берсе дә табылмаса (мәсәлән, андый сүз үзе генә аерым китерелсә яки зур паузадан соң килгән фраза яисә җөмлә башында торса), иҗек башындагы сузык үзенчәлекле бер шартлаулы тартык – һәмзә (кнаклаут) белән әйтелә: *ʼалма,* ләкин: *ʼәнис‿алмасы; ʼурман,* ләкин: *Без‿урманга бардық; ʼөлкә,* ләкин: *Чиләб‿өлкәсе* [*чи-лә-бөл-кә-се*]; *Әлфиә сәғәт сигездә‿үк килде, ʼә ул – ʼәле генә.*

Сүз башындагы сузыкны шушы соңгы очрактан башка вакытта һәмзә белән әйтү (‘кистереп’ әйтү) матур яңгырамый, әдәби әйтелеш өчен ул аһәңле булып чыкмый.

7. Бер төшенчә яки тәгалләнгән бер уй белдерә торган янәшә сүзләр, гадәттә, гомуми бер басым – ритмик басым (фраза басымы) белән әйтеләләр һәм шул нигездә бер ритмик төркем (ритмик группа) тәшкил итәләр. Әгәр ритмик төркемгә беренчесе – сузыкка беткән, икенчесе сузык белән башланган сүзләр керсә, алар өчен беренче сүз азагындагы сузыкның икенче сүз башындагы сузык тарафыннан йотылу тенденциясе хас. Чөнки ритмик төркемдә басым күп очракта икенче сүзнең соңгы иҗегенә төшә, ә беренче сүз азагы басымсыз кала. Басымсыз калган сузык, үзеннән-үзе аңлашылганча, күрше сузык тарафыннан йотылуга җиңелрәк бирелә. Тик шунысы бар, бу тенденция һәртөрле сузык очрашуда да башкарыла алмый: бертөрле сузыклар «көчлерәк» (мәсәлән, калын сузыклар – үзләренең нечкә парлары каршысында, *у, ү, и, а, ә* сузыклары – *ŏ, ө, ы, ĕ* каршысында көчлерәк), икенче төрләләре «көчсезрәк» булып чыга һ.б. Ритмик төркемнәрне әйтүдәге мондый закончалык аеруча сөйләшү стилендә нык саклана, тулы стильдә исә чагыштыр-

мача аз үткәрелә (бу соңгысында, кирәгенә карап, һәр сүзне «китапта язылганча» аерым-аерым рәвештә аныклап әйтү очраклары да була).

Беренчесе – сузыкка беткән, икенчесе сузык белән башланган сүзләрнең бер ритмик басым (бер фраза басымы) белән әйтелә торганнарында сузыклар очрашуы түбәндәгечә:

1) Ике бертөрле сузык бер генә сузыкка кала (ягъни: *а+а = а, ә+ә=ә, у+у=у, ү+ү=ү, ы̆ ы̆ = ы̆, ĕ+ĕ = ĕ*) һәм ул тулы стильдә сузыбрак, сөйләшү стилендә, башлыча, бер аваз итеп әйтелә: *қара аны → қар‿аны, ничә әйттем → нич‿әйттем, кайту урыны → қайт‿урны, чигү үрнәге → чиг‿үрнәге, йарты ындыр → йарт‿ындыр, серле ĕзләр → серл‿ĕзләр, килми иде → килм‿иде;* беренче яки икенче сүз, яисә ул сүзләрнең һәр икесе берәр генә иҗекле булса, ике бертөрле сузык әдәби әйтелешнең һәр стилендә дә сузыбрак әйтелә: *ки итек → к‿итек, чи ит → ч‿ӣт, бу урам → б‿ӯрам.*

2) Калын һәм нечкә пар сузык очрашканда, нечкәсе калыны тарафыннан йотыла (ягъни: *а+ә* яки *ә+а=а; у+ү* яки *ү+у = у; ы+ĕ* яки *ĕ+ы̆ = ы̆*): *қара әйбер → қара‿йбер, өлгерә алмадым → өлгер‿алмадым, күктә ай → күкт‿ай, дару үләне →дару‿ләне, килү урыны → кил‿урны* (*ү* белән *у* кушылганда, *у* һәрвакыт сузыбрак әйтелә), *туры ĕлемтә → туры‿лемтә, иске ыңгырчақ → иск‿ыңгырчақ, қоры ĕремчек → қоры‿ремчек.*

3) *А, ә* сузыклары *ŏ, ө, ы̆, ĕ* авазларыннан элек килсә, *ŏ, ө* яки *ы̆, ĕ* катышлыгында дифтонгоидлаштырылган *а, ә* авазлары әйтелә (ягъни: *а+ŏ=а*$^{о}$, *а+ө=а*$^{ө}$, *ә+ŏ=ә*$^{о}$, *ә+ө=ә*$^{ө}$, *а+ы̆=а*$^{ы}$, *а+ĕ=а*$^{е}$, *ә+ы̆=ә*$^{ы}$, *ә+ĕ=ә*$^{е}$): *қарчыға оча →қарчыға*$^{о}$*‿ча, бура өстендә →бура*$^{ө}$*‿стендә, қойма ышығы → қойма*$^{ы}$*‿шығы, барыннан да ĕлек → барыннан да*$^{е}$*‿лек, нигә озақ → нигә*$^{о}$*‿зақ, ничә өрлек → ничә*$^{ө}$*‿рлек, мин дә ышанам → мин дә*$^{ы}$*‿шанам, кичә ĕссе булды →кичә*$^{е}$*‿ссе булды.*

*А, ә* сузыклары *ы̆, ĕ* авазларыннан соң килсә, *а, ә* авазлары әйтелә (ягъни: *ы̆+а* яки *ĕ+а=а; ы̆+ә* яки *ĕ+ә=ә*): *солы ашы → сол‿ашы, берсе алма → берс‿алма, йуқмы әллә → йуқм‿әллә, килде ме әле → килдем‿әле.*

4) *Ы̆, ĕ* авазларыннан соң *ŏ* килсә – *ŏ*, әгәр *ө* килсә – *ө* әйтелә: *арғы очта → арғ‿очта, қайсы өлкә → қайс‿өлкә, ике орчық → ик‿орчық, кичәге өмә → кичәг‿өмә.*

5) *У, ү* сузыклары *о̆, ө, ы̆, ӗ* авазларыннан элек килсә, *о̆, ө, ы̆, ӗ* катышлыгында дифтонгоидлаштырылган *у, ү* авазлары әйтелә (ягъни: *у+о̆= у*$^{о}$, *у+ө=у*$^{ө}$, *ү+о̆=ү*$^{о}$, *ү+ө=ү*$^{ө}$, *у+ы̆=у*$^{ы}$, *у+ӗ=у*$^{е}$, *ү+ы̆=ү*$^{ы}$, *ү+ӗ= ү*$^{е}$): *Қайтышлый миңа Бату очрады → ...Бату*$^{о}$*‿чрады; дару өләште → дару*$^{о}$*‿ләште, тату ӗшлиләр → тату*$^{е}$*‿шлиләр.*

Аерым очракларда *о̆, ө, ы̆, ӗ* авазлары (бигрәк тә *ө, ӗ*) бөтенләй төшеп, *у, ү* авазлары гына әйтелә: *о̆, ө* авазлары төшкәндә, аннан соңгы иҗекләрдәге сузыклар *о̆, ө* төсмерләрен ала (*ы, е* авазлары тулысынча *о̆, ө* гә әйләнә): *уқу өчен → уку‿чөн, күрү өчен → күрү‿чөн, қайту ышанычы → қайту‿шанычы.*

*У, ү* сузыклары *ы̆, ӗ* авазларыннан соң килсә, *у, ү* авазлары әйтелә (ягъни: *ы̆+у* яки *ӗ+у=у; ы+ү* яки *ӗ+ү=у*): тары *ура → тар‿ура, иске урын → иск‿урын, ике үрдәк → ик‿үрдәк.*

6) *У, ү* сузыкларыннан соң *а, ә, и* авазларының берәрсе килсә, ике арага йөгерек *w* авазы өстәлә: *су асты →* су$^{w}$*сты, қу әле → қу*$^{w}$*әле, ку инде → ку*$^{w}$*инде.*

7) *У, ү* сузыклары, *а, ә* авазларыннан соң килсә, кыскара – *w* авазы кебек әйтелә (ягъни: *а+у* яки *а+ү=аw; ә+ү* яки *ә+у=әw);* әгәр икенче сүзнең беренче иҗеге ачык булса (ягъни *у* яки *ү* авазыннан торса, мәсәлән: *у-рақ, ү-рә), у, ү* сузыкларының кыскаруы ныграк, әгәр ябык булса (мәсәлән: *ур-ман, ускән*), азрак була; әгәр икенче сүз ябык бер иҗектән генә торса (мәсәлән: *ул*), кыскарган *у, ү* авазларыннан соң (ягъни: *w* дән соң) йөгерек *ы̆, ӗ* авазлары әйтелеп китә: *қайда ул → қайда‿wыл, қайда урақ → қайда‿wрақ, нәрсә үрә → нәрсә wра, барысы да үзенеке → барысы да‿wзенеке, бақчада үскән → бақчада‿*$^{w}$*үскән, аwыл очында урман → аwыл очында‿*$^{w}$*урман.* Даими кулланылышта бер сүз булып киткән кайбер мондый ритмик төркемнәрдә *а, ә* авазлары бөтенләй төшеп кала, мәсәлән: *қара урман → қарурман* (ягъни биредә беренче сүз үзенең мөстәкыйль басымын югалткач, басымсыз калган *а* сузыгы тора-бара әйтелмәс булган).

8) *И* сузыгыннан соң *а, ә, у, ү* авазларының берәрсе килсә, ике арага йөгерек *й* авазы өстәлә (ягъни: *и+а=и*$^{й}$*а, и+ә=и*$^{й}$*ә, и+у=и*$^{й}$*у, и+ү=и*$^{й}$*ү*): *ни аласың → ни* $^{й}$*аласың, ни әйтәсең → ни* $^{й}$*әйтәсең, йүри уза → йүри* $^{й}$*уза, йүри үрти → йүри* $^{й}$*үрти.*

9) *И* сузыгыннан соң *о̆, ө, ы̆, е* авазларының берәрсе килсә, ике арага йөгерек й өстәлә һәм *о̆, ө, ы̆, ӗ* авазлары кыскарак әйтелә (ягъни:

*и+о̆=и о̆, и+ ө=и$^{й}$ө, и+ы̆= и$^{й}$ы, и+ӗ= и$^{й}$ӗ*): *нинди оста → нинди‿$^{й}$оста, нинди өрлек → нинди $^{й}$өрлек, нинди ыңгырчаķ → нинди‿$^{й}$ыңғырчаķ, бу ни эш → бу ни‿$^{й}$еш.*

Аерым очракларда, *о̆, ө, ы̆, ӗ* авазлары (бигрәк тә *ө, ӗ*) бөтенләй төшеп, *и* авазы гына әйтелә; *о̆, ө* авазлары төшкәндә, аннан соңгы иҗекләрдәге сузыклар *о̆, ө* төсмерләрен ала (*ы, е* авазлары тулысынча *о̆, ө гә* әйләнә): *ни өчен → ни‿чөн, нинди ёлемтә → нинди‿лемтә, килми озаķ торма → килми за$^{о}$ķ торма, нинди ышаныч → нинди‿шаныч.*

10) *И* сузыгы, *а, ә* авазларыннан соң килсә, кыскара – *й* авазы кебек әйтелә (ягъни: *а+и=ай, ә+и=әй*); әгәр икенче сүзнең беренче иҗеге ачык булса (ягъни *и* авазыннан торса, мәсәлән: *и-де, и-ләк*), *и* авазының кыскаруы ныграк, әгәр ябык булса (мәсәлән: *илт-те, ик-мәк, ир-тән*), азрак була: *баķчаға илтте → баķчаға‿й$^{и}$лтте, йаңа икмәк → йаңа‿й$^{и}$кмәк, йаңа иләк → йаңа‿йләк, болында иде → болында‿йде, кичә иртән → кичә й$^{и}$ртән.*

11) *И* сузыгы, ы авазыннан соң килеп, ачык иҗек башында торса (мәсәлән: *и-де, и-ли*), *й* авазына әйләнә (ягъни: *ы̆+и=ы̆й*)*: яķты иде → яķты‿йде, машина солы или → ...солы‿йли.* Әгәр*и* сузыгы ябык иҗек башында килсә (мәсәлән: *ир-тә, ис-тәлек*), *ы̆* авазы гадәттә бөтенләй төшеп, *и* авазы гына әйтелә: *шатлыķлы иртә → шатлыķл‿иртә, йаķты истәлек → йаķт‿истәлек.* Ләкин кулланышы даимиләшкән *ы̆+и* кушылмасында, *и* сузыгы ябыкиҗек башында тормаса да, *и* авазы гына әйтелергә мөмкин, мәсәлән: *ķайттымы икән → ķайттымикән.*

12) *И* сузыгы *ӗ* авазыннан соң килсә, *ӗ* авазы һәрвакыт төшеп кала һәм *и* авазы үзе генә әйтелә (ягъни: *ӗ+и=и*)*: килде инде → килд‿инде, көн җилле иде → ...җилл‿иде.*

Югарыда күрсәтелгән төрләрдәге янәшә сузыклар үзгәреше, алда искәртеп үтелгәнчә, бер ритмик басым (бер фраза басымы) белән әйтелгән янәшә сүзләр аралыгында гына була. Башка шартларда һәрбер сузык, гадәттә, үзе әйтелә, ләкин бер сузыктан икенче сузыкка күчү «кырт кисеп» (ягъни һәмзә белән) түгел, бәлки «йөздереп», бер сузыкны икенче сузыкка дифтонгоид кебегрәк итеп ялгау рәвешендә әйтелә. Теге очракка да, бу очракка да әзер мисалларны без һаман да шигъри әсәрләрдән җиңел таба алабыз, чөнки шигырьдә ритмик төркем чикләре цезура һәм юл аралары ярдәмендә анык билгеләнә,

ритмик басым исә ритмик төркемнең (фразаның) соңгы иҗегенә төшә. Мәсәлән, Һади Такташ шигырьләреннән ике өзек:

*Кызыл көрәшче, син ⸽ ат өстендә;|*
*Очкан коштай синең ⸽ туры атың.|*
*Көрәш кырларында ⸽ җан юлдашың,|*
*Хыянәтсез дустың ⸽ канатың.|*
(«Атлы сугышчыга»)

*Зурлар кебек, кулны ⸽ артка куеп,|*
*Йөри идек, таптап ⸽ болынны.|*
(«Мокамай»)

Беренче мисалда *«туры атың»* сүзләре бер ритмик басым белән әйтелгән, ике сүз арасындагы *ы̆* авазы бөтенләй төшеп, *а* авазы гына калган: *«тур‿атың»*. Шундый ук янәшә сузыклар (*ы̆* һәм *а*) икенче мисалда да бар: *«қулны | артқа қуйып»;* ләкин биредә аларның һәр икесе дә әйтелә – берсе икенчесе тарафыннан йотылмый, чөнки *«қулны»* сүзе *«артқа қуйып» сүзләре* белән бергә бер ритмик төркем тәшкил итми (арада кечкенә цезура бар).

Бер ритмик басым белән әйтелә торган сүзләрдә беренче сүзнең соңгы авазы икенче сүз башындагы авазга ялганып китү, янәшә сүзләр арасындагы сузыкларның берсе икенчесе тарафыннан йотылу яки билгеле шартларда теге йә бу авазның төшеп калуы һәм башка шундый күренешләр кайбер Европа телләренә, мәсәлән, француз теленә дә хас. Рус теленең әдәби әйтелешендә исә, киресенчә, андый үзенчәлек юк.

8. Ниһаять, татар әдәби теленең сузыклар әйтелешендә тагын шул үзенчәлекне билгеләп үтәргә кирәк: тойгылы сөйләмдә кайбер сүзләрнең (мәсәлән, мәгънә үзәгенә куелган сүзләрнең) сүз басымы туры килгән сузыклары гадәттәгедән күп мәртәбә сузыбрак әйтелергә мөмкин. Мәсәлән: *Қāйа киттең? Ашықма. Мин дә барам.* Бу бигрәк тә сөйләшү (диалог) стиленә хас.

**Тартыкларның дөрес әйтелеше.** 1. *Б* авазы, ике сузык яки сузык белән *р* тартыгы арасында килгәндә (бу очрак бер сүз эчендә генә түгел, ике сүз аралыгында да булырга мөмкин), шартлаулы үзенчәлеген югалта һәм өрелмәле *б̊* булып әйтелә (бу аваз ишетелеше ягыннан ирен-теш тартыгы *в* гә якын): *қаб̊ақ, киб̊ән, күб̊әләк, торб̊а, тиб̊рән, туб̊‿ала* («туп ала»), *суга‿б̊ара, ике‿б̊үлмә;* ләкин: *багана, бүрәнә,*

*болын* (чөнки бу соңгы сүзләрдә сузык аваз *б* тартыгының бер генә ягында).

2. *Ч* тартыгы – әдәби телдә гади өрелмәле аваз. Көнбатыш диалектының кайбер вәкилләре аны *т* һәм *ш* авазларыннан торган кушма тартык [т$^{ь}$‿ш$^{ь}$] итеп әйтәләр. Бу – дөрес әйтелеш түгел.

Әдәби телдә *ч* андый авазлар катышлыгыннан башка,ягъни саф *ч* булып әйтелә: тел очының өске өлеше алгы каты аңкауга *т* не әйткәндәге кебек тиеп китми, бәлки ул урында тар гына аралык кала – һава шуннан өрелеп чыга. Ләкин шул вакытта әйтелгән аваз *ш* дә түгел, бәлки татарча *ч* булып яңгырый, чөнки *ш* ны әйткәндә, тел очының иң алгы өлеше, *ч* ны әйткәндә исә, аннан чак арткырак – киңрәк өлеше катнаша. Мәсәлән: *чана, чәнечке, чәй, кич, күчә.*

*Җ* тартыгы – әдәби телдә шулай ук гади өрелмәле аваз: ягъни ул – *д* һәм *ж* авазлары кушылмасы түгел, бәлки саф *җ* авазы, *ч*-нең яңгырау пары. Мәсәлән: *җәмгыять, җаwап, җәwһәр, җәй, гаҗиз, таҗ.*

3. *С, з* тартыклары әдәби әйтелештә тел очында һава өреп әйтелә. Мәсәлән: *су, қузгалақ, сирәк, қызыл.* Ул авазларны, минзәлә сөйләшендәгечә, теш арасы авазлары итеп (ягъни тел очын ике теш арасына куеп) әйтү әдәби әйтелешкә туры килми.

4. Ирен-ирен ярым сузыгы *w*, гамәлдәге орфография буенча, иҗек башында *в,* иҗек ахырында *у – ү* хәрефләре белән бирелә. Язылыш белән әйтелеш арасында зур аерма булганлыктан, шуны искәртергә кирәк: *w* авазы, үзенең табигате белән сузык *у – ү* авазларына якын булып, саф тартыктан – алынма сүзләрдәге (*вагон, завод*) ирен-теш тартыгы *в* дан бик нык аерыла. *W* авазын дөрес әйтергә өйрәнү өчен (моны белү көнбатыш диалектының кайбер вәкилләре өчен аеруча мөһим), иң элек *у* яки *ү* сузыгын әйтергә дә аңа нинди дә булса башка берәр сузыкны ялгап җибәрергә кирәк: ике сузык арасында (дөресрәге, *у* яки *ү* дән соң икенче иҗек башында) барлыкка килгән аваз шул *w* ярым сузыгы булыр (мәсәлән: *у+а=уwа*). Аннары шул авазның үзен башка төрле сүзләр эчендә дә әйтә башларга кирәк: *таwыш* (язылышта *«тавыш»*), *таwы* (*«тавы»*), *дәwер* (*«дәвер»*), *wатан* (*«ватан»*), *wәкил* (*«вәкил»*).

Ягъни *w* авазын әйткәндә, иреннәр бер-берсенә тимиләр – һава шул аралыктан һичнинди тоткарлыксыз үтеп китә, *б* ны әйткәндә – иреннәр бер-берсенә, *в* ны әйткәндә, аскы ирен өске тешләргә тия.

5. *Һ* авазын *х* белән, *қ, ғ, ң* авазларын *к, г, н* белән алыштырып сөйләү ялгышларыннан арыныр өчен, ул авазларның ясалыш үзенчәлекләрен ныклап үзләштерергә кирәк.

*Һ* авазын әйткәндә, һава тамак төбеннән һичнинди диярлек тоткарлыксыз үтә, мәсәлән: *шәһәр, һаwа, даһи.* Татарча *х* (рус теленнән кергән сүзләрдәге түгел) авазын әйткәндә исә, телнең арткы өлеше арткы йомшак аңкауга якынлашып, анда тар гына аралык барлыкка килә, һәм һава, шуннан өрелеп, кече телне авыз куышлыгына таба этәреп, ышкылып чыга, мәсәлән: *хикәйә, хуҗа, бәхәс.*

*Ғ* авазының ясалышы да шундый ук үзенчәлеккә якын, ләкин *ғ* – яңгырау аваз, мәсәлән: *ағым, иғлан, иғтибар, чаған, кәғәз.*

*Ғ* авазын барлыкка китергән сөйләү әгъзалары – телнең арткы өлеше һәм кече тел бер-берсе белән йомылып китсә, үзенчәлекле бер шартлаулы аваз – *ғ* авазының саңгырау пары *қ* әйтелә, мәсәлән: *қармақ, қәрдәш, диққәт.*

*Қ, ғ* һәм татарча *х* авазларының әйтелеш урыны, шул рәвешчә, авыз куышлыгының арткырак өлешендә булса, *к, г* һәм алынма сүзләрдәге русча нечкә *х* авазларыныкы – алгырак өлешендә; ягъни *к, г* һәм русча нечкә *х* (русча калын *х* нигездә татарча *х* ның калын варианты кебек үк) авазларын әйткәндә, тел өстенең урта өлеше алгы йомшак аңкауга (йомшак аңкауның каты аңкау белән тоташкан урынына) күтәрелә, мәсәлән: *чәчәк, кәрәз, Камал, шкаф, гүзәл, газон, химия.* Ясалыш урыннары башка булгач, ул авазларның ишетелешләре дә башкача.

*Ң* авазы телнең арткы өлеше кече телгә (калын варианттагы *ң*) яки телнең урта өлеше алгы йомшак аңкауга (нечкә варианттагы *ң*) тиеп йомылу һәм һаваның берникадәресе борын куышлыгыннан чыгу белән ясала, мәсәлән: *таң, ыңғырчак, иң, иңсә. Н* авазын әйткәндә исә, тел өстенең алгы өлеше өске теш казналарына тия, мәсәлән: *ындыр, нигез, нур.* Ягъни биредә төп аерма шунда, беренчедән, *ң* авазын әйткәндә, телнең арткы өлеше яки уртасы хәрәкәт итсә, *н* ны әйткәндә, телнең очы хәрәкәт итә; икенчедән, *ң* ны әйтүдә йомшак аңкау катнашса, *н* ны әйтүдә өске теш казналары катнаша.

6. Теге яки бу аваз күршелегендә булуга карап, тартыкларның кайберләре билгеле фонетик шартларда төрле үзгәрешләр кичерәләр. Ләкин аларның үзгәрешләре, сузыклардагы шикелле, башлыча бер ритмик басым астында әйтелә торган сүзләр аралыгында гына түгел, бәлки бер

ритмик басым белән әйтелмәгән, бер ритмик төркем эченә кермәгән, ләкин җөмлә эчендә үзара янәшә торган сүзләр аралыгында да булырга мөмкин. Тартыклар әйтелешендәге төп үзгәрешләр түбәндәгеләр:

1) Саңгырау тартык алдында килгән *з* авазы *с* булып әйтелә: *тиз кил → тис‿кил, йөз сум → йөс‿сум, ққаз қанаты → қас‿қанаты, тоз → тоссы*$^{о}$*з.*

2) Беренче сүз *қ, к, п* авазларына бетеп, икенче сүз сузыктан яки *р* тартыгыннан башланса, *қ, к, п* тартыклары яңгыраулаша – *ғ, г, б* булып әйтелә: *китап ала → китаб‿ала, ақ алйапқыч → ағ‿алйапқыч, бик иртә → биг‿иртә, ақ роза →ағ‿роза, биек рәшәткә→ биег‿рәшәткә, Хатип абый → Хатиб‿абый;* шулай ук: *халықара → халығара. Қ, к, п* авазларының мондый фонетик шартларда яңгыраулашмавы бик сирәк вакытта, мәсәлән, тулы стильдә сөйләгәндә, шул авазлар кергән сүзне аерымлап әйтү очрагында гына булырга мөмкин. Мәсәлән: *Спектакльне бик тырышып, б и к о з а қ әзерләдек.*

3) Беренче сүз *к* авазына бетеп, икенчесе *қ* белән башланса, *к* авазы *қ* булып әйтелә (ягъни: *кқ → ққ*)*: бик қызық → биқ‿қызық, биек қойма → биеқ‿қойма, киек қаз → киеқ‿қаз.*

Ләкин калын варианттагы *к* авазына беткән сүзләрдән соң килгән кисәкчә яки кушымчаларда *қ* авазы, киресенчә, *к* белән алышына: *әле бу парк кына* (*парк‿қына* яки *парқ‿қына* түгел), *паркка* (*парққа* яки *парққа* түгел).

4) Беренче сүз *қ* авазына бетеп, икенчесе *к* белән башланса, *қ* авазы *к* булып әйтелә (ягъни: *қк → кк*): *ақ күгәрчен → ак̎‿күгәрчен,* ақ *күмәч → ак̎‿күмәч, озақ килде → озак̎‿килде.*

5) Беренче сүз *қ* авазына бетеп, икенчесе *г* белән башланса, *қ* авазы *к* булып әйтелә (ягъни: *қг → кг*)*: қыйақ гөл → қыйак‿гөл.*

6) Беренче сүз *к* авазына бетеп, икенчесе *ғ* белән башланса, *к* авазы берникадәр яңгыраулаша – *ғ* ға якын әйтелә (ягъни: *кғ → к*$^{ғ}$*ғ*)*: бик ғәҗәп → бик*$^{ғ}$*‿ғәҗәп, бик ғәйрәтле → бик*$^{ғ}$*‿ғәйрәтле.*

7) Беренче сүз нечкә *к* авазына бетеп, икенчесе яңгырау *җ, ж, л, м, н, w, й* яки өрелмәле саңгырау *с, ф, х, һ, ч, ш* авазларының берәрсе белән башланса, *к* авазы шартлаулы үзенчәлеген берникадәр югалта (нечкә *г* гә якын төсмердә әйтелә, ягъни: *к'җ → к*$^{г}$*'җ,* һ.б.): *бик җайлы → бик*$^{г}$*'‿җайлы, ник йырақ → ник*$^{г}$*'‿йырақ, тизрәк сөйлә → тизрәк*$^{г}$*'‿сөйлә.*

8) Беренче сүз *қ* авазына бетеп, икенчесе *х* яки *ш* белән башланса, *қ* авазы *х* га якын әйтелә (ягъни: *қх → қ*$^{х}$*х, қш → қ*$^{х}$*ш*)*: ақ халат → ақ*$^{х}$‿*халат, ақ шар → ақ*$^{х}$‿*шар.*

9) *Ғ, г, қ, к* авазлары алдыннан килгән *н* тартыгы *ң* булып әйтелә (ягъни: *нг → ңг, нғ → ңғ, нк → ңк, нқ → ңқ*): *унға тула → уң"ға тула, ун көнгә килгән → уң көң'гә килгән.*

10) *Б* яки *м* авазы алдыннан килгән *н* тартыгы *м* булып әйтелә (ягъни: *нб → мб, нм → мм*)*: унбер → умбер, ун минут → ум‿минут.*

11) *Н, ң* авазларыннан соң килгән *л* тартыгы *н* булып түгел, *л* килеш, ягъни ничек язылса – шулай әйтелә: *аң – аңлы* (аңлы кеше), *утын – утынлық, дулқын – дулқынлану, бөтенләй* (*аңны, утынның, дулқыннану, бөтеннәй* түгел).

**Рус теленнән яки аның аша башка телләрдән кергән сүзләр әйтелеше.** Рус теленнән яки аның аша башка телләрдән кергән сүзләр әйтелешләре ягыннан төп ике төргә бүленәләр:

1) сөйләү теле аша (башлыча, Октябрь инкыйлабына кадәр) кергән сүзләр;

2) язма тел аша (башлыча, Октябрь инкыйлабыннан соң) кергән сүзләр.

Беренче төр сүзләр фонетик-морфологик яктан татар әдәби теленә ничек үзләштерелеп кабул ителгән булсалар, шулай әйтеләләр. Мәсәлән: *өстәл* (стол), *самавыр* (самовар), *карават* (кровать), *эшләпә* (шляпа), *эскәтер* (скатерть), *кәбестә* (капуста).

Икенче төр сүзләр үзләренең тамыр һәм нигез өлешләрендә рус әдәби әйтелешендәгечә әйтеләләр: *револ*$^{ь}$*уцыйа* (революция), *трактыр̆* (трактор), *реактиф* (реактив) һ.б. Мондый сүзләрнең, татар әдәби теле фонетик-морфологик төзелешенә туры китерелеп, бары тик кушымча яки суффикслары гына үзгәртелергә мөмкин: *кукуруз* (кукуруза), *секунт* (секунда), *минут* (минута), *электр* (электричество), *министрлык,* (министерство), *коллектифлашу* (коллективизация) һ.б.

Рус әдәби әйтелешендәгечә кабул ителгән сүзләрдә кайбер авазларны татар телендәге шуңа охшашлы авазлар белән бутамауга игътибар итәргә кирәк. Мәсәлән, *о, ы, э* (*е*) хәрефләре белән бирелгән сузыклар татар әдәби телендә тар әйтелешле (*ŏчқын, ŏчрақ, тĕрĕкөмĕш*)*,* рус телендә – киң әйтелешле (*кино, эстетика, поэма, музыка*)*;* татар әдәби телендәге өрелмәле (ике сузык арасына туры килгән) *б̊* – ике ирен

арасы белән (*киб̊ән, саб̊ан, суб̊ашы̆*), русчадагы *в* аскы ирен һәм өске теш арасы белән әйтелә (*вагон, противогаз, ванна*). Рус орфоэпиясендәгечә кабул ителгән сүзләрне дөрес әйтү өчен, рус теленең башка төрле авазларын, мәсәлән, *и* төсмерле нечкә тартыкларны (*ль, нь, рь, тъ* һ.б., мәсәлән: *роль, менᵇу* «меню», *секретарь, промышленность*), *ц, щ* аффрикатларын (*цирк, щи, борщ*), янәшә тартыкларны (*штык, стандарт, психология, аттракцион, ксилофон*) һ.б. да әйтә белергә, гомумән, рус теленең үзен яхшы белергә кирәк. Шуның белән бергә, татар теленең үз сүзләрен һәм татарчалашкан алынма сүзләрне башка тел акценты белән (мәсәлән, *шәһәр, һәм, wақыт, Рәwил, Рөстәм, Җәмилә* урынына *шәхәр, хәм, вакыт, Равиль, Рустем, Джамиля* яки *Замиля* дип) әйтергә ярамаганын да искәртергә кирәк.

**Әйтелешләре белән язылышлары арасында зур аерма булган сүзләр.** Түбәндә бертөрле аваз хәрефләре белән язылып, икенче төрле укыла торган сүзләрнең берничәсе китерелә. Язылышлары белән әйтелешләре арасындагы аерма билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнмәгәнлектән, андый сүзләрнең дөрес әйтелешләрен турыдан-туры истә тотарга, язылышлары белән бутамаска кирәк:

*аwу* «аву»
*аwыз* «авыз»
*а*wыл «авыл»
*аwыр* «авыр»
*Ағидел* «Агыйдел»
*баwыр* «бавыр»
*баwырсақ* «бавырсак»
*wаба* «ваба»
*Wағиз* «Вагыйз»
*wазыйфа* «вазифа»
*wайымсыз* «ваемсыз»
*wақ* «вак»
*wақиғә* «вакыйга»
*wақыт* «вакыт»
*wалчық* «валчык»
*wасиат* «васиять»
*wатан* «ватан»
*Wахит* «Вахит»
*Wафа* «Вафа»
*wатық* «ватык»
*wәғдә* «вәгъдә»
*wәйран* «вәйран»
*wәкил* «вәкил»
*Wәли* «Вәли»
*Wәсим* «Вәсим»
*wәсwәсә* «вәсвәсә»
*wәхши* «вәхши»
*ғәдел* «гадел»
*ғәдәт* «гадәт»
*ғәйеп* «гаеп»
*ғәйбәт* «гайбәт»
*ғәйрәт* «гайрәт»
*ғәләмәт* «галәмәт»
*ғәмсез* «гамьсез»

*гәмәл* «гамәл»
*гәнимәт* «ганимәт»
*гәрип* «гарип»
*гәрлек* «гарьлек»
*гәрәп* «гарәп»
*гаскәр* «гаскәр»
*гашиқ* «гашыйк»
*гайәт* «гаять»
*гәжҫәп* «гаҗәп»
*гөзер* «гозер»
*гөмер* «гомер»
*гөреф* «гореф»
*гибарә* «гыйбарә»
*гибарәт* «гыйбарәт»
*гибрәт* «гыйбрәт»
*гилем* «гыйлем»
*гилми* «гыйльми»
*даwыл* «давыл»
*дәwа* «дәва»
*дәwам* «дәвам»
*дәwер* «дәвер»
*дәгwа* «дәгъва
*зәгиф* «зәгыйфь»
*игәнә* «иганә»
*иглан* «игълан»
*игтибар* «игътибар»
*ижҫтимаги* «иҗтимагый»
*қәбер* «кабер»
*қәбилә* «кабилә»
*қаwық* «кавык»
*қаwын* «кавын»
*қаwышу* «кавышу»
*қагидә* «кагыйдә»
*қәдер* «кадер»
*қәдәр* «кадәр»
*қайық* «каек»
*қәләм* «каләм»
*қәнәгәт* «канәгать»
*қәнәфер* «канәфер»
*қәрдәш* «кардәш»
*қәтги* «катгый»
*кигәwен* «кигәвен»
*кәwеш* «кәвеш»
*кәгәз* «кәгазь»
*кәрwан* «кәрван»
*маwыгу* «мавыгу»
*мәгкүл* «мәгъкуль»
*мәқәл* «мәкаль»
*мәқәлә* «мәкалә»
*мәнфәгәт* «мәнфәгать»
*мөгамәлә* «мөгамәлә»
мөрәжәгәт «мөрәҗәгать»
*мөстәкил* «мөстәкыйль»
*нәқес* «нәкыс»
*ойық* «оек»
*пәрwайсыз* «пәрвайсыз»
*пәрәwез* «пәрәвез»
*рисwай* «рисвай»
*Рифгәт* «Рифгать»
*рәwеш* «рәвеш»
*саwу* «саву»
*саwыгу* «савыгу»
*саwыт* «савыт»
*самаwыр* «самовар»
*эскәмиә* «скамья»
*сәгәт* «сәгать»
*сәнгәт* «сәнгать»
*Сәрwәр* «Сәрвәр»
*табигәт* «табигать»
*табиги* «табигый»
*таwық* «тавык»
*таwыш* «тавыш»

*тәқәт* «тәкать»
*Тәлғәт* «Тәлгать»
*тәwәккәл* «тәвәккәл»
*тәнқит* «тәнкыйть»
*фиғел* «фигыль»
*фәқәт* «фәкать»
*фәқир* «фәкыйрь»
*Фәрwәз* «Фәрвәз»
*хайwап* «хайван»
*хәwеф* «хәвеф»
*шағир* «шагыйрь»
*шиғер* «шигырь»
*шөғел* «шөгыль»
*йуғисә* «югыйсә»
*йә әле* «я әле»
*йаwу* «яву»
*йаwыз* «явыз»
*йәғни* «ягъни»
*йәдәч* «ядәч»
*йәисә* «яисә»
*йалwару* «ялвару»
*йалтыраwық* «ялтыравык»
*йәм* «ямь»
*йәмшәйү* «ямьшәю»
*йәм-йәшел* «ямь-яшел»
*йәнчү* «яньчү»
*йәнә* «янә»
*йәнәсе* «янәсе»
*йәнәшә* «янәшә»
*йәп-йәш* «япь-яшь»
*Йәсәwи* «Ясәви»
*йәтим* «ятим»
*йәшел* «яшел»
*йәшен* «яшен»
*йәшерү* «яшерү»
*йәшкелт* «яшькелт»
*йәш* «яшь»
*йәшә* «яшә»
*әwен* «әвен»
*әwерелү* «әверелү»
*әwернә* «әвернә»
*әwеш-тәwеш* «әвеш-тәвеш»
*әwәлә* «әвәлә»
*әwәрә булу* «әвәрә булу»
*әкиәт* «әкият»
*Әнwәр* «Әнвәр»
*хәл-әхwәл* «хәл-әхвәл»
*әwwәл* «әүвәл»
*әһәмиәт* «әһәмият»
*җанwар* «җанвар»
*җинайәт* «җинаять»
*җәмғиәт* «җәмгыять»
*җәмәғәт* «җәмәгать»
*һаwа* «һава»
*һәwәскәр* «һәвәскәр»

ӘДӘБИЯТ


Вещикова И.А. Орфоэпия: основы теории и прикладные аспекты. М.: Наука, 2007. 345 с.

Заляй Л.З. Основы татарской орфоэпии // Изв. АПН РСФСР. М., 1952. Вып. 40. С. 84–95.

Курбатов Х. Орфоэпия // Современный татарский литературный язык. М.: Наука, 1969. С. 100–110.

Хангилдин В.Н. Татар теленең орфоэпик нормалары мәсьәләсе // Совет мәктәбе. 1941.№ 5. Б. 15−17.

Курбатов Х. Неполный стиль произношения: сценическое (драматургическое) произношение // Курбатов Х. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М.: Наука, 1978. С. 141−153.

Прядильникова, О.В. Региональные особенности произносительной системы современного русского языка в Республике Башкортостан: дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2010. 214 с.

Җәләй Л. Татар теленең орфоэпик нигезләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1953. 72 б.

Курбатов Х. Татар теленең әдәби әйтелеше (Орфоэпия) // Совет мәктәбе. 1962. № 2. Б. 25–31.

Курбатов Х. Сөйләү теле үзенчәлекләре (Орфоэпия) // Татар теле һәм әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 2 китап. Б. 191−208.

Курбатов Х. Орфоэпия // Хәзерге татар әдәби теле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. Б. 133–153.

# 7. МОРФЕМИКА

Татар грамматикасында **морфемика** дигән бүлек беренче мәртәбә 1993 елда русча чыккан академик грамматика өчен эшләнде. Аңа кадәр бу тема аерып алып эшкәртелмәгән иде, шуңа күрә аның татарча терминнары да утырып җитмәгән әле.

Морфемика – бер яктан сүзнең мәгънәле кисәге булган морфемалар җыелмасы, икенче яктан, морфемаларның гомуми үзенчәлекләре турындагы фән. Морфемаларны, үз мәнфәгатьләреннән чыгып, морфонология, сүзьясалышы, морфология һәм синтаксис бүлекләре дә өйрәнә.

Морфема турындагы гомуми өйрәтмә буларак, морфемика ул сүз, сүзформа, морфема һәм морф төшенчәләрен билгели һәм конкрет шулар белән эш итә.

Тел берәмлеге буларак, сүз ул тиешле авазлар комплексының (кайчакта бер авазның) билгеле бер төшенчә белән кушылмасы. Сүз сүзлекләрдә теркәлә һәм тел белүченең исендә кала. Тел берәмлеге булган сүз, сөйләмгә килеп кергәч, күп төрле формаларны алып, сүзформа дип атала башлый. Сүзформа сөйләмдә сүзләрне үзара бәйләүче һәм модаль мәгънә белдерүче формаларны ала (анда нуль форма да булырга мөмкин). Мәсәлән, *шәһәр* – сүз, *шәһәргә, шәһәрнең, шәһәрне, шәһәрнеке, шәһәрдәге* һ.б. – сүзформа булалар. *Шәһәр бакчасы* дигәндәге *шәһәр* сүзе дә – сүзформа (төгәлрәк әйткәндә, нуль формалы сүзформа).

Сүзформадагы иң кечкенә мәгънәле кисәкне **морф** дип атыйлар. Мәсәлән, *урманнардан* сүзформасында *урман, -нар, -дан* морфлары бар.

Төрле сүзформада кулланылган бер исемдәге, бер мәгънәдәге һәм бер-берсенә якын яңгырашлы морфлар берләшмәсе **морфема** дип атала. Мәсәлән, *урманга, кулгә, ташка, тешкә* сүзформаларындагы *-га/-гә/-ка/-кә* морфлары бер морфемага берләшәләр, һәм бу морфема юнәлеш килеше морфемасы дип атала.

Шулай итеп, морфемика тел берәмлекләреннән сүз һәм морфема белән, сөйләм берәмлекләреннән сүзформа һәм морф белән эш итә.

Шулай итеп, сүз сөйләм агымында сүзформа буларак катнаша, сөйләмдә мәгънәле кисәк буларак аерылып тора. Фонетик планда ул ике яктан да пауза һәм үзенең басымы белән аерыла. Бу хәл сүзформа үзе генә аерым синтагма булып килгәндә күзәтелә.

Сүзформа башка сүзформа белән бергә бер синтагма эченә керсә, ул фонетик яктан пауза һәм үз басымы белән аерылып тормый, чөнки синтагмага кергән берничә сүзформа бер синтагматик басымга карый, пауза да ике яктан да булмый. Мәсәлән, *Алар күрше авылга таба киттеләр* дигән сөйләм барышында фонетик яктан ике сүзформа гына аерылып тора: *алар* һәм *киттеләр,* чөнки болар икесе дә аерым синтагма төзегәннәр. Ә *күрше* һәм *авылга таба* сүзформалары икесе бергә бер синтагма (интонацион буын) эчендә торалар, шуңа күрә алар бары мәгънә ягыннан гына аерылалар, фонетик яктан икесе бергә кушылып әйтеләләр. *Күрше авылга таба* бер синтагма буларак кушылып әйтелсә дә, телне белүче кеше анда өч сүз аера һәм орфографик яктан ул синтагманы өч сүз итеп яза. Бер синтагма эченә кергән бу өч сүз ике сүзформа итеп танылa: *күрше* һәм *авылга таба,* чөнки татар телендә бәйлекләр, кушымчалар кебек үк, сөйләмдә алдагы сүзнең формасын тәшкил итеп, аннан сүзформа ясыйлар.

Сөйләм барышында сүзформаны дөрес аеру өчен, түбәндәгечә тәҗрибә ясап карарга була. Татар сөйләменең сүзформасы, русчадагы кебек үк, ике үзенчәлек белән характерлана: 1) төрле урынга күчеп йөри алу һәм 2) эченә башка сүзформа кертмәү белән. Болар – бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән үзенчәлекләр. Моны мисалда тәҗрибә юлы белән тикшереп карыйк. *Безнең авыл зур елга буена утырган* җөмләсендә биш сүзформа аерып була: *безнең, авыл, зур, елга буена, утырган.* Боларның һәрберсе сөйләм барышында мәгънәле кисәк булып аңлашылып тора, монда *авыл, елга буена, утырган* сүзформалары күчеп йөри алалар, ягъни урынны үзләренә үзләре сайлый алалар: *зур елга буена безнең авыл утырган; зур елга буена утырган безнең авыл* һ.б. Мондагы аергыч булып килгән сүзформалар (*безнең, зур*) үзләре генә, ягъни аерылмыштан башка күчеп йөри алмыйлар, үзләренә үзләре урын сайлый алмыйлар, һәм аергыч белән аерылмыш арасына башка сүзформа керә дә алмый.

Бер үк сүзгә караган берничә аергыч кына үзара урын сайлый ала: *Зур матур талгын елга – матур зур талгын елга – талгын зур матур елга.* Бу очракта *матур елга* аергычы һәм аерылмышы арасына башка сүзформа да килеп керә ала. Шуннан чыгып аергычларны, гомуми кагыйдәгә бик нык туры килмәсәләр дә, сүзформа дип танырга тиеш булабыз.

Әле генә китерелгән җөмләдәге *елга буена* сүзләре икесе бер сүзформа төзи, чөнки, беренчедән, *буена* сүзе лексик яктан мәгънәле кисәк түгел, ул алдагы сүзнең лексик мәгънәсенә грамматик мәгънә генә өсти; икенчедән, *елга* сүзе *буена* сүзеннән башка, *буена* сүзе *елга* сүзеннән башка күчеп йөри алмый; өченчедән *елга* һәм *буена* сүзләре арасына башка сүзформа куеп булмый.

Димәк, сүзформаның чикләрен тәҗрибә юлы белән дә билгеләп була икән.

Рус телендә ярдәмлек сүз төркемнәре һәр очракта да мөстәкыйль сүзформа төзиләр. Татарчада төрлечәрәк. Мәсәлән, русчада *Дом стоит на горе* җөмләсендә *на горе* бер сүзформага оешмый, икесе ике сүзформа булып килә, чөнки хәтта *на* предлогы да үзе генә күчә ала, *на* һәм *горе* арасына башка сүз кертеп куеп була: *на высокой горе, на очень большой горе* һ.б. Русчадагы башка ярдәмлек сүзләрнең мөстәкыйль сүзформа төзүләрен дә шул юл белән исбатлыйлар. Болардан тыш русчада башка төр аналитик сүзләрнең өлешләре дә күчү иреге белән һәм араларына башка сүзләр үткәрә алу белән характерланалар. Мәсәлән, *буду писать, давай скажем, в комнате, о нем, на балконе, по реке, при тебе* сүзләрен сөйләм барышында болай үзгәртеп куллана алабыз: *буду я писать, давайте мы вам скажем, в большой светлой комнате* һ.б. Күренә ки, русча ярдәмлек сүзләр мөстәкыйль сүзформа төзиләр.

Татарча эш башкачарак тора. Теркәгечләр сүзформа төзи алалар, чөнки алар башка сүзформасын тәшкил итмиләр. *Мин килдем, чөнки сагындым* җөмләсендә *чөнки* теркәгече *сагындым* сүзенең формасын тәшкил итми, алар арасына башка сүз керә ала: *чөнки сезне сагындым.* Барлык теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр белән шул рәвештә тәҗрибә үткәреп була, димәк, алар мөстәкыйль сүзформа төзиләр.

Кисәкчәләрнең бер төре сүзформа төзи, бер төре төземи. Сүз алды кисәкчәләре *тик, бары, ни, фәкать, нәкъ, һич, әллә, да/дә/та/тә* (*һәм* мәгънәсенә якын булганда), *хәтта, соң,* теркәгечләр кебек үк, сүзформа таләпләренә җавап бирәләр.

Кисәкчәләрнең башка төркемнәре – сыйфаттагы артыклык дәрәҗәсен белдерүчеләре (*иң-, чем-, дөм-, ап-, зәп-, кап-, кып-, нәп-, неп-, оп-, сап-, сөп-, тап-, түм-, үтә, чалт, җете, тома, шыр* һ.б.), шулай ук сүз ахыры кисәкчәләре (*гына/генә/кына/кенә, мы/ме, мыни/мени, бит, ич, дыр/дер/тыр/тер, чы/че, сана/сәнә, инде, ук/үк, ләбаса/лабаса, ла/лә, -са да, соң*) сүзформа таләпләренә җавап бирмиләр, башка сүзформаны төзүдә генә катнашалар, ягъни башка сүзләрнең модаль формаларын барлыкка китерәләр.

И с к ә р м ә . *Әллә, дыр/дер/тыр/тер* кисәкчәләре сүзьясагыч булып килгәндә дә (*әллә кем, кемдер, әллә нәрсә, нәрсәдер, әллә ничек, ничектер, әллә нинди, ниндидер, әллә кайда, кайдадыр*) аерым сүзформа төземиләр, алмашлыкның сүзформасын төзүдә генә катнашалар.

Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, кушымчалар кебек үк, мөстәкыйль сүзформа буларак кулланыла алмыйлар, үз алдындагы сүзформаны төзүдә генә катнашалар, чөнки алар, беренчедән, үзләре генә урын сайлый алмыйлар; икенчедән, бәйлек яки бәйлек сүз белән алдагы сүз арасына башка сүз килеп керә алмый; өченчедән, үз алдындагы сүз белән бик тыгыз мөнәсәбәткә керәләр һәм шуңа күрә төп сүз аны үз яныннан җибәрми, дүртенчедән, интонацион яктан үз хуҗасы белән бер синтагма (интонацион буын) төзиләр, бишенчедән, төп сүзнең килеш кушымчаларын да үзләренә алып, төп сүзнең сүзформасы эчендә калалар.

Татар телендә ярдәмче фигыльләр дә мөстәкыйль сүзформа төземиләр, төп сүзнең сүзформасына керәләр: *укый ала, укырга тора, укый торгандыр, укымакчы булды, укыйсым калган, укый иде, укыган иде, укый торган булды, укыячак иде, язып атты, әйтеп салды, егыла язды, өлгереп килә, язып тора, укып чыкты.*

Татар телендә кайбер хәбәрлек һәм модаль сүзләр дә (*юк, бар, түгел, бугай, икән*), мөстәкыйль сүзформа төземичә, башка сүзформа эчендә генә киләләр: *барасым бар, барасым юк, төн түгел, бармадым түгел, укый бугай, укый икән.*

И с к ә р м ә 1 . Кайбер ярдәмлек фигыльләр мөстәкыйль лексик мәгънәле фигыльләрдән торалар. Мәсәлән, *салды* фигыле *әйтеп салды* тезмәсендә грамматик мәгънә белдерә һәм алдагы сүзнең сүзформасына керә; *ясап салды* тезмәсендә ул үзенең лексик мәгънәсендә кулланыла: *әйберне ясап, савытка салды.* Бу очракта *салды* фигыле үзе мөстәкыйль сүзформа булып килә.

И с к ә р м ә 2 . Кушма аналитик сүз бер генә сүзформа төзи: *үзаң, ата-ана, каен җиләге, ду килә, коты очты, акылга килде* һ.б.

Агглютинатив телләрдә сүзформаның структур төзелеше тамырга сүз ясаучы һәм грамматик мәгънә белдерүче кушымчаларның, бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең, кайбер кисәкчәләрнең бер-бер артлы тезелеп китүләре белән характерлана: *болынлыккача – болын-лык-кача; болынлыкка чаклы, укытучыдагысы белән – укы-т-у-чы-да-гы-сы белән* һ.б.

Охшаш сүзформаларны үзара чагыштырып карау юлы белән андагы иң кечкенә мәгънәле кисәкләрне – морфларны аерып була: *укытучы, укучы, укыту, укыган, укыткан, укыды, укыр, укытыр* һ.б. сүзформалардан түбәндәге иң кечкенә мәгънәле кисәкләрне, ягъни морфларны аера алабыз: *укы, -т, -у, -чы, -ган, -ды, -р, -ыр.*

Сүзформада бер генә морф (*өй, ук, ат, кеше* һ.б.) һәм берничә морф (*укны, өйдә, атларның, кешедәгесенә*) булырга мөмкин.

Татарча морфлар өч төрле булалар: *тамыр, кушымча* (аффикс), *ярдәмлек.*

Тамыр лексик мәгънәне яисә лексик мәгънәнең бер өлешен белдерүе белән башка морфлардан аерылып тора. Мәсәлән, *яздым* сүзформасында тамыр *-яз,* чөнки ул лексик мәгънәне белдерә, *ташчыны* сүзформасында тамыр – *таш,* чөнки нәкъ менә шушы морф лексик мәгънәнең төп өлешен белдерә, *ташчы* – нигез яки икенчел тамыр дип йөртелә, һәм анда лексик мәгънә тулысынча бирелә.

Тамыр морф һәрбер сүзформада була, ансыз сүзформа сөйләмгә керә алмый, чөнки ул гына лексик төшенчә бирә ала. Сүздә лексик мәгънә булмаса, аны сүзформа дип әйтеп булмый. Мәсәлән, *белән* сүзендә лексик мәгънә юк, грамматик мәгънә генә бар, шуңа күрә ул үзе генә сүзформа төземи, башка сүзформаның формасын гына тәшкил итә: *әти белән.*

Димәк, тамыр лексик мәгънә белдергәндә генә аерым сүзформага нигез була ала.

Кушымча морф (аффикс) һәрчак грамматик мәгънә белдерә. Грамматик мәгънә сүз ясау һәм төрле мөнәсәбәт белдерүдән туа. Төрле мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны, форма яисә төр ясаучылар дип, сүз ясаучыларга каршы куялар һәм төрләндергечләр дип атыйлар. Шулай итеп, башта кушымчаларны ике зур төркемгә аералар: ясагычлар һәм төрләндергечләр. Төрләндергечләрне (форма ясагычларны) тагын икегә аералар: сүз бәйләүчеләр, модаль мәгънә белдерүчеләр.

Сүз бәйләүчеләре төшенчәләр арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдерә һәм, төшенчәләр сүз белән бирелгәнлектән, алар сүзләрне сөйләмдә үзара бәйләү функциясен дә үтиләр.

Модаль мәгънә белдерү – ул сөйләгәндә сөйләүченең чынбарлыкка (тыңлаучыга, үзенә, хәбәр ителә торган мәгънәгә, аның формасына, сөйләм вәзгыятенә) төрле мөнәсәбәттә торуын белдерү дигән сүз. Сөйләүче гадәттә аерым сүз белән бирелми, шуңа күрә модаль мәгънә белдерүче кушымчалар сүз бәйләүче була алмыйлар.

Төрки телләрдә сүзләрне үзара бәйләүче кайбер кушымчаларны, кая куярга белмәгәнлектән, ясагычларга кертеп йөртү гадәте дә бар. Мәсәлән, *атлы кеше* тезмәсендә *-лы* кушымчасы ике исемне бер-берсенә бәйли, шул яктан ул килеш кушымчасы төркеменә керергә тиеш. Ләкин русча моңа охшаган килеш булмаганга, аны сыйфат ясаучы морф итеп таныганнар. Тагын бер мисал, *-дай* кушымчасы *таудай танк* тезмәсендә ике исемне бәйли, ягъни ике төшенчә арасында мөнәсәбәт белдерә, димәк, ул да килешләр системасында каралырга тиеш иде. Ләкин русчада моңа охшаш килешләр булмагач, аны рәвеш ясаучыларга керткәннәр. Бу төр кушымчалар аерым өйрәнүне сорыйлар, чөнки алар бер очракта ясагыч, икенче очракта бәйләгеч ролен үтәргә мөмкиннәр. Хәзергә без андый кушымчаларны ясагычлар белән төрләндергечләр арасында күрсәтү белән чикләнәбез.

Татар телендә кушымча морфлар төркемләнүен схемада күрсәтик:



Гомуми тел гыйлемендә кушымчаларны, тамырдан соң килә торганнарын **суффикс** дип, тамыр алдыннан килә торганнарын **префикс** дип, кушылып килгән тамырлар арасында килә торганнарын **интерфикс** (*вод-о-провод*) дип, сүзнең иң соңында килә торганнарын **флексия** (окончание) дип аерып атап йөртәләр, боларның барысын бергә җыеп **аффикс** диләр. Мондый бүленешләрне агглютинатив телләргә кертеп бетереп булмый, чөнки боларда сүз төзелеше башкачарак.

Татарча сүзформаларда префикс дип аталырлык кушымча морфлар сыйфатларда артыклык дәрәҗәсе белдергәндә барлыкка килә: *мап-матур, ап-ачык, кап-кара, зәп-зәңгәр, дөм-сукыр, сап-сары, тап-тар* һ.б. Алынма сүзләр белән флектив телләрдә префикслар да кулланылырга мөмкин: *ультракыска, ультрауң, антикисәкчә* һ.б.

Искәрмә. Кайбер тикшеренүчеләр, *алып кил* сүзенең *апкил* формасында әйтелешен күз алдында тотып, фигыльдә *ап* дигән префикс морф бар диләр. Ләкин бу орфоэпик чыгарма гына.

Татарча сүзформаларда интерфикс диярлек морфлар да юк. Чыгарма буларак, *яңгыра, мөңрә* сүзләрендәге *г* һәм *ң* авазларын гына интерфикс морфка якынайтучылар күренгәли.

Татарчада аффикстан флексияне, ягъни суффикстан кушымчаны аеруның да кирәге күренми.

Сөйләмдә **нуль кушымча** дигән чараны да аералар һәм аны **нуль морф** дип тә атыйлар. Сүз тел яссылыгында аерым торганда, анда нуль кушымчаның барлыгын белеп булмый. Сөйләмдә исә ул җиңел сизелә. Мәсәлән, *китап* сүзе аерым торганда кушымчасыз, *мин китап укыйм* дип сөйләмгә кертсәң, андагы *китап* сүзформасында төшем килеше мәгънәсендә нуль кушымча – нуль морф бар: *мин китап*(*ны*) *укыйм. Әтисе малае* тезмәсендәге беренче сүзформада нуль кушымча белән иялек килеше мәгънәсе бирелгән.

Нуль кушымчаны башка морфлар белән чагыштырып карап та белеп була. *Китап* сүзен *китапларның* дигән сүзформа белән чагыштырганда, анда берлек саны, баш килеш грамматик мәгънәләре бар, бу мәгънәләр нуль кушымча белән бирелгәннәр. *Яз* сүзен *язмадылар* сүзформасы белән чагыштырсак, анда нуль кушымча ярдәмендә берлек саны, икенче зат, барлык аспекты (*язма* кебек юклык түгел), боеру наклонениесе бирелгән.

Нинди дә булса бер кушымча үзенең функциясен күршесенә тапшырып төшеп калганда да нуль кушымча хасил була. Мәсәлән, *а, ә, ы, э* авазларына беткән сүзләрдә (*бала, кеше*) I һәм II зат тартымын зат кушымчалары гына белдереп, тартым үзе төшеп кала, ягъни нуль кушымчага әйләнә: *бала-м, кеше-м, бала-быз, кеше-без* сүзформаларында тартым мәгънәсе нуль кушымча белән бирелгән. Башка төр авазларга беткән сүзләрдә тартым кушымчасы *-ы* үзе килә: *ат-ы-м, ат-ы-быз, ат-ы-ң, ат-ы-гыз.*

Нуль кушымча тиңдәш кисәкләрне санаганда да (соңгысыннан башкаларында) барлыкка килә. Мәсәлән, *Полк бик күп авыл һәм шәһәрләрне азат итте* җөмләсендә *авыл* сүзформасы нуль кушымчалы, ул *-лар-ны* кушымчаларын алмаштыра.

Нуль кушымча киңрәк мәгънәдә кулланыла торган нуль формага (нуль чарага) карый. Нуль форма дигәндә, ул кушымча мәгънәсен дә һәм башка грамматик чаралар мәгънәләрен дә белдерә ала.

Махсус грамматик хезмәтләрдә нуль кушымча, фонетикадагы нуль фонема кебек үк, хәреф өстенәрәк янәшә куела торган нуль билгесе белән күрсәтелә: *китап°укыды.*

Димәк, авазлар белән бирелгән кушымча булу да мәгънә белдерә, андый кушымча булмау да, ягъни нуль кушымча булу да мәгънә белдерә һәм сүзформа төзи.

Ярдәмлек морфлар, кушымчалар кебек үк, грамматик мәгънә белдерәләр, ләкин тышкы кыяфәтләре белән аерым сүзгә тартымнар, сүзгә ассимиляцияләнеп кушылып китмәгәннәр. Шуңа күрә ярдәмлек морфлар кушма сүзформа ясыйлар.

Кушымчалар кебек үк, ярдәмлек морфлар да ясагыч, төрләндергеч дигән төрләргә бүленә, төрләндергечләре бәйләүчеләргә һәм модаль мәгънә белдерүчеләргә аерыла.

Ясагыч ярдәмлек морфлар яңа сүз ясыйлар: *ду килә, көл итә, хәлдән тайды, тәкъдим кылды, һәлак булды.* Биредә *кил, ит, тай, кыл, бул* фигыльләре, бу очракта ярдәмлек булып килеп, яңа сүз ясауда катнашалар. Бу юл белән ясалган сүзләр сөйләм барышында кушма сүзформа буларак урын алалар.

Төрләндергеч (форма ясагыч) ярдәмлек морфлар икегә бүленәләр:

1) сүз бәйләүчеләр;

2) модаль ярдәмлекләр.

Сүзбәйләгечләргә бәйлекләр һәм бәйлек сүзләрдән торган ярдәмлек морфлар карый: *урманга таба* (*бару*), *әти белән* (*килү*), *әти төсле* (*эшләү*), *әти турында* (*уйлау*), *әти аркасында* (*белү*) сүзформаларында *таба, белән, төсле, турында, аркасында* ярдәмлек морфлары төшенчәләр арасында төрле грамматик мәгънә белдерәләр, шул юл белән сүзләрне үзара бәйлиләр.

Модаль мәгънә белдерүче ярдәмлек морфларга кисәкчәләр, кайбер ярдәмче фигыльләр карый: *килә ала, килергә тора, килгән булган, килгән иде, килде ләбаса, әнием генә, дөм сукыр, үтә ялкау*.

Кушымчалар кебек үк, ярдәмлек морфлар да сүз алды (препозитив), сүз арты (постпозитив) дигән төрләргә бүленәләр: *үтә саран, чалт аяз, урманга таба, килә иде* һ.б.

Нигезгә һәм кушымчага бүленә торган ярдәмлек морфлар **кушма ярдәмлек морф** дип, бүленмәсә, **гади ярдәмлек морф** дип йөртелә. *Урманга таба, синең өчен* сүзформаларында *таба, өчен* ярдәмлек морфлары – гади, *әни аркасында, авыру сәбәпле* сүзформаларында *ар-ка-сы-н-да, сәбәп-ле* ярдәмлек морфлары кушма төргә карый.

Искәрмә. Ярдәмлек морфлар сөйләмдә кушымчалар функциясен башкарсалар да, тел яссылыгында алар **ярдәмлек сүзләр** буларак өйрәнеләләр.

Әйтергә кирәк, нуль кушымча булган кебек үк, нуль ярдәмлекләр дә була. *Ул эшли һәм укый иде* җөмләсендә *эшли* сүзформасында *иде* мәгънәсен белдерүче нуль ярдәмлек бар. Шуңа күрә *эшли* сүзформасын *эшли иде* дип тикшерергә кирәк була.

Морф – сөйләм элементы, ә морфема – тел берәмлеге. Сөйләмдә бер үк мәгънәдә кулланыла һәм фонетик составы бер-берсенә якын булган морфлар, тел яссылыгында алганда, **морфема** дигән гомуми төшенчәгә тупланалар. Мәсәлән, сөйләмдә төрле сүзформаларда кулланыла торган *-дан, -дән, тан, -тән, -нан, -нән* морфлары тел яссылыгында бер морфемага кереп бетәләр. Тел белүченең аңында да болар бер морфема буларак истә калалар, фонетик яктан гына ассимиляциягә биреләләр.

Морфлар кебек үк, морфема да тамыр төрләргә, кушымча төрләргә бүленә. Ләкин тел яссылыгында ярдәмлек морфемалар дип аеру гадәте юк, аларны бу яссылыкта ярдәмлек **сүзләр** дип атыйлар, монда бәйлек һәм бәйлек сүзләр, кисәкчәләр һәм ярдәмлек фигыльләр керә.

Сүз алды (префиксаль) морфемалар сүзьясагычлар (*ультра-, контр-, анти-*) һәм модаль дигән төрләргә (*ап-ак, кап-кара*)

бүленәләр. Сүз арты (суффиксаль, постфиксаль) морфемалары ясагычлар (сүзьясагычлар), төрләндергечләр (форма ясагычлар) дигән төрләргә аерылалар. Төрләндергечләр тагын сүзбәйләгечләр һәм модаль мәгънә белдерүчеләргә бүленәләр. Димәк, телдәге морфемалар сөйләмдәге морфлар кебек төркемләнәләр.

Флектив телләрдән аермалы буларак, тамыр морфемалар бер генә морфлы булалар. Моннан бер генә чыгарма бар: кушымчадагы авазның кире ассимиляциясе нәтиҗәсендә, тамыр морфеманың соңгы авазы үзгәргәндә, тамыр морфеманың ике морфы була: *ак-ты, аг-а* сүзләрендә ике тамыр морф бар (*ак, аг*)*,* бер генә морфема санала. *Күз – күссез* (языла *күзсез*) сүзформасында ике тамыр морф бар, бер генә тамыр морфема бар.

Бер морфема төзү өчен охшаш мәгънәле морфлар аваз составлары буенча да охшаш булырга тиешләр. Мәсәлән, *-лар, -ләр, -нар, -нәр* морфлары аваз составлары буенча бер-берсенә якын, мәгънәләре дә бер үк, димәк, алар бер морфема төзиләр. *Юын, төрен, бизән* сүзформаларындагы *-ын, -ен, -н* морфлары да охшаш тышчалы һәм бер үк мәгънәле, димәк, алар да бер морфемага берләшәләр.

Фонетик яктан охшашлык булмаса, бер үк мәгънә белдерсәләр дә, морфлар бер морфема төземиләр, төрле морфемага керәләр. Мәсәлән, *агыз, уйлат* сүзформаларында *-т* һәм *-ыз* морфлары йөкләтү мәгънәсен белдерү ягыннан бер үк, ләкин авазларда охшашлык юк. Шуңа күрә *-т* морфы *-т* морфемасын, *-ыз* морфы *-ыз* морфемасын бирә.

*Өйрәнмәгәч белми, өйрәнмәгәнгә белми, өйрәнмәгәнлектән белми* тезмәләрендәге беренче сүзформаларда *-гәч, -гәнгә, -гәнлектән* морфлары да, сәбәп мәгънәсен белдерсәләр дә, охшаш формалы булмаганлыктан, бер морфемага тупланмыйлар, аерым морфемалар булалар.

Әгәр дә морфларның мәгънәләре төрле булса, алар бер үк авазлардан торып, бер-берсенә туры килсәләр дә, аерым морфемалар төзиләр: *килче, килгәнче* һәм *тимерче* сүзформаларындагы өч *-чы* морфы телгә дә өч морфема булып күчә. Беренчесен хәтта кисәкчәгә карату гадәте дә бар. Мондый морфемаларны омоним морфемалар дип атыйлар. Шундыйларга тагын мисал. *Яздык, язсак* сүзләрендәге I зат күплек морфемасы *-к, терәк, бизәк* сүзләрендәге сүзьясагыч *-к* морфемасына омоним була. *Тотка* һәм *ташка* сүзләрендәге *-ка* морфемалары да омоним.

Морфемага берләшә торган охшаш морфларның бер-берсеннән аерылып тору сәбәпләре фонетикага кайтып кала: бер морфның икенчесенә фонетик тәэсире нәтиҗәсе булып тора. Мәсәлән, *шул* һәм *шу-ныкы* сүзләрендә *шул* һәм *шу* морфлары, *шулныкы* дигәндә, л авазының уңайлык өчен төшеп калуыннан ясалган. *Үлде* һәм *үтерде* сүзләрендәге *үл* һәм *ү* тамыр морфлары да шул ук әйтү өчен уңайлыктан туган. Бер үк морфеманың мондый вариантлары тарихтан килә, хәзерге фонетик процесс нәтиҗәсе түгел. Флектив телләрдә морфеманың шундый тарихи вариантларын **алломорф** дигән исем белән өйрәнәләр: грекча *allos* ‘башка’ мәгънәсен бирә, димәк, *алломорф* ‘башка морф’ дигән сүз була.

Морфеманың вариантлары хәзерге фонетик процесслар нәтиҗәсендә дә ясала: *урман-нан, таш-тан, кыр-дан* сүзләрендә чыгыш килеше морфемасының өч варианты (өч морфы) бирелгән, бу вариантлар тарихтан калып, хәзер традиция буларак кулланылган вариантлар түгел, хәзерге уңай ассимиляция нәтиҗәсе буларак туганнар. Мондый вариантларны флектив телләрдә алломорф дип атамыйлар, бары **морфның фонетик төрләре** дип кенә йөртәләр.

Шулай итеп флектив телләрдә, шул исәптән рус телендә, алломорфлар һәм морфның фонетик төрләрен аералар, алломорфлар морфонологиядә, морфның фонетик вариантлары фонетикада җентекләп өйрәнелә. Бу аңлашыла да, чөнки флектив телләрдә алломорфлар (морфның борынгыдан килә торган вариантлары) бик еш очрыйлар, һәм аларны аерып алып өйрәнергә дә була. Агглютинатив төзелешкә караган төрки телләрдә, мәсәлән, татар телендә алломорфлар аз күзәтеләләр, шуңа күрә аларны аерым алып өйрәнеп тормыйлар, морфның хәзерге фонетик закончалыкларга нигезләнеп ясалган фонетик төрләре белән бергә карыйлар. Алломорфларны да морфның фонетик вариантларын да морфонологиядә дә морфемикада да өйрәнәләр. Бу да дөрес һәм максатка ярашлы.

Татарчадагы алломорфларга мисаллар: *халык – халк-ым, әче – әч-келт, кызыл – кыз-гылт, озын – оз-аю, мин – ми-нем, үл – ү-тер.* Болар тамыр алломорфлар. Кушымча алломорфлары да була:1) киләчәк заман алломорфлары – -*р-с: ашар-ашамас;* 2) йөкләтү юнәлеше алломорфлары – *-кыз, -кыр, -гер, -гез: ят-кыр, ят-кыз, мен-гер, мен-гез*; 3) иялек килеше алломорфлары – *-ның, -нем, -ем: ата-ның, ми-нем, без-ем*.

Кушымча морфемаларның фонетик төрләре сингармоник ассимиляция нәтиҗәсендә ясалалар: *-лар/-ләр/-нар/-нәр, -быз/-без, -лык/-лек, -чы/-че, -дан/-дән/-тан/-тән/-нан/-нән* һ.б.

Фонетик вариантлар кайбер кисәкчәләрдә дә күзәтеләләр: *мыни/мени, сана/сәнә, да/дә, гына/генә/кына/кенә.*

Татарчада, барлык агглютинатив телләрдәге кебек үк, сүзформалар морфларга, ә сүзләр морфемаларга бик ачык бүленәләр. Хәтта кушма морфемалар да гади морфемаларга җиңел таркалалар, шуңа күрә татарчада кушма морфемаларның чиген билгеләү дә кыенлаша. Ләкин мәгънәдән чыгып, кушмаларны аерып күрсәтергә дә туры килә. Мәсәлән, исем исем белән урын яки вакыт мөнәсәбәтендә торганда, бу мәгънәне *-дагы* кушма морфемасы белдерә: *урмандагы агач, узган елдагы хәл.* Бу кушма морфеманы ике гади морфемага таркатып аңлатып та була: *-да* һәм *-гы; -да* – урын-вакыт килеше кушымчасы, *-гы* – вакыт һәм урын белдерә торган сүзләргә үзе генә дә кушыла һәм исемне исемгә яки рәвешне исемгә бәйли: *узган елгы хәл, түбәнге кат.*

Тагын мисал. *Күрмәгәнлектән белми* тезмәсендә *-лектән* сәбәп белдерүче кушма морфема, ул *-лек* һәм *-тән* дигән гади морфемалардан тора. *-дагы* кушма морфемасының мәгънәсе гади морфемалар мәгънәләре кушылмасына якын, ә *-лектән* морфемасының мәгънәсе *-лек* һәм *-тән* гади морфемалар мәгънәләре кушылмасын хәтерләтми. Биредә ике мәгънәне белдерүче ике морфема кушылып, өченче мәгънәне белдерүче кушма морфема ясалган. Бу – телдәге табигый бер хәл.

Кайбер кушма морфемаларда башлангыч гади морфемалар үзгәрергә дә мөмкин. Мәсәлән, *-ныкы* – кушма морфема, галимнәр уйлаганча, *-ның* һәм *кы* өлешләреннән тора, ләкин беренче гади морфема тарихи үзгәреш кичергән.

Кушма һәм гади морфемалар кушымчаларда гына аерым алып өйрәнелә, тамыр һәм ярдәмлек морфемаларны алай бүлү кабул ителмәгән.

Сүзьясалышында һәм морфологиядә сүзне билгеләү процессында *тамыр* һәм *нигез* аерыла. Тамырны билгеләү кыенлык тудырмый, ләкин нигезне билгеләүдә төрлечә карашлар яшәп килә.

Кайбер грамматик хезмәтләрдә сүзнең соңгы кушымчадан башка өлеше нигез дип йөртелә. Мәсәлән, Н.А. Баскаков, *эшләштеләр* сүзеннән *-ләр* кушымчасын алсаң, күп морфлы нигез кала, ди: *эшләште.*

Аныңча, тагын *-те* кушымчасын алсаң, тагын нигез кала: *эшләш; -ш* кушымчасын алсаң, тагын *эшлә* нигезе кала [Историко-типологическая морфология тюркских языков, 1979, с. 251–259].

Күбрәк очракларда сүзнең нигезе дип тамырга ясагычлар кушылып ясалган өлешен генә алалар. Мәсәлән, *эш* – тамыр, *эшлә* – нигез, *эшләш* – уртаклык юнәлеше кушымчасы булган сүзформа гына, *эшләште* дә, *эшләштеләр* дә – сүзформалар.

Сүздә ясагыч кушымча булмаса, тамыр белән нигез бер-берсенә туры килә.

Сүз алды (префиксаль) морфлар гадәттә нигез эчендә каралалар: *архи-авыр, ультра-миләүшә, транс-себер, экстра-класс, кып-кызыл, ямь-яшел* һ.б.

Сүз (лексема) грамматик яктан сүзформаларның системасыннан тора, ләкин сүзформаларның нигезе бер үк мәгънәле, бер үк формада булырга тиеш. Мәсәлән, *ташчы, ташчым, ташчыбыз, ташчың, ташчыгыз, ташчысы* сүзформалары барысы бергә бер сүз (лексема) тәшкил итәләр, чөнки алар мәгънә ягыннан һәм фонетик составы ягыннан охшаш, хәтта бер үк нигезле (*ташчы*). Нәкъ менә шул формада бу сүз сүзлекләргә кертелә һәм тел белүченең исендә кала.

Сүзформа һәм морф сөйләм берәмлеге санала, ә тел берәмлеге итеп санаганда, аларны телнең хәрәкәттәге берәмлеге (линейные единицы) диләр. Сүз һәм морфема – телнең статик халәте берәмлеге санала, дигән идек. Тел һәм сөйләм дәрәҗәләрендәге мондый берәмлекләрне аера белү грамматика фәнен өйрәнүдә бик әһәмиятле.

Сүзформаларның, морф санына һәм үзенчәлегенә карап, төрле типлары аерыла. Сүзформаның морфларга таркалу ягыннан төзелешен күрсәтү өчен, шартлы билгеләр кулланалар. Бу шартлы билгеләр гомуми тел гыйлемендәге билгеләргә туры килсен өчен, татар грамматикасында да шул ук уртак латин хәрефләре кулланыла: R – тамыр морф, s – сүз арты кушымчалары, ягъни суффиксаль морф; pr – сүз алды (префиксаль) морфы, si – ярдәмлек (служебный) морф.

Һәрбер агглютинатив телдәге кебек үк, татарчада да сүзформа структурасы бик гади, ачык һәм тәртипле. Морфлар урнашу буенча сүзформалар түбәндәге типларга бүленәләр:

1. R (*ат, кинәт, һәм, яз, бер*).
2. R-s (*атлы, яза, аттай, күргән*).

3. R-s-s (*атларда, язам*) һ.б.

4. R-s-s-s (*атлыларда, яздырам*).

5. R-s-s-s-s (*атлыларныкыдыр, яздырмаячакмын*).

6. R-s-s-s-s-s (*атлылардагыныкыдыр, яздырмаганлыктан*).

7. R-s-s-s-s-s-s (*атлылардагыныкынадыр, яздырмаганлыктандыр*).

Сүз формаларның бердән алып дүрткә кадәр морфы булганнары еш очрый һәм табигыйрак күренә. Биш яки алты морфлылар сирәк очрый, аларны куллану да уңайсызрак.

Сүз алды морфлары да булса, сүзформаның күбрәк очрый торган типлары түбәндәгеләр:

1. pr-R-s (*анти-кисәкчә*).

2. pr-R-s-s (*анти-кисәкчәнеке*).

3. pr-R-s-s-s (*анти-кисәкчәләрнеке*).

4. pr-R-s-s-s-s (*анти-кисәкчәләрнекедер*) һ.б.

Ярдәмлек морфы да булса, сүз формаларның күбрәк очрый торган типлары түбәндәгеләр:

1. R-s-sl (*урманга таба*).

2. R-s-sl-s (*яза идем – яз-а иде-м*).

3. R-s-s-sl-s *(яз-ма-ган иде-м*).

4. pr-R-sl-sl-s (*анти-фашист түгел идең*) һ.б.

Бу очракта сүз формаларның тибы, моделе гаҗәеп күп төрле булырга мөмкин.

Сүзформада кушма нигез (тамыр) булганда да югарыда әйтелгән типларның барысы да очрый. Берничә мисал:

1. R-R (*ата-ана*).

2. R-s-R (*елдан-ел*).

3. R-s-s-R (*үзеннән үзе*).

4. R-s-R-s (*анда-монда*).

5. R-R-s (*ата-аналар*).

6. R-R-s-s (*ата-аналарда*) һ.б.

Сүзформаның морф буенча типлары бик күп. Биредәге үрнәкләр нигезендә аларның һәрберсен шундый схемаларда күрсәтергә мөмкин.

Морфемика фәнен махсус өйрәнүче булса, анда морфемаларның башка күп төрле гомуми проблемалары да урын алырга мөмкин.

# 8. МОРФОНОЛОГИЯ

Татар тел гыйлемендә бу бүлек тә, морфемика кебек үк, беренче мәртәбә 1993 елда русча чыккан академик грамматикада фәнни яктыртылды. **Морфонология (морфофонология, фономорфология, морфофонемика),** башка тел гыйлеме терминнарына хас булганча, төп ике мәгънәдә (тар һәм киң) куланыла: морфонология – морфемаларның кулланышы, ягъни функциональ хәрәкәте вакытында бу морфемалар составында бара торган фонетик үзгәрешләрне өйрәнә торган фән; шул ук вакытта морфонология телдәге мондый үзгәрешләр, чиратлашулар, морфемаларны төрле позицияләрдә куллану процессында бу морфемалар составында бара торган фонетик үзгәрешләр системасы. Морфонология тел гыйлеменең бер өлеше буларак, морфология, фонетика һәм сүзьясалыш, морфемика кебек фәннәр белән тыгыз бәйләнгән. Тел гыйлеменең бу бүлегенең берничә атамасы булуы нәкъ менә шуның белән аңлатыла.

Сөйләм процессында морфемалар төрле фонетик һәм морфемик чолганышта калалар, нәтиҗәдә янәшә торучы морфемаларның фонематик составына бәйле рәвештә фонетик үзгәрешләр, чиратлашулар барлыкка килә. Морфеманың төрле фонетик вариантлары, ягъни аерым конкрет бер формасы морфеманың алломорфы дип атала. Мәсәлән, күплек сан кушымчасы *-лар* алдагы морфеманың фонема составына карап, түбәндәге әдәби вариантларда (алломорфларда) чагыла: *-лар*/*-ләр, -нар*/*-нәр;* шулай ук диалекталь *-тар*/*-тәр, -дар*/*-дәр* формалары да бар. (Тугандаш башкорт телендә соңгы вариантлар да әдәби норма булып исәпләнә.) Морфеманың алломорфлары фонемалар (сирәк кенә – авазлар) чиратлашуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу чиратлашуларны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин: 1) бер үк морфемадагы фонемалар алмашуы, ягъни тар мәгънәдә чиратлашу (*урман-да, таш-та: -да*/*-та* морфларындагы (д – т)); 2) фонеманың нуль фонема белән алмашуы, ягъни нигез кыскару (*милек – милке*

(э – Ø)), яки фонемалар керешү (*артист+та=артиста:* (т – Ø) – тамыр алломорфларында күзәтелә *артист – артис);* 3) нуль фонеманың башка бер фонема белән алмашуы, ягъни асемантик фонема ялгану (*зың+ылда=зыңгылда:* (Ø – ғ)); 4) фонемалар комплексының бер фонема белән чиратлашуы (*карт+карт=кап-карт:* (рт – п)); 5) фонемалар комплексының нуль фонема белән алышынуы (*алып кит=апкит:* (лы – Ø)); 6) ә кайчак аваз белән аваз чиратлашуы (*ба$^{о}$ла+лар=ба$^{о}$ла$^{о}$-лар:* (а – а$^{о}$)). Морфемалар составындагы чиратлашучы бу фонетик берәмлекләр мәгънә аеру функциясенә ия түгел. Морфемаларның төрле фонетик позицияләрдә кулланылуы нәтиҗәсендә сүз составында чиратлашучы фонетик берәмлекләр (авазлар, фонемалар, фонемалар комплексы) морфонема дип атала. Морфонемалар морфеманың билгеле бер позициясе өчен генә характерлы, ягъни алар морфеманың алломорфларын барлыкка китергән шартларда гына релевант булмаган функция үтиләр.

Икенче төрле әйткәндә, морфонология төрле позицияләрдә килүче морфемалар составындагы фонетик чиратлашуларны, аларның составын, морфонемаларның кулланылу үзенчәлекләрен, морфемаларның алломорфларын һ.б.ны өйрәнә.

Морфонология, икенче төрле итеп әйткәндә, морфемаларның фонологик структурасын, фонологик чараларның морфологик ролен, морфологик процесслардагы «хезмәт»ен өйрәнә. Телдәге төп фонетик үзгәрешләр ахыр чиктә авазлар, фонемалар яки фонемалар комплексы чиратлашуга кайтып кала. Фонемаларның морфонологик сурәтен аныклау телебезнең берничә мөстәкыйль бүлегә яссылыгында гына тулы барырга мөмкин.

Морфонология, морфемалар составындагы фонетик үзгәрешләрне өйрәнүче фән буларак, беренче чиратта фонетика белән тыгыз бәйләнгән, чөнки позицион үзгәрешләр морфонологиядә дә, фонетикада да өйрәнелә. Фонетикада позицион үзгәрешләрнең артикуляциягә бәйле сәбәпләре тикшерелсә, морфонологиядә чиратлашучы фонетик берәмлекләр, морфонемалар өйрәнелә, морфемаларның барлык алломорфлары да морфонологиянең өйрәнү объекты булып санала.

Морфонология, бәхәссез, фонология белән дә бик тыгыз бәйләнештә тора. Бу ике фән бүлегенең икесендә дә фонемалар өйрәнелә, тик фонология өчен фонемаларның мәгънә аеру (релевант) үзен-

чәлекләре өйрәнү объекты булса, морфонологиядә фонемаларның релевант булмаган үзлекләре өйрәнелә.

Морфонология шулай ук морфология һәм синтаксис белән дә тыгыз бәйләнгән.

Морфонологиядә морфемаларның фонетик чиратлашулары бер сүз формасы белән генә чикләнмәскә дә мөмкин (агглютинация, редупликация һ.б.). Чиратлашулар кайчак синтагмалар яссылыгында да бара. Бу нәкъ менә төрки телләр өчен характерлы күренеш. Билгеле булганча, бу телләрдә сөйләм агымында интонацион рәвештә сүзләр түгел, ә синтагмалар бүленә. Синтагма берничә сүз формасыннан торганда, соңгылары бер фраза басымына буйсына һәм кушылып әйтелә. Бу вакытта синтагманы төзүче сүзләр җөендә төрле фонетик үзгәрешләр килеп чыгарга, ягъни кушылып әйткән беренче сүздәге соңгы морфема һәм икенче сүзнең беренче морфемасында фонетик чиратлашулар күзәтелергә мөмкин. Мәсәлән, татар телендәге бер җөмлә: *Ул эштәге атны килеп алып китте* (*Ул*/ *эштәгатны* / *килебапкитте*). Икенче синтагмада ике сүз арасындагы җөйдә (э – Ø) аваз үзгәреше барлыкка килде, ягъни беренче сүзнең [э] фонемасы нуль фонема белән алмашынды. Өченче синтагмада исә беренче җөйдә [п] һәм [б] фонемалары чиратлашса, икенче җөйдә *-лы* комплексы нуль фонема белән алышынды: (-лы – Ø). Морфонологиянең просодия белән дә уртак яклары бар, чөнки позиция, басым үзгәрүгә бәйле рәвештә, морфемалар составында да фонетик үзгәрешләр килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, *ба$^{о}$ла* сүзендә басым соңгы иҗеккә төшә һәм соңгы [а] иренләшмәгән, ә бу тамыр морфемасына аффиксаль *-лар* килеп ялгангач, соңгы кушымча басымны үзенә ала, һәм басымын югалту сәбәпле, иренләшмәгән [а] иренләштерелеп әйтелә башлый: *ба$^{о}$ла$^{о}$лар.*

Морфонология, лингвистиканың башка бүлекләре белән тыгыз бәйләнештә булганга күрә, бу бүлекләрнең берәмлекләре белән дә эш итә: авазлар, фонемалар (сегмент), просодемалар, ягъни суперсегмент фонемалар, морфемалар, сүзләр, синтагмалар да морфонология яссылыгында каралалар. Бу берәмлекләрдән тыш морфонологиянең үз берәмлеге – морфонема бар.

Биредә контрастив планда татар (гомумән төрки) морфонологиясенең аермасын күрсәтергә кирәк. Рус морфонологиясендә күбрәк традицион (икенче төрле әйткәндә, тарихи, морфологик, регуляр һәм

автоматик булмаган) чиратлашулар өйрәнелә. Ә бүгенге фонетик закончалыкларга нигезләнгән чиратлашу-үзгәрешләр рус морфологиясенә кертелмиләр диярлек. Тарихи яктан гына аңлатып була торган традицион чиратлашулардан аеру өчен, позицион чиратлашуларны русистикада авазларның үзгәрешләре дип билгелиләр. Морфологиядәге бу принцип билгеле бер дәрәҗәдә тарихи фонетиканы аерымлау принцибы белән тәңгәл килә. Бу яктан караганда, морфонологияне тарихи позицион үзгәрешләрне өйрәнүче фән дип билгеләп булыр иде.

Морфонологияне бары традицион тарихи чиратлашулар, аваз үзгәрешләре белән генә чикләү флектив телләр өчен отышлы да: бу телләрдә күп очракта тамыр морфемасы ныклы, стандартлашкан фонематик составка ия түгел, ягъни сүзнең иң төп морфемасы тамырда гына да төрле морфологик процесслар вакытында бик күп төрле чиратлашулар күзәтелә – морфонологиянең өйрәнү объекты биредә бик киң. Агглютинатив телләргә килгәндә исә, биредә морфонологияне бары традицион үзгәрешләр белән генә чикләү максатка ярашлы түгел: бу телләрдә тамыр морфемасы күп очракта стандартлашкан, ныклы һәм үзгәрешсез кала; биредә тарихи альтернацияләр бик сирәк күзәтелә. Ә сирәк кенә очраучы мондый чиратлашуларны тарихи фонетикада да карап булыр иде. Шуңа күрә татар морфонологиясенә тарихи традицион һәм позицион чиратлашуларны бергә кертеп карау отышлы булыр. (Морфемалар хәрәкәте вакытында күзәтелә торган барлык төр үзгәрешләрне дә өйрәнү.) Аннары төрки тел гыйлемендә фонетика өлкәсендә тарихи һәм позицион аваз үзгәрешләренең гадәттә аерылмыйча, бергә өйрәнелүен дә игътибарга алырга кирәк.

Татар тел белемендә күбрәк позицион аваз үзгәрешләре өйрәнелгән, морфонологиягә бәйле рәвештә тарихи альтернацияләрне дә ныклап өйрәнү бурычы килеп баса.

**Нигез кыскару:** сүзләр яки сүзләрнең формалары ясалу процессында нигез һәм аффиксаль морфема җөендә кайвакыт татар теле өчен хас булмаган күренеш барлыкка килә: бер үк яки бер типтагы фонемалар җыелмасы очраша. Артикуляция өчен авыр булган мондый фонемалар группасыннан котылу максатында, татар телендә кайбер мисалларда нигез кыскару күзәтелә. Әйтелгәннәргә өстәп, шуны да ассызыкларга кирәк: бу морфонологик күренешнең икенче сәбәбе – [ы] һәм [е] кыска сузыкларының редукциягә омтылышында.

Кагыйдә буларак, төрки телләр өчен авазлар чылбырында сузык һәм тартыкларның тигез рәвештә чиратлашып килүе хас, тартыклар янәшәлеге сирәк күренеш, ә сузыкларның янәшә килүе тагын да сирәгрәк очрый. Тик сөйләм телендә бер үк төрле авазлар очрашуы (гадәттә бу хәл ике мөстәкыйль сүз арасында яки ике сүз нигезләренә төрле аффикслар ялганганда була) шулай да еш күзәтелә.

1. Исем тамырларда һәм нигезләрдә нигез кыскару (бу күренешне **фонема йотылу** дип тә атап булыр иде) түбәндәге очракларда бара:

а) исемнәр нигезенә тартым кушымчалары ялганганда: *халык+ы= халкы* (ы – Ø); [ы] фонемасы нуль фонема белән чиратлаша, *милек+е= милке* (е – Ø); б) исемнәрдән иркәләү-кечерәйтү формалары ясалганда: *әни+кәй=әнкәй* (и – Ø), *әби+кәй=әбкәй,* шулай ук (и – Ø); в) *абый* сүзенә иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганганда нигезнең соңгы фонемасы йотыла: *абый+кай=абыкай.* Шунысы кызык, бөек мәгънәле әни, ипи сүзләренә мондый кушымча ялганганда нигез кыскару күзәтелми: биредә фонемаларның гади чиратлашуы: *ипи+кәй= ипекәй, әни+кәй=әнекәй* (и – е); г) сыйфатлардан кимлек дәрәҗәсе ясалганда: *ачы+кылт= ачкылт* (ы – Ø), *төче+келт=төчкелт* (е – Ø); Кызыл һәм яшел сыйфатларының кимлек дәрәҗәсе ясалганда нигез кыскару башкачарак формула буенча бара: *кызыл+гылт=кызгылт* (ыл – Ø), *яшел+келт= яшькелт* (ел – Ø). Татар тел белемендә бу сыйфатларның борынгы төрки тамыры *кыз-, яшь-* булган дигән фикер, димәк, морфологик аспект өчен дә кыйммәтле.

Мондый чиратлашуларның нәкъ менә морфонологик характерда булуы тагын бер мисалда ачык күренә: халык – халкым (ы – Ø), шундый ук диярлек авазлар төркеме булган балык сүзендә башка чиратлашу: балкым түгел, балыгым (тартык фонема үзгәрде), ягъни мондый мисаллар гади фонетик чиратлашулар гына түгел, ә нәкъ менә морфемаларның хәрәкәте, морфологик (яки сүз ясалу) адымнар белән бәйләнгән очракта күзәтелә.

Нигез кыскару исем тамырлар кушылганда – сыйфат һәм исемнән яңа исем ясалганда да күзәтелә, биредә дә беренче компонентның соңгы фонемасы йотыла: *сары+ут=сарут;* ике исем арасында да шул ук фонема төшеп калу күренеше: (ы – Ø), *тары+ургыч= тарургыч,* ягъни (ы – Ø) морфонемасы ясала.

Исем тамырлардан фигыль ясалганда да кайвакыт нигездәге фонеманың йотылуы очрый: *уйын+ый=уйный* (ы – Ø), *яшен+и=яшьни* (е – Ø) һ.б. Бу мисалларда нигез кыскаруга китерүче ике фактор да әһәмияткә ия: бер үк типтагы фонемалар очрашуы, шулай ук [ы] һәм [е] сузыкларының редукциягә омтылышы.

2. Фигыль тамыр һәм нигезләрдә фонема йотылу күренеше кайбер фигыльләрнең хәзерге заман формасы ясалганда күзәтелә: *йо-лык+а=йолка, курык+а=курка,* ике мисалда да (ы – Ø).

Кушма фигыльләр ясалганда, әгәр ике сүз чигендә сузык авазлар очрашырга тиеш булса, шулай ук бу сузыкларның берсенең йотылуы очрый: *көтә+ала–көтала, менэ+ала=менала* (ә – Ø). *Алып+бар=ап-пар, алып+куй=апкуй* мисалларында исә нигез кыскару ике фонема хисабына бара: (лы – Ø). Соңгы ике мисал күбрәк сөйләм теле өчен характерлы, шулай да, нәкъ менә сөйләм процессының нәтиҗәсе буларак, әдәби әсәрләр, матбугат телендә дә *апкуй, апмен, апкит* формалары торган саен күбрәк очрый. (Кушма фигыль ясалганда очрашырга тиеш булган ике бер үк төрле фонеманың берсе йотылуын без фонемалар керешүе күренеше дип карыйбыз: *бара+ала=барала* һ.б.)

3. Алмашлыкларда нигез кыскару күбрәк тартык фонемалар хисабына бара. Мәсәлән, зат алмашлыгы *ул* һәм күрсәтү алмашлыгы *шул* килеш һәм сан һ.б. формалары ясалганда, үзләренең составындагы соңгы [л] фонемасын «югалталар»: *ул+ны=аны, шул+лар=шулар* һ.б. (л – Ø). Биредә фонема йотылу күренеше икенче морфонологик процесс – беренче сузыкларның чиратлашуы белән бергә бара. Алмашлыклар составындагы бу аваз үзгәрешләре тарихи чиратлашулар белән тыгыз бәйләнгән.

4. Саннарда нигез кыскару шулай ук [ы] һәм [е] сузыклары йотылуы нәтиҗәсендә бара. Мәсәлән, җыю саннары ясалганда: *ал-ты+ау=алтау, җиде+әү=җидәү* һ.б. башлангыч формалардагы [ы], [е] фонемалары безгә билгеле (ы – Ø), (е – Ø) морфонемаларын хасил итә. Биредә дә нигез кыскару сандхи, элизия очракларында сузыкларның редукциягә омтылышы белән аңлатыла.

Кайбер кушма саннар ясалганда исә, нигез кыскару бүгенге позицион чиратлашулар белән генә түгел, ә тарихи үзгәрешләр, тарихи сәбәпләр белән бәйләнгән: *сигез+ун=туксән, тугыз+ун=туксан.* Бу мисалларда (ы – Ø), (е – Ø) морфонемаларыннан тыш, [з] фонемасы-

ның саңгырау пары белән чиратлашуы, ягъни (з–с), арткы рәт сузыгының алгы рәт сузыгы [ә] белән алышынуы да кызыклы: (у–ә). Алтмыш һәм җитмеш саннары ясалганда да, (ы – Ø), (е – Ø) морфонемалары барлыкка килә: *алты+мыш=алтмыш, җиде+меш= җитмеш* (бу ике санның составында бүгенге көндә активлыгын югалткан борынгы төрки аффикс *-мыш*/*-меш* сакланган).

Югарыда әйтелгәннәре йомгаклап, түбәндәгеләрне ассызыклап китү максатка ярашлы булыр: 1) татар телендә нигез кыскару күренеше күп очракта редукциягә омтылучы чагыштырмача кыска сузыклар [ы] һәм [е] йотылуы хисабына бара; 2) морфемалар һәм сүзләрнең линия юнәлешендә күбрәк регрессив йогынты күзәтелә; 3) нигез кыскару мисалларының таралышы төрлечә: күпчелеге бүгенге фонетик, позицион аваз үзгәрешләре белән аңлатыла һәм шактый типиклашкан (мәсәлән, сонант авазлар янәшәсендәге кыска сузыкларның редукциясе), кайбер чиратлашулар исә (мәсәлән, алмашлыклар составында) тарихи үзгәрешләрнең нәтиҗәсе булып бәяләнә; 4) нигез кыскару нәтиҗәсендә, күп очракта бер генә төрле морфонема барлыкка килә: фонема – нуль фонема; фонемалар комплексы – нуль фонема бик сирәк күзәтелә; 5) татар телендәге нигез кыскару мисаллары барысы да диярлек орфографиядә чагылыш тапкан (*утыр+ау=утрау*), кайбер мисаллар орфография өчен дә, орфоэпия өчен дә ике вариантта йөриләр: *сеңел+ем=сеңелем* яки *сеңлем* (әдәби текстларда без язылуның *ике вариантын да еш очратабыз),* сөйләм теле өчен генә хас мисаллар да очрый (*бирә+ала=бирала*) һ.б.; 6) телдәге бу күренеш – нигез кыскару – тел өчен мөһим принципларның берсе булган экономия факторы белән дә аңлатылса кирәк.

**Асемантик фонема ялгану.** Морфемалар кушылганда, кайчак, морфонологик чара буларак, асемантик фонема ялгану күзәтелә. Сүз составында мондый фонема семантик, шулай ук грамматик мәгънәгә дә ия түгел, шуңа да аны «асемантик» дип атыйлар (образлы итеп әйткәндә, аны «бутафорик элемент» дип атап булыр иде). Мондый асемантик элементлар ролендә татар телендә аерым фонемалар гына килә ала, һәм күпчелек очракта алар – тартык фонемалар.

1. Аваз ияртемнәреннән *-ылдау*/*-елдәү* кушымчалары ярдәмендә фигыль ясалганда: *кет+к+елдәү=кеткелдәү, кар+ҡ+ылдау= карҡылдау* (Ø – ҡ), (Ø – к) морфонемалары барлыкка килә; *зың+г+ылдау*

(Ø – ғ) һ.б. Кайбер белгечләр фикеренчә, бу [к], [қ], [ғ] фонемалары ялганучы асемантик фонема түгел, ә тамырның үз составына керә. Мондый фикер бәхәсле, чөнки *карк, зыңг, кетк* һ.б. шундый тартык комплекслары татар теле өчен хас күренеш түгел; аннары нигезе *к, қ, г, ғ,* авазларына беткән аваз ияртемнәренә мондый фонемалар ялганмый бит: *тек+елдәү=текелдәү, елк+ылдау=елкылдау* һ.б. Димәк, мондый күренешнең морфонологик характеры, ягъни морфема җөе өчен уңай шартлар тудыру максатыннан килеп чыгуы аңлаешлы.

2. Микъдар саннарыннан бүлем саннары ясалганда, нигез белән аффикс арасында асемантик [ш] фонемасы ялгана: *ике+ш+әр= икешәр, алты+ш+ар= алтышар.* Мисаллардан күренгәнчә, [ш] фонемасы ике сузык кушылырга тиеш булган морфема җөенә килеп керә, тартыкка беткән саннарга исә *-ар*/*-әр* кушымчасы ялгана. Чагыштыру өчен: *ун+ар=унар, биш+әр+бишәр.*

3. Исем (яки сыйфат) тамырлардан *-ай*/*-әй* кушымчалары ярдәмендә фигыль ясалганда да, морфемалар җөендә асемантик фонемалар ялгану күренеше күзәтелә. Мәсәлән, *зур+ай=зурай* һәм *кече+р+әй= кечерәй,* ягъни (Ø – р). *Олы* һәм *сары* тамырларыннан фигыль формалары ясалу барышында да тамыр белән кушымча арасына [г] фонемасы килеп керә: *олы+г+ай=олыгай, сары*+ғ+*ай=саргай:* (Ø – ғ). Тарихи фонетика күзлегеннән чыгып карaганда, биредә бернинди асемантик фонема да юк, чөнки бу тамырларның борынгы варианты *сарыг* һәм *олуг.* Ә синхроник аспекттан, телнең бүгенге торышыннан алып фикер йөрткәндә, мондый мисаллар нәкъ менә морфонологик характерга ия. Бүгенге тел өчен *-гай* фигыль ясагыч кушымчасы да (чагыштыр: *туры – турай, матур – матурай* һ.б.), *сарыг, олуг* тамырлары да хас түгел. Димәк, синхроник һәм диахроник аспектларның үзенчәлекләрен искә алып (ә морфонология ул синхроник фән), мондый чиратлашуларның морфонологик характерын танырга туры килә. Шундый ук мисалларны *дус* исемендә һәм исем урынында йөрүче *ал, ас, өс* сүзләрендә күрергә була: тартым кушымчалары ялганганда, тамыр белән аффикс арасында [д], [т] фонемалары да ялгана: *ян+ым= яным,* тик *ал+д+ым=алдым, төс+ ем=төсем,* тик *өс+т+ем=өстем,* ягъни (Ø – д), (Ø –т); *уч+ым=учым,* тик *дус+т+ым=дустым* һ.б. Бүген асемантик фонема ролендә йөри торган бу [д], [т] фонемалары кайчандыр телебездә бу сүзләрнең тамыр составына кергәннәр: *дуст,*

*аст, өст.* Хәзерге телдә [д], [т] фонемалары бу сүзләрнең күп формаларында сакланмаган: *аска, өскә, дуслар, аслар* һ.б. һәм «бутафорик», ягъни морфонологик роль генә башкара.

4. [н] асемантик фонемасы ялгану, ягъни (Ø – н) морфонемасы телдә ике очракта күзәтелә: *-ча/-чә* кушымчалары ярдәмендә рәвешләр ясалганда. Мәсәлән, *татар+ча=татарча, кеше+чә=кешечә,* тик *тиеше+н+чә=тиешенчә, гадәте+н+чә=гадәтенчә.* Шул ук морфонема (Ø – н) *бу* күрсәтү алмашлыгының төрле морфологик вариантлары ясалганда барлыкка килә: *бу+дай=мондый, бу+дан=моннан* һ.б. Тарихи чиратлашуларга бай булган алмашлыклар составындагы асемантик фонема ялгану, күренгәнчә, башка морфонологик күренешләр белән бергә бара: (б–м), (у–о).

5. Исемнәр III зат тартым кушымчасы белән төрләнгәндә, морфема җөендә (Ø – с) чиратлашуы барлыкка килә: *тун+ы=туны, эт+е=эте,* ләкин *бала+с+ы=баласы, таба+с+ы=табасы.* Асемантик [с] фонемасы исемнең нигезе сузык авазга беткән очракта, ягъни татар теленә хас булмаган күренеш – ике сузыкның бергә килүен булдырмау максатыннан ялгана.

6. *-ачак/-әчәк* аффикслары белән киләчәк заман сыйфат фигыль формалары ясалганда, нигез белән кушымча арасына [й] фонемасы килеп керә: чагыштыр: *ат+ачак=атачак, бас+ачак=басачак* һәм *җырла+й+ачак=җырлаячак, сора+й+ачак=сораячак.* (Ø – й) морфонемасы ясалу биредә дә ике сузык янәшәлегеннән котылу максаты белән аңлатыла.

7. Гадәттә татар телендә асемантик фонема ролендә тартыклар килә. Ә тартык авазларга беткән алынма сүзләргә төрле аффикслар ялганганда, морфема җөендә «читтән килгән» сузыклар да пәйда булырга мөмкин: *Смоленск+и+да=Смоленскида, отпуск+ы+да=отпускыда, пропуск+ы+ны=пропускыны* һ.б. (Ø – и), (Ø – ы) морфонемаларының барлыкка килүе шулай ук телнең фонетик закончалыклары белән аңлатыла: татар теле өчен сүз азагында ике, бигрәк тә өч тартык килүе хас күренеш түгел, асемантик фонемалар шул тартыклар арасына килеп кереп, артикуляция өчен уңай шартлар тудыралар да инде.

8. Югарыда китерелгән мисаллар – асемантик фонема ялгану очраклары – барысы да орфографиядә чагылыш тапкан; сөйләм

телендә генә бара торган, әмма орфоэпик нормага әйләнгән чиратлашу мисаллары да бар. Мәсәлән, ике сүз кушылып әйтелгәндә, беренче сүз *-у/-ү* авазларына бетеп, икенче сүз *-а/-ә/-и* авазларына башлана икән, сүзләр чигендә ирен-ирен [w] авазы әйтелә: *су+асты=су*$^{w}$*асты.* Ә [и] авазыннан соң [а], [ә], [у], [ү] авазлары килсә, алар арасында [й] авазы әйтелә: *ни+аласың=ни*$^{й}$*аласың, кими+ул= кими*$^{й}$*ул.* Асемантик фонема, морфонологик күренеш буларак, татар теле өчен аерым бер закончалык чагылышы булып тора. Орфографиядә морфема принцибын бозу кебек бәяләнсә дә, асемантик фонема ялгану татар теленең фонетик үзенчәлекләрен бик төгәл чагылдыручы, шулай ук телдәге тарихи чиратлашуларның эзләрен саклаучы, алынма сүзләр татар теле тарафыннан үзләштерелгәндә, төрле фонетик үзгәрешләр кичерүләрен яктыртучы күренеш. Димәк:

1) татар телендә асемантик фонема ролендә күбрәк увуляр [к], [к], [ғ],[г], шулай ук [ш], [д], [т], [н], [с] тартыклары килә, сузыклардан [ы],[е], [и] ялгаучы (беркетүче) ролен уйнарга мөмкин. Бу фонемалар лексик яки грамматик мәгънәгә ия түгел, шуңа да аларны тамыр яки аффикс составында карау дөрес булмас иде, бу фонемалар төзүче материал, ныгытучы элемент ролен генә үти;

2) асемантик фонема ялгану нәтиҗәсендә бары бер генә модельдәге морфонема барлыкка килә: нуль фонема конкрет бер фонема белән чиратлаша;

3) бу морфонологик күренешкә мисаллар барысы да диярлек орфографиядә чагылыш тапкан.

**Фонемалар керешүе.** Татар телендә бу морфонологик күренеш киң таралмаган, чөнки ике бер үк төрле фонемалар очрашуы телдә сирәк очрый. Фонемалар керешүнең икенче бер морфонологик күренеш – нигез кыскару белән уртак яклары күп, тик аларны аерып карарга кирәк. Беренчедән, фонемалар керешү бары бер үк төрле фонемалар очрашканда гына бара; икенчедән, нигез кыскарудан аермалы буларак, фонемалар керешү морфема җөендә, бер үк фонемага беткән сүзгә шул ук фонемага башланган икенче компонент ялганган вакытта күзәтелә:

1. Рус теленнән (яки рус теле аша башка телләрдән) кергән алынмаларга аффикслар килеп кушылганда: *артист+та=артиста, поезд+да=поезда* һ.б. Шунысы кызыклы: сонантлар катнашкан тар-

тыклар җыелмасы үзгәрешсез кала, биредә фонемалар йотылмый: *цемент+та=цементта, порт+та=портта,* ягъни (т – Ø) биредә юк.

2. Алмашлыклардагы фонемалар керешү аеруча кызыклы: *мин+не=мине, син+не=сине* (н – Ø). Исемнәрне алыштыручы алмашлыклар *мин* һәм *син* сүзләренә тартым кушымчалары *-ныкы/-неке* ялганганда да, морфема чигендә ике [н] авазының берсе йотыла: *мин+ неке=минеке, син+неке=синеке,* шул ук вакытта аерым бер килеш формасында бу алмашлыкларда ике [н] авазының да саклануы игътибарга лаек: *мин+нән=миннән, син+нән=синнән.* (н – Ø) морфонемасы ясалу, югарыда инде әйтелеп үтелгәнчә, алмашлыклар составындагы тарихи үзгәрешләр, чиратлашуларга кайтып кала.

Китерелгән бу ике мисал татар телендә орфографиядә чагылыш тапса, фонемалар керешүнең сөйләм телендә генә бара торган очраклары да бар. Чөнки сөйләм процессында ике сүз арасында бер үк фонемалар очрашуы шактый еш күзәтелә: *бара+алмый=баралмый, ныклы+ышаныч=ныклышаныч, түзә+алмый=түзалмый, түзәлмый, түзәлми* һ.б. (а – Ø), (ы – Ø), (ә – Ø). Әйтергә кирәк, соңгы мисал язма текстларда да күзәтелә (мәсәлән, җыр текстларында соңгы өч вариант та очрый), димәк, морфонологик модельләр норма булырга хокук яулыйлар. Кушма исемнәр ясалгандагы фонемалар керешүе традицион рәвештә язуда да чагылыш таба: *алма+агач=алмагач, таба+агач=табагач* (а – Ø).

Йомгаклап, шуны әйтергә мөмкин:

1) башка телләрдән аермалы буларак, татар телендә бары аерым фонемаларның кушылуын, керешүен танырга кирәк;

2) мисалларның күпчелеге – алынма сүзләрнең татар теле тарафыннан үзләштерелүе нәтиҗәсе;

3) телдә артык һәм сузык авазлар да керешергә мөмкин;

4) бер үк төрле фонемалар йотылуы татар теленең фонетик үзенчәлекләре белән бәйләнгән, әйтик, 2–3 бер төрле авазларның янәшәлегеннән качу; алмашлыклардагы чиратлашулар безгә билгеле тарихи үзгәрешләр, телнең үсеш процессы закончалыклары белән аңлатыла;

5) орфографиядә чагылыш тапкан мисаллар татар телендә аз. Бер үк төрле фонемаларның керешүе ешрак ике сүз чигендә, бу сүзләрнең бер ритмик басым белән әйтелгән чагында күзәтелә;

6) бу морфологик күренеш нәтиҗәсе булып, бер генә модельдә морфонема барлыкка килә: (Ф – Ø) яки (ФФ – Ф).

**Фонемалар чиратлашуы.** Татар телендә иң күп таралган морфологик күренеш – фонемалар чиратлашуы. Ассызыклап әйтик: бар морфологик күренешнең дә асылында, нигезендә чиратлашулар ята. Тик бу соңгы күренешне аерып алып карарга, өйрәнергә кирәк: биредә без конкрет бер фонеманың икенче бер конкрет фонема белән алмашынуы, чиратлашуы турында сүз алып барабыз. Фонемалар чиратлашуының нәтиҗәсе булып (Ф – Ф), (Ф – Ф – Ф), (Ф – Ф – Ø) һ.б. модельдәге морфонемалар ясала. Бу морфонемалар сүзләрнең тамырын, нигезен, аффикслар составындагы чиратлашучы фонемаларны берләштерә. Морфонемалар составындагы фонемаларны аларның төп дифференциаль билгеләре аспектында да өйрәнергә кирәк. Бу яктан чыгып караганда, морфонемалар төп ике төрле группага бүленә: 1) үз составында сузык авазларны берләштерүче, ягъни сузык морфонемалар; 2) тартык морфонемалар.

**Сузык морфонемалар.** Татар теленең вокализмы өчен сузыклар гармониясе төп закон булып тора. Белгәнебезчә, гармония – сүздә морфемаларны беркетүче, мәгънә һәм фонетик бердәмлеген, бөтенлеген тәшкил итүче көч. Сузыклар гармониясе законы йогынтысында сузык фонемаларның кайбер аерымлыклары нейтральләшә, чөнки чын төрки-татар сүзләрдә төрле сингармоник модельле сузыклар килә алмый. Сингармоник модельләр сузыкларның рәте (аңкау гармониясе) һәм иренләшүе (ирен гармониясе) белән билгеләнә. Бер сүз чигендә бу билгеләре белән аерылучы сузыклар килә алмаганлыктан, мондый билгеләр сүз аеру өчен кулланыла алмыйлар. Шуңа күрә рәте һәм иренләшүе белән аерылып, башка билгеләре буенча тәңгел булган сузык фонемаларны аерым бер берәмлеккә – морфонемага берләштерергә мөмкин. Икенче төрле әйткәндә, бу – морфемалар янәшәлегенә бәйле рәвештә чиратлашучы фонемалар, авазлар бердәмлеге дигән сүз.

Татар телендә сузыкларның көчле фонологик позициясе булып, тамырдагы беренче иҗек санала. Бу позициядә сузыкларның бөтен дифференциаль билгеләре дә реаль көчкә ия, шуңа күрә 12 сузык фонема да биредә бернинди чикләүләрсез кулланыла. Башка позициядәге сузыкларның яшәешен исә сингармонизм законы билгели. Татар телендә 4 сингармоник модель аерып чыгарырга була.

Беренче сингармоник модель. Әгәр сүзнең беренче иҗегендә иренләшмәгән арткы рәт сузыклары [а], [ы] килсә, калган иҗекләрдә [а], [ы], [у] сузыклары килә ала: *ба-ла-лар, ба-ла-ча-гым, ы-ша-ну, ы-шан-ды-лар, ы-ша-ну-ым.*

Икенче сингармоник модель. Беренче иҗектә иренләшкән арткы рәт сузыклары [о], [у] булса, калган иҗекләрдә [а], [ы], [у], [о] сузыклары килә ала: *о-лы-лар, ор-лык* (бу ике сүзнең икенче иҗекләрендә иренләшкән [о] авазы ишетелә), *ур-ман, у-тын, у-кы-ту, у-зы-шып* һ.б.

Өченче сингармоник модель. Әгәр беренче иҗектә иренләшмәгән алгы рәт сузыклары [ә], [и], [е] булса, калган иҗекләрдә [ә], [е], [ү], [и] сузыклары кулланыла ала: *ә-ни-ем, эш-ли, ип-тәш-лә-ре, эз-лә-нү-ләр* һ.б.

Дүртенче сингармоник модель. Беренче иҗектә иренләшкән алгы рәт сузыклары [ө], [ү] булса, калган иҗекләрдә [ә], [ү], [и], [ө], [е] килә ала: *үр-дәк, ү-ке-нү, ө-лөш-ләп, ү-тә-ми, өз-ми* һ.б.

Татар телендәге сузыклар гармониясен, ягъни сузыкларның сингармоник модельләрен түбәндәге таблицада күрсәтергә була:

| Сингармоник модель | Сүзнең беренче иҗеге | Калган иҗекләр |
|---|---|---|
| 1 | а, ы | а, ы, у |
| 2 | о, у | а, ы, у, о |
| 3 | ә, е, и | ә, е, ү, и |
| 4 | ү, ө | ә, е, ү, и, ө |

Һәрбер модельдә берәр: а) иренләшмәгән киң сузык [а], [ә]; б) иренләшмәгән урта күтәрелеш сузыгы [ы], [е]; в) иренләшкән тар сузык [у], [ү] бар. Димәк, татар телендә өч сузык морфонеманы аерып алырга була:

1) иренләшмәгән киң морфонема (а – ә); 2) иренләшмәгән ярымтар морфонема (ы – е); 3) иренләшкән тар морфонема (у – ү).

Бу морфонемалар тамыр яки нигезгә барлык төр аффикслар ялганганда диярлек барлыкка килә: *-лар/-ләр, -а/-ә, -да/-дә, -мы/-ме, -ар/-әр* һ.б.: *кыз-лар, күз-ләр, урман-да, ил-дә, ул-мы, без-ме.* Морфонема составындагы фонемалар чиратлашудан сүзләрнең ни лексик,

ни грамматик мәгънәләре үзгәрми. Бу өч морфонема – универсаль, алар бар төрле диярлек морфологик үзгәрешләр вакытында да реаль хәрәкәттә. Алардан башка татар телендә тагын берничә төрле сузык морфонема ясала: болары аерым сүз төркемнәрендә, аерым бер грамматик формалар ясалганда гына барлыкка киләләр.

(ы – е – о – ө – Ø). Бу морфонема да татар телендә шактый актив, ул түбәндәге очракларда ясала:

1) исемнәргә тартым кушымчалары ялганганда: *кыр+ым=кырым, тел+ем=телем, кот+ом=котом, көн+өм=көнөм, ата+м=атам.*

Морфонемага берләшүче сузык фонемалар аффикслар составында тамыр, нигезнең сузыкларына бәйле рәвештә чиратлаша;

2) фигыль нигезләрдән *-ыш*/*-еш*/*-ш* аффикслары ярдәмендә исемнәр ясалганда, бу морфонеманың сузыклары бер-берсен алыштыралар: *утыр+ыш=утырыш, күрен+еш=күренеш, борол+ош=боролош, төзөл+өш=тәзөлөш* һәм *кара+ш=караш* (соңгы мисалда, югарыдагысы шикелле, аффикста нуль фонема сузыкка беткән нигез составында);

3) (ы – е – о – ө – Ø) морфонемасы хәл фигыль һәм инфинитив формалары ясалганда да барлыкка килә: *сора+п=сорап, ал+ып=алып, бел+еп=белеп, тор+оп=тороп, төр+өп=төрөп һәм ал+ырга=алырга, бел+ергә=белергә, тор+орга=торорга, төр+өргә=төрөргә, сора+рга=сорарга* һ.б. Бу морфонеманың ясалу сәбәпләре – рәт һәм ирен гармониясендә, шулай ук телнең ике сузык янәшәлегеннән качарга омтылуында.

(а–ә–ы–и). Бу сузык морфонема бары тик фигыльләрдә генә – хәзерге заман хикәя фигыль формалары һәм хәзерге заман сыйфат фигыль ясалганда барлыкка килә: *тор+а=тора, бел+ә=белә, уйла+ый=уйлый, эшлә+и=эшли;* шулай ук *торасы, беләсе, уйлыйсы, эшлисе* һ.б.

(а – ә – ы – е – ө – о). Морфонема шулай ук фигыльләрдә, мәсәлән, йөкләтү юнәлеше формалары барлыкка килгәндә, ясала: *кайт+ар=кайтар, үт+кәр=үткәр, оч+ор=очор, төш+өр=төшөр, сат+тыр=саттыр, кис+тер=кистер* һ.б. Күргәнебезчә, бу аффикслар составында сузык һәм тартык фонемаларның да чиратлашуы бергә бара.

(а – ә – Ø). Морфонема исемнәрдән фигыльләр ясалганда, *-ар*/*-әр*/*-р* аффиксларында чиратлашучы сузыкларны берләштерүче берәмлек булып барлыкка килә: *ак+ар=агар, яшь+әр=яшәр, яхшы+р=*

*яхшыр.* Сузык фонемаларның чиратлашуы биредә дә нигездәге сузыкларның рәтенә һәм соңгы авазның характерына бәйле.

(у – а) морфонемасы *ул* алмашлыгының төрле формалары ясалганда күзәтелә: *ул+ның=аның, ул+дай=андый;* әйтеп үтелгәнчә, алмашлыклар составындагы бу чиратлашулар тарихи үзгәрешләр нәтиҗәсе булып бәяләнә, (у–а) морфонемасы *аксак* сүзеннән редупликация юлы белән *аксак-туксак* сүзе ясалганда да аерымлана. Ике мисалда да, бу морфонемадан тыш, башка төр морфологик күренешләр күзәтелә.

(у – о) морфонемасының ясалуы татар телендә шулай ук бик чикләнгән: морфонема ул,*бу* алмашлыкларының төрле формаларында барлыкка килә: *ул+га=моңа, бу+ны=моны, бу+дай=мондый.* Соңгы мисалда аффикс составындагы сузыклар чиратлашуы нәтиҗәсе булып, тагын бер сузык морфонема (а – ы) барлыкка килә. (а – ы) чиратлашуы редупликация юлы белән ясалучы аваз ияртемнәрендә дә күзәтелә: *шарык-шырык, шатыр-шытыр* һ.б.

Димәк, татар телендә берничә төрле сузык морфонема ясала. Аларның берничәсе (а – ә), (ы – е) универсаль: барлык сүз төркемнәрендә диярлек һәм аларның формаларында барлыкка килә, бу морфонемалар татар вокализмының иң зур закончалыгы – сингармонизм белән бәйләнгән; икенче төрле морфонемалар (а – ә – ы – и), (а – ә – Ø) – аерым сүз төркемнәрендә, аерым грамматик формалар ясалганда барлыкка килә, аларның ясалышы татар теленең фонетик структурасына бәйле; өченчеләре исә – индивидуаль чиратлашулар нәтиҗәсе булып тора – бер сүз төркеме өчен генә характерлы (мәсәлән, алмашлыклардагы сузыкларның үзгәрешләре). Шунысы игътибарга лаек: татар телендә сузыклар сүзләрнең тамырында да, аффикслар составында да чиратлаша, тамырдагы сузыклар алмашынуы күбрәк тарихи сәбәпләр белән аңлатылса, аффикслардагы чиратлашулар телнең фонетик закончалыклары белән бәйләнгән.

**Тартык морфонемалар.** Татар телендәге тартык морфонемалар саны сузыкларныкыннан шактый күп. Бу аңлашыла да, чөнки телдә тартык фонемаларның саны да сузыклардан күпкә зуррак. Димәк, чиратлашу, алмашыну мөмкинлекләре дә тартыкларда күбрәк дигән сүз. Чиратлашуларда морфемаларның регрессив һәм прогрессив тәэсир итешүләре ачыклана: янәшә торган фонемаларның беренчесе аннан соң килә торган фонемага тәэсир итә һәм киресенчә.

Татар телендә тартык морфонемалар барлыкка килү дә морфемалар җөендә күзәтелә – морфемалар азагында һәм аффиксларның беренче фонемаларында.

Морфемалар азагында (тамыр, аффикслар ахырында) телдә түбәндәге чиратлашулар игътибарга лаек: (қ – г), (к – г), (п – б), (с – з), (ч – ж), (к – қ), (г – ғ), (н – ң), (н – м), (ң – м), (лг – ң), (нг – ң).

(қ – ғ), (к – г), (п – б) морфонемаларындагы яңгырау алломорфоннар фигыль тамырларга хикәя фигыльнең хәзерге заман, киләчәк заман формалары, хәзерге заман сыйфат фигыль, *-ып* ка беткән хәл фигыль, исем фигыль формаларын ясаучы аффикслар ялганганда очрый: *ақ+а=аға, ақ+ачак=ағачак, ақ+учы=ағучы, ақ+ып=ағып, ақ+у=ағу; тап+а=таба, тап+ачак=табачак, тап+учы=табучы, тап+ып=табып, тап+у=табу* һ.б.

Шул ук фонемаларның чиратлашуы исемнәрдә – исем тамырларга тартым кушымчалары ялганганда һәм сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе формалары ясалганда бара: *тап+ы=табы, уқ+ы=уғы, ақ+рақ=ағрақ, чирек+е=чиреге, сирәк+рәк=сирәгрәк* (тешле тарак) һ.б.

Исемнәрдә шушы ук позициядә – интервокаль һәм сузык белән сонант арасында – [ч] һәм [ж], [с] һәм [з] чиратлашулары күзәтелә: *тач+ы=тажы, тис+рәк=тизрәк.* (с–з) морфонемасы фигыльләрдә II зат күплек сан аффиксларының азагында да ясала: *бардыгыс+мы=бардыгызмы, беләсес+ме=беләсезме,* ягъни *-мы/-ме* сорау кисәкчәсе ялганганда, саңгырау [с] булып ишетелүче [з] фонемасы үзе кулланыла.

(қ – к) морфонемасы исә тамыр, аффиксларның азагында, сузыкларның рәтенә бәйле рәвештә чиратлашучы тартык фонемаларны берләштерә: *бар+дық=бардық, бел+дек=белдек, тара+қ=тарақ, күрә+к=күрәк* һ.б.

(н – ң) морфонемасы [н] фонемасына беткән исем һәм фигыль тамырларга [н], [к], [ғ], [г] ларга башланган аффикслар ялганганда барлыкка килә: *әни+кәй=әнкәй, кун+ған=куңған, мен+гән=меңгән* һ.б.

(н – м) морфонемасына берләшүче фонемалар чиратлашуы исем һәм фигыль сүз төркемнәрендә бара. Фигыльләрдә, мәсәлән, [н] га беткән тамырларга [м]га башланган аффикслар ялганганда, [м] фонемасы кулланыла: *кун+мый=куммый;* шундый ук күренеш исемнәрдә дә – *тун+мы=туммы;* (н – м) чиратлашуы, кушма саннар ясалганда да,

шул ук позициядә күзәтелә: *ун+биш=умбиш, ун+меӊ= уммеӊ*. Әйтергә кирәк: язма әдәбиятта ике төрле вариант та кулланышта йөри: *унмеӊ – уммеӊ, унбиш – умбиш,* ихтимал, язылышның бер генә вариантын норма итеп тану кулайрактыр.

(н – м) һәм (н – ӊ) морфонемаларының барлыкка килүенә сәбәп булып, өлешчә яки тулы, регрессив, контактлы ассимиляция күренеше тора. Кайбер алмашлыклар составындагы шушы ук фонемалар чиратлашуы исә тарихи үзгәрешләр, чиратлашулар нәтиҗәсе: *мин+га= миӊа, син+га=сиӊа.*

Фамилияләр ясаучы аффикслар ахырында чиратлашып килгән фонемалар (ф – в) морфонемасына берләшә: *Галиеф+а=Галиева, Сабироф+а=Сабирова* ([в] фонемасы хатын-кыз фамилияләрен ясаучы аффикс составында). Күргәнебезчә, бу чиратлашу язуда чагылыш тапмый, сөйләм варианты булып кына кала.

Алмашлыкларга килгәндә, биредә тагын бер-ике чиратлашуга игътибар итәргә кирәк: *ул+га=аӊа, шул+га=шуӊа, шул+ны=шуны, ул+ны= аны* һ.б. (лг – ӊ), (л – Ø) чиратлашулары да тарихи чиратлашулар, ахыр чиктә, телнеӊ фонетик закончалыкларының үсеше белән аӊлатыла.

(қ – к – ғ – г) һәм (д – т) морфонемалары күпмедер дәрәҗәдә универсаль; алар исем һәм фигыльләрдәге аффикслар башындагы чиратлашучы фонемалар берлеген хасил итә: *яз+ғы=язгы, күз+ге=күзге, кыш+қы=кышқы, кич+ке=кичке,* ягъни исемнәрдән сыйфат ясаучы аффикслар һәм сыйфатларның кимлек дәрәҗәләрен ясаучы аффикслар *-ғылт/-қылт/-қылт/-келт* составында һ.б., мәсәлән, *сары+ғылт= сарғылт, ачы+қылт=ачқылт, төче+келт=төчкелт* һ.б. Шушы ук морфонемалар фигыль формаларында да ясала: *ат+қан=атқан, кит+ кән=киткән, бар+ған=барған, бел+гән* һ.б.

(д – т) морфонемасының фонемалары да бик күп формаларда чиратлашып килә. Мәсәлән, нигезнеӊ соӊгы авазына бәйле рәвештә билгеле үткән заман формасын ясаучы аффиксларның башында: *кара+ ды=карады, чык+ты=чыкты;* исемнәрдә һәм исемнәрдән рәвеш ясаучы аффиксларда: *юл+даш=юлдаш, як+таш=якташ, ат+тай= аттай, гөл+дәй=гөлдәй; ут+тыр=уттыр, ул+дыр=улдыр;* шулай ук кисәкчәләрдә: *яз да..., ат та...* һ.б.

Аффикслар башында ясалучы кайбер тартык морфонемаларның кулланылу даирәсе тар, алар бары аерым бер сүз төркемендә генә

барлыкка киләләр; андый чиратлашулар күбрәк исемнәрдә һәм алмашлыкларда очрый.

(ҡ – к – ғ – г – н – Ø) морфонемасы составындагы фонемалар, мәсәлән, исемнәрнең юнәлеш килеш формасында чиратлашып киләләр: *ат+ҡа=атҡа, эт+кә=эткә, кул+ға=кулға, гөл+гә=гөлгә, улы+на= улына* һәм *балам +а=балама.* Тартыкка беткән тартым кушымчасы булган исемгә ялганган килеш кушымчасына нуль тартык фонема ялгана. Башка фонемаларның чиратлашуында нигездәге сузыкларның рәте, тартыкларның яңгырау-саңгырау булуы зур роль уйный.

(т – д – н – нн) морфонемасы исемнәрнең чыгыш килеш формасы аффиксларында барлыкка килә: *-тан/-дан/-нан/-ннан* кушымчаларындагы тартыклар нигезнең соңгы авазларына бәйле рәвештә чиратлашалар: *ат+тан=аттан, кул+дан=кулдан, урман+нан=урманнан, баласы+ннан=баласыннан.* [нн] алломорфоны сузыкка бетүче тартым кушымчасы булган исемнең килеш формасында кулланыла.

(т – д – нд) морфонемасы да исемнәрнең бер генә формасында – урын-вакыт килеше кушымчалары составында барлыкка килә: *ур-ман+да=урманда, ут+та=утта, баласы+нда=баласында.* Соңгы алломорфон [нд] шулай ук сузыкка беткән тартым кушымчасы булган исем составында күзәтелә.

(л – н) морфонемасы күплек сан кушымчалары составында ясала, [л] һәм [н] чиратлашуы исем, фигыльләрдә бер үк фонетик закончалыкны чагылдыра: борын авазларына беткән сүзләргә [н] га башланган аффикс ялгана: *кул+лар=куллар, ком+нар=комнар, тун+нар=туннар; барган+нар=барганнар, килгән+нәр=килгәннәр* һ.б.

Димәк, татар телендәге тартык морфонемалар, сузык морфонемалар кебек үк, берничә төрле була. Аларның кайберләре (к – г), (ҡ – ғ), (п – б) берничә сүз төркемендә, билгеле бер фонетик шартларда ясала; икенчеләре (т – д – нд) бары бер сүз төркемендә, әмма аның берничә формасында барлыкка килә; өченчеләре исә аерым бер грамматик форма өчен генә характерлы (к – м). Тартык фонемаларның чиратлашулары ассимиляциянең төрләренә, шулай ук кайбер тарихи үзгәрешләргә бәйле. Тартык морфонемалар бигрәк тә исем һәм фигыль сүз төркемнәрендә еш барлыкка килә; алар морфемалар азагында һәм аффикслар башында чиратлашучы тартык фонемаларны берләштерәләр. Татар телендә шактый күп тартык морфонемалар редупликация вакы-

тында күзәтелә (редупликация шулай ук сузык фонемаларның чиратлашуына да мисал булып тора).

**Редупликация вакытында морфонологик күренешләр.** Татар теленең морфологик структурасында редупликация юлы белән ясалган сүзләр аерым урын алып тора. Сүзләрнең кабатлануы нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа сүзләр составындагы бу чиратлашуларның морфонологик характеры бәхәс тудырмый, чөнки чиратлашу-үзгәрешләр нәкъ менә морфемалар хәрәкәте, аларның янәшәлеге белән бәйләнгән. Сүзләрнең составында редупликация вакытында бара торган чиратлашуларны аерым карау, өйрәнү максатка ярашлы. Беренчедән, бу чиратлашу-үзгәрешләр башка грамматик формаларда бөтенләй очрамый, ягъни алар типик характерда түгел, ә бик индивидуаль, икенчедән, редупликация вакытында ,сузык һәм тартык морфонемалардан тыш, бөтенләй яңа төрле морфонема (без аны «катнаш морфонема» дип атадык) барлыкка килә.

Редупликация вакытында ясала торган сузык морфонемалар арасыннан түбәндәгеләрне аерып алырга була:

(а – о). Бу фонемаларның чиратлашуы аваз ияртемнәрендә: *шак+шак=шак-шок;* исемнәрдә: *карчык+карчык=карчык-корчык;* рәвешләрдә: *ашык+ашык=ашык-пошык* һ.б.;

(и – о). Исемнәрдә: *им+им=им-том; тимер+тимер=тимер-томыр; рәвешләрдә: кирле+кирле=кирле-морлы*;

(ә – ө). Рәвешләрдә: *әштер+әштер=әштер-өштер; әпен+әпен=әпен-төпен*;

(е – а) морфонемасы да беренче иҗектәге сузыклар чиратлашуы нәтиҗәсендә барлыкка килә: *черек+черек=черек-чарык* һ.б.

Редупликация вакытында шактый күп санда тартык морфонемалар да барлыкка килә:

(к – м) – исемнәрдә, сыйфатларда, рәвешләрдә ясала: *китап+ китап=китап-митап; кирле+кирле=кирле-морлы; күк+күк=күм-күк* һ.б.

(с – м) морфонемасы сыйфатларда һәм рәвешләрдә: *сырлы+сырлы=сырлы-морлы; сирәк+сирәк=сирәк-мирәк*;

(т – м): исемнәрдә, сыйфатларда: *тиле+тиле=тиле-миле;*

(т – б) морфонемасы аваз ияртеменнән кушма фигыль ясалганда: *тыз+тыз=тыз-быз* (*килү);*

(б – с) шулай ук рәвешләрдә: *берән+берән=берән-сәрән* һ.б.

Югарыдагы мисалларда фонемаларның «чиста» чиратлашулары да, сузык һәм тартык фонемаларның чиратлашуы бергә баруы да күренә. Башка төрле морфонологик күренешләр, әйтик, асемантикфонема ялгану редупликация вакытында шулай ук еш очрый. Биредә дә асемантик фонема ролендә тартык фонемалар кулланыла. Икенче төрле әйткәндә, сүзләрнең кабатлануы нәтиҗәсендә яңа сүзләр барлыкка килгәндә, кабатлауның икенче компонентының башында «артык» бер тартык фонема пәйда була. Морфонологик күренеш буларак асемантик фонема ялгану гадәттә морфема җөендә – нигез белән аффикс арасында бара; редупликация вакытында исә андый фонема кабатлауның икенче компонентының беренче фонемасы булып ялгана.

(Ø – м). Бу морфонема исемнәрдә, сыйфатларда, аваз ияртемнәрендә шактый еш очрый: *уен+уен=уен-муен; имеш+имеш=имеш-мимеш; иләс+иләс=иләс-миләс; ык+ык=ык-мык* (*итү*), *эңгер+эңгер+эңгер-меңгер* һ.б.;

(Ø – т): исемнәрдә, рәвешләрдә: *аксак+аксак=аксак-туксак; ал-пан+алпан=алпан-тилпән; әвеш+әвеш=әвеш-тәвеш*;

(Ø – п): *ашык+ашык=ашык-пошык; артык+артык=артык-портык*;

(Ø – ч): исемнәрдә: *әби+әби=әби-чәби;*

(Ø – з): *ыгы+ыгы=ыгы-зыгы* (килү);

(Ø – ж): *эге+эге=эге-җөге* (килү) шулай ук аваз ияртемнәреннән фигыльләр ясалганда һ.б.

Редупликация юлы белән сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе ясалганда, яңа типтагы морфонема барлыкка килә. Биредә бер үк вакытта ике морфонологик күренеш бара: беренче компонентның соңгы өлеше йотыла һәм нигезнең киселгән бу өлешенә яңа фонема килеп ялгана, ягъни (ФФ – Ф), (ФФФ – Ф) тибындагы морфонема барлыкка килә.

(ры – п): *сары+сары=сап-сары; туры+туры=туп-туры*;

(ра – п): *кара+кара=кап-кара*;

(рт – п): *карт+карт=кап-карт*;

(шел – м): *яшел+яшел=ямь-яшел*;

(за – п): *таза+таза=тап-таза*;

(рес – п): *дөрес+дөрес=дөп-дөрес.*

Ә бу мисалда исә асемантик фонема ялгануның «классик» варианты: *чи+чи=чип-чи* (*ялган*).

Бу морфонемалардан тыш редупликация вакытында фонемалар комплексының башка бер фонемалар комплексы белән чиратлашуы да очрый, ягъни (ФФ – ФФ) тибындагы морфонемалар барлыкка килә. Мәсәлән, *каршы+каршы=капма-каршы*: (ршы – пма); *ялгыз+ялгыз= япа-ялгыз*: (лгыз – па); *көндез+көндез=көпә-көндез:* (ндез – пә) һ.б.

Шулай итеп, татар телендә редупликация вакытында барлык төр морфонологик күренешләр дә очрый. Сүзләрнең фонемалар составындагы үзгәрешләрне берничә төрлегә бүлеп карарга була:

1) беренче иҗектәге сузык фонемалар чиратлаша: *шарт-шорт;*

2) беренче һәм икенче иҗектәге сузыклар да алмашына: *черек-чарык, тимер-томыр;*

3) беренче тартык фонемалар чиратлаша: *малай-салай, сирәк-мирәк;*

4) кабатлауның икенче компоненты башында асемантик фонема барлыкка килә: *ыбыр-чыбыр, ыгы-зыгы;*

5) асемантик фонема ялгану бер үк вакытта сузыкларның чиратлашуы белән бергә бара: *им-том, аксак-туксак;*

6) өч яклы чиратлашу, ягъни беренче тартык фонемалар, беренче һәм икенче сузыкларның бергә чиратлашуы: *кирле-морлы;*

7) сүздәге фонемалар комплексы икенче бер фонемалар комплексы яки бер фонема белән чиратлаша: *сап-сары, капма-каршы* һ.б.

Мондый төр чиратлашулар вакытында төрле сандагы фонемалар катнаша: ике ((ра – п), *кап-кара*)*;* өч ((рес – п), *дөп-дөрес*)*;* дүрт ((мәхә – п), *шәп-шәмәхә*)*;* биш ((раңгы – п) *кап-караңгы*). Ялганучы асемантик фонемалар арасында [п], [м] фонемалары бик актив. Бу авазлар бик җиңел әйтелә, өстәмә артикуляция таләп итми; ихтимал, телдәге традицион фактор да билгеле бер роль уйный торгандыр.

Әлбәттә, мондый кабатлаулардан торган сүзләр аерым бер стиль, хис-тойгы белдерү, бәя бирү чарасы да булып тора. Әлеге бүлеккә бәйле рәвештә исә, мондый мисалларны кызыклы морфонологик модельләр яссылыгында гына карыйбыз.

Татар телендәге бу кызык күренеш (кабатлануларның төрле вариантлары еш кулланылу), мисаллардан күренгәнчә, рус теленә дә йогынты ясый. Сөйләм телендә русча да бүген мондый кабатлануларны еш очратып була: *фрукты-мрукты, танцы-манцы, такси-макси, колбаса-молбаса* һ.б. Рус телендәге бу мисаллар төрле генеалогик тарихлы, төрле гаиләдәге телләрнең дә бер-берсенә якынаерга омтылуына

мисал булып тора, чөнки бу сүзләрдә эмоциональлек, экспресссивлык, интенсивлык категорияләре дә чагылыш таба. «Телләр берлеге» (языковой союз) төшенчәсе, шулай итеп, үзен яңа төрле формаларда, мисалларда күрсәтә ала.

**Татар телендәге морфонемаларның төрләре.**

1. Чиратлашучы фонемаларның төп дифференциаль билгеләре ясылыгында караганда, морфонемаларның өч төрен күрсәтергә була:

1) сузык морфонемалар (а – ә), (у – о), (а – ә – Ø) һ.б.;

2) тартык морфонемалар (қ – ғ), (к – г), (п – б), (м – с) (с – м) һ.б.;

3) катнаш морфонемалар (бәр – п), (за – п), (шел – м) һ.б.

2. Чиратлашуларның төп сәбәпләре күзлегеннән караганда, ике төр группа морфонемалар аерылып тора: 1) хәзерге татар әдәби теленең фонетик структурасы, орфоэпик нормалары, аваз үзгәрешләре белән аңлатыла торган чиратлашулардан торучы морфонемалар; 2) сүзләр составындагы тарихи чиратлашу-үзгәрешләр нәтиҗәсе булган морфонемалар. Беренче группа морфонемалар телдә шактыйга күбрәк, димәк, татар телендәге зур күпчелек морфонемалар фонетик берәмлекләрнең морфологик процесслар вакытындагы тәэсир итешүләре, бер-берсенә йогынтысы нәтиҗәсе булып тора.

3. Морфонемаларның структурасы ягыннан аларны берничә төргә бүлеп була:

1) фонема – фонема, ягъни (Ф – Ф): (а – ә), (к – г);

2) нуль фонема – фонема, ягъни (Ø – Ф): (Ø – ғ), (Ø – й);

3) фонема – нуль фонема, ягъни (Ф – Ø): (ы – Ø), (н – Ø);

4) фонемалар комплексы – фонема, ягъни (ФФ – Ф): (ры – п), (за – п);

5) фонемалар комплексы – нуль фонема, ягъни (ФФ – Ø): (лы – Ø), (ры – Ø);

6) фонемалар комплексы – фонемалар комплексы, ягъни (ФФ – ФФ): (лгыз – па), (ндез – пә);

7) сирәк очрый торган тагын бер модель бар: аваз – аваз, ягъни (А – А). Бу морфонема сөйләм телендә генә очрый һәм сүздәге беренче [а] авазының иренләштерелеп әйтелүе яки соңгы [у], [ү] фонемаларының дифтангоид характеры белән бәйләнгән. Мәсәлән, *та$^{о}$ба+лар=та$^{о}$ба$^{о}$лар,* биредә (а – а$^{о}$) яки *ку$^{w}$+а=кywа,* ягъни (у$^{w}$ – уw).

4. Морфонемаларның позицион чагылышы буенча караганда, берничә төрен аерырга була: 1) бер морфема эчендә чиратлашулар нәти-

җәсе булган морфонемалар: (ы – Ø), *халык – халкы;* 2) морфемалар җөендәге чиратлашулар: (ы – Ø), *ачы+кылт=ачкылт;* 3) ике сүз уртасында, ягъни сүзләр кушылган урында баручы чиратлашуларның нәтиҗәсе булган морфонемалар: (ы – Ø), *сары+ут=сарут;*(а – Ø), *алма+ агач=алмагач.* Мисаллардан күренгәнчә, (ы – Ø), (е – Ø) морфонемалары һәр өч позициядә дә ясала. Димәк, [ы] һәм [е] сузыкларының редукциягә омтылышы – татар вокализмының төп үзенчәлекләреннән берсе.

*1 нче таблица*

Татар телендә төрле сүз төркемнәрендә морфологик күренешләр

| Сүз төркемнәре | Морфонологик күренешләр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | нигез кыскару | фонемалар чиратлашу | асемантик фонема ялгану | фонемалар керешү | редупликация вакытында морф. күр. |
| исем | + | + | + | + | + |
| сыйфат | + | + | – | – | + |
| сан | + | + | + | – | – |
| алмашлык | + | + | – | + | – |
| фигыль | + | + | + | – | + |
| рәвеш | – | + | + | – | + |
| ярдәмлек сүз | – | + | – | – | – |
| аваз ияртемнәре | + | + | + | – | + |

*2 нче таблица*

Морфонологик күренешләрнең позицион чагылышы

| Чиратлашу бара торган позиция | Морфонологик күренешләр | | | |
|---|---|---|---|---|
| | нигез кыскару | асемантик фонема ялгану | фонемалар керешү | фонемалар чиратлашу |
| морфема эчендә | + курык – курка | – | – | + бу – моңа |
| морфемалар арасында | + ачы – ачкылт | + җиде – җидешәр | + мин – мине | + тап – таба |
| сүзләр арасында | + сары ут – сарут | + ни ала – ни$^{й}$ала | + алма агач= алмагач | + халык ара= халыгара |

*3 нче таблица*

## Морфонологик күренешләр вакытында барлыкка килгән морфонемалар модельләре

| Морфонемаларның модельләре | Морфонологик күренешләр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | нигез кыскару | фонемалар чиратлашу | асемантик фонема ялгану | фонемалар керешү | редупликация вакыт. |
| (Ф–Ф) | – | + | – | – | + |
| (Ф–Ø) | + | – | – | + | – |
| (ФФ – Ø) | + | – | – | – | – |
| (Ø–Ф) | – | – | + | – | + |
| (ФФ – Ф) | + | + | – | + | + |
| (ФФ – ФФ) | – | + | – | – | + |

*4 нче таблица*

## Морфонологик күренешләр вакытында барлыкка килгән морфонемалар

| Морфонема модельләре | Морфонологик күренешләр | | | |
|---|---|---|---|---|
| | нигез кыскару | асемантик фонема ялгану | фонемалар керешү | фонемалар чиратлашу |
| аваз – аваз | | – | – | та$^{о}$ба+да=<br>та$^{о}$ба$^{о}$да (а$^{о}$ – а) |
| фонема – фонема | – | – | | кыз-лар<br>он-нар (л – н) |
| нуль фонема – фонема | – | кар-ҡ-ылда<br>(Ø – ҡ) | – | бал-ы бала-с-ы<br>(Ø – с) |
| фонема-нуль фонема | курык –<br>курка<br>(ы – Ø) | – | син-нең<br>синең<br>(н – 0) | ат-ып<br>ата-п<br>(ы – 0) |
| фонемалар комплексы – фонема | йомры+<br>йомры=<br>йоп-йомры<br>(мры – п) | – | – | кара+кара=<br>кап-кара<br>(ра – п) |
| фонемалар комплексы – нуль фонема | алып кит =<br>апкит<br>(лы – Ø) | – | – | – |

*5 нче таблица*

Морфонемаларны чиратлашу сәбәпләре буенча классификацияләү

| Морфонема | Барлыкка килү сәбәбе | | |
|---|---|---|---|
| | сөйләмдәге аваз үзгәрешләре | тарихи үзгәрешләр | очраклылык күренешләре |
| сузык морфонема | ал-ып, кил-еп, тот-оп, көт-өп, сора-п (ы – е – о – ө – Ø) | ул-га > аңа (у – а) бу-га > моңа (у – о) | көл-әр, кил-ер (ә – е); яз-ар, бар-ыр (а – ы) |
| тартык морфонема | ак-а > ага (қ – ғ) тап-ы > табы (п – б) | шул-га > шуңа (лг – ң) мин-га > миңа (нг – ң) | – |
| катнаш морфонема | алып куй > апкуй (лы – Ø) | ялгыз-ялгыз > япа-ялгыз (лгыз – па) | – |

*6 нчы таблица*

Татар теленең сузык морфонемалары

| Модель | Морфонема | Исем | Сыйфат | Алмашлык | Сан | Фигыль | Рәвеш | Аваз иярт. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Ф – Ф | (а – ә) | + | + | + | + | + | + | + |
| | (ы – е) | + | + | + | + | + | + | + |
| | (у – ү) | + | + | – | – | + | – | – |
| | (у – о) | – | – | + | – | – | – | – |
| | (а – ы) | – | – | + | – | – | – | + |
| | (у – а) | – | – | + | + | – | – | – |
| | (ә – ө) | – | – | – | – | – | + | + |
| | (у – а) | + | – | – | – | – | – | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (ә – о) | + | – | – | – | – | – | – |
| | (ы – у) | – | + | – | – | – | – | + |
| | (и – о) | + | – | – | – | – | – | – |
| | (ы – а) | + | – | – | – | – | – | + |
| | (а – у) | + | – | – | – | + | – | – |
| | (а – и) | – | – | – | – | – | + | – |
| | (е – а) | + | – | – | – | – | + | – |
| | (а – ы) | – | – | – | – | – | – | + |
| | (о – а) | + | – | – | – | – | – | + |
| | (а – о) | + | – | – | – | – | + | + |
| Ф – Ф – Ф | (а – ы – ә – е) | – | + | – | – | + | – | – |
| | (а – э – ы – и) | – | – | – | – | + | – | – |
| Ф – Ф – Ø | (а – ә – Ø) | – | – | – | – | + | – | – |
| | (ы – е – Ø) | – | – | – | – | + | – | – |
| | (а – ә – о – ө – ы – е – Ø) | – | – | – | – | + | – | – |
| | (ы – е – о – ө – Ø) | + | – | – | – | + | – | – |
| Ф – Ø | (и – Ø) | + | – | – | – | – | – | – |
| | (ы – Ø) | + | + | – | + | + | + | – |
| | (е – Ø) | + | + | – | + | + | + | – |
| | (а – Ø) | + | – | – | – | + | – | – |
| | (ә – Ø) | + | – | – | – | + | – | – |
| Ø – Ф | (Ø – ы) | + | | – | – | – | – | – |
| | (Ø – и) | + | – | – | – | – | – | – |

*7 нче таблица*

Татар теленең тартык морфонемалары

| Модель | Морфонема | Исем | Сый-фат | Ал-маш-лык | Сан | Фи-гыль | Рәвеш | Аваз иярт. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Ф – Ф | (қ – ғ) | + | + | | + | + | + | + |
| | (қ – г) | + | + | | + | + | + | + |
| | (қ – к) | + | + | + | + | + | + | + |
| | (п – б) | + | + | | + | + | + | + |
| | (л – н) | + | | + | + | + | + | + |
| | (д – т) | + | + | | + | + | + | + |
| | (ф – в) | + | | | | | | |
| | (с – з) | + | + | | | + | | |
| | (з – с) | + | + | | | + | | |
| | (н – м) | | | | + | + | | |
| | (н – ң) | + | | + | | | | |
| | (ң – м) | | | + | | | | |
| | (р – з) | | | | | + | | |
| | (к – м) | + | + | | | | | + |
| | (ш – п) | | + | | | | | + |
| | (ч – ж) | + | | | | + | | |
| | (н – п) | + | | | | | + | |
| | (к – т) | + | | | | | + | |
| | (б – с) | | | | | | + | |
| | (ч – б) | + | | | | | + | |
| | (ч – м) | | | | | | + | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (ш – м) | + | | | | | | |
| | (т – п) | | | | | | + | + |
| | (к – п) | | | | | | | + |
| | (с – м) | | + | | | | + | |
| | (м – с) | + | | | | | | + |
| | (т – м) | | + | | | | | |
| | (р – п) | | + | | | | + | |
| | (ң – к) | | | | | | + | |
| | (ч – п) | | | | | | | + |
| Ф – Ф – Ф | (қ – к – ғ – г) | + | + | | | + | + | |
| | (т – д – нд) | + | | | | | | |
| | (нг – ң) | | | + | | | | |
| | (лг – ң) | + | | + | | | | |
| Ф – Ф – Ø | (қ – к – ғ – г – Ø) | + | | | | | | |
| Ø – Ф | (Ø – т) | + | | | | | + | |
| | (Ø – б) | + | | | | | | |
| | (Ø – ж) | | | | | + | | + |
| | (Ø – к) | | | | | + | | + |
| | (Ø – қ) | | | | | + | | + |
| | (Ø – г) | | | | | + | | + |
| | (Ø – ғ) | | | | | + | | + |
| | (Ø – ң) | | | | | + | | |

*8 нче таблица*

Сузык һәм тартык фонемалар комплексыннан торган морфонемалар

| Модель | Морфонема | Исем | Сый-фат | Ал-маш-лык | Сан | Фи-гыль | Рәвеш | Аваз иярт. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| ФФ – Ф | (лы – п) | | + | | | + | | |
| | (ры – п) | | + | | | | + | |
| | (ди – п) | | + | | | | + | |
| | (гез – п) | | + | | | | + | |
| | (рес – п) | | + | | | | + | |
| | (за – п) | | + | | | | | |
| | (шел – м) | | + | | | | + | |
| | (ңгәр – п) | | + | | | | + | |
| | (мәхә – п) | | + | | | | + | |
| | (зыл – п) | | + | | | | + | |
| | (раңгы – п) | | + | | | | + | |
| | (бәр – п) | | + | | | | | |
| | (гәрәк – п) | | + | | | | + | |
| | (цел – п) | | + | | | | + | |
| | (лы – м) | | + | | | | + | |
| | (мшак – п) | | + | | | | + | |
| | (ты – п) | | + | | | | + | |
| | (гәл – п) | | + | | | | + | |
| | (зын – п) | | + | | | | | |
| | (ска – п) | | + | | | | | |
| | (йнар – п) | | + | | | | | |
| | (лкын – п) | | + | | | | + | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ФФ – Ф | (ндез – пә) | | | | | | + | |
| | (лгыз – па) | | | | | | + | |
| | (ршы – пма) | | | | | | | |
| ФФ – Ø | (лы – Ø) | | | | | | | |
| | (ыл – Ø) | | | | | | | |
| | (ел – Ø) | | | | | | | |

*9 нчы таблица*

Татар теленең морфонемалары
(гомумиләштерелеп бирелә)

| Морфонема | Мисал | Төре | | | | | | | | Күренеш | | | | Сәбәп | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | a | b | c | d | e | f | g | i | j | k | l | m | n | o | p |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| (а – а) | ат-та – эт-тә | + | | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (а$^{о}$ – а) | а$^{о}$ла – а$^{о}$ла$^{о}$лар | + | | + | | | | | | | | | + | + | | |
| (а – ә – ы – и) | ала – элә – уйлый – эшли | + | | | + | | | | | | | | + | + | + | |
| (а – ә – ы – е – о – ө – Ø) | язар – көләр – калыр – бирер – корор – төрөр – укы-р | + | | | + | | + | | | | | | + | + | | + |
| (ы – е – о – ө – Ø) | кырым – илем – оном – көнем – балам | + | | | + | | + | | | | | | + | + | | |
| (у – а) | ул – аңа | + | | | + | | | | | | | | + | | + | |
| (у – о) | бу – моны | + | | | + | | | | | | | | + | | + | |
| (а – о) | карчык – корчык | + | | | + | | | | | | | | + | | + | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| (ҡ – ғ – к – г – н – Ø) | атка – ярга – иткә – илгә – улына – балама | | + | | + | | + | | | | | | + | + | + | |
| (ҡ – ғ – к – г) | кышкы – язгы – кичке – көзге | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (д – т) | карда – атта | | + | | + | | | | | | | | + | + | + | |
| (ҡ – к) | бардык – белдек | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (ғ – г) | алдыгыз – элдегез | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (ҡ – ҡ) | таҡ – тага | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (к – г) | чик – чигә | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (п – б) | кап – каба | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (т – д – н – нн) | аттан – судан – туннан – суыннан | | + | | + | | | + | | | + | | + | + | | |
| (т – д – нд) | атта – суда – суында | | + | | + | | | + | | | + | | + | + | | |
| (н – ң) | әни - әңкәй | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (н – м) | ун - умбер | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (ң – м) | кемнең – минем | | + | | + | | | | | | | | + | | + | |
| (ф – в) | Галиеф – Галиева | | + | | + | | | | | | | | + | + | | |
| (с – Ø) | ата-анасы | | + | | | + | | | | | + | | | | + | |
| (Ø – ҡ) | кар-ҡ-ылда | | + | | | + | | | | | + | | | | + | |
| (н – Ø) | син-синең | | + | | | | + | | | + | | | | | + | |
| (ы – Ø) | утыр – утрау | + | | | | | + | | | + | | | | + | + | |
| (лы – Ø) | алып кит – апкит | | | | | | | | + | + | | | | + | | |
| (зыл – п) | кызыл – кып-кызыл | | | | | | | + | | + | | | | | + | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| (қ – п) | ак – ап-ак | | + | | + | | | | | | | | + | | + | |
| (Ø – г) | зың - ғ- ылда | | + | | | + | | | | | + | | | | + | |
| (Ø – д) | ал – алды | | + | | | + | | | | | + | | | | + | |
| (а – Ø) | таба агач – табагач | + | | | | | + | | | + | | | | + | | |
| (Ø – з) | ыгы-зыгы | | + | | | + | | | | | + | | | | + | |

Искәрмә: a – сузык, b – тартык, c – аваз – аваз, d – фонема – фонема, e – Ø – фонема, f – фонема – Ø, g – фонемалар комплексы – фонема, i – фонемалар комплексы – Ø, j – нигез кыскару, k – асемантик фонема ялгану, 1 – фонемалар керешү, m– фонемалар чиратлашу, n – аваз үзгәрешләре, o – тарихи үзгәреш-чиратлашулар, p – очраклылык күренеше.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: тел белемендә сүзләрнең, сүзформаларның, синтагмаларның морфонологик «партитурасын» өйрәнү дәвам итә, үз чиратында, бу – практик максатка да ярашлы, чөнки татар теленең шактый катлаулы орфограммалары нәкъ менә фонетик-морфологик чараларның бер-берсенә тәэсир итүенең, шул ук вакытта тарихи үзгәрешләр-чиратлашуларның чагылышы.

## ӘДӘБИЯТ


Ахманова О.С. Фонология: Морфонология. Морфология. М.: МГУ, 1966. 108 с.

Бернештейн С.Б. Введение в славянскую морфонологию // ВЯ. 1968. № 4. С. 43–59.

Виноградов В.В. Проблемы морфематической структуры слова и явления омонимии в славянских яхыках // Славянское языкознание. М., 1968. – С. 53–119.

Грамматика современного башкирского языка. М.: Наука, 1981. 495 с.

Джамилов Ф.А. Очерки по морфонологии азербайджанского языка. Баку: АзГУ, 1985. 108 с.

Единицы разных уровней грамматического строя и их взаимодействие. Сб.статей. М.: Наука, 1969. 331 с.

Зәкиев М.З. Морфонология турында // Совет мәктәбе. 1983. № 6. Б. 21–26.

Зәкиев М.З., Салихова Д.Ә. Татар морфонологиясенә кереш. Казан: КДПИ, 1983. 32 б.

Закиев М.З. О тюркской морфонологии // Советская тюркология. 1984. № 1. С. 35–43.

Закиев М.З., Салимова Д.А. Морфонология // Татарская грамматика. Казань: Таткнигоиздат, 1993. Т. 1. С. 160–188.

Золхоев В.И. Фонология и морфонология агглютинативных языков: (особенности функционирования системы фонем). Новосибирск: Наука. Сиб. отд-ние, 1980. 143 с.

Ильина Н.Е. Морфонология глагола в современном русском языке. М.: Наука, 1980. 147 с.

Кайдаров А.Т. Структура односложных корней и основ в казахском языке. Алма-Ата: Наука, 1986. 327 с.

Кубрякова Е.С. Основы морфологического анализа. М.: Наука, 1974. 319 с.

Кубрякова Е.С., Панкрац Ю.Г. Морфонология в описании языков. М.: Наука, 1983. 119 с.

Лаврентьев Г.И. О некоторых морфонологических явлениях в марийском языке // Вопросы марийской диалектологии. Йошкар-Ола, 1981. С. 164–187.

Лопатин В.В. Морфонологические явления в словообразовании // Русская граммтика. Т. 1: Фонетика. Фонология. Ударение. Интонация. Словообразование. Морфология. М.: Наука, 1982. С. 413–452.

Лопатин В.В. Русская словообразовательная морфемика. Проблемы и принципы описания. М.: Наука, 1977. 315 с.

Реформатский А.А. Очерки по фонологии, морфонологии и морфологии. – М.: Наука, 1979. 103 с.

Русская грамматика. 1. AcademiaPraha, 1979. 664 с.

Русская грамматика. 2. AcademiaPraha, 1979. 1093 с.

Русская грамматика. Т. 1: Фонетика. Фонология. Ударение. Интонация. Словообразование. Морфология. М.: Наука, 1982. 783 с.

Русская грамматика. Т. 2: Синтаксис. М.: Наука, 1982. 709 с.

Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге. Казан: Яңалиф, 2004. 192 б.

Салимов Х.Х., Салимова Д.А. Сопоставительная фонетика татарского и русского языков (в таблицах, схемах и упражнениях): учебно-метод. пособие для студентов-филологов. Елабуга: Изд-во ЕГПУ, 2007. 86 с.

Салихова Д.А. Татар телендә морфонологик күренешләр // Совет мәктәбе. 1983. № 9. Б. 22–25.

Салихова Д.А. Учет морфонологических особенностей русского языка в татарской школе // Совет мәктәбе. 1985. № 8. С. 37–39.

Салимова Д.А. Нормативность и вариативность морфонологических явлений в татарском языке // Нормативность и вариативность в татарском языке. Сборник научных статей. Казань: Изд-во КФАН СССР, 1987. С. 24–32.

Салимова Д.А. Наращение основы как морфонологическое явление в русском и татарском языках // Двуязычие: типология и функционирование. Казань: Изд-во КФАН СССР, 1990. С. 82–88.

Сафиуллина Ф.С., Салимов Х.Х., Салимова Д.А. Тел гыйлеменә кереш. Казан: Арт-кафе, 2000. 126 с.

Современный татарский литературный язык: Лексикология. Фонетика. Морфология. М.: Наука, 1969. 380 с.

Современный татарский литературный язык. Синтаксис / автор «Синтаксиса» М.З. Закиев, «Чужой речи» Х.Р. Курбатов). М.: Наука, 1971. 310 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Фонетика. М.: Наука, 1984. 484 с.

Тенишев Э.Р. Строй саларского языка. М.: Наука, 1976. 576 с.

Тенишев Э.Р. Строй сарыг-югурского языка. М.: Наука, 1976. 308 с.

Трубецкой Н.С. Некоторые соображения относительно морфонологии // Пражский лингвистический кружок. М.: Прогресс, 1967. С. 115–118.

Хәзерге татар әдәби теле: югары уку йортлары өчен программа. Тулыландырылган, төзәтелгән 3-басма. Казан: КДПИ, 1982. 44 б.

Чурганова В.Г. Очерк русской морфонологии. М.: Наука, 1973. 239 с.

Юлдашев А.А. Сведения по фономорфологии // Грамматика современного башкирского литературного языка. М.: Наука, 1981. С. 79–87.

Morphology: An International Handbook on Inflection and Word-Formation / Edited by G. Booij, Ch. Lehmann, J. Mugdan. Vol. 1–2. Berlin, New York: Walter de Gruyter, 2000 (Handbooks of linguistics and communication science; 17.1–17.2).

Word-Formation: An International Handbook of the Languages of Europe / Edited by P.O. Müller, I. Ohnheiser, S. Olsen, F. Rainer. Vol. 1–3. Berlin, New York: Walter de Gruyter, 2015 (Handbooks of linguistics and communication science; 40.1–40.3).

Syntax: Theory and Analysis: An International Handbook / Edited by K. Tibor, A. Artemis. Vol. 1–3. Berlin, New York: Walter de Gruyter, 2015 (Handbooks of linguistics and communication science; 42.1–42.3).

# 9. СҮЗЬЯСАЛЫШ

## 9.1. ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНЕҢ БЕР БҮЛЕГЕ БУЛАРАК СҮЗЬЯСАЛЫШ

Сүзьясалыш татар тел белеменең мөстәкыйль бер тармагы булып тора. Шул ук вакытта ул аның башка бүлекләре – морфология, синтаксис, лексикология, фонетика, стилистика, семасиология һәм тел тарихы белән бәйләнгән.

Сүзьясалышның күп кенә процесслары телнең морфологик күренешләренә охшаш. Татар телендә яңа сүзләр дә һәм сүзнең грамматик формалары да кушымчалар ярдәмендә ясала. Мәсәлән, *-че, -чән* кушымчалары *эшче* һәм *эшчән* сүзләрендә лексик мәгънә, *-нең, -кә* кушымчалары – *эшнең* һәм *эшкә* сүзләрендә грамматик мәгънә белдерәләр. Кайбер кушымчалар лексик мәгънәгә дә, грамматик мәгънәгә дә ия. Мәсәлән, *-лы/-ле, -сыз/-сез, -лык/-лек* кушымчалары *тәмле, ямьсез, каенлык* сүзләрендә яңа семантика, *портфельле* (кеше), *утынсыз* (калу) кебек сүз формаларында грамматик мәгънә белдерәләр.

Сүзьясалыш синтаксис белән дә тыгыз бәйләнгән. Бик күп кушма сүзләр синтаксик берәмлекләрдән ясалганнар. Кушма сүзләргә характеристика биргәндә һәм аларның асылын ачыклаганда, аларда булган синтаксик мөнәсәбәтләрне читләтеп узып булмый. Аерым кушымчаларның этимологиясен ачыклаганда, шулай ук, сүзләрдәге синтаксик мөнәсәбәтләрне исәпкә алмыйча булмый, чөнки төрки телләрдә кушымчаларның күпчелеге мөстәкыйль сүзләрдән килеп чыккан.

Сүзьясалыш үзенең кайбер яклары белән лексикологиягә дә бәйләнгән. Сүзьясалыш вакытында сүзнең яңа формасы түгел, ә яңа төшенчә яки төшенчәнең төсмерен белдергән яңа лексик берәмлек барлыкка килә. Билгеле, сүз, телнең берәмлеге буларак, лексикологиянең дә өйрәнү объекты булып тора. Сүз синонимия, антонимия, омономия күзлегеннән, аның активлыгы һәм пассивлыгы, чыгышы ягыннан характерланырга мөмкин.

Һәр сүз авазлар ярдәмендә матди чагылыш таба һәм мәгънә белән тавыш формасының бергәлеген тәшкил итә. Яңа сүзләр шул телнең фонетик законнарына ярашлы рәвештә ясала. Әйтик, татар телендә һәр кушымча сүз ясаучы нигезгә сингармонизм законыннан чыгып ялгана: *авыл+даш, сер+дәш.* Шуның нәтиҗәсендә кушымчалар телебездә һәрвакыт ике – нечкә һәм калын – вариантта була.

Татар теленең төп фонетик күренешләре: редукция, элизия, ассимиляция һ.б. сүзьясалышында да чагылалар: *күренеш → күрнеш, сары ут → сарут, таба агач → табагач, чалгы, чапкы* һ.б.ш.

Сүзьясалышның стилистика белән дә билгеле бер бәйләнеше бар. Яңа ясалган теләсә нинди сүз стильгә карата нейтраль түгел. Кайбер сүз ясаучы чаралар, мәсәлән, *-ылда/-елдә, -чак/-чәк, -чык/-чек* кушымчалары *чәрелдә, такылда, бәйләнчек, иренчәк* кебек сүзләргә ачыктан-ачык экспрессив-эмоциональ төсмер өстиләр.

Сүзьясалыш шулай ук тел тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Аның күп кенә чаралары үзгәрәләр, бер үк хәлдә булмыйлар. Телнең тарихи үсеш процессында сүзьясагыч кайбер чаралар һәм ысуллар үзләренең активлыгын югалталар, яңа сүз ясауда катнашмый башлыйлар, хәтта үлегә әйләнәләр. Кайберләре, киресенчә, активлашалар. Мәсәлән, *арыслан, куйан, болан, йомран* сүзләрендәге *-ан* кушымчасы хәзерге көндә үле кушымчага әйләнгән. *-чы/-че, -лаштыр/-ләштер, -лык/-лек* кушымчалары хәзерге көндә бик продуктив, алар алынма сүзләрдән дә яңа сүз ясыйлар: *тракторчы, дизельче, индустрияләштерү, механикалаштыру, активлык, продуктивлык.*

Сүзьясалыш семасиологик процесслар белән дә бәйләнгән. Яңа сүзне ясау семасиологиягә турыдан-туры караган яңа мәгънә һәм яңа мәгънә төсмере, төшенчәләрне дифференцияләү белән бәйләнгән.

Әмма сүзьясалыш үзенең күп яклары белән грамматика белән дә, лексикология белән дә һәм тел белеменең башка тармаклары белән бәйләнгән булса да, аңарда грамматикага да, лексикологиягә дә карамаган үзенчәлекләр бар. Сүзьясалыш белән грамматика арасында сүзьясалыш процессларын грамматик күренешләргә кайтарып калдырырга мөмкин булмаган җитди аермалар бар. Мәсәлән, яңа сүзләр кушымчалау, сүзләр кушылу һәм лексик-грамматик ысуллардан тыш, лексик-семантик һәм фонетик ысуллар белән ясала. Соңгылары бө-

тенләй грамматикага кермиләр. Шуңа күрә сүзьясалыш процессларын грамматика кысаларында һәм яссылыгында гына карап булмый.

Сүзьясалышның үзенең махсус үзенчәлекләре бар. Сүзьясалышның эчтәлегенә сүзьясалыш мәгънәсен гомумиләштерү, сүзьясалыш чараларының мәгънәләре, яңа сүзләр ясауның ысуллары, сүзьясалыш чараларының җыелмасы керә. Грамматиканың һәм лексикологиянең методлары һәм алымнары югарыда күрсәтелгән күренешләрне тикшерү-өйрәнү өчен бик үк яраклы түгел.

Сүзьясалыш чараларына да, грамматик чараларга да гомумиләштерү хас. Мәсәлән, сүзьясагыч кушымча бер гомуми лексик-семантик мәгънәгә ия берничә сүз ясарга мөмкин. Мәсәлән, *-чы/-че* кушымчасы *көрәш+че, таш+чы* дигән сүзләрдә бер уртак лексик мәгънә, атап әйткәндә зат исемен белдерә. *Каен җиләге, җир җиләге, мүк җиләге* кебек кушма сүзләр, *җиләк* сүзе белән чагыштырганда, таррак мәгънә белдерәләр. Алар төр төшенчәсенең төрле мәгънәсен ачыклыйлар. Сүзьясалышта гомумиләштерү грамматикадагы абстракциядән бик нык аерыла. Сүзьясалыш гомумиләштерүе яңа мөстәкыйль төшенчә төсмере белән бәйләнгән: *батыр* (кеше) – *батырлык* (бөтенләй яңа төшенчә – билге исеме), *уку* (эш-хәрәкәт) – *укып чыгу* (эш-хәрәкәтнең төсмере, үзенчәлеге). Грамматик абстракция вакытында гомумән «лексик эчтәлектән аерылу, грамматик билгеләрнең һәм мөнәсәбәтләрнең бүленүе» килеп чыга. Мәсәлән, *урманга бару, урманнан кайту* сүзтезмәләрендә *-га* һәм *-нан* кушымчалары грамматик абстракцияне, атап әйткәндә сүз бәйләнешен генә белдерәләр.

Сүзьясалыш гомумиләштерүе грамматик абстракциягә караганда күпкә тар. Грамматик абстракция бер лексик-грамматик класстагы барлык сүзләрне үз эченә алырга мөмкин. Мәсәлән, татар телендәге барлык фигыльләр дә сан, зат, аспект һәм заман белән төрләнәләр.

Сүзьясалыш законнары һәм чаралары нигезнең лексик каршылыгы белән чикләнә, шунлыктан, мәсәлән, кушымчалар һәр тамырга һәм нигезгә кушыла алмый. Мәсәлән, *тара-, көрә-* дигән фигыль нигезләренә *-к* кушымчасы ялганып, *тара+к, көрә+к* дигән исемнәр ясала. Әмма шундый ук төзелештәге башка фигыльләрдән *-к* кушымчасыннан яңа сүзләр ясап булмый: *кайна, калтыра, кама, күзә.* Шулай ук теләсә нинди фигыль ярдәмче фигыль ярдәмендә кушма (тезмә) фигыль ясый алмый. Мәсәлән, *бар-* фигыленнән *җибәр-* ярдәмче фигыле

белән яңа тезмә фигыль ясап булмый (*барып җибәрү?*), гәрчә тезмә фигыльләрнең мондый моделе татар телендә киң таралган.

Шуңа күрә татар телендә сүзьясалыш үзенең анык проблематикасы булган мөстәкыйль лингвистик дисциплина тәшкил итә. Моннан күренгәнчә, татар тел белемендә «сүзьясалыш» дигән терминның ике мәгънәсе бар: 1) телнең сүз ясаучы чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы, ягъни махсус сүзьясалыш процессы; 2) яңа сүзләрнең һәм типларның ясалыш законнарын һәм ысулларын өйрәнә торган лингвистик дисциплина.

## 9.2. ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИК СИСТЕМАСЫНЫҢ ҮСЕШ ЮЛЛАРЫ

Хәзерге татар теленең лексикасын бай һәм киң әтрафлы сүзләр системасы һәм аларның мәгънәләре тәшкил итә. Аның лексик байлыгы зур үсеш алган дип саналган телләрдән берничек тә калышмый. Анда төрле структураларга һәм стильләргә караган йөзләрчә мең сүзләр бар.

Татар теленең лексик байлыгы, башка телләрдәге кебек үк, кинәт кенә барлыкка килмәгән. Анда акрынлап яңа сүзләр барлыкка килгән, яшәп килгән сүзләрнең мәгънәләре киңәйгән. Бу процесс халыкның сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышы белән бәйле рәвештә барган. Татар телендә бигрәк тә XX йөзнең башларында һәм урталарында бик күп яңа сүзләр барлыкка килә: *алдынгы, ракета, субүләр, күпбуын, азчылык, үзаң.*

Татар теле нинди конкрет юллар ярдәмендә байый?

Хәзерге татар теленең сүзлек составы иң башта телнең үзенең сүз ясаучы чаралары нигезендә үсә. Мәсәлән, *эшче, терлекчелек, аң-белем, үзаң, күмәкләштерү* кебек сүзләр телнең сүз ясаучы чаралары белән ясалганнар. Лексика үсешенең бу юлы бик борынгыдан килә.

Татар телендә яңа сүзләр кушымчалар ярдәмендә генә түгел, сүзләр кушылу, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү юлы белән барлыкка киләләр.

Татар теленең сүз ясаучы чаралары, аның грамматик формантлары кебек, бик тотрыклылар. Мәсәлән, хәзерге татар теленә хас булган сүзьясагыч чараларның һәм ысуллар күпчелеген безнең көнгә сакланып калган борынгы татар теленең язма ядкаре «Кыйсса-и Йосыф»та

(1262 ел) очратырга була: *күрек+ле, дат+лы* (*тат+лы*)*, яр+лы, йөрәк+ле, карен+дәш, кардәш+лек, ялау+чы, ач+ык, су+сыз+лык, ач+ыл, ун+бер* һ.б.

Татар теленең лексик системасы, шулай ук сүзләрнең мәгънәсе киңәю юлы үскән һәм үсә. Телнең тарихи үсеш процессында сүзләр өстәмә лексик мәгънәләр һәм төсмерләр алалар, шулай итеп, аларның семантик кыры киңәя. Телнең лексикасы баюның бу юлы бик экономияле. Тел яңа сүзләр ясамыйча һәм башка телләрдән сүзләр алмыйча яшәп килгән сүзләр нигезендә үзенең лексик системасын үстерә.

Бу очракта телнең законнарына ярашлы рәвештә кулланыла торган сүзләрнең мәгънәләрен бутау куркынычы янамый. Чөнки, мәгълүм булганча, күп мәгънәле сүз текстта яки сөйләм ситуациясендә бары үзенең бер мәгънәсендә генә килә.

Төрки телләрдә, безнең көннәргә килеп җиткән язма ядкарьләр күрсәткәнчә, борынгы вакытта ук күп мәгънәле сүзләр булган. Мәсәлән, Мәхмүт Кашгарый *лачын* сүзенең күчмә мәгънәсен аңлатып, «кыю егетләрне дә лачын дип атыйлар» ди.

Борынгы татар әдәбияты әсәрләрендә үзләренең төп семантикасы белән беррәттән өстәмә, күчмә мәгънәләре булган сүзләр дә очрый. Мәсәлән, анда *кылу* сүзенең, «эшләү» мәгънәсеннән тыш, «төзү» мәгънәсе дә күзәтелә (*бина кылу*)*, алтын* сүзе, затлы металл белән беррәттән, акчаның санау берәмлеген дә белдерә (*икешәр алтын әлендә дота кәлде*)*, яну* фигыле күчмә мәгънәдә дә кулланылган (*бәгъре янды*). Сүзләрнең мәгънәсе киңәю берөзлексез бара, һәм хәзерге татар телендә бөтенләй бер мәгънәле сүзләр аз, аларның күпчелеге полисемантик (күп мәгънәле) булып торалар. Моңа ышану өчен хәзерге татар сүзлекләрен карау да җитә, аларда ике, өч, ун, хәтта мәгънәләре уннан да артыграк булган сүзләр тулып ята, мәсәлән, *баш, кул, аяк, күз, бару, тору, салу* һ.б.ш. Татар теленең өчтомлык аңлатмалы сүзлегендә, мәсәлән, *чыгу* сүзенең 40 тан артык мәгънәсе күрсәтелә (төсмерләреннән башка): 1) кайдан да булса китү; 2) берәр урында булудан туктау; 3) берәр нәрсә аша узу; 4) икенче якка кушылу; 5) ярышта узу; 6) киләсе яшькә күчү; 7) берәр нәрсә өстендә барлыкка килү; 8) берәр әгъза үсү; 9) горизонт өстенә күтәрелү; 10) ис таралу; 11) яңгырау; 12) катнашудан туктау; 13) котылу; 14) үзлекләр бетү; 15) башлану, күтәрелү; 16) барлыкка килү; 17) басылу; 18) игълан ителү; 19) чыгыш

ясау; 20) табылу; 21) сарыф ителү; 22) чишелү; 23) читләшү; 24) чебеш барлыкка килү һ.б.

Татар теленең мәгънәсе киңәю процессы узган гасырның 80–90 нчы елларында халыкның сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышында килеп чыккан зур үзгәрешләр нәтиҗәсендә бик нык көчәйде.

Күп кенә сүзләргә бер яки берничә мәгънә өстәлде: *күзлек* 1) әсбап; 2) караш; *иптәш* 1) бергә эшләүче; 2) тормыштагы иптәш; *күтәрелү* 1) югарыга табан; 2) баш күтәрү; *көллек* 1) тәмәке өчен; 2) пар казанында; *кыйммәт* 1) бәяле; 2) термин – алгебрада; 3) термин – медицинада. Лексика системасы үсешенең бу юлы хәзер дә гамәлдә һәм лексиканы киләчәктә дә баетачак.

Татар теленең лексикасы башка телләрдән сүзләр алу юлы белән арткан һәм арта. Теләсә нинди башка тел кебек, татар теле дә яңа төшенчәләрне белдерү һәм булган төшенчәләрне тагын да дифференцияли төшү өчен башка телләрдән сүзләр алган һәм ала. Татарлар мең еллар буена телләре төрле гаиләгә караган халыклар белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Күп гасырлы сәяси, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләре телдә, аның иң сизгер өлешендә – лексикасында чагылмый калмаган әлбәттә.

Татар теленең борынгы катламында санскрит алынмалары: *тун, әрдәнә;* монгол телләреннән алынган сүзләр: *нарат, чаган, кияү, кодагый, үлҗә, ура;* фин-угыр алынмалары: *кәрәз, миләш, пошый* һ.б. бар.

Кайбер мәдәни-икътисади сәбәпләр белән бәйле рәвештә, борынгы вакытлардан башлап, инкыйлабка кадәр татар теленә гарәп һәм фарсы телләреннән бик күп сүзләр кергән. Гарәп-фарсы алынмаларының тематикасы бик күп төрле, алар барлык функциональ стильләрдә кулланылалар: *китап, мәктәп, мәкалә, сәгать, мәкаль, җәмгыять, сыйныф, мәрҗән, акыл, бина, гомер, кабилә, әүвәл, сарай.*

Бик борынгыдан ук татарлар белән руслар арасында телләрнең үзара йогынтысына китергән сәүдә-икътисади, сәяси үзара мөнәсәбәтләр яшәп килгән һәм килә. Моның нәтиҗәсендә XVI гасырга кадәр үк татар теленә шактый рус сүзләре кергән: *көнҗәлә, гөмбә, әвен, салам, эскерт* һ.б. Бу процесс Казан ханлыгы яулап алынгач тагын да көчәйгән. Тора-бара капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килгәч, 1905–1907 елгы буржуаз-демократик инкыйлаб чорында, бигрәк тә инкыйлабтан соң татар теленә тормышның төрле өлкәләренә кара-

ган бик күп рус сүзләре килеп керә: *приказ, пристав, исправник, өяз, сотник, пароход, поезд, паровоз, кислота, большевик, меньшевик, гласный, колхоз, совхоз, ударник* һ.б. Татар теле рус теле аша Европа телләреннән дә шактый сүзләр алган һәм ала: *конгресс, материя, орфоэпия, орфография, грамматика, антенна, радио, космос, ракета, дизель, футбол, термос, республика, социализм* һ.б. Татар теле рус теленнән сүзләрне турыдан-туры гына алмыйча, аларны калькалаштыру, ягъни сүзнең һәр морфемасын тәрҗемә итү юлы белән дә ала: *өскорма, ассызымлау.* Калькалаштыру, кагыйдә буларак, телнең грамматик законнарына һәм сүз ясау модельләренә ярашлы рәвештә башкарыла. Шуңа күрә калькаларны ясау һәм аларның структурасы татар сүзләре ясалышыннан һәм структурасыннан бер ягы белән дә аерылмыйлар. Шуңа бәйләнешле рәвештә калькаларны ясау сүзьясалышка карый һәм алар шул бүлектә карала да.

Алынмаларның байтагы татар теле тарафыннан фонетик һәм морфологик яктан үзләштерелгән, ягъни телебезнең структур үзенчәлегенә яраклаштырылган. Шундый үзгәрешне борынгы алынмалар, гарәп-фарсы алынмаларының бер өлеше, инкыйлабка кадәр рус теленнән кергән сүзләр кичергән, чөнки бу чорда рус сүзләре татар теленә сөйләү теле аша кергәннәр.

Инкыйлабтан соң рус сүзләре татар теле тарафыннан рус әдәби теленең әйтелеш һәм орфографик нормаларында алына башлаган: *чек, чекист, танк, старт, кино, строй.* Хәзерге көндә Инкыйлабка кадәр алынган һәм фонетик, морфологик яктан үзләштерелгән кайбер рус алынмалары рус теленең орфоэпик һәм орфографик нормаларында кулланыла башладылар. Мәсәлән, *рам, фанер, торба, кәрт, самауыр* кебек сүзләр газета һәм журналларда *рама, фанера, труба, карта, самовар* дип языла башладылар.

Әдәби телнең лексика системасының үсешендә дүртенче чыганак бар – әдәби телдә булган сүзләрнең мәгънәләрен дифференцияләү һәм яңа төшенчәләрне белдерү өчен диалектлардан һәм сөйләшләрдән сүзләр алу. Диалектлар һәм сөйләшләр әдәби телнең лексикасын үстерүдә ышанычлы чара булып тора. Әдәби телнең лексикасын баетуда диалекталь сүзләрне файдалану тел үсешен аңлы рәвештә көйләүгә кирә. Бу эштә телче галимнәрнең, язучыларның һәм журналистларның роле зур.

Диалекталь сүзләр, әдәби телдә куллану күзлегеннән караганда, прогрессив һәм регрессивларга бүленәләр. Прогрессив диалекталь сүзләрнең әдәби телдә эквивалентлары булмый. Алар әдәби телдә сүз белән белдерелмәгән предметларны һәм күренешләрне тәгъбир итәләр. Мәсәлән, *агын* дигән диалекталь сүзнең мәгънәсен әдәби телдә бары тасвирлап кына аңлатып була. Г. Ибраһимов, Г. Камал, Г. Бәширов, Ә. Еники, Н. Исәнбәт, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Н. Фәттах һ.б. язучыларның әсәрләрендә диалекталь сүзләр уңышлы кулланылып, әдәби телгә шундый прогрессив диалекталь сүзләр килеп кергән: *җайдак, күлдәвек, күбә, көнозын, әзмәвер, тернәкләнү* һ.б.ш.

Бүгенге көндә диалектларда һәм сөйләшләрдә татар әдәби теленең лексикасын баетырдай сүзләр байтак, мәсәлән: *игәч, тумача, пычу.*

Регрессив диалекталь сүзләрнең әдәби телдә төгәл эквивалентлары була, әдәби телдәге сүзләрнең абсолют синонимнары булганлыктан, алар әдәби телне чүплиләр. Мәсәлән, *биккели, дымык, бөргән* кебек диалекталь сүзләрнең әдәби телдә турыдан-туры эквивалентлары бар: *тулысынча, тыныч, эт эчәгесе.*

Татар теле лексикасының баю юлларының барсы да сүзьясалышка карамый. Бары телнең сүзьясагыч чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы гына сүзьясалышны тәшкил итә.

Лексика үсешенең алда әйтеп кителгән юллары – сүзьясалыш, сүзнең мәгънәсе киңәю һәм алынмалар алу татар теленең сүзлек составы баюының җанлы һәм продуктив чаралары булып торалар.

Сүзнең мәгънәсе үзгәрү, киңәю сүзнең семантик эчтәлеге яңа барлыкка килә торган мәгънәгә яки төшенчәгә каршы килмәсә генә, телдә файдаланыла. Шуңа күрә сүзнең мәгънәсе киңәю һәрвакытта да була алмый.

Алынмалар алу – шулай ук чикләре булган күренеш: башка телләрдән ихтыяҗ булмаганда сүзләр алырга ярамый. Телдә үз сүзең була торып башка телләрдән сүз алу телне баетуга түгел, ә чүпләүгә китерә. Алынмалар алу шулай ук ала торган телнең фонетик һәм грамматик закончалыклары белән чикләнә.

Бары сүзьясылыш кына иксез-чиксез мөмкинлекләргә ия, шуңа күрә татар теле лексикасын үстерүдә һәм баетуда ул төп рольне уйный.

## 9.3. СҮЗЬЯСАЛЫШ ЫСУЛЛАРЫ

Сүзьясалыш ысулы – нинди дә булса телнең матди берәмлекләреннән, алар арасында сүзьясалыш мөнәсәбәтләре хасил итеп, яңа сүзләр ясау алымы, методы. Үзенең барлык чаралары һәм типлары белән барлык ысуллар телнең сүзьясалыш системасын тәшкил итә. Татар телендә сүзьясалышның түбәндәге ысуллары бар: 1) фонетик ысул; 2) кушымчалау ысулы; 3) сүзләр кушылу; 4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 5) сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе; 6) конверсия (лексик-грамматик ысул); 7) лексик-семантик ысул; 8) аббревиация (кыскартылмалар ясалышы). Кушымчалау, сүзләр кушылу, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчүе иң продуктив ысуллар булып тора. Конверсия һәм лексик-семантик ысуллар ул кадәр үк продуктив түгелләр.

**Сүзьясалышның фонетик ысулы.** Бу ысул тел үсешенең башлангыч чорында шактый продуктив булган. Хәзерге вакытта бу ысул белән сүзләр ясалмый диярлек.

Сүздә фонетик яки просодик үзгәреш сүзнең семантик эчтәлеген үзгәрткәндә генә фонетик сүзьясалыш була. Әгәр бу үзгәреш сүзнең семантикасын үзгәртмәсә, сүзьясалышны ул тәшкил итми.

Татар телендә сүзнең мәгънәсен үзгәртүгә китерә торган берничә фонетик үзгәреш бар: сүздә аерым авазларның төшеп калуы, авазларның чиратлашуы, басымның күчүе һәм нигезнең палатализациясе (нечкәрүе). Бу фонетик үзгәрешләрнең барлык төрләре татар телендә сүзьясалыш ысулының алымнарын тәшкил итәләр[1].

**Кушымчалау ысулы.** Сүзьясалышның бу ысулы сүзьясалыш типларына ярашлы рәвештә кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясаудан гыйбарәт. Татар телендә кушымчаларның бөтен байлыгы телнең кайсы катламына хезмәт күрсәтүеннән чыгып сүзьясагыч, грамматик һәм стилистик кушымчаларга бүленә. Кушымчаларны болай бүлү конкрет һәм фәнни яктан аларның табигатен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирә. Чөнки, мәгълүм булганча, телнең теләсә нинди сүзенең ике аспекты була: билгеле бер лексик-семантик мәгънәсе булган лексик берәмлек – сүз һәм тиңдәш лексик-семантик мәгънәсе булган, әмма

[1] Ганиев Ф.А. Фонетическое словообразование в татарском языке. Казань: Татар. кн. изд-во, 1973.

нинди дә булса грамматик функциясе белән аерылып торган аның грамматик формалары (сүз формалары). Моннан шул килеп чыга: алар яңа сүз яки бары грамматик форма гына ясауларына карап сүзьясагычка һәм грамматик кушымчаларга бүленәләр.

Яңа лексик мәгънәгә ия яңа сүз ясый торган кушымчалар сүзьясагычлар дип аталалар. Мәсәлән, *-че* кушымчасы *эшче* сүзендә *эш* нигезеннән яңа лексик мәгънәгә ия яңа сүз ясый һәм ул сүзьясагыч кушымча булып тора.

Сүзнең грамматик формаларын ясый торган кушымчалар (телнең грамматикасына хезмәт күрсәтә торганнары) грамматик кушымчалар дип аталалар. Мәсәлән, *-нең* кушымчасы *эшнең* дигән сүз формасында грамматик форма хасил итә – *эш* сүзенең иялек килеше һәм грамматик кушымча булып тора. Грамматик кушымчаларга исемнәрдә – килеш, тартым, сан һәм хәбәрлек, фигыльләрдә – зат, сан, заман, наклонение, аспект, юнәлеш күрсәткечләре һәм сыйфат фигыль, хәл фигыль, инфинитив һәм исем фигыль кушымчалары, сыйфатларда һәм рәвешләрдә чагыштыру категориясе күрсәткечләре керә.

Грамматик кушымчалар, үз чиратында, грамматик мәгънәләренең табигатенә карап, икегә бүленә. Билгеле булганча, грамматик кушымчаларның бер өлеше җөмләдә турыдан-туры сүзләрне бәйләү өчен хезмәт итәләр, шуңа күрә аларны сүз бәйләүче (синтаксик) кушымчалар дип атарга мөмкин. Андыйларга килеш, тартым, сан, зат һәм хәбәрлек кушымчалары керә. Грамматик кушымчаларның икенче өлеше синтаксик функция башкармый, бер сүзне икенче сүз белән бәйләргә хезмәт итми, нинди дә булса бер морфологик форма ясый. Аларны форматив, форма ясагыч кушымчалар дип атарга була. Шундый кушымчаларга фигыльләрдә – заман, наклонение, юнәлеш, дәрәҗә, аспект, сыйфатларда һәм рәвешләрдә – чагыштыру кушымчалары керә. Сүз бәйләүче һәм форматив кушымчалар эчендә ара (күчеш) очраклары булырга мөмкин. Мәсәлән, хәзерге татар телендә синтаксик күплек кушымчасы фигыль-хәбәрне иягә һәрвакытта да бәйләмәскә мөмкин, ягъни синтаксик бәйләнеш аерым форма белән белдерелми. *Еллар үтте.* Г. Ибраһимов. *Болытлар тарала.* Г. Ибраһимов. Шул вакытта аларның ярашкан очраклары да бар, моның, әлбәттә, үз сәбәпләре бар: *Иптәшләре кул чабарга тотындылар.* Г. Бәширов. *Кызлар, шау-гөр килеп, көлешә башладылар.* Г. Бәширов.

Әгәр кушымчалар нигезгә ялганганда яңа сүз ясамасалар һәм грамматик мәгънә дә белдермәсәләр, сүзнең бары стилистик төсмерен генә үзгәртсәләр, андыйлар стилистик кушымчалар дип аталалар. Мәсәлән, *-кәй* кушымчасы *күгәрченкәй* сүзендә бары стилистик мәгънә генә белдерә һәм стилистик кушымча булып тора. Стилистик кушымчаларга шулай ук *-кәш* (*энекәш*), *-чык*/*-чек* (*кызчык*) кушымчалары керә.

Сүзьясагыч, грамматик һәм стилистик кушымчалар арасында кискен чик юк, алар бер-берсе белән бәйләнгәннәр, бер-берсенә күчәргә мөмкиннәр, Мәсәлән, башка төрки телләрдәге кебек, татар телендә дә исемнәр ясый торган, бары лексик мәгънә генә белдерә торган кушымчалар бар: *-даш*/*-дәш, -чылык*/*-челек, -ымта*/*-емтә* кушымчалары, тик сыйфатлар ясый торганнар гына – *-чыл*/*-чел, -лач*/*-ләч, -ынке*/*-енке* һ.б.ш. Болар саф сүзьясагыч кушымчалар. Телебездә шулай ук саф грамматик кушымчалар да бар (мәсәлән: аспект, сан, тартым кушымчалары). Тел белемендә аларны гадәттә сүз төрләндергечләр дип йөртәләр.

Шуның белән бергә хәзерге татар телендә бары лексик мәгънә белдерә торган саф сүзьясагыч һәм, фәгать грамматик мәгънә белдерә торган саф грамматик кушымчалар белән беррәттән, лексик мәгънә дә һәм грамматик мәгънә дә белдерә торган кушымчалар бар: *-лык*/*-лек*$_1$, *-лы*/*-ле, -сыз*/*-сез.*

*-лык*/*-лек*$_1$ кушымчасы хәзерге татар телендә түбәндәге төп мәгънәләрне белдерә: коралны һәм җайланманы (*аркалык, күзлек, битлек*), табигать күренешләрен (*каенлык, юкәлек, ташлык*), хуҗалык кирәк-яраклары куела торган яки саклана торган урынны (*утынлык, печәнлек, саламлык*), абстракт билгене, төшенчәне (*активлык, картлык, чибәрлек, хәрәкәтчәнлек*), хуҗалык тармагының, профессиянең җыйма исемен (*терлекчелек, игенчелек, белгечлек, укытучылык*) һ.б. Бу мәгънәләр лексик мәгънә тәшкил итәләр һәм китерелгән мисалларда *-лык*/*-лек* кушымчасы сүзьясагыч чара булып тора. Шуның белән бергә шул ук кушымча сүзгә грамматик мәгънә дә бирә ала. Мәсәлән, барлыктагы һәм күплектәге киләчәк заман сыйфат фигыльгә кушылып, сыйфат фигыльнең катлауланган формасын барлыкка китерә һәм аның мәгънәсен үзгәртә: *барыр юл – барырлык юл, эшләр эш – эшләрлек эш, эшләмәслек эш* һ.б.ш.

Бу кушымча шулай ук үткән заман сыйфатка ялганып, сыйфат фигыльдән ясалган исем фигыль китереп чыгара: *алган+лык, килгән+лек, барган+лык.* Кушымчаның үткән заман сыйфат фигыльгә ялгануы сыйфат фигыль формасының сыйфат фигыль билгеләрен югалтуына китерә, исем фигыль үзенчәлекләрен ул ала һәм җөмләдә аергыч булып килә алмый, килешләр белән төрләнә. Бу хәл *барганлык, арганлык, килгәнлек* формаларының төзелеше буенча да, мәгънәсе буенча да исем фигыльгә якын торуын күрсәтә. Мисаллар*: Кошчыклар, үзләренең могҗизанә көчкә ия булган җырлары белән бөтен тирәякка дәрт биреп, табигатьнең у я н г а н л ы г ы н хәбәр иттеләр.* А. Расих. *Садыйк хаҗи Әмирҗан белән Чуркинның килеп чыгуларын, нәрсә өчен к и л г ә н л е к л ә р е н бөтен тулылыгы белән сөйләде.* Ш. Камал.

Мисаллар күрсәткәнчә, *-лык* кушымчасы алган сыйфат фигыльләр үзләренең нигез формаларыннан лексик мәгънә түгел, грамматик мәгънә белдерү белән аерылып торалар. Өстәвенә, бу кушымча үткән һәм киләчәк замандагы барлык сыйфат фигыльләргә кушыла ала. Бу үзенчәлек аның китерелгән мәгънәдә универсаль булуы турында сөйли, ул исә кушымчаның грамматик характерда булуын күрсәтә, сүзьясагыч кушымчаларда бу хәл күзәтелми.

Болар барысы да татар телендә *-лык* кушымчасының яңа сүз ясау белән беррәттән грамматик форма да хасил итә алуын күрсәтә.

Биредә омонимия күренеше күзәтелмиме? дигән сорау туа. Бәлки аны ике төрле кушымча дип карарга кирәктер. Әмма болай фикер йөртү өчен җитәрлек нигез юк.

Беренчедән, ике очракта да аның этимологик нигезе бер, ул бер үк чыганакка кайтып кала. Икенчедән, ул җанлы бәйләнешләрен югалтырлык дәрәҗәдә аерылмаган. Лексик мәгънә белдергәндә дә, грамматик форма ясаганда да кушымчаның гомуми семантикасы – тулылык, ия, бар булу мәгънәсе саклана. Беренче очракта матди, икенче очракта абстракт мәгънә белдерә. Грамматик омонимия булганда мәгънәләре бер-берсенә бөтенләй туры килмиләр.

*-чы/-че кушымчасы.* Исемнәрдән эшне башкаручыны (*эш+че, доклад+чы*), иҗтимагый-сәяси яки фәнни агым тарафдарын (*дарвин+чы, мәгърифәт+че*), берәр эш-хәрәкәткә һәвәс булган кешене (*гайбәт+че, әләк+че, эчке+че*) һ.б. белдерә.

Китерелгән мисалларның мәгънәләре лексик мәгънә тәшкил итәләр, яңа ясалган сүзләр ясаучы нигезләрдән матди, лексик мәгънә белән аерылып торалар. Шуның белән бергә *-чы/-че* кушымчасы исем фигыльгә ялганып, хәзерге заман сыйфат фигыль ясауда катнаша: *бару+чы, килү+че, сөйләү+че, ясау+чы* һ.б. Бу кушымча ярдәмендә теләсә нинди исем фигыльдән хәзерге заман сыйфат фигыль формасын ясарга мөмкин, бу хәл аның универсаллыгы турында сөйли, грамматик чара булуын раслый.

*-лы/-ле кушымчасы* шулай ук полифункциональ күрсәткеч булып тора. Бер яктан, ул сүзьясагыч кушымча буларак кулланыла. Мәсәлән, *көчле кеше, гайрәтле егет, сөтле сыер* тезмәләрендә *-лы* кушымчасы белән килгән сүзләр ясалма сыйфатлар тәшкил итәләр, чөнки кушымча нигез сүзләрнең лексик, матди мәгънәсен үзгәртә. Икенче яктан, ул грамматик мәгънә дә белдерергә мөмкин. Бу түбәндәге мисаллардан күренә: *[Якуб:] Безнең теләк башка: ярлыны а т л ы итү, с ы е р л ы итү.* И. Газый. *Кайткач, исән булсак, и к м ә к л е дә, с ы е р л ы да итәрбез.* А. Шамов. *[Байморат: ] Мә ал, яшь к ә л ә ш л е булыйк, син а к ч а л ы бул.* Т. Гыйззәт.

*Сыерлы итү, акчалы булу, икмәкле итү* тезмәләрендә *-лы/-ле* кушымчасы бары сүзләрне бәйләү өчен генә хезмәт итә. Югарыда китерелгән җөмләләрдә бу кушымчадан башка сүзләрнең табигый бәйләнеше бозылыр иде, конструкция үзенең бөтенлеген югалтыр иде, мәсәлән: *сыер ... итү, акча ... булу, икмәк ... итү.* Димәк, *-лы/-ле* кушымчасы бу мисалларда нигез сүзләрнең лексик, матди мәгънәсен үзгәртми. Моннан кушымчаның хәзерге татар телендә грамматик чара, иялек килешенең күрсәткече буларак та кулланылуы ачык күренә[1].

*-сыз/-сез* кушымчасы турында да шуны ук әйтергә була. Бер очракта ул сүзьясагыч кушымча, икенче очракта – грамматик чара буларак кулланыла. Мәсәлән, *зарарсыз, ямьсез* сүзләре *зарарсыз эш, ямьсез күренеш* дигән тезмәләрдә кушымча исемне сыйфатка әйләндерә, лексик мәгънә белдерә. Мәсәлән, *зарарсыз эш, ямьсез күренеш* дигән

[1] Бу турыда тулырак мәгълүматны түбәндәге хезмәтләрдән алырга мөмкин: Закиев М.З. К вопросу о категории падежа в тюркских языках // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964; Ганиев Ф.А. О синтетических и аналитических падежах в татарском языке // Вопросы тюркологии. Казань, 1971.

тезмәләрдә *-сыз/-сез* кушымчасы исемнәрдән сыйфат ясый, лексик мәгънә белдерә. Әмма бу кушымча җөмләдә сүзләрне бәйләү өчен дә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *Кайбер кешеләр «Дүрт җан бер а т с ы з ничек каласы» дип* (*атны*) *бирмәскә димлиләр иде.* М. Гафури. *-сыз* кушымчасы *атсыз калу* тезмәсендә лексик мәгънә белдерми, чөнки нигез сүзнең матди, лексик мәгънәсен үзгәртми, шуңа күрә сүзьясагыч дип карала алмый. Аны бары юклык килешен белдерә торган грамматик кушымча дип кенә карап була.

Татар телендә кире күренеш тә бар, ягъни кайбер грамматик кушымчалар лексик мәгънә белдерергә мөмкиннәр. Мәсәлән, юнәлеш кушымчалары татар телендә, башка төрки телләрдәге кебек үк, кайбер очракларда нигез сүзгә лексик мәгънә бирергә мөмкин. Мәсәлән, юнәлеш белдерә торган *-л* кушымчасы *агылу, ыргылу, тукталу* кебек сүзләрдә, *-н* кушымчасы *укыну, сызгырыну, коену, кагыну, чишенү* кебек сүзләрдә, *-ш* кушымчасы *ярышу, кайнашу, авышу* кебек сүзләрдә матди, лексик мәгънә белдерә. Бу сүзләр үзләренең нигезләреннән юнәлеш яки башка берәр грамматик мәгънә белән аерылмыйлар. Үзләренең нигезләренә карата алар лексик мәгънәгә ия яңа сүзләр булып торалар. Димәк, юнәлеш категориясе кушымчалары, дөрес, чикләнгән күләмдә лексик мәгънә белдерергә мөмкиннәр. Бу хәл төрки телләрдә «юнәлешнең тарихи яктан сүзьясалыш категориясе булуыннан, соңыннан гына форма ясалышына әйләнүеннән килә» (Э.В. Севортян).

Стилистик кушымчалар да кайбер очракларда сүзьясагыч булып килергә мөмкин: мәсәлән, *-чык* кушымчасы *капчык* сүзендә лексик мәгънә белдереп, яңа сүз ясый. Полифункциональ кушымчаларда лексик мәгънәдән грамматик мәгънәне аеру критерийлары түбәндәге билгеләрдән гыйбарәт.

1. Югарыда китерелгән кушымчалар, грамматик мәгънә белдергәндә, җөмләдә сүзләрне бәйләүче чара буларак киләләр, лексик мәгънә белдергәндә сүзләр бәйләнешенә бөтенләй катнашлары булмый.

2. Грамматик мәгънә белдерә торган кушымчалар сүзнең грамматик формасын тәшкил итәләр, лексик мәгънә белдергән яңа лексик берәмлек барлыкка китерәләр һәм нинди дә булса морфологик категориянең күрсәткече булып тормыйлар.

3. Грамматик мәгънә белдергәндә кушымчалар күпчелек очракта универсаль булалар, ягъни барлык мөмкин булган нигезләрдән сүзнең

формасын ясыйлар, лексик мәгънә белдергәндә ул кушымчаларда андый универсальлек күзәтелми. Кагыйдә буларак, яңа сүзләр ясау мөмкинлеге чикләнгән була.

Шулай итеп, «полифункциональ кушымча» дигән термин кушымчаның ике функциядә – сүзьясагыч булып та, грамматик кушымча булып та килүен аңлата.

«Полисемантик кушымча» дигән термин кушымчаның бер функциядә күп мәгънәле булуын белдерә. Полифункциональ кушымчалар да, саф сүзьясагыч кушымчалар да күп мәгънәле булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, *-чы*/*-че*$_1$ полифункциональ кушымчасы сүзьясагыч кушымча буларак бик күп мәгънәле, аның утызга якын мәгънәсе бар. *-лык*/*-лек*$_1$ кушымчасы сүз ясау функциясендә шулай ук күп мәгънәле.

Бер үк кушымчаның ике функциядә – сүзьясагыч буларак та, грамматик кушымча буларак та кулланылуы омонимия тәшкил итми, чөнки ул ике функциясендә дә этимологик яктан бер чыганакка кайтып кала, үзенең элекке мәгънәсе белән бәйләнешен саклый.

Шуның белән бергә татар телендә омосуффикслар да бар. Мәсәлән, исем ясаучы *-ча*/*-чә* кушымчасы (*кисәкчә*) белән рәвеш ясаучы *-ча*/*-чә* (*искечә*)омоним тәшкил итәләр. Алар, беренчедән, бөтенләй төрле мәгънә белдерәләр, икенчедән, этимологик яктан төрле чыганакка барып тоташалар, өченчедән, сүзьясагыч чара буларак икесе ике сүз төркеменә карый. Мәгълүм булганча, исем ясаучы *-ча*/*-чә* кушымчасы *чак* (аз, җитәрлек түгел) сүзеннән килә, рәвеш ясаучы *-ча*/*-чә* кушымчасы *тәк* → *тек* → *чик* → *чәк* → *чак* (охшаш, кадәр, охшаган) дигән борынгы төрки сүзгә барып тоташа, хәзерге көнгә *чаклы* (диалекталь *тикле*) сүзендә очрый.

Хәзерге татар телендә еш кына авазлары ягыннан бертөрле, әмма төрле мәгънә белдерә һәм төрле чыганакка барып тоташа торган омоним сүзьясагыч һәм грамматик кушымчалар бар. Мәсәлән, *тот+ка, сөяр+кә* сүзләрендә очраган *-ка*/*-кә* сүзьясагыч кушымчасы һәм юнәлеш килеш кушымчасы *-ка*/*-кә* (*атка, сөткә*) бөтенләй ике төрле мәгънә белдерәләр, телнең төрле яссылыгына карыйлар, аларны нинди дә булса бер чыганакка кайтарып калдырып булмый. Сүзьясагыч кушымчалар гына түгел, грамматик кушымчалар да үз эчендә омоним булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, фараз (гөман) кушымчасы *-дыр*/*-дер* (*-тыр*/*-тер*) (*баргаи+дыр, килгәндер*) белән хәбәрлек кушымчасы

*-дыр*/*-дер* (*-тыр*/*-тер*) (*сакалдыр, сыердыр*) һәм йөкләтү юнәлеше кушымчасы *-дыр*/*-дер* (*-тыр*/*-тер*) төрле мәгънә белдерә һәм төрле чыганакка барып тоташа торган *омокушымча* булып торалар. Кайбер омокушымчалар омограф тәшкил итәләр – бары авазлары ягыннан гына тәңгәл киләләр, әмма просодик яктан (басымы белән) аерылалар (мәсәлән, сүзьясагыч *-ма*/*-мә* һәм фигыльләрдәге юклык күрсәткече *-ма*/*-мә,* исемнәрдәге *-ча*/*-чә* һәм рәвешләрдәге *-ча*/*-чә* кушымчалары).

Әгәр дә кушымчалар төрле этимологик чыганакка барып тоташсалар, алар, әлбәттә, омоним булып торалар. Бу хәлне бары этимологик эзләнүләр белән генә ачыкларга мөмкин. Омокушымчалар барлыкка килүнең икенче юлы – кушымчаларның мәгънәләре бер-береннән шулкадәр аерылалар ки, алар арасында аларны бәйләгән семантик инвариант (уртаклык) юкка чыга. Кушымчаларның омонимлыгын билгеләгәндә, аларның төрле сүз төркеменә каравы (ягъни функциясе) һәм парадигмаларының төрле «булуы принципиаль роль уйнамый. Мәсәлән, исем ясаучы *-чы*/*-че*$_1$ (*эшче*) кушымчасы һәм хәзерге заман сыйфат фигыль ясаучы шул ук *-чы*/*че*$_1$ (*баручы*) кушымчасы, төрле функцияләрдә килсәләр дә, омокушымчалар тәшкил итмиләр. Аларның мондый мәгънәләре *-чы*/*-че* кушымчасының полифункциональлегеннән (күп функциялелегеннән) килә.

Омокушымчаларның барлыкка килүенең сәбәпләре түбәндәгеләр:

1) аларның очраклы тәңгәллеге;

2) кушымча мәгънәләренең бер-берсеннән бөтенләй аерылуы;

3) кайбер кушымчаларның фонетик үзгәреше.

Хәзерге татар телендәге омокушымчаларның җыелма исемлеге

| Исем ясаучы кушымчалар | Сыйфат ясаучы кушымчалар | Фигыль ясаучы кушымчалар | Рәвеш ясаучы кушымчалар | Грамматик мәгънә белдерә торган кушымчалар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| -а/-ә$_1$ | -а/-ә$_2$ | -а/-ә$_3$ | -а/-ә$_4$ | -а/-ә$_4$ |
| -ай/-әй$_1$ | -ай/-әй$_1$ | -ай/-әй$_2$ | – | – |
| -ак/-әк, -к$_1$<br>-ак/-әк, -к$_2$ | -ай/-әк, -к$_3$ | – | – | – |
| -ан/-ән, -н$_1$ | -ан/-ән, -н$_1$ | -ан/-ән, -н$_2$ | – | – |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| -га/-гә<br>(-ка/-кә) $_{1}$ | – | -га/-гә<br>(-ка/-кә)$_{2}$ | - га/-гә<br>(-ка/-кә)$_{3}$ | -га/-гә<br>(-ка/-кә)$_{3}$ |
| -гын/-ген<br>(-кын/-кен) $_{1}$ | -гын/-ген<br>(-кын-кен) $_{1}$ | -гын/-ген<br>(-кын/-кен)$_{2}$ | – | – |
| -гы/-ге<br>(-кы/-ке) $_{1}$ | -гы/-ге<br>(-кы/-ке) $_{1}$ | -гы/-ге<br>(-кы/-ке)$_{2}$ | – | – |
| -гыр/-гер<br>(-кыр/-кер)$_{2}$ | -гыр/-гер<br>(-кыр$_{1}$-кер$_{1}$ | -гыр/-гер<br>кыр/-кер)$_{2}$ | – | – |
| -дык/-дек<br>(-тык/-тек) $_{1}$ | -дык/-дек<br>(-тык/-тек)$_{2}$ | – | – | -дык/-дек<br>(-тык/-тек)$_{3}$ |
| -ла/-лә$_{2}$ | – | -ла/-лә, | -ла/-лә$_{3}$ | – |
| -ләй/-ләй$_{1}$ | – | -лай/-ләй$_{2}$ | -лай/-ләй$_{3}$ | – |
| -лык/-лек$_{1}$ | -лык/-лек$_{1}$ | -лык/-лек$_{2}$ | – | -лык/-лек$_{1}$ |
| – | – | -лаш/-ләш$_{1}$ | -лаш/-ләш$_{2}$ | - |
| -ма/-мә$_{1}$ | -ма/-мә$_{1}$ | -ма/-мә$_{2}$ | -ма/-мә$_{3}$ | -ма/-мә$_{4}$ |
| -на/-нә$_{1}$ | – | -на/-нә$_{2}$ | – | – |
| – | -пы/-пе. | -пы/-пе$_{2}$ | – | – |
| – | – | -сыт/-сет$_{1}$ | – | – |
| – | – | -сыт/-сет$_{2}$ | – | – |
| -чан/-чән$_{1}$ | -чан/-чән$_{2}$ | – | -чан/-чән$_{3}$ | – |
| -ча/-чә$_{1}$ | -ча/-чә$_{1}$ | – | -ча/-чә$_{1}$ | – |
| -ча/-чә$_{2}$ | – | – | -ча/-чә$_{3}$ | – |
| -чы/-че$_{1}$ | -чы/-че$_{1}$ | -чы/-че$_{3}$ | -чы/-че$_{4}$ | -чы/-че$_{5}$ |
| -чы/-че$_{2}$ | – | - | – | – |
| -чык/-чек$_{1}$ | -чык/-чек$_{2}$ | -чык/-чек$_{3}$ | – | – |
| – | -шы/-ше$_{1}$ | -шы/-ше$_{2}$ | – | – |
| – | -шын/-шен$_{1}$ | -шын/-шен$_{2}$ | – | – |
| -ы/-е$_{1}$ | -ы/-е$_{1}$ | -ы/-е$_{2}$ | – | -ы/-е$_{3}$ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| -ык/-ек, -$к_1$ | -ык/-ек, -$к_1$ | -ык/-ек, -$к_2$ | – | – |
| -ыл/-ел, -$л_1$ | – | -ыл/-ел, -$л_2$ | – | -ыл/-ел, -л |
| -ын/-ен, -$н_1$ | -ын/-ен, -$н_2$ | -ын/-ен, -$н_3$ | -ын/-ен, -ын/-ен, -$н_3$ | – |
| -ыт/-ет, -$т_1$ | – | -ыт/-ет, -$т_2$ | – | -ыт/-ет, -$т_2$ |
| -ыр/-ер, -$р_2$ | -ыр/-ер, -$р_1$ | -ыр/-ер, -$р_2$ -ыр/-ер, -$р_3$ | – | -ыр/-ер, -$р_3$ |
| -ыш/-еш, -$ш_1$ | -ыш/-еш, -$ш_2$ | -ыш/-еш, -$ш_3$ | – | -ыш/-еш, -$ш_3$ |
| -$ый_1$ | -$ый_1$ | – | – | – |

Сүзьясагыч кушымчалар омонимнар гына түгел, үзара синонимнар да булырга мөмкиннәр. Сүзьясагыч кушымчаларның синонимлыгы шунда ки, бер үк нигезләрдән төрле кушымчалар бер үк мәгънәдәге ясалма сүзләр ясыйлар. Шундыйларга, мәсәлән, *-мак* һәм *-вык, -выч* һәм *-гыч, -ка* һәм *-кыч, -ма* һәм *-гыч* кушымчалары керә: *тотка* һәм *тоткыч, бастырма* һәм *бастыргыч, каптырма* һәм *каптыргыч.* Мондый кушымчалар белән ясалган сүзләр мәгънәләре ягыннан туры килсәләр дә, кайвакыт стилистик яктан аерылалар: *шарлама* һәм *шарлавык, үлчәгеч* һәм *үлчәвеч.* Мисалларның беренчеләре сөйләм стиленә карыйлар.

Шулай итеп, уртак нигезләре һәм төрле кушымчалары булган кайбер ясалма сүзләр сүзьясалыш ягыннан синоним булырга мөмкиннәр. Кайвакытта кушымчалар гына түгел, кайбер сүзьясалыш модельләре дә синоним булып килергә мөмкиннәр. Әлбәттә, хәзерге татар телендә сүзьясалыш модельләренең тулы синонимлыгы күзәтелми. Өлешчә синоним модельләр бар. Мәсәлән, фигыль + *-ма*/*-мә* кушымчалы һәм фигыль + *-гы*/*-ге* (*-кы*/*-ке*) кушымчалы модельләре корал, җайланма белдерү мәгънәсендә бер-беренә туры киләләр: *җайлан+ма* һәм *сос+кы.* Шулай ук фигыль+*-чы*/*-че*$_1$ кушымчалы һәм фигыль+*-кын* кушымчалы модельләр, нигез белдергән эш-хәрәкәт белән шөгыльләнүчене белдергәндә, семантикалары белән тәңгәл киләләр: *йөгерешче* һәм *качкын.*

Хәзерге көндә яңа сүз ясау сәләтенең булу-булмавына карап, кушымчалар яңа сүз ясарга сәләтле һәм яңа сүз ясарга сәләтсезләргә бүленәләр.

Яңа сүз ясарга сәләтле кушымчалар бүгенге көндә дә яңа сүз ясыйлар, бу кушымча белән килгән сүзьясалыш типлары ачык система тәшкил итәләр: мондыйларга, мәсәлән, *-чы/-че*$_1$, *-лык/-лек*$_1$ кушымчалары керә: *трактор+чы, комбайн+чы, икътисад+чы, программ+чы, абстракт+лык, доктор+лык, кочегар+лык.*

Яңа сүз ясарга сәләтсез кушымчалар хәзерге көндә яңа сүз ясауда катнашмыйлар. Алар бары ясалма сүзләр составында гына очрыйлар. Бу кушымча белән килгән сүзьясалыш типлары ябык система тәшкил итәләр. Хәзерге татар телендә шундый кушымчалар, мәсәлән: *-әт* (*ул+әт*), *-сак* (*бавыр+сак*).

Телнең үсеш процессында күпсанлы ясалма сүзләр ясаган кушымчалар продуктив дип аталалар. Мәсәлән, татар телендәге *-чы/-че*$_1$ кушымчасы шундыйлардан: *алтынчы, көмешче, күнче, кашыкчы, тимерче, күрәзәче* һ.б. Мәсәлән, 2007 елда басылып чыккан «Татарча-русча сүзлек»тә бу кушымча белән ясалган меңнән артык сүз бирелә.

Телнең үсеш процессында бик аз гына ясалма сүзләр ясаган кушымчалар продуктив булмаган кушымчалар дип йөртеләләр. Бары берничә генә сүз ясаган кушымчалар шундыйлар рәтенә керә: *-ша* (*хатынша*), *-чак* (*муенчак*), *-па/-пә* (*элпә*), *-гыл/-гел* (*-кыл/-кел*) (*баткыл*). Яңа сүз ясый торган һәм яңа сүз ясамый торганнарга һәм, икенче яктан, продуктив һәм продуктив булмаганнарга бүлү сүзьясалышта синхрония белән диахронияне ачык аерырга мөмкинлек бирә.

Үзләренең чыгышы ягыннан кушымчалар телнең үзенеке булганнарга һәм алынмаларга бүленәләр.

Телнең үзенең кушымчалары телнең үзендә барлыкка киләләр, башка телләрдән алынмыйлар. Шундыйларга, мәсәлән, *-ма/-мә*$_1$ (*тартма, берләшмә*), *-гы/-ге* (*-кы/-ке*) (*тойгы, пычкы*) кушымчалары керә.

Телнең үзенең кушымчалары күп вакытта үзләренең табигатен лексик берәмлек буларак югалткан мөстәкыйль сүзләрдән килеп чыкканнар. Башка телләрдән кергән яки алынган һәм татар теле нигезендә аның сүзьясалыш законнарына ярашлы рәвештә яңа сүзләр ясаган һәм ясый торган кушымчалар алынма кушымчалар тәшкил итәләр.

Хәзерге татар телендә андый кушымчалар күп түгел. Шундыйларга фарсы теленнән алынган *-стан* (*Татарстан*), *-ханә* (*хастаханә*), *-сар* (*каенсар*) һәм кайбер башка кушымчалар керә.

Тюркологик әдәбиятта төрки телләрдә яңа сүзләр ясаган алынма кушымчаларның зур исемлеге бирелә: *-ист, -ер, -ор, -ёр, -ник, -ка, -ец, -ек, -ница* һ.б. (*марксист, коммунист, социалист, танкист, революционер, агитатор, милиционер, шахтер, администратор, командир, ударник, ударница, артистка, Ульяновск* һ.б.ш.). Әмма болар чынбарлыкта алынма кушымчалар белән татар телендә сүзьясалышны тәшкил итмиләр, алар сүзләрнең рус теленнән бөтен килеш алынуы гына булып торалар. Марксист, командир, агитатор кебек сүзләрдә сүзьясалыш мөнәсәбәтләре мәгънәле кисәкләр арасында татар телендә түгел, рус телендә хасил булганнар. Татар телендә татар теле базасында *-ист, -изм, -ер, -ор* кебек кушымчалар белән ясалган бер генә сүз дә юк.

Татар телендә кайбер алынмаларның аерым морфемалары (тамырлары) мөстәкыйль яшәвен күрсәтеп китәргә кирәк (*танк, революцион, комсомол*). Сорау туа: китерелгән морфема (тамыр) белән тиешле кушымча арасында сүзьясалыш бәйләнеше татар теле нигезендә барлыкка килмәгәнме? Бу сорауга, һичшиксез, кире җавап бирергә кирәк. Чөнки татар телендә кайбер алынма сүзләрнең тамырлары аерым кулланылса да, бу сүзләрдә тамыр белән кушымча арасында сүзьясалыш бәйләнеше татар телендә түгел, рус телендә барлыкка килгән, һәм бу сүзләр тулы, бөтен килеш рус теленнән алынган. Шуңа күрә мондый сүзләр сүзьясалыш ягыннан рус теленеке булып торалар.

Гарәп һәм фарсы сүзләре белән дә шундый ук хәл. Әгәр дә гарәп һәм фарсы алынмаларының ясалуы чыганак телдә булган икән, ала торган телдә аларның сүзьясалыш ысулын эзләү фәнни эш булмас иде. Мәсәлән, *мәктәп, мәктүп, китап* кебек гарәп сүзләре гарәп телендә *кәтәбә* сүзеннән ясалган ясалма сүз булсалар да, татар теле өчен алар ясалма булмаган, тамыр сүзләр тәшкил итәләр, татар теле күзлегеннән караганда алар арасында сүзьясалыш бәйләнеше күзәтелми. Чөнки бу сүзләрдәге барлык лексик-грамматик үзгәрешләр татар теленең сүзьясалыш кагыйдәләре белән түгел, гарәп теленеке белән аңлатылалар.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә кирәк, теләсә нинди телнең сүзьясагыч чаралары, морфемаларның берсе шул телгә караган вакытта гына, сүзьясалыш бәйләнешен хасил итәләр. Бу критерий сүзьясалыш бәйләнешен билгеләгәндә төп чара тәшкил итә. Бу күзлектән караганда, алынмаларда очраган рус һәм гарәп-фарсы телләренең сүзьясагыч чаралары татар теле өчен хас түгел.

Хәзерге сүзьясагыч кушымчаларны шулай ук тере һәм үле кушымчаларга бүләргә мөмкин. Тере кушымчаларның ясаучы нигезләре хәзерге телдә яшиләр һәм аларны кушымчалардан аерып алырга мөмкин. Андый кушымчалы сүзләрнең төзелеше ачык билгеле була, һәм ул тиешле морфемаларга бик җиңел аерыла. Мәсәлән, *ташчы* сүзендә *-чы* кушымчасы тере кушымча булып тора. Аерып булмый торган үле кушымчалар ясаучы нигезләре белән шул кадәр нык береккән булалар, аларның ясаучы нигезләрен телнең хәзерге хәлендә аерып алып булмый. Мәсәлән, *шырпы, курпы, кырпы, керпе* сүзләрендәге *-пы*/*-пе* кушымчасы ясаучы нигезләреннән аерылмый һәм бу ясаучы нигезләр (*шыр, кур, кыр, кер*) мөстәкыйль кулланылмыйлар.

Сүзьясагыч кушымчалар гади һәм кушмаларга бүленәләр. Гади кушымчалар бер генә кушымчадан гыйбарәт булып, тагын да нинди дә булса мәгънәле кисәкләргә бүленмиләр. Гади кушымчаларга этимологик яктан кушма булган, әмма хәзерге көндә бүленмәс бербөтен тәшкил иткән кушымчалар да керә. Мәсәлән, *-чы*/*-че*$_1$, *-гы*/*-ге* (*кы*/*-ке*), *-ын*/*-ен* һ.б. күп кушымчалар гади кушымча тәшкил итәләр.

Ике яки берничә береккән кушымчадан гыйбарәт һәм бер сүзьясалыш мәгънәсе белдерә торган кушымчалар кушма кушымчалар булалар. Кушма кушымчаларга, мәсәлән, *-чы+лык*/*-че+лек* (*ким+челек*), *-ын+кы*/*-ен+ке* (*бас+ынкы, күтәр+енке*) кушымчалары керә, алар ике мөстәкыйль кушымчаның кушылуыннан килеп чыкканнар.

Ясалма сүзнең мәгънәсен барлыкка китерүдә сүзьясагыч кушымчалар ясаучы нигезнең берәр мәгънәсен кушымча белән бәйли торган «күперчек» ролен уйныйлар. Шунлыктан әгәр ясаучы нигездән башка, аңа бәйләмичә кушымчаның мәгънәсен ачарга омтылу тулы һәм дөрес булмый. Моннан, кушымчаларның мәгънәләрен ясаучы нигезләр белән бәйләнештә генә билгеләргә кирәк, дигән нәтиҗә чыга.

Сүзьясалыш ысулларының типлары була. Мәсәлән, кушымчалау ысулының тибы – уртак кушымча белән ясалган ясалма сүзләрне ясаучы нигезләрдән аерган, конкрет лексик берәмлекләрдән абстрактлашкан, сүзләр төзелешенең формаль-семантик схемасы. Мәсәлән, ясаучы нигез + *-лык*/*-лек*$_1$ кушымчасы, ясаучы нигез + *-чы*/*-че*$_1$ кушымчасы сүзьясалыш типлары булып торалар.

Сүзьясалыш типларының модельләре була. Сүзьясалыш моделе – конкрет лексик берәмлекләрдән абстрактлашкан, сүзләр төзелешенең

формаль-семантик схемасы. Сүзьясалыш моделе 1) ясалма сүзләрне ясаучы нигезләрдән аера торган уртак кушымчадан, 2) уртак лексик-грамматик ясаучы нигездән гыйбарәт. Мәсәлән, исем + *-чы/-че*$_1$ кушымчасы, фигыль + *-чы/-че*$_1$ кушымчасы, сан + *-чы/-че*$_1$ кушымчасы һ.б. схемалары модельләрне тәшкил итәләр. Сүзьясалыш типларының төрле санда модельләре булырга мөмкин. Мәсәлән, ясаучы нигез + *-чы/-че*$_1$ тибының дүрт моделе бар → (исем+*чы*$_1$, фигыль+*чы*$_1$, сан+*чы*$_1$, сыйфат+*чы*$_1$); ясаучы нигез + *-ма/-мә*$_1$тибының ике моделе бар (исем+*-ма/-мә*$_1$, фигыль+*-ма/-мә*$_1$). Кайбер очракларда сүзьясалыш тибының бер генә моделе булырга мөмкин. Мәсәлән, ясаучы нигез + *-са/-сә* кушымчасы, ясаучы нигез + *-гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*) кушымчасы типларының бер генә модельләре бар (исем+*-са/-сә,* фигыль+*-гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*)). Аерым модельләрнең бердән алып берничәгә кадәр мәгънәләре була ала. Мәсәлән, фигыль + *-ык/-ек, -к* моделе 4 мәгънәгә, фигыль + *-нак* моделе бер мәгънәгә ия.

### 9.3.1. Кушма сүзләр ясалышы

Татар телендә кушма сүзләр өч ысул белән ясала: 1) нигезләр кушылу; 2) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 3) сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе.

#### Сүзләр кушылу

Бу ысул ике яки сирәк кенә берничә гади нигезнең бер сүз булып кушылуыннан гыйбарәт, һичшиксез, телнең теләсә нинди берәмлекләрендәге кебек, кушма сүзләрнең компонентлары арасында үзара бәйләнешләр бар, бу хәл компонентларның грамматик табигатеннән һәм лексик эчтәлегеннән чыгып сайлап алынуында чагыла. Сүзләрнең лексик һәм грамматик каршылыгы нәтиҗәсендә һәр сүз теге яки бу кушма сүзнең компоненты була алмый.

Кушма сүзләрнең компонентлары үзара тигез хокуклы, идарә итүче һәм бәйле булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, *хатын-кыз* дигән кушма сүзнең компонентлары үзара тигез хокуклылар. Димәк, телнең тигез хокуклы берәмлекләре арасында булган бәйләнешне лингвистикада «тезүле бәйләнеш» дип атыйлар. Шуннан чыгып, югарыда китерелгән кушма сүзнең компонентлары арасында да тезүле бәйләнеш билгеләргә мөмкин. *Урынбасар* дигән сүзнең компонентлары арасында

без ияртүле бәйләнеш күрәбез, алар арасында бәйлелек мөнәсәбәте күзәтелә. Моннан татар телендә компонентлары арасында һәм тезүле, һәм ияртүле бәйләнешле кушма сүзләр булуы күренә.

**Компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы.** Компонентлары тезүле бәйләнеш белән, кагыйдә буларак, куш сүзләр ясала. Куш сүзләрнең компонентлары тигез хокуклылар һәм бер-берсенә бәйле түгелләр: *савыт-саба* (савыт+савыт), *бала-чага* (бала+бала). Татар телендә компонентлары мондый бәйләнештә булган бик күп сүзләр бар. Куш сүзләрнең мәгънәләре метафоралашырга мөмкин: *урын-җир, кыз-кыркын.* Куш сүзләрнең күбесе бик борынгы вакытта барлыкка килгән. Куш сүзләр татар теленә гарәп-фарсы сүзләре кергән чорда да барлыкка килгәннәр. Бүгенге көндә телдә гарәп-фарсы алынмалары катнашында ясалган шактый күп куш сүзләр очрый: *гореф-гадәт, үгет-нәсыйхәт, хәер-сәдака, хәер-фатыйха* һ.б. Шуның белән бергә куш сүзләр бүгенге көндә дә барлыкка киләләр: *урман-дала, тимер-бетон, яшелчә-җимеш* һ.б.ш.

**Компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы.** Телдә ияртүле бәйләнеш төп бәйләнеш булып тора. Җөмләдәге бәйләнешләрдән чыгып, түбәндәге ияртүле бәйләнешләрне билгеләргә мөмкин: предикатив (хәбәрлек бәйләнеше), атрибутив бәйләнеш, объект һәм хәл бәйләнешләре. Кушма сүзләрнең структурасын һәм асылын билгеләгәндә, компонентларының бәйләнешеннән чыгып тикшерү максатка ярашлырак. Беренчедән, болай эшләгәндә кушма сүзләргә компонентларының берегү дәрәҗәсеннән чыгып характеристика бирергә була, икенчедән, ияртүле бәйләнешне болай аеруның нигезендә бүлүнең бердәм нигезе ята. Хәзерге татар телендә компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сүзләрнең ясалышының түбәндәге типлары бар: 1) компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы; 2) компонентлары объект бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы; 3) компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы.

**Компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы.** Кушма сүзләр ясалышының бу тибы хәзерге татар телендә киң таралган. Бу очракта икенче компонентлары булып, кагыйдә буларак, исем килә. Беренче компонентлары булып 1) исем: *сабантуй, җирҗиләк, кырсабын, күкебаш;* 2) сыйфат: *терекөмеш, яшүсмер;*

3) алмашлык: *үзидарә, үзкыйммәт;* 4) сан: *ярымшар, бербөтен;* 5) сыйфат фигыль: *торагташ, үрмәгөл, кайтаваз.*

Компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләрнең лексик-грамматик характеры, ягъни кайсы сүз төркеменә каравы, кагыйдә буларак, икенче компонент белән билгеләнә.

**Компонентлары объект бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы.** Хәзерге татар телендә компонентлары объект бәйләнешендә булган кушма сүзләр дә очрый: *электротапшыру, радиотапшыру.*

**Компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы.** Телебездә компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр шактый күп: *радиоидарә, көнбагыш, аэрочәчү.*

Компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр телдә ике төрле юл белән барлыкка киләләр: беренчедән, нигезләр кушылу, икенчедән, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү юлы белән. Сүзләр кушылып яңа сүзләр ясалу татар телендә барлык мөстәкыйль сүз төркемнәрендә очрый. Компонентларның лексик-грамматик характерлары күп төрле. Беренче компонент буларак та, икенче компонент буларак та барлык сүз төркемнәренең дә сүзләре килә ала.

## Сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе (сүзтезмәнең лексикализациясе)

Сүзьясалышның бу ысулы шактый продуктив. Тюркологиядә кушма сүзләр ясалышының гадәттә бары бер ысулы гына – сүзләр кушылу гына күрсәтелә. Әмма төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә кушма сүзләр ясалышының өч ысулы бар. Алар сүзләр кушылу белән генә түгел, сүзтезмәнең кушма сүзгә әйләнүе һәм сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчү юлы белән ясала.

Сүзтезмәнең *конверсияләнүе* белән ясалган кушма сүзләр составы буенча кушма булып торалар. Мәсәлән, *өчпочмак* сүзе *өч почмак* сүзтезмәсе кушма сүзгә әйләнүеннән килеп чыккан.

Кайвакытта кушма сүзнең ничек ясалганын билгеләве бик кыен була: сүзләр кушылу юлы белән ул ясалганмы, әллә сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүеннән барлыкка килгәнме. Аның ясалыш ысулын аеру өчен телдә кушма сүзгә тәңгәл «тере» сүзтезмәнең булуы критерий булып тора. Мәсәлән, *өчпочмак* кушма сүзе *өч* һәм *почмак* компонент-

ларын кушып ясалмаган, ә *өч почмак* дигән сүзтезмә, билгеле бер геометрик фигураны атау өчен кулланылган. Шулай итеп, бу сүзтезмә «өчпочмак» мәгънәсен белдерү өчен берегеп китә. Бу вакытта мөһим лексик-грамматик үзгәрешләр килеп чыга. Беренчедән, сүзтезмәнең компонентлары арасында тере синтаксик бәйләнеш юкка чыга, шуңа күрә сүзтезмә компонентларының мөстәкыйльлеге югала, хәзер инде алар җөмләдә мөстәкыйль җөмлә кисәкләре булып килә алмыйлар. Икенчедән, сүзтезмәнең мөстәкыйль сүзләре арасында булган кече пауза юкка чыга. Өченчедән, просодик үзгәреш барлыкка килә: сүзтезмәнең мөстәкыйль басымнарының берсе бетә. Дүртенчедән, сүзтезмә бер төшенчә белдерә башлый. Мисалдан күренгәнчә, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе мөһим лексик-грамматик, фонетик-просодик үзгәрешләр китереп чыгара.

Сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчүе барлык тип – предикатив, атрибутив, хәл һәм объект бәйләнешендәге сүзтезмәләрдә күзәтелә.

### Сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчүе

Сүзтезмәнең лексикализациясе вакытында бөтен сүзтезмә кушымча алырга мөмкин. Хәзерге көндә сүзьясалышның бу ысулы шулай ук продуктив. Тел фактлары күрсәткәнчә, соңгы вакытта бу ысул белән ясалган терминнар фәннең төрле тармакларында очрый: *бишь+ел+лык, күп+милләт+ле, сүзь+ясалыш+ы* һ.б.ш. Бу ысул исемнәр һәм сыйфатлар ясаганда кулланыла. Мондый кушма сүзләр ясалган вакытта сүзтезмәнең компонентлары үзләренең лексик-грамматик мөстәкыйльлеген югалтып, лексик-семантик бөтенлек барлыкка китерәләр. Кушма сүзнең киләчәктәге үзгәреше аның аерым компонентларына карамыйча, бөтен сүзгә кагыла. Кушма сүзләрнең беренче компонентлары, кагыйдә буларак, грамматик күрсәткечләр белән килмиләр. Мәсәлән, кушма исемнәр – килеш, сан, тартым; кушма фигыльләр – наклонение, заман, сан, зат белән төрләнгәндә, аларның бары икенче (соңгы) компонентлары гына грамматик формантлар ала. Кушма сүзнең грамматик үзгәреше, кагыйдә буларак, аның аерым компонентлары буенча түгел, бөтен комплексы белән бара.

Кушма сүзләрнең компонентлары, лексик-семантик күзлектән караганда, үзара төрле мөнәсәбәттә булалар.

Компонентларның тулы мәгънәлелеге ягыннан кушма сүзләрнең түбәндәге төрләрен билгеләргә мөмкин.

1. Кушма сүзнең ике компоненты да тулы мәгънәле: *үзаң, үзидарә, бала-чага, янарчәчәк, дөньякүләм.*

2. Кушма сүзнең беренче компоненты тулы мәгънәле, икенче компоненты ярдәмче мәгънәле була. Кушма сүзләрнең бу тибы хәл фигыль+ярдәмче фигыльдән гыйбарәт тезмә фигыльләрдә очрый: *укып чык, җырлап җибәр.* Хәл фигыль булып килгән төп (беренче) компонент реаль мәгънә белдерә, ә ярдәмче (модификацияләүче) фигыль булып килгән икенче компонент ярдәмче мәгънә генә белдерә, төп компонентның мәгънәсен «конкретлаштыра», «ачыклый төшә». Мисаллардан күренгәнчә, икенче компонентның мәгънәсе үзгәрә, кими, эш-хәрәкәтнең ысулын гына белдерә. Кайбер куш исемнәрдә дә, сыйфатларда да икенче компонент реаль мәгънә белдермәскә мөмкин: *чокыр-чакыр, тимер-томыр, иске-москы, ашык-пошык.*

3. Кушма сүзнең беренче компоненты ярдәмче мәгънә, икенче компоненты реаль мәгънә белдерергә мөмкин. Бу моңа кадәр игътибар ителмәгән, кызыклы күренеш. *Укып чык* кебек тезмә фигыльләрдә ярдәмче (модицикацияләүче) фигыль булып икенче компонент килә. Әмма, тел материалын тикшерү күрсәткәнчә, ярдәмче (модификацияләүче) фигыль булып беренче компонент та килергә мөмкин: *алып бар, алып кит, алып кер, алып бир, алып кил.* Бу мисалларда кушма сүзләрнең төп мәгънәсе икенче, төрләнә торган компонент белән, ярдәмче мәгънә беренче компонент (хәл фигыль) белән белдерелә. Димәк, биредә модификацияләүче (ярдәмче) фигыль булып хәл фигыль формасында *ал* сүзе килә, төп мәгънә *бар, кит, кер, бир, кил* фигыльләре белән белдерелә. Бу феномен тагын да шуның белән раслана: сөйләү телендә *алып* модификацияләүче (ярдәмче) фигыле кыскарып префиксоидка әйләнә. Бу вакытта сүзнең төп мәгънәсе, еш кына тулы мәгънәле икенче компонент белән белдерелә: *апкит – алып кит, апкил – алып кил, апир – алып бир, апар – алып бар.*

Димәк, хәзерге татар телендә тезмә фигыльләрдә ярдәмче фигыль булып икенче компонент кына түгел, кайбер вакытта беренче компонент та килергә мөмкин.

4. Кушма сүзнең ике компоненты да аерым кулланылмыйлар һәм мөстәкыйль мәгънәгә ия түгелләр: *әштер-өштер, ыгы-зыгы, әкәм-*

*төкәм, урык-сурык.* Китерелгән компонентларның күпчелеге телнең борынгы вакытында, әлбәттә, нинди дә булса мәгънә белдергәннәр. Әмма бүгенге көндә аларның реаль мәгънәләре юк.

5. Кушма сүзләрнең мәгънәсе метафорик булырга мөмкин. Бу очракта кушма сүзнең мәгънәсе компонентлар мәгънәсенең гади кушылуыннан яки төп мәгънәне аныклаудан гыйбарәт булмый, бөтенләй яңа күчмә мәгънә барлыкка килә: *наратбаш, юк-бар, карга борын.* Бу кушма сүзләрнең конкрет эчтәлеге беренче компонент белән дә (*нарат, юк, карга*), икенче компонент белән дә *баш, бар, борын* бәйләнмәгән. Бу кушма сүзләрдә аның компонентлары белән бәйләнмәгән мәгънәләр барлыкка килгән. Сүзтезмәләрнең лексикалашуы белән барлыкка килгән күпчелек кушма сүзләрнең мәгънәләре метафорик була: *ишәк колагы, аю колагы, аю табаны, бүре аягы.* Бу кушма сүзләр бер мәгънә белдерәләр. Аларның метафориклыгы юкка чыкса, яңадан ирекле сүзтезмә килеп чыга, шуңа бәйләнешле рәвештә аларның лексик-семантик структурасы да үзгәрә.

### 9.3.2. Конверсия

Саф яки грамматик формантлар алган нигезләрнең башка сүз төркеменә күчүе юлы белән яңа сүзләр ясалу бу ысулны тәшкил итә. Конверсия, ягъни сүзьясалышның лексик-грамматик ысулы дөньяның күп телләренә билгеле. Ул – инглиз, француз, молдаван, әрмән һ.б. күп телләрдә бар. Сүзләрнең бер лексик-грамматик класстан икенче лексик-грамматик класска күчүе юлы белән яңа сүзләр ясалу төрки телләрдә дә очрый. Бу соңгы вакыттагы кайбер төрки грамматикаларда һәм махсус хезмәтләрдә искә алына.

Татар телендә конверсия юлы белән исемнәр, сыйфатлар, рәвешләр, бәйлекләр, ымлыклар, кисәкчәләр һәм теркәгечләр ясалалар. Бу ысул сыйфатлар, рәвешләр, исемнәр, бәйлекләр ясалуда продуктив булып тора. Башка сүз төркеменә күчкән сүзләр тулысынча шул сүз төркеменең лексик-грамматик үзенчәлекләрен алалар. Мәсәлән, башка сүз төркемнәреннән исемгә күчкән сүзләр исем сүз төркеме парадигмасына күчәләр: килеш, сан, тартым һәм хәбәрлек белән төрләнә башлыйлар. Семантик яктан алар грамматик мәгънәдәге предметны белдерәләр. Тамыр сүзләр дә, ясалма сүзләр дә конверсиягә дучар булырга мөмкиннәр. Алынма сүзләр дә конверсияләнергә мөмкиннәр.

Конверсия юлы белән барлыкка килгән исемнәр, сыйфатлар, рәвешләр һ.б. функциональ исемнәр, функциональ сыйфатлар, функциональ рәвешләр һ.б. булып торалар.

Сүзьясалышның лексик-грамматик ысулын билгеләгәндә аны сүзнең башка сүз төркеменә вакытлы (окказиональ) күчүеннән аерырга кирәк. Сүзнең окказиональ (ситуациягә бәйле) башка сүз төркеменә күчүе бары шул ситуациягә генә бәйле була, сөйләмгә генә карый. Шуңа күрә андый окказиональ күренешләрне тел фактларына кертеп булмый. Мәсәлән, *Ашаган белми, тураган белә* һәм *Тырышкан тапкан, ташка кадак каккан* җөмләләрендәге сыйфат фигыльләр исем функциясендә аерылмыш сүздән башка кулланылганнар. Әмма аларның болай кулланылуы окказиональ, аларда бары вакытлыча *кеше* сүзе төшереп калдырылган. Лексик-грамматик ысул белән яңа сүз ясалганда сүзнең башка сүз төркеменә күчүе телгә карый.

Тел фактлары күрсәткәнчә, башка сүз төркеменә саф нигезләр генә түгел, сүзнең формалары да күчәргә мөмкин.

Нигез яки сүз формасы башка сүз төркеменә күчкәндә, билгеле бер лексик-грамматик үзгәрешләр килеп чыга.

Беренчедән, яңа ясалган сүз белән ясаучы арасында эчке семантик сүзьясалыш мөнәсәбәте килеп чыга, ягъни күрсәтелгән берәмлекләр арасында матди-семантик бәйләнеш саклана.

Икенчедән, ясалма сүзнең мәгънәсе ясаучы нигез белән чагыштырганда үзгәрә. Мәсәлән, исем сыйфатка күчкәндә, предметлык белдерүдән туктап, билге белдерә башлый.

Өченчедән, ясалма сүзләрнең җөмләдә бәйләнеше үзгәрә. Әйтик, исем җөмләдә теләсә нинди урында, позициядә кулланыла алса, сыйфатка күчкәндә, ул бары исем алдында гына кулланыла, башка позицияләрдә ул үзенең ясалма сүз булуыннан туктый һәм мәгънәсезгә әйләнә.

Дүртенчедән, сүзнең парадигмасы үзгәрә, ягъни сүз башка сүз төркеменә күчкәндә, ул шул сүз төркеменең барлык грамматик билгеләрен ала. Мәсәлән, исемнәр сыйфат лексик-грамматик классына күчкәндә, сыйфат кебек үк килеш, сан һәм тартым белән төрләнүдән туктыйлар. Сыйфатлар исә, исемгә күчкәндә, исемнәрнең барлык морфологик-синтаксик билгеләрен ала. Сүзләрнең төрләнми торган сүз төркемнәренә күчүен билгеләгәндә, аларның позициясе (җөмләдәге

урыны), лексик-грамматик үзенчәлеге һәм синтаксик функциясе критерийлар булып тора.

Конверсияне тикшергәндә, ясалма сүзнең ясаучы нигезен билгеләү бик мөһим, әмма шул ук вакытта авыр да, мәсәлән, исем сыйфатка күчтеме, яисә сыйфат исемгәме? Бу очракта чынбарлыкны билгеләүгә, беренчедән, сүзьясалышның гомуми теориясе ярдәмгә килә: ясалма сүзнең семантика күләме (семантика спектры) ясаучы нигез белән чагыштырганда һәрвакыт кимрәк (таррак) була. Конверсия ысулы белән барлыкка килгән ясалма сүзләрнең семантикасына анализ ясаганда, аларның семантикасының, ясаучы нигезләре семантикасына караганда, тар, конкрет булуы күренә.

Икенче яктан, кайбер очракларда ясаучы нигезләрнең грамматик формантлары һәм сүзьясаучы дериватлары билгеле бер дәрәҗәдә баштагы лексик-грамматик классны (сүз төркемен) билгеләргә мөмкинлек бирә.

Өченчедән, тикшерелә торган сүзләрнең лексик мәгънәсенә анализ ясау, доминант семантиканы ачыклау – аларның башлангыч лексик эчтәлеген ачарга ярдәм итә.

Конверсия ысулы белән ясалган ярдәмче сүз төркемнәренә караган сүзләрнең ясалыш юнәлешен билгеләү кыен түгел. Аларның ясалышы мөстәкыйль сүз төркемнәре сүзләреннән ярдәмче сүз төркемнәре сүзләренә күчү юлы белән барган, грамматик (абстракт) мәгънә, әлбәттә, конкрет (*исем → бәйлек*) мәгънәдән килеп чыккан, киресенчә була алмый.

Югарыда күрсәтелгән критерийлар, кагыйдә буларак, конверсия вакытындагы ясаучы нигезләрне дөрес билгеләргә мөмкинлек бирә.

Кушымчалы сүзләрнең ясаучы нигезләрен ачыклаган вакытта билгеле бер кыенлыклар килеп чыга, чөнки бер үк дериватлар (кушымчалар) төрле сүз төркемнәрендә очрыйлар (мәсәлән, исемнәрдә дә, сыйфатларда да). Әгәр кушымчалы сүзнең башка сүз төркеменә караган мөнәсәбәттәш кушымчалы сүзе юк икән, ул, һичшиксез, кушымчалау юлы белән ясалган булып чыга. Әгәр дә кушымчалы сүздә теге яки бу сүз төркеменең мәгънәсе бар икән, ул вакытта аның ясаучы нигезен билгеләүнең критерийлары булып семантика доминантасы һәм әйтеп үтелгән билгеләр тора. Конверсияне сүз ясалышының лексик-семантик ысулы белән бутарга ярамый. Лексик-семантик ысул вакытында

сүзләр бер үк нигездән барлыкка киләләр, бер үк сүз төркеменә карыйлар, үзара лексик омоним булып торалар. Алар бер сүздән аерылып китеп, үзара «тере» мөнәсәбәтләрен югалтканнар. Конверсия ысулы белән ясалган сүзләр төрле сүз төркеменә карыйлар. Алар ясаучы нигезләреннән семантикасы белән генә түгел, лексик-грамматик класс ягыннан да аерылалар.

### 9.3.3. Сүзьясалышның лексик-семантик ысулы

Сүзнең семантикасы омонимнарга бөтенләй аерылып китү юлы белән яңа сүз, яңа матди лексик берәмлек ясалу бу ысулны тәшкил итә. Нинди дә булса бер сүз базасында омонимнар барлыкка килү лексик-семантик ысулның төп шарты булып тора. Шул юл белән телдә ике матди берәмлек – элекке мәгънәсе белән иске сүз һәм яңа мәгънәле яңа сүз барлыкка килә. Ни өчендер тикшеренүчеләр бу ысулның шул үзенчәлегенә игътибар итеп җиткермиләр. Мәсәлән, *йомгак* сүзе элек бер конкрет мәгънәсе булган әйберне белдергән, тарихи планда караганда күптән түгел аның яңа мәгънәсе барлыкка килгән. Бу ике мәгънә семантик яктан бөтенләй аерылып китеп, ике матди лексик берәмлек барлыкка килгән. Татар телендә мондый сүзләр юк түгел, мәсәлән, *юлдаш* (кеше) һәм *юлдаш* (сателлит), *ия* (хуҗа) һәм *ия* (грамматикада).

Бер үк чыганак сүзгә барып тоташмаган очраклы омонимнар лексик-семантик ысул белән сүзьясалышны тәшкил итмиләр. Мәсәлән, *ял* (ял итү) һәм *ял* (атта), *якут* (кеше) һәм *якут* (асылташ) сүзләре лексик-семантик ысул белән сүзьясалышка карамыйлар. Сүзьясалышның бу ысулына сүз үсеше процессында полисемиянең омонимик мөнәсәбәтләргә әйләнүе һәм ике матди лексик берәмлек ясалу хас.

### 9.3.4. Сүзьясалыш ысулы буларак аббревиация

Сүзтезмәләрнең беренче элементларын (морфемаларын) яки сүзләрнең беренче авазларын яки хәрефләрен кушу юлы белән сүзләр ясау бу ысулны тәшкил итә. Татар телендә бу ысул белән ясалган беренче сүзләр XIX йөзнең ахырында һәм XX йөзнең башында барлыкка киләләр. Әмма алар ул вакытта киң үсеп китмиләр. Инкыйлабтан соң аббревиатуралар шактый күбәя. *Күмхуҗ* (колхоз), *төбком* (райком), *эшхәб* (эшче хәбәрче) кебек кыскартмалар барлыкка килә. Телдә-

ге табигый сайланыш тиешле таләпләргә җавап бирмәгән һәм очраклы кыскартылмаларның телнең үсеш процессында төшеп калуына китергән. Аббревиатураларның ясалышы аңлы рәвештә алып барыла торган процесс, шуңа күрә аның төп аспектлары белән идарә итеп була. Татар телендәге күпчелек кыскартылма сүзләр рус теленнән алынган һәм алына. Рус телендә исә кыскартылмаларның абсолют күпчелеге үз теле җирлегендә ясала: *вуз* (высшее учебное заведение), *нот* (научная организация труда), *кпд* (коэффициент полезного действия). Бары кайбер аббревиатуралар гына анда Европа телләреннән алына, мәсәлән, *НАТО, лазер, напалм* һ.б. Бу сүзләрнең ясалышы рус теле материалына карамый.

Кыскартылма сүзләр ясалышы билгеле бер дәрәҗәдә кушма сүзләр ясалышын хәтерләтә, әмма асылда аңардан бик нык аерыла. Аббревиация вакытында сүзләрнең баш авазлары яки хәрефләре, яки аерым элементлары кушыла, бу исә сүзләр кушылу закончалыкларыннан аерыла.

Дөрес, кайбер кыскартылмалар ясалышында кушма сүзләр билгеләре күзәтелә, мәсәлән, *политбүлек, партҗыелыш, комбиазык.* Кыскартылма сүзләр ясалышының бу төре аббревиация белән сүзләр кушылу арасында тора, шуңа күрә аны катнаш сүзьясалыш дип атарга мөмкин. Әмма мондый ясалыш, беренчедән, аерым бер очрак булып кына тора, һәм сүзьясалыш ысулы буларак аббревиацияне бозмый. Икенчедән, күчеш күренешләре телнең башка категорияләре арасында да очрый.

Татар телендә аббревиатуралар чагыштырмача сирәк ясала: *АКШ, БГР, КДУ, БМО* һ.б. Әмма татар телендә үз материалы нигезендә аббревиатуралар ясау өчен бернинди дә киртә юк.

## 9.4. СҮЗЛӘРНЕҢ СҮЗЬЯСАЛЫШ СТРУКТУРАСЫ

Сүзнең (лексик берәмлекнең) грамматик һәм формаль күрсәткечләреннән башка булган кисәге сүзьясалыш структурасын, ягъни морфологик структура белән бернинди дә уртаклыгы булмаган нигез тәшкил итә. Нигезгә өстәлгән яки кушылган барлык нәрсә морфологик яки формаль күрсәткечләр булып тора һәм морфологиядә ул өйрәнелә. Морфологик һәм сүзьясалыш структуралары арасында тигезлек

билгесе куеп булмый. «Морфологик структура» термины «сүзьясалыш структурасы» төшенчәсен белдерү өчен туры килми. Димәк, сүзьясалыш һәм морфологик структураларын аеру сүзьясалыш күренешләрен дә, морфология күренешләрен дә тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

Теләсә нинди телнең сүзләрен күптөрле аспектлардан чыгып классификацияләргә мөмкин. Бу очракта безне сүзьясалыш структурасыннан чыгып классификацияләү кызыксындыра. Сүзләрнең структурасы беренче чиратта составы һәм ясалу-ясалмавы ягыннан каралырга мөмкин.

Татар теленең сүзләре, ясалу-ясалмавыннан, чыгып ясалма булмаган һәм ясалма сүзләргә бүленәләр.

Ясалма булмаган сүзләргә: 1) тамыр сүзләр, 2) телнең хәзерге торышында аерым кисәкләргә аерылмый торган нигезләр һәм 3) алынмалар керә. Калганнары барысы да нинди дә булса сүзьясалыш ысулы белән ясалган ясалма сүзләр тәшкил итәләр. Телдә ясалма сүзләрнең төрләре берничә.

Беренчедән, кушымчалы сүзләр ясалма сүзләр булып торалар, алар нигездән кушымча ярдәмендә ясалалар: *таш+чы, баш+ка, йәм+ле.*

Икенчедән, фонетик һәм просодик үзгәрешләр белән ясалган сүзләр шулай ук ясалма сүз тәшкил итәләр.

Өченчедән, ясаучы нигезләрдән сүзләрнең бер лексик-грамматик класстан (сүз төркеменнән) икенче лексик-грамматик класска күчү юлы белән ясалган сүзләр дә ясалма сүзләр рәтенә керә: *сайрар* (*сайра* фигыленнән ясалган киләчәк заман сыйфат фигыль) – *сайрар кош* (*сайрар* сүзе сыйфат булып килгән), *кайнар* (*кайна* фигыленнән ясалган киләчәк заман сыйфат фигыль – *кайнар су* (*кайнар* сүзе сыйфат булып килгән), *булган* (*бул* фигыленнән ясалган үткән заман сыйфат фигыль) – *булган егет* (*булган* сүзе сыйфат булып килгән), *көчкә* (*көч* сүзенең юнәлеш килеш формасы) – *көчкә* (*көчкә өлгердем* тезмәсендә рәвеш булып килгән). Бу ысул белән кушымчалы сүзләр генә түгел, тамыр сүзләр дә ясалырга мөмкин. Бу расламада бернинди дә каршылык юк, чөнки *тамыр* төшенчәсе сүзнең структурасына карый, *ясалма* төшенчәсе сүзнең ясалу-ясалмавына карый.

Дүртенчедән, кушма сүзләрнең барлык төрләре дә ясалма сүзләр тәшкил итәләр, чөнки алар ясалу процессында барлыкка киләләр: *укып чык, җырлап җибәр, хатын-кыз, савыт-саба, кызылтүш.*

Тюркологиядә һәм татар тел белемендә кушымчалы сүзләрне генә белдерү өчен ясалма сүзләр дигән терминны куллану дөрес түгел, чөнки башка төр сүзләр дә (мәсәлән, кушма сүзләр), конверсия юлы белән ясалган сүзләр дә ясалма сүзләр тәшкил итә.

Кайбер нигезләргә кушымчалар ялганганда нигез ахырындагы кайбер авазлар чиратлашырга мөмкин, саңгырау тартыклар үзләренең яңгырау парларына күчәргә мөмкин (к → г, п → б): *чык-чыг+ым, тип-тиб+ен, чап-чаб+ын.* Мондый фонетик үзгәрешләр авазларның гадәти корреспонденциясеннән читкә чыкмыйлар, сүзнең структур бөтенлеген җимермиләр, шуңа күрә мондый сүзләрне дә ясалма сүзләр буларак карарга кирәк.

Сүзләрнең сүзьясалыш структурасын тикшереп, татар телендә синтетик, аналитик һәм кыскарма сүзләр билгеләргә мөмкин.

## Синтетик сүзләр

Бу төр сүзләргә тамыр һәм кушымчалы сүзләр керә. Татар тел белемендә синтетик сүзләрне гади сүзләр дип йөртәләр.

**Тамыр сүзләр.** Нигезләре тамыр белән тәңгәл килгән сүзләр тамыр сүзләр тәшкил итәләр, ягъни аларның составын нинди дә булса морфемаларга бүләргә мөмкин түгел: *күз, кыш, ай, җир, ат, бар, үт.*

Әмма болар белән генә тамыр сүзләр бетми. Татар телендә кайчандыр кушымчалар белән ясалган сүзләр бар, ләкин телнең үсеш процессында аларның структурасы үзгәреп, бер бөтен барлыкка килгән, һәм хәзерге көндә алар ясаучы нигез белән кушымчага аерылмыйлар. Мисал итеп *болан*сүзен китерергә мөмкин. Бу сүз үзенең чыгышы ягыннан кушма сүз тәшкил итә: *бол+ан.* Биредә *ан* элементы кайчандыр *киек, хайван* мәгънәсен белдергән. Мәсәлән, себер татарлары телендә *аңчы* сүзе *киекче* мәгънәсен белдерә. Ләкин хәзерге татар телендә мәгънәле *бол* һәм *ан* морфемалары юк, шуңа күрә бу сүзне хәзерге көн күзлегеннән ясалма сүз дип карап булмый, ул тамыр сүзләр рәтенә керә. Телебездә кайчандыр ике сүз кушылып ясалган сүзләр дә бар, телнең тарихи үсеш процессында аларның компонентлары берберенә берегеп китеп, компонентлар үзләренең бөтенлеген югалтканнар, аларда инде мәгънәле элементлар табып булмый. Болар шулай ук тамыр сүзләр тәшкил итәләр; *бүген* (*бу+көн*), әмма хәзерге көндә

мәгънәле *бү* һәм *ген* морфемалары юк; *беләзек* (беләк йөзек), ләкин бүгенге көндә телдә мәгънәле *белә+зек* элементлары юк.

Ясалышын бары этимологик эзләнүләр нәтиҗәсендә генә билгеләргә мөмкин булган сүзләр шулай ук тамыр сүзләргә керәләр. Кушымчалы һәм кушма алынма сүзләр шулай ук тамыр сүзләр итеп каралырга мөмкин, чөнки бу сүзләр (кушымчалы һәм кушма сүзләр) татар телендә ясалмыйча, чыганак тел закончалыклары нигезендә хасил булганнар. Татар телендә андый сүзләр күп: *коррупционер, агитатор, мәктәп, китап, каһарман* һ.б. Алар татар телендә ясалмаганнар, татар теле өчен тамыр сүз булып торалар.

Шулай итеп, хәзерге татар телендә тамыр сүзләргә 1) саф тамыр сүзләр, 2) ясалу-ясалмауларына карамастан, чит телләрдән алынган сүзләр, 3) үзләренең электә булган структурасын югалткан, бүгенге көндә тамыр сүзгә әйләнгән сүзләр.

**Кушымчалы сүзләр.** Нигезгә кушымча ялганып ясалган сүзләр кушымчалы сүзләр булалар: *эш+лә* (*эш* – нигез + фигыль ясаучы кушымча *-лә*)*; эш+че* (*эш* – нигез + исем ясаучы кушымча *-че*)*, эш+чән* (*эш* – нигез + сыйфат ясаучы кушымча *-чән*).

Татар телендә, һинд-европа телләреннән аермалы буларак, сүзләр префикслар белән түгел, суффикслар (кушымчалар) белән ясалалар. Татар телендә инфиксларда юк. Димәк, татар телендә аффиксларның бер генә төре – суффикслар (кушымчалар) гына кулланыла.

## Аналитик сүзләр

Икедән дә ким булмаган тулы мәгънәле мөстәкыйль морфемалардан яки берсе тулы мәгънәле, икенчесе тулы мәгънәле булмаган сүздән гыйбарәт сүзләр аналитик сүзләр дип аталалар. Аларны икенче төрле кушма сүзләр дип тә йөртәләр.

Хәзерге татар телендә аналитик сүзләрнең абсолют күпчелеге ике сүздән гыйбарәт: *укып чык, ташбака, килә төш.* Бик сирәк очракларда гына аналитик сүзләрне өч һәм аннан да күбрәк сүзләр тәшкил итәргә мөмкин: *үги ана яфрагы.* Хәзерге татар телендә кушма сүзләрнең түбәндәге төрләре бар: 1) куш, 2) саф кушма һәм 3) тезмә.

Кушма сүзләрнең аерым төрләрен билгеләгәндә, аларның структурасының матди табигатен ачыкларга һәм аннан чыгып эш итәргә кирәк. Кушма сүзләр төрләрен аның язудагы күренеше белән, шартлы

рәсеме белән билгеләү дөрес түгел. Ул төрләр аның матди үзлекләреннән чыгып билгеләнә. Бу үзлекләр кушма сүзгә әйләнгән яки шул модель белән ясалган комбинациянең синтаксик мөнәсәбәтләрендә чагыла. Һичшиксез, хәзерге вакытта кушма сүзләрнең компонентлары арасында синтаксик бәйләнешләр күзәтелми. Әгәр дә кушма сүзләрнең компонентлары арасында андый бәйләнешләр булса, алар кушма сүз түгел, ирекле сүзтезмәләре булыр иде. Кушма сүзләрнең компонентлары арасындагы синтаксик мөнәсәбәтләр турында бары шартлы рәвештә генә, кушма сүзләр кисәкләренең гадәттәге сүзтезмәнең сүзләр мөнәсәбәтенә охшаш булуы планында гына сөйләргә мөмкин.

Шулай да сүзтезмәдәге сүзләрнең, кушма сүзгә күчкәнче, үзара булган синтаксик мөнәсәбәтләре компонентларның береккәнлек дәрәҗәсен билгеләү өчен ышанычлы критерий булып тора. Мәсәлән, атрибутив бәйләнеш нигезендә барлыкка килгән кушма сүз объект бәйләнешендә барлыкка килгән сүздән, һичшиксез, аерыла. Моннан шул килеп чыга: кушма сүзләр компонентлары арасында аңа кадәр булган синтаксик мөнәсәбәтләрне билгеләү тикшерүчегә кушма сүзнең төрен билгеләү өчен объектив критерий була. Кушма сүзнең төре аның компонентларының лексик-грамматик үзенчәлекләренә һәм алар белдерә торган мәгънәгә бәйле. Аңлашыла ки, кушма сүзнең төре, шулай итеп, компонентларның лексик-грамматик үзлекләре, компонентларның мәгънәне белдерү дәрәҗәсенә карап билгеләнә. Мәгълүм булганча, бу дәрәҗә төрле булырга мөмкин, ул исә кушма сүзнең лексик-семантик үзенчәлегендә чагылмый калмый. Шуңа күрә компонентларның грамматик бәйләнешләрен, аларның лексик-грамматик үзенчәлекләрен искә алганда гына, кушма сүзләрнең характерын дөрес билгеләргә, аларның төрләрен дөрес классификацияләргә мөмкин.

**Саф кушма сүзләр.** Кушма сүзләрнең бу төре, синтаксик мөнәсәбәтләре юкка чыгып, үзара атрибутив, объект һәм предикатив бәйләнештәге сүзләрнең кушылуыннан барлыкка килә.

Атрибутив, объект һәм предикатив бәйләнеш белән яки шул бәйләнеш моделе нигезендә барлыкка килгән кушма сүзләрнең структур компонентлары үзара нык береккән була, чөнки телдә атрибутив, объект һәм предикатив мөнәсәбәтләр иң тыгыз бәйләнеш булып торалар.

Атрибутив бәйләнеш нигезендә яки шул бәйләнеш моделендә хасил булган саф кушма сүзләрнең беренче компонентлары булып

исемнәр, сыйфатлар, саннар, алмашлыклар һәм фигыльләр, икенче компонентлары булып исемнәр килә: *сабантуй, җиржиләк, кызылканат, өчаяк, үзаң, үзидарә, янартау, үлмәсгөл.*

Предикатив бәйләнеш нигезендә яки шундый бәйләнеш моделендә барлыкка килгән кушма сүзләрнең беренче компонентлары булып гадәттә исемнәр, икенче компонентлары булып фигыльләр килә: *Ходайбирде, Уразбакты.*

Саф кушма сүзләрнең бу төре, кагыйдә буларак, антропонимиядә, топонимиядә очрый. Хәзерге вакытта предикатив мөнәсәбәт нигезендә яки шундый мөнәсәбәт моделендә кушма сүзләр ясалмый диярлек.

Объект бәйләнеш нигезендә яки шул бәйләнеш моделендә барлыкка килгән кушма сүзләрнең беренче компоненты булып исем, икенчесе булып фигыль килә: *урынбасар, сибүләр, бозваткыч.*

Компонентлары комплетив бәйләнештә булган, исем белән фигыль кушылып ясалган сүзләр шулай ук кушма сүзләр (фигыльләр) тәшкил итәләр: *хис ит, сабыр ит* һ.б.

**Куш (парлы) сүзләр.** Төрки телләрдә кушма сүзләрнең бу төре ясалышы ягыннан бик оригиналь һәм киң таралган. Башка телләрдә, мәсәлән, һинд-европа телләрендә куш сүзләр сирәк очрый. Куш сүзләрнең компонентлары үзара тигез хокуклылар, тезүле бәйләнеш белән бәйләнгәннәр, грамматик яктан бер-берсенә бәйле түгелләр: *бала-чага, ата-ана, моң-зар, савыт-саба.* Аларның шактый күп өлеше борынгырак чорда барлыкка килгәннәр.

Татар телендә күп куш сүзләрнең компонентлары төрле диалектлардан, хәтта телләрдән булырга мөмкин. Мәсәлән, *бала-чага* сүзендә беренче компонент татар теленең урта диалектында, икенче компоненты мишәр диалектында очрый, ике компонент та *бала* мәгънәсен белдерә. *Савыт-саба* сүзенең беренче компоненты татар телендә бар, икенче компонент анда очрамый, әмма ул үзбәк, казакъ телләрендә бар, икесе дә савытны, аның төрен белдерәләр. Моннан татар теленең лексикасы формалашуында күп кабиләләрнең һәм халыкларның теле катнашуы күренә.

**Тезмә сүзләр.** Татар телендә кушма сүзләрнең байтак өлешен тезмә сүзләр тәшкил итә. Алар бигрәк тә фигыльләрдә күп очрый, анда аларның саны берничә дистә меңгә җитә.

Тезмә сүзләр үзләренең структурасы ягыннан ике төргә бүленә: 1) компонентлары икенче изафә мөнәсәбәте нигезендә кушылып ясалган тезмә исемнәр: *йорт куяны, җир җиләге, мүк җиләге, үги ана яфрагы;* 2) компонентлары комплетив бәйләнештә булган, исем белән фигыль кушылып ясалган тезмә фигыльләр: *хис ит, тәэмин ит, сабыр ит, тәэсир ит;* 3) компонентлары комплетив бәйләнештә булган ике фигыльнең (тулы мәгънәле һәм модификацияләүче фигыльнең) кушылуыннан ясалган тезмә фигыльләр: *пешә төш, укып чык, язып бир.*

## Кушма сүзләрнең ирекле сүзтезмәләреннән аермасы

Хәзерге татар телендә кушма сүзләрнең байтагы тышкы яктан ирекле сүзтезмәләренә яки фразеологик берәмлекләргә охшый.

Сүзне, аның табигатен билгеләү өчен бөтенлек критерие кабул ителгән.

Татар телендәге кушма сүзләрнең сүз буларак бөтенлеге нәрсәдә соң?

Кушма сүзләрне тәшкил иткән компонентлар бер лексик мәгънә белдерә һәм бер җөмлә кисәге буларак килә: *Төн уздырыр өчен, чуртаннан куркып сайга чыккан т а ш б а ш л а р төркеме... тирәнгәрәк кереп китте.* М. Әмир. *Безнең барыш т а ш б а к а барышына әйләнде.* Ф. Әмирхан. *Каңгылдап а к к о ш йөзә аукан күлдә.* Дәрдемәнд.

Югарыда китерелгән җөмләләрдә *ташбаш, ташбака, аккош* кушма сүзләре бер лексик мәгънә белдерәләр һәм җөмләдә бер җөмлә кисәге булып киләләр. *Ташбаш* һәм *ташбака* сүзләре аергычны, *аккош* сүзе ияне белдерәләр. *Ташбаш, ташбака, аккош* (чагыштыр: *кара аккош*) кушма сүзләре идиоматик мәгънә тәгъбир итә, ягъни аларның мәгънәсе аларны тәшкил иткән сүзләрнең мәгънәләренең суммасы түгел. Әмма кушма сүзләрнең бер өлешенең мәгънәләре компонентлар мәгънәләренең суммасы булырга мөмкин: *Бу бит а т а - а н а с ы н күрергә кунакка кайтып килә.* Г. Ибраһимов. *Шәрифҗан уракка баручы х а т ы н - к ы з л а р н ы куып җитте.* И. Газый. Мисаллардан күренгәнчә, бу куш сүзләрнең мәгънәләре компонентлары мәгънәләренең суммасына тигез.

Ирекле сүзтезмәләре үзләренә охшаган кушма сүзләрдән аермалы буларак ике аерым лексик мәгънә белдерәләр һәм җөмләдә ике җөмлә кисәге булып киләләр: *Күлдә бер ак кош йөзеп йөри.*

*Ак кош* сүзтезмәсе бу җөмләдә ирекле сүзтезмә булып тора, компонентлары ике аерым мәгънә белдерәләр: *ак* (төс) һәм *кош* (нинди дә булса). Җөмләдә ике җөмлә кисәге булып киләләр: *ак* – аергыч, *кош* – ия.

Кушма сүзләр татар телендә мөстәкыйль мәгънәгә ия өченче сүз белән аерылмый, ягъни бер-береннән ерак урнаша алмыйлар. Мәсәлән, *аккош* дигән кушма сүзнең компонентлары арасына өченче сүз куеп булмый, арасына өченче сүз килеп керсә, кушма сүз ягадәти ирекле сүзтезмәгә әйләнә, йә үзенең бөтенлеген югалта, мәгънәсез ясалма бер тезмәгә әйләнә. Җөмләдә *ак кош* дигән кушма сүзнең компонентларын өченче сүз белән аерсак, ул ирекле сүзтезмәгә әйләнә: *Күлдә ак, соры кошлар йөзеп йөриләр. Ә ташбаш* дигән кушма сүзнең компонентлары арасына өченче сүз килеп керсә, ул мәгънәсез бер тезмәгә әйләнә: *Елгада таш, агач башлар очрый.*

Ирекле сүзтезмәләрнең компонентлары, кушма сүзләрдән аермалы буларак, җөмләдә бер-береннән ерак урнаша ала, бу хәлдә дә аның бөтенлеге бозылмый, мәгънәсе үзгәрми. Мәсәлән, *соры кош* дигән синтаксик сүзтезмәне җөмләдә өченче сүз белән аерсак, аның бөтенлеге бозылмый һәм мәгънәсе юкка чыкмый: *Безнең урманнарда соры, күк кошлар бар.*

Кушма сүзләрнең компонентлары арасында үзара бәйләнгәнлек һәм бер-берсенә үтеп керү күзәтелә, шул сәбәптән аның кайсы да булса компонентын мәгънәсен югалтмыйча, бөтенлеген бозмыйча төшереп калдырып булмый. Мәсәлән, *аккош, каракош* кебек кушма сүзләрнең җөмләдә берәр компонентын төшерсәң, аларның бөтенлеге һәм мәгънәсе бозыла: *Күлдә аккош бар – күлдә кош бар.*

Кушма сүзләр белән ирекле сүзтезмәләре арасында шулай ук фонетик һәм просодик аермалар да бар. Беренчедән, тышкы яктан кушма сүзләргә охшаган тезмә сүзләрдә гадәттә ике мөстәкыйль басым була. Ирекле сүзтезмәләрне хәтерләткән кушма сүзләрдә, куш сүзләрдән башка, бары бер генә динамик басым була, бары кайбер очракта гына беренче компонентта ярдәмче басым булырга мөмкин. Мәсәлән, *каракóш* сүзендә бер генә басым күзәтелә, ул соңгы иҗеккә төшә. Бу кушма сүзгә охшаган сүзтезмәне просодик яктан карасак, бөтенләй башка күренеш күрербез. Беренчедән, аңарда ике мөстәкыйль басым күзәтелә. Икенчедән, кушма сүзләрнең компонентлары арасында бер-

нинди дә тукталыш, пауза юк. Синтаксик тезмәләрнең сүзләре арасында һәрвакыт зур булмаган пауза күзәтелә. Паузаның булмавы сүтезмәне кушма сүздән аера торган билге булып тора. Мәсәлән, *кызылтүш* дигән кушма сүздә компонентлары арасында нинди дә булса пауза күзәтелми. *Кызыл түш* дигән сүтезмә компонентлары арасында беркадәр тукталыш, пауза бар.

Кушма сүзләрнең бөтенлеген түбәндәге элементлар тәшкил итә: 1) бердәм мәгънә (семантика); 2) бер басым (куш сүзләрдән башка); 3) компонентлар арасында паузаның булмавы; 4) компонентларның аерылмавы, ягъни кушма сүзләр компонентларының мөстәкыйль мәгънәле сүзләр белән аерылмавы. Күрсәтелгән бу билгеләр кушма сүзләрне ирекле синтаксик сүтезмәләреннән аера.

## Кушма сүзләрнең фразеологик берәмлекләрдән аермасы

Тел берәмлеге буларак, кушма сүзләрне билгеләгәндә, аларны фразеологик берәмлекләрдән аерырга туры килә. Мәгълүм булганча, фразеологик берәмлек семантик һәм синтаксик планда аерым сүз хокукында яши, шулай ук фразеологик кушылмаларны732бербөтен тел берәмлеге буларак куллану аларны кушма сүзләр белән якынлаштыра, ирекле сүтезмәләреннән аера. Сүз, гомумән, фразеологик берәмлекләр турында бармый, ә үзләренең тышкы күренеше белән кушма сүзләргә охшаган, әмма алардан аерырга кыен булган фразеологик берәмлекләр турында бара. Билгеле булганча, кушма сүзләрне ирекле сүтезмәләрдән аеру җиңелрәк, чөнки кушма сүзләр ирекле сүтезмәләреннән һәм семантик, һәм синтаксик яктан аерыла. Кушма сүзләр һәм фразеологик берәмлекләр арасында аларны аера торган югарыда күрсәтелгән билгеләр юк: фразеологик берәмлекләр дә, кушма сүзләр дә күбрәк идиоматик бер мәгънә белдерәләр һәм җөмләдә бары бер җөмлә кисәге генә булып киләләр. Әмма бу хәл алар арасында аларны аера торган билгеләр юк дигән сүз түгел. Алар арасында җитди аермалар бар.

Кушма сүзләр фразеологик берәмлекләрдән аермалы буларак, мөстәкыйль сүзләрдән гыйбарәт булмыйча, нигез-морфемадан торалар. Мәсәлән, *кушбаш, аккургаш, ислемай, башкала, ташкүмер* кебек

кушма сүзләрнең компонентлары мөстәкыйль сүзләр түгел, алар арасында бәйлелелек һәм бер-беренә үтеп керү күзәтелә, шуңа күрә алар бәйле нигез – морфема тәшкил итәләр. *Куян йөрәк, җылы сүз, карт төлке, сатлык җан* фразеологик берәмлекләрен барлыкка китергән ике компонент та чагыштырмача мөстәкыйльләр.

Китерелгән фразеологик берәмлекләрдәге сүзләрнең чагыштырмача мөстәкыйльлеге аларның фонетик-морфологик үзлекләрендә дә чагыла.

Кушма сүзләрнең компонентлары, тышкы яктан үзләренә охшаган фразеологик берәмлекләрдән аермалы буларак, бер басым белән оешалар, бары кайвакытта гына ярдәмче басым өстәлергә мөмкин. Фразеологик берәмлекләр исә, кагыйдә буларак, ике яки аннан да күбрәк басым белән киләләр, бу аларның составына кергән сүзләрнең чагыштырмача мөстәкыйль булуы белән аңлатыла. Мәсәлән, *аксакал, балачак, кулбаш, билбау, төньяк* кебек кушма сүзләр соңгы иҗеккә төшкән бер басым белән аерылып торалар. *Эт токымы, сатлык җан, карт төлке, сафсата сату* кебек фразеологик берәмлекләр ике басым белән киләләр, һәр компонент мөстәкыйль басымга ия. Күрсәтелгән акцентологик үзенчәлек кушма сүзләрне фразеологик берәмлекләрдән аеруда төп критерийларның берсе булып тора.

Фразеологик берәмлекләр кушма сүзләрдән үзләренең семантик-экспрессив үзенчәлекләре белән аерылып торалар. Фразеологик берәмлекләргә кушма сүзләрдән аермалы буларак бик ачык күренеп торган образлылык (тасвирлылык) хас. Гадәттә кушма сүзләрдә андый образлылык күзәтелми. Дөрес, кушма сүзләр белән фразеологик берәмлекләр арасында торган күчеш очраклары да булырга мөмкин. Әмма фразеологик берәмлекләрнең абсолют күпчелеге, һичшиксез, образлылык ягыннан аерылып тора. Мәсәлән, *колагына да элми, эчне бушату, кибәк баш, чүбек баш* кебек фразеологик берәмлекләр бик ачык беленеп торган экспрессивлык, образлылык белән аерылып торалар. Кушма сүзләрдә шундый образлылык билгеләп булмый. Кушма сүзләрдә фразеологик берәмлекләргә хас образлылыкның булмавы аларның иң төп үзенчәлекләренең берсе. Шулай итеп, кушма сүзләрнең фразеологик берәмлекләрдән аермасы фонетик-морфологик, просодик һәм экспрессив үзенчәлекләргә кайтып кала. Алар, барлык очракларда диярлек, кушма сүзләрне фразеологик берәм-

лекләрдән аерырга мөмкинлек бирә. Әйтелгәннәрдән чыгып, кушма сүзләр белән фразеологик берәмлекләр арасында үтеп булмый торган стена юк, дип раслап булмый, алар эчендә күчеш очраклары булырга мөмкин.

## Кыскартылма сүзләр

Татар телендә күпчелек кыскартылмалар рус теленнән алынган һәм алына: *диссовет, вуз, завхоз.* Шулай ук татар теленең үз җирлегендә ясалган аббревиатуралар да бар: *АКШ, БМО, КДУ, КДПУ, АДПУ.*

Кыскартылма сүзләрнең татар телендә түбәндәге төрләре бар.

1. Инициаль кыскартылма сүзләр, ул үзе өч төркемгә бүленә: 1) сүзләрнең беренче хәрефләрен кушу белән ясалган кыскартылмалар: *ФРГ* (ФыэРГэ), *ГДР* (ГэДэәР); 2) сүзләрнең беренче авазларын кушу юлы белән ясалган кыскартылмалар: *КФУ, БУБК;* 3) сүзләрнең беренче авазларын һәм беренче хәреф исемнәрен кушу юлы белән ясалган кыскартылмалар: *ТР* (ТэР), *БР* (БэР).

2. Элементлары кушылып ясалган кыскартылмалар. Алар ике төркемгә бүленәләр: 1) сүзләрнең беренче иҗекләрен кушып ясалган кушылган кыскартылмалар: *райком* – район комитеты, *раймаг* – район магазины. Бу төр кыскартылмалар татар телендә сирәк очрыйлар; 2) тезмәнең беренче сүзенең башлангыч элементын һәм икенче тулы сүзен кушып ясалган кыскартылмалар: *драмтүгәрәк, профхәрәкәт, педсовет.* Бу төр кыскартылмалар татар телендә очрый. Монда шуны әйтергә кирәк: татар телендә кыскартылмалар ясау өчен бернинди киртәләр юк.

Хәзерге татар телендә сүзләр структурасының таблицасы

| № | Синтетик (гади) сүзләр | Аналитик (кушма) сүзләр | Аббревиатуралар (кыскартылмалар) |
|---|---|---|---|
| 1 | тамыр сүзләр | саф кушма сүзләр | инициаль кыскартылмалар |
| 2 | кушымчалы сүзләр | куш сүзләр | элементлы кыскартылма сүзләр |
| 3 | – | тезмә сүзләр | – |

## 9.5. ИСЕМНӘР ЯСАЛЫШЫ

### 9.5.1. Исемнәрнең фонетик ысул белән ясалышы

Бу ысул белән сүзләр ясалышына, телчеләрдән беренче булып, Г. Алпаров игътибар итә. Фонетик сүзьясалышка шулай ук Ф.С. Фасиев һәм К.С. Сабиров та тукталалар.

Татар телендә фонетик ысул белән сүзьясалышның түбәндәге алымнары бар: 1) аваз яки авазлар төшеп калу; 2) авазның яки авазларның чиратлашуы; 3) нигезнең палатальләшүе (нечкәрүе); 4) басым күчү.

#### Аваз яки авазларның төшеп калу алымы

Бу алым бигрәк тә гарәп-фарсы алынмаларында очрый. Кайбер алынмалар татар телендә төрле фонетик вариантта килеп, фонетик яктан да, лексик мәгънәләре ягыннан да аерылалар. Мисаллар итеп түбәндәге исемнәрне китерергә мөмкин:

*хаҗәт* (кирәклек) һәм *әҗәт* (бурыч)
*гамәл* (эш) һәм *әмәл* (алым)
*мәгънә* (эчтәлек) һәм *мәне* (юнь).

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, беренче баганадагы сүзләрнең баштагы *х* һәм *г* авазлары төшеп калган, ягъни татар телендә фонетик үзгәрешкә дучар булганнар. Фонетик үзгәреш семантик үзгәрешне китереп чыгарган. Фонетик яктан үзгәргән сүзнең мәгънәсе фонетик яктан үзгәрмәгән сүзнең мәгънәсеннән нык аерыла. Фонетик яктан үзләштерелгән вариантларда чыганак телдә бөтенләй булмаган мәгънәләр килеп чыккан. Бер үк алынманың төрле мәгънәдәге вариантларының килеп чыгу сәбәбе турында нәрсә дә булса әйтүе кыен. Бәлки бу хәл сүзләрне төрле чорда, шулай ук язма яки сөйләм теле аша алуга бәйләнгәндер. Алынмаларның бу төркемендә, аерым авазлар төшеп калу белән беррәттән, кайбер вакытта семантиканы үзгәртүгә китерә торган метатеза күренеше, авазлар чиратлашуы да була: *хикмәт – әкәмәт, хикәят – әкият*. Күренгәнчә, китерелгән сүзләрдәге катлаулы фонетик үзгәреш аларның семантикасын үзгәртә, һәм бу күренеш фонетик сүзьясалыш буларак каралырга тиеш.

Чыганак телдә үк бер үк нигездән ул телнең закончалыкларына ярашлы рәвештә ясалып, татар теленә алынган сүзләр татар теленең

сүзьясалыш ысулын тәшкил итми. Мәсәлән, *хак* һәм *хокук* сүзләре кайвакытта татар телендә фонетик сүзьясалышка мисал итеп китерeләләр, әмма аларда татар телендә сүз ясалу билгеләре юк. Чөнки бу сүзләр гарәп телендә татар теле сүзьясалыш законнары нигезендә түгел, ә гарәп теле сүзьясалыш законнары нигезендә ясалган. Мәгълүм булганча, *хак* һәм *хокук* сүзендәге үзгәрешләр чыганак тел законнарына карый, шуңа күрә алар татар теле Сүзьясалыш нәтиҗәсе булып тормыйлар.

Шуны әйтеп китәргә кирәк, татар телендә семантикасы белән аерылмый торган төрле фонетик вариантларда йөри торган алынмалар да бар: *газап – азап, сәгать – сәәт* һ.б. Бу сүзләр сүзьясалышны тәшкил итмиләр, чөнки аларның мәгънәсе бер үк. Алар бары шул сүзнең диалекталь яки фонетик вариантлары гына булып торалар.

Аваз яки авазлар төшеп калып яңа сүзләр ясалу саф татар сүзләрендә дә очрый. Ясаучы нигезнең берәр авазы яки авазлары төшеп кала, төп сүз үзенең мәгънәсен саклый, ә фонетик үзгәреш белән ясалган яңа сүз, нигез белән чагыштырганда, яңа мәгънә ала. Мәсәлән, *тәңре* сүзе алла мәгънәсен бирә, шул сүздәге *ң* авазы төшеп калып, бөтенләй яңа мәгънәле *тәре* сүзе ясала.

*Тәңре* сүзенә мисаллар: *Салма безне, т ә ң р е ,  тагын син газапка, кайгыга.* Һ. Такташ. *Ана хакы,  т ә ң р е  хакы, диләр. Түзем биргәй иде, т ә ң р е ,  җанга.* Ф. Бурнаш.

*Тәре* сүзенә мисаллар: *Почмактагы  т ә р е л ә р  астына утырып..., икмәк белән чәй эчтек.* М. Галәү. *Хәзер муенына  т ә р е  тагып йөри.* Г. Ибраһимов. Татар телендә телнең тарихи үсеш процессында кайбер сүзләрнең аерым авазлары төшеп калып фонетик йөзе үзгәргән очраклар да бар. Әмма аларда мәгънә үзгәреше килеп чыкмаган: *ул, йыла, ыру* сүзләре *угыл, йыгла, ыруг* сүзләреннән *г* авазы төшеп калып барлыкка килгәннәр. Әмма ул сүзләр фонетик сүзьясалышны тәшкил итмиләр, чөнки аларда семантика үзгәрмәгән.

### Аваз яки авазлар чиратлашу алымы

Алтай телләрендә сүзләрдә авазлар чиратлашу киң таралган. Моңа беренче башлап, В. Шотт һәм И. Грунцель игътибар иткәннәр. Авазларның позициядәге һәм тарихи чиратлашуы Г. Алпаровның, А. Голәмевнең, Л. Җәләйнең, Н.К. Дмитриевның, Э.В. Севортянның,

А. Нагаевның, Р. Әхмәтьяновның, Ф. Фасиевның, К. Сабировның һ.б.ның өйрәнү объекты булдылар.

Билгеле булганча, авазларның чиратлашуы бер телнең төрле сөйләшләре арасындагы сүзләрдә: *җегерме* (урта диалект) һәм *йегерме* (мишәр диалекты); *менгер* (урта диалект) һәм *менгез* (мишәр диалекты); бер гаиләгә кергән төрле телләр арасындагы сүзләрдә: *су* (татар теле) һәм *һу* (башкорт тел), *эч* (татар теле) һәм *эс* (башкорт теле), *кыш* (татар теле) һәм *кыс* (кыргыз теле) очрый. Бу күренеш фонетикага карый, аның сүзьясалыш белән бер нинди дә уртаклыгы юк. Чөнки лексик мәгънәне үзгәртмичә авазлар чиратлашуы сүзьясалышны тәшкил итми. Татар теленең үсеш тарихында, мәсәлән, *сыгыр* сүзендә *г* авазы *й* авазына, *бозак* сүзендә *к* авазы *у* авазына күчкән. Аңа карап *сыйыр* һәм *бозау* сүзләре *сыгыр* һәм *бозак* сүзләреннән ясалган яңа мәгънәле сүз булып тормыйлар. Алар мәгънә үзгәрмичә сүзләрнең фонетик үсешен генә тәшкил итәләр.

Татар телендә авазларның мондый тарихи чиратлашуы билгеле бер закончалыклар нигезендә бара һәм бер система тәшкил итә: *таг – тау, баг – бау, яг – яу, саг – сау* һ.б. Авазларның чиратлашуы сүзләрнең мәгънә үзгәрешенә китерсә генә, алар сүзьясалыш нәтиҗәсе булалар.

Фактлар күрсәткәнчә, авазлар альтернациясе татар теленең тарихи сүз ясалышында билгеле бер урын алып тора. Борынгы татар телендә *г* авазының *к* авазына күчүе кайбер сүзләрдә аларның семантикасын үзгәрткән: *каг* (кипкән) һәм *как* (каты, бернәрсә дә җәелмәгән); *саг* (сау) һәм *сак* (саклау); *бег* (хуҗа) һәм *бәк* (титул). Татар телендә мәгънә үзгәрү нәтиҗәсендә исемнәр ясауга китергән түбәндәге авазлар чиратлашуын күрсәтергә мөмкин:

*а* авазының *о* авазына күчүе: *йагынты – йогынты;*

*а* авазының ы авазына күчүе: *кабарчык – кабырчык; сан – сын;*

*п* авазының *ф* авазына күчүе: *калпак – калфак;*

*т* авазының *ч* авазына күчүе: *бөртек – бөрчек.*

### Нигезнең палатальләшүе (нечкәрүе)

Нигезнең нечкәрүе фонетик сүзьясалышның мөстәкыйль һәм аерым бер алымы булып тора, аны авазлар чиратлашуы белән бутарга ярамый. Нигез үзгәргәндә тартык авазлар да, сузык авазлар да нечкәрә. Әмма нигезнең теләсә нинди нечкәрүе сүзьясалышны китереп

чыгармый. Татар телендә калын нигезләрнең нечкә вариантлары күп очрый: *аз – әз, ач – әч, акрын – әкрен, ана – әнә, арчы – әрче, арлы-бирле – әрле-бирле, кычыту – кечетү, мачы – мәче, салыну – сәлену.* Күренгәнчә, нечкә вариантлар мәгънәсе ягыннан калын варинтлардан аерылмыйлар. Димәк, бу вариантлар арасында сүзьясалыш мөнәсәбәтләре юк. Алар сүзләрнең, мәгънә үзгәрмичә, гадәти фонетик үзгәрешен генә тәшкил итәләр. Мондый фонетик үзгәрешләр төрки телләрдә дә очрый: *байрам* (башкорт теле) һәм *бәйрәм* (татар теле), *айран* (башкорт теле) һәм *әйрән* (татар теле).

Нигезләрнең мәгънәне үзгәртүгә китергән нечкәрүе генә Сүзьясалышны тәшкил итә: *чачак* (пәрдәдә) һәм *чәчәк* (үсемлектә), *багыр* (әгъза – иске сүз) һәм *бәгырь* (җан, күңел). Нигезләрнең нечкәрүе башка фонетик үзгәрешләр килеп кушылудан булса. Бу вакытта аерым авазлар төшеп калырга мөмкин. Мәсәлән, *карындаш* сүзе үзенең тарихи үсешендә *кардәш* сүзен бирә, әмма, күренгәнчә, аның *ын* элементы төшеп калган.

## Басым күчү алымы

Төрки телләрне өйрәнүчеләр басым күчеп яңа сүз ясалуны фонетик сүзьясалышның продуктив алымы итеп күрсәтәләр: төрекмән телендә: *гайнатма́* (шулпа) һәм *гайна́тма* (фигыль), *говурма́* (куырма) һәм *говурма́* (фигыль); үзбәк телендә: *тугма́* (төймә) һәм *ту́гма* (бәйләмә); карачай-балкар телендә *киртмә́* (груша) һәм *киртмә́* (фигыль), татар телендә *бүлмә́ – бү́лмә, чыгарма́ – чыга́рма* һ.б. Чынбарлыкта исә биредә бернинди дә фонетик сүзьясалыш күзәтелми, чөнки каршы куелган сүзләрнең беренчеләре фигыльләрдән басымлы *-ма/-мә* кушымчасы белән ясалган исемнәр, икенчеләре фигыльләрнең төрләнеш формалары, ягъни юклыктагы II зат боерык фигыль формалары булып торалар. Юклык кушымчасы татар телендә бервакытта да үзенә басымны алмый. Китерелгән мисаллар очраклы тәңгәл килгән омографлар тәшкил итәләр. Димәк, *гайнатма́* (исем) һәм *гайна́тма* (фигыль) сүзләре фонетик сүзьясалышка карамыйлар, беренчесе – фигыльдән кушымча белән ясалган, икенчесе фигыльнең бер грамматик формасын гына тәшкил итә. Бу сүзләрдәге үзгәрешләр фонетик сүзьясалышны тәшкил итмиләр. Шуңа күрә, китерелгән сүзләрне фонетик сүзьясалыш дип карау тюркологиядә хата булып тора.

Басым күчкәндә мәгънә үзгәрсә һәм ул сүз шул ук нигезнең фонетик үсеше генә булып торса, бары шул вакытта гына басым күчү фонетик сүзьясалышны тәшкил итә. Бу шартларга тюркологлар тарафыннан фонетик сүзьясалышка китерелгән мисалларның абсолют күпчелеге туры килми (*алмá – áлма* һ.б.)

Болардан чыгып, төрки телләрдә басым күчеп яңа сүз ясалмый, дип әйтеп булмый. Исемнәр ясалышында бу алым очрамый. Башка сүз төркемнәре ясалышында ул беркадәр күзәтелә. Мәсәлән, *яңá* (сыйфат) һәм *я́ңа* (рәвеш). Мисаллар: *Тимеринең күз алдында элеккесенә һич кенә дә охшамый торган яңá* (сыйфат) *бер дөнья туа башлады.* Г. Бәширов. *Атаң я́ңа гына* (рәвеш) *сукрана-сукрана тимерлеккә китте.* Г. Ибраһимов.

### 9.5.2. Кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышы

#### Кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышын тюркологиядә өйрәнү тарихына карата

Төрки телләрдә сүзләр ясалышын өйрәнү XIX гасырда башлана. Сүзьясалыш мәсьәләләре ул вакытта грамматикаларда гына карала. Мәсәлән, А. Казимбәк үзенең грамматикасында исем ясаучы 5 кушымча китерә. «Алтай теле грамматикасы» авторлары исем ясаучы 19 кушымча китереп, аларның төп мәгънәләрен ачалар. Н.И. Ашмарин фикеренчә, исем ясаучы 13 кушымча бар. Н.Ф. Катанов тува телендә исем ясаучы 12 кушымча күрсәтә, кайберләренең мәгънәләрен билгели. Фигыльдән ясаучы кушымчаларга ул тукталмый. В.А. Гордлевский төрек телендә исем ясаучы 19 кушымча китерә. Н.К. Дмитриев башкорт телендә исем ясаучы 13 кушымча билгели, әмма алар арасында башкорт телендә сүз ясаучы булып тормаган, бары алынмаларда гына очрый торган *-ист, -ер* кебек кушымчаларны да китерә. Л.Н. Харитонов якут телендә исем ясаучы 14 кушымча таба. Н.П. Дыренкова хакас телендә исем ясый торган 49 кушымча билгели, әмма аларның бер төркеме сыйфат ясаучы булып торалар (*-гер, -чан, -к, -чак, -кай* һ.б.).

Исемнәрнең кушымчалар белән ясалышы Н.А. Баскаковның каракалпак теле грамматикасында җентекле тикшерелгән. Галимнең фикеренчә, каракалпак телендә ясалма исемнәр ясауда 28 кушымча катнаша. А.Н. Кононов грамматикаларында исемнәр ясалышы лаеклы

урын алып тора. Мәсәлән, үзбәк теле грамматикасында ул исем ясаучы 44 кушымча китерә. «Төрекмән теле грамматикасы» авторлары исем ясаучы 48 кушымча билгелиләр.

Хәзерге вакытта кушымчалар белән сүзләр ясалышы, аерым алганда исемнәр ясалышы турында, берничә зур хезмәт бар. Алар арасында иң алдан Э.В. Севортянның капиталь монографиясен күрсәтергә кирәк. Бу хезмәттә азәрбайҗан телендә кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышы бер системага салып өйрәнелә, кушымчаларның мәгънәләре ясаучы нигезләргә бәйләп ачыла, төрки телләрдә кушымчалар белән сүзләр ясалышына тирән тарихи экскурслар үткәрелә. Төрек галиме Бесим Аталай хезмәтендә кушымчаларның, мисаллар белән ныгытылып, бик зур исемлеге бирелә.

Аерым төрки телләрдә исемнәр ясалышы, шул исәптән кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышы, традицион планда Г.С. Садвакасов, Т.М. Гарипов, А.Х. Соттаев, А.Ю. Бозиев хезмәтләрендә тикшерелә. Азәрбайҗан, кыргыз, карачай-балкар телләрендә сүзьясалыш, шул исәптән кушымчалар белән исемнәр ясалышы, С. Джафаров, Б.О. Орузбаева, М.А. Хабичев хезмәтләрендә өйрәнелә.

Югарыда китерелгән барлык хезмәтләр төрки телләрдәге сүзьясалышны өйрәнүгә зур өлеш кертәләр.

## Татар тел белемендә кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышын өйрәнү тарихына карата

Кушымчалар белән исемнәр ясалышы беренче татар грамматикаларында ук карала башлый. Мәсәлән, И. Гиганов үзенең грамматикасында исемнәрдән һәм фигыльләрдән исем ясаучы берничә кушымча китерә. Ал. Троянский үзенең грамматикасының беренче басмасында исем ясаучы 2 кушымча күрсәтә, икенче басмасында аларның саны арта. М. Иванов исем ясаучы 20 гә якын кушымча китерә, аларның төп мәгънәләрен билгели.

К. Насыйри кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышына нык игътибар итә. Аның фикеренчә, татар телендә исемнәрдән һәм фигыльләрдән исемнәр ясаучы 19 кушымча бар.

XX гасыр башындагы мәктәп грамматикаларында кушымчалар белән исемнәр ясалышында, элекке грамматикалар белән чагыштырганда, яңалык юк. Инкыйлабтан соңгы елларда ук татар теленең өч

грамматикасы басылып чыга, анда сүзләр ясалышы да карала. Мәсәлән, Г. Ибраһимов грамматикасында – 12, Җ. Вәлидидә – 62 (сыйфат кушымчалары белән бергә), Г. Алпаровта – исем ясаучы 14 кушымча тикшерелә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Г. Алпаров *-асы, -мак, -ыйсы* кебек грамматик кушымчаларны да сүзьясагыч итеп карый.

60 нчы елларда В.Н. Хангилдин һәм Д.Г. Тумашева грамматикалары дөнья күрә. В.Н. Хангилдин исем ясаучы – 28, Д.Г. Тумашева – 19 кушымча китерәләр, кушымчаларның мәгънәләрен ачалар. Әмма бу хезмәтләрендә кушымчаларның мәгънәләре тулысынча ачылмый, мәгънәләр ясаучы нигезләргә бәйләмичә билгеләнә. Ф.С. Фасиев терминологиягә бәйләп сүзьясагыч кушымчаларны шактый җентекле тикшерә. 1965, 1970 һәм 1972 елларда басылып чыккан грамматикаларда сүзьясалышны өйрәнүдә, В.Н. Хангилдин грамматикасы белән чагыштырганда, бернинди яңалык юк.

Хәзерге татар телендә исемнәр ясалышында кушымчалау ысулы продуктив һәм ул зур урын тота. Исем ясаучы кушымчалар күп төрле. Мәгънәләренең типлары буенча алар берничәгә бүленә: зат исемнәрен белдерә торган кушымчалар: *-чы/-че*$_1$, *-даш/-дәш, -ыш/-еш, -вык/-век, -чык/-чек*$_1$, *-лы/-ле, -ша/-шә, -ка/-кә*$_1$, *-дак/-дәк, -тараш;* абстракт исемнәр ясый торган кушымчалар: *-лык/-лек*$_1$, *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$, *-ма/ -мә*$_1$, *-ыш/-еш, -ым/-ем, -ыч/-еч, -ынты/-енте, -ымта/-емтә, -ат/-әт;* предмет исемнәрен белдерә торган кушымчалар: *-ча/-чә*$_1$, *-са/-сә, -гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*), *-ма/-мә*$_1$, *-ык/-ек, -к*$_1$, *-ак/-әк, -мак/-мәк, -гын/ -ген* (*-кын/-кен*)$_1$, *-ынты/-енте, -ымта/-емтә, -чык/-чек*$_1$, *-ганак/-гәнәк, -дык/-дек*$_1$, *-тын/-тен*$_1$, *-гак/-гәк* (*-как/-кәк*), *-сак/-сәк*. Предмет белдерә торган кушымчаларны темалары буенча тагын да ваграк төркемнәргә бүләргә мөмкин.

Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, хәзерге татар телендә абстракт исемнәр, зат һәм предмет исемнәре ясый торган бик күп кушымчалар бар. Исем ясый торган кушымчаларны мәгънәләренең типларыннан чыгып бүлү, беркадәр шартлы булса да, аларның табигатен дөрес күзалларга мөмкинлек бирә.

Шуны әйтеп китәргә кирәк, кайбер кушымчалар абстракт исемнәр дә, зат һәм предмет исемнәре дә ясарга мөмкин. Мәсәлән, *-лык/-лек*$_1$ кушымчасы *башлык* сүзендә зат исемен дә, предмет исемен дә белдерә, *аркалык* сүзендә предметны, *гүзәллек* сүзендә абстракт төшен-

чәне тәгъбир итә. Шундый кушымчаларга тагын түбәндәгеләр керә: *-ыш/-еш, -вык/-век, -ма/-мә$_1$, -ым/-ем, -мак/-мәк.*

Исем ясый торган кушымчалар исемнәргә, сыйфатларга, фигыльләргә, саннарга, ияртемнәргә ялганалар.

Мәсәлән, *-чы/-че$_1$, -лык/-лек$_1$, -даш/-дәш, -ча/-чә$_1$, -са/-сә, -лы/-ле, -ак/-әк, -к$_2$* кушымчаларының ясаучы нигезләре булып исемнәр; *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$, *-гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*), *-ыш/-еш, -ш, -ма/-мә$_1$, -ак/-әк, -к$_1$, -ыч/-еч, -вык/-век, -ым/-ем, -выч/-веч, -мак/-мәк, -мыш/-меш, -чын/-чен, -дык/-дек* кушымчаларының ясаучы нигезләре булып фигыльләр; *-чы/-че$_1$, -лык/-лек$_1$, -ча/-чә* кушымчаларының ясаучы нигезләре булып сыйфатлар; *-дык/-дек* кушымчасының ясаучы нигезләре булып ияртемнәр киләләр.

Еш кына бер үк кушымча төрле сүз төркемнәренә караган сүзләргә ялганырга мөмкин. Мәсәлән, *-чы/-че$_1$* кушымчасы исемнәргә (*тимер+че, күн+че*), сыйфатларга (*кадим+че*), саннарга (*мең+че*), фигыльләргә (*күзәт+че*) ялгана ала. *-лык/-лек$_1$* кушымчасы сыйфатларга (*матур+лык, горур+лык*), исемнәргә (*каен+лык, саз+лык*) ялганып килә ала.

Ясаучы нигезләрнең структурасы ягыннан караганда, алар тамыр да (*ак+лык, эш+че*), кушымчалы да (*уз+ыш+чы, утыр+ыш+чы, күн+дәм+лек, хезмәт+тәш+лек*), кушма да (*ил+басар+лык, бер+туган+лык, эч+керле+лек*) булырга мөмкиннәр.

## Хәзерге көндә исемнәр ясый торган кушымчалар

**Нигез+*-чы/-че$_1$* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-чы,* нечкә нигезләргә *-че* ялгана. Бу кушымча хәзерге көндә дә исемнәр ясый һәм бик продуктив. Кушымчаның килеп чыгышы турында тюркологиядә төрле фикерләр бар. Мәсәлән, Н.Ф. Катанов аны *к* авазы төшеп калып, *чик* элементыннан барлыкка килгән дип саный. Н.А. Баскаков бу кушымчаны *-са/-сә* формантыннан килеп чыккан, дигән фикер әйтә. Г. Рамстедт аны кытай-корей телендәге *-ча* (*кеше, зат, ир*) сүзеннән килеп чыккан ди. Бу фикер дөреслеккә туры килә кебек. *-чы$_1$* кушымчасы исемнәрнең төрле лексик-семантик группаларына ялгызлык һәм уртаклык исемнәренә, конкрет һәм абстракт исемнәргә ялгана ала.

Кушымча 1) ялгызлык исемнәренә: *нахимов+чы, суворов+чы, дарвин+чы, мичурин+чы;* 2) уртаклык исемнәренә: *балта+чы, тире+че, җыр+чы, китап+чы, сәгать+че, гармун+чы* кушыла.

Шулай ук кушымча 1) конкрет исемнәргә: *көмеш+че, кран+чы, алма+чы, нефть+че, тимер+че;* 2) абстракт исемнәргә: *гайбәт+че, җинаять+че, республика+чы, мәгърифәт+че* ялгана.

Аның ясаучы нигезләре булып исемнәр, сыйфатлар, саннар һәм фигыльләр килә. Ул саф татар нигезләренә кушыла: *кыр+чы, дау+чы, таш+чы.* Аның ясаучы нигезләре булып алынмалар да килә: 1) гарәп теле алынмалары: *хәзинә+че, кәсап+чы, бәхәс+че, мәдхия+че, ришвәт+че;* 2) фарсы теле алынмалары: *хәлвә+че, кәрван +чы, насвай+чы;* 3) рус теле алынмалары: *станок+чы, заготовка+чы, расчет+чы, забой+чы;* 4) рус теле аша европа телләреннән кергән алынмалар: *парашют+чы, массаж+чы, преферанс+чы, модель+че, гестапо+чы, фокус+чы, кран+чы, турбина+чы, проект+чы, баскетбол+чы, футбол+чы, хоккей+чы, комбайн+чы, гипноз+чы, хор+чы, атом+чы, нефть+че, новелла+чы, мандолина+чы, контор+чы, карикатура+чы, гарпун+чы, штурвал+чы, аренда+чы, слалом+чы.* Бу кушымча белән сүзьясалышның берничә моделе бар.

Исем + *-чы/-че*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән материалдан берәр әйбер ясаучы яки аның белән эш итүче затны: *бакырчы, алтынчы, көмешче.*

2. Ясаучы нигез белдергән материалны әзерләүче затны: *дегетче, күмерче, цементчы.*

3. Ясаучы нигез белдергән материалны җир астыннан чыгаручы затны: *нефтьче, күмерче, ташчы, мәрмәрче.*

4. Ясаучы нигез белдергән коралны, савытны, ашамлыкны, эчемлекне ясаучы яки шуларны сатучы затны: *көпчәкче, иләкче, кашыкчы, мичкәче, чүлмәкче, хәлвәче, кымызчы.*

5. Ясаучы нигез белдергән юл мәгънәсенә бәйләнешле эш белән шөгыльләнүче затны: *сәфәрче, юлчы, ямчы, сәяхәтче.*

6. Ясаучы нигез белдергән терлекне яки кошны караучы затны: *елкычы, терлекче, куянчы, тавыкчы.*

7. Ясаучы нигез белдергән авыл хуҗалыгы азыклары, җимешләре үстерүчене яки аларны сатучы затны: *яшелчәче, игенче, мамыкчы, карбызчы.*

8. Ясаучы нигез белдергән корал белән эш итүче затны: *уракчы, тырмачы, китмәнче, чалгычы.*

9. Ясаучы нигез белдергән транспорт белән идарә итүче затны: *трамвайчы, көймәче, тракторчы, комбайнчы.*

10. Ясаучы нигез белдергән спорт белән шөгыльләнүче затны: *футболчы, волейболчы, көрәшче, баскетболчы, шахматчы.*

11. Ясаучы нигез белдергән акыл хезмәте яки иҗади, фәнни эш белән шөгыльләнүче затны: *хикәяче, тарихчы, рәсемче, әдәбиятчы, телче.*

12. Ясаучы нигез белдергән уен коралында уйнаучы затны: *гармунчы, кубызчы, курайчы, баянчы.*

13. Ясаучы нигез белдергән киекләрне аулаучы затны: *куянчы, төлкече, киекче.*

14. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән шөгыльләнүче затны: *хезмәтче, эшче, имче, һөҗүмче, ярышчы.*

15. Ясаучы нигез белдергән эш өлкәсендә эшләүче затны: *китапханәче, архивчы, конторчы.*

16. Ясаучы нигез белдергән милекнең, кәсәбәнең хуҗасы булган затны: *кибетче, кабакчы, заводчы.*

17. Ясаучы нигез белдергән эшлекленең, агымның тарафдары булган затны: *мәгърифәтче, республиканчы, монархияче, дарвинчы.*

18. Ясаучы нигез белдергән оешмада торучы, шуның әгъзасы булган затны: *думачы, динамочы, спартакчы, партияче.*

19. Ясаучы нигез белдергән кире сыйфат белән характерлана торган затны: *әләкче, гайбәтче, биләмче, интригачы, көнче.*

20. Ясаучы нигез белдергән урында булган яки торган затны: *котыпчы.*

Сыйфат + *-чы/-че*$_1$ моделе. Ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатланучы затны: *кадимче.*

Фигыль + *-чы/-че*$_1$ моделе. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән шөгыльләнүче затны: *өләшче, күзәтче, булышчы.*

Сан + *-чы/-че*$_1$ моделе. Ясаучы нигез белдергән сан белән характерланучы затны: *меңче, егермебишмеңче, йөзче, утызмеңче.*

**Нигез + *-лык/-лек*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча күп мәгънәле һәм бик продуктив. Аның этимологиясе турында берничә караш бар.

В. Котвич, аның *lug-lig* формасы төп форма булып тормый, төп формасы итеп *е* ны санарга кирәк, тунгус телләрендә хәзерге көнгә кадәр *е* күплек санын белдерә, ди.

В. Банг, *-лык/-лек* кушымчасы *эл* дигән мөстәкыйль сүздән килеп чыккан, ди.

Н.А. Баскаков аны мөстәкыйль сүзгә кайтарып калдыра: «Төрки *luk-lük,* мөгаен, яңа уйгыр һәм башка телләрдә очрый торган ‘тулы, күп’ дигән мәгънәдәге *lik* сүзе белән бәйләнгән».

Бу фикергә Д.Г. Тумашева да кушыла. Бу кушымчаның этимологиясе турында М. Рясенен, Ф.Г. Исхаков, А.Г. Голәмев һәм башкаларның әйткән сүзләре бар. Барлык карашлардан, бигрәк тә Н.А. Баскаков фикере дөреслеккә туры килә.

Тулы мәгънәсендәге *лык, лыкма* дигән татар сүзләре *-лык* кушымчасы килеп чыккан мөстәкыйль сүзнең реликтлары булса кирәк.

Мәгълүм булганча, бу кушымча күпчелек очракта абстракт исемнәр ясый. Ясаучы нигезләре булып исемнәр һәм сыйфатлар, сирәгрәк саннар, фигыльләр, хәбәрлекләр, рәвешләр һәм алмашлыклар килә.

Ул күпчелек очракта конкрет исемнәргә ялгана: *су+лык, нарат+лык, ишек+лек, хан+лык.* Чыгарма буларак абстракт исемнәргә дә ялганырга мөмкин: *ышаныч+лык, төш+лек. -лык* кушымчасы кыек килештәге исемнәргә яки хәтта кисәкчә алган исемнәргә дә ялганырга мөмкин: *көн+дә* (*кисәкчә*)*+лек, ис+тә* (*урын-вакыт килеше күрсәткече*)*+лек, эч+тә+лек* (*урын-вакыт килеше күрсәткече*)*, нәсел+дән+лек* (*чыгыш килеше күрсәткече*). Барлык бу исемнәр аерым (индивидуаль) ясалыш тәшкил итәләр. Бу кушымча, югарыда әйтелгәнчә, сыйфатларга ялгана: *күк+лек, көрән+лек, сары+лык, кечкенә+лек, нечкә+лек, батынкы+лык, сукыр+лык, батыр+лык.*

Шулай ук ул, сирәк кенә, фигыль нигезләргә дә кушылырга мөмкин: *кыркы+лык* (диал.), *имез+лек, ягу+лык.*

Бу кушымча кайбер саннарга да кушылып исемнәр ясый: *бер+лек* (*акча*)*, беренчел+лек, өч+лек, йөз+лек, ун+лык.* Сүз бара торган кушымча берничә хәбәрлек сүзгә дә ялгана: *кирәк+лек, бар+лык, юк+лык, тиеш+лек.*

Кайвакыт кушымча рәвешләр белән дә килергә мөмкин: *башкача+лык, үзенчә+лек, бердәй+лек.* Шулай ук ул берничә алмашлыкка да кушылырга мөмкин: *кем+лек, нәрсә+лек, үз+лек, мин-мин+лек.*

*-лык* кушымчасы саф татар сүзләрендә дә, алынмаларга да ялгана. Ясаучы нигезләре булып килгән саф татар сүзләренә мисаллар: *каен+ лык, саз+лык, кырыс+лык, каты+лык.* Ул шулай ук алынмаларга да 1) гарәп сүзләренә: *газиз+лек, вәзир+лек, даhи+лык, гадел+лек;* 2) фарсы сүзләренә: *дәрвиш+лек, гөнаh+лык ялгана*.

Рус теленнән кергән алынмаларга да кушыла: *вестовой+лык, старовер+лык, кенәз+лек, закуска +лык.*

Рус теле аша татар теленә европа телләреннән кергән алынмаларга да ялгана: *декан+лык, ректор+лык, куратор+лык, депутат+лык, диктатор+лык, деспот+лык, агроном+лык, варвар+лык, автоном+ лык, дипломат+лык, дилетант+лык, дезертир+лык, коммерсант+ лык, шаблон+лык, вахтер+лык, шпион+лык, лидер+лык*. Ясалышның бу тибының берничә моделе бар.

Исем + *-лык/-лек*$_1$ моделе. Ул түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән предметларның күп үскән яки күп булган урынны: *юкәлек, каенлык, усаклык, ташлык, комлык, үләнлек, чәчәклек.*

2. Ясаучы нигез белдергән әйбернең саклану яки ташлану урынын: *утынлык, көллек, чүплек, тиреслек, печәнлек, саламлык.*

3. Җәмгыятьтә яки коллективта билгеле бер вазифаны үтәгән затны: *башлык.*

4. Ясаучы нигез белдергән әгъза өчен билгеләнгән җайланманы: *битлек, башлык, авызлык, күзлек, борынлык.*

5. Ясаучы нигез белдергән кием-салым яки аяк киеме җитештерү өчен кирәк булган материалны: *бишмәтлек, чалбарлык, күлмәклек, эчлек, ямаулык, итеклек.*

6. Ясаучы нигез белдергән хуҗалык кирәк-яраклары яки төзү эшләре өчен кирәк булган материалны: *түшәмлек, идәнлек, коймалык, бусагалык.*

7. Ясаучы нигез белдергән вазифа, дәрәҗә, һөнәр исемнәрен: *рәислек, депутатлык, профессорлык, секретарьлык.*

8. Ясаучы нигез белдергән кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең атамасын: *туганлык, әшнәлек, күршелек, дуслык.*

9. Ясаучы нигез белдергән кеше гомерендәге билгеле чорның атамасын: *балалык, үсмерлек, картлык, егетлек.*

10. Ясаучы нигез белдергән сүзләрнең мәгънәсе белән билгеле бер метафорик бәйләнеше булган кешенең рухи халәтен, холкын: *бозаулык, әтәчлек, этлек, төлкелек, кешелек, хайванлык.*

11. Ясаучы нигез белдергән мәгънәгә бәйләнешле: а) фәнни, иҗтимагый-сәяси, әдәби һ.б. агымнарның исемнәрен: *декадентлык;* б) дини инанулар исемнәрен: *христианлык, мөселманлык, буддистлык.*

12. Ясаучы нигез белдергән башлык белән идарә ителүче илнең исемен: *корольлек, ханлык, патшалык.*

13. Ясаучы нигез белдергән вәкил яки төркем белән атала торган җәмгыять исемен: *ыруглык, феодаллык.*

Сыйфат + *-лык*/*-лек*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Кешенең ясаучы нигез белдергән физик билгеләренең атамасын: *пеләшлек, сукырлык, аксаклык, чукраклык.*

2. Предметларның ясаучы нигез белдергән форма (шәкел) исемнәрен: *юкалык, калынлык, киңлек, тарлык, озынлык.*

3. Ясаучы нигез белдергән физик үзенчәлекләрнең атамасын: *катылык, тыгызлык, сыгылмалык, куелык, җылылык.*

4. Ясаучы нигез белдергән төсләрнең исемен: *кызыллык, аклык, күклек, сарылык.*

5. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлекләрнең булуын: *бетчәлелек, мүклелек, төерлелек, керлелек, тозлылык.*

6. Кешеләрнең ясаучы нигездә белдерелгән рухи үзенчәлекләрен һәм хисси халәтләрен: *ялкаулык, уңганлык, батырлык, азгынлык, кирелек, изгелек, шатлык, күңелсезлек.*

Сан + *-лык*/*-лек*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Кыйммәте ясаучы нигездә белдерелгән акча берәмлекләренең атамасын: *унлык, йөзлек, меңлек.*

2. Ясаучы нигез белән бәйләнешле абстракт мәгънәләрне: *берлек, бергәлек* ‘союз’.

Фигыль + *-лык*/*-лек*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән әсбапны: *имезлек.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән материалны: *ягулык.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән урынны: *чабулык.*

Рәвеш + *-лык/-лек*$_1$ моделе берәр төрле үзенчәлекне яки билгене аңлата торган абстракт мәгънәне белдерә: *башкачалык, бердәйлек, азлык, күплек.*

Алмашлык + *-лык/-лек*$_1$ моделе кешенең яки нәрсәнең дә булса асылының атамасын белдерә: *кемлек, нәрсәлек, үзлек.*

Хәбәрлек + *-лык/-лек*$_1$ моделе ясаучы нигез белән бәйләнешле абстракт мәгънәне белдерә: *юклык, тиешлек, кирәклек.*

**Нигез + *-даш/-дәш* (*-таш/-тәш*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-даш/-таш,* нечкә нигезләргә *-дәш/-тәш* кушымчасы ялгана. Сузыклардан һәм яңгыраулардан соң *-даш/-дәш,* тартыклардан соң *-таш/ -тәш* килә.

Кушымчаның этимологиясе турында берничә төрле караш бар. Бер иш тикшеренүчеләр, *-даш* кушымчасы ике элементтан: *-да* элементыннан (урын-вакыт килеше күрсәткече) һәм *иш* дигән сүздән тора, диләр. Икенчеләре, *-да* элементы фигыль ясаучы кушымча, *-ш* элементы юнәлеш ясаучы яки исем ясаучы кушымча тәшкил итә, дип саныйлар. Өченче төркем тикшеренүчеләр (К. Менгес, С.Н. Моратов), *-даш* кушымчасы борынгы *даш* (*иптәш*) дигән сүзгә барып тоташа, дип раслыйлар. Бу сүз хәзерге фарсы телендә очрый, әмма ул телгә бу сүз төрки телләрдән кергән. С. Джафаров, киресенчә, аны фарсы теленнән төрки телләргә кергән, дип саный иде, ләкин соңыннан ул бу фикереннән баш тартты. К. Менгес һәм С.Н. Моратов карашы дөреслеккә якын һәм аны кабул итәргә була.

*-даш* кушымчасы, кагыйдә буларак, исемнәргә ялгана: *исем+дәш, заман+даш, көрәш+тәш, кабилә+дәш, ыру+даш.* Ул шулай ук сыйфатларга (*тиң+дәш*) һәм сирәк кенә фигыльләргә (*утыр+даш*) кушылырга мөмкин. Бу кушымча саф татар сүзләренә һәм алынмаларга да ялгана.

Саф татар нигезләренә мисаллар: *як+таш, туган+даш, авыл+даш, бүлмә+дәш.* Алынмалардан гыйбарәт ясаучы нигезләр: а) гарәп һәм фарсы телләре сүзләре: *сыйныф+таш, гапь+тәш, фикер+дәш, нәсел+дәш;* б) рус теленнән һәм рус теле аша европа телләреннән кергән сүзләр: *фамилия+дәш, курс+таш, автор+даш.*

Сүзьясалышның бу тибы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән урында бергә торган, яшәгән затны: *якташ, авылдаш, өйдәш, ватандаш.*

2. Ясаучы нигез белдергән яшькә туры килгән яки шул вакытта яшәгән затны: *яшьтәш, замандаш, елдаш.*

3. Ясаучы нигез белдергән ыругка, нәселгә һ.б.ш.га бәйле затны: *ыругдаш, кабиләдәш, тугандаш, милләттәш.*

4. Ясаучы нигез белдергән урында бергә хезмәт итүче, эшләүче, яки укучы затны: *курсташ, полкташ, сыйныфташ.*

5. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәттә катнашучы затны: *әңгәмәдәш, юлдаш, иҗатташ, сабакташ.*

6. Ясаучы нигез белдергән милеккә уртак хуҗа булган затны: *милектәш, варисташ.*

7. Ясаучы нигез белдергән фикерне, дөньяга карашны уртаклашучы затны: *фикердәш, мәсләктәш, сердәш.*

8. Ясаучы нигез белдергән корал белән бергә эш итүче затны: *коралдаш, каләмдәш.*

**Нигез + *-лы/-ле* кушымчасы.** *-лы* кушымчасы калын сүзләргә, *-ле* кушымчасы нечкә сүзләргә ялгана. Хәзерге татар телендә *-лы* кушымчасы исемнәр һәм сыйфатлар ясауда катнаша. Күпчелек галимнәр бу кушымчаны *-лык* кушымчасыннан килеп чыккан дип саныйлар. Кушымчаларның семантик һәм кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып караганда, бу фикер белән тулысынча килешергә мөмкин. Татар теленең үсеш процессында билгеле булганча, нинди дә булса ил, шәһәр, авыл, кайвакытта берәр милләт яки этник төркем вәкиле *-лык* кушымчасы белән белдерелгән: *казанлык, болгарлык, бохарлык. Казанлы* сүзен шул ук мәгънәдәге (*казанлык* сүзеннән килеп чыккан дип фараз кылу бик табигый һәм логикага сыя. Сүз ахырындагы *к* төшеп калган.

Кушымча яңа сүзләр ясаганда тик исемнәргә генә ялгана: *бөгелмә+ле, латвия+ле, уфа+лы, казан+лы, биш+ле.*

Исем + *-лы/-ле* моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән илдә, шәһәрдә һ.б.ш. урында яшәүче затны: *америкалы, мисырлы, дагстанлы, татарстанлы, һиндстанлы.*

2. Ясаучы нигез белдергән милләткә караган затны: *литвалы.*

3. Ясаучы нигез белдергән лагерьга, төркемгә караган затны: *колчаклы.*

Сан + *-лы/-ле* моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән мәктәп билгесенең исемен: *икеле, өчле.*

2. Кәрт уенының исемен: *тугызлы, егерме берле.*

*-лы* кушымчасы бер үк сүзгә ялганып, милләт вәкилен дә һәм шул илнең кешесен дә белдерергә мөмкин, мәсәлән, *америкалы* сүзе ике мәгънәгә ия: Америкада яшәүчене дә һәм Төньяк Америка милләте вәкилен дә белдерә.

Хәзерге татар телендә милләт вәкиле бары сүзнең нигезе белән генә дә белдерелергә мөмкин: *һинд, кытай, япон.* Мисаллар: *Без тимерюл үткәрсәк, әгелчәннең һ и н д л ә р белән сәүдәсенә китереп суга.* Ә. Фәйзи. *Машина туктагач, ул, майор янына килеп, к ы т а й г а карамаска тырышып, пышылдап кына әйтте.* А. Шамов. *Я п о н н а р да чапан кисен диеп, куптармаңыз җәнҗал!* Г. Тукай.

**Нигез + *-ча/-чә*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ча,* нечкә нигезләргә *-чә* ялгана. Бу кушымчаны белгечләр терминнар, бигрәк тә техник терминнар ясау өлкәсендә киң кулланалар: *йодрыкча.* Аның этимологиясе турында бердәм фикер юк. Мәсәлән, Г. Рамстедт, *-ча* кушымчасы, мөгаен, *-ч* ның *-ай* кушымчасы белән кушылуыннан килеп чыккан, дип саный. Н.А. Баскаков белән А.Г. Голәмев аны, *-чык* дигән кечерәйтү кушымчасының фонетик үзгәрешенең нәтиҗәсе, дип карыйлар. Ж. Дени, *-ча* кушымчасы вакыт мәгънәсендәге *чак* сүзенә барып тоташа, ди. Бу кушымча «шундый», «охшаш» дигән мәгънәдәге *-чак, -тәк, -тик* сүзләренә барып тоташа булса кирәк, чөнки кушымчаның һәм китерелгән сүзнең семантик эчтәлеге бер-беренә тулысынча туры килә, кушымчаның ялгану үзенчәлеге һәм сүзнең структурасы бик табигый килеп чыга. *-ча*$_1$ кушымчасы исемнәргә, сыйфатларга, фигыльләргә ялгана.

Ясаучы нигезләре исем булган сүзләр: *сабак+ча, орлык+ча, сызык+ ча, бармак+ча, ак+ча* (*ак* – кыйммәтле әйбер, көмеш).

Ясаучы нигезләре сыйфат булган сүзләр: *яшел+чә, сыек+ча, кызыл+ча.*

Ясаучы нигезләре фигыль булган сүзләр: *төшен+чә, бәр+чә.*

Бу кушымча бары татар сүзләре белән генә килә: *табан+ча, чыбык+ча, сызык+ча.*

Исем + *-ча/-чә*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән предметның кечерәк аналогы булган предметны: *сабакча, сүзлекчә, мыекча.*

2. Ясаучы нигез белдергән әгъза өчен хезмәт итә торган әйберне: *бармакча, күкрәкчә, чигәчә.*

3. Ясаучы нигезгә берәр ягы белән бәйләнгән үсемлекләрнең, бөҗәкләрнең һ.б. ның атамасын: *орлыкча, кабакча, көлчә.*

Фигыльгә ялганып, абстракт исем ясый: *төшенчә.*

*Кодача* сүзендәге *-ча* кушымчасының бу кушымчага бернинди дә бәйләнеше юк (чагыштыр: *бик+әч, хан+ча*).

**Нигез + *-чык/-чек*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-чык,* нечкә нигезләргә *-чек* ялгана. Чынбарлыкта исә бу кушымча телдә киң кулланыла торган стилистик кушымча булып тора: *кызчык, китапчык, өстәлчек* һ.б. Шуның белән бергә бу кушымчаның сүзьясагыч функциясе дә бар.

Бу кушымчаны Ж. Дени вакыт мәгънәсендәге *чак* сүзенә кайтарып калдыра. Бу фикергә, нигездә, Э.В. Севортян да кушыла. Г. Рамстедт, ул ике кисәктән – *ч+ак* элементларыннан тора, дип саный. А. фон Габен, ул ике кушымча (*ч+ак*) кушылуыннан килеп чыккан, ди.

*-чык/-чек*$_1$ кушымчасы стилистик һәм сүзьясагыч функциясендә дә «кечкенә, бәләкәй» дигән мәгънәдәге *чак* сүзенә барып тоташа. Аның бу ике функциядә дә семантикасы сакланып калган. Дөрес, сүзьясагыч функциясендә мәгънәсе бераз үзгәргән, әмма тулысынча түгел.

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып исемнәр һәм фигыльләр килә.

Ясаучы нигезләре исемнәр булган сүзләр: *кап+чык, уен+чык, ян+чык.*

Ясаучы нигезләре фигыльләр булган сүзләр: *кабар+чык, мәтәл+чек, вал+чык, бөркән+чек, бөтер+чек.*

Ясаучы нигезләрнең барысы да саф татар сүзләре.

Исем + *-чык/-чек*$_1$ моделе ясаучы нигез белән бәйләнгән әйберне белдерә: *уенчык, капчык.*

Фигыль + *-чык/-чек*$_1$ моделе. Ул түбәндеге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә хезмәт итә торган предметны (әйберне): *бөркәнчек, бөтерчек.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе буларак килеп чыккан предметны (әйберне): *кабарчык, мәтәлчек, җыерчык, валчык.*

Бу кушымча *чыпчык, сыерчык, орчык* кебек сүзләрдә дә очрый. *Чыпчык* дигән сүздә ясаучы нигез, бәлки, аваз ияртеме булып торадыр.

**Нигез + *-чылык/-челек* кушымчасы.** Кушымчаның структурасы бик ачык, ул ике элементтан (*-чы* һәм *-лык*) кушылып ясалган. Та-

мыр сүзләргә ялганып, ул беренчел ясалма сүзләр ясый: *ким+челек, аз+чылык.* Татар телендә *кимче* һәм *азчы* дигән сүзләр юк, шуңа күрә китерелгән мисалларда *-чылык* комплексы тамыр сүзләрдән беренчел ясалма сүзләр барлыкка китерә торган катлаулы кушымча тәшкил итә.

Кайвакытларда *-чылык* кушымчасының ясаучы нигезен билгеләгәндә, кыенлыклар килеп чыга. Мәсәлән, *кошчылык* дигән сүз кайсы нигездән ясалган – *кош* сүзеннәнме, яки *кошчы* сүзеннәнме? Фәнни анализ бу сүзнең семантикасы, сүзьясалыш мәгънәсе *кошчы* сүзеннән түгел, *кош* сүзеннән килеп чыкканын күрсәтә. Аның мәгънәсе *кошчы* сүзе белән бәйләнгән булса, ул вакытта бу сүз профессия атамасын белдерер иде. Бу кушымча исемнәргә, сыйфатларга, рәвешләргә ялганып килә.

Ясаучы нигезләре исем булган сүзләр: *урын+чылык, суфый+чылык, мәктәп+челек, дәүләт+челек, бакча+чылык, иген+челек.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган сүзләр: *арзан+чылык, кыйбат+чылык, түбән+челек, имин+челек.*

Бу кушымча саф татар сүзләренә дә, алынмаларга да ялгана.

Саф татар сүзләре булган ясаучы нигезләр: *түгәрәк+челек, ким+челек, урын+чылык.*

Рус теленнән кергән ясаучы нигезләр: *кулак+чылык.*

Рус теле аша европа телләреннән алынган ясаучы нигезләр: *культура+чылык, плебей+чылык.*

Исем + *-чылык*/*-челек* моделе. Ул түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән идея, фән, көнкүреш күренеше атамасын: *мөритчелек, урынчылык, мәктәпчелек, шәһәрчелек, славянчылык;*

2. Ясаучы нигез белдергән җәмгыять төзелешенең исемен: *феодалчылык, кабиләчелек, дәүләтчелек;*

3. Ясаучы нигез белдергән хуҗалык, кәсеп тармагының атамасын: *игенчелек, яшелчәчелек, кошчылык, умартачылык;*

4. Җыймалык мәгънәсен: *эшмәкәрчелек, җәмәгатьчелек.*

Сыйфат + *-чылык*/*-челек* моделе ясаучы нигез белдергән абстракт билге атамасын (исемен): *арзанчылык, кыйммәтчелек, азчылык.*

**Нигез + *-сызлык*/*-сезлек* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-сызлык,* нечкә нигезләргә *-сезлек* ялгана. Бу кушымча белән ясалган сүзләр күп түгел. Аның структурасы бик ачык: ул ике элементтан (*сыз+лык*) гыйбарәт булып катлаулы кушымча тәшкил итә. Әмма аны *-сыз*

кушымчалы ясаучы нигезгә *-лык* кушымчасының ялгануыннан аерырга кирәк. Мәсәлән, *эшсез* дигән беренчел ясалма сүзгә *-лек* кушымчасы ялганып, *эшсезлек* дигән икенчел ясалма сүз ясалырга мөмкин. Бу очракта *эшсезлек* сүзендәге *сезлек* комплексы бер бөтен кушымча тәшкил итми, аның кисәкләре төрле сүз төркемнәренә карыйлар: *-сез* кушымчасы сыйфат, *-лек* кушымчасы исем ясый. Боларны аеру критерийлары *-чылык* кушымчасыныкы кебек. Әгәр *-сызлык* кушымчасына тәмамланган сүзнең *-сыз* кушымчасы ясаучы нигезе булмаса, ул вакытта бу кушымча, һичшиксез, бер бөтен кушымча булып тора. Мәсәлән, *саусызлык* сүзендә ясаучы нигез булып *сау* сүзе килә, чөнки татар телендә *саусыз* дигән реаль сүз юк, шуңа күрә *саусызлык* сүзендәге *-сызлык* кушымчасы бер бөтен кушымча тәшкил итә. (*Мин саусызлыктан зарланмыйм.* Р. Зиятдинов).

Бу кушымча сыйфатларга (*сау+сызлык, дуамал +сызлык, пөхтә+сезлек*), исемнәргә (*күрем+сезлек, абай+сызлык*) ялгана. Кайбер вакытта ясаучы нигезләре булып алынмалар да килергә мөмкин: *пөхтә+сезлек* (*пөхтә* – фарсы сүзе).

*Сыйфат + -сызлык/-сезлек* моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Берәр төрле кимчелекне яки бик үк яхшы булмаган хәлне: *саусызлык, абайсызлык.*

2. Уңай үзенчәлек, үзлек мәгънәсен: *дуамалсызлык.*

**Нигез + *-лылык/-лелек* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-лылык,* нечкә нигезләргә *-лелек* ялгана.

Бу кушымча *-лы+лык* кисәкләреннән гыйбарәт булып, катлаулы кушымча тәшкил итә. Үзенең тышкы структурасы ягыннан *-лы* кушымчасына тәмамланган сүзләрдән *-лык* кушымчасы белән ясалган комплексны хәтерләтә (чагыштыр: *һава+лы+лык, әдәп+ле+лек, партия+ле+лек*). Аларны аеруның критерийлары булып *-чылык* һәм *-сызлык* кушымчаларында китерелгән билгеләр тора. Әгәр *-лы* кушымчасына тәмамланган ясаучы нигез булмаса, шул ук нигездәге *-лылык* үзе катлаулы кушымча булып чыга.

Бу кушымча исемнәргә (*утопия+лелек*), сыйфатларга (*конкрет+ лылык*) ялгана. Чыгарма буларак рәвешләр белән дә килергә мөмкин: (*үзенчә+лелек*). Кушымча саф татар сүзләренә дә, алынмаларга да кушыла кала: *утопия+лелек* (рус теле аша грек теленнән алынган сүз).

Бу кушымча белән килгән нигез абстракт үзенчәлекнең яки билгенең атамасын белдерә: *утопиялелек, үзенчәлелек.*

**Нигез + *-лар/-ләр* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-лар,* нечкә нигезләргә *-ләр* ялгана. *-лар/-ләр* кушымчасы күплекне белдерә торган грамматик формант. Шуңа карамастан татар телендә ул сүзьясагыч чара буларак та килергә мөмкин. Кушымчаның этимологиясе турында бик киң әдәбият бар. А.Н. Кононов әйтүенчә, галимнәр бу кушымчаны тулы мәгънәле мөстәкыйль сүздән китереп чыгарырга омтылдылар. Н. Поппе һәм Д. Синор фикеренчә, ул күплекне белдерә торган ике (*л+р*) кушымчадан гыйбарәт. Хезмәтеннән күренгәнчә, А.Н. Кононов та шул фикер яклы. Безнеңчә, бу кушымчада чыннан да ике кушымча кушылган, әмма беренчесе күплекне түгел, ә иялекне белдерә торган *-лы* кушымчасына барып тоташа, икенчесе борынгы күплек кушымчасы *-р* дан гыйбарәт. *-лы* кушымчасы, мәсәлән, *лыкма* сүзендә күренә.

Ясаучы нигезләр булып исемнәр – ялгызлык исемнәре килә: *мәскәүләр, аланбашлар.* Мисаллар: *Ни кылырсың, Хаҗи абзый, тотса, мәскәүләр якаң?* Г. Тукай. *Аланбашлар аларның борыннарын җимереп, кулларын тайдырып җибәрә торган булганнар*. Г. Бәширов.

Кайчак сыйфатлар да ясаучы нигез булып торырга мөмкиннәр: *кызыл+лар, яшел+ләр.*

Исем + *-лар/-ләр* моделе ясаучы нигез белдергән торак пунктында яшәүче затларны белдерә: *минзәләбашлар, нисебашлар, мәскәүләр.*

*-лар* кушымчасы үзенең төп грамматик мәгънәсенә бәйләнешле рәвештә, берлектәге затны белдерә алмый. Моның өчен татар телендә *-лы* кушымчасы файдаланыла (*казанлы*). Хәзерге телдә, кагыйдә буларак, бер урында яшәүче кешеләрне белдерү өчен *-лы* кушымчасына тәмамланган сүзләргә *-лар* кушымчасы ялгана. Шулай итеп, бу очракта *-лар* кушымчасы үзенең сүзьясагыч функциясен югалта. Биредә, күрәсең, телнең грамматик һәм сүзьясагыч функцияләрен ачык итеп аерырга омтылуы чагыла.

Сыйфат + *-лар/-ләр* моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Билгеле бер төркемгә караган затларның исемен: *аклар, кызыллар, яшелләр.*

2. Ясаучы нигездә белдерелгән үзенчәлекне билге буенча үсемлекләр һәм хайваннар төрләренең атамаларын: *энәтирелеләр, иренчәчәклеләр, оешмачәчәклеләр.*

**Нигез+*-гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-гыч*/*-кыч,* нечкә нигезләргә *-геч*/*-кеч* кушымчасы ялгана.

Кушымча бик продуктив, аның ярдәмендә күп фәнни-техник терминнар ясала. Аның этимологиясе турында бердәм караш юк. Мәсәлән, Г. Рамстедт, кушымча ике:*-гы* һәм *-ыч* кушымчалары берегү юлы белән килеп чыккан, дип раслый. Н.А. Баскаков аны, *-гъу+-чы* кушымчасына мөнәсәбәтле, дип саный. А.Г. Голәмев, *-гы* кушымчасыннан килеп чыккан катлаулы кушымча, дип карый. Бу кушымча, һичшиксез, катлаулы кушымча булып тора. Ул корал белдерә торган *-гы* кушымчасыннан һәм *-чы*$_2$ кушымчасыннан гыйбарәт. Кушымча бары фигыльләр белән генә килә. Күпчелек очракта аның ясаучы нигезләрен күчемле фигыльләр тәшкил итә: *беркет+кеч, үткәр+ геч, чиклә+геч, җилгәр+геч, җылыт+кыч.* Сирәк кенә күчемсез фигыльләр дә ясаучы нигез булырга мөмкин: *шартла+гыч, оч+кыч, таян+гыч.*

Бу кушымча бары саф татар сүзләренә генә ялгана.

Фигыль + *-гыч*/*-геч* (*-кыч*/*-кеч*) моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән коралны, әсбапны, җайланманы: *сөзгеч, кыргыч, очкыч, болгаткыч, җилгәргеч, чапкыч.*

2. Ясаучы нигез белдергән эшне, хәлне башкару өчен хезмәт итә торган матдәне: *әчеткеч, тәмләткеч.*

3. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлеккә ия затны яки хайванны: *ерткыч, корткыч, белгеч.*

4. Абстракт мәгънәле фәнни төшенчәләрне: *ясагыч, теркәгеч, төрләндергеч.*

**Нигез + *-ыш/-еш, -ш*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ыш,* нечкә нигезләргә *-еш* кушымчасы ялгана, *-ыш*/*-еш* тартыкларга тәмамланган нигезләргә, *-ш* сузыкларга тәмамланган нигезләргә кушыла. Бу кушымча шулай ук бик күп сүзләр ясый. Ул бигрәк тә фәнни һәм техник терминнар ясауда еш кулланыла. Аның этимологиясенә багышланган махсус тикшеренүләр юк. В.Н. Хангилдин фикеренчә, бу кушымча ике аерым кушымчадан: исем фигыль кушымчасыннан (*борыл+ыш*) һәм уртаклык юнәлеше кушымчасыннан (*талаш, кычкырыш*) гыйбарәт. Азәрбайҗан телен тикшерүче галим Э.В. Севортян нигездә шул ук фикердә тора.

Лексик-семантик һәм морфологик билгеләреннән чыгып караганда, *-ыш* кушымчасы, эш-хәрәкәт атамасын белдергәндә, *эш* сүзенә барып тоташа. Ясаучы нигезләре булып бары фигыльләр генә килә.

Кайвакыт нигез белән кушымча арасында *й* авазы барлыкка килә. Мәсәлән, *яшә* дигән нигезгә *-еш* кушымча ялганганда шул аваз пәйда була. Безнең карашыбызча, ул аваз нигез белән кушымча арасындагы, татар теленә хас булмаган хиатусны (ачыклыкны) бетерү өчен барлыкка килә. Бу аваз, һичшиксез, сүзьясагыч түгел, интерфикс, морфологик чара булып тора.

*-ыш*$_1$ кушымчасы татар сүзләре белән килә. Кайчак нигезләрнең тамырлары алынма булырга мөмкин: *нур+ла+ныш* (тамыр гарәп сүзе), *план+лаштырыл+ыш* (тамыры латин сүзе).

Фигыль + *-ыш/-еш, -ш*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш, хәрәкәтнең атамасын: *ясалыш, камалыш, үсеш, тукланыш, үзгәреш, очыш.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсен: *чигеш, отыш, күренеш, чагылыш.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең, процессның ысулын, алымын: *башкарылыш, торыш, йөреш, яшәеш, бөгелеш, тезелеш.*

**Нигез + *-ма/-ма*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча ярдәмендә шактый күп фәнни-техник терминнар ясалган һәм ясала. Аның этимологиясенә берничә галим тукталып уза. Мәсәлән, Г. Рамстедт кушымчаны, *-м* элементыннан һәм сыйфат ясаучы *-а* кушымчасыннан торган катлаулы кушымча, дип саный.

Н.А. Баскаков аны, генетик яктан *-мак/-мәк* кушымчасы белән бәйләнгән, дип саный. Бу кушымча үзенең лексик-семантик һәм структур үзенчәлекләре буенча борынгы исем фигыль кушымчасы *-мак/-мәк* белән бәйләнгән, ул үзенең үсеш процессында *-ма/-мә* кушымчасы биргән. Мәсәлән, татар телендәге *сырма* сүзе каракалпак телендә шул ук мәгънәдәге *сырмак* сүзенә тәңгәл килә. Бу хәл *-мак* кушымчасы белән *-ма* кушымчасы арасында генетик бәйләнеш булу турында сөйли. *-ма*$_1$ кушымчасы, кагыйдә буларак, фигыль нигезләргә ялгана: *аер+ма, ашла+ма, хисаплан+ма, ту+ма, яр+ма, бүл+мә, төнәт+мә, туңдыр+ма.* Чыгарма буларак кына исемнәргә

ялганырга мөмкин: *уч+ма, шөлдер+мә.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ма/-мә*$_1$ моделе. Фигыльләргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйберне: *ярма, бүлмә, сөзмә.*

Шул юл белән ясалган сүзләр: а) төзелгән нәрсәләрнең исемнәрен: *корылма, ныгытма;* б) коралларның, әсбапларның атамаларын: *эшләнмә;* в) тукымаларның, киемнәрнең исемнәрен: *сырма, тукыма, чалма;* г) ашамлык исемнәрен: *кабартма, күпертмә, ярма;* д) матдә исемнәрен: *эремә, эретмә, әчемә, катнашма;* е) авыру (чир, хаста) исемнәрен: *чабыртма;* ж) табигать күренешләре исемнәрен: *убылма, шарлама.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш өчен хезмәт итә торган әйберне: *каптырма, бастырма, каплама, белешмә.*

3. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлеккә ия булган затны: *тотлыкма.*

4. Ясаучы нигез белән бәйләнешле абстракт төшенчәләрне: *берләшмә, билгеләмә, тигезләмә.*

5. Ясаучы нигез белдергән процессның атамасын: *утырма, киңәшмә.*

Исем + *-ма/-мә*$_1$ моделе ясаучы нигезгә якын мәгънәне белдерә: *шөлдермә, учма.* Бу кушымчаның нигездән аерылмаган очраклары да бар: *торма, төймә.*

**Нигез + *-ык/-ек, -к*$_1$ кушымчасы.** Киң әйтелешле *-ак/-әк, -к* кушымчасы аның фонетик варианты түгел, мөстәкыйль кушымча. С. Джафаров, Ж. Дени, А. Зайончковский һ.б. шул ук фикерне яклыйлар. Н.А. Баскаков аны, *-гак/-как* кушымчасыннан килеп чыккан, дип саный. Башкорт теле белгече Т.М. Гарипов аның фикеренә кушыла. Рамстедт бу кушымчада, мөгаен, төрле күренешләр кушылган, шуңа күрә барлык алтай телләре өчен туры килгән бер типлар билгеләве мөмкин түгел, дип яза.

*-ык/-ек, -к*$_1$ кушымчасы барлык очракларда да түгел, бары үзенең аерым мәгънәләрендә генә *-гак/-кәк* кушымчасына барып тоташа. Аның ясаучы нигезләре булып фигыльләр килә: *йөткер+ек, тиш+ек, кирт+ек, төкер+ек, бүл+ек, боер+ык, бастыр+ык, кун+ык, яр+ык, сыз+ык.*

Сузык авазларга тәмамланган ясаучы нигез белән кушымча арасында татар теле өчен хас булмаган ачыклыкны (хитаусны) бетерү өчен «в (w)» интерфиксы барлыкка килә. Элемент «в (w)»кушымча составына керми, ул морфонологик чара булып тора: *мышна+в+ык, тәтелдә+в+ек.*

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-ык/-ек, -к*$_1$ кушымчасы. Түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсендә барлыкка килгән (хасил булган) әйберне: *киртек, черек, ватык, көек.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтне башкару өчен хезмәт итә торган коралны, әсбапны: *бастырык, шалтыра+в+ык, шапылда+в+ык.*

3. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерланучы затны: *мышна+в+ык, лыгырда+в+ык.*

4. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең, тавышның атамасын: *кычкырык, күкрә+в+ек, гөрелдә+в+ек.*

5. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлеккә ия булган урынны: *кичек* (иск.), *тупла+в+ык, тетрә+в+ек.*

Бу кушымча белән ясалган сүзләргә, мөгаен, түбәндәге сүзләр керә: *кыз+ык* (*кыз* нигезе *күз кызу* дигәндәге *кызу* сүзендә сакланган), *ким+ек* (*ким* элементы, мәсәлән, *кимерү* сүзендә очрый), *каб+ык* (*каб* сүзе борынгы төрки телдә *каплау* мәгънәсен белдергән), *кав+ык, күр+ек* (*күр* нигезе *күрү* фигыле белән бәйләнгән булса кирәк), *күб+ек* (*күп* нигезе *күбү* фигыленнән килә), *ку+ык* (*ку* нигезе *буш* дигәнне белдерә) һ.б.

**Нигез + *-ак/-әк, -к*$_1$ кушымчасы.** С. Джафаров, *-ык/-ек, -к*$_1$ һәм *-ак/-әк, -к* кушымчалары – мөстәкыйль кушымчалар, дип исбатлый. Э.В. Севортян фикеренчә, -(*а*)*к* кушымчасы -(*ы*)*к* кушымчасы белән тугандаш булса да, кайбер очракларда мөстәкыйль кушымча булып тора. Тюркологларның күпчелеге бу кушымчаның килеп чыгышын *-гак/-гәк* кушымчасы белән бәйли.

*-ак/-әк, -к*$_1$ кушымчасы фигыльләргә ялгана: *ур+ак, бүл+әк, ят+ак, тор+ак, тел+әк.* Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ак/-әк, -к*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән сыйфатка ия булган затны: *аксак, елак, килмешәк.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган корал яки чараны: *иләк, кадак, терәк, тарак, көрәк.*

3. Ясаучы нигез белдергән хәл өчен билгеләнгән урынны: *ятак, торак.*

4. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны яки нәрсәне: *сөйләк, теләк, бүләк.*

Фигыльләрдән сүз ясый торган *-ак/-әк, -к*$_1$ кушымчасы тагын түбәндәге сүзләрдә очрый, әмма аларның нигезләре аерылмый: *тайак, тулгак* (*тулга* сүзе диалектларда *эләктерү* мәгънәсендә очрый).

**Нигез + *-ым/-ем, -м*$_1$ кушымчасы.** Ясаучы булып фигыльләр килә: *атла+м, аг+ым, кил+ем, катла+м, ал+ым, сөйлә+м.*

Фигыль + *-ым/-ем, -м*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны (әйберне): *тезем, сызым, бәйләм, савым.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең атамасын: *сөйләм, агым, явым.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән әйберне: *кием, йолым, җим.*

4. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән башкарыла торган үлчәм мәгънәсен: *йотым, чеметем, тотам, чакырым.*

**Нигез + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$ кушымчасы.** Н.А. Баскаков бу кушымчаны *-гык* кушымчасыннан китереп чыгара. Азәрбайҗан теле белгече С. Джафаров аның фикере белән килешә.

Кушымча фигыльләргә ялгана: *той+гы, көл+ке, чабырт+кы, ярал+гы, әчет+ке, чабыш+кы, кач+кы (*диал.).

Фигыль + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән коралны һәм әсбапны: *чәнечке, чапкы, чалгы, киерге, себерке, соскы, сөзге* (диал.)

2. Ясаучы нигез белдергән процесс өчен билгеләнгән матдәне: *оеткы, әчетке.*

3. Ясаучы нигез белдергән процессның, халәтнең нәтиҗәсе булган предметны: *тойгы, көлке, чабыртқы, яралгы.*

4. Ясаучы нигез белдергән хәлнең яки эш-хәрәкәтнең атамасын: *коткы, эчке. Степан эчкегә бирелеп, шешенеп үлде.* Ш. Камал. Бу мәгънәгә диахроник планда караганда *йокы* сүзе дә карый. Бу сүзнең структурасында авазлар метатезасы килеп чыккан, иске татар телендә ул *уйкы* формасында булып, *уй – ой, -ойы* нигез тәшкил иткән. Бүгенге күзлектән *йокы* сүзе, һичшиксез, ясалма сүз булып тормый.

5. Ясаучы нигез белдергән билгегә ия затны яки хайванны: *качкы, чабышкы.*

Сүзьясалышның бу тибына тагын *сөлге, карачкы, быргы, сыбызгы, елкы* сүзләре карый. Хәзерге татар телендә *сөл* (төрек телендә *сөртү* мәгънәсендә йөри), *быр, сыбыз, карач* нигезләре булмаганлыктан аларны ясалма сүзләр дип карап булмый.

**Нигез + *-ыч/-еч, -ч* кушымчасы.** Бу кушымчаның килеп чыгышы турында тюркологиядә берничә гипотеза бар. Мәсәлән, Н.Ф. Катанов аны *-ыш* кушымчасыннан китереп чыгара. Азәрбайҗан телен тикшерүче С. Джафаров аны, *-гыч* кушымчасыннан килеп чыккан, дип раслый. Г.И. Рамстедт фикеренчә, *-ыч* кушымчасы *-чак* кушымчасының фонетик үзгәрешенең нәтиҗәсе. Исем ясаучы буларак бу кушымча генетик яктан *-гыч* кушымчасы белән бәйләнгән. Хәзерге татар телендә бер үк нигездән, әмма төрле кушымчалар белән ясалган сүзләрнең бер үк мәгънәгә ия булуы бу фикер файдасына сөйли: *таяныч* һәм *таянгыч.*

Кушымча фигыльләргә ялгана: *чүке+ч, үтен+еч, таян+ыч, терә+в+еч, инан+ыч, сөен+еч, юан+ыч, ышан+ыч.*

Кушымча сузык авазларга тәмамланган нигезләргә ялганганда нигез белән кушымча арасында *в*(w) элементы барлыкка килә, ул нигез белән кушымча арасындагы хиатусны (ачыклыкны) бетерү өчен хезмәт итә. Кушымча составына ул керми, морфонологик чара булып тора: *капша+в+ыч, чорна+в+ыч, үрмә+в+еч.* Ясаучы нигезләре булып һәрвакыт татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ыч/-еч, -ч* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш өчен хезмәт итә торган коралны яки җайланманы: *чүкеч, таяныч, үлчә+в+еч, яна+в+ыч.*

2. Ясаучы нигез белдергән процессның нәтиҗәсе булган рухи халәтне: *үкенеч, сөенеч, юаныч, көенеч.*

Бу юл белән хасил булган сүзләргә тагын *бурыч, куныч* сүзләре кирә булса кирәк.

**Нигез + *-ымта/-емтә* кушымчасы.** Кушымча *-ым* һәм *-та* элементларыннан гыйбарәт, әмма ул бердәм кушымча булып киткән. Фигыль нигезләргә ялгана, ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ымта/-емтә* кушымчасы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметларны һәм төшенчәләрне тәгъбир итә: *сөземтә, карымта, барымта, сыгымта.* Бу кушымча шулай ук нигезе ачык булмаган *чырымта* сүзендә очрый. *Элемтә* сүзенең мәгънәсе сүзьясалыш мәгънәсеннән шактый ераклашкан.

**Нигез + *-ынты/-енте* кушымчасы.** Сузыклардан соң *-нты/-нте* килә, яңгырау варианты *-ынды/-енде.* Хәзерге татар телендә, мәсәлән, *сөренте, ерынты, агынты* сүзләрендә очрый. Аның килеп чыгышы турында тюркологиядә аерым фикерләр юк. Барлык тюркологлар да *-ын* элементын юнәлеш кушымчасы дип карыйлар. Бәлки телнең борынгы хәлендә юнәлеш кушымчасы булгандыр, әмма хәзерге вакытта аны грамматик кушымча дип санап булмый, чөнки аның күпчелек ясаучы нигезләре хәзерге татар телендә мөстәкыйль сүз буларак очрамыйлар. Шуңа күрә *-ынты* кушымчасын мөстәкыйль кушымча дип санарга туры килә. Ул – фигыльләргә ялгана.

Фигыль + *-ынты/-енте* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны: *сыгынты, урынты* (диал.), *ерынты, юынты, кырынды, кисенте, үсенте, чыгынты, үренте.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең атамасын: *агынты.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең башкарыла торган урынын: *сөренте, чабынды* (диал.), *керенте* (диал.).

4. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән предметны: *ашанды* (диал.).

5. Ясаучы нигез белдергән билге белән характерланучы затны: *куынты* (диал.), *асранты* (диал.).

*Сүренте, икенде* сүзләре, этимологик яктан караганда шулай ук ясалма булып торалар, ләкин *сүр-, ик-* нигезләре телнең бүгенге

торышында аерылмаганлыктан ул сүзләрне ясалма сүзләр дип санап булмый.

**Нигез + *-чалар/-чәләр* кушымчасы.** *-чалар* кушымчасы *-ча+-лар* элементларыннан гыйбарәт булган катлаулы кушымча тәшкил итә. Ул бары исемнәргә генә ялгана.

Исем + *-чалар/-чәләр* кушымчасы ясаучы нигез белән бәйле үсемлекләр семьялыгын белдерә: *төнбоекчалар.*

## Аз продуктивлы кушымчалар

**Нигез + *-са/-сә* кушымчасы.** Татар телендә бу кушымча продуктив түгел. Ул асылда исемнәргә ялгана: *җиң+сә, биләү+сә, муен+са, култык+са, туфрак+са, төп+сә.* Фактлар күрсәткәнчә, *-са* кушымчасының ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Бу кушымча кайбер нигезләрнең мәгънәсен үзгәртми, әмма сүзнең мөстәкыйльлегенә басым ясый. Шундыйларга *иң* һәм *иңсә, биләү* һәм *биләүсә* сүзләре керә. Мәсәлән, *Җантимер агай иңсәгә китереп шундый тамызды. Корякин... иңсәләрен генә җыерды* җөмләләрендәге *иңсә* сүзе түбәндә китерелгән җөмләләрдәге *иң* сүземәгънәсенә туры килә: *Кызлар да, иңнәренә пальтоларын салып, аны озата чыктылар.* Ә. Еники. *Мөнәвәрә көянтә-чиләген, иңеннән алып, иплән кенә яр читенә куйды.* Г. Ахунов.

Исем + *-са/-сә* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән әгъза өчен билгеләнгән әсбапны: *муенса, беләксә, җиңсә, култыкса.*

2. Ясаучы нигез белдергән нәрсәне хәтерләткән, әмма аңардан аерылып торган предметны: *туфракса, төпсә.*

Әдәби телдә һәм диалектларда *-са* кушымчалы башка сүзләр дә очрый: *бүксә, корымса, тупса.* Китерелгән сүзләр мәгънәле кисәкләргә аерылмыйлар, шуңа күрә аларны ясалма сүзләр дип карап булмый.

**Нигез + *-дырык/-дерек* (*-тырык/-терек*) кушымчасы.** Татар теленең лексикасы үсеше процессында бу кушымча бик аз сүзләр хасил иткән. Аның этимологиясе турында Г. Рамстедт, М. Рясенен, А.Н. Кононов, Э.В. Севортян һәм башкаларның фикере бар. С.Н. Моратов кушымчаның этимологиясенә багышланган үзенең зур мәкаләсендә, *-турук/-дурук* кушымчасын *торык* сүзеннән килеп чыккан, *тор* элементы фигыль, *-ык* элементы фигыльдән исем ясаучы кушымча, дип

саный. Кушымчаның ясаучы нигезләрен татар сүзләре тәшкил итә. Ләкин бүгенге көн күзлегеннән күп кенә сүзләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел, әмма аларның кайберләренең этимологиясен җиңел билгеләргә була: *боендырык, күзелдерек, чөелдерек, тәбәлдерек*. Мәсәлән, *боендырык* сүзендәге *боен* сүзе азәрбайҗан телендә *муен* мәгънәсен белдерә. *Күзел, тәбәл, чөел* нигезләрендәге *-ел, әл, -л* элементларын С.Н. Моратов, бернинди дә грамматик яки семантик мәгънә белдерми, бары сүзләр кушылу техникасына гына карый, дипраслый. Бу, һичшиксез, дөрес фикер, алар интерфикс тәшкил итә.

Исем + *-дырык*/*-дерек* (*-тырык*/*-терек*)кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән әгъза өчен билгеләнгән җайланманы: *боендырык, сакалдырык, күзелдерек, түшелдерек.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән коралны, предметны: *тәбәлдерек, чөелдерек.*

Татар телендә *-дырык*/*-дерек* (*-тырык*/*-терек*) кушымчалы башка сүзләр дә бар: *бүлтерек, бустырык, сагалдырык, ташалдырык, ташландырык.*

**Нигез + *-ганак*/*-гәнәк* (*-канак*/*-кәнәк*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ганак*/*-канак*, нечкә нигезләргә *-гәнәк*/*-кәнәк* ялгана. Кушымчаның ясаучы нигезләре булып фигыльләр килә: *ти+гәнәк, сыр+ганак, ер+ганак, туз+ганак, тай+ганак, кат+канак.*

Чыганак тел ягыннан аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ганак*/*-гәнәк* (*-канак*/*-кәнәк*) кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бәйләнешле билгегә ия булган үсемлекләрнең исемен: *сырганак, тузганак, тигәнәк.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бәйләнешле билгегә ия урынны: *ерганак, катканак, тайганак.*

3. Ясаучы нигез белдергән хәл белән бәйләнешле затны: *көйгәнәк.*

Диалектта структурасы ачык булмаган тагын бер сүз бар: *бигәнәк* (ялкау кеше).

**Нигез + *-галак*/*-гәләк* (*-калак*/*-кәләк*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-галак*/*-калак,* нечкә нигезләргә *-гәләк*/*-кәләк* ялгана, яңгырау варианты – *-галак*/*-гәләк,* саңгырау варианты – *-калак*/*-кәләк.* Кайбер

сүзләрдә бу кушымча *-ганак*/*-гәнәк* (*-канак*/*-кәнәк*) кушымчасының варианты булса кирәк, чөнки татар телендә бер үк нигездән бер үк мәгънәдә *-ганак* кушымчасы белән дә, *-галак* кушымчасы белән дә ясалган сүзләр очрый: *тайганак* һәм *тайгалак, катканак* һәм *каткалак.* Кушымча фигыльләргә ялгана: *шу+галак, оч+калак.* Ясаучы нигез булып гадәттә татар сүзләре килә.

Фигыль + *-галак*/*-гәләк* (*-калак*/*-кәләк*) кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бәйләнешле билгегә ия булган үсемлекне яки хайванны: *очкалак, дүңгәләк* (*дүң – түң*), *сеңгәләк.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бәйләнешле урынны: *шугалак, тайгалак, каткалак.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә билгеләнгән әйберне: *бугалак.*

**Нигез+*-дык*/*-дек* (*-тык*/*-тек*)$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-дык*/*-тык,* нечкә нигезләргә *-дек*/*-тек* ялгана. Кушымчаның килеп чыгышы турында берничә фикер бар. Мәсәлән, Н.А. Баскаков бу кушымчаны фигыльнең сыйфат фигыль формаларына кайтарып калдыра. М. Рясенен *-дык* кушымчасын *-дырык* кушымчасыннан китереп чыгара, *-дык* кушымчасы бер генә чыганакка барып тоташмый, ул берничә кушымча контаминациясенең нәтиҗәсе булып тора.

Беренчедән, *шаркылдык* сүзендәге *-дык* кушымчасы *-да+в+ык* (*шаркыл+да+в+ык*) элементларына кайтып кала. Шуңа күрә *-да+в+ык* элементларыннан килеп чыккан *дык* бары фигыльләргә генә ялгана.

Икенчедән, кайбер очракларда *-дык* кушымчасының этимоны *-дырык* булырга мөмкин. Ул бу очракта нигезгә якын мәгънә белдерә: *карындык, урындык.*

Өченчедән, *-дык* кушымчасының этимологик элгәре *-лык* кушымчасы да булырга мөмкин: (чагыштыр: *төнлек* (әдәби сүз) һәм *төндек* (диалекталь сүз)).

Кушымча хәзерге татар телендә исемнәргә: фигыльләргә һәм иялтемнәргә ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә. Бу кушымча төрле этимологик чыганакларга барып тоташканлыктан, аның мәгънәләре күп төрле.

Исем + *-дык*/*-дек* (*-тык*/*-тек*)$_1$ моделе ясаучы нигез белдергән нәрсәгә бәйләнешле әйберне тәгъбир итә: *урындык, үлемтек, карындык.*

Фигыль + *-дык*/*-дек* (*-тык*/*-тек*) моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган предметны: *җыентык, калдык, сидек, табылдык, кушылдык, белдек* (диал.).

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган әйберне: *элдек.*

Ияртем + *-дык*/*-дек* (*-тык*/*-тек*)$_1$ моделе нигез белдергән билге белән сыйфатланучы затны тәгъбир итә тәгъбир итә: *лыгырдык, мыгырдык, лабырдык, кыбырдык*.

Хәзерге татар телендә *-дык* кушымчалы башка сүзләр дә очрый: *борындык, уйдык, азымтык* (диал.), *ышандык* (диал.), *чыбылдык.*

**Нигез + *-тык*/*-тек*$_2$ кушымчасы.** Бу кушымчаның яңгырау варианты юк, ул *бәләкәй* мәгънәсендәге *чак* сүзенә кайтып кала. Биредә төрки телләргә закончалыклы рәвештә хас булган *ч* авазы *т* авазына күчкән. Ул бары исемнәргә генә кушыла: *бүлем+тек, уем+тык.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

Исем + *-тык*/*-тек* кушымчасы ясаучы нигез белдергән предметны кечерәйтү төсмере белән тәгъбир итә: *муентык, уемтык, бүлемтек, янтык.*

**Нигез + *-ак*/*-әк, -к*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ак,* нечкә нигезләргә *-әк* ялгана. Бу кушымча *-ак*/*-әк, -к*$_1$ кушымчасыннан аерыла. Тикшерелә торган кушымча ачыктан-ачык кечерәйтү төсмерен белдерә. Г.И. Рамстедт фикеренчә, бу кушымча *-чак* кушымчасыннан килә.

Кушымча исемнәргә (*саб+ак, баш+ак, эч+әк, бөер+әк, каб+ак*), сыйфатларда (*игез+әк, ялгыз+ак*), алмашлыкка (*үз+әк*) ялгана.

Ясаучы нигезләре булып, кагыйдә буларак, татар сүзләре килә.

Исем + *-ак*/*-әк, -к*$_2$ моделе ясаучы нигез белдергән предмет мәгънәсен кечерәйтү төсмере белән тәгъбир итә: *сабак, башак, бөерәк.*

Алмашлык + *-ак*/*-әк, к*$_2$ моделе ясаучы нигез белдергән предметны конкретлаштыра төшә: *үзәк.*

Сыйфат + *-ак*/*-әк, -к*$_2$ моделе ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатланучы затны тәгъбир итә: *ялгызак, игезәк.*

Мөгаен, -*ак*$_2$ кушымчасы белән ясалган сүзләргә түбәндәгеләр дә керә: *яңак* (*яң+ак* сүзендә *н* авазы *а* сузыгы алданнан *ң* авазына әйләнгән), *җек, кабак* (*кап*), *күнәк* (диал.), *улак* (*ул=йул=йул+ак*), *ылак* (*ыл=кәҗә*), *кузак* (*куз=чикләвек*).

**Нигез + *-гак/-гәк (-как/-кәк)*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-гак/-как,* нечкә нигезләргә *-гәк/-кәк* ялгана. Кушымчаның килеп чыгышы турында кайбер фикерләр генә бар. Мәсәлән, А.Г. Голәмев, ул ике элементтан – фигыльне көчәйтә торган *-ка* һәм фигыльдән исем ясаучы *-к* кушымчаларыннан тора, дип саный. В. Банг аны, фигыльдән исем ясаучы *-га+к* кушымчаларыннан гыйбарәт, ди, һәм катлаулы кушымчалар рәтенә кертә. Бу фикергә Г.И. Рамстедт та кушыла.

Кушымча фигыльләргә ялгана: *бат+как, йом+гак, төр+гәк, пычрак* (*пычыр+ак*). Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-гак/-гәк* (*-как/-кәк*) кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән характерлана торган урынны: *баткак, очкак, чумгак.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган әйберне: *ишкәк, элгәк.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган әйберне: *төргәк.*

Бу кушымча шулай ук сыйфатлар ясауда да катнаша: *тибешкәк, сөзгәк, өркәк.*

*Бизгәк* сүзе дә шушы кушымча белән ясалган булса кирәк. Борынгы төрки телдә *без* калтырау мәгънәсен белдергән. *Түмгәк* сүзе шулай ук бу ясалышка керә булса кирәк. *Түм* нигезе, мәсәлән, *түмәр* сүзендә очрый.

**Нигез + *-ыр/-ер, -ар/-әр, -р*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ыр/-ар,* нечкә нигезләргә *-ер/-әр* кушымчасы ялгана, сузыклардан соң *-р* килә. Сузык авазга тәмамланган нигез белән кушымча арасында, кагыйдә буларак, *й* интерфиксы хасил була, мәсәлән, *ти+й+әр* (орфографиядә *тияр*). Бу кушымча белән ясалган сүзләрнең структурасын һәм семантик үзенчәлекләрен исәпкә алгандааны сыйфат фигыль күрсәткеченнән килә дип карау дөресрәк булыр.

Хәзерге вакытта *-ыр* кушымчалы күп сүзләр үзләренең элекке формалары белән семантик бәйләнешен югалтканнар, шуңа күрә аны сүзьясагыч дип карарга кирәк.

*-ыр*$_1$ кушымчасы, кагыйдә буларак, эш яки хәрәкәт белдерә торган фигыльләргә ялгана: *өй+ер, чокы+р.* Борынгы төрки телдә һәм татар диалектларында ул исемнәргә дә кушылган: *аст+ыр* (диал.), *чәй+ер. Чәй+ер* (*чай+ыр*) сүзендә *чәй* нигезе *май* дигәнне белдергән.

Бу кушымча белән ясалган исемнәр нигездә белдерелгән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны тәгъбир итә: *өйер, чокыр, тийәр* (орфографиядә *тияр*). Нигезләре ачык булмаган *сеңер, комар, күпер, чумар* сүзләре дә бәлки бу кушымча белән ясалганнар.

**Нигез + *-га/-гә(-ка/-кә)*$_1$ кушымчасы.** Н.А. Баскаков һәм С. Джафаров, *-га/-гә* кушымчасын *-гак/-гәк* тән килеп чыккан, дип карыйлар. Э.В. Севортян аны, *-гы* кушымчасының бер төре, дип саный. Этимологик яктан караганда, бәлки алар бер үк кушымчадыр. Шуңа карамастан, телнең бүгенге торышында алар аерым кушымча булып торалар, аларның үзләренең вариантлары һәм сүзьясалыш ягыннан үзенчәлекләре бар. Ясаучы нигезләре булып фигыльләр (*кис+кә, тот+ка*) һәм иярмемнәр (*кар+га, чәү+кә*) килә.

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләрне татар сүзләре генә тәшкил итә.

Фигыль + *-га/-гә* (*-ка/-кә*)$_;$ моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган җайланманы: *тотка.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган әйберне: *кискә, ярка.*

Иярмем + *-га/-гә* (*-ка/-кә*)$_1$ моделе ясаучы нигез белдергән билгегә ия булган яисә шул билгедән чыгып бирелгән исемне аңлата: *карга, чәүкә, күркә.*

Диахроник планда сүзьясалышның бу тибына түбәндәге сүзләр кертелергә мөмкин: *йа+ка* (орфографиядә *яка, йа* элементы хәзерге телдә *ян, як* сүзләрендә бар), *юр+га* (*юр* элементы *юрту* сүзендә очрый), *кап+ка* (*кап* кисәге *капла* фигылендә бар), *там+га* (*там* кисәге борынгы төрки телдәге «яндыру» мәгънәсендәге *тамдур* сүзендә очрый), *сер+кә* (борынгы төрки телдә *сер* сүзе «катып калу» мәгънәсен белдергән), *сөр+ кә, йомыр+ка, чикерт+кә, ар+ка, җил+кә, күлә+ гә, корос-ка* (диал.), *кәшлә+кә, кыл+ка* (*диал.*), *бот+ка, өл+кә.* Бу сүзләрнең барысын да ясалма булмаган сүзләр дип санарга туры килә,

чөнки хәзерге телдә алар мәгънәле кисәкләргә аерылмыйлар, ягъни нигезләре билгеле түгел.

**Нигез + *-гын*/*-ген* (*-кын*/*-кен*)$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-гын*/*-кын,* нечкә нигезләргә *-ген*/*-кен* ялгана. Бер төркем тюркологлар (О. Бётлингк, Т.М. Гарипов, М.А. Хабичев), бу кушымчаны *-гы+-н* элементларыннан тора, дип санныйлар. Башкалар (Ж. Дени, Н.К. Дмитриев, Э.В. Севортян), генетик яктан сыйфат фигыль *-ган* кушымчасы белән бәйләнгән, дип карыйлар. *-гын*$_1$ кушымчасы белән ясалган сүзләрнең лексик-семантик һәм кулланылыш үзенчәлекләре икенче фикер файдасына сөйли.

Бу кушымча фигыль нигезләргә ялгана: *чәч+кен, тот+кын, кыр+гын, кап+кын, чап+кын, таш+кын, кач+кын, ян+гын.* Кайчак кушымчаның ясаучы нигезе булып исем дә килергә мөмкин: *чәйген* (диал.).

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-гын*/*-ген* (*-кын*/*-кен*)$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган затны: *тоткын, качкын, кугын, килген* (диал.).

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең, хәлнең атамасын: *кыргын, баскын, ташкын, янгын.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган коралны: *капкын.*

4. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бәйле урынны: *сөрген, упкын.*

5. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәттән килеп чыккан нәтиҗәне: *чәчкен.*

*-гын*$_1$ кушымчалы кайбер сүзләр гадиләшеп, тамыр сүзгә әйләнгәннәр: *дул+кын* сүзендәге *дул* кисәге *тул* сүзе белән бәйләнгән булса кирәк, *ял+кын* сүзендәге *ял* (*йал*) кисәге борынгы төрки телдә «янып китү» мәгънәсен белдергән. Этимологик яктан ясалма исемнәр рәтенә бәлки түбәндәге сүзләрне кертергә буладыр: *юшкын, тезген, кыркын, козгын, кыпкын* (*искергән сүз*).

**Нигез + *-ын*/*-ен, -н*$_1$ кушымчасы.** Күпчелек тюркологлар аның этимологиясен *-гын* кушымчасыннан китереп чыгаралар. С. Джафаров *-ын* кушымчасын, юнәлеш күрсәткече, дип саный.

Кушымча фигыльләргә ялгана: *иг+ен, тиб+ен, тег+ен* (диал.), *чаб+ын, кил+ен, җый+ын, яу+ын* (диал.), *эре+н.* Чыгарма буларак исемнәргә дә кушылырга мөмкин: *ут+ын.*

Фигыль+*-ын/-ен, -н*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән нәрсәне: *иген, эрен, чыгын, җыен.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең атамасын: *теген, явын, тибен.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән урынны: *чабын, тибен.*

4. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бәйле затны: *килен.*

*Чуйын* (*чуен*)*, төйен* (*төен*)*, төтен, куйын* (*куен*)*, табын, бөтен, борын, колын, урын* сүзләре -*ын* кушымчасы белән ясалганнар, әмма тел үсеше процессында аларның структурасы томанланган һәм алар тамыр сүзгә әйләнгәннәр.

**Нигез + *-ан/-ән, -н*$_1$ кушымчасы.** Күпчелек тюркологлар бу кушымчаны, сыйфат фигыль кушымчасы *-ган* нан килеп чыккан, дип саныйлар. Бу кушымчаны һәр очракта да сыйфат фигыль күрсәткечено кайтарып калдырып булмый. Мәсәлән, *божан, болан, куйан* (орф. *куян*)*, озан* (диал.), *ан* элементы «җәнлек» мәгънәсендә электә мөстәкыйль сүз булган дип уйланыла. Бу кисәк диалектта *аңчы* (*аучы*) дигән сүздә очрый. Хәзерге көндә ул мөстәкыйль сүз буларак татар телендә очрамый. Этимологик яктан караганда алар кушма сүз тәшкил иткәннәр, хәзер аларның беренче компонентын ачыклавы кыен. Гипотеза рәвешендә шуны әйтергә кирәк*божҗ*, мәсәлән, элементы аваз ияртеме булырга мөмкин. Югарыда китерелгән сүзләр хәзерге татар телендә структур яктан бүленмәгәнлектән, аларны ясалма булмаган сүзләр дип карарга туры килә. Фигыльләрдән ясалган сүзләрдә *-ан* кушымчасы сыйфат фигыль кушымчасы *-ган* ның фонетик-грамматик үзгәреше дип санарга була. Ул, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана (*печ+ән, туз+ан*)*,* сирәк кенә исемнәргә (*сүс+ән, чит+ән*)*,* сыйфатларга (*күч+ән*) кушыла.

Фигыль + *-ан/-ән, -н*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйберне: *тузан, печән, талкан.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән җайланманы: *таган.*

*Исем* яки сыйфат +*-ан/-ән, -н*$_1$ моделе ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган үсемлекне белдерә: *сүсән, кучән.*

Бу юл белән ясалган сүзләргә шулай ук *буран* (нигезе *бур=бор*), *йөгән, сырлан* (нигезе *сырыл*) сүзләре керә булса кирәк. Боларның барысын да ясалма булмаган сүзләр дип санарга туры килә, чөнки аларның структурасын бары этимологик тикшеренүләр белән генә билгеләп була.

**Нигез + *-ган/-гән* (*-кан/кән*)$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ган/-кан,* нечкә нигезләргә *-гән/-кән* ялгана. Бу кушымча генетик яктан сыйфат фигыль кушымчасы белән бәйләнгән. Ул, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана: *җил+кән* (*җил* «бару, чабу» мәгънәсендә), *ту+ган.* Кайвакыт саннарга кушылырга мөмкин: *җиде+гән* (йолдызлык). Кушымчаның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

*-ган* кушымчасы белән килгән исемнәр ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган затны яки предметны тәгъбир итә: *туган, җидегән, җилкән.* Тарихи яктан караганда *юр+ган* (*йур* нигезе *юрмә* сүзендә очрый), *балтыр+ган, саес+кан, тыч+кан, бөрле+гән, су+ган, тил+гән, карчы+ган* (диал.), *сөтле+гән, карлы+ган, кал+кан* (*кал=саклау?*) сүзләре дә бу кушымча белән ясалганнар булса кирәк.

**Нигез + *-мак/-мәк* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-мак,* нечкә нигезләргә *-мәк* кушыла. Тюркологиядә аның этимологиясе мәсьәләсе бәхәсле. Э.В. Севортян фикеренчә, кушымчасы *-ма* дан килеп чыккан. Үз вакытында бу фикерне В. Банг әйткән иде инде. Г.И. Рамстедт аны, *-м* һәм *-ак* кисәкләреннән тора, дип саный. Н.А. Баскаков, *-м, -ма* һәм *-маг* кушымчаларын тиңдәшләр, дип карый. А.Н. Кононов фикеренчә, ул ике кисәктән *-ма+-га* дан торган катлаулы кушымча. Мәгълүм булганча, хәзерге татар телендә *-ма* кушымчасына тәмамланган фигыльләр бар: *тукма, карма* һ.б. Шуңа күрә мондый фигыльләргә *к* кушымчасының ялгануын башка фигыльләргә *-мак* кушымчасы ялгануыннан аера белергә кирәк. Мәсәлән, *тукма+к, карма+к* сүзләре фигыльләрдән *к* кушымчасы белән ясалганнар, *элмәк* сүзе исә *эл* нигезеннән *мәк* кушымчасы белән ясалган. Бу төрле төрдәге комплекслар үзләренең тышкы ягы белән охшаш булсалар да, эчке структуралары һәм функцияләре белән бер-береннән нык аерылалар. Кушымча эшне

(*ик+мәк, уй+мак*)һәм хәрәкәтне (*бас+мак*)белдергән фигыльләргә ялгана.

Фигыль + *-мак*/*-мәк* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган җайланманы яки коралны: *басмак, элмәк.*

2. Ясаучы нигез белдергән эшнең нәтиҗәсе буларак килеп чыккан предметны: *кисмәк, икмәк, уймак, ермак.*

3. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган терминны: *табышмак.*

Шуның белән бергә, татар телендә составында *-мак* кушымчасы булган, әмма нигезләре бүгенге көндә ачык булмаган сүзләр дә бар: *каймак* (*кай* кисәге *кайыру* сүзендә очрый), *такмак* (*таг* элементы борынгы төрки телдә «шигырь уку» мәгънәсендәге *тагсур* сүзендә очрый, *тармак* (*тар* кисәге борынгы төрки телдә «тарату» мәгънәсен белдергән, хәзерге татар телендә *таралу* сүзендә очрый), *чүлмәк* (*чүл* кисәге борынгы төрки телдә «сыеклык» мәгънәсендә йөргән), *күлмәк* (*күл* элементы борынгы төрки телдә «уратып бәйләү» мәгънәсен белдергән), *башмак* (*баш* элементы Урал татарлары диалектында *башай* (оекбаш) сүзендә очрый). Шулай ук бу юл белән ясалган сүзләргә *бармак, колмак* һ.б. керә булсалар кирәк.

**Нигез + *-мыш*/*-меш* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-мыш,* нечкә нигезләргә *-меш* ялгана. Электә кыпчак телләрендә үткән заман сыйфат фигыле күрсәткече тәшкил иткән, хәзер угыз телләрендә шундый кушымча булып тора. В.Н. Хангилдин *-мыш* кушымчасын сүз ясаучы чаралар рәтенә кертми, грамматик формаларның исемгә күчүе генә дип саный. Бу, өлешчә, дөрес. Ләкин хәзерге телдә шундый ук параллель грамматик формаларның булмавыннан чыгып, бүгенге көн күзлегеннән аны сүзьясагыч кушымча дип карарга туры килә.

Кушымча процесс, хәрәкәт, эш белдерә торган фигыльләргә ялгана: *ту+мыш, җи+меш* (*җи* «ашау»), *укы+мыш, гөрлә+меш.*

Барлык ясаучы нигезләр татар сүзләре булып торалар.

Фигыль + *-мыш*/*-меш* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Ясаучы нигез белдергән процессның яки эш-хәрәкәтнең атамасын: *язмыш, тормыш, укымыш, узмыш* (*язмыштан узмыш юк*).

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән төшенчәне: *җыймыш, санамыш, сынамыш.*

3. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган атаманы: *кырыкмыш, чукынмыш.*

**Нигез + *-лак/-ләк* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-лак,* нечкә нигезләргә *-ләк* ялгана. Бер яктан, ул ике кушымчадан – фигыль ясаучы *-ла* һәм исем ясаучы *-к* морфемаларыннан гыйбарәт: *кыш+ла+к.* Икенче яктан, ул мөстәкыйль кушымча дабулып тора: *ау+лак.* Мөстәкыйль кушымча буларак, ул генетик яктан *-лык* кушымчасы белән бәйләнгән булса кирәк.

Фигыль + *-лак/-ләк* моделе ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган урынны тәгъбир итә: *торлак* (диал.).

Исем + *-лак/-ләк* моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган урынны белдерә: *аулак, ермалак.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән тасвирлана торган затны белдерә: *алдалак.*

**Нигез + *-чак/-чәк* кушымчасы.** Кушымчаның этимологиясе тюркологиядә төрлечә аңлатыла. Бер төркем тюркологлар аны, микъдарны белдергән *чак* сүзенә барып тоташа дип саныйлар, башкалар (А. фон Габен, Г.И. Рамстедт) ике элементтан *-ча+-к* дан тора дип карыйлар. Фактлар күрсәткәнчә, *-чак* кушымчасы ике чыганакка барып тоташа. *Киленчәк, колынчак* сүзләрендә «кечкенә» мәгънәсендәге *чактәк* сүзе белән, *иренчәк, катынчак* (диал.) сүзләрендә «охшаш», «шундый» мәгънәсендәге *гак* сүзе белән бәйле. Кушымча исемнәргә һәм фигыльләргә ялгана. Барлык ясаучы нигезләре татар сүзләре булып торалар.

Фигыль + *-чак/-чәк* моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган предметны: *имчәк, кимерчәк, тәгәрчәк.*

2. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган затны: *иренчәк.*

Исем + *-чак/-чәк* моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән бәйле затны: *күңелчәк, уенчак.*

2. Ясаучы нигез белдергән әгъза өчен билгеләнгән коралны яки җайланманы: *муенчак, борынчак.*

*Ыңгырчак, борчак, чапчак* сүзләре дә бу кушымча белән ясалган дип уйларга нигез бар.

**Нигез + *-ылты/-елте* кушымчасы.** Кушымча ике элементтан гыйбарәт: *-ыл+-ты*. Калын нигезләргә *-ылты,* нечкә нигезләргә *-елте* ялгана. Аваз ияртемнәренә кушыла: *гөр-елте.*

Аваз ияртемнәре+*-ылты/-елте* кушымчасы нигез белдергән тавышның атамасын тәгъбир итә: *гөрелте, шавылты, гүелте.* Башка төрки телләрдә, мәсәлән, азәрбайҗан телендә бу кушымча ясалган сүзләр шактый күп.

**Нигез + *-авыл/-выл* кушымчасы.** В. Банг һәм Э.В. Севортян фикеренчә, бу кушымча *-гыл* кушымчасыннан килеп чыккан, *-гыл* кушымчасы үзе исә исем ясаучы *-гы* һәм *-л* элементыннан гыйбарәт, *г* авазының төрки телләрдә закончалыклы рәвештә *у* (*w*) авазына күчүен исәпкә алганда, В. Банг һәм Э.В. Севортян фикере иң дөресе булырга мөмкин. Бу кушымча монгол телләрендә дә бар.

Кушымча фигыльләргә ялгана, ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-авыл/-выл* моделе ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтне башкаручы затны тәгъбир итә: *каравыл, багавыл* (диал.). Татар телендә *-выл* кушымчалы башка сүзләр дә бар: *ча-выл* (диал.), *кыргавыл.* Әмма ясаучы нигезләре ачык булмаганлыктан аларны тамыр, ягъни ясалма булмаган сүзләр дип карарга туры килә.

**Нигез + *-ыт/-ет, -т* (*-ат/-әт*)$_1$ кушымчасы.** Кушымчаның килеп чыгышы турында тюркологиядә төрле карашлар бар. Мәсәлән, П.М. Мелиоранский, А. фон Габен, В.М. Насилов, Л.Н. Харитонов аны борынгы күплек кушымчасына кайтарып калдыралар. Н.А. Баскаков фикеренчә, *-ыт* кушымчасы *-ты/-тык* кушымчасыннан килеп чыккан. *-ыт*$_1$ кушымчасының иң борынгы кушымчалардан булуын искәртеп китәргә кирәк, ул төрки телләрнең лексикасының борынгы катламында очрый: *егет, сөт, савыт* һ.б. Шуңа күрә дә аның чын этимологиясен билгеләү бик кыен. Аны күплек кушымчасына кайтарып калдыру бик бәхәсле, чөнки кушымча ничек кенә үзгәрсә дә, аңарда күплек мәгънәсенең рефлексы чагылмый калмас иде. Бу хәл исә *-ыт*$_1$ кушымчалы сүзләрдә бер дә күзәтелми. Бу кушымча берничә кушымчаның контаминациясеннән гыйбарәт булса кирәк. Хәзерге татар телендә *-ыт/-ет, -т*$_1$ кушымчалы сүзләр шактый очрый: *камыт, үгет, оят.* Әмма аларның ясаучы нигезләре мөстәкыйль яшәмиләр, исем булып та, сыйфат булып та, фигыль булып та тормыйлар. Бу хәл кушым-

чаның сүз төркемнәре әле ныклап аерылып җитмәгән вакытта нигезгә ялгануы белән аңлатыла. Хәзерге көн күзлегеннән *-ыт/-ет, -т*$_1$ кушымчасы, структур яктан, бары берничә сүздә генә аерыла: *кагыт* (нигез *как), сырт* (*сыр* «чик, билге»), *карт* (*карый* сыйфат), *арт* (ары).

Кушымча исемнәргә һәм сыйфатларга ялгана, аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Исем + *-ыт/-ет, -т* (*-ат/-әт*)$_1$ моделе ясаучы нигез белән белдерелгән билге белән тасвирлана торган затны яки предметны тәгъбир итә: *кагыт*.

Фигыль + *-ыт/-ет, -т* (*-ат/-әт*)$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган предметны: *савыт*.

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең атамасын: *үләт, сыгыт* (*сыктау* «елау»).

Хәзерге көндә ясалма булмаган сүзләргә әйләнгән, әмма борынгыда *-ыт/-ет, -т*$_1$ кушымчасы белән ясалган сүзләргә мисаллар: *күкерт* (*күкер* морфемасы *күкерә* фигылендә очрый), *урт* (*ур* элементы *урын* сүзендә күзәтелә), *көрт* (*көр* компоненты *көрә* сүзендә бар), *егет, болыт* (*бол* морфемасы *болга* фигылендә очрый), *кибет, оят, бөйәт, корт, саркыт* (диал.), *чыгыт* (диал.).

**Нигез + *-ты/-те*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча генетик яктан *-та/-тә* кушымчасы белән бәйләнгән, фигыльләргә ялгана, аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ты/-те*$_1$ кушымчасы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны тәгъбир итә: *ярты, якты*.

**Нигез + *-а/-ә*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-а,* нечкә нигезләргә *-ә* ялгана. Ясаучы нигезләре булып фигыльләр, исемнәр, аваз ияртемнәре килә: *сук+а, бак+а, чумар+а, томан+а.*

Исем + *-а/-ә*$_1$ моделе ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган затны яки предметны тәгъбир итә: *түрә* (*түр* нигезенең мәгънәсе хәзерге телдә *түр* (*өйнең түре*)сүзендә сакланган), *чумара.*

Фигыль + *-а/-ә*$_1$моделе түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе буларак килеп чыккан предметны: *буа, уба, кыйа* (орф. *кыя*)*, йара* (орф. *яра*)*, әйләнә.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган предметны: *җәйә* (орф. *җәя*)*, инә, сука* (борынгы төрки телдә *сук/сок* сүзе «ваклау, китү» мәгънәсен белдергән), *кыса.*

Аваз ияртеме + *-а/-ә*$_1$ моделе ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган тереклек иясен тәгъбир итә: *бака.*

Хәзерге татар телендә *-а* га тәмамланган исемнәр шактый күп: *ана, ата, ага, чага, ийә* (орф. ия), *әрә, тана, түбә, ара, тоба, күмә, ойа* (орф. оя), *йуа* (орф. юа), *кинә, айа* (орф. ая).

**Нигез + *-ы/-е*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ы,* нечкә нигезләргә *-е* кушыла. Бер тикшеренүчеләр (П.М. Мелиоранский, Г.И. Рамстедт) *-ы/-е*$_1$кушымчасын *-гы* кушымчасыннан, башкалар (А.Н. Кононов, Н.А. Баскаков, М. Рясенен) *-ык* кушымчасыннан килеп чыккан диләр. С. Джафаров фикеренчә, *-ы* кушымчасы ике чыганакка *-гы* һәм *-ык* кушымчаларына барып тоташа. Бу дөрес фикер, чөнки, фактлар күрсәткәнчә, татар теле диалектларында бер үк сүз *-ы* кушымчасы белән дә, *-ык* кушымчасы белән дә килә: *өте – өтек, үле – үлек.* Кушымча татар сүзләре булган фигыльләргә ялгана.

Фигыль + *-ы/-е*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирланган предметны: *өре, үле.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән предметны: *өте.*

Хәзерге татар телендә структур яктан аерылмый торган *-ы/-е* кушымчасына тәмамланган сүзләр байтак: *өке, чүре, кеше, ары, кузы, бүре, тары, койы* (орф. кое), *дары* һ.б.

**Нигез + *-анак/-әнәк* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-анак,* нечкә нигезләргә *-әнәк* ялгана. Генетик яктан ул, мөгаен, *-ганак* кушымчасы белән бәйләнгән. Әмма аңардан аермалы буларак, исемнәргә дә кушыла (*саз+анак, күз+әнәк*)*.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

*-анак/-әнәк* кушымчалы исемнәр ясаучы нигез белдергән билге белән кайсы яктан булса да тасвирлана торган предметны тәгъбир итә: *сазанак, күзәнәк, чыганак.* Бу кушымча ясаучы нигезе аерылмаган сүздә дә очрый: *бәбәнәк* (мәсәлән, *бәб* нигезе *бәпчек* сүзендә күзәтелә).

**Нигез + *-алак/-әләк* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-алак,* нечкә нигезләргә *-әләк* ялгана. Аның ясаучы нигезләре булып фигыльләр килә. *-алак/-әләк* кушымчалы исемнәр ясаучы нигез белдергән эш-

хәрәкәт белән сыйфатлана торган затны тәгъбир итә: *көй+әләк* (орф. *көяләк*), *алдалак, шаталак.*

**Нигез + *-агай/-әгәй* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-агай,* нечкә нигезләргә *-әгәй* ялгана. Күп кенә тюркологлар (С. Джафаров, М. Хабичев) аны, *-гай* дигән кечерәйтү кушымчасыннан килеп чыккан, дип саныйлар. Э.В. Севортян фикеренчә, бу кушымчада кечерәйтү мәгънәсе күзәтелми. Татар теленең фактлары бу фикерне раслый. Мәсәлән, *сулагай* сүзендә бернинди дә кечерәйтү мәгънәсе юк. Кушымча исемнәргә (*кыр+агай*) һәм сыйфатларга (*сул+агай*) ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Исем + *-агай/-әгәй* кушымчасы ясаучы нигез белдергән сыйфат (билге) белән тасвирлана торган затны тәгъбир итә: *сулагай, кырагай, кулагай* (диал.), *уңагай, болагай* (диал.), *комагай.*

**Нигез + *-гай/-гәй* (*-кай/-кәй*) кушымчасы.** Кушымчаның килеп чыгышы турында тюркологиядә төрле фикерләр бар. Г.И. Рамстедт аны монгол теленнән килә, дип саный. Н.А. Баскаков фикеренчә, ул *-ган/-гән* кушымчасыннан килеп чыккан. Карачай-балкар теле белгече М.А. Хабичев аңарда кечерәйтү мәгънәсе бар, дип раслый. Татар теле фактлары бу кушымчада кечерәйтү мәгънәсе юклыгын күрсәтә. Структур яктан ул бары *яла+гай* сүзендә генә мөстәкыйль морфемаларга аерыла.

Фигыль + *-гай* кушымчасы ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган затны тәгъбир итә. Дөрес, мәгънәсе беркадәр метафоралашкан.

Бу кушымча ясаучы нигезе аерылмаган түбәндәге сүзләрдә очрый: *карагай, әҗекәй, мәчкәй* (диал.), *сыптыгай, субагай* (диал.). Кайбер вакытта бу кушымча сыйфат та ясарга мөмкин: *уңгай* (диал.).

**Нигез + *-акса/-әксә* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-акса,* нечкә нигезләргә *-әксә* ялгана, *-са* элементы генетик яктан «охшаш» мәгънәсендәге *тактәг* сүзеннән килеп чыккан *-сак* кушымчасына барып тоташа. Кушымча фигыльләргә ялгана.

Фигыль + *-акса/-әксә* кушымчасы ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган предметны тәгъбир итә: *утыракса, үләксә.*

**Нигез + *-у/-ү* (*-ау/-әү*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-у* (*-ау*), нечкә нигезләргә *-ү* (*-әү*) ялгана. Э.В. Севортян бу кушымчаны борынгы *-агу/-әгү* дән килеп чыккан, ди. Бу фикер дөрес. Ләкин кушымча

барлык очракларда да күрсәтелгән кушымчага кайтып калмый булса кирәк. Фактлар күрсәткәнчә, кайчак *-г* (*к*) кушымчасының *-у* кушымчасына күчү очраклары да бар (*кай-рак=кайрау* (диал.)).

*-у* авазына тәмамланган барлык исемнәр дә *-у* (*ү*) кушымчасы белән ясалмаганнар. Мәсәлән, хәзерге татар телендәге *-у* га тәмамланган исемнәр *-у* кушымчалы исем фигыльнең исемгә күчүеннән килеп чыкканнар (*чагыштыру, күчү, сайлау* һ.б.). Бу, әлбәттә, Сүзьясалышның кушымчалау ысулы түгел, бөтенләй башка ысулы.

*-у* га тәмамланган исемнәрнең ясалышы ысулын билгеләү өчен түбәндәге критерийлар бар. Беренчедән, телдә шундый фигыльнең булмавы (мәсәлән, *борау* исеменең фигыльдә шундый параллель формасы юк). Икенчедән, параллель фигыль формасы булганда борынгыда сүзнең ахырында *-г* (*к-* авазының килүе) (*йамау=йамак*). Өченчедән, ясаучы нигездә бүгенге мәгънәнең булмавы яки ясаучы нигезнең мәгънәсе сүздәге семантикага туры килмәве. Күрсәтелгән өч билгенең берсе булуы тикшерелә торган исемнең кушымчалау ысулы белән ясалуын күрсәтә. Бу кушымча, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана (*чолга+у, асра+у*). Кайчак исемнәргә дә кушылырга мөмкин (*арка+у*).

Исем + *-у*/*-ү* (*-ау*/*-әү*) моделе ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган предметны тәгъбир итә: *аркау.* Дөрес, мәгънәсе хәзерге көндә беркадәр метафоралашкан.

Фигыль + *-у*/*-ү* (*-ау*/*-әү*) моделе ясаучы нигез белдергән эшхәрәкәт өчен хезмәт итә торган предметны тәгъбир итә: *борау, йамау* (орф. *ямау*), *кыршау, кырау, келәү* (*келә* диал. *телә*).

Хәзерге татар телендә бу кушымча белән ясалган исемнәр байтак, әмма аларның нигезләре аерылмый: *тарлау, карлау, чабу, кисәү, кыңгырау* (бәлки *кыңгыр* фигыль булып «яңгырау» мәгънәсен белдергәндер), *ачу, богау* (*бог – баг* «бәйләү»), *тимерәү, кизү, кизләү* (диал.), *азау, ыклау, сакау, томау, беләү* һ.б.

**Нигез + *-гыра* кушымчасы.** Бу кушымча структурасы һәм мәгънәсе ягыннан фигыльләрдәге кечерәйтү кушымчасын хәтерләтә (*барынкыра*). Ул исемнәргә ялгана. *-гыра* кушымчалы исем ясаучы нигез белдергән нәрсәнең булмавы белән тасвирлана торган затны тәгъбир итә: *аңгыра.*

**Нигез + *-дак*/*-дәк* (*-так*/*-тәк*) кушымчасы.** Бу кушымча генетик яктан, мөгаен, *-дык*/*-дек* кушымчасы белән бәйләнгән. Ләкин хәзер-

ге көндә ул аерылган һәм мәгънәсенең үзенчәлеге буенча мөстәкыйль кушымча тәшкил итә. *-дак*/*-дәк* кушымчасы исемнәргә (*буй+дак, баш+так* (диал.)) һәм фигыль нигезләргә (*куыр+дак*) ялгана.

Фигыль + *-дак*/*-дәк* кушымчасы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны белдерә: *куырдак.*

Хәзерге татар телендә *-дак*/*-дәк* кушымчалы, әмма нигезләре ачык булмаган сүзләр дә бар: *кештәк, калтак* (диал.), *балдак, тинтәк, йәлтәк* (диал. = *йәл* «чабу», «йөгерү»), *үрдәк, чигелдәк, дуадак, ардак* (диал.). Һичшиксез, бу сүзләр структур яктан мәгънәле кисәкләргә бүленмиләр. Әмма бернәрсә бәхәссез: күпчелек очракта алар *-дак*/*-дәк* кушымчасы белән ясалганнар.

**Нигез + *-дәл* кушымчасы.** Бу кушымча татар телендә бары бер сүздә генә очрый: *шәмдәл.* Шунлыктан аның татар теленеке булуына шик туа. Монгол телләрендә *-дәл* кушымчасы белән ясалган сүзләр байтак, әмма аларда татар телендәге корал, җайланма мәгънәсе юк.

**Нигез + *-кым*/*-кем* кушымчасы.** Ул фигыль нигезләргә ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-кым*/*-кем* кушымчасы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны тәгъбир итә: *салкым, төркем.* Күренгәнчә, *-кым* кушымчалы исемнәр ясаучы нигезләрнең беренче мәгънәләреннән шактый ераклашканнар.

**Нигез + *-мар*/*-мәр* кушымчасы.** Кушымча исемнәргә ялгана. Аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Исем + *-мар*/*-мәр* кушымчасы ясаучы нигез белдергән нәрсә белән тасвирлана торган предметны тәгъбир итә: *чукмар.* Бу кушымча *телмәр* дигән башкорт сүзендә очрый.

**Нигез + *-мыр*/*-мер*$_1$ кушымчасы.** *-мар*/*-мәр* кушымчасы белән *-мыр*/*-мер*$_1$ кушымчасы арасында генетик бәйләнеш бар. Ул – исемнәргә ялгана: *төс+мер.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Исем + *-мыр*/*-мер* моделе ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган предметны тәгъбир итә: *төсмер.* Шул ук мәгънәгә *тамыр* сүзе карый, *та* элементы хәзерге татар телендә *таралу* фигылендә очрый.

Фигыль + *-мыр*/*-мер*$_1$ моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган җайланманы: *уймыр.* Бәлки *тимер* сүзе дә бу ясалышка карыйдыр.

Борынгы төрки телдә *ти* (*тег*) фигыле «үтеп керү, җимерү» мәгънәсен белдергән.

2. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган затны: *кысмыр, үсмер.*

**Нигез + *-ман/-мән* кушымчасы.** Кушымча бик аз сүзләр ясый. Бәлки ул контаминация кичергәндер. Фигыльләргә (*тиш+мән*) һәм исемнәргә ялгана (*ата+ман*). Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

*-ман, -мән* кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итәләр:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган предметны: *азман, тишмән.*

2. Ясаучы нигез белән сыйфатлана торган урынны: *чытырман.*

3. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган корал яки җайланманы: *сөймән* (борынгы төрки телдә *сөй,* хәзерге татар телендә *суй* «актару» мәгънәсен белдерә), *китмән.*

Хәзерге татар телендә нигезе ачык булмаган *-ман, -мән* кушымчалы башка сүзләр дә бар: *тегермән, тирмән* (диал.), *урман* (бәлки *чытырман* моделе кебек, мәсәлән, М. Кашгарыйда *ур+га* сүзе «биек агач» мәгънәсен белдергән) *кушман, токман, узаман.*

**Нигез + *-на/-нә*$_1$ кушымчасы.** Берничә сүздә генә очрый. Фигыльләргә (*бир+нә*) һәм аваз ияртемнәренә ялгана: *тор+на.*

Фигыль + *-на/-нә*$_1$ моделе ясаучы нигез белдергән эш өчен билгеләнгән предметны: *бирнә.*

Аваз ияртеме + *-на/-нә*$_1$ кушымчасы ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган җанлы затны: *торна.*

*-на*$_1$ кушымчасын башка сүзләрдә дә очратырга мөмкин, әмма аларның ясаучы нигезләре ачык түгел: *гөбнә, күнә, казна* (*казан* «иреш?»).

**Нигез + *-ана/-әнә* кушымчасы.** Генетик яктан ул *-анак/-әнәк* кушымчасы белән бәйләнгән булса кирәк. Исемнәргә (*баг+ана,* борынгы төрки телдә *баг* сүзе «беркетү, бәйләү предметы» дигән мәгънәне белдергән), ияртемнәргә (*бүдәнә, бүд=бүт* сүзе *бүдәнә* тавышына ияртем) ялганып*, ана/-әнә* кушымчалы исемнәр ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган җанлы затны яки предметны тәгъбир итә: *бүдәнә, багана.*

**Нигез + *-сак/-сәк* кушымчасы.** Кушымча төрле булган ике чыганакка барып тоташа. Мәсәлән, *ашамсак, йөремсәк, ярамсак* (диал.) сүзләрендә теләк мәгънәсе бар, бу очракта *-сак*/*-сәк* кушымчасы теләк мәгънәсен белдергән *-са*/*-сә* кушымчасы белән фигыльдән исем ясаучы *-к*/*-ык* кушымчасының кушылуыннан килеп чыккан. Башка сүзләрдә «охшату» мәгънәсе күзәтелә (*бавыр+сак*). Бу мәгънәдә ул *сак – тәк* «охшаш» сүзе белән бәйле.

*-сак* кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә һәвәс затны: *йөремсәк, ашамсак, ярамсак.*

2. Ясаучы нигез белдергән затны теләүчене, яратучыны: *ирсәк.*

3. Ясаучы нигез белдергән предметны кай ягы белән дә булса хәтерләтә торган предметны: *бавырсак.*

Хәзерге татар телендә *-сак* кушымчалы, әмма нигезләре анык булмаган башка сүзләр дә бар: *корсак, карсак, сарымсак* (бәлки *сару* фигыленнән).

**Нигез + *-ча/-чә*$_2$ кушымчасы.** Бу модель хатын-кыз җенесен белдерә. Әгәр ул мөмкин булган барлык сүзләрдә очраса, бу кушымчаны мөәннәс җенесен тәгъбир иткән грамматик кушымча дип карарга булыр иде.

*-ча* кушымчасы караим телендә күп очрый: *керключа* «чибәркәй», *сюверчя* «сөяркә». Ул ирләр җенесен белдергән сүзләргә ялгана: *би+чә, кода+ча.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

*-ч* элементының татар телендә гомумән хатын-кыз җенесе мәгънәсен белдерүен билгеләп китәргә кирәк: *бик+әч* «бик кызы», *иг+әч* «кыз туган».

**Нигез + *-ша/-шә* кушымчасы.** Кушымчаның этимологиясе ачык түгел. *-ча*/*-чә* кушымчасы белән *-ша*/*-шә* кушымчасы арасында генетик бәйләнеш бар кебек. Рус телендә шундый ук мәгънәле шундый ук кушымча бар: *губернатор+ша, казначей+ша.* Ул исемнәргә (*хатын+ша*), сыйфатларга (*күк+шә*) ялгана. Аның ясаучы нигезләре – барысы да татар сүзләре.

*-ша* кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә.

1. Ир җенесе мәгънәсен белдергән сүздән ясалган хатын-кыз җенесендәге затны: *ханша.*

2. Ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган затны яки тереклек иясен: *хатынша, күкшә.*

Бу кушымча *колаша, кәлшә* кебек сүзләрдә очрый, әмма аларның ясаучы нигезләре ачык түгел.

**Нигез + *-ка/-кә*$_1$ кушымчасы.** Кушымча бары берничә сүздә генә очрый. Исемнәргә (*би+кә*), фигыльләргә (*сөяр+кә*) ялгана. Н.К. Дмитриев *-к* элементын кушымча составыннан чыгара, *-а* элементын, гарәп теленнән алынган кушымча, дип карый. *-кә* кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән ирнең хатыны яки хатын-кыз җенесендәге затны: *бикә.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең объекты булган хатын-кыз җенесендәге затны: *сөяркә.*

*Кортка* сүзендә ясаучы нигез ачык түгел.

**Нигез + *-чыл/-чел* кушымчасы.** Татар телендә бу кушымча белән ясалган сүзләр күп түгел. Ул исемнәргә ялгана: *кыр+чыл.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

**Нигез + *-чыл/-чел* кушымчасы** ясаучы нигез белдергән билге белән нинди дә булса бәйләнеше булган предметны яки затны тәгъбир итә: *кырчыл, утчыл, чәмчел.*

**Нигез + *-ым/-ем*$_2$ кушымчасы.** Сүзьясагыч *-ым*$_2$ кушымчасының тартым категориясен белдергән *-ым*$_3$ кушымчасы белән бернинди дә уртаклыгы юк, алар төрле чыганакка барып тоташалар. *-ым*$_2$ кушымчасының этимологиясе борынгы төрки телдәге *ем* «хатын» сүзе белән бәйләнгән булса кирәк (монгол телендә *ем* шулай ук «хатын» мәгънәсен белдерә).

Кушымча ир җенесен белдергән исемгә кушылып хатын-кыз җенесен белдергән исем ясый: *ханым.*

Үзбәк телендә дә бу кушымча бар: *бегим, айим.*

**Нигез + *-чы/-че*$_2$ кушымчасы.** Бу кушымча этимологиясе ягыннан *-чы*$_1$ кушымчасы белән бәйләнмәгән, аның белән бернинди дә уртаклыгы юк. Фигыльләргә ялгана: *там+чы, сөен+че, кай+чы* (*кай* нигезе *кайыру* фигылендә очрый).

*-чы*$_2$ кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итәләр:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт нәтиҗәсе булган предметны: *там+чы, юн+чы.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш өчен билгеләнгән предметны: *кайчы.* Бу мәгънә шулай ук *камчы* сүзенә дә карый булса кирәк.

**Нигез + *-чын*/*-чен*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-чын,* нечкә нигезләргә *-чен* ялгана. Ясаучы нигезләре булып исемнәр (*колак+чын*) һәм фигыльләр (*ияр+чен, кыр+чын*) килә, алар барысы да татар сүзләре.

*-чын*/*-чен*$_1$ кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган затны, тереклек иясен яки предметны: *күгәрчен, иярчен, кырчын.*

2. Ясаучы нигез белдергән нәрсә өчен хезмәт итә торган предметны: *колакчын.*

**Нигез + *-әзә* кушымчасы.** Хәзерге татар телендә бары берничә сүздә генә очрый, ясаучы нигезләре булып фигыльләр килә. *-әзә* кушымчалы исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән характерлана торган затны: *күрәзә.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән предметны: *җилпәзә.*

**Нигез + *-сын*/*-сен*$_1$ кушымчасы.** Ул *кавырсын, сусын, алсын* (диал.), *селәүсен* кебек сүзләрдә күзәтелә. Бу сүзләрдәге *-сын*/*-сен* бер үк кушымча түгел булса кирәк. *Сусын* сүзендәге *-сын* кушымчасы, мөгаен, борынгы төрки телдәге теләк фигыль күрсәткеченә, *кавырсын* сүзендә ул *-сы*/*-су* охшату күрсәткеченә кайтып кала.

**Нигез + *-ыз*/*-ез* (*-аз*/*-әз*)$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча бары *ки+ез* сүзендә генә мәгънәле кисәкләргә аерыла (*ки=кию*), ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән предметны тәгъбир итә. Хәзерге татар телендә бу кушымча белән башка сүзләр дә бар, әмма аларның нигезен билгеләве кыен: *ауыз* (орф. *авыз*), *бугаз, игез* (*ике*), *мөгез, айаз* (орф. *аяз*), *ай* – (*ачылу, аерылу*), *йолдыз* (нигез *йолт – йолд* образ ияртеме).

**Нигез + *-дәмә* кушымчасы.** Исемгә ялгана: *бил+дәмә, иң+дәмә* (диал.). Бу кушымча белән килгән сүзләр ясаучы нигез белдергән предмет янында булган предметны белдерә: *билдәмә, иңдәмә.*

**Нигез + *-гыл*/*-гел* (*-кыл*/*-кел*) кушымчасы.**

Аның ясаучы нигезләре булып фигыльләр килә.

Бу кушымча ялганган исемнәр түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән билге белән тасвирлана торган урынны: *үткел, чумгыл, баткыл.*

2. Ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган предметны: *сипкел.*

*Чоңгыл* сүзе дә бу кушымча белән ясалган булса кирәк.

**Нигез + *-ыл/-ел, -л*$_1$ кушымчасы.** Тартыкларга тәмамланган сүзләргә *-ыл/-ел,* сузыкларга тәмамланганнарга *-л* кушымчасы ялгана: *саркы+л, тукал* (*тук/ток* нигезе *мөгезсез* мәгънәсендәге кытай сүзе), *чагыл, айыл* (*айа* нигезе саклауны белдерә), *тел* (нигезе *те – ти – ди*), *күгел* (нигез *күк* сыйфаты), *дау+ыл* (орф. *давыл*).

Бу кушымча, мәсәлән, *саркыл* сүзендә ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән предметны белдерә.

**Нигез + *-ай/-әй*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымчаның төрле чыганакларга барып тоташуы бик мөмкин. Ул хәзерге көндә нигез белән тоташып киткән. Ул күпчелек очракта мәгънәле кисәкләргә аерылмый. *-ай/-әй* кушымчасы *-а* һәм *-ә* авазларына тәмамланган нигезләргә ялганганда элизия күренеше килеп чыга: *анай* (диал.), *атай* (диал.), *бабай, тәтәй* (диал.), *нәнәй* (диал.).

Хәзерге татар телендә *кендек+әй* һәм *тамак+ай* сүзләре генә мәгънәле кисәкләргә аерыла.

Бу кушымча тагын кайбер исемнәрдә очрый, ләкин хәзерге көн күзлегеннән караганда күпчелегенең ясаучы нигезләре ачык түгел: *күгәй* (диал. нигезе *күк*)*, калай* (*кал* кисәге *калкан* сүзендә күзәтелә), *тугай* (*туг* кисәге борынгы төрки телдәге *туглык* (өсте буш, тигез урын) сүзендә күзәтелә), *тургай* (туры борынгы төрки телдә «көрән» мәгънәсен белдергән), *бүкәй* (*бүк* нигезе борынгы телдә «сер» мәгънәсендә йөргән).

**Нигез + *-ла/-лә*$_2$ кушымчасы.** Бу кушымча *кысла* сүзендә очрый. Күренгәнчә, ясаучы нигезе булып фигыль килгән. Бу сүз нигез белдергән билгенең иясен тәгъбир итә. Азәрбайҗан телендә бу кушымча белән ясалган сүзләр шактый күп.

**Нигез + *-сыл/-сел* кушымчасы.** Бу кушымча *юк+сыл, җеп+сел* сүзләрендә очрый. Сыйфатларда ул күбрәк очрый: *аксыл, күксел.* Исемнәрдә дә, сыйфатларда да бу кушымча бер үк чыганакка барып тоташа.

**Нигез + *-лай/-ләй*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча *эт+ләй, кора+лай* (*кора* нигезе борынгы төрки телдә «җитез» мәгънәсен белдергән).

**Нигез + *-аган* кушымчасы.** Бу кушымча *ят+аган* (диал.) сүзендә очрый (нигезе *ят*). Кушымча билгенең иясен белдерә. Башка төрки

телләрдә, мәсәлән, азәрбайҗан телендә бу кушымча белән ясалган сүзләр шактый күп.

**Нигез + *-таи/-тәй*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча *түбә+тәй, шыран+тай* (*шыран* нигезенең *шәрә* сүзе белән бәйләнеше бар), *торымтай, кәнтәй.* Кушымчаның семантикасы борынгы төрки телдәге *таг-тәк* сүзенә барып тоташа булса кирәк.

**Нигез + *-тый/-ти* кушымчасы.** Бу кушымча түбәндәге сүзләрдә очрый: *пул+тый* (диал.) «угры» (*пул* нигезе борынгы төрки телдә «эләктерү» мәгънәсен белдергән); *чыштый* (диал.), *чәнти.* Мәгънәле кисәкләргә бары *чыш+тый* сүзе генә аерыла (*чыш* – аваз ияртеме).

Безнең фикеребезчә, *-тый/-ти* кушымчасы генетик яктан *-тай/ -тәй* кушымчасына барып тоташа.

**Нигез + *-па/-пә* кушымчасы.** Бу кушымча *элпә, кылпа, көрпә* I (он калдыгы), *көрпә* II (аяк аслыгы) сүзләрендә очрый. *Элпә* сүзеннән башкалары мәгънәле кисәкләргә аерылмыйлар. Кушымча *-пак/-пәк* кушымчасына барып тоташа булса кирәк.

**Нигез + *-пу* кушымчасы.** Бу кушымча *кырпу, чалпу* сүзләрендә күзәтелә. *Кырпу* сүзенең нигезе булып *кыр* (*кырый*) сүзе тора.

**Нигез + *-тыш* кушымчасы.** Бу кушымча *кыр+тыш* (*кыр – кырый*), *артыш* сүзләрендә очрый.

**Нигез + *-лач* кушымчасы.** Кушымча исемнәргә (*карт+лач*) һәм фигыльләргә (*ерт+лач*) ялгана. Бу тип ясаучы нигез белдергән билгегә ия затны тәгъбир итә. Кушымча тагын кушма исемнәрдә очрый: *агам кырлач, энем кырлач.*

**Нигез + *-әбәт* кушымчасы.** Бу кушымча *үл+әбәт* сүзендә очрый. Ясаучы нигез белдергән процесс нәтиҗәсендә барлыкка килгән предметны белдерә: *үләбәт.*

**Нигез + *-гач/-гәч* (*-кач/-кәч*) кушымчасы.** Бу кушымча генетик яктан *-гыч/-геч* кушымчасы белән бәйләнгән. Ул – фигыль нигезләргә ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

*-гач* кушымчалы исемнәр ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган предметны тәгъбир итә: *себер+кәч, тот+кач* (диал.).

Бу кушымча белән килгән кайбер исемнәр бүгенге көндә тамырлашканнар: *капкач* (*кап* кисәге *капу* (капка), *капла* сүзләрендә очрый), *сәркәч* (диал.).

**Нигез + *-пак/-пәк* кушымчасы.** Бу кушымча *кыр+пак* (нигезе *кыр* «ваклау» мәгънәсендә), *эл+пәк* (диал.).

**Нигез + *-ар* кушымчасы.** Кушымча исемгә (*аст+ар*) ялгана. Бу кушымча белән килгән исем ясаучы нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган предметны тәгъбир итә: *астар* (рус. подкладка).

**Нигез + *-ача* кушымчасы.** Кушымча фигыльгә ялгана: *кун+ача.*

*Фигыль + -ача* моделе ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган предметны тәгъбир итә: *кунача.*

**Нигез + *-ама* кушымчасы.** Бу кушымча *кор+ама* сүзендә очрый. Фигыльгә кушылып ясаучы нигез белән бәйләнгән предметны тәгъбир итә: *корама.*

**Нигез + *-лама* кушымчасы.** Бу кушымча *кара+лама* (нигезе сыйфат) сүзендә очрый, мәгънәсе метафоралашкан.

**Нигез + *-чи/-чый* кушымчасы.** Бу кушымча белән килгән исем ясаучы нигез белдергән гомуми билге белән сыйфатлана торган затны тәгъбир итә: *тумачый.* Бу кушымча мәгънәле кисәкләргә аерылмый торган *арчи* (арчый) сүзендә дә очрый.

## Алынма кушымчалар белән исемнәр ясалышы

Ала торган телнең базасында һәм закончалыклары нигезендә генә кушымча яңа сүзләр ясаса, ул кушымча алынма кушымча була. Ә бу барлык очракта да күзәтелми.

Мәсәлән, *-ист, -изм, -ер* (карьерист*, сюрреализм, коррупционер*) кушымчалары татар теле нигезендә һәм аның закончалыклары буенча яңа сүзләр ясамаганнар һәм ясамыйлар. Ул кушымчалар алынма сүзләр белән бергә кабул ителгәннәр. Шуңа күрә ул кушымчаларны алынма кушымчалар дип санап булмый.

Шулай да хәзерге татар телендә татар теле нигезендә һәм аның закончалыклары буенча яңа сүзләр ясаган һәм ясый торган алынма кушымчалар бар. Шундый кушымчалар булып фарсы теленнән алынган *-стан, -ханә, -намә, -сар, -тараш, -кәр* тора. Дөрес, аларның күпчелеге фарсы телендә мөстәкыйль сүзләр, әмма татар телендә мөстәкыйль кулланылмаганлыктан аларны кушымча рәтендә йөртәләр. Гарәп теленнән *-ый/-и* кушымчасы алынган. Рус телендә

фамилия һәм «отчество» (ата исеме белән атау сүзе) күрсәткече татар теле өчен алынма кушымча булып торалар: *-ов*/*-ев* һәм *-ова*/*-ева, -ин*/*-ина, -ович*/*-евич* һәм *-овна*/*-евна, -ский*/*-ская.* Югарыда китерелгән барлык кушымчалар татар теле нигезендә яңа сүзләр ясыйлар, ягъни аларның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә. Алынма кушымчалар, кагыйдә буларак, исемнәргә ялгана. Алар рус теленнән алынган фамилия һәм отчество күрсәткечләреннән башка продуктив түгелләр.

**Нигез + *-стан* кушымчасы.** Хәзерге татар телендә калын вариантлары гына йөри: *Кыргызстан, Төрекмәнстан, Татарстан. -стан* кушымчасы белән килгән исемнәр нигез белдергән кешеләр яши торган республиканы яки административ-территориаль берәмлекне тәгъбир итәләр: *Чувашстан, Үзбәкстан.*

**Нигез + *-ханә* кушымчасы.** Бу кушымча белән ясалган сүзләр татар телендә шактый күп: *сыраханә, отышханә, эшханә, ашханә, шифаханә, сырхауханә, хастаханә, чәйханә, басмаханә, даруханә.*

Бу кушымча белән килгән исемнәр ясаучы нигез белән бәйләнешле нинди дә булса җитештерү, җәмәгать туклануы предприятиесен, дәвалану учреждениесен тәгъбир итә: *басмаханә, эшханә, чәйханә, шифаханә.*

**Нигез + *-намә* кушымчасы** телдә сирәк очрый. Бу кушымча белән килгән исемнәр берәр эш кәгазен, китапны һ.б.ш. тәгъбир итә: *низамнамә, елнамә, юраунамә.*

**Нигез + *-сар*$_1$ кушымчасы.** Фарсы телендә *-зар* формасында йөри: *гөлзар. -сар* кушымчасы белән килгән исемнәр нигез белдергән үсемлекләр үскән урынны тәгъбир итә: *каенсар, имәнсар, юкәсәр.*

*-сар* кушымчасы *сусар* сүзендә очрый. Биредә ул фарсы телендәге кушымчага барып тоташмый булса кирәк, чөнки мәгънәсе ягыннан фарсы кушымчасыннан бик ерак тора.

**Нигез + *-тараш* кушымчасы.** Бу кушымча белән килгән исем нигез белдергән эш белән шөгыльләнүче затны яки аның эш урынын тәгъбир итә: *чәчтараш.*

**Нигез + *-задә* кушымчасы.** Бу модель татар телендә сирәк очрый: *шаһзадә, ханзадә.* Бары *ханзадә* сүзе генә татар теле ясалышына керә, чөнки аның ясаучы нигезе татар теленеке. Бу кушымча белән килгән исем атасының титулы белән белдерелгән улны тәгъбир итә.

Хәзерге татар телендә *-задә, -тараш, -стан* һ.б.лар мөстәкыйль сүз буларак кулланылмыйлар, шуңа күрә аларны кушымчалар дип карарга туры килә.

**Нигез + *-и/-ый* кушымчасы.** Бу кушымча гарәп телендә нисби сыйфатлар ясый: *хосус+ый.* Әмма татар телендә аның исем ясаган очраклары да бар. Кагыйдә буларак, мондый исемнәр туган яки торган җиренә бәйләнешле ялгызлык исемнәрен тәгъбир итәләр: *Болгарый, Казаный.*

**Нигез + *-ов/-ев, -ин, -ский* кушымчалары.** Бу кушымчалар рус телендә ир затлары фамилияләренең күрсәткечләре булып торалар. Хәзерге татар телендә алар шулай ук татар теле нигезләреннән ир заты фамилияләрен ясыйлар: *Кәрим+ов, Бари+ев, Саф+ин, Шамиль+ский.*

Шуңа күрә аларны татар теленең сүзьясагыч чаралары итеп карарга туры килә. *-ин* кушымчасы сузык авазларга тәмамланган исемнәргә ялганганда, аның соңгы сузыгы төшеп кала: *Гата – Гатин, Мостафа – Мостафин.* Бу кушымчаларның иң таралганнары – *-ов/-ев, -ин, -ский* кушымчасы сирәк, бары кайбер сәнгать кешеләренең фамилияләрендә генә очрый.

**Нигез + *-ова/-ева, -ина, -ская* кушымчалары.** Бу кушымчалар рус телендә хатын-кыз җенесе фамилияләрен тәгъбир итәләр. Хәзерге татар телендә аларның барысы да татар теле нигезләреннән хатын-кыз фамилияләре ясыйлар: *Кәрим+ова, Бари+ ева, Саф+ина, Болгар+ская.* Шуның өчен дә алар татар теленең сүзьясагыч чаралары итеп каралалар. Китерелгән кушымчалар, *-ская* кушымчасыннан башкалары, телдә киң таралган.

**Нигез + *-ович/-евич* кушымчалары.** Бу кушымчалар рус телендә ир җенесе «отчество»сы мәгънәсен бирәләр. Хәзерге татар телендә алар татар теле нигезләреннән шулай ук ир җенесе отчествосын ясыйлар: *Кәрим+ович, Бари+евич.*

**Нигез + *-овна/-евна* кушымчалары**. *-овна/-евна* кушымчалары рус телендә хатын-кыз җенесе «отчество»сы мәгънәсен бирәләр. Хәзерге татар телендә алар татар теле нигезләреннән хатын-кыз отчестволарын ясыйлар: *Сәлим+овна, Сираҗи+евна.*

**Нигез + *-дар* кушымчасы.** Бу кушымча ялгызлык исемнәрен ясый: *Ил-дар, Ай-дар. Ил, ай* исемнәре – татар сүзләре.

## Нигезләреннән аерылмый торган кушымчалар

Хәзерге татар телендәге кайбер исемнәрнең структурасында нигезләреннән аерылмый торган кушымчалар, ягъни үле кушымчалар очрый. Кайберләре аларның контаминация нәтиҗәсендә ике яки күбрәк элементларның кушылуыннан килеп чыккан булырга, йә алынма булырга мөмкин.

***-гыр/-гер* (*-кыр/-кер*)$_2$ кушымчасы.** Аның килеп чыгышы турында ачык фикер юк. Сыйфат ясагыч *-гыр/-гер* кушымчасы (*үт+кер*) белән бәйләнеше турындагы фикер бик шикле, чөнки бу кушымча белән ясалган исемнәрнең берсендә дә аларны сыйфат белән якынлаштыра торган мәгънәләр күзәтелми. Хәзерге көндә *-гыр* кушымчалы барлык фигыльләр мәгънәсе ягыннан да, структурасы ягыннан да мөстәкыйль кисәкләргә аерылмыйлар, шуңа күрә алар тамырлашкан сүзләр булып торалар: *яңгыр, эңгер* (*Салмак кына җәелә кичке эңгер.* Ш. Маннур), *кыйгыр, айгыр.*

***-гар/-гәр* (*-кар/-кәр*)$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча хәзерге татар телендә аерылмый: *кучкар, элгәр* (*эл* кисәге *элек* сүзендә очрый), *болгар, өлкәр.*

***-мач/-мәч* кушымчасы.** Берничә сүздә генә очрый: *тәгәрмәч, толмач* (*тел+мәч*)*, йыр+мач* (диал.). *Тәгәрмәч* сүзендәге нигезне кайбер тикшеренүчеләр *тәгәрә* фигыле белән бәйлиләр. Безнең фикеребезчә, *тәгәрә* сүзе үзе *-ә* кушымчасы ярдәмендә борынгы *тәгәр* сыйфатыннан ясалган.

***-та/-тә* кушымчасы,** *-та* кушымчалы сүзләрнең лексик-семантик үзенчәлекләре һәм структурасына караганда ул кушымча *тәг* «шундый» дигән сүзгә барып тоташа кебек. Мәсәлән, борынгы төрки телдә *тү* сүзе «чыгу, чыгып тору» мәгънәсен белдергән, димәк, нәкъ рус телендәге кебек – обухший – обух, *түтә* сүзе «чыккан, чыгып торган нәрсә» дигәнне белдергән. *Көлтә* сүзендә *көл* нигезе борынгы төрки телдә «бәйләү» мәгънәсен белдергән.

Этимологияләре буенча фараз итеп караганда, *-та* кушымчалы исемнәр нигез белдергән билге белән сыйфатлана торган предметны тәгъбир итәләр: *түтә, арата, көлтә.* Хәзерге татар телендә *-та* кушымчалы башка исемнәр дә бар: *турта, оста, балта, карта, чабата. Тур-, ос-, бал-, чаба-* – борынгы төрки телдә мөстәкыйль мәгънәле сүзләр булганнар. Мәсәлән, *ос* (*ус*) нигезе анда үзе *оста* сыйфа-

ты булган. Шуңа күрә *оста* сүзе, кайбер тикшеренүчеләр раслаганча, фарсы теленнән алынмаган, ә, киресенчә, фарсы телендә бу сүз төрки телләрдән алынган сүз булып тора.

***-чан/-чән$_1$* кушымчасы.** Бу кушымча структурасы ягыннан аерым кисәкләргә аерылмаган. Бүгенге көн күзлегеннән структур яктан нигездән аерылмый: *билчән, суалчан. Билчән* сүзенең нигезе борынгы төрки телендәге «үткен» мәгънәсендәге *бел* сүзе белән, *суалчан* сүзенең нигезе борынгы төрки телендәге «сузылу» мәгънәсендәге *су* сүзе белән бәйләнгән булса кирәк.

***-мык/-мек$_1$* кушымчасы.** Бу кушымча белән килгән сүзләр шулай ук нигездән аерылмыйлар: *боламык, кызамык, сазламык, көртләмек.* Бары диалекталь *кара+мык* сүзендә генә мөстәкыйль нигез күзәтелә. Тарихи яктан бу кушымча, һичшиксез, сүзьясагыч булып тора. Мәсәлән, *боламык* сүзенең нигезе *болга* булган. Борынгы төрки телдә шул ук мәгънәдәге *болга+ма* сүзе очрый.

***-аш/-әш, -ш* кушымчасы.** Ул бары берничә сүздә генә күренә: *көрәш, туташ. Туташ* сүзендәге *-аш* элементы, *бикәч* сүзендәге *-ач/-әч* кушымчасы белән тәңгәл булса кирәк. Сүзнең беренче кисәге сөйләмнәрдә мөстәкыйль сүз буларак та килә: *тута* «апа». *Урнаш* сүзендәге *-аш* кисәгенең бу кушымча белән бернинди дә уртаклыгы юк. *Урнаш* сүзе кушма сүз тәшкил итә, *урн=урын* «яшертен» дигән мәгънәне белдерә, *аш* сүзе мөстәкыйль сүз булып тора.

***-лан/-лән$_1$* кушымчасы**. *Каплан, сыртлан, әрлән, арыслан* кебек сүзләрдә очрый. Бу сүзләрнең барсы да җәнлекләрнең атамасын белдерә. Бу сүзләрнең нигезләре бүгенге көндә билгеле түгел, бары этимологик эзләнүләр нәтиҗәсендә генә аларны ачыкларга мөмкин. *Ак+лан* сүзендәге *-лан* кушымчасы урын мәгънәсен тәгъбир итә.

***-җа/-җә* кушымчасы.** Бу кушымча түбәндәге сүзләрдә очрый: *калҗа, морҗа, бөгәлҗә, кинҗә, көрҗә, баҗа, бөгәрҗә* (диал.), *бәлҗә.* Безнең фикеребезчә, бу сүзләрдәге *-җа/-җә* кушымчасы бер чыганактан гына түгел, төрле чыганаклардан килә.

***-дә* кушымчасы.** *Гәү+дә* сүзендә очрый. *Гәү* нигезенең саңгырау варианты *кәү+сә* сүзендә очрый.

***-ра/-рә* кушымчасы:** *шишара* (диал.), *туйыра* (орф. *туера*), *чүпрә, кәпрә, кура, бакра.* Мәсәлән, *кура* сүзендәге *ку* нигезе электә «буш» дигән мәгънәне аңлаткан.

***-гыз*/*-гез* кушымчасы:** *диңгез, дуңгыз, ңг* кушымчасы *ң* авазының таркалуыннан килеп чыкмаган микән, чөнки борынгы төрки телдә *дуңгыз тоңуз* вариантында йөргән.

***-дыз* кушымчасы:** *балдыз, кондыз.* Бәлки бу кушымча бер чыганактан килмидер.

***-быз* кушымчасы**: *кубыз.*

***-җын* кушымчасы:** *курҗын, кырҗын* (диал.).

***-май*/*-мәй* кушымчасы:** *көсәмәй* (*көсә* нигезе диалекталь *көсән* («сорау») сүзендә очрый), *ачамай* (диал.), *мәмәй, акамай* (диал.).

***-сык* кушымчасы.** *Бурсык* сүзендә очрый. Безнең фикеребезчә, *бур* нигезе электә «ис килү» мәгънәсен белдерә, исле булу бурсыкның бер үзенчәлеге булып тора.

***-ырым* кушымчасы.** *Йылдырым* сүзендә *йылд* (*йылт*) нигезе образлы ияртеме булып тора.

***-пы*/*-пе* кушымчасы**: *курпы, кырпы, шырпы, керпе, чулпы* сүзләрендә очрый. Әмма бу сүзләрдәге *-пы*/*-пе* кушымчасының бер чыганакка барып тоташуы шикле.

***-бык*/*-бек* кушымчасы**: *ләҗбек, дарбык* (диал.).

*-**кыт**/**-кет*** **кушымчасы**: *оңкыт* (диал.), *бөркет.*

***-рак*/*-рәк* кушымчасы**: чүпрәк, күкрәк, байрак.

***-ры*/*-ре* кушымчасы.** Бу кушымча сыйфатларда да (*кәкре*), исемнәрдә дә (*тәңре*)очрый. Хәзерге көндә *бөк+ре, кай+ры* (*кай* «аеру») сүзләрендә генә нигезләре тегеләйме, болаймы аерыла.

***-рәм* кушымчасы**: *бәйрәм.*

***-тан*/*-тән* кушымчасы**: *куштан, кәйтән, олтан, чуртан.*

***-тал***/*-тәл* **кушымчасы**: *байтал, түтәл.*

***-пан*/*-пән* кушымчасы**: *чулпан, талпан.*

***-әнтә* кушымчасы**: *көйәнтә* (орф. *көянтә*).

***-дырак* кушымчасы**: *кыйндырак.*

***-гый* кушымчасы:** *чылгый. Кодагый* сүзендә очрый, әмма бу сүз монгол теленнән алынма дип санала.

***-ба* кушымчасы:** *торба* (атларны ашату өчен).

***-авыт* кушымчасы**: *алпавыт.*

***-гыш* кушымчасы**: *алгыш, каргыш.*

***-кал* кушымчасы**: *ырыскал* (диал.).

***-мәт* кушымчасы**: *бишмәт, колмәт.*

### 9.5.3. Кушма исемнәр ясалышы

Татар телендә кушма исемнәр өч төрле ысул белән ясалалар: нигезләр (сүзләр) кушылу, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә әйләнүе, сүзтезмәләрнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе.

#### Нигезләр кушылу ысулы белән кушма исемнәр ясалышы

Татар телендә нигезләр тезүле бәйләнеш юлы белән дә, ияртүле бәйләнеш юлы белән дә кушма исемнәр ясаганнар һәм ясыйлар.

##### *Компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылу юлы белән кушма исемнәр ясалышы*

**Компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылу юлы белән кушма исемнәр ясалышының тюркологиядә һәм татар тел белемендә кыскача өйрәнелү тарихы.** Компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылу юлы белән кушма сүзләр ясалышы төрки телләрдә тигез өйрәнелмәгән. Бу юл белән сүзләрнең ясалышы түгел, ә куш сүзләрнең структурасы тикшерелгән. Аерым төрки телләрдәге куш сүзләр турында монографияләр һәм мәкаләләр бар.

Куш сүзләр турында беренче башлап әйтелгән сүзне без «Алтай теле грамматикасы»нда очратабыз. Аннан соң чыккан барлык төрки грамматикаларда, кагыйдә буларак, куш сүзләр искә алына. Н.К. Дмитриевның «Башкорт теле грамматикасы»нда куш сүзләр турында җентекле мәгълүмат бирелә. Галим фикеренчә, аларны семантик, фонетик һәм синтаксик яктан классификацияләргә мөмкин.

Шуннан башлап төрки грамматикаларда кайбер өстәмәләр белән Н.К. Дмитриев концепциясе китерелә.

Сүзьясалышка багышланган хезмәтләрдә шулай ук куш сүзләргә багышланган бүлекләр бар. К. Фой, Т. Ковальский, Н.К. Дмитриев, С.К. Кенесбаев, Е.И. Убрятова, Ж.Ш. Шукуров, А.Т. Кайдаров һ.б.ның бу мәсьәләгә багышланган махсус хезмәтләре һәм мәкаләләре бар. Бу хезмәтләрдә тикшерелә торган телләрдәге куш сүзләрнең тиешле тирәнлектә семантик һәм структур үзенчәлекләре ачыклана. Әмма шуны истә тотарга кирәк: куш сүзләрне классификацияләүдә, еш кына, «бүленешнең бердәм нигезе» сакланмый.

К.М. Любимов гомумән куш сүзләрне лексик берәмлекләр дип санамый, аларны сүзтезмәләре дип карый. Аның фикеренчә, куш сүзләрнең ике компоненты да грамматик категория белән үзгәрәләр. Әмма татар теле фактлары моны расламый.

Татар теле турында чыккан беренче грамматикаларда куш сүзләр турында мәгълүматлар очрамый. Бу аңлашыла да, чөнки төрки телләрне тикшерүчеләр, Ф. Менинскийдан башлап, төрки телләрдә кушма сүзләр юк яки бик аз дип санап килделәр. Мәсәлән, И. Гиганов «татар телендә кушма сүзләр аз» дип язды. А.Казимбәк фикеренчә, «төрек телендә тезмә сүзләр юк» һ.б.

Татар тел белемендә куш сүзләргә беренчеләрдән булып К.Насыйри игътибар итә. Ул аларның берничә төрен күрсәтеп, аларның шактый тулы исемлеген бирә.

Г. Ибраһимов үзенең грамматикасында «юлдаш сүзләр» исеме белән куш сүзләр турында шулай ук мәгълүмат бирә: *тау-таш, килем-китем, алыш-биреш, ир-ат,* сүз җилемнәре дип *карт-коры* кебек сүзләрне атый.

Г. Алпаров 1928 елда Көнчыгыш белеме институтында ясаган зур докладында, кушма сүзләр белән беррәттән, куш сүзләргә дә туктала. Куш сүзләрне ул семантик һәм фонетик принциплардан чыгып төркемли, кабатлауны куш сүзләрнең үзенчәлекләре күрсәтелә. Галимнең докладта китерелгән фикерләре соңыннан төрки телләргә караган күп хезмәтләрдә һәм мәкальләрдә үстерелә.

Ш.А. Рамазанов шулай ук куш сүзләрне күрсәтеп уза. Әмма аның мисаллары арасында кушма хәл фигыль формалары да очрый: *йөри-йөри.*

В.Н. Хангилдин һәм Д.Г. Тумашева грамматикаларында куш сүзләр турында шактый тулы мәгълүмат бирелә, аларның структур үзенчәлекләре күрсәтелә.

Ф.С. Фасиев үзенең хезмәтендә редупликация юлы белән терминнар ясалышын тикшерә, аларның компонентларыннан чыгып төрләрен билгели.

1969 елда басылып чыккан Татар теле грамматикасында Н.К. Дмитриев идеяләре үткәрелә.

Татар тел белемендә куш сүзләрнең өйрәнелүен кыскача күзәтү, алар турында мәгълүмат, нигездә, гомуми грамматикаларда гына

бирелүен, куш сүзләрнең, кагыйдә буларак, структуралары ягыннан гына тикшерелүен күрсәтә.

Тел материалыннан күренгәнчә, куш сүзләр төрле сүз төркемнәренә карарга мөмкин. Әмма татар телендә сан ягыннан куш исемнәр өстенлек итә.

### *Куш исемнәрнең компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып ясалуы*

Мондый ысул белән куш исемнәр ясалышының берничә тибы бар.

**Исем+исем тибы.** Аның түбәндәге модельләре бар.

*Төп формадагы исем*$_1$*+төп формадагы исем*$_2$ моделе: *җир-су, дус-иш, ил-күз, сарык-үгез, савыт-саба, урын-җир, җиләк-җимеш, туган-тумача, көньяк-көнбатыш, аң-белем, сын-сыйфат*. Бу модельдәге куш сүзләрнең компонентлары булып тамыр, кушымчалы һәм кушма сүзләр киләләр.

Тартымлы исем + тартымлы исем моделе: *аты-чабы, нигезе-төбе, эте-бете, яше-карты, иге-чиге.*

*-лы кушымчалы исем+-лы кушымчалы исем* моделе: *ирле-хатынлы, аталы-кызлы, аталы-уллы, апалы-сеңелле.* Китерелгән куш сүзләрнең компонентларының урыннары алмашынырга мөмкин (*хатынлы-ирле*), әмма, әдәби тел күзлегеннән караганда, бу куш сүзнең баштагы варианты дөресрәк. Бу модельдәге куш исемнәр күп түгел, башка сүз төркемнәрендә алар күбрәк: *язлы-көзле* (рәвеш), *иртәле-кичле* (рәвеш) һ.б.

Берлектәге исем$_1$ + күплектәге исем$_2$ моделе: *галим-голяма, гарип-гораба.* Бу куш исемнәрнең компонентлары булып, кагыйдә буларак, гарәп-фарсы сүзләре килә. Бу төр куш исемнәрнең икенче компоненты татар телендә түгел, ә чыганак телдә күплек формасын тәшкил итә, татар телендә бернинди грамматик кушымчасыз гади сүз булып кабул ителә. Шуңа күрә сөйләү телендә бу куш исемнәр күплек кушымчасын алырга мөмкин: *гарип-горабалар* һ.б. Бу модель, әлбәттә, гарәп телен яхшы белгән галим-голяма тарафыннан ясалган. Мисаллар: *Мин бит гарип-гораба түгел.* Т. Гыйззәт. *Газетачылар галим-голяманы хурлыйлар.*

Мөзәккәрдәге (ир җенесендәге) исем$_1$ + мөәннәстәге (хатын җенесендәге) исем$_1$ моделе: *ятим-ятимә, мөгаллим-мөгаллимә.* Билгеле булганча, татар телендә җенес (род) категориясе юк. Куш сүзләрнең бу

моделенең компонентлары булып гадәттә гарәп сүзләре килә: *мөгаллим* (мөзәккәрдә) һәм *мөгаллимә* (мөәннәстә). Бу төр куш исемнәр, кагыйдә буларак, берлектә кулланылмыйлар. Аларның күплектә кулланылуы табигыйрәк килеп чыга: *мөгаллим-мөгаллимәләр, ятим-ятимәләр.*

Исем$_1$ + аваздаш сүз моделе: *китап-митап, кыз-мыз, аракы-моракы.* Кагыйдә буларак, мондый куш исемнәрнең икенче компоненты сөйләмдә кулланылмый, чөнки телдә мөстәкыйль *митап, мыз, моракы* сүзләре юк. Бу модель ясалышының бик ачык кагыйдәләре бар: беренче компонентның алдына я *м* авазы өстәлә (*идән+мидән*), я беренче компонентның беренче авазы *м* авазы белән алмашына (*дәфтәр-мәфтәр*). Бу очракта беренче иҗектәге сузык авазлар кайбер үзгәрешләр кичерергә мөмкин: *а* авазы *о* га, *ә* авазы *ө* гә күчәргә мөмкин. Татар телендә бу модель буенча, теоретик яктан, һәр конкрет исемнән кабатлаулы куш сүз ясарга мөмкин: *дәфтәр-мәфтәр, өстәл-мөстәл, идән-мидән, тәмәке-мәмәке* һ.б. Ләкин аларның күпчелеге ясалма буларак индивидуаль сүз ясау нәтиҗәсендә барлыкка киләләр һәм тел күренеше югарылыгына күтәрелә алмыйлар, сүз уйнату өчен яхшы чара булып торалар.

Кабатлаулы куш сүзләр яңа семантикалы яңа лексик берәмлек тәшкил итмиләр. Биредә, стилистик кушымча кушылгандагы кебек, стилистик мәгънә барлыкка килә: *кыз – кыз+чык, малай – малай+чык.*

Стилистик кушымчаларның мәгънәләреннән (кимсетү, кечерәйтү) аермалы буларак, кабатлаулы куш сүзләрдә җыймалык, билгесезлек, күплек кебек грамматик мәгънәләр күзәтелә.

**Фигыль+фигыль тибы.**

Исем фигыль$_1$ + исем фигыль$_2$ моделе*: уру-сугу, уку-укыту, кату-чәнчү, киенү-ясану, язу-сызу* һ.б. Китерелгән куш сүзләр, фигыль формасында булсалар да, фигыль кебек төрләнмиләр, шуңа күрә алар куш исемнәр булып торалар.

Исем фигыль$_1$ + исем фигыль$_2$ моделе фигыль формасында да булырга мөмкиннәр, ул вакытта алар фигыль кебек төрләнәләр: *ялыну-ялвару* (ялындык, ялвардык), *уйнау-көлү* (уйнадык, көлдек), *ару-талу* (ардык, талдык), *этү-төртү* (этте, төртте). Бу модельгә караган кайбер куш сүзләр исем булып та, фигыль булып та килергә мөмкиннәр: *ару-талу* (ару-талусыз) – исем, *ардык-талдык* – фигыль, *ашау-эчү* (ашау-эчүдә) – исем, *ашадык-эчтек* – фигыль.

Боерык фигыль$_1$ + боерык фигыль$_2$ моделе*: әйлән-бәйлән, кап-йот, ал-йот.*

Боерык фигыль$_1$ + боерык фигыль$_2$ моделе: *кач-кач.*

Үткән катгый замандагы фигыль$_1$ + үткән катгый замандагы фигыль$_2$ моделе: *алдым-бирдем.*

*-алак* кушымчасына тәмамланган исем + *-алак* кушымчасына тәмамланган исем$_2$ моделе: *ачалак-йомалак.* Китерелгән куш исемнең компонентлары хәзерге татар телендә мөстәкыйль кулланылмыйлар. Алар телнең үткән чорына карыйлар булса кирәк, бәлки алар анда сыйфат булганнардыр.

**Хәбәрлек сүз + хәбәрлек сүз тибы.**

Хәбәрлек сүз$_1$ + хәбәрлек сүз$_2$ моделе: *юк-бар.*

Башка куш сүзләрдәге компонентларның урыннарын алмаштырып булмаган кебек, бу куш исемнең компонентлары урынын алмаштырып булмый.

*-ы* кушымчасына тәмамланган хәбәрлек сүз + *-ы* кушымчасына тәмамланган хәбәрлек сүз$_2$ моделе: *бары-югы.*

**Ияртем$_1$+ияртем$_2$ тибы.** Мисаллар: *гөр-гөр, һөд-һөд.*

Татар телендә компонентларга морфологик интерпретация бирү кыен булган куш исемнәр дә бар: *кирәк-ярак, якын-тирә.*

*Кирәк-ярак* дигән сүзнең икенче компоненты *яраклы, яраксыз* дигән кушымчалы сыйфатлар составында очрый. *Ярак* сүзе *яра* фигыленә *-к* кушымчасы ялгану юлы белән ясалган: *яра+к.*

Татар теленең үсеш тарихында ул мөстәкыйль исем булган күрәсең, хәзер инде ул аерым кулланылмый. Бу куш сүзнең беренче компоненты булган *кирәк* сүзен предикатив сүз яки сыйфат дип карап булмый, чөнки ул вакытта компонентлар арасында атрибутив бәйләнеш (сыйф.+ис. яки хәбәрлек сүз+ис.) барлыкка килер иде. Бу очракта бу тезмә йә ирекле сүзтезмә, йә компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сүз булыр иде. Куш сүзнең беренче компоненты *кирәк* исемләшкән сүз булып тора. Димәк, *кирәк-ярак* дигән куш сүз *исем+ исем* моделендә ясалган булып чыга.

*Якын-тирә* дигән куш сүзнең беренче компонентын сыйфат дип карасак, ул вакытта куш сүз таркала, *якын тирә* (якын урын) дигән ирекле сүзтезмә барлыкка килә. Бу комбинациягә анализ ясаганда, аның бер мәгънә белдерүе, хәтта күчмә семантикага да ия булуы

күренә. Шуңа күрә бу комбинацияне ирекле сүзтезмә дип карап булмый. Моннан *якын* компонентының мөстәкыйль сыйфат түгел, ә исемгә әверелгән сыйфат икәне күренә. Димәк, *якын-тирә* дигән куш сүз исем+исем моделе нигезендә ясалган булып чыга.

Еш кына компонентлары атрибутив бәйләнештәге кушма сүзләрне куш сүзләр рәтенә кертеп карыйлар. Аларның күпчелеге компонентлары рус телендә дефис аша язылган, аннан алынган, калька яки ярымкалька булып торалар.

Мәсәлән, *мамык йон* комбинациясендә *мамык* сүзе аергыч булып килә, ә аергыч белән аерылмыш арасында сызыкча куелмый. Шундый ук *йомшак йон, ясалма йон* кебек тезмәләрдә дә аергычтан соң сызыкча куелмый.

*Ут койрык* кебек кушма сүздә *ут* сүзе шулай ук аергыч ролен башкара.

*Шеф повар* (рус телендә шеф-повар) тезмәсендә *шеф* сүзе татар телендә шулай ук аергычка әйләнә, ул *нинди повар* дигән сорауга җавап бирә.

*Баш повар, җитәкче повар* дип тә әйтергә мөмкин, бу тезмәләрнең компонентлары арасында сызыкча куелмый, чөнки бу тезмәләрдә беренче компонентлар аергыч булып килә.

*Икс нурлар* дигән тезмәдә *икс* сүзе шулай ук атрибутив булып килә, шуңа күрә рус телендә бу тезмәнең компонентлары арасында сызыкча куелса да, татар теле закончалыклары моңа каршы килә.

*Геркулес коңгыз* (рус телендә *геркулес-жук*) татар телендә *геркулес* сүзе атрибутив ролен уйный, шуңа күрә рус телендәге сызыкчаны татар теленә күчерү дөрес түгел[1].

### *Куш сүзләрнең семантикасы*

**Куш сүзләрнең барлыкка килү сәбәпләре.** Төрки телләрдә куш сүзләрнең барлыкка килүенең беренче һәм төп сәбәбе булып кардәш кабиләләрнең һәм халыкларның кушылуы тора. Т.А.Дегтярева болай дип яза: «Куш сүзләр кабиләара контактлар чорындатөрле кардәш телләрнең вәкилләренә төрле кабилә, ә кайчакта төрле тел лексикасын әйткән нәрсәне аңлату йөзеннән барлыкка килә»[2].

---

[1] Мисаллар 1996 елда Мәскәүдә чыккан «Татарча-русча сүзлек»тән алынды.

[2] Дегтярева Т.А. Пути развития современной лексики. М., 1964. С. 136.

Бу хәл төрки телләр материалы белән дә раслана. Мәсәлән, *савыт-саба, ир-ат, бала-чага, мал-туар, иген-тару, азык-төлек, исе-коңгысы* кебек куш сүзләрдә ике компонент та аерым хәлдә дә, нигездә, бер үк төшенчәне белдерәләр. Әмма аларның беренче компонентлары татар әдәби телендә генә кулланылалар, икенче компонентлары исә татар әдәби телендә юклар. Аларның кайберләре бары аерым диалектларда гына очрый. Ә *ат, туар, төлек* сүзләре казакъ, уйгур, кыргыз, балкар һ.б. телләрдә очрый. Шулай итеп, төрки телләрнең тел материаллары төрки халыкларның һәм кабиләләрнең бик интенсив кушылуын, мөнәсәбәтен раслый.

Моннан шундый нәтиҗәдә ясарга мөмкин: төрле диалектларда (кабиләләрдә) булган бер мәгънәдәге ике сүзне шул диалектлардагы (кабиләләрдәге) кешеләргә аңлашылсын өчен кушканнар. Моңа тигезләнеп, хәзерге көндә ике компонентының да лексик эчтәлеге ачык булмаган куш сүзләрнең этимологик мәгънәләрен ачыкларга мөмкинлек туа. Мәсәлән, ике компоненты да билгеле булмаган куш сүзләрнең, башка сүзләр белән чагыштырып, юк дигәндә, бер компонентының этимологиясен аңлатырга мөмкин: *ыбыр-чыбыр* (кыргызча *ыбыр+сы* ‘кече булу’), *ыгы-зыгы* (*ыгы+ш* – диалекталь сүз), *әвеш-түеш* (*әве+р – әйләндерү*), *алам-салам* (*алама – начар*), *ырык-шырык* (*ыры+п-еры+п*), *урык-сурык* (*урын+тын*).

Моннан татар телендә асемантик (мәгънәсез) куш сүзләрнең булмавы ачык күренә, компонентларның берсенең булса да мәгънәсе бар булып чыга.

Икенчедән, куш сүзләрнең бер өлеше күплекне, җыймалыкны белдерү өчен ясалганнар.

Моның өчен синоним яки мәгънәләре якын булган сүзләр кулланыла: *дус-иш, мәкер-хәйлә, кардәш-ыру, туган-тумача.* Шул максаттан чыгып нигезләр кушылып куш аваз һәм образ ияртемнәре ясала. Мәгълүм булганча, безне әйләндереп алган мохитта аваз (тавыш) бер мәртәбә яки күп мәртәбәләр яңгырарга мөмкин. Авазның бер мәртәбә яңгыравы тамыр (гади) аваз ияртемнәре белән белдерелә: *шап, дөберт, гөрс, шарт* һ.б. Авазларның кабат, күп мәртәбәләр яңгыравын белдерү өчен тамыр (гади) аваз ияртемнәренең редупликациясе (кабатлануы) файдаланыла: *шык-шык, кыйгак-кыйгак, бак-бак, шыгыр-шыгыр.* Аерым очракларда куш сүзләр өч компоненттан торырга

мөмкин: *бак-бак-бак, шык-шык-шык.* Бу очракта өч компонентлы аваз ияртеме шундый сүзләрдән гыйбарәт ике компонентлы аваз ияртеменнән үзенең экспрессивлыгы, күп мәртәбәләр кабатлануны белдерүе белән аерылып тора. Димәк, өч компонентлы аваз ияртемеизоморфлы ике компонентлы аваз ияртеменнән бары экспрессивлыгы белән генә аерылып тора. Шуңа күрә өч компонентлы аваз ияртемнәре, кагыйдә буларак, ике компонентлы аваз ияртемнәре белән чагыштырганда, яңа лексик берәмлек итеп каралмый.

Өченчедән, куш сүзләр экспрессив мәгънәләрне белдерү, эмоциональ бизәк бирү һәм беркадәр кире мәгънә белдерү өчен хасил булганнар һәм кулланылалар. Бу очракта икенче компонент булып фонетик яктан беркадәр үзгәргән беренче компонент кулланыла. Бу вакытта куш сүз җыймалыкны һәм беркадәр билгесезлекне белдерә. Икенче компонент чынбарлыкта телдә очрамый, ул лексик мәгънәсе булмаган беренче компонентның аналогын тәшкил итә: *карт-коры, чокыр-чакыр, карчык-корчык.* Бу куш сүзләр күплектәге *картлар, чокырлар, карчыклар* сүзләреннән эмоциональ төсмерләр белән аерылып торалар.

Күплекне белдерү өчен икенче компоненты беренче компонентка якын булган аваз ияртемнәре дә ясала: *шарт-шорт, лач-лоч, чаптыр-чоптыр, шап-шоп, шак-шок.* Бу төр куш сүзләрнең икенче компонентлары лексик мәгънә белдермиләр, телдә аерым-аерым кулланылмыйлар, алар бары китерелгән куш сүзләрдә генә очрыйлар. Беренче компонентлары исә лексик мәгънәгә ияләр һәм телдә мөстәкыйль кулланылалар. Бу куш сүзләрнең семантикасына анализ ясаганда, аларның икенче компонентлары, кабатлануны, һәм күплекне белдерү белән беррәттән, экспрессив мәгънәгә дә ия булып торалар, беркадәр хупламау төсмере дә күренә (*карчык-корчык*).

Дүртенчедән, куш сүзләр җыйма, гомумиләштергән һәм абстракт мәгънәләр белдерү өчен ясалалар. Бу максат өчен мәгънәләре белән сүз ара якын мөнәсәбәттә булган сүзләр файдаланыла: *уку-укыту, баш-тояк, сөт-катык, күлмәк-ыштан, күз-колак, уен-көлке* һ.б. Бу мисаллар күрсәткәнчә, компонентлар тезүле бәйләнеш нигезендә кушылганда гомуми һәм җыйма мәгънәле сүзләр ясала.

**Куш сүзләр компонентларының лексик-семантик үзенчәлекләре.** Югарыда сөйләгәннәрдән куш сүзләрнең компонентлары

төрле семантик үзенчәлекләргә ия булуы күренә. Куш сүзләрнең семантик үзенчәлекләренә карап түбәндеге төркемнәрен билгеләргә мөмкин.

Беренчедән, куш сүзләрнең компонентларының икесе дә хәзерге телдә мөстәкыйль яшиләр һәм реаль мәгънә белдерәләр: *көн-төн, ата-ана, алыш-биреш, алдым-бирдем, урман-дала.*

Икенчедән, куш сүзнең беренче компоненты хәзерге телдә мөстәкыйль яши һәм аның реаль мәгънәсе бар, ә икенче компоненты бары диалектларда, кардәш телләрдә очрый яки алар телнең борынгы хәлендә булганнар.

Өченчедән, куш сүзнең беренче компоненты телдә мөстәкыйль кулланыла һәм аның лексик мәгънәсе бар, ә икенче компоненты беренче компонентның реаль мәгънәсе булмаган үзгәргән фонетик варианты, асемантик аналогы булып тора: *ярык-йорык, ялгыш-йолгыш, алдау-йолдау, имеш-мимеш, эңгер-меңгер* (*Салмак кына җәелә кичке эңгер.* Ш. Маннур), *малай-шалай.*

Дүртенчедән, куш сүзнең беренче компоненты да, икенче компоненты да телдә мөстәкыйль яшәми, ләкин аларның берсен яки икесен дә этимологик яктан диалектлар яки кардәш телләр материалы белән аңлатырга мөмкин: *ыбыр-чыбыр, ыгы-зыгы.* Югарыда китерелгән мисаллардан аңлашылганча, гәрчә ике компонент та хәзерге көн күзлегеннән караганда ачык булмаса да, ахыр чиктә ул компонентларның берсенең этимологиясен диалектлардан яки кардәш телләрдән чыгып билгеләргә мөмкин. Аларда бары икенче компонент кына мәгънәсе булмаган бердәй диярлек яңгырашлы сүз булырга мөмкин.

Куш сүзләргә караган татар теле материалы Н.К. Дмитриевның кайбер куш сүзләрнең «ике элементының мәгънәсе юк» дигән фикерен расламый. Галим тарафыннан китерелгән мисалларга анализ ясау компонентларның берсенең лексик мәгънәсе булганлыгын һәм булуын күрсәтә: *элә-сала* (чагыштыр: *колагына да элми, күз elenү*), *ыбыр-чыбыр* (кыргыз телендәге *ыбыр+сы* ‘кечкенә булу’), *ялбыр-йолбыр* (*ялбыр* компоненты *ялбырда* фигылендә очрый), *әпен-төпен* (*әп* – бик тиз дигән мәгънәне белдерә).

**Компонентларның лексик-семантик яктан үзара бәйләнеше.** Куш сүзләрне тагын компонентларның лексик-семантик үзара бәйләнешеннән чыгып классификацияләргә мөмкин. Татар теле материалы

семантик бәйләнеш ягыннан куш сүзләрнең түбәндәге төркемнәрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

1. Куш сүзләрнең компонентлары этимологик яктан яки хәзерге телдә синонимнар булып торалар, ягъни алар арасында синонимик мөнәсәбәт күзәтелә: *тирә-як, кагу-сугу, буй-сын, моң-зар, көч-куәт, рәхим-шәфкать, талаш-ызгыш, кайгы-хәсрәт, гореф-гадәт, таныш-белеш, бала-чага, мал-туар.*

2. Куш сүзләрнең компонентлары үзара антоним булып торалар, ягъни үзара антонимик мөнәсәбәттә булалар: *алыш-биреш, керем-чыгым, юк-бар, көн-төн, ачлы-туклы.*

3. Куш сүзләрнең компонентлары бер-беренә өлеш бөтенгә караган кебек карыйлар: *тау-таш, бәла-каза, җил-давыл.*

4. Куш сүзләрнең компонентлары бер төр күренешләргә һәм предметларга караган, бер-беренә якын булган төшенчәләрне белдерә: *сөт-катык, хатын-кыз, ата-ана, агый-эне, өс-баш, баш-тояк, кату-чәнчү, ир-егет.*

5. Куш сүзләрнең компонентлары бер-беренә карата берлектә һәм күплектә киләләр: *фәкыйрь-фөкара, галим-голама, гарип-гораба, вәзир-вөзара, хәл-әхвәл.* Анализ беренче компонентның берлектә, икенче компонентның күплектә килүен күрсәтә. Бу мисалларда беренче һәм икенче компонент та гарәп-фарсы сүзләрен тәшкил итәләр. Шуңа карамастан бу сүзләрне татар теленең сүзьясалыш нәтиҗәсе дип карарга туры килә, чөнки компонентларның кушылуы чыганак телдә түгел, татар телендә барлыкка килгән.

6. Куш сүзләрнең компонентлары ир һәм хатын-кыз җенесен белдерәләр, бер үк сүз ике җенестә килә: *ятим-ятимә, мөгаллим-мөгаллимә, талиб-талибә.* Бу төр куш сүзләрнең компонентлары булып гарәп һәм фарсы сүзләре килә.

7. Куш сүзләрнең компонентларының лексик мәгънәләре тулысынча тәңгәл киләләр, ягъни куш сүз бер үк сүзнең кабатлануы белән ясала: *һөд-һөд, чәбәк-чәбәк, качыш-качыш.*

Куш сүзләрнең бу төренә бер үк гади нигезне кабатлап ясалган ияртемнәр дә керә: *чи-чи, чут-чут, мырк-мырк, гөрр-гөрр, келт-келт, бүлт-бүлт, елт-елт* һ.б.

8. Куш сүзләрнең беренче компоненты реаль мәгънәгә ия булып, икенче компоненты телдә мөстәкыйль кулланылмыйча, куш сүзгә

җыймалык, күплек төсмерен генә өсти: *черек-чарык, малай-шалай, хәбәр-хәтер, карчык-корчык.* Бу куш сүзләрнең икенче компонентлары телдә аерым кулланылмасалар да һәм реаль лексик мәгънәләре булмаса да, куш сүз составында хупламау төсмере яисә җыймалык, күплек кебек грамматик мәгънә алалар.

9. Куш сүзнең икенче компоненты куш сүзгә бернинди лексик мәгънә өстәми, куш сүзгә бары гомуми билгесезлек төсмере бирә: *әйбер-мазар, гөнаһ-мазар, кеше-фәлән* һ.б. Әйтергә кирәк, мондый куш сүзләрнең икенче компонентлары булып бик чикләнгән сүзләр генә килә: *фәлән, мазар, кара, ни, нитү.*

*Фәлән* сүзе телдә *кемдер, нәрсәдер, нинди дә булса* мәгънәсендә кулланыла. Теоретик яктан караганда бу сүз барлык диярлек исемнәр белән килә ала. Ул конкрет исемнәр белән дә, абстракт исемнәр белән дә кулланыла: *кеше-фәлән, егет-фәлән, гөнаһ-фәлән, акыл-фәлән, зыян-фәлән.*

*Мазар* сүзе хәзер телдә мөстәкыйль кулланылмый, аның куш сүзләр составында кулланылуы чикләнгән. Кешене яки хайванны белдергән һәм абстракт исемнәргә ялгана: *кеше-мазар, эт-мазар, ат-мазар, бүре-мазар, гөнаһ-мазар* һ.б.

*Кара* сүзе куш сүзләрдә бик чикләнгән санда кулланыла: *кеше-кара, әйбер-кара, күрше-кара.*

*Ни* алмашлыгы куш сүзләр составында, кагыйдә буларак, берәр *кемдер,* берәр *нәрсәдер* мәгънәсендә билгесезлекне, билгесез кешене яки хайванны белдерү өчен кулланыла: *кеше-ни, кәҗә-ни, сыер-ни.*

*Мазар* сүзе гарәп телендә «кабер, зират» мәгънәсен, чуваш телендә – «үлгән кешенең әйберләрен ташлый торган урын», мари телендә – «һәртөрле нәрсә» мәгънәсен белдерә. Татар телендә куш сүздә *мазар* компоненты билгесез кеше яки нәрсә мәгънәсендә кулланыла һәм аның мари теле белән турыдан-туры бәйләнеше дә бар кебек.

*Кара* компоненты *кеше-кара* дигән куш сүздә *кара+мык, кара+чкы* кебек сүз белән бәйләнгән булса кирәк, чөнки *кара* сүзе куш сүзгә түбән стиль, бик хуплап җиткермәү төсмере бирә.

**Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсенең барлыкка килүе.** Куш сүзләрнең гомуми мәгънәләренең барлыкка килүе шактый кызыклы күренеш булып тора. Бу яктан аларны түбәндәге төркемнәргә бүлергә мөмкин.

1. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе аларны хасил итүче компонентлар мәгънәләренең суммасына тигез: *ата-ана, керем-чыгым, олысы-кечесе, ятим-ятимә, көн-төн, алыш-биреш.* Мондый куш сүзләрнең бер өлешенең мәгънәләре беркадәр метафорик мәгънә кичергән: *алдым-бирдем.*

2. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе аларны хасил итүче компонентлар мәгънәләренең суммасыннан артыграк булырга, куш сүз белдергән төшенчәгә компонентлар белдермәгән элементлар да керергә, ул гомумирәк мәгънә белдерергә мөмкин: *эчәк-бавыр, баш-тояк, күлмәк-ыштан, аш-су, сөт-катык, тау-таш, елан-чаян.*

3. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе аларны хасил итүче компонентларның мәгънәләре суммасын тәшкил итә, әмма аңа күплек мәгънәсе өстәлә: *дус-иш, таныш-белеш, явым-төшем, чәбәк-чәбәк, дөң-дөң, бак-бак, чең-чең.*

4. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе аларны хасил итүче компонентлар мәгънәләренең суммасына тигез, әмма төшенчәнең экспрессив мәгънәсе көчәя: *асу-кисү, җәбер-золым, ару-талу, бәла-каза, кату-чәнчү.*

5. Куш сүзләрнең мәгънәсе беренче компонент мәгънәсенә тигез, әмма төшенчәгә кимсетү яки хупламау төсмере өстәлә: *бүләк-санак, тиле-миле, ботак-чатак, артык-портык, агач-богач.*

6. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе беренче компонент мәгънәсенә тигез, әмма икенче компонент төшенчәгә җыймалык, күплек төсмерен өсти: *вак-төяк, чыбык-чабык, чокыр-чакыр.*

7. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе беренче компонентның мәгънәсенә тигез, әмма икенче компонент төшенчәгә күплек, җыймалык мәгънәсе белән беррәттән хупламау төсмере дә өсти: *имеш-мимеш, иске-москы, шәкерт-шөкерт, әби-чәби, ырым-шырым.*

8. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе беренче һәм икенче компонентларының уртасында торган мәгънәгә тигез: *төньяк-көнбатыш, урман-дала, урман-тундра, сарык-үгез, кысла-чаян, маймыл-кеше.* Мисаллардан күренгәнчә, куш сүзләрнең семантикасы ике компонент белдергән төшенчәләрнең уртак билгесен тәгъбир итә.

9. Куш сүзләрнең гомуми мәгънәсе беренче компонент мәгънәсенә тигез булып, ул мәгънәгә икенче компонент белдергән билгесезлек төсмере өстәлә: *кеше-мазар, эт-мазар, күрше-фәлән, эт-ни, йорт-ни.*

Кайбер куш сүзләрнең мәгънәсе үзләрен хасил итүче компонентларның мәгънәсе белән турыдан-туры бәйләнеше булмыйча, метафорик үзенчәлек алганнар: *һөд-һөд* (кош), *кач-кач* (уен), *юк-бар, усал-унтагай.*

## Ияртүле бәйләнештә булган компонентлар кушылып кушма исемнәр ясалуы

### *Атрибутив бәйләнештә булган компонентлар кушылып кушма исемнәр барлыкка килү*

Хәзерге татар телендә атрибутив бәйләнештәге компонентлар кушылып шактый күләмдә кушма исемнәр ясала. Сүзләр кушылуның бу тибында беренче компоненты икенче компонентның атрибуты (аергычы) булып килә. Югарыда әйтелгәнчә, кушма сүзләрнең компонентлары арасында «тере» атрибутив бәйләнеш турында бары шартлы рәвештә генә, композит элементларының атрибутив сүзтезмәләрдәге бәйләнешләргә шартлы туры килүе турында гына сүз барырга мөмкин.

Тюркологиядә моңа кадәр кушма сүзләр компонентлары бәйләнешләреннән чыгып өйрәнелмәде.

Компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләрнең беренче компоненты булып барлык мөстәкыйль сүз төркемнәренең сүзләре килергә мөмкин: *сабантуй, үзидарә, мыраубикә, җитенчәчәк, янбаш.*

Атрибутив бәйләнештәге кушма сүзләрнең компонентларының лексик-грамматик яктан татар телендә түбәндәге типлары бар.

**Исем + исем тибы.** Татар телендә компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләр шактый күп: *атнакөн, тузбашъелан* һ.б.

Бу тип кушма сүзләрнең беренче компонентлары түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1) материалны: *ташъязма, ташаяк, тимерташ, ташбака, тиреканат, ташкүмер, корычагач.* Бу сүзләрдә *материал* сүзе шартлы рәвештә генә кулланыла, ул чын материалны түгел, күп очракта «уйланма» материалны белдерә;

2) форманы яки охшашлыгы буенча форманы: *уймакчәчәк, чукмарбаш, айбалта, кәҗәсакал, каешъяфрак, алкагөл, аюколак, яфракканат, тукранбаш, тырнакгөл, кылычбалык, казаяк, чүкечбалык, укъ-*

*яфрак, сарыкташ, мөгезборын* һ.б. Китерелгән мисалларда беренче компонент, күренгәнчә, икенче компонентның формасын белдерә. Форма төшенчәсе астында биредә, кагыйдә буларак, уйланыла торган, күзаллана торган форма тәгъбир ителә;

3) төсне: *җизмыек, җизьелан, тузбаш, бакыръелан, алтын чәчәк* һ.б. Биредә кушма сүзләрнең беренче компонентлары предметны белдермиләр, предмет исеме белән төсне тәгъбир итәләр;

4) функциясен, нәрсә өчен билгеләнүен: *ашъяулык, кулъяулык, килесап, балавыз, кулбау, билбау, кашбау, фотокәгазь, радиоҗиһаз, табагач, балаяк, кәрвансарай.* Бу куш сүзләрнең беренче компонентлары аларның нәрсә өчен билгеләнүен аңлата;

5) икенче компонентның характерын, сыйфатын: *башкода, башкала, фоторәсем, хәтфәгөл, радиосәгать, радиоэлемтә, майбалык, көньяк, җилембалык, күбекташ, корымбаш* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, беренче компонентларның мәгънәләре күпчелек очракта күчмә, метафорик характерда киләләр (*хәтфәгөл, утчәчәк, җилембалык);*

6) урынны: *таусагыз, суүсем, күлбуга, янкорма, чынаяк* (*чин аяк*), *алкушымча, алтөрән*. Биредә беренче компонентлар әйбернең беренче башлап ясалган урынын (*чынаяк*), биләгән урынын (*алкушымча, алтөрән*) аңлата;

7) коралны, берәр әйбер ярдәмендә ясалган башка әйберне: *кулъязма, ташбасма, култамга;*

8) эш-хәрәкәт субъектын: *көнчыгыш, көнбатыш.* Биредә *көн* сүзе үзенең борынгы мәгънәсендә, *кояш* мәгънәсендә кулланылган;

9) нәрсәгә каравын: *радиодулкын, йөззурлык.*

Мисаллардан күренгәнчә, татар исемнәре борынгыдан ук, беренче кушма сүзләр ясалган вакытта ук, атрибутив функциясендә, ягъни сыйфат функциясендә кулланылганнар.

Кушма сүзләрнең бу тибында үзара тоташкан компонентлар да очрарга мөмкин. Бу бигрәк тә ике компонент та татар теленеке булганда шулай килеп чыга: *каенсеңел, каената, каенэне, каенана* һ.б. Мондый компонентлар калькаларда да күзәтелергә мөмкин, аларның бер компоненты интернациональ сүз була: *агрочара, агроуку, вибротегермән, аэрочана, ортосу, авточана, автохуҗалык, авиамәктәп, автосабан, электромич, комбиазык, виброиләк, микроашлама,*

*нитрокушылма* һ.б. Барлык бу кушма сүзләр фәнни-техник терминология тәшкил итәләр, аларның беренче компонентлары телдә аерым кулланылмыйлар, алар татар телендә рус телендәге кушма сүзләрне калькалау нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Барлык төрки телләрдәге кебек, татар телендә дә җенес категориясе юк. Әммә бу хәл татар теле җанлы затларның җенесен белдерә алмый дигән сүз түгел. Җенес билгеләрен белдерүнең татар телендә түбәндәге төрләре бар: 1) иркәкләр һәм тешеләр дә рус телендәге кебек бер сүз белән белдерелә: *чебен, алабуга, тиен, саескан, сандугач;* 2) алар ике төрле исем белән йөртелә: *бия – айгыр, сыер – үгез;* 3) аерым сүзләр белән белдерелә: *ана, ата, тәкә, теше* (*ата эт – ана эт, ата каз – ана каз, ата бүре – ана бүре, ата арыслан – ана арыслан, үгез бозау – теше бозау, кәҗә тәкәсе*) һ.б.

Күренгәнчә, мондый сүзләрнең өченче төре – *ата* (*ана*) + тереклек иясенең исеме моделе компонентлары атрибутив мөнәсәбәттә булган кушма исем тәшкил итә. Бу төр кушма исемнәрдә *ата* (*ана*) компоненты атрибут функциясендә килә. Китерелгән кушма исемнәр бер басымлы булып бер мәгънә белдерәләр, ягъни аларда кушма сүзләрнең барлык билгеләре бар.

**Исем$_1$ + тартымлы исем$_2$ тибы.** Мәгълүм булганча, төрки телләрдә бу тезмә изафәнең икенче формасын тәшкил итә һәм ул иркле сүзтезмә булып тора. Сүзтезмәдә бәйләүче чара – тартым кушымчасы *-ы* һәм сүз тәртибе. Бу тип сүзтезмәләргә кергән сүзләр арасында атрибутив бәйләнеш була, ягъни комбинациядәге беренче сүз икенче сүзнең ачыклагычы булып тора, ул икенче сүзнең мәгънәсен конкретлаштыра, ачыклый.

Югарыда әйтелгәнчә, төрки телләрдә кушма сүзләр өч төрле алым белән ясала:

1) сүзләр кушылу, бу исә синтаксик тезмәләр ясалуның кагыйдәләре һәм закончалыклары нигезендә бара; 2) сүзтезмәнең кушма сүзгә әйләнүе; 3) сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе. Моннан шундый нәтиҗә килеп чыга: сүзтезмәдәге төп лексик-грамматик мөнәсәбәтләр, теге яки бу формада, кушма сүзләрдә чагыла.

Сүзтезмәләрнең кушма сүзләргә күчүенә мисаллар: *эт эчәге, каз аягы, бүре тырнагы, песи тырнагы, сыер теле, елан теле, тычкан койрыгы.* Болар барысы да, кушма сүзләр буларак, үсемлек атамала-

рын белдерәләр, сүзтезмәләр буларак, ике сүзе дә мөстәкыйль мәгънәле синтаксик төркем (комбинация) тәшкил итәләр. Боларны ике сүз кушылу нигезендә кушма сүзләр ясалган дип карап булмый, чөнки телдә нәкъ шундый сүзтезмәләр бар.

Телдә шундый ук типтагы, әмма инде беренче мәртәбә барлыкка килгәндә үк ике сүз кушылуыннан ясалган кушма исемнәр дә бар, аларның телдә аерым синтаксик тезмәләре юк, алар кушма сүз буларак кына телдә яшиләр: *эт балыгы, зәйтүн гөле.*

*Агач, җиләк, гөл, гөмбә, чикләвек, ут* (*үлән*), *үлән, балык* һ.б. сүзләр, икенче компонент буларак килеп, кушма сүзләр ясыйлар, алар төр төшенчәсенә карата ыруглык төшенчәсе мөнәсәбәтендә торалар.

*Агач* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *имән агачы, усак агачы, алма агачы* һ.б. алар бер сүз белән белдерелергә мөмкиннәр: *имән, усак* һ.б.

*Чыпчык* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *миләш чыпчыгы, камыш чыпчыгы, кычыткан чыпчыгы.*

*Гөмбә* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *усак гөмбәсе, имән гөмбәсе, нарат гөмбәсе, ку гөмбәсе, чебен гөмбәсе, каен гөмбәсе, кәҗә гөмбәсе, әтәч гөмбәсе.*

*Чикләвек* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *имән чикләвеге, җир чикләвеге, мөшкәт чикләвеге, пестә чикләвеге.*

*Чәчәк* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *пәйгамбәр чәчәге, роза чәчәге, канәфер чәчәге, давыл чәчәге, умырзая чәчәге.*

*Ут* (үлән) сүзе белән килгән кушма исемнәр: *хисамә уты, бүре уты, турак уты, күз уты, саз күзлуты.*

*Үлән* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *очкылык үләне, күз үләне, елан үләне, тутык үләне, кенәр үләне, ут үләне, чүп үләне.*

*Җиләк* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *мүк җиләге, нарат җиләге, каен җиләге, кура җиләге.*

*Бала* сүзе белән килгән кушма исемнәр: *эт баласы, мәче баласы, бүре баласы, аю баласы* һ.б.

Татар телендә мондый типтагы башка кушма сүзләр дә бар. Алар үсемлекләрне, бөҗәкләрне, хайваннарны, төрле әйберләрне белдерәләр. Бу тип кушма сүзләрнең беренче компонентлары түбәндәгеләрне тәгъбир итәләр:

1) бөтеннең өлешен: *тузан бөртеге, йон бөртеге, чәй бөртеге, чәчәк төбе, күз кабагы, күз карасы, күз чокыры;*

2) урынны: *саз чиясе* (диал.), *йорт иясе, амбар иясе, урман иясе, урман тавыгы, урман какысы, бохар кынасы, кәгъбә бодае, урман өреге, су сыеры, азов чабагы, су үгезе, кыр тычканы, кыр тавыгы, урман сыеры, чүл бүресе, диңгез мәчесе, тау чыпчыгы, тау кәҗәсе, саз карчыгасы, диңгез акчарлагы, су эте, юл чаты;*

3) ыруглык төшенчәсенә карата төр төшенчәсен: *хокук белеме, әдәбият белеме, туфрак белеме, тел белеме, чикләвек чыпчыгы, чыршы бәйрәме, тары чыпчыгы, киндер чыпчыгы, чамбыр үләне;*

4) мөнәсәбәтне: *алма печәне, бака яфрагы, бака ефәге, эт какысы, эт тигәнәге, торна борчагы, тычкан борчагы, мәче борчагы;*

5) яшәү (тору) яки эш-хәрәкәт урынын: *бөре корты, иген коңгызы, орлык күбәләге, агач күбәләге, балавыз көясе, гәрәнкә күбәләге, алма күбәләге, кәбестә күбәләге, җитен борчасы, агач корты;*

6) материалны: *чәч толымы, черек оны, чәчәк бәйләме, чуен юлы, боз сөңгесе, балык шулпасы* (материал сүзен биредә чын материал дип аңларга кирәк түгел);

7) әйбернең нәрсә өчен билгеләнүен: *яра үләне, кунак өе, эт абзары, ук кынысы, аркау җебе, чабыш аты, бүре уты, яра ташы, ут ташы, бал корты, дары савыты;*

8) вакытны: *төн күбәләге, төн карчыгасы, яз гөле, ай башы, печән өсте, урак өсте;*

9) коралны, эш-хәрәкәт әйберен: *пычкы чүбе;*

10) эш-хәрәкәтне башкаручыны, субъектны: *йөрәк тибеше, тамыр тибеше, кояш батышы;*

11) билгене, үзенчәлекне: *кәлтә еланы, күбек ташы, тамыр билгесе;*

12) профессия предметын: *балта остасы;*

13) милләтне: *татар какысы, кытай карасы, һинд сүсе.*

Кушма сүзләрнең компонентлары арасындагы бәйләнешләр турында сөйләгәндә, сүз бүгенге көн күзлегеннән булган табигыйлогик бәйләнешләр турында түгел, ә аларның кушма сүзләр барлыкка килгән вакыттагы эчке мотивлашуы турында бара. Шуңа күрә биредә тикшерелә торган кушма сүзләрнең күбесенең семантикасы бүгенге көндә метафорик характерда гына: *давыл хәбәрчесе, эт ти-*

*гәнәге, эт какысы, елан көпшәсе, чыпчык җилеме, бака яфрагы, елан тамыры.*

**Сыйфат + исем тибы.** Бу типтагы кушма сүзләр татар телендә күп түгел. Мондый төзелештәге кушма сүзләр нигезләр кушылу юлы белән түгел, ә ирекле сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүеюлы белән барлыкка килгәннәр. Шунлыктан компонентлары атрибутив бәйләнештәге кушма сүзләрнең ясалыш алымын билгеләү шактый кыен һәм катлаулы эш булып тора, ягъни сүзтезмә кушма сүзгә әйләнгәнме, яисә ул ике нигезнең кушылуыннан барлыкка килгәнме?

Компонентлары атрибутив бәйләнештәге түбәндәге кушма сүзләр ике яки өч нигез кушылу юлы белән ясалганнар: *ачуташ, терекөмеш, күксагыз, кызылмал, кызылъюл, чынбарлык, сарысукош, тилеакбаш, акзелпе, каразелпе.* Күренгәнчә, бу кушма сүзләрнең телдә аларга тәңгәл мөстәкыйль, ирекле сүзтезмәләре юк, шуңа күрә аларны сүзтезмәләреннән барлыкка килгән дип санап булмый.

Компонентлары артибутив мөнәсәбәттә булган кушма сүзләрнең беренче компонентлары булып тамыр сүзләр генә түгел, кушымчалы ясалма сыйфатлар да килергә мөмкин: *ислегөл, саплаяк, төклетура, тәмлетамак, комлытуфрак, күзлут, үрмәлегөл, сөтлегөл, сиртмәкойрык, чакматаш, кисекбаш* һ.б.

**Алмашлык + исем тибы.** Бу тип кушма сүзләр телдә аз очрый. Аларның күпчелеге рус телендәге кушма сүзләрне калькалау нәтиҗәсе булып тора. Моннан аларның ике сүз кушылу юлы белән барлыкка килүе шөбһәсез: *үзкыйммәт, үзидарә, үзмаксат, үзаң, үзбилгеләнеш, үзагыш, үзидарә, үзагач.* Аларның берничәсе телдә күптән яшәп килә: *үзчир, үзавыру.* Боларның телдә тәңгәл сүзтезмәләре юк, шуңа күрә аларны ике нигез кушылып барлыкка килгән дип санарга туры килә.

**Сан + исем тибы.** Бу тип кушма сүзләрнең күпчелеге, кагыйдә буларак, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә әйләнү юлы белән барлыкка килә. Аларның кайберләре генә ике нигез кушылу юлы белән барлыкка килгәннәр. Мәсәлән, математика термины *өчбуын* башта ук калька буларак барлыкка килгәнлектән ике нигез кушылып ясалган. Шулай ук *кырыккарта* сүзенең тәңгәл сүзтезмә булмаганлыктан аны ике нигез кушылу юлы белән ясалган дип карарга туры килә.

**Сыйфат фигыль + исем тибы.** Бу тип кушма исемнәрнең ясалыш ысулын билгеләве бик кыен.

Мисаллардан аңлашылганча, аларның бер төркеме генә ике нигез кушылу юлы белән барлыкка килгән, чөнки телдә аларга туры килгән мөстәкыйль сүзтезмәләр юк: *янартау, янарчәчәк, буаръелан, түндербаш, үлмәсгөл.*

Мисаллардан күренгәнчә, сыйфат фигыльләр *-р* кушымчалы киләчәк заман формасында килсәләр дә, алар статик билгене белдерәләр.

**Хәл фигыль + исем тибы.** Телдә бу типтагы бары бер генә кушма сүз күзәтелә: *кайтаваз* (*кайтааваз*). Хәл фигыль бу кушма сүздә икенче сүзнең атрибуты булып килә.

**Аваз ияртеме+исем тибы.** Бу тип кушма сүзләр телдә бик сирәк: *мыраубикә, мияубикә, мыраужан.* Беренче компонент аваз ияртеме булса да, икенче компонентның атрибутын тәшкил итә.

### *Кушма исемнәрнең объект бәйләнешендәге компонентлардан кушылып ясалышы*

Татар телендә компонентлары объект бәйләнешендәге кушма сүзләр дә очрый. Аларның бер ишесе ике нигез кушылу юлы белән ясалганнар.

**Исем + исем тибы.** Телдә ике модель бар:

1) исем + исем фигыль моделе: *электртапшыру, радиотапшыру.* Бу сүзләрдә объект мөнәсәбәте күзәтелә. Бу модельдә беренче компонентлар кыскарган яки үзара бәйләнешле дә булырга мөмкиннәр: *метеокүзәтү.*

2) исем + *-ма* кушымчалы исем моделе: *елъязма, кулъязма, алъяпма.*

Барлык бу кушма исемнәр рус сүзләренең яки терминнарының калькалары булып торалар, шуңа күрә аларның сүзтезмәләрнең лексикалашуы дип карап булмый.

### *Кушма исемнәрнең хәл бәйләнешендәге компонентлар кушылып ясалуы*

Бу тип кушма сүзләрнең абсолют күпчелеге рус сүзләрен калькалаштыру юлы белән барлыкка килгәннәр.

**Исем + исем тибы.** Исем + *-гыч* кушымчалы исем моделе: *радиоалгыч, радиошартлаткыч.*

Бу сүзләрнең компонентлары арасында хәл бәйләнеше күзәтелә. Бу кушма исемнәр сүзтезмәләрнең кушымча алып лексикалашу

нәтиҗәсе түгел. Мәгълүм булганча, бу сүзләр хасил булган көненнән алып сүзләр кушылу нигезендә барлыкка килгәннәр, чөнки алар рус сүзләренең калькалары булып торалар. Хәзерге татар телендә бу тип кушма сүзләр байтак, әмма аларның беренче компонентлары булып бәйле яки кыскарган сүзләр килә: *вибросүндергеч, автотуктаткыч, гидрокүчергеч, гидрокөчәйткеч.*

Исем + исем моделе: *күзүлчәм, радиоидарә.* Бу модельдә дә беренче компонент булып бәйле яки кыскарган сүзләр килергә мөмкин: *телетапшыру, радиотапшыру, телеидарә, аэрочәчү.* Бу кушма сүзләрнең барысы да рус сүзләренең калькалары буларак барлыкка килгәннәр, шуңа күрә аларны татар теле җирлегендә сүзтезмәләрнең лексикалашуы дип санап булмый.

## Сүзтезмәләрнең лексикалашуы юлы белән кушма исемнәр барлыкка килү

Татар телендә кушма сүзләр кушылу юлы белән генә түгел, бәлки сүзтезмәләрнең лексикалашуы, сүзтезмәнең кушма сүзгә әйләнүе юлы белән дә хасил булалар. Сүзтезмәнең лексикалашу юлы белән барлыкка килгән кушма сүз сүзьясалыш ысулы ягыннан түгел, төзелеше ягыннан кушма сүз булып тора. Мәсәлән, *өчпочмак* сүзе кушма сүз булып тора, әмма ул *өч почмак* сүзтезмәсенең кушма сүзгә әйләнүе (күчүе) юлы белән барлыкка килгән. Мондый сүзләрнең нинди ысул белән хасил булуын билгеләве шактый кыен мәсьәлә булып тора: бу кушма сүз сүзләр кушылу юлы беләнме яки сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе беләнме барлыкка килгән?

Чөнки телдә аларның барлыкка килү ысулын билгеләү өчен бернинди дә тышкы билгеләр юк. Төп критерий булып телдә кушма сүзгә тәңгәл булган «тере» сүзтезмәнең яшәве шарт булып тора. Мәсәлән, *өчпочмак* кушма сүзе *өч* һәм *почмак* компонентларының кушылу юлы белән түгел, ә *өч почмак* сүзтезмәсен билгеле бер геометрик фигураны атау өчен файдалану нигезендә барлыкка килгән. Шулай итеп, бу сүзтезмә *өчпочмак* төшенчәсен белдерү өчен ныгып кала. Бу очракта җитди лексик-грамматик үзгәрешләр килеп чыга. Беренчедән, сүзтезмәгә кергән сүзләр арасындагы «тере» синтаксик бәйләнеш юкка чыга, моның нәтиҗәсендә сүзләрнең мөстәкыйльлеге югала, хәзер алар җөмләдә җөмлә кисәге булып килә алмыйлар. Икенчедән,

сүзтезмәнең мөстәкыйль сүзләре арасындагы пауза, тыналыш бетә. Өченчедән, просодик үзгәреш килеп чыга, мөстәкыйль басымнарның берсе юкка чыга. Дүртенчедән, сүзтезмә бердәм мәгънә белдерә башлый.

Күренгәнчә, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе җитди лексик-грамматик һәм фонетик-просодик үзгәрешләр белән бергә бара.

Сүзтезмәләрнең барлык төрләре дә: предикатив, атрибутив һәм комплетив сүзтезмәләр дә кушма исемнәргә күчәргә мөмкин.

### *Предикатив сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе*

Предикатив (хәбәрлекле) сүзтезмәләрнең кушма исемгә күчүе кеше исемнәрендә, топонимнарда, үсемлек исемнәрендә күзәтелә. Мәсәлән, *Уразгилде, Хангилде, Уразбакты, Ходайбирде, Аллабирде* кебек антропонимнар предикатив сүзтезмәләрнең лексикалашу юлы белән барлыкка килгәннәр. Кагыйдә буларак, мондый кушма исемнәрнең беренче компонентлары булып исемнәр, икенче компонентлары булып фигыльләр килә.

Әмма кайчак сүзтезмәләрнең сүзләрендә кире тәртип тә күзәтелә беренче компонент булып фигыль, икенче компонент булып исем килә: *Килде+бикә, Килде+бай, Килде+яр.* Бу мисаллар телнең борынгы хәлендә хәбәрнең урыны сүзтезмәнең башында булуын, юк дигәндә, мисаллардан күренгәнчә, аның урынының ирекле булуын күрсәтә.

Мондый кушма исемнәрдә хәбәр булып боерык фигыль, хикәя фигыль һ.б. килергә мөмкин.

Татар телендә предикатив сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчүенең түбәндәге типлары күзәтелә.

**Исем + фигыль тибы.** Бу типның берничә моделе бар.

Исем + боерык фигыль моделе: *үрмәкүчкач, Ишкил, Иштуг. Антропонимнарда кире сүз тәртибе дә булырга мөмкин: Килморза, Килтимер, Килбай, Торсынбай, Торбай.*

Исем + хикәя фигыль моделе. Бу модельнең берничә төре бар.

Исем + хәзерге заман хикәя фигыль: *Илүсә, Гөлүсә, Иштуа, Ирбула*.

Исем + үткән категорик заман хикәя фигыль формасы: *Ишбулды, Уразбакты, Хангилде, Байгилде, Айбирде.*

Бу модельдә сүзләрнең кире тәртибе дә булырга мөмкин: *Бакты-хуҗа, Килдебәк, Килдеураз, Бирдебәк.*

Исем + үткән билгесез заман хикәя фигыль формасы: *Аюкөйдер-гән* (*урын*)*, Биябаткан* (*урын*)*, Айтуган, Иштуган.*

Исем + барлыктагы фигыльнең беренче киләчәк заман формасы: *көнтуар, җантуар, этөрер* (мифик агач).

Исем + юклыктагы фигыльнең беренче киләчәк заман формасы: *кошкунмас, чебенкунмас, этбасмас* (урын).

Исем + исем фигыль моделе: *җиртетрәү, паръясалу, башәйләнү*.

Фактлар күрсәткәнчә, кайбер вакытта бу алым, аңлы рәвештә, терминнарны ясау өчен кулланылырга мөмкин: *паръясалу.*

Югарыда китерелгән барлык кушма сүзләр дә үзләренә тәңгәл булган сүзтезмәләреннән ясалганнар.

**Исем + предикатив сүз тибы:** *Илбар, Ишбар, Айбар* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу тип антропонимнарда очрый.

**Исем + сыйфат тибы:** *Илшат, Илгүзәл, Юлкотлы.*

Компонентлары предикатив бәйләнештә булган күмәклек кушма исемнәре бүгенге көндә ясалмый диярлек. Кеше исемнәрен ясауда бу алым бүгенге көндә дә файдаланыла: *Гөлүсә, Илүсә, Илшат* һ.б.ш.

### *Атрибутив сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе*

Татар телендә бигрәк тә сыйфат+исем һәм сан+исем сүзтезмәләренең лексикалашуы еш очрый.

**Сан + исем тибы.** Бу алым хәзерге көндә терминнар ясауда файдаланыла. Мисаллар:

| **сүзтезмә** | → | **кушма сүз** |
|---|---|---|
| *дүрт почмак* | | *дүртпочмак* |
| *биш почмак* | | *бишпочмак* |
| *сигез аяк* | | *сигезаяк* |
| *биш бармак* | | *бишбармак* |
| *өч аяк* | | *өчаяк* |
| *биш авыз* | | *бишавыз* |
| *мең яфрак* | | *меңьяфрак* |

Күренгәнчә, китерелгән кушма исемнәрнең үзләренә тәңгәл ирекле сүзтезмәләре бар. Шуңа күрә аларны сан белән исем кушылып ясалган дип санап булмый,алар сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү юлы белән барлыкка килгәннәр. Кушма сүзләрнең бу төре бигрәк тә топонимнарда күп очрый: *Бишмунча, Бишкәҗә, Бишбалта, Бишавыл, Дүртөйле.*

**Сыйфат + исем тибы.** Хәзерге татар телендә сыйфат + исем тибындагы атрибутив сүзтезмәләрдән ясалган кушма сүзләр күп очрый. Мисаллар:

| **сүзтезмә** | → | **кушма сүз** |
|---|---|---|
| *ак сакал* | | *аксакал* |
| *зур колак* | | *зурколак* |
| *ак чәчәк* | | *акчәчәк* |
| *кара бүрек* | | *карабүрек* |
| *кара түш* | | *каратүш* |
| *кара күз* | | *каракүз* |
| *кара кош* | | *каракош* |
| *ак кош* | | *аккош* |
| *озын борын* | | *озынборын* |
| *озын аяк* | | *озынаяк* |
| *ак күбәләк* | | *аккүбәләк* |
| *соры корт* | | *сорыкорт* |
| *ал як* | | *алъяк* |

Мисаллардан күренгәнчә, икенче баганада китерелгән кушма исемнәрнең тәңгәл ирекле сүзтезмәләре бар һәм ул сүзләрнең шул сүзтезмәләрдән килеп чыгуы логикага сыя. Шуңа карамастан бу төр кушма сүзләрнең ясалыш ысулын ачыклавы шактый авыр. Алар ике сүз кушылудан да, сүзтезмәләрнең лексикалашуыннан да барлыкка килергә мөмкин. Бу сүзләрнең күпчелеге бик борынгыда барлыкка килгәннәр, шуңа күрә аларга туры килгән конкрет сүзтезмәләрне билгеләве кыенлаша.

Хәзерге вакытта бу кушма сүзләрнең тәңгәл сүзтезмәләре булганлыктан, аларны шул сүзтезмәләрдән ясалган дип уйларга була.

**Сыйфат функциясендәге исем + сыйфат тибы:** *Гөлчибәр, Гөлсылу, Айчибәр, Айбулат, Тамчыгөл, Ташбулат, Ташбәк, Алмахан* һ.б. Мондый ясалыш нигездә антропонимнарда гына очрый.

**Сыйфат + сыйфат тибы:** *Гаделсылу, Иркәсылу, Күркәмсылу.* Бу төр кушма сүзләр кеше исемнәрендә генә күзәтелә.

**Сыйфат фигыль + исем тибы:** *Сулмасгөл, Үлмәсбикә, Үлмәсбай, Сулмасхан.* Бу юл белән бары ялгызлык исемнәре генә ясала. Бу тип белән ясалган борынгырак исемнәр дә бар: *Утәмешгәрәй, Туктамышхан, Туктамышгәрәй,* чөнки боларның беренче компонентлары фигыльнең борынгы формаларын тәшкил итәләр.

**Исем + тартымлы исем тибы.** Телдә тартым белән килгән ирекле сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчүе еш очрый.

Билгеле булганча, тартымлы сүзтезмәләр төрки телләрдә бик үзенчәлекле күренеш булып торалар. Бу тип сүзтезмәләр үсемлекләрне, авыруларны, коралларны һ.б.ш. атау өчен дә кулланылалар.

Мәсәлән, билгеле бер хайванның берәр әгъзасын белдерә торган сүзтезмә алына һәм ул үзенчәлекле билгесе буенча үсемлекне атау өчен кулланыла. Мисаллар:

| **сүзтезмә** | → | **кушма сүз (үсемлек)** |
|---|---|---|
| *аю колагы* | | *аю колагы* |
| *ишәк колагы* | | *ишәк колагы* |
| *куян колагы* | | *куян колагы* |
| *карга күзе* | | *карга күзе* |
| *күгәрчен күзе* | | *күгәрчен күзе* |
| *үгез күзе* | | *үгез күзе* |
| *песи табаны* | | *песи табаны* |
| *аю табаны* | | *аю табаны* |
| *үгез теле* | | *үгез теле* |
| *сыер теле* | | *сыер теле* |
| *эт эчәге* | | *эт эчәге* |
| *бүре аягы* | | *бүре аягы* |
| *бүре тырнагы* | | *бүре тырнагы* |
| *бүре күзе* | | *бүре күзе* |

Телдә тартымлы сүзтезмәләреннән ясалган, әмма башка мәгънә белдерә торган кушма сүзләр дә бар: *өй алды, ишек алды, бал карагы* (*бөҗәк*), *шайтан бармагы.*

Шуның белән бергә татар телендә тартымлы икенче компонент белән ясалган башка кушма сүзләр дә бар. Алардагы компонентларның

үзара лексик-семантик бәйләнеше бик кызыклы: нинди дә булса бер үсемлек билгеле бер хайванныкы итеп күрсәтелә (*ат кузгалагы, чыпчык кузгалагы, куян кәбестәсе, эт җимеше, бүре җиләге, күке җитене, песи борчагы, торна борчагы, эт какысы*).

Бу кушма исемнәр телдә ике төрле юл белән барлыкка килгән дип карарга була. Беренчедән, бу сүзләрнең ясалышы бик борынгыга, тотемизм чорына кайтып калырга, бу үсемлекләр илаһилаштырылган кошныкы, хайванныкы, тотемныкы дип каралырга мөмкин. Икенчедән, бәлки кайбер үсемлек атамаларының алар белдергән реалийлар белән бәйләнеше бар дип тә уйлаган булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, *торна борчагын* торналар өчен азык дип санаганнар. Ләкин болар барысы да фараз гына, югарыда китерелгән мисалларның күпчелегенең үзләре белдергән реалийлар белән бернинди дә бәйләнешләре юк. Шуңа күрә бу кушма сүзләрне исем сүзләр кушылып ясалган дип карарга туры килә, чөнки телдә аларга туры килгән ирекле сүзтезмәләр юк.

### *Компонентлары объект бәйләнешендәге сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе*

**Туры объект функциясендәге исем + *-р* кушымчалы сыйфат фигыль тибы:** *сусөяр, чәчәкашар, субуяр, юлбасар, тиреашар, эшкуар, айбагар, субүләр, йонашар, эзтабар, Илсөяр, Илтөзәр, Илгизәр, Малтабар.* Күренгәнчә, бу тип кушма сүзләр ялгызлык исемнәрендә очрый.

Туры объект функциясендәге алмашлык+*-р* кушымчалы сыйфат фигыль*: үзсөяр.* Мондый кушма исем ясалмарак булып чыга, шуңа күрә әдәби телдә мондый ясалыш юк диярлек.

### *Компонентлары хәл бәйләнешендәге сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе*

**Рәвеш + фигыль тибы.** Бу типның түбәндәге модельләре бар:

Рәвеш + фигыльнең үткән категорик заман формасы: *Яңатуды, Яңакилде, Яшькилде, Теребирде, Төзкилде, Исәнбирде, Саубакты.*

Рәвеш + фигыльнең үткән билгесез заман формасы: *Төзтуган, Төзкилгән, Яшьтуган, Актуган, Каратуган.*

Рәвеш + боерык фигыль формасы: *Исәнкил, Саут, Исәнбул, Төгәлкара.*

Рәвеш + фигыльнең юклыктагы беренче киләчәк заман формасы: *тиктормас*.

Рәвеш + исем фигыль: *күмәк җырлау, ялгыз җырлау.* Бу кушма сүзләр аларга туры килгән сүзтезмәләрдән ясалганнар. Бу модельгә шулай ук *үрәкарау* (чир) кушма сүзе дә керә. Хәзерге көндә бу сүзтезмәләрнең кушма сүзләргә күчүе тулысынча тәмамланып җитмәгән, тел аңында алар тиешле төшенчәләрнең билгесе буларак кына күз алдына киләләр. Телнең киләчәктә үсеше аларның никадәр кушма сүз табигатенә туры килүен күрсәтер.

**Сан + фигыль тибы:** *йөзьяшәр, меңьяшәр, алтатар* (*алтыатар*), *кырыгалдар.*

**Фигыль + фигыль тибы.** Бу юл белән ясалган кушма исемнәр телдә күп түгел: *күрә алмау, сатып алу, урып җыю, танып белү, эшләп чыгару, уйлап табу.*

### Сүзтезмәләрнең, кушымчалар алып, кушма сүзгә күчүе

Сүзтезмә лексикалашканда бөтен сүзтезмә кушымча алырга мөмкин. Мондый сүзьясалыш татар телендә шактый продуктив. Фактлар күрсәткәнчә, соңгы чорда фән һәм техниканың күп кенә терминнары бу алым белән ясалганнар: *бишьел+лык, күпмилләт+ле, карүлчә+геч, парчистарт+кыч.* Бу алым исемнәр ясауда да, сыйфатлар ясауда да киң кулланыла.

Бу юл исемнәр ясалышының түбәндәге типлары бар.

**Сүзтезмә + *-чы/-че* кушымчасы.** Бу типның сүзтезмәсе сыйфатында исем сүзтезмәләре дә (*кызылфлот+чы*), фигыль сүзтезмәләре дә (*чәй үстерү+че, чөгендер үстерү+че, кер юу+чы, хәреф җыю+чы, сыер саву+чы, пыяла кисү+че*). Бу тип кушма сүзләр түбәндәге мәгънәне белдерәләр: 1) берәр оешма яки төркемгә караган затны: *кызылфлотчы, карагруһчы, утызмеңче, егермебишмеңче;* 2) фигыль белдергән эш-хәрәкәт белән шөгыльләнүче затны: *кукуруз үстерүче, җитен тараучы, ат караучы, бала караучы, бозау караучы.* Кайвакыт мондый кушма сүзләрнең семантикасы бик нык метафоралашырга мөмкин.

**Сүзтезмә + *-гыч/-геч,* (*-кыч/-кеч*) кушымчасы.** Кушма исемнәр ясалышының бу тибында сүзтезмә сыйфатында фигыль сүзтезмәләре кулланыла. Аларның беренче компонентлары буларак нигездә исемнәр

(*тамыркискеч, адымүлчәгеч, суүлчәгеч*), сирәк кенә – рәвеш (*тизагызгыч*) һәм алмашлык (*үзбушаткыч*) килә. Бу тип кушма сүзләр түбәндәге мәгънәне белдерәләр: 1) сүзтезмә тәгъбир иткән эш хәрәкәт өчен хезмәт итә торган машинаны, коралны, җайланманы: *кулъюгыч, бозваткыч, көчүлчәгеч, буйүлчәгеч, алъяпкыч, куаккискеч, дулкынтоткыч, паръүлчәгеч;* 2) сүзтезмә тәгъбир иткән билге белән тасвирлана торган җәнлекне, бөҗәкне, һ.б.ш.ны: *комказыгыч, җимешкорткыч.* Бу юл белән ясалган кушма сүзләр арасында индивидуаль мәгънәлеләре дә очрый: *башваткыч.*

**Сүзтезмә + *-лык/-лек* кушымчасы.** Татар телендә бу юл белән ясалган кушма сүзләр күп түгел: *бишкөнлек,简нкөнлек, бишьеллык, үтәкүренүчәнлек.*

Бу төр кушма исемнәр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: 1) сүзтезмә тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең атамасын: *эшбашкаручылык;* 2) сүзтезмә белән бәйле үзенчәлекне: *минбеләмлек;* 3) сүзтезмә белдергән вакыт аралыгын: *бишьеллык, ункөнлек, бишкөнлек.*

*-лык/-лек* кушымчасы белән сыйфат сүзтезмәләреннән дә кушма исемнәр ясалырга мөмкин: *азканлы+лык, эчкерле+лек, азҗирле+лек.*

**Сүзтезмә + *-ыш/-еш, -ш* кушымчасы.** Бу типта сүзтезмә сыйфатында фигыль сүзтезмәләре килә: *көнкүр+еш, көнит+еш, тынал+ыш, күзбәйлә+ш, аркасуг+ыш.*

**Сүзтезмә + *-чылык/-челек* кушымчасы.** Бу типтагы сүзтезмә сыйфатында исем сүзтезмәләре дә, фигыль сүзтезмәләре дә килә: *карагруһ+чылык, чәчәк үстерү+челек.*

Бу кушма сүзләрне *-чы/-че* кушымчасы белән түгел, *-чылык/-челек* кушымчасы белән ясалган дип карау аларның төзелеш табигатенә туры килә.

Алар түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: 1) җитештерү тармагын: *чөгендер үстерүчелек, чәчәк үстерүчелек, мамык игүчелек;* 2) иҗтимагый агымны: *карагруһчылык.*

### 9.5.4. Исемнәрнең конверсия ысулы белән ясалышы

Бер сүз төркеменә кергән сүзләрнең башка сүз төркеменә күчү юлы белән сүзләр ясалышы төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, киң таралган, рәвешләрдән башка барлык мөстәкыйль сүз төркемнәренә кергән сүзләр исемгә күчәргә мөмкин.

### *Сыйфатларның исемгә күчүе*

Фактлар күрсәткәнчә, татар телендә сыйфатлардан конверсия юлы белән ясалган исемнәр күп. Аларның ясаучы нигезләре – сыйфатлар төрле тематик төркемнәргә карый.

1. Төсне белдерә торган сыйфатлардан конверсия юлы белән ясалган исемнәр ясаучы нигез билгесе белән бәйле предметны белдерә:

| **сыйфатлар** | **→** | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *кара* | | *кара* (күк кара) |
| *ак* | | *ак* (күзенә ак төшкән) |
| *күк* | | *күк* (күк йөзе) |
| *чал* | | *чал* (чәченә чал кергән) |
| *ак бүз* | | *акбүз* (тукыма) |

Мисаллар: *Ул ... ак төшкән күзен ялтыратып туп-туры миңа карады.* М. Гали. *Кайнаган суга йомырка агын салыгыз.* Г. Ибраһимов. *Кәгазь алды, каләмен карага манды.* И. Газый. *Озын акбүз күлмәге тезләренә хәтле җиткән.* М. Җәлил.

2. Кешенең рухи-психик үзенчәлекләрен белдерә торган сыйфатлар конверсия ысулы белән исемнәргә күчеп, нинди дә булса рухи-психик үзенчәлекле затны тәгъбир итәләр:

| **сыйфатлар** | **→** | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *мактанчык* | | *мактанчык* |
| *кыю* | | *кыю* |
| *тиле* | | *тиле* |
| *ахмак* | | *ахмак* |
| *ялкау* | | *ялкау* |
| *ялагай* | | *ялагай* |
| *аумакай* | | *аумакай* |
| *азгын* | | *азгын* |
| *аңгыра* | | *аңгыра* |
| *ертлач* | | *ертлач* |

Мисаллар: *Ләкин студент мәҗлес әдәбе белми торган бер ахмак булырга кирәк.* Ф. Әмирхан. *Аумакайлардан, ахмаклардан арыныйк, туган.* К. Тинчурин. *Ул башын тилегә сала да, эшне шома гына уздырып җибәрә.* М. Гали.

3. Кешенеӊ физик үзенчәлекләрен белдерә торган сыйфатлар конверсия юлы белән исемнәргә күчеп, нинди дә булса физик үзенчәлекле затны тәгъбир итә:

| **сыйфатлар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *саӊгырау* | | *саӊгырау* |
| *гарип* | | *гарип* |
| *сырхау* | | *сырхау* |
| *чатан* | | *чатан* |
| *авыру* | | *авыру* |
| *сукыр* | | *сукыр* |
| *сылу* | | *сылу* |

Мисаллар: *Мондый с ы р х а у л а р г а да дәва бар икән.* Г. Бәширов. *Ул с у к ы р н ы ӊ күзләрен син ник килеп чиштеӊ.* М. Гафури. *Ул с ы л у н ы ӊ унҗидедә булсын яше.* М. Гафури.

4. Кешенеӊ социаль үзенчәлекләрен белдерә торган сыйфатлар конверсия ысулы белән исемнәргә күчеп, нинди дә булса социаль үзенчәлеккә ия булган затны тәгъбир итә:

| **сыйфатлар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *бай* (*кеше*) | | *бай* |
| *хәрби* | | *хәрби* |
| *изге* | | *изге* |
| *гаскәри* | | *гаскәри* |
| *вәхши* | | *вәхши* |

Мисаллар: *Сезнеӊ җырыгызны ишеткәч, табигатьнеӊ нечкә серләренә төшенә алмаган в ә х ш и шикелле булдым мин.* М. Әмир. *Мин бер ел торгач, ул да хезмәтче малай булып б а й г а ялланды.* Г. Камал. *Бу китаптан и з г е л ә р вә аларныӊ тормышлары хакында язылган хикәяләрне чын бер дәрт белән укый.* Ф. Әмирхан.

5. Кешенеӊ яшь үзенчәлекләрен белдерә торган сыйфатлар конверсия ысулы белән исемнәргә күчеп, яшькә бәйле затны тәгъбир итә:

| **сыйфатлар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *карт* (*кеше*) | | *карт* |
| *яшь* | | *яшь* |

| | |
|---|---|
| *өлкән* | *өлкән* |
| *кече* | *кече* |
| *олы* | *олы* |

Мисаллар: *Шундый к а р т к а биреп куйсалар, бетте баш.* М. Фәйзи. *Мин к а р т янына барып утырдым.* Ә. Айдар. *Наданлыкны бетерербез, белемнәрне арттырырбыз, я ш ь л ә р н е яңа тормышка өндәрбез.* Ф. Бурнаш. *Я ш ь л ә р г ә бик зур сабак булды.* М. Җәлил.

6. Табигать күренешләренең үзенчәлекләрен белдергән сыйфатлар конверсия ысулы белән исемнәргә күчеп, билгеләре буенча шул күренешләрнең атамасын тәгъбир итә:

| **сыйфатлар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *суык* (*көн*) | | *суык* |
| *кызу* | | *кызу* |
| *җылы* | | *җылы* |
| *салкын* | | *салкын* |
| *эссе* | | *эссе* |
| *караңгы* | | *караңгы* |

Мисаллар: *Крестьяннарны тәүлектән артык кар өстендә с у ы - к т а тотканнар. «Урал» газ. Чыдый алмый с у ы к к а калтыранып тора.* М. Гафури. *Яз иде, тәрәзәдән яз җ ы л ы с ы белән күперенгән дымлы җир исе, тал бәпчекләренең төчкелт баллы исе бәреп тора иде.* Г. Бәширов. *Җәй э с с е с е н д ә шәһәрдә торып туйган Тукай бу чакырудан мәмнүн иде.* Ф. Әмирхан. *Ул бер к а р а ң г ы д а н икенче к а р а ң г ы г а кадәр эшли.* М. Гали.

Бу пунктта китерелгән сыйфатлар конверсия ысулы белән, исемнәрдән тыш, рәвешләр дә ясыйлар.

| **сыйфатлар** | → | **рәвешләр** |
|---|---|---|
| *суык* | | *суык* (булып китте) |
| *кызу* | | *кызу* (эшли) |
| *җылы* | | *җылы* (сөйләшә) |
| *салкын* | | *салкын* (каршы алды) |
| *эссе* | | *эссе* (булып китте) |

Мисаллар: *Бик күңелле булыр, җиңеп кайтып, җ ы л ы күрешү.* М.Җәлил. *Сезнең монда бик э с с е булып китте.* Ф.Әмирхан.

Телдә конверсия ысулы белән сыйфатлардан ясалган башка исемнәр дә бар:

| **сыйфатлар** → | **исемнәр** |
|---|---|
| *чын* | *чын* (уены, чыны бергә) |
| *асыл* | *асыл* (эшнең асылы) |
| *яңа* | *яңа* (яңаның көрәше) |
| *иске* | *иске* (искегә тимә) |

Кушымчалы сыйфатлар шулай ук исемнәргә күчәргә мөмкин. Мондый очракларда аларның ясалыш ысулын билгеләү бик кыен: алар кушымчалар белән ясалганмы, әллә конверсия ысулы беләнме? Биредә исемнәрнең конверсия ысулы белән ясалуына мисаллар китерелә.

***-лы* кушымчалы сыйфат → исем:**

| **сыйфат** → | **исем** |
|---|---|
| *ярлы* (кеше) | *ярлы* (ярлылар бистәсе) |
| *җәяүле* | *җәяүле* (җәяүлегә янчык та авыр) |
| *сөекле* | *сөекле* (аның сөеклесе) |

Мисаллар: *Ул һаман я р л ы л а р белән начар мөгамәлә итә*. М. Гафури. *Бер почмакта бер төркем җ ә я ү л е белән ике-өч атлы арасында кайсы гаскәрнең яхшырак икәнлеге турында бәхәс бара*. Ш. Усманов.

*-лы* кушымчасы белән ясалган сүзләр һәм структурасы, һәм семантикасы буенча, кагыйдә буларак, сыйфатлар булып торалар, чөнки бу дериват бары сыйфатлар ясый. Шуңа күрә *-лы* кушымчалы исемнәрне, телдә шундый ук сыйфатлар булганлыктан, конверсия юлы белән сыйфатлардан ясалган исем дип карарга туры килә.

***-сыз* кушымчалы сыйфат → исем:**

| **сыйфат** → | **исем** |
|---|---|
| *эшлексез* | *эшлексез* (эшлексезләр җыелган) |
| *грамотасыз* | *грамотасыз* (грамотасызлар белән эшләү) |
| *телсез* | *телсез* (телсезләр мәктәбе) |
| *эшсез* | *эшсез* (эшсезләр күбәйде) |
| *оятсыз* | *оятсыз* (ул оятсыз нишләгән?) |

*-сыз* кушымчасы, кагыйдә буларак, сыйфатлар ясый, шуңа күрә бу кушымчалы исемнәрне конверсия ысулы белән шундый ук сыйфатлардан ясаган дип санарга туры килә.

Бу сыйфатларның исем мәгънәләре татар теленең сүзлекләрендә күрсәтелә.

Боларның исемнәргә күчүе эллипсис нәтиҗәсе.

Мисаллар: *Җыен эшлексезне, җыен бозыкны, нәсел черетеп, син җыеп ятасың!* Г. Бәширов. *Эшсезләр бик күп, һәр көн иртә завод капкасы... ач эшчеләр белән тулган була.* Г. Ибраһимов.

***-ык/-ек, -к* кушымчалы сыйфат → исем:**

| **сыйфат** | **→** | **исем** |
|---|---|---|
| *ватык* | | *ватык* (тимер ватыклары) |
| *сынык* | | *сынык* |
| *аксак* | | *аксак* |
| *өтек* | | *өтек* |
| *елак* | | *елак* |

Мисаллар: *Танк ватыкларын сандалга салыр бу көн безнең тимерче.* Ф. Кәрим. Ми*чкә карасалар, мәрхүм гитараның актык сыныгы янып бетмәктә иде.* Г. Ибраһимов. *Синең кебек аксакларга күп мал түгел.* М. Фәйзи. *Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер.* Мәкаль.

Тел фактлары күрсәткәнчә, *-ык/-ек, -к* кушымчасы исемнәр дә, сыйфатлар да ясый. Әгәр *-ык/-ек, -к* кушымчалы исемнең шундый ук сыйфаты юк икән, ә *-ык/-ек, -к* кушымчалы сыйфатның шундый ук исеме юк, икән, болар, һичшиксез, кушымчалау ысулы белән ясалган исем яки сыйфат булып торалар. Әгәр *-ык/-ек, -к* кушымчасы белән килгән сүзләрдә сыйфат мәгънәсе дә, исем мәгънәсе дә булса, ул вакытта аларның ясалышы ысулын билгеләү кыенлаша. Сыйфат исемгә күчкәнме яки исем сыйфатка күчкәнме дигән сорау туа. Бу мәсьәләдә сүзьясалыш теориясенең гомуми принцибы ярдәмгә килә. Ясалган сүзнең семантикасының спектры, мәгънә кыры һәрвакыт ясаучы нигездән киңрәк була. Мәсәлән, *ватык, сынык* сүзләрендә беренче төп мәгънә булып сыйфат мәгънәсе килә. Икенче яктан, аларның семантик спектры, мәгънә кыры шундый ук сыйфатлары тәңгәл

килгән исемнәрга караганда киңрәк. Бу критерий исә сыйфатларның исемнәргә күчүен исбатлый торган критерий булып тора.

***-ры* кушымчалы сыйфат → исем:**

| **сыйфат** | **→** | **исем** |
|---|---|---|
| *бөкре* | | *бөкре* |
| *кәкре* | | *кәкре* (мат.) |

Мәсәлән, *Б ө к р е л ә р е тураеп, менә китте зураеп.* Н. Исәнбәт.

Югарыда китерелгән мисалларда сыйфат мәгънәсе исем мәгънәсенә караганда киңрәк, ә исем мәгънәсе шактый тар. Шуңа күрә биредә сыйфат исемгә күчкән булып чыга, киресенчә түгел.

***Фигыльнең исемгә күчүе***

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә фигыльләрдән конверсия ысулы белән шактый күп исемнәр ясала.

Бигрәк тә фигыль формалары исемнәргә җиңел күчә. Исем фигыльләр конверсия ысулы белән исемгә күчә:

| **фигыль** | **→** | **исем** |
|---|---|---|
| *җиңү* | | *җиңү* |
| *белдерү* | | *белдерү* |
| *янау* | | *янау* |
| *кисәтү* | | *кисәтү* |
| *чигү* | | *чигү* |
| *чолгау* | | *чолгау* |
| *язу* | | *язу* |
| *ялгау* | | *ялгау* |
| *уку* | | *уку* |
| *ямау* | | *ямау* |
| *чагыштыру* | | *чагыштыру* |
| *асрау* | | *асрау* |
| *өстәү* | | *өстәү* |
| *терәү* | | *терәү* |
| *буяу* | | *буяу* |
| *түләү* | | *түләү* |
| *үлчәү* | | *үлчәү* |
| *сайлау* | | *сайлау* |
| *көтү* | | *көтү* |

Мисаллар: *Иртәгесен инде чаттагы баганага зур-зур хәрефләр белән бик тырышып язылган бер б е л д е р ү ябыштырылгын иде*. А. Шамов. *Аларның я н а у л а р ы н а җавап итеп, бистә эшчеләре кораллы дружиналарга язылдылар.* К. Нәҗми. *Төсе уңган, берничә җиренә пөхтә итеп я м а у салынган соры кофта белән күн чалбар кигән.* А. Шамов. *А с р а у н ы ң китергән язуы егетне тагы шөбһә катнаш хәсрәткә төшерде.* Г. Ибраһимов. *Афишалар зур хәрефләр белән өс яктан кызыл астан яшел б у я у белән басылган.* Г.Камал.

Фигыльләрдән конверсия юлы белән ясалган исемнәр түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1) эш-хәрәкәтне башкару өчен кирәк булган нәрсәне: *үлчәү, терәү, буяу;*

2) эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсен: *чигү, ялгау, язу;*

3) эш-хәрәкәтнең атамасын: *янау, уку, кисәтү.*

*-мыш* кушымчалы кайбер тарихи фигыль формалары шулай ук исемнәргә күчкән: *-мыш* кушымчалы борынгы сыйфат фигыль формалары, мәсәлән, исемгә әйләнгән: *тумыш, укымыш, сынамыш.*

Мисаллар: *Мәрьям т у м ы ш т а н ук артык шау-шуны, көтүкөтү балалар белән җенләнеп уйнап йөрүне яратмый*. Г. Ибраһимов. *Юаш, бастырынкы, бик инсафлы, бик чибәр бала, у к ы м ы ш ы да зур, диләр*. Г. Камал. *У к ы м ы ш ы аз булса да, сизгер, җитез, акыллы*. Г. Әпсәләмов.

Һичшиксез, бу сүзләр тарихи яктан караганда фигыль формаларының исемгә күчү юлы белән ясалганнар. Хәзерге көндә бу сүзләрнең параллель формалары юк, шунлыктан аларны кушымчалау ысулы белән ясалган дип тә карап була.

*-мак* кушымчалы кайбер тарихи фигыль формалары шулай ук исемнәргә күчкән.

*Табышмак, ашамак* (диал.), *ермак*.

Мисаллар: *Боз китеп бетүгә инешкә коя торган е р м а к к а алып төштеләр.* Г. Гобәй. *Мин бу юлы да аны берәр башваткыч т а б ы ш м а к бирер дип, уйлаган идем.* А. Шамов.

Борынгы телдә бу форма инфинитивны белдергән. Хәзерге телдә ул бары мәкальләрдә һәм әйтемнәрдә генә сакланып калган: *Май язмак – җан чыкмак. Ир бирмәк – җан бирмәк.* Мәкаль.

*-мак* кушымчалы сүзләр татар телендә байтак, әмма аларның күпчелегенең ясалыш структурасы ачык түгел: *күлмәк, колмак, чүлмәк, каймак, тармак, сукмак.*

*-ган* кушымчалы кайбер сыйфат фигыльләр конверсия юлы белән исемгә күчкәннәр һәм алар эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсен белдерәләр:

| **сыйфат фигыльләр** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *үткән* | | *үткән* |
| *үтелгән* | | *үтелгән* |

Мисаллар: *Класста бүген ү т е л г ә н н е кабатладылар. Ү т к ә н н е искә төшереп утырдылар.*

*-чы/-че* кушымчалы сыйфат фигыльләр конверсия юлы белән исемнәргә күчәләр һәм алар фигыль белдергән эш-хәрәкәт белән шөгыльләнүче затны тәгъбир итәләр:

| ***-чы/-че*** **кушымчалы сыйфат фигыльләр** | → **исемнәр** |
|---|---|
| *язучы* (хат язучы) | *язучы* |
| *укучы* | *укучы* |
| *тукучы* | *тукучы* |
| *сатучы* | *сатучы* |
| *кыручы* | *кыручы* |
| *тегүче* | *тегүче* |
| *чәчүче* | *чәчүче* |
| *сөрүче* | *сөрүче* |

Барлык грамматикаларда диярлек бу сүзләрне, фигыльләргә *-чы/-че* кушымчасы ялганып ясалган исемнәр, дип карыйлар. Бу дөрес түгел. Алар хәзерге заман сыйфат фигыльләрдән барлыкка килгәннәр, чөнки аларның шундый ук сыйфат фигыль формалары бар.

Мисаллар: *Я з у ч ы л а р өчен шартлар тудырылган иде. Т у к у ч ы л а р да бар, о ч у ч ы л а р да бар, гөрләп яши безнең Татарстан.* Ә. Ярикәй. *Каюм т е г ү ч е кием үлчәгән шикелле, идәнгә тезләнеп, бик тиз үлчәп алды.* Г. Гобәй. *Килешли бригаданың төрле якларга сибелеп эшләп яткан т ы р м а ч ы л а р н ы , ч ә ч ү ч е л ә р н е күздән кичерде.* Г. Бәширов.

Мондый ысул белән сыйфат фигыльләрдән ясалган сүзләр терминология өлкәсендә күп очрый:

| **сыйфат фигыльләр** | **→** | **терминнар** |
|---|---|---|
| *сөйрәлүче* | | *сөйрәлүче* (биол.) |
| *бүленүче* | | *бүленүче* (мат.) |
| *бүлүче* | | *бүлүче* (мат.) |
| *алынучы* | | *алынучы* (мат.) |
| *кушылучы* | | *кушылучы* (мат.) |
| *эксплуатацияләүче* | | *эксплуатацияләүче* (сәяси) |
| *эксплуатацияләнүче* | | *эксплуатацияләнүче* (сәяси) |

-*ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләр конверсия ысулы белән исемнәргә күчәләр һәм алар фигыль белдергән эш-хәрәкәткә бәйле предметны тәгъбир итәләр:

| **сыйфат фигыльләр** | **→** | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *көтәчәк* | | *көтәчәк* |
| *киләчәк* | | *киләчәк* |
| *күрәчәк* | | *күрәчәк* |
| *алачак* | | *алачак* |
| *бирәчәк* | | *бирәчәк* |

Мисаллар: *Хәзер инде сез шул б и р ә ч ә к л ә р н е түләмәкче буласызмыни?* Г. Камал. *К и л ә ч ә к к ә хатлар.* Һ. Такташ. *Орлыгың аз булса, к ө т ә ч ә к к ә бирермен.* М. Җәлил.

-*р* кушымчалы сыйфат фигыльләр конверсия юлы белән исемнәргә күчәләр һәм фигыль белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булган предметны тәгъбир итәләр.

| **сыйфат фигыль** | **→** | **исем** |
|---|---|---|
| *килер* | | *килер* (табыш) |

Мисал: *Йортны алып барырлык к и л е р е дә бар.* А. Шамов.

-*сы* кушымчалы сыйфат фигыльләр дә, шулай ук, конверсия юлы белән исемнәргә күчәләр һәм фигыль белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган предметны тәгъбир итәләр:

| **сыйфат фигыльләр** | **→** | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *бирәсе* | | *бирәсе* |
| *көтәсе* | | *көтәсе* |
| *аласы* | | *аласы* |
| *күрәсе* | | *күрәсе* |

Мисаллар: *Мәскәү һәм Варшава фабрикантлары к ө т ә с е г ә мал биреп торалар.* Ш. Мөхәммәдев. *Галиулланың б и р ә с е л ә р е н шул акчадан тотып калырмын.* И. Газый.

Мисаллардан күренгәнчә, китерелгән исемнәрнең ясаучы нигезләре булып фигыль формалары килә. Шулай итеп, телдә структурасы ягыннан бердәй булган исемнәр һәм фигыль формалары рәттән яшәп киләләр. Аларны аеру өчен нинди критерийлар бар соң?

Беренчедән, аларның семантикасы төрлечә. Фигыль формалары эш-хәрәкәтне, процессны белдерәләр, алар динамикада булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, *янау, кисәтү, язу* фигыльләре эш-хәрәкәтне, процессны белдерәләр, алар үткәндә булган (*яна+ды, кисәт+те, яз+ды*), хәзер башкарыла торган (*ян+ый, кисәт+ә, яз+а*) һәм киләчәктә булачак (*ян+ар, кисәт+ер, яз+ар*)эш-хәрәкәтне тәгъбир итә алалар. Фигыль формаларыннан килеп чыккан исемнәр грамматик мәгънәдәге предметны белдерәләр: *язу* (документ), *кисәтү* (атама), *янау* (атама). Алар фигыльлекне түгел, предметлыкны белдерәләр.

Икенчедән, алар тулысынча фигыльнең барлык категорияләрен югалталар, исемнәрнең парадигмасын алалар.

Өченчедән, фигыль формаларыннан конверсия юлы белән барлыкка килгән исемнәр җөмләдә һәм сүзтезмәләрендә исем өчен типик булган позицияләрдә кулланыла.

Фигыль формалары җөмләдә, кагыйдә буларак, бәйле җөмлә кисәге булып киләләр: *К ө т е л м ә г ә н кечкенә бер вакыйга Нургалинең күзен ачты.* Ә. Еники. Шул ук нигезләрдән килеп чыккан исемнәр мөстәкыйль буларак һәм ия буларак та кулланылырга мөмкин. *Кешенең күңелен к и л ә ч ә к борчый.*

Дүртенчедән, фигыль формалары күпчелек очракта полисемантик булалар, ягъни аларның семантика спектры киңрәк була. Шул нигезләрдән ясалган исемнәр абсолют күпчелектә бер генә мәгънә белдерәләр: *язу, киләчәк, үткән.*

### *Алмашлыкларның исемгә күчүе*

Кайбер очракларда алмашлыклар бернинди үзгәрешсез исемнәргә күчәләр:

*нәрсә* → *нәрсә* (әйбер): *Яңа язган н ә р с ә л ә р е м н е җибәреп торыр идем.* М. Җәлил.

*һәрбер* → *һәрбер: Һ ә р б е р е шул фикердә тора.*

*беркем* → *беркем: Б е р к е м е м дә юк минем, тик иң якын Анам булган илем, халкым бар.* М. Җәлил.

*бернәрсә* → *бернәрсә: Аның өчен оекбашның пычрануы б е р н ә р с ә түгел иде.* А. Шамов.

*барлык* → *барлык: Егерме чанның б а р л ы г ы юылып, ... бишне яңадан өлгерткәннәр.* Ш. Камал. *Шулар б а р л ы г ы җыелып килеп, картның күңелен йомшарттылар.* Г. Ибраһимов.

*теге* → *теге: Т е г е с е бик кызып җавап бирде.* К. Нәҗми. *Нәгыймнең җавабы т е г е л ә р н е к е н ә капма-каршы иде.* Ш. Камал.

*бөтен* → *бөтен: Гәрәй б ө т е н е с е н туктатты.* Ш. Усманов. *Б ө т е н н е алып бирдем дә, алар акырынып-җикеренеп эчә калдылар.* Г. Камал. *Б ө т е н н е уртага бүлү.*

*барча* → *барча: Җирнең йөзе матурлана, кояш көлә, б о р ч а б ы з н ы ң тереклеге шуннан килә.* М. Гафури.

*бары* → *бары: Б а р ы с ы да Хәйдәр янына җыелдылар.* Г. Бәширов.

### *Саннарның исемгә күчүе*

Кайбер саннар һәм аларның формалары конверсия юлы белән исемнәргә күчәргә мөмкин. Саннар исемләшеп, төрле тематик төркемнәр хасил итә:

1. Кайбер саннар «ашамлык» мәгънәсендә исемләшә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *беренче* | | *беренче* |
| *икенче* | | *икенче* |
| *өченче* | | *өченче* |

Мәсәлән: *Б е р е н ч е г ә – аш аласың – син бер кисәк икмәк өчен акча түлисең, и к е н ч е г ә итле ризык – тагын бер кисәк түлисең,*

*ө ч е н ч е г ә – чәй, кесәл, кофе, сөт алган очракта, икмәк өчен түләмисең*. Ватаным Татарстан

2. «Нинди дә булса билгесез кеше» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *берәү* | | *берәү* |
| *кемдер* | | *кемдер* |

Мәсәлән: *Б е р ә ү яраланган килеш тә ут эченә керә*. Г. Гобәй.

3. «Җаваплы урыннарда эшләүче кеше» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *беренче* | | *беренче* |
| *икенче* | | *икенче* |

Мәсәлән: *Кабул итү бүлмәсендә күренүгә үк ярдәмче Б е р е н ч е - г ә хәбәр салырга кереп тә китте…* Р. Мирхәйдәров;

4. «Мәктәптә куела торган билге» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *бер* | | *бер* |
| *ике* | | *ике* |
| *өч* | | *өч* |
| *дүрт* | | *дүрт* |
| *биш* | | *биш* |

Мәсәлән: *Элек студентлар имтиханны ө ч к ә , д ү р т к ә яки б и ш к ә бирәләр иде... Ә хәзер – ө ч м е ң г ә , д ү р т м е ң г ә , ә кайсы хәтта ки б и ш м е ң г ә .* Мәзәк

5. «Комарлы уен» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *егерме бер* | | *егерме бер* |
| *алтмыш алты* | | *алтмыш алты* |

Мәсәлән: *Бер карчык үзенең карта уйнап эштән чыгып беткән улына: «Их улым, улым, шул «е г е р м е б е р » харап итте инде сине», – ди икән*. М. Гали.

6. «Акча» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *мең* | | *мең* |
| *миллион* | | *миллион* |
| *миллиард* | | *миллирд* һ.б.ш. |

Мәсәлән: *Беренче м е ң н е кулына тоткач, бер шешә сөт белән ак ипи алып, «бәйрәм өстәле» оештырды*. Г. Гыйльман.

7. «Уенның нәтиҗәсе» мәгънәсендә:

Мәсәлән:: *Магнитогорск «Металлург»ы икенче тапкыр Нижегородск «Торпедо»сын д ү р т к ә и к е исәбе белән җиңде*. Татарстан яшьләре.

8. «Сыйныф» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *беренче* | | *беренче* |
| *икенче* | | *икенче* |
| *өченче* | | *өченче* |
| *дүртенче* | | *дүртенче* |
| *бишенче* | | *бишенче* |
| *алтынчы* | | *алтынчы:* |
| *унберенче* | | *унберенче* |

Мәсәлән: *Бервакытны а л т ы н ч ы д а укыганда, ахрысы, тарих дәресендә ислам диненең барлыкка килүе дигән теманы үткәч, ул инәсе белән дин турында, Алла турында бәхәс куертып җибәрде* Н. Фәттах.

9. «Ел» мәгънәсендә:

Мәсәлән: *К ы р ы к б е р н е ң июнь-октябрь айларында сугышка алынганнарның күпчелеген мылтыктан да ата белмәгән көйләренә Мәскәү оборонасына тыктылар*. З. Зәйнуллин.

10. «Йөз, гасыр» мәгънәсендә:

Мәсәлән: *Бу стиль, XVI йөзгә һәм XVII йөзнең беренче яртысына хас стиль белән чагыштырганда, сыйфат ягыннан түбәнрәк дәрәҗәдә*... И. Һадиев.

11. «Мөселман халыкларында тәгъзия, ягъни туганнарның кайгысын уртаклашу һәм мәрхүмне искә алып, аның рухына дога кылу мәҗлесләре» мәгънәсендә:

| **саннар** | → | **исемнәр** |
|---|---|---|
| *өч* | | *өчесе* |
| *җиде* | | *җидесе* |
| *кырык* | | *кырыгы* |

Мәсәлән: *Татар мохитендә тәрбияләнмәсәләр, яшәмәсәләр дә, әниләре теләге буенча, Мәхмүт абыйның ө ч е с е н, җ и д е с е н, к ы р ы г ы н үткәрделәр.* М. Әхмәтҗанов

Әлеге саннар эллипсис нәтиҗәсе буларак һәм тартым кушымчасы алып исемләшкән. Монда *көн* сүзенең кыскаруы күзәтелә.

***Ияртемнәрнең исемнәргә күчүе***

Телдә ияртемнәрнең дә исемнәргә күчү очраклары күзәтелә:

*чытыр-чатыр → чытыр-чатыр: Ч ы т ы р - ч а т ы р җыеп, учак ягып җибәрү.* Сөйләм теленнән.

*чыш-пыш →чыш-пыш: Безнең сөйләшүне тыңлап торучылар арасында ч ы ш - п ы ш китте...* Г. Минский.

*кәккүк → кәккүк: Аларның сүзен сузып-сузып кычкыручы к ә к - к ү к тавышы бүлде: «Кәк-күк», «Кәк-күк»...* Г. Гыйльман.

*чыр-чу → чыр-чу: Колхоз төзүчеләр кереп-чыккан өйләрдән ч ы р - ч у, елаш-каргыш ишетелгәч төшенде моңа Хәбиб.* Р. Гыйззәтуллин. *Куаклыкка якынлашуга, ч ы р - ч у көчәйде.* И. Салахов.

*шау-шу шау-шу: [Зөһрә] ... экрандагы ш а у - ш у г а төбәлде.* Г. Гыйльман.

*шаңгыр →шаңгыр: Ш а ң г ы р яратмаган кеше тимерче алачыгына кермәс.* Әйтем.

*мияу →мияу: Бас әле м и я у, м и я у, Бул син һәрчак уяу...* Т. Миңнуллин.

*гөр-гөр → гөр-гөр* (балалар уены); *Балалар г ө р - г ө р уйнадылар.* Сөйләм теленнән.

*шөлдер→ шөлдер* (кыңгырау): *...Тальян, ш ө л д е р тавышына эт заты чыдый алмый.* М. Мәһдиев.

Мисаллардан күренгәнчә, ияртемнәр исемләшү телдә бик продуктив күренеш.

## Лексик-семантик ысул белән исемнәр ясалышы

Татар телендә ясаучы нигезнең семантикасы аерылу юлы белән дә яңа сүзләр ясала. Бу очракта яңа сүз бер үк сүз төркеме эчендә барлыкка килә: *тамыр* (*үсемлек тамыры*) – *тамыр* (математикада). Лексик-семантик ысул белән яңа сүз ясалганда, сүзләр омонимлаша. Алар сүзлектә рим цифрлары белән аерым сүз итеп бирeләләр. Очраклы рәвештә матда яктан туры килгән омоним сүзләр сүзьясалышны тәшкил итмиләр: *ял* (*атта*) – *ял* (*ял итү*).

Тюркологиядә сүзьясалышның лексик-семантик ысулын АН. Кононов, Н.А. Баскаков, Б.О. Орузбаева, Г.С. Садвакасов, Е.Н. Шипова, М.А. Хабичев һ.б. күрсәтеп китәләр. Татар тел белемендә аңа В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева, Ф.С. Фасиев игътибар итәләр.

Татар телендә лексик-семантик ысул белән сүзьясалышның түбәндәге төрләре бар:

**1. Кеше әгъзасы атамасы → зат атамасы**

*кул* — *кул* (эшче көч)
*буын* — *буын* (кешеләр яшәешендә)
*тамак* — *тамак* (ашаучы)

**2. Әйбер атамасы → зат атамасы**

*итәк* — *итәк* (хатын-кыз)

**3. Йорт атамасы → коллектив атамасы**

*өй* — *өй* (гаилә)

**4. Конкрет предмет → авыру атамасы**

*арпа* — *арпа*
*чәчәк* — *чәчәк*

**5. Күк җисемнәренең атамасы → вакыт атамасы**

*ай* — *ай* (исәбе)
*көн* (иск.) — *көн* (якты көн)

**6. Әгъза атамасы → корал атамасы**

*терсәк* — терсәк (техн.)
*каш* — *каш* (йөзектә)
*аяк* — *аяк* (савыт)

| **7. Әгъза атамасы** | → | **урын атамасы** |
|---|---|---|
| *култык* | | *култык* (геогр.) |
| *борын* | | *борын* (геогр.) |
| *бугаз* | | *бугаз* (геогр.) |
| *бил* | | *бил* (геогр.) |
| *түбә* | | *түбә* (геогр.) |

Семантик омонимнар барлыкка килүдә, фактлар күрсәткәнчә, түбәндәге факторлар ята.

1. Теге яки бу дәрәҗәдә билгеләрнең охшашлыгы (яки охшашландыру):

| | | |
|---|---|---|
| *арпа* | → | *арпа* |
| *сакал* | → | *сакал* (бизәнү әсбабы) |
| *түбә* | → | *түбә* |

2. Метонимия күренеше:

| | | |
|---|---|---|
| *итәк* | → | *итәк* |
| *туп* | → | *туп* |

3. Эчке сыйфатның охшашлыгы:

| | | |
|---|---|---|
| *хәбәр* | → | *хәбәр* (грамматикада) |
| *ия* | → | *ия* (грамматикада) |
| *тамыр* | → | *тамыр* (математикада) |

## 9.6. ФИГЫЛЬЛӘР ЯСАЛЫШЫ

### 9.6.1. Фонетик ысул ярдәмендә фигыльләр ясалышы

Кайбер фигыльләр татар телендә фонетик ысул белән ясалганнар. Авазларның чиратлашуы белән, мәсәлән, түбәндәге фигыльләр хасил булган: *түн → дүн, йалтыра → йылтыра, бәр → бир.*

Нигезләрнең палатальләшү (нечкәрү) юлы белән барлыкка килгән фигыльләр: *тырнаклан → тернәклән, чыңла → чеңлә, сук → сүк, токкар → төткәр, сылта → селтә, сыпыр → себер, пыч → печ, яраш → ярәш.*

### 9.6.2. Кушымчалау ысулы белән фигыльләр ясалышы

Беренче төрки грамматикаларда ук фигыль ясаучы кайбер кушымчалар күрсәтелә. Мәсәлән, А. Казимбәк грамматикасында – 4, Алтай миссиясе грамматикасында 6 фигыль ясаучы кушымча китерелә. Тора-бара төрки грамматикаларда карала торган фигыль ясаучы кушымчаларның саны арта бара. О. Бётлингк – 16, Н.И. Ашмарин 12 фигыль ясаучы кушымчага туктала.

М. Терентьев, В. Гордлевский, А.Ш. Караханов юнәлеш категориясе формаларын хасил итүче кушымчаларны, мөстәкыйль фигыль ясаучы кушымчалар, дип карыйлар. Әмма саф фигыльләр ясалышын алар тикшермиләр. П.М. Мелиоранский үзенең грамматикасында фигыль ясаучы 8 кушымча китерә. Н.Ф. Катанов, С.В. Ястремский, Н.К. Дмитриев фигыль ясалышына юнәлеш категориясе ясалышын да кертәләр.

XX гасырның 40–60 нчы елларында инде күпчелек төрки грамматикаларда юнәлеш формалар ясалышы мөстәкыйль фигыльләр ясалышыннан аерып алына. Н.П. Дыренкова – 16, Л.Н. Харитонов – 10, Н.А. Баскаков – 13, А.Н. Кононов – 24 мөстәкыйль фигыль ясаучы кушымчаны тикшерәләр. Үзбәк теле грамматикасында 17 фигыль ясаучы кушымча китерелә, аларның өчесе чынында фигыльнең формаларын ясаучы булып торалар (*-сыра, -кыра, -келә*). Анда кушымчаларның мәгънәләре тулырак ачыла.

XX гасырның соңгы елларында чыккан төрки грамматикаларда фигыль ясалышына нык игътибар ителә. «Хәзерге казакъ теле» (рус телендә), «Төрекмән теле грамматикасы» (рус телендә), «Азәрбайҗан теле грамматикасы» (рус телендә) дигән коллектив хезмәтләрдә ясаучы нигезләрнең нинди сүз төркемнәре белән килүе күрсәтелә, кушымчаларның төп мәгънәләре ачыла.

Тюркологиядә кушымчалар белән фигыльләр ясалышына багышланган махсус хезмәтләр дә бар. Биредә иң башта Э.В. Севортянның капиталь хезмәтен, С. Джафаров монографиясенең бер бүлеген һәм В.А. Исенгалиева монографиясен күрсәтергә кирәк. С. Джафаров китабында фигыль ясаучы шактый күп – 38 кушымча тикшерелә, аларның ясаучы нигезләре күрсәтелә. Ләкин юнәлеш категориясенең форма ясаучы кушымчалары һәм лексик-грамматик категория тәшкил иткән эш-хәрәкәт ысулы кушымчалары мөстәкыйль фигыль ясаучылар дип карала.

Э.В. Севортянның фундаменталь хезмәтендә азәрбайҗан теленең билгеләргә мөмкин булган барлык фигыль ясаучы кушымчалары тикшерелә, шулай ук борынгы ядкарьләрдән һәм башка төрки телләрдән материаллар китерелә, төрки телләрдә фигыль ясалышына караган яңа теоретик положениеләр куела. Э.В. Севортян монографиясенең иң төп һәм мөһим якларыннан берсе – кушымчалар ярдәмендә фигыльләр ясалышын системалы һәм аларның төзелешенә бәйләп өйрәнү, барлык кушымчаларның мәгънәләрен ясаучы нигезләрдән чыгару. Төрки телләрдәге сүзьясалышны өйрәнүдә мондый юнәлеш беренче буларак Э.В. Севортяннан башлана[1].

В.А. Исенгалиеваның китабы рус теленнән алынган нигезләрдән фигыльләр ясалышына багышланган. Хезмәттә мондый фигыльләр ясалышы бик җентекле тикшерелгән.

XIX гасыр башы татар теле грамматикаларында фигыль ясаучы кайбер кушымчалар күрсәтелә. Әмма аларның мәгънәләре йә бөтенләй ачылмый, яисә бик гомуми планда гына бирелә.

XIX гасырдагы грамматикаларның кайберләрендә грамматик күренеш булган юнәлеш категориясе ясалышы, традиция буенча, фигыльләрдән мөстәкыйль фигыльләр ясалышы дип өйрәнелә.

XX гасыр башында чыккан грамматикаларда кушымчалар ярдәмендә фигыльләр ясалышын өйрәнүдә җитди яңалыклар күзәтелми. Соңгы елларда чыккан грамматикаларда фигыль ясаучы төп кушымчалар тикшерелә, әмма аларның мәгънәләре ясаучы нигезләрдән чыгып ачылмый.

Күренекле тел галиме Ш.А. Рамазановның «Татар телендә фигыльләр ясалышы» дигән тирән эчтәлекле хезмәтен аерып күрсәтеп китәргә кирәк. Анда татар телендә фигыльләр ясалышы һәрьяклап бик киң итеп тикшерелә, структур яктан ясаучы нигезләрдән аерыла ала торган 22 кушымча анализлана. Бу хезмәтнең кыйммәте тагы шунда, анда вариантлары белән санаганда 120 үле кушымчаның исемлеге мисаллар белән китерелә.

Мәгълүм булганча, хәзерге татар телендә кушымчалау ысулы белән фигыльләр ясалышы иң продуктив ысулларның берсе булып тора.

---

[1] Севортян Э.В. Аффиксы глаголообразования в азербайджанском языке. М., 1962. 96 с.

### *Продуктив типлар*

**Нигез + *-ла/-лә* кушымчасы.** Борынгы төрки телдән үк килгән *-ла*/*-лә* кушымчасы – хәзерге татар телендә иң күп фигыль ясаучы кушымча. Бу кушымча барлык төрки грамматикаларда да күрсәтелә.

Тюркологиядә аның килеп чыгышы турында берничә фараз бар. «Алтай грамматикасы» авторлары һәм Г.И. Рамстедт, *-ла*/*-лә* кушымчасы генетик яктан атрибутив – *лы* кушымчасы белән бәйләнгән, дип саныйлар. Казакъ теле галиме А.К. Хасенова бу кушымчаны, мөстәкыйль мәгънәле *-де*/*-те* (*ди, диде*)сүзеннән килеп чыккан, ди.

В. Котвич һәм А.Г. Голәмев *-ла*/*-лә* кушымчасын *-лан* кушымчасы белән бәйлиләр.

Н. Остроумов *-ла* кушымчасын *айла* (*эшлә*) сүзеннән чыгара. Ләкин, А.Н. Кононов бик дөрес әйткәнчә, «бу фараз бернәрсә дә ачыкламый, чөнки *айла* сүзе үзе = *ай+ла*».

Ж. Дени фаразынча, *-ла* кушымчасы ике компонентка бүленә: *-л* + *-а* биредә төп элемент булып *-а* тора, *-л* элементы исә ясаучы нигезнең үзгәрүеннән килеп чыккан.

*-ла* кушымчасы бик борынгы кушымча булганлыктан, аның этимологиясен билгеләү шактый кыен. Бары кайбер кыек мәгълүматлар нигезендә генә бу кушымчаның килеп чыгышы турында фикер йөртергә була.

Татар телендә ясалма фигыльләр хасил итүдә фигыльләр (соңыннан ярдәмче фигыльләр) шактый урын алып торган, тора-бара акрынлап алар сүзьясагыч кушымчага әйләнгәннәр. Мәсәлән, *югал, төзәл, карал* фигыльләре *бул* (фонетик варианты *ул*) фигыле ярдәмендә ясалганнар: *югал=юк+ул, төзәл=төз+ул, карал=кара+ул* һ.б.

*-р, -ар*/*-әр* сүзьясагыч кушымчасы *агар, күгәр, кызар, яңар, яхшыр* кебек фигыльләрдә борынгы төрки телдәге *и* (*ирде, ирсә*) фигыленә барып тоташа.

*-ай*/*-әй* кушымчасы *матурай, зурай, саргай, шәбәй, күбәй* кебек фигыльләрдә *и* (*ирсә, ирде*) фигыленең фонетик үзгәргән вариантыннан башка бернәрсә дә түгел.

*-т*/*-ыт*/*-ет* кушымчасы *җылыт, суыт* кебек фигыльләрдә *ит* ярдәмче фигыленә кайтып кала, *ит* фигыле үзе исә тарихи яктан *и* (*ирсә, ирде*) фигыленең йөкләтү юнәлеше формасы булып тора.

Моннан күренгәнчә, хәзерге көндә фигыль ясаучы күп кенә кушымчалар телнең борынгы хәлендә үзләре фигыль булганнар. Шуңа күрә *-ла* кушымчасының да, бу яктан чыгарма булмыйча, нинди дә булса бер борынгы фигыльгә барып тоташуы бик мөмкин. Мәгънәсе һәм тышкы күренеше буенча мондый фигыль итеп борынгы *и* (*ирсә, ирде*) фигылен карарга була. Моның шулай булуы түбәндәге фактлардан күренә. *Көйрә, шалтыра, челтерә, йалтыра, йылтыра, мөңрә* кебек фигыльләрдә *-ра/-рә* кушымчасы *и* (*ирсә, ирде*) фигыленең фонетик үзгәрешенең нәтиҗәсен тәшкил итә. Бу фигыльләр *көй, шалт, челтер, йалтыр, йылтыр, мөң* (мү) нигезләреннән ясалганнар. Мәгълүм булганча, *-ра/-рә* кушымчасы белән *-ла/-лә* кушымчасы арасындагы генетик бәйләнеш барлыгы тюркологиядә шик астына алынмый.

Шулай итеп, теге яки бу дәрәҗәдәге ихтималлык белән *-ла/-лә* кушымчасын этимологик яктан *и* (*ирсә, ирде*) фигыле белән бәйләнгән дип уйларга була. *-ра/-рә* кушымчасындагы *р* авазы *-ла/-лә* кушымчасында *л* авазына әйләнгән дип фараз итәргә мөмкин.

*-ла/-лә* кушымчасының ясаучы нигезләре булып исемнәр, сыйфатлар, иялтемнәр килә. Шулай ук беркадәр дәрәҗәдә ясаучы нигезләр буларак саннар, рәвешләр, ымлыклар, хәбәрлекләр һәм алмашлыклар да килә.

*-ла/-лә* кушымчасының ясаучы нигезләре булып түбәндәге сүз төркеменә кергән сүзләр килә:

– исемнәр: *эш+лә, ау+ла, камыт+ла, чүкеч+лә, кыргыч+ла, дага+ла, җиһаз+ла, җилем+лә;*

– сыйфатлар: *кук+лә, йөнтәс+лә, сирәк+лә, кадерсез+лә, чатан+ ла;*

– иялтемнәр: *чың+ла, чыр+ла, без+лә, мыр-ла;*

– ымлыклар: *әйдүк+лә, зинһар+ла;*

– рәвешләр: *соң+ла, җәяү+лә, иртә+лә;*

– хәбәрлекләр: *жәл+лә, бар+ла;*

– фигыльләр: *үчек+лә, бөк+лә, көй+лә.*

Хәзерге татар телендә составында *-ла/-лә* кушымчасы булган күп кенә фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел, ягъни ул нигезләр телдә мөстәкыйль кулланылмыйлар. Мөгаен, алар кайчандыр мөстәкыйль булгандыр, әмма хәзерге көндә аларның кайсы сүз төркеменә каравы һәм конкрет мәгънәсе ачык түгел: *чәрдәклә, дөмбәслә, сайла, эрлә, шүрлә, шәйлә.*

Структурасы ягыннан *-ла/-лә* кушымчасының ясаучы нигезләре тамыр, кушымчалы һәм кушмада булырга мөмкин.

Тамыр булган ясаучы нигезләр: *чама+ла, чүп+лә, шау+ла, көй+лә, кыш+ла, аң+ла.*

Кушымчалы булган ясаучы нигезләр: *җәенке+лә, үткен+лә, болганчык+ла, кыргыч+ла, сизем+лә, тузгак+ла.*

Кушма сүз булган ясаучы нигезләр: *билбау+ла, акбур+ла, чүпчар+ла.*

*-ла/-лә* кушымчасының күпчелек ясаучы нигезләрен тамыр сүзләр тәшкил итә.

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып чыганак тел ягыннан саф татар сүзләре дә, алынмалар да килә.

Саф татар сүзләре булган ясаучы нигезләр: *болыт+ла, борау+ла, кыр+ла, буй+ла, ак+ла, каршы+ла, нигез+лә, сагыш+ла.*

Ясаучы нигезләр булып түбәндәге телләрдән алынган сүзләр килергә мөмкин:

Европа телләреннән (рус теле аша): *эксплуатация+лә, трансформация+лә, озон+ла, брикет+ла, патент+ла.*

Рус теленнән: *расход+ла, прокат+ла, каток+ла, забой+ла.*

Гарәп һәм фарсы телләреннән: *газап+ла, дәва+ла, вәгазь+лә, гаеп+лә, хикәя+лә, тәнкыйть+лә, сихер+лә, сөрмә+лә.*

Башка телләрдән: *ыспай+ла* (һинд теленнән), *нукта+ла* (монгол теленнән), *көй+лә* (кытай теленнән).

Фактлар күрсәткәнчә, *-ла/-лә* кушымчасы белән ясалган фигыльләрнең бер, сирәк кенә ике һәм аннан да күбрәк мәгънәсе була. Мәсәлән, ясаучы нигез булып торган *баш, күз, аш* кебек сүзләрнең хәзерге татар телендә мәгънәләре шактый күп. Бу нигезләрдән ясалган фигыльләрнең мәгънәсе бары бер-ике генә: *ашлау* (басуны ашлау), *күзләү* (карау һәм ялгау), *башлау* (эшне башлау).

Фигыльләр ясаучы нигезнең туры мәгънәсеннән түгел, күчмә мәгънәсеннән ясалырга мөмкин. Мәсәлән, *нигезлә* фигыле ясаучы нигезнең туры мәгънәсеннән (фундамент, нигез) түгел, ә күчмә мәгънәсеннән (аргумент, дәлил) ясалган.

Кушымча белән ясалган фигыльләрдә еш кына ясаучы нигездән килеп чыкмаган мәгънә очрый. Мәсәлән, *майла* фигылендә, «берәр нәрсә майлау» мәгънәсеннән тыш, «ришвәт бирү» мәгънәсе дә бар.

Бу фигыльнең икенче мәгънәсе сүзьясалыш нәтиҗәсе түгел, чөнки *май* сүзендә *ришвәт* мәгънәсе юк. Күчмә мәгънә фигыльнең семантикасы үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Шулай итеп, фигыльнең күп мәгънәлелеге һәрвакытта да кушымчалау ысулының нәтиҗәсе булып тормый. *-ла/-лә* кушымчасы белән ясалган кайбер фигыльләрнең семантик структурасы бүгенге көн күзлегеннән ачык түгел: *ташла, якла, юлла, үпкәлә.* Боларның бүгенге мәгънәләре аларның структурасыннан килеп чыкмый һәм ясаучы нигезләрнең мәгънәләре белән турыдан-туры бәйләнми. Ләкин телнең борынгы хәлендә бу фигыльләрнең семантик структурасы ачык булган, һәм, һичшиксез, бу сүзләрнең мәгънәләрен тарихи планда тикшереп карaганда, аларның семантик төзелешен аңлатып була. Мәсәлән, *ташла* фигыле иң башта *таш ыргыту* мәгънәсен белдергән, вакытлар үтү белән аның семантикасы киңәйгән, һәм ул *гомумән ташлауны* белдерә башлаган. Мондый фигыльләр тел белемендә махсус тикшерелергә тиешләр.

*-ла/-лә* кушымчалы фигыльләр күчемле дә (*тышла, җизлә, көмешлә, бораула, имлә, дәвала, алтынла, эксплуатациялә*), күчемсез дә (*эренлә, яңгырла, шаула, чирлә, тавышла, зыңла*) булырга мөмкиннәр. Әйтеп китәргә кирәк, мондый кушымча белән килгән фигыльләрнең күпчелеге күчемле булалар.

*-ла* кушымчасы калын нигезләргә, *-лә* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана.

I. Исемнәргә кушылып, ул түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтне башкаруны: *алкышла, исбатла, фикерлә, эшлә.*

2. Кемне яки нәрсәне дә булса ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә дучар итүне: *җәзала, җәберлә, назла, имлә.*

3. Кемне яки нәрсәне дә булса ясаучы нигез белдергән матдә тәэсиренә дучар итүне: *агула, борычла, кайрыла, көллә.*

4. Ясаучы нигез белдергән материал белән каплауны, көпләүне, киртәләүне: *күнлә, пыялала, алтынла, көмешлә.*

5. Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән тәэмин итүне: *җимлә, энҗелә, бүләклә.*

6. Ясаучы нигез белдергән предмет формасын бирүне: *челтәрлә, кирпечлә, кырла, гофрла*.

7. Ясаучы нигез белдергән корал белән эш итүне: *өтелә, бораула, пычакла, игәүлә, тырмала.*

8. Ясаучы нигез белдергән әйберне беркетүне яки шул әйбер белән ныгытуны: *сапла, дагала, болтла.*

9. Ясаучы нигез белдергән затка яки хайванга хас булган яки хас дип саналган эш-хәрәкәтне башкаруны: *кияүлә, каравылла, кунакла, кәҗәлә, юргала.*

10. Ясаучы нигез белдергән нәрсәдән арындыруны: *кишәнкелә, төплә, кылла.*

11. Ясаучы нигез белдергән чир белән авыруны: *маңкала* (ат турында), *кычула, тимрәүлә.*

12. Берәр нәрсәне ясаучы нигез белдергән үлчәү белән үлчәүне: *буйла, карышла, метрла, мыскалла.*

13. Ясаучы нигез белдергән табигать күренешенең башкарылуын: *яшенлә, җиллә, давылла.*

14. Ясаучы нигез белдергән кеше яки хайван баласын тудыруны: *бәрәнлә, колынла, балала.*

15. Ясаучы нигез белдергән урынга сугуны яки тәэсир итүне: *яңакла, түбәлә, җилкәлә.*

16. Ясаучы нигез белдергән вакытны уздыруны: *җәйлә, кышла, көзлә.*

17. Ясаучы нигез белдергән вакытның башлануын: *кичлә.*

18. Ясаучы нигез белдергән урында хәрәкәт итүне: *үрлә, буйла, салула.*

19. Кемне яки нәрсәне дә булса ясаучы нигез белдергән хәлгә китерүне: *гипнозла, электрла, магнитла.*

20. Ясаучы нигез белдергән хәлдә булуны: *сагышла, ваемла.*

21. Ясаучы нигез белдергән әйбергә әйләндерүне яки әйләнүне: *чүбеклә, мунчалала, йомычкала.*

22. Ясаучы нигез белдергән бөҗәкләрнең күпләп барлыкка килүен: *кортла, бетлә, көялә.*

23. Ясаучы нигез белдергән үзлек (сыйфат) бирүне: *тәмлә, яраула, иплә, куәтлә.*

24. Ясаучы нигез белдергән урынга куюны: *җирлә.*

25. Ясаучы нигез белдергән мөнәсәбәтне, үзлекне, сыйфатны күрсәтүне: *хөрмәтлә, санла, кадерлә.*

26. Ясаучы нигез белдергән тавышны һ.б.ш.ны барлыкка китерүне: *шаула, көйлә, җырла, тавышла.*

27. Ясаучы нигез белдергән ысул белән чикләүне, күрсәтүне: *тамгала, ызанла, билгелә, нормала.*

28. Ясаучы нигез белдергән бүлекләргә төркемләүне: *төркемлә, кисәклә, ишлә, парла.*

II. Сыйфатларга ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән сыйфатны (билгене) бирүне: *үткенлә, җәенкелә, чуарла, матурла, чибәрлә.*

2. Ясаучы нигез белдергән сыйфатны (үзлекне) алуны: *аксакла, акрынла, иркенлә.*

3. Ясаучы нигез белдергән мөнәсәбәтне (билгене) күрсәтүне: *иркәлә, назла, ирексезлә.*

III. Саннарга ялганып, ясаучы нигез белдергән сан кадәр төркемләүне белдерә: *икелә, өчлә, өчәрлә, унарла.*

IV. Ияртемнәргә ялганып, ясаучы нигез белдергән тавышка якын авазларны, тавыш чыгаруны яки образны тасвирлауны: *мияула, ула, кыйгакла, мыжла.*

V. Алмашлыкка ялганып, ясаучы нигез белдергән сүз белән мөрәҗәгәть итүне аңлата: *синлә.*

VI. Рәвешләргә кушылып, эш-хәрәкәтне ясаучы нигез белдергәнчә башкаруны аңлата: *җәяүлә, кулалмашла, кабатла.*

VII. Хәбәрлек сүзгә ялганып, ясаучы нигез белдергән мөнәсәбәтне күрсәтүне: *жәллә.*

VIII. Ымлыкларга кушылып, ясаучы нигез белдергән ымлыкны әйтүне: *зинһарла, әйдәлә, әйдүклә.*

**Нигез + *-лан/-лән*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-лан,* нечкә нигезләргә *-лән* кушымчасы ялгана.

Кайбер тюркологлар бу кушымчаны кайтым юнәлеше кушымчасы дип карыйлар. Бер иш тикшеренүчеләр аны бөтенләй аерым кушымча дип санамыйлар. Бары Э.В. Севортянның фигыльләргә багышланган хезмәтләреннән соң гына аны мөстәкыйль сүзьясагыч кушымча рәтенә кертә башладылар. Аның составы бик ачык, ул *-ла* һәм *-н* элементларыннан тора, *-ла* кисәге фигыль процессын, *-н* кисәге ул процесска күчемсезлек мәгънәсен бирә. Хәзерге көндә фигыль ясаучы бербөтен кушымча тәшкил итә. Төрки телләрдә аның барлыкка килүен Э.В. Се-

вортян бик ышандыргыч итеп аңлата: *-ла* кушымчасы белән фигыльләр ясалышы процессында эш-хәрәкәтнең тышкамы яки эчкәме юнәлешен (көчемлелекне һәм көчемсезлекне) белдерү ихтыяҗы килеп чыга. Азәрбайҗан телендә исемнән фигыльләр ясаучы яңа *-лан/-лән* кушымчасы хасил була. Бу кушымча эчкә юнәлгән эш-хәрәкәтне белдерә башлый.

Бу сүзьясагыч кушымчаны төшем юнәлеше кушымчасы *-ла+-н* кушымчасы белән бутарга ярамый. Шул ук ясаучы нигездән *-ла* кушымчалы фигыль булмаса, *-лан* кушымчасы сүзьясагыч кушымча булып тора. Мәсәлән, *батыр* ясаучы нигезеннән *батырлан* фигыле ясала, ләкин *батырла* дигән фигыль телдә юк, шуңа күрә *батырлан* фигыле нинди дә булса фигыльнең юнәлеш формасы итеп берничек тә карала алмый.

Әмма бу кагыйдәдән чыгармалар бар. Беренчедән, кайчак *-лан* кушымчалы фигыль юнәлеш формасы булмыйча, гәрчә телдә шул ук ясаучы нигездән *-ла* кушымчалы фигыль яшәсә дә, мөстәкыйль фигыль тәшкил итәргә мөмкин: *балала* һәм *балалан, икелә* һәм *икелән, бәйлә* һәм *бәйлән.*

Бу фигыльләр арасында үзара лексик-семантик бәйләнеш юк, ягъни *балалан* фигыле *балала* фигыленнән килеп чыкмыйча, *бала* дигән ясаучы нигездән *-лан* кушымчасы белән ясалган. Шуның өчен *балалан* фигылен берничек тә юнәлеш формасы дип карап булмый. *Балалан* фигыленең мәгънәсе ясаучы нигез белән бәйләнгән, бу сүзнең мәгънәсе *-лан* кушымчасының мәгънә системасына һәм структурасына керә: *циркачлан, хайванлан, клоунлан, диваналан.*

Икенчедән, *-лан* кушымчасы белән ясалган кайбер фигыльләрдә, юнәлеш категориясе белән беррәттән, лексик мәгънә дә күзәтелә: *ваклану* 1) төш. юн. *ваклау*, 2) күч. вак кеше булу; *иплән*ү 1) төш. юн. *ипләү*, 2) күч. төзелү; *төймәләнү* 1) төш.юн. *төймәләү*, 2) җимеш яралгысы барлыкка килү; *чарлану* 1) төш. юн. *чарлау*, 2) тәҗрибәлеге әйләнү; *известьләнү* 1) төш.юн. *известьләү*, 2) *известькә әйләнү*.

Бу ике төрле тел күренешен аеру өчен нинди критерийлар бар соң? Әгәр *-лан* кушымчалы фигыльнең ясаучы нигез белән семантик бәйләнеше булса, шул вакытта ул мөстәкыйль фигыль-лексик берәмлек тәшкил итә. Мәсәлән, *ваклан, эрелән, төймәлән* кебек фигыльләрнең

лексик мәгънәсе тулысынча аларның ясаучы нигезләреннән килеп чыга: *вак* (вак кеше), *эре* (эре кеше), *төймә* (җимеш яралгысы). Бу очракта *-лан* кушымчалы юнәлеш формасы (*ваклан – акча вваклана*) һәм мөстәкыйль фигыль булган *ваклан* (*бу кеше ваклана*) үзләренең составында бер үк нигез булса да, алар төрле яссылыктагы берәмлекләр булып торалар.

Әгәр *-лан* кушымчалы фигыльләрнең ясаучы нигез белән семантик бәйләнеше булмаса, ул вакытта андый фигыльләрнең мәгънәсе юнәлеш формасының семантик үсеше яисә *-н* кушымчасының сүзьясагыч мәгънәсе булып тора: *чарлан* 1) *төш. юн.* чарла, 2) *күч.* тәҗрибәле кешегә әйләнү; *сабынлан* 1) *төш .юн.* сабынла, 2) нык тирләү (*ат турында*). Һичшиксез, китерелгән фигыльләрнең күчмә мәгънәләре *чар, сабын* кебек ясаучы нигезләрдән килеп чыкмаганнар. Бу мисалларда фигыльләрнең мәгънәләре сүзнең семантик үсешенең нәтиҗәсе булып тора, яисә *-н* кушымчасының ике функциялелегеннән килеп чыга.

Шуның белән бергә *-лан* кушымчалы кайбер фигыльләр ике юнәлеш мәгънәсен – төшем һәм кайтым мәгънәсен белдерергә мөмкин: *бөдрәлән* 1) *төш. юн.* бөдрәлә; 2) *кайт. юн.* бөдрәлә; *сафлан* 1) *төш. юн.* сафла; 2) *кайт. юн.* сафла; *туплан* 1) *төш. юн.* тупла; 2) *кайт. юн.* тупла. Билгеле булганча, тел белемендә гомумән кайтым юнәлеше лексик күренеш дип карала.

*-лан/-лән*$_2$ кушымчасының ясаучы нигезләре булып исемнәр, сыйфатлар, фигыльләр һәм саннар килә:

– исемнәр: *сабак+лан, миләш+лән, шамакай+лан, төлке+лән, дус+лан, кибәк+лән, канат+лан, кул+лан, тез+лән, дәрт+лән, дулкын+лан;*

– сыйфатлар: *чандыр+лан, саңгырау+лан, миңгерәү+лән, үҗәт+лән, битсез+лән, кырыс+лан;*

– фигыльләр: *бута+лан, үртә+лән;*

– саннар: *ике+лән, икенче+лән.*

*-лан* кушымчалы кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре хәзерге көндә аерым кулланылмыйлар, шуңа күрә аларның лексик-грамматик асылын билгеләве кыен: *сырпа+лан, ярга+лан, чәбәк+лән, өтә+лән, каба+лан.* Әлбәттә, кайчандыр монда китерелгән нигезләр мөстәкыйль мәгънәле сүзләр булгандыр.

*-лан/-лән*$_2$ кушымчасы тамыр, кушымчалы һәм кушма сүзләргә ялганып фигыльләр ясый:

– тамыр сүзләр: *шат+лан, сәер+лән, мут+лан, шук+лан;*

– кушымчалы сүзләр: *ярма+лан, булдыксыз +лан, басынкы+лан, битсез+лән, телчән+лән;*

– кушма сүзләр: *беркатлы+лан, башбаштак+лан, икейөзле+лән.* Чыганак тел ягыннан караганда, ясаучы нигезләр булып саф татар сүзләре дә, алынмалар да килә:

– саф татар сүзләре: *әтәч+лән, моң+лан, тамыр+лан, кул+лан, ерткыч+лан, ат+лан, корт+лан, көя+лән, көчсез+лән, сизгер+лән;*

– рус теле аша европа телләреннән кергән сүзләр: *либерал+лан, нерв+лан, попугай+лан, педант+лан, сентименталь+лән;*

– гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр: *шөгыль+лән, өмет+лән, ризык+лан, рия+лан, хыял+лан, файда+лан, гөнаһ+лан, дәва+лан, горур+лан, фәкыйрь+лән.*

Кушымчаның ясаучы нигезләре арасында рус сүзләре сирәк очрый: *задор+лан.*

I. *-лан/-лән* кушымчасы исемнәргә ялганып түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән затка яки хайванга хас яки хас дип уйланган эш-хәрәкәтне башкаруны: *төлкелән, әтәчлән, куштанлан, шамакайлан, бозаулан, ишәклән.*

2. Ясаучы нигез белдергән затка әйләнүне: *либераллан, дуслан, батырлан.*

3. а) Ясаучы нигез белдергән әйбер хасил булуны: *җимешлән, юшкынлан, бөрелән, куаклан, тамырлан, кузаклан, кыяклан;*

б) ясаучы нигез белдергән нәрсәләргә ия булуны: *гаиләлән, коралլан, өйлән, корчаңгылан.*

4. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә әверелүне: *мөгезлән, ташлан, каешлан, бозлан, сазлан, тузанлан, булан, койкалан.*

5. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлекне, сыйфатны яки билгене күрсәтүне: *шөбһәлән, шомлан, әсәрлән, гарьлән, илһамлан, ачулан.*

6. Ясаучы нигез белдергән сыйфатны, үзенчәлекне, билгене алу: *ислән, сөтлән, иялән, сусыллан.*

7. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтләрне башкаруны: *шөгыльлән, файдалан, хәрәкәтлән, ялкынлан, кәсеплән, моңлан.*

8. Ясаучы нигез белдергән әгъза белән хәрәкәт итүне: *тезлән, терсәклән, аяклан.*

9. Ясаучы нигез белдергән әйбернең шәкелен алуны, шул шәкелгә керүне: *ясмыклан* (ясмык шәкелен алу); *дугалан* (дуга кебек булу), *күзәнәклән*(күзәнәк шәкелен алу); *борчаклан* (борчак шәкелен алу).

10. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә дучар булуны: *бурычлан, хаталан, гөнаһлан, чыгымлан.*

II. Сыйфатларга кушылып, ул түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлекне, билгене һәм сыйфатны күрсәтүне: *иләслән, шатлан, горурлан, ваклан.*

2. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлекне, билгене, сыйфатны алуны: *һәвәслән, тәкәбберлән, сусыллан, саңгыраулан, иплән, сизгерлән.*

*-лан/-лән* кушымчасы сыйфат, билге, үзенчәлек белдерә торган бер үк нигезгә ялганып, ике мәгънә белдерә торган фигыльләр ясарга мөмкин:

1) ясаучы нигез белдергән сыйфат, үзенчәлек, билгене алуны; 2) ясаучы нигез белдергән сыйфат һәм үзенчәлекне күрсәтүне: *саранлан* 1) саранга әйләнү, 2) саранлык күрсәтү; *зәһәрлән* 1) зәһәргә әйләнү. 2) зәһәрлек күрсәтү.

III. Саннарга кушылып, ясаучы нигез белдергән үзенчәлек алуны тәгъбир итә: *икенчелән, өчлән, икелән.*

IV. Фигыльләргә кушылып ясаучы нигез белдергән мәгънәдәге эш-хәрәкәтне башкаруны: *уртәлән, буталан.*

**Нигез + *-ландыр/-ләндер* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ландыр,* нечкә нигезләргә *-ләндер* кушымчасы ялгана. Бу кушымча ике кисәктән тора – сүзьясагыч *-лан* кушымчасыннан һәм йөкләтү юнәлеше кушымчасы *-дыр.* Хәзерге көндә ул бербөтен кушымчага әйләнгән: *газ+ландыр, газсыз+ландыр, җирсез+ләндер, йогышсыз+ландыр, шапшак+ландыр.* Күренгәнчә, *-ландыр* кушымчалы фигыльләрнең грамматик (йөкләтү юнәлеше) мәгънәсе юк. Бу кушымча исемнәргә һәм сыйфатларга ялганып, күчмә мәгънәле мөстәкыйль фигыльләр хасил итә. Мондый очракларда *-ландыр* кушымчалы фигыльләр шул ук ясаучы нигезләрдән *-ла* кушымчасы ярдәмендә ясалган фигыльләр белән алыштырыла ала, ягъни аларның мәгънәләре туры килә: *газландыр – газла, газсызландыр – газсызла, җиһазландыр – җиһазла,*

*шапшаклandыр – шапшакла.* Мисаллар күрсәткәнчә, ике очракта да йөкләтү юнәлеше мәгънәсе түгел, төп юнәлеш мәгънәсе белдерелә. Э.В. Севортян *-ландыр* кушымчасының барлыкка килүен фигыльләрнең тулысынча күчемле һәм күчемсезләргә аерылуы белән аңлата.

Әммә *-ландыр* кушымчалы мөстәкыйль фигыльләрне *-лан+дыр* кушымчалы йөкләтү формаларыннан аера белергә кирәк: *тезләндер, сөйлән+дер, икелән+дер.* Бу формалар ачыктан-ачык йөкләтү мәгънәсен белдерәләр һәм, кагыйдә буларак, мәгънәләре сакланган хәлдә шул ук ясаучы нигездән *-ла* кушымчасы ярдәмендә ясалган фигыльләр белән алыштырыла алмыйлар.

Кайбер тюркологлар, *-ландыр* кушымчасы бары йөкләтү мәгънәсен генә белдерә, дип саныйлар (А. Казимбәк, М. Хортен, Г. Янски). Бер төркем галимнәр бу кушымчаны тик фигыль ясаучы кушымча дип кенә карыйлар (А.Н. Кононов, Э.В. Севортян, А. Хасенова). Күп авторлар *-ландыр* комплекслы мөстәкыйль фигыльләрне һәм юнәлеш формаларын аермыйлар.

Мисаллардан күренгәнчә, *-ландыр* кушымчалы фигыльләр ике төрле өлкәгә карарга мөмкиннәр. Ләкин шуны әйтеп китәргә кирәк: *-ландыр* комплекслы юнәлеш формалары сирәк очрый.

*-ландыр* кушымчасының ясаучы нигезләре булып исемнәр һәм фигыльләр килә.

Ясаучы нигезләре исем булган фигыльләр: *газ + ландыр, бөр-тек + ләндер, орлык + ландыр, тап + ландыр.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган фигыльләр: *сәламәт + ләндер, йомры + ландыр, бактериясез + ләндер, җансыз + ландыр, күркәм + ләндер.*Чыганак тел ягыннан аның ясаучы нигезләре булып саф татар сүзләре дә, алынмалар да килергә мөмкин.

Ясаучы нигезләре саф татар сүзләре булган фигыльләр: *төзек+ ләндер, кытыршы+ландыр, йогышсыз+ландыр.*

Ясаучы нигезләре гарәп-фарсы сүзләре булган фигыльләр: *зәгыйфь+ләндер, канәгать+ләндер, пакь+ләндер, никах+ландыр.*

Ясаучы нигезләре рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләр булган фигыльләр: *бактериясез+ләндер, газ+ландыр.*

Исемнәргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән әйбер яки матдә тәэсиренә дучар итүне: *газландыр, дымландыр, серкәләндер, юешләндер.*

2. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә әйләндерүне: *мумияләндер, лайлаландыр, сазландыр, күбекләндер.*

3. Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән тәэмин итүне: *җиһазландыр, коралландыр, тапландыр.*

4. Ясаучы нигез белдергән шәкел бирүне: *йомрыландыр, бөртекләндер.*

5. Ясаучы нигез белдергән үзенчәлек, сыйфат һәм билге бирүне: *ямьләндер, тәмләндер.*

6. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә дучар итүне: *никахландыр, тәэсирләндер.*

Сыйфатларга ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән хәлгә китерүне: *тынычландыр, шатландыр, канәгатьләндер, татуландыр, куркынычсызландыр.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән билге, үзенчәлек бирүне: *үтмәсләндер, кытыршыландыр, көпшәкләндер, чуарландыр.*

Кушымчаның мәгънәләренә анализ ясау аның барлык мәгънәләренең *-ла* кушымчасының мәгънәләренә туры килүен күрсәтә. Бу хәл *-дыр* кушымчасының *-лан* кушымчалы күчемсез фигыльләрне күчемлегә әйләндерүе белән бәйләнгән булса кирәк. Мәгълүм булганча, бер үк ясаучы нигездән *-ла* һәм *-лан* кушымчасы белән ясалган фигыльләрнең, мәгънәләре якынча бер үк булып, аермалары аларның күчемле-күчемсезлеккә кайтып кала. *-дыр* кушымчасы *-лан* кушымчалы фигыльгә ялганганда, фигыльнең гомуми лексик мәгънәсе үзгәрми, күчемлелек ягыннан *-ла* кушымчалы фигыльгә якыная, бу хәл аларның мәгънәләренең параллельлеген китереп чыгара.

**Нигез+*-лаш/-ләш*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезгә *-лаш,* нечкә нигезгә *-ләш* кушымчасы ялгана. Бу кушымча ике кисәктән: фигыль ясаучы *-ла* кушымчасыннан һәм уртаклык юнәлеше *-ш* кушымчасыннан гыйбарәт, алар, бергә кушылып, бердәм морфема китереп чыгарганнар. Шуның белән бергә телдә уртаклык юнәлешен тәшкил иткән *-ла+ш* кушымчалы фигыльләр дә очрый.

Структурасы һәм семантикасы ягыннан да *-лаш* кушымчасы белән ясалган мөстәкыйль фигыльләр һәм *-ла* кушымчалы фигыльләрнең уртаклык юнәлеше формалары бер-береннән нык аерылалар. Фигыль ясаучы *-лаш* кушымчасы исем нигезләргә ялгана, һәм алардан «үзгәрү, үсү» мәгънәсендәге фигыльләр ясый: *кристал+лаш.* Кагыйдә буларак,

*-лаш* кушымчалы фигыльләрнең ясаучы нигезләреннән *-ла* кушымчалы фигыльләр барлыкка килми.

Уртаклык юнәлеше формалары ясалганда *-ш* кушымчасы *-ла* кушымчалы фигыльләргә ялгана, һәм ул лексик мәгънә түгел, грамматик мәгънә, бу очракта юнәлеш мәгънәсен белдерә: *эшлә+ш, ела+ш.* Бу кушымча соңгы вакытта гына, бары Э.В. Севортян тикшеренүләреннән соң гына мөстәкыйль морфема буларак күрсәтелә башлады.

*-лаш*$_1$ кушымчасының ясаучы нигезләре булып исемнәр һәм сыйфатлар килә.

Ясаучы нигезләре исем булган фигыльләр: *канун+лаш, гәп+ләш, борын+лаш, сер+ләш, низаг+лаш, дус+лаш.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган фигыльләр: *кискен+ләш, нормаль+ләш, хәрби+ләш, җиңел+ләш, рәсми+ләш, җитди+ләш.*

Чыгарма буларак, кушымчаның ясаучы нигезләре булып саннар (*бер+ләш*), ияртемнәр (*чыш-пыш+лаш*) һәм ымлыклар килергә мөмкин.

Кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел: *чәкә+ләш, әүмәк+ләш.*

Чыганак тел күзлегеннән караганда, ясаучы нигезләре саф татар сүзләре дә, алынмалар да булырга мөмкин.

Ясаучы нигезләре саф татар сүзләре булган фигыльләр: *кыен+лаш, ярак+лаш, туган+лаш, тел+ләш, саубул+лаш, бер+ләш.*

Ясаучы нигезләре гарәп-фарсы сүзләре булган фигыльләр: *җитди+ләш, гади+ләш, низагъ+лаш, мәслихәт+ләш, сәлам+ләш, мәдәни+ләш.*

Ясаучы нигезләре Европа телләреннән кергән сүзләр булган фигыльләр: *стабиль+ләш, либерал+лаш, бюрократ+лаш, климат+лаш, автомат+лаш.*

Ясаучы нигезләре рус теленнән алынган сүзләр булган фигыльләр: *яровой+лаш, суд+лаш.*

Исемнәргә кушылып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтне башкаруны: *сатулаш, гәпләш, бәхәсләш, киңәшләш, низагълаш, карулаш.*

2. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә әверелүне: *рәвешләш, мәкальләш, кристаллаш, гибридлаш.*

3. Ясаучы нигез белдергән шәхескә хас булган үзенчәлекне алуны: *дуслаш, туганлаш, либераллаш.*

4. Ясаучы нигез белдергән төркемгә оешуны: *колхозлаш, коллективлаш, әртилләш.*

5. Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән эш-хәрәкәт башкаруны: *күсәкләш, хәнҗәрләш, телләш.*

Сыйфатларга ялганып түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән юнәлештә үзгәрүне: *ераклаш, якынлаш, камилләш.*

2. Ясаучы нигез белдергән сыйфатны, үзлекне алуны: *суллаш, уңлаш, активлаш, стабильләш.*

Ымлыкларга ялганып ясаучы нигез белдергәнне әйтүне белдерә: *саубуллаш, сәламләш.*

**Нигез + *-лаштыр/-ләштер* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-лаштыр,* нечкә нигезләргә *-ләштер* варианты ялгана.

Бу кушымчаны элегрәк фигыль ясаучы мөстәкыйль кушымча дип санамыйлар иде. Бары А.Н. Кононов, А. Хасенова, Э.В. Севортян, В.А. Исенгалиева хезмәтләрендә генә ул тулы хокуклы сүзьясагыч кушымча дип карала. Соңгы төрки грамматикаларда *-лаштыр* кушымчасы үзенә урын тапмый.

Бу кушымча бер кушымча булып берләшкән ике кисәктән тора (*лаш+тыр*). *-лаштыр* комплексы фигыльләр мөстәкыйль дә, лексик берәмлек тә һәм йөкләтү юнәлеше формасы да булырга мөмкиннәр.

Юнәлеш формаларын ясаганда *-тыр* күрсәткече *-лаш* кушымчалы фигыльләргә ялгана һәм аларга йөкләтү мәгънәсе бирә: *сатулаш+тыр, низаглаш+тыр, судлаш+тыр, бәхәсләш+тер.*

Мөстәкыйль фигыльләр ясаганда *-лаштыр* комплексы исемнәргә, сыйфатларга һәм рәвешләргә ялгана, аларны яңа мәгънәле фигыльләргә әйләндерә: *закон+лаштыр, сәхнә+ләштер, кино+лаштыр, ара+лаштыр, мәңге+ләштер, хәрби+ләштер, татарча+лаштыр. -лаштыр* кушымчалы мөстәкыйль фигыльләрнең күпчелегенең *-лаш* кушымчалы мөнәсәбәттәш ишләре юк: *татарчалаштыр, кинолаштыр, сәхнәләштер, идеаллаштыр, гомумиләштер.*

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып исемнәр, сыйфатлар, рәвешләр һәм аерым авазлар килә:

– исемнәр: *план+лаштыр, район+лаштыр, механика+лаштыр, калька+лаштыр, алла+лаштыр, үзәк+ләштер, урын+лаштыр;*

– сыйфатлар: *нейтраль+ләштер, әдәби+ләштер, читен+ләштер, гади+ләштер, гомуми+ләштер;*

– рәвешләр: *татарча+лаштыр, казакъча+лаштыр, украинча+лаштыр;*

– авазлар исемнәре: *о+лаштыр, а+лаштыр, цы+лаштыр, җе+ләштер, йе+ләштер, ы+лаштыр.*

Тагын ясаучы нигезе сан булган *бер+ләштер* фигылен күрсәтергә була.

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләр булып саф татар сүзләре дә, алынмалар да килергә мөмкин.

Ясаучы нигезләре саф татар сүзләре булган фигыльләр: *борын+лаштыр, бер+ләштер, урын+лаштыр, үзәк+ләштер, ы+лаштыр, татарча+лаштыр.*

Ясаучы нигезләре рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләр булган фигыльләр: *реаль+ләштер, экран+лаштыр, радио+лаштыр, легаль+ләштер.*

Ясаучы нигезләре рус теленнән булган фигыльләр: *яровой+лаштыр, уҗым+лаштыр, совет+лаштыр, совхоз+лаштыр, колхоз+лаштыр.*

Ясаучы нигезләре гарәп-фарсы телләреннән булган сүзләр: *мәдәни+ләштер, рәсми+ләштер, җәмәгать+ләштер, мәркәз+ләштер.*

Бу кушымча исемнәргә ялганып түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән затка яки нәрсәгә әйләндерүне: *дуслаштыр, уҗымлаштыр, сәхнәләштер, туганлаштыр.*

2. Ясаучы нигез белдергән үзлек бирүне, берәр нәрсә белән тәэмин итүне: *телефонлаштыр, витаминлаштыр, механикалаштыр.*

3. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә дучар итүне: *колонизацияләштер, демократизацияләштер.*

4. Ясаучы нигез белдергән тәэсиргә дучар итүне: *борынлаштыр, иренләштер, климатлаштыр, электрлаштыр.*

5. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә берләштерүне: *колхозлаштыр, коллективлаштыр.*

6. Ясаучы нигез белдергән предметка хас сыйфатны яки үзенчәлекне бирүне: *схемалаштыр, ритмлаштыр, проектлаштыр, комплектлаштыр.*

7. Ясаучы нигез белдергән җиргә урнаштыруны: *урынлаштыр, диспансерлаштыр.*

Сыйфатларга ялганып ясаучы нигез белдергән үзенчәлек бирүне: *саңгыраулаштыр, мәдәниләштер, кискенләштер, әдәбиләштер.*

Рәвешләргә ялганып ясаучы нигез белдергән телгә тәрҗемә итүне: *татарчалаштыр, төрекчәләштер, русчалаштыр, кыргызчалаштыр.*

Авазларга ялганып тиешле аваз урынына ясаучы нигез белдергән башка авазны әйтүне: *җеләштер, олаштыр, еләштер.*

**Нигез + -*лат*/-*ләт* кушымчасы.** Бу кушымча ике кисәктән тора: фигыль ясаучы *-ла* һәм йөкләтү юнәлеше күрсәткече *-т* кушымчаларыннан.

Тюркологиядә бары кайбер тикшеренүчеләр генә (А.Н. Кононов, Э.В. Севортян) аны сүзьясагычка кертәләр.

*-лат* кушымчасы үзенең тышкы күренеше белән *-ла* кушымчалы фигыльләрдән *-т* кушымчасы белән ясалган йөкләтү юнәлеше *-ла+т* комплексын хәтерләтә (*барла+т, сапла+т*), биредә *-ла* һәм *-т* кушымчалары мөстәкыйль кушымчалар.

Исемнәрдән, сыйфатлардан *-лат* кушымчасы белән ясалган фигыльләр грамматик йөкләтү юнәлешен белдермиләр.

Ясаучы нигезләр булып исемнәр, сыйфатлар һәм сирәк кенә саннар, ымлыклар килә:

– исемнәр: *окись+лат, аң+лат, хәтер+ләт;*

– сыйфатлар: *яссы+лат, яшел+ләт, җиләс+ләт, күркәм+ләт;*

– саннар: *ике+ләт, өч+ләт;*

– ияртемнәр: *шарт+лат.*

Кайвакыт ымлыклар да ясаучы нигез булып килергә мөмкин: *өс+ләт.*

*-лат* кушымчалы кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре хәзерге көндә аерылмый: *чы+лат.*

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып, кагыйдә буларак, саф татар сүзләре килә: *кызу+лат, яшел+ләт, миңгерәү+ләт.*

Сирәк кенә булса да гарәп-фарсы сүзләре дә ясаучы нигез булырга мөмкин: *риза+лат, зәгыйфь+ләт. -лат* кушымчасы белән ясалган күпчелек фигыльләрнең *-ландыр* кушымчасы белән ясалган мөнәсәбәттәш ишләре бар: *зәгыйфьләт– зәгыйфьләндер, миңгерәүләт – миңгерәүләндер, кызулат – кызуландыр.* Телдә *-ландыр* кушым-

чалы фигыльләр *-лат* кушымчалы фигыльләргә караганда күбрәк кулланыла.

*-лат* кушымчасы, исемнәргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәгә әйләндерүне: *җепселләт, окисьләт.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән предмет тәэсиренә дучар итүне: *җилләт, тузанлат, төтенләт, корымлат.*

3. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт ясауны (шул нәтиҗәгә китерүне): *аңлат.*

Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигез белдергән билгене китереп чыгаруны: *кылыйлат, турылат, кәкреләт, яшелләт, күркәмләт, матурлат.*

Саннарга ялганып, ясаучы нигез белдергән кадәр бирәр нәрсәне ясауны: *икеләт, өчләт, дүртләт, унлат, йөзләт.*

Аваз ияртемнәренә ялганып, ясаучы нигез белдергән авазлар хасил итеп эш-хәрәкәт башкаруны: *шартлат, чыжлат, зырлат.*

Ымлыкларга ялганып, кемне дә яки нәрсәне дә булса ясаучы нигез белдергән ымлыкны әйтеп бирәр эш-хәрәкәт башкарырга мәҗбүр итүне: *өсләт, улат, ай-вайлат.*

**Нигез + *-ылда/-елдә* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ылда,* нечкә нигезләргә *-елдә* кушымчасы ялгана. Күпчелек тюркологларның фикеренчә, бу кушымча *-ла* кушымчасына кайтып кала. Әлеге материал шулай ук бу карашны раслый, *-ыл* элементы, *-да* кушымчасы бер иҗекле сүзләргә ялганганда барлыкка килгән интерфикс булып тора: *уф+ыл+да, ыр+ыл+да, быз+ыл+ да.* Ул берничек тә ясаучы нигезгә карамый, чөнки телдә *уфыл, ырыл, бызыл* дигән сүзләр юк, телдә бары *уф, ыр, быз* дигән сүзләр генә бар. Әмма тюркологиядә интерфикс теориясе әле ныгып җитмәгәнлектән, биредә *-ыл* кисәге *-ылда* кушымчасының составында карала.

*-ылда* кушымчасы күбрәк аваз ияртемнәренә, сирәгрәк тасвир ияртемнәренә ялгана.

Ясаучы нигезләре аваз ияртемнәре булган фигыльләр: *хыр+ылда, чер+елдә, чыр+ылда, торк+ылда, мыр+ылда, мырк+ылда, тек+елдә.*

Ясаучы нигезләре тасвир ияртемнәре булган фигыльләр: *елк+ылда, җем+елдә.*

Кайбер очракларда *-ылда* кушымчасы белән ясаучы нигез арасында *к* яки *г* авазы күзәтелә: *кет+к+елдә, кар+к+ылда, каң+г+ылда, зың+г+ылда, ләң+г+елдә.* Телнең борынгы хәлендә ул авазлар ясаучы нигез составына кергән булса кирәк.

1. Аваз ияртемнәренә ялганып, ясаучы нигездә бирелгән авазга охшаш аваз чыгаруны яки шул авазларга охшаган тавыш чыгарып эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *торкылда, шаркылда, сулкылда.*

2. Тасвир ияртемнәренә ялганып, ясаучы нигездә бирелгән образны хасил итүне: *елкылда, җемелдә.*

**Нигез + *-да/дә* (*-та/-тә*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-да/-та,* нечкә нигезләргә *-дә/-тә* кушымчасы ялгана. Күпчелек галимнәр бу кушымчаны генетик яктан *-ла* кушымчасы белән бәйләнгән дип саныйлар. *-да/-дә* (*-та/-тә*) кушымчасының ясаучы нигезләре булып аваз һәм тасвир ияртемнәре, сирәк кенә исемнәр һәм ымлыклар килә.

Ясаучы нигезләре аваз ияртемнәре булган фигыльләр: *дыңгыр+да, быгыр+да, чөкер+дә, чытыр+да, кетер+дә, мыгыр+да, мекер+дә, лыбыр+да, шыгыр+да.*

Ясаучы нигезләре тасвир ияртемнәре булган фигыльләр: *кыймыл+да, кыбыр+да, җилфер+дә, лыҗыр+да. -да* кушымчасы белән ясалган фигыльләрнең ясаучы нигезләре хәзерге телдә куш сүзләр буларак кулланыла: *богыр-богыр, кетер-кетер, мыгыр-мыгыр.*

Ясаучы нигезләре ымлыклар булган фигыльләр: *әй+дә.*

Ясаучы нигезләре исемнәр булган фигыльләр: *өн+дә, ал+да* (борынгы телдә *ал* «хәйлә» дигән мәгънәне белдергән).

Хәзерге татар телендә *-да* кушымчалы кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел: *тукта, үртә, сылта, селтә.*

Чыганак тел ягыннан кушымчаның ясаучы нигезләре булып саф татар сүзләре килә.

1. Аваз ияртемнәренә ялганып ясаучы нигездә бирелгән авазларны якынча әйтүне яки шундый авазлар белән эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *шыңгырда, лаштырда, кытырда, чөкердә, чытырда, дөңгердә.*

2. Тасвир ияртемнәренә ялганып ясаучы нигездә бирелгән образны хасил итүне белдерә: *кыймылда, җилфердә, лыҗырда.*

3. Исемнәргә ялганып ясаучы нигездә күрсәтелгән эш-хәрәкәтне башкаруны белдерә: *әйдә, өндә.*

*-да* кушымчалы кайбер фигыльләр хәзергә көндә метафорик мәгънә алганнар: *әйдә, өндә.*

**Нигез + *-ыт/-ет, -т*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ыт* кушымчасы, нечкә нигезләргә *-ет* кушымчасы ялгана.

Галимнәрнең күпчелеге *-ыт, ет, -т*$_2$ кушымчасын фигыль юнәлеше ясый торган кушымча дип исәплиләр. Бары тик кайберәүләр генә (мәсәлән, Э.В. Севортян) анда сүзьясагыч мәгънәләрен күрәләр. Мисаллар да шуны дәлилли, чөнки алар фигыльләргә генә түгел, бәлки сыйфатларга һәм рәвешләргә дә ялганалар. Мәсәлән, *җылы+т, әй+т* сүзләрендә бу кушымча турыдан-туры сыйфатка, ымлыкка ялганып, фигыльләр ясаган, *-ыт* кушымчасы ярдәмендә ясалган, мәсәлән, *корыт, ныгыт, кимет* кебек башка фигыльләр дә бар. Бу кушымча *-ит* ярдәмче фигыленә барып тоташа. Югарыда китерелгән фигыльләрнең структурасы түбәндәгечә билгеләнә: *коры, нык, ким* сыйфатлары + *-ит* ярдәмче фигыль ялгана (*коры+ит – корыт, нык+ит=ныгыт, ким+ит=кимет*). Шулай итеп, *-ыт, -ет, -т*$_2$ кушымчаларыннан ясалган ясалма фигыльләр, фигыль яки фигыль булмаган нигезләренә карамастан, йөкләтү юнәлеше мәгънәсен белдермәсәләр, сүз ясалышы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип саналырга тиешләр. *-ыт, -ет, -т*$_2$ кушымчасы, нигездә, фигыльләргә ялгана: *болга+т, җилтерә+т.* Сирәк кенә сыйфатларга да ялганырга мөмкин: *җылы+т.*

Хәзерге татар телендә *-ыт/-ет, -т*$_2$ кушымчалары белән ясалган, әмма ясаучы нигезе ачык билгеле булмаган фигыльләр дә бар: *юырт, чирт, юат, сөрт, ишет, оныт, чемет.*

Ясаучы нигезләре булып гадәттә саф татар сүзләре килә.

1. Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигездә бирелгән билгене хасил итүне белдерә: *җылыт, суыт.*

2. Фигыльләргә ялганып, ясаучы нигездә белдергән эш-хәрәкәтне башкаруны тәгъбир итә: *әчет, үрчет, керт.*

**Нигез + *-ыш/-еш, -ш* (*-аш/-әш*)$_3$ кушымчасы**. Калын нигезләргә *-ыш/-аш,* кушымчасы, нечкә нигезләргә *-еш/-әш* кушымчасы ялгана. Бу кушымча борынгы заманнардан ук билгеле. Юнәлеш форманты буларак «Борынгы төрки сүзлек»тә дә китерелә. Э.В. Севортян бу кушымчада сүзьясагыч мәгънәсе бар дип таба, аны *-л* кушымчасына кайтарып калдыра (*ш – л* алтай лабдаизмы). Галим, юнәлешне белдерә торган һәм сүзләр ясый торган *-ш* кушымчалары икесе ике чыганакка

барып тоташа, дип саный. Бу кушымча татар телендә сүзьясагыч буларак та йөри, чөнки *-ыш/-еш, -ш,* (*-аш/-әш*) кушымчалы фигыльләрнең барысында да грамматик мәгънә – юнәлеш мәгънәсе күзәтелми.

Икенче яктан, бу кушымча белән килгән кайбер фигыльләрнең семантикасы ясаучы нигезләрдән килеп чыкмый, алар тел үсешенең билгеле бер чорында метафорик мәгънә алганнар: *кереш* (йон турында), *күреш, кыйыш* (диал.), *алыш* (көрәшү мәгънәсендә).

Ясаучы нигезләре булып гадәттә фигыльләр килә: *бөр+еш, кор+ыш, ав+ыш* (*ау+ыш*). Кайвакыт исемнәр дә бу кушымчаның ясаучы нигезе була ала: *урнаш* (*урын+аш*). Бу кушымча, кагыйдә буларак, күчемсез фигыльләр ясый: *биреш, корыш, эчеш.*

Ул шулай ук ясаучы нигезләре ачык булмаган фигыльләрдә дә очрый: *ireш, тырыш, бөтәш* (чагыштыр: *бөт+ен*).

Кагыйдә буларак, бу кушымча татар сүзләренә ялгана. Юнәлеш кушымчасы сүзьясагыч кушымчадан аермалы буларак ярдәм итү (*эшләш*), уртаклык (*иснәш*), күплек (*торкылдаш*), даимилек (*урлаш*) мәгънәләрен белдерә.

Калган мәгънәләр сүзьясалышка карый һәм сүзьясалыш күренеше буларак өйрәнелергә тиеш.

Бу кушымча фигыльләргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең бераз кимегән дәрәҗәдә башкарылуын: *авыш, корыш, калыш.*

2. Ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең артык дәрәҗәдә башкарылуын: *бетәш, кызыш, кайнаш, сырыш, әчеш.*

Фигыльләргә ялганып, ясаучы нигездә бирелгән мәгънә белән бик үк туры килмәгән мәгънәләрне: *ойыш, тоташ, орыш, сугыш, җиңеш, килеш, өзеш, ярыш, кереш* (*йон*), *күреш.*

Кайбер фигыльләр метафорик мәгънә тәгъбир итәләр: *эләгеш.* Аларда бу мәгънә сүзнең семантикасы үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килә: *эләгеш* сүзенең туры мәгънәсе «бер-береңә тию»дән үзгәреп, «оршышу» мәгънәсе килеп чыккан.

**Нигез + *-ыл/-ел, -л$_2$* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ыл,* нечкә нигезләргә *-ел* кушымчасы ялгана.

Бу дериват тюркологиядә байтак кына хезмәтләрдә юнәлеш ясаучы кушымча буларак күрсәтелә. А. Казимбәк, Ш.А. Рамазанов, Н.А. Бас-

каков, В.Н. Хангилдин, А.Н. Кононов, С. Джафаров, Э.В. Севортян хезмәтләрендә һәм кайбер грамматикаларда сүзьясагыч буларак китерелә. Чыннан да, фактлар күрсәткәнчә, аның сүзьясагыч буларак та мәгънәсе бар.

Хәзерге татар телендә бу кушымча фигыльләргә ялгана һәм кайтым юнәлешендәге күчемсез фигыльләр ясый: *ургы+л, ыргы+л, у+ал, тукта+л, йончы+л, ат+ыл, әвер+ел, борчы+л.* Мәгълүм булганча, кайтым юнәлешендәге фигыльләр лексик берәмлекләр рәтендә каралалар.

Күпчелек тикшеренүчеләр бу кушымчаны ярдәмче фигыльгә кайтарып калдыралар. Кайбер галимнәр бу фикер белән килешмиләр (мәсәлән, П.М. Мелиоранский). Э.В. Севортян фаразынча, сүзьясагыч буларак та, юнәлеш кушымчасы буларак та ул бер чыганакка барып тоташа. А.Н. Кононов бу кушымчаны *-ла* (*-л+а*) кушымчасыннан килеп чыккан дип саный.

Фигыль ясагыч буларак, аны ярдәмче фигыль белән бәйләү бик кыен. Фактлар күрсәткәнчә, төрки телләрдә фигыльләрдән дә һәм исемнәрдән дә бер үк кушымча белән сүзләр ясалмый диярлек.

*-ыл/-ел,* $-л_2$ кушымчалы күп кенә фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел. Бүгенге көндә аларны фигыль буларак та, исем буларак та карап булмый: *кузгал, чуал, инәл, ябырыл, ярал, оял, таркал, тарал.* Бу фигыльләр телдә тулы хокуклы лексик берәмлек булып торалар, аларны нинди дә булса юнәлешкә кертеп булмый, чөнки аларның төп юнәлеш формалары юк.

Бу кушымча шулай төшем юнәлеш формалары да ясый: *сөйел, савыл, бурал, озатыл, чакырыл, чабыл* һ.б. Күренгәнчә, югарыдагы фигыльләрдә *-ыл/-ел,* $-л_2$ кушымчасы тик грамматик мәгънә генә – юнәлеш мәгънәсе генә белдерә. Шунлыктан алар кушымча белән ясалган мөстәкыйль фигыльләр тәшкил итмиләр.

Фигыльләргә ялганып, ул берәр нәрсәдә, субъектта бара торган яки берәр нәрсә, яки субъект белән була торган эш-хәрәкәтне белдерә: *туктал, уал, борчыл, ургыл, йончыл, манчыл, сүрел, убыл.*

**Нигез + *-ын/-ен,* $-н_3$ кушымчасы**. Сүзьясагыч кушымча буларак кайбер галимнәр (Г.И. Рамстедт, Ш.А. Рамазанов, Э.В. Севортян, А.Н. Кононов, төрекмән һәм азәрбайҗан грамматикалары авторлары) тарафыннан гына күрсәтелә.

Бу кушымча шулай ук төшем һәм кайтым юнәлеш формаларын да ясарга мөмкин. Кайтым юнәлеш формалары: *чиг+ен, күб+ен, ябь+ын, йөр+ен.* Төшем юнәлеш формалары: *тәнкыйть+лә+н, тормоз+ла+н, бүләк+лә+н.*

Төшем килеш формалары саф грамматик күренеш тәшкил итә, чөнки *-ын/-ен, -н* күрсәткече аларның лексик мәгънәсен үзгәртми.

Кайтым юнәлеше фигыльләренә килгәндә, аларның барлык мәгънәләрен дә грамматик семантикага кайтарып калдырып булмый. Мәсәлән, эш-хәрәкәтнең эчке объектка карау (*кырын*) һәм субъектка җәелү (*кызарын, шешен*) күренешләре лексик мәгънә тәшкил итәләр.

Кайбер тикшеренүчеләр кайтым фигыльләренең барлык мәгънәләрен дә лексик мәгънә дип игълан итәләр һәм аларны сүзьясалыш күренеше дип карарга тәкъдим итәләр. Э.В. Севортян күрсәткәнчә, *-ын/-ен, -н* кушымчасы белән ясалган мөстәкыйль фигыльләр дә, кайтым юнәлеше формалары да, тарихи яктан караганда, бер үк кушымча белән ясалганнар. Бу кушымча исемнәргә дә, фигыльләргә дә ялганырга мөмкин *ар+ын* (ар=саф), *йөг+ен, төш+ен.* Хәзерге телдә китерелгән фигыльләрнең фигыль нигезләре юк, шуңа күрә дә алар фигыль формасын тәшкил итмиләр, мөстәкыйль фигыль булып торалар. Күп фигыльләрдә бу кушымча аларның нигезләреннән аерылмый: *сыгын, үкен, үтен, сагын, ялын.*

Күренгәнчә, китерелгән фигыльләрнең ясаучы нигезләре юк, шуңа күрә алар берничек тә фигыльнең формасы итеп карала алмыйлар. Һичшиксез, алар кайчандыр ясалма фигыльләр булганнар, моны хәзер этимологик тикшеренүләр белән генә билгеләп була. Аларның ясаучы нигезләре исемнәр дә булырга бик мөмкин.

Бу кушымча нигездә татар сүзләренә ялгана, сирәк кенә алынма сүзләргә дә ялганырга мөмкин: *әсәр+ен* (гарәп теле алынмасы), *чистар+ын* (рус теле алынмасы).

Бу кушымча исемнәргә ялганып, ясаучы нигезгә бәйле берәр эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *арын, төшен.* Фигыльләргә кушылып, субъектның үзенә караган эш-хәрәкәтне тәгъбир итә: *күгәрен, агарын, шешен.* Мондый фигыльләрнең күпчелеге күчмә, метафорик мәгънәгә ия булып, мөстәкыйль фигыль тәшкил итәләр: *бөтерен, тартын, сөен, ачын, шапырын, үсен, телән.*

**Нигез + *-ыр/-ер, -р,* (*-ар/-әр*)$_2$ кушымчасы.** *-ыр*/*-ар* кушымчалары калын нигезләргә, *-ер*/*-әр* кушымчалары нечкә нигезләргә ялгана. Татар әдәби телендә продуктив, хәтта алынма сүзләрдән дә фигыль ясый (*чистар*). Этимологиясе ачык түгел. Бериш галимнәр *ир* ярдәмче фигыле белән (И.А. Батманов, К. Брокельман, В.Н. Хангилдин), икенчеләре (Н.А. Баскаков) *-гар*/*-гәр* кушымчасы белән бәйлиләр.

Сыйфатларга, сирәк кенә исемнәргә, ияртемнәргә ялгана:

– сыйфатлар: *аг+ар, иске+р, шома+р, чал+ар, яңа+р, кыска+р, нечкә+р, таза+р.*

– исемнәр: *ис+әр, кайгы+р;*

– ияртемнәр: *бак+ыр, уф+ыр, кик+ер, как+ыр, өф+ер.* Чыганак тел ягыннан караганда, бу кушымча күпчелек татар сүзләренә ялгана.

I. Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән үзенчәлекне алу мәгънәсен белдерә: *нечкәр, яңар, кыскар, чалар, агар, тазар, яктыр.*

II. Исемнәргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез белдергән нәрсәгә әверелүне: *сүсәр.*

2. Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән капланууны яки ул сыйфатны үзенә алуны: *бәсәр, симер.*

3. Ясаучы нигез белдергән нәрсәнең тәэсиренә бирелүне: *исер.*

III. Ияртемнәргә ялганып, нигездә күрсәтелгән авазларга охшаган авазлар чыгарып, нинди дә булса эш-хәрәкәт башкаруны: *уфыр, өфер, какыр.*

**Нигез + *-ыр/-ер, -ар/-әр, -р$_3$* кушымчасы.** Бу кушымча фигыльләргә ялгана. Кайбер галимнәр (Н.А. Баскаков, А.Н. Кононов, В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева, К.З. Зиннәтуллина) аны йөкләтү юнәлеше кушымчасы дип саныйлар, ләкин ул бу мәгънәне белдерми. Мәсәлән, *өй+ер, пеш+ер, бет+ер, бат+ыр* фигыльләре гадәти төп төшем мәгънәсен тәгъбир итәләр.

Фигыльләргә ялганып, бу кушымча түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигездә күрсәтелгән эш-хәлләрнең тагы да интенсивраk башкарылуын: *күпер, йомшар.*

2. Ясаучы нигездә күрсәтелгән күчемсез фигыльләрдән аермалы буларак, эш-хәрәкәтләрне күчемле итеп башкаруны: *пешер, төшер, күчер, китер, бетер, кубар.*

Кайбер фигыльләр метафорик мәгънә белдерәләр: *кичер, чигер.*

Хәзерге телдә ясаучы нигезләре ачык булмаган фигыльләр дә байтак: *айыр, кайыр, томыр, җимер, җибәр.* Шуңа күрә аларны берничек тә юнәлеш формалары дип карап булмый. Дөрес, кайбер нигезләрне башка сүзләр составында күрергә мөмкин (*аймылыш, кайры*).

Шулай да алар хәзерге вакытта мөстәкыйль кулланылмыйлар.

***Хәзерге көндә сирәк сүз ясый торган типлар***

**Нигез + *-дыр/-дер* (*-тыр/-тер*) кушымчасы.** *-дыр*/*-тыр* кушымчасы калын нигезләргә, *-дер*/*-тер* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана: *ышандыр, типтер*.

*-тыр*/*-тер* варианты саңгырау авазларга беткән нигезләргә ялгана: *үстер, арттыр.* Бу кушымчаның структурасы икегә бүленә: *-д*(*т*) һәм *-ыр*. *-ыр* элементы фигыль ясагыч *-ыр* кушымчасына, *-т* элементы йөкләтү юнәлеше *-т* күрсәткеченә барып тоташа. Йөкләтү юнәлеше күрсәткече һәрвакыт фигыльләргә ялгана һәм каузатив мәгънә (йөкләтү мәгьнәсе) белдерә: *кос+тыр, чукын+дыр, ат+тыр, сат+тыр.*

Фигыль ясагыч *-дыр* кушымчасы тышкы яктан йөкләтү юнәлеше кушымчасы *-дыр* ны хәтерләтә, ләкин тегесеннән аермалы буларак, төп юнәлеш мәгънәсен белдерә. Шунлыктан ул фигыль булмаган сүз төркемнәренә дә ялгана. Сирәк кенә ымлыкларга һәм ияртемнәргә ялгана.

Ясаучы нигезләре фигыль булган фигыльләр: *тип+тер, чәл+дер, үс+тер, алыш+тыр, арт+тыр, сүн+дер, чагыш+тыр.*

Ясаучы нигезләре ымлык, ияртем булган фигыльләр: *әйт+тер, җил+дер.*

I. Фигыльләргә ялганып, ясаучы нигез белдергән хәлгә китерү дигән мәгънәне белдерә: *таушалдыр, киптер, туздыр, ышандыр.*

II. Ымлыкларга, ияртемнәргә ялганып, ясаучы нигезгә нинди дә яктан бәйле булган эш-хәлләрне башкаруны тәгъбир итә: *өстер, җилдер.*

**Нигез + *-ат/-әт* кушымчасы.** *-ат* кушымчасы калын нигезләргә, *-әт* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана: *ярат, кисәт.*

*-ат* кушымчасы *ит* ярдәмче фигыленә барып тоташа: *йүн+ит= йүнәт, яр+ит=ярат.*

Бу кушымча белән ясалган фигыльләр аз. Нигездә, ул исемнәргә, сыйфатларга, фигыльләргә ялгана.

I. Исемнәргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигездә күрсәтелгән нәрсә белән эш-хәрәкәтне башкаруны: *күзәт.*

2. Ясаучы нигездә күрсәтелгән сыйфатны бирүне: *юнәт, ярат.*

II. Сыйфатларга ялганып ясаучы нигез белдергән билгене бирүне: *төзәт.*

Фигыльләргә ялганып, метафорик мәгънә белдерергә мөмкин: *кисәт.*

**Нигез + *-ра/-рә* (*-ыра/-ерә*)$_3$ кушымчасы.** *-ра*/*-ыра* кушымчасы калын нигезләргә, *-рә* (*-ерә*) нечкә нигезләргә ялгана: *сайра, кыҗра, иңрә, мөгрә.*

Бу кушымчаның ясаучы нигезләре булып ияртемнәр, сыйфатлар һәм исемнәр килә.

Ясаучы нигезләре ияртемнәр булган фигыльләр: *мелт+ерә, җилт+ерә, иң+рә, мөң+рә.* Нигез белән кушымча арасындагы *«ң»* һәм *«г»* авазларын интерфикс дип карарга була: *мө+ң+рә.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган фигыльләр: *миңге+рә, сәлпе+рә, шәлбе+рә.*

Исем булган ясаучы нигезләр: *өст+ерә, оч+ра.*

*-ра* кушымчасы белән килгән кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел: *кайра, әлсерә, сөйрә, сизрә, өлтерә.*

Бу кушымчаның ясаучы нигезләрен татар сүзләре тәшкил итә. Бу кушымча түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

I. Аваз ияртемнәренә ялганып ясаучы нигездә күрсәтелгән авазларны якынча чагылдыруны: *мөңрә, иңрә, сайра.*

II. Образлы ияртемнәргә ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән билгеләргә бәйле эш-хәлләрне башкаруны: *мелтерә, җилтерә.*

III. Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән билгене алуны: *миңгерә, сәлперә.*

IV. Фигыльләргә ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән эш-хәрәкәтнең үзеннән-үзе башкарылуын: *чәчрә, җәйрә, изрә.*

Бу кушымча күчемсез фигыльләргә ялганып, мәгънәсе шул ук ясаучы нигезгә якын күчемсез фигыль ясый: *мәлҗерә, көйрә.*

**Нигез + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_2$ кушымчасы.** *-гы* кушымчасы калын нигезләргә, *-ге* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана, *-кы*/*-ке* варианты саңгырау сузыкларга тәмамланган нигезләрдән соң килә.

Бу кушымча фигыльләргә (*туз+гы, кал+гы, йол+кы*), ияртемнәргә (*мыж+гы, пыс+кы*) ялгана.

Татар телендә *-гы* кушымчалы сүзләрнең кайберләренең нигезләре мөстәкыйль кулланылмыйлар: *ыргы, талкы, селке, ургы, аңкы, балкы, ышкы, бөрке.*

I. Аваз ияртемнәренә ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән авазларга якын авазлар чыгарып, эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *пыскы.*

II. Образлы ияртемнәргә ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән билгене чагылдыра торган эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *мыжгы.*

III. Фигыльгә ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән эш-хәрәкәтне интенсив рәвештә башкаруны яисә аның башкарылуын, аны билгеле нәтиҗәгә җиткерүне белдерә: *тузгы, йолкы, калгы.*

**Нигез + *-га/-гә* (*-ка/-кә*)$_2$ кушымчасы.** *-га* кушымчасы калын нигезгә, *-кә* кушымчасы нечкә нигезгә ялгана. Саңгырау тартыкларга тәмамланган нигезләрдән соң *-ка/-кә* кушымчасы кушыла: *ис+кә, чай+ка.*

Бу кушымчаның килеп чыгышын В. Банг *-а* кушымчасына бәйләп карый, «г» авазы соңыннан барлыкка килгән дип фаразлый. Башкалар (А.Н. Кононов, Э.В. Севортян) *-га* кушымчасын *-гы* варианты дип саныйлар.

*-га* кушымчасы кайбер очракларда юнәлеш кушымчалары белән килергә мөмкин: *кузгат, меңгәш, бөркән, чиркан, имгәт.*

Кайбер фигыльләрнең нигезләре ачык билгеле түгел: *теркә, тиргә, ялга, айка, чолга, болга, карга, чайка.*

Сүзьясалышның бу тибы ясаучы нигез белдергән мәгънә белән бәйле эш-хәрәкәтне башкаруны белдерә: *искә.*

**Нигез + *-ык/-ек, -к*$_2$ кушымчасы.** *-ык* кушымчасы калын нигезләргә, *-ек* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана.

*-ык* кушымчасының *-кы* кушымчасы белән элемтәсе бар дип исәпләнә. Болай уйларга нигез дә бар, чөнки бу кушымчалар кайбер очракларда бер үк нигезгә ялгана алалар: *кыр+ык=кыр+кы, йол+ык= йол+кы.*

Әмма, фактлар күрсәткәнчә, *-ык*$_2$ кушымчасы мәгънәсе һәм ясаучы нигезләре ягыннан *-гы* кушымчасыннан аерыла. Фигыльләрдән башка, ул исемнәргә һәм сыйфатларга да кушыла ала.

Ясаучы нигезләре фигыль булган фигыльләр: *пеш+ек, тар+ык, йот+ык, күн+ек.*

Ясаучы нигезләре исем булган фигыльләр: *юл+ык, күз+ек, кан+ык, тут+ык, дым+ык.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган фигыльләр: *ач+ык, сай+ык, сав+ык* (*сау+ык*).

Аерым очракларда саннар да ясаучы нигез булып килергә мөмкин: *бер+ек.*

Кайбер фигыльләрнең нигезләре хәзерге көндә мөстәкыйль кулланылмый: *боек, өрек, курык, сурык, мавык, күшек.*

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигез булып татар сүзләре генә килә.

I. Сыйфатларга ялганып, нигездә бирелгән билгене алуны белдерә: *сайык, ачык, чынык, савык, тарык.*

II. Исемнәргә ялганып, бу кушымча түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигездә күрсәтелгән әйбернең тәэсиренә дучар булуны: *күзек, зарык, үчек.*

2. Ясаучы нигездә тәгъбир ителгән әйбергә ия булуны: *дымык, тутык.*

3. Нигездә күрсәтелгән урында яки вакытта эш-хәрәкәт башкаруны: *кичек, юлык.*

III. Фигыльләргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигездә тәгъбир ителгән мәгънәгә якын эш-хәрәкәт башкаруны: *кибек, күнек, тарык, кызык.*

2. Ясаучы нигездә белдерелгәнне теләүне: *ялык, каныk.* Бу очракта алар метафорик мәгънә белдерәләр.

IV. Санга ялганып, нигездә белдерелгән хәлгә килүне тәгъбир итә: *берек.*

**Нигез + *-а/-ә*$_3$ кушымчасы.** *-а* кушымчасы калын нигезләргә, *-ә* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана.

Этимологиясе ачык түгел. Күп кенә галимнәр бу кушымчаны *-га* кушымчасына кайтып кала дип саныйлар. Н.А. Баскаков аны *-ла* кушымчасының фонетик үсешенең нәтиҗәсе дип карый. Э.В. Севортян бу фикергә каршы чыга, *-а/-ә* кушымчасын *-ла* кушымчасыннан борынгырак дип таба. *-а/-ә* кушымчасы мөстәкыйль кушымча булып тора, аны башка кушымчаларга кайтарып калдырырга мөмкин түгел.

Бу кушымча исемнәргә, сыйфатларга, фигыльләргә, ияртемнәргә ялганып төрле мәгънәләр белдерә.

Ясаучы нигезләре исем булган фигыльләр*: өст+ә, ярлык+а, ат+а, төн+ә, тун+а, ут+а, теш+ә, кыйн+а,* (*кыйын=җәза*).

Ясаучы нигезләре сыйфат булган фигыльләр: *төз+ә, буш+а.*

Ясаучы нигезләре фигыль булган фигыльләр: *тек+ә, үт+ә.*

Ясаучы нигезләре ияртем булган фигыльләр: *гөлдер+ә, елтыр+а, ялтыр+а, шылтыр+а, челтер+ә, келтер+ә, чәп+ә.*

Татар телендә *-а/-ә* гә беткән күп кенә фигыльләр морфологик яктан аерым өлешләргә таркалмыйлар: *сөйә, бута, буйа, айа, илә, көрә, төтә, тура, сыла, яма, яла.*

Татар телендә бу кушымча белән ясалган күп кенә сүзләрнең нигезләре ачык түгел һәм морфологик яктан бүленмиләр: *сөйә, бута, буйа, айа, илә, изә, тура, төтә, чыда, кама, када, көрә, сыла, сула, сора, тара, тала, яса, яна, яма, яла, яса.*

*«Н»* авазына тәмамланган нигезләрдә аннан алда булган *-ы/-е* авазлары төшеп кала: *уйын – уйна.*

I. Исемнәргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигезләрдә күрсәтелгән нәрсәне хасил итүне: *төйнә, яшнә, борна, тешә, өстә.*

2. Ясаучы нигезләрдә күрсәтелгән эш-хәрәкәтне башкаруны: *уйна, сана, аша, ата.*

3. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәдән арындыруны: *ута, туна, бота, буна.*

4. Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән эш-хәрәкәт башкаруны: *күзә.*

II. Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигез белдергән билгегә ия булуны тәгъбир итә: *буша.*

III. Ияртемнәр белән килеп, түбәндәге мәгънәләрне тәгъбир итә:

1. Ясаучы нигез белдергән авазларны чыгарып эш-хәрәкәт башкаруны, якынча шундый авазларны чыгаруны: *гөлдерә, күкерә, шалтыра, чалтыра, чәпә.*

2. Ясаучы нигез белдергән хәлгә килүне: *лыжбыра, ләпшерә.*

IV. Фигыльләргә ялганып, мәгънәсе ясаучы нигез мәгънәсе белән бәйләнгән фигыльләр ясый: *үтә, текә, сына.*

**Нигез + *-ы/-е*$_2$ кушымчасы,** *-ы* кушымчасы калын нигезләргә; *-е* кушымчасы нечкә нигезләргә ялгана: *шакы, төзе.*

Хәзерге татар телендә *-ы*$_2$ кушымчасы белән килгән күп кенә фигыльләр мөстәкыйль мәгънәле кисәкләргә аерылмыйлар: *өше, эре, чере, укы, ойы, сасы, чүке, казы, ташы.* Аның ясаучы нигезләре булып, кагыйдә буларак, татар сүзләре килә.

Бу кушымчаның килеп чыгышы турында каршылыклы фикерләр яши. Кайбер тикшеренүчеләр аны *-а* кушымчасыннан килеп чыккан диләр. Н.А. Баскаков аны, *-ык* кушымчасыннан килеп чыккан, дип саный. Татар теле фактлары бу фикерне раслый. Мәсәлән, *бай+ы* фигыле күп кенә диалектларда *бай+ык* дигән формада йөри. Э.В. Севортян әйтеп киткәнчә, күпчелек яңа хезмәтләрдә бу кушымча бөтенләй төшереп калдырыла. Аның ясаучы нигезләре булып исемнәр, сыйфатлар һәм ияртемнәр килә:

– исемнәр: *тат+ы;*

– сыйфатлар: *ким+е, ныг+ы, төз+е, бай+ы;*

– ияртемнәр: *тук+ы, шак+ы, балк+ы.*

I. Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигез тәгъбир иткән билге алуны белдерә: *киме, ныгы, байы.*

II. Ияртемнәргә ялганып, нигез тәгъбир иткән авазлар чыгарып эш-хәрәкәтләр башкаруны белдерә: *тукы, шакы.*

III. Исемнәргә ялганып, нигездә белдерелгән нәрсә белән бәйләнгән эш-хәрәкәт башкаруны аңлата: *таты.*

**Нигез + *-ай/-әй, -й*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ай* кушымчасы, нечкә нигезләргә *-әй* кушымчасы ялгана.

Г.И. Рамстедт фикеренчә, бу кушымча борынгы уйгур кушымчасы *-а* га барып тоташа. Сыйфатларга, сирәк кенә рәвешләргә, исемнәргә, ияртемнәргә ялгана.

Ясаучы нигезләре сыйфат булган фигыльләр: *карт+ай, җиңел+әй, авыр+ай, буш+ай, батыр+ай, зур+ай, еш+ай, ераг+ай, түбән+әй.*

Ясаучы нигезләре исем булган фигыльләр: *чокыр+ай, ис+әй, кот+ай.*

Ясаучы нигезләре рәвеш булган фигыльләр: *аз+ай, күб+әй, соң+ай.*

Ясаучы нигезләре образ ияртемнәре булган фигыльләр: *бүлт+әй, тырт+ай, турс+ай.*

Кайбер ике иҗекле ясаучы нигезләргә *-ай* кушымчасы ялганганда, кыска *-ы* юкка чыга: *олай* (*олы*), *салпай* (*салпы*), *саргай* (*саргы*), *кәкрәй* (*кәкре*), *турай* (*туры*), *бөкрәй* (*бөкре*).

*-ай* элементына тәмамланган күп кенә фигыльләр хәзерге көндә морфологик яктан таркалмый: *йәмшәй, ыржай, масай, муртай, серәй.*

I. Сыйфатларга ялганып түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигездә күрсәтелгән билге алуны: *кырысай, киңәй, начарай, төзәй, көрәй.*

2. Ясаучы нигезләрдә тәгъбир ителгән тарафка хәрәкәт итүне: *ерагай, түбәнәй, якынай.*

II. Исемгә ялганып, нигездә күрсәтелгән теге яки бу шәкелне яки сыйфатны алуны: *чокырай, өңерәй, котай, исәй, ишәй.*

III. Ияртемнәргә ялганып, нигездә тәгъбир ителгән тасвирны чагылдыруны: *бүлтәй, тасырай.*

**Нигез+*-ал/-әл, -л* кышымчасы.** Калын нигезләргә *-ал,* нечкә нигезләргә *-әл* кушымчасы ялгана.

Исемнәргә, сыйфатларга, хәбәрлек сүзләргә ялгана.

Бу кушымчаның борынгы *ул* фигыле белән бәйләнеше бар. Аның һәм кушма фигыльләрнең бер үк мәгънәдә параллель кулланылышы шул турында сөйли (*юг+ул=югал*).

*-ал/-әл, -л* кушымчасы ясаучы нигез белдергән сыйфат яки билгене алу мәгънәсен тәгъбир иткән күчемсез фигыльләр ясый: *терел, төзәл, югал.*

**Нигез + *-арла/-әрлә* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-арла,* нечкә нигезләргә *-әрлә* кушымчасы ялгана.

Бу кушымча ике элементтан тора: *ар+ла.* Бу элементлар мөстәкыйль *-ар* (итератив мәгънәле) һәм *-ла* кушымчаларына барып тоташа. Ул фигыльләргә ялгана.

Фигыльләргә ялганып итератив төсмер белән нигездәге фигыль мәгънәсенә якын булган мәгънә белдерә: *йомарла, бөгәрлә, ботарла* (чаг.: *ботак*).

**Нигез + *-са/-сә* (*-сы/-се*)$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-са* (*-сы*), нечкә нигезләргә *-сә,* (*-се*) кушымчасы ялгана.

Г.И. Рамстедт, Э.В. Севортян бу кушымчаны тунгус телләрендәге *-са* (эшләү, сөйләү, сөйләшү) сүзе белән бәйлиләр. Ләкин моның белән килешү кыен, чөнки бу сүздә теләк мәгънәсе юк. Бу кушымча *сагын* (теләү) сүзенең беренче кисәге белән бәйле булса кирәк. Ул берничә сүздә генә очрый.

Исемнәргә ялганып нигездә күрсәтелгән нәрсәне теләү мәгънәсен белдерә: *суса, җирсе.*

*-сы/-се* кушымчалы кайбер фигыльләр метафоралашкан: *йөрәксе* (бик нык теләү мәгънәсендә).

**Нигез + *-са/-сә (-сы/-се)*$_3$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-са* (*-сы*), нечкә нигезләргә *-сә* (*-се*) кушымчасы ялгана.

Тунгус телендәге *-са* (эшләү) сүзе белән генетик бәйләнеше бар.

Кайбер фигыльләр структур кисәкләргә бүленми: *бурсы* (*бур* – ис килү), *сөрсе* (черү, бозылу), *акса, ярсы.*

Исемнәргә (*как+сы*), ияртемнәргә (*кыбыр+сы, үк+се*) ялгана.

I. Исемнәргә ялганып, нигез тәгъбир иткән предмет кебек булу, яки шул сыйфатны яки билгене алу мәгънәсен белдерә: *күксе, каксы.*

II. Ияртемнәргә ялганып, нигездә күрсәтелгән авазларны чыгару яки шул тасвирны чагылдыруны белдерә: *кыбырсы, үксе.*

**Нигез + *-сын/-сен*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-сын,* нечкә нигезләргә *-сен* кушымчасы ялгана. Бу кушымча да тунгус телендәге *-са* сүзенә барып тоташа, төрки телләрдәге *санау* сүзе шул ук тамырдан.

Мондый кушымчалы кайбер фигыльләр аерым кисәкләргә бүленмиләр: *дәмсен, җиксен.*

Ясаучы нигезләре булып исемнәр, сыйфатлар, алмашлыклар һәм хәбәрлек сүзләр киләләр:

– исемнәр: *намус+сын, иш+сен, аш+сын, бала+сын;*

– сыйфатлар: *кыен+сын, тар+сын, ят+сын, гаҗәп+сен, тук+сын, ким+сен, артык+сын, кызык+сын;*

– алмашлыклар: *мин+сен, үз+сен;*

– хәбәрлек сүзләр: *кирәк+сен, юк+сын, тиеш+сен.*

Күпчелек очракта ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә, әмма алынмалар да килергә мөмкин: *гаҗәп+сен, җәбер+сен* (гарәп сүзләре).

1. Исемнәргә һәм сыйфатларга ялганып, үзен ясаучы нигез тәгъбир иткән зат яки нәрсә дип санау мәгънәсен белдерә: *тиңсен, кимсен, гаҗәпсен.*

2. Исемнәргә ялганып, нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә, нәрсәгә дучар булуны белдерә: *күзсен, ялыксын, җиксен.*

**Нигез + *-сыт/-сет*$_1$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-сыт,* нечкә нигезләргә *-сет* кушымчасы ялгана.

Бу кушымча ике өлештән: исәпләргә, санарга мәгънәсендәге сүзьясагыч *-сы* һәм грамматик кушымча *-т* дан тора, телдә ул бер кушымча буларак кулланыла, чөнки *-т* кушымчасыннан башка шул ук нигезләрдән ясалган фигыльләр юк.

Исемнәргә (*бала+сыт*) һәм сыйфатларга ялгана (*ким+сет, түбән+сет, үги+сет*).

Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

1. Бу кушымчалы фигыльләр ясаучы нигез тәгъбир иткән затның боерыгын белдерә: *түбәнсет, баласыт, үгисет.*

2. Шулай ук бу төр фигыльләр ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәгә дучар итүне белдерә: *җиксет, җәберсет, кыенсыт.* Шул ук мәгънәгә *кыерсыт* фигыле карый.

**Нигез + *-сыра/-серә* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-сыра,* нечкә нигезләргә *-серә* кушымчасы ялгана. Ул берничә фигыльдә генә кулланыла. Борынгы төрки телдә ул ешрак кулланылган: *кагансыра, илсерә.*

Бу тип фигыльләр нигез тәгъбир иткән нәрсәне югалту мәгънәсен белдерә: *кансыра.*

Шушы ук мәгънәне *самсыра* (*сам, сөм=хис*), *әлсерә* (*әл=хәл*), *иләмсерә* (*иләм=илһам*) фигыльләре белдерә.

**Нигез + *-шы/-ше* (*-ша/-шә*)$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-шы* (*-ша*)*,* нечкә нигезләргә *-ше* (*-шә*) кушымчасы ялгана.

Исемнәрдән (*кыр+шы*)*,* фигыльләрдән (*куп+шы*)*,* ияртемнәрдән (*шың+шы*) фигыльләр ясый.

I. Исемнәргә ялганып, нигездә күрсәтелгән билгене үзенә алуны яки бирүне белдерә: *кыршы, кәкше, мүкше.*

II. Фигыльләргә ялганып, нигездә күрсәтелгән эш-хәрәкәтнең беркадәр генә башкарылуын белдерә: *купшы, кипше, җепше.*

III. Ияртемнәр белән килеп, нигездә күрсәтелгән авазларны якынча чыгаруны яки шул авазларны чыгарып эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *укшы, шыңшы.*

Кушымчаның кайбер ясаучы нигезләре бүгенге көндә аерым кулланылмыйлар: *корша* (борынгы телдә *кор = түгәрәк*)*, охша, кауша.*

**Нигез + *-шыр/-шер* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-шыр,* нечкә нигезләргә *-шер* кушымчасы ялгана.

Бу кушымча ике кисәктән тора: *-шы+-р. -шы* элементы югарыда күрсәтелгән *-шы* кушымчасы белән бәйле, *-р* кушымчасы борынгы *ир*

сүзенә барып тоташа. Ул бары тик берничә сүздә генә очрый (*тап+шыр, кип+шер*).

Фигыльләргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигездә белдерелгән эш-хәрәкәтнең ким дәрәҗәдә башкарылуын: *кипшер.*

2. Ясаучы нигездәге мәгънәгә бәйле эш-хәрәкәтне башкаруны: *тапшыр.*

**Нигез + *-шын*/*-шен* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-шын,* нечкә нигезләргә *-шен* кушымчасы ялгана.

Бу кушымча ике өлештән тора: сүзьясагыч *-шы* һәм грамматик *-н* кушымчасыннан. Ләкин телдә ул бербөтен кушымча буларак кулланыла.

Ул фигыльләргә ялгана. Ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Фигыльләр белән килеп, ул түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең ким дәрәҗәдә башкарылуын: *купшын, кипшен.*

2. Ясаучы нигез белән бәйләнешле эш-хәрәкәтнең башкарылуын: *тыкшын.*

**Нигез + *-чы*/*-че*$_3$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-чы,* нечкә нигезләргә *-че* ялгана. Күпчелек галимнәр аны гомумән күрсәтмиләр. Э.В. Севортян аны *-ша*/*-шы* кушымчасының варианты дип саный.

Бу кушымча исемнәргә (*төп+че, тын+чы*), фигыльләргә (*күп+че, ман+чы, тип+че*), ияртемнәргә (*тыпыр+чы* (диал.), *чәп+че*) ялгана.

Ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

I. Исемнәр белән килеп, ясаучы нигез мәгънәсе белән бәйләнешле эш-хәрәкәтне белдерә: *тынчы, төпче.*

II. Фигыльләр белән килеп, ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең артык дәрәҗәдә башкарылуын белдерә: *күпче, манчы, үрче* (нигез аерылмый).

III. Аваз һәм образ ияртемнәре белән килеп, ясаучы нигез белдергән авазларга якын авазлар чыгаруны яки тасвирлы эш-хәрәкәтне башкаруны тәгъбир итә: *чәпче, тыпырчы.*

Хәзерге татар телендә бу кушымча белән килгән башка фигыльләр дә бар, ләкин аларның ясаучы нигезләре аерылмыйлар: *йәнче,* (*йан= йән*)*, чәнче, чокчы* (чагыштыр: *чокы*)*, тупчы, йончы, борчы.*

**Нигез + *-чык*$_3$ кушымчасы.** Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең артык дәрәҗәдә башкарылуын белдерә: *тал+чык.*

*-чык* кушымчасы килгән кайбер фигыльләр морфологик яктан таркалмыйлар: *ялчык, тончык* (борынгы төрки телдә *тун* – ‘*каплану*’).

**Нигез + *-гыр*/*-гер* (*-кыр*/*-кер*)$_3$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-гыр* (*-кыр*), нечкә нигезләргә *-гер* (*-кер*)кушымчасы ялгана.

Бу кушымча ияртемнәргә (*ыж+гыр, ба+кыр, а+кыр, ү+кер, пош+кыр, төш+кер*) һәм фигыльләргә (*ят+кыр, җит+кер, бел+гер, ки+гер*) ялгана.

I. Аваз ияртемнәренә кушылып, ясаучы нигез белдергән авазларга охшаш авазларны чыгаруны яки шундый авазлар чыгарып эш-хәрәкәт башкаруны тәгъбир итә: *ү+кер, а+кыр, ка+кыр, аж+гыр, чаж+гыр.*

II. Фигыльләргә ялганып, ясаучы нигез белдергән көчемсез эш-хәрәкәттән аермалы буларак, көчемле эш-хәрәкәтне тәгъбир итә: *яткыр, җиткер.*

Бу кушымча белән килгән кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел: *өшкер, өлгер.*

**Нигез + *-гыз*/*-гез* (*-кыз*/*-кез*) кушымчасы.** Телдәкушымчаның киң варианты да очрый, мәсәлән, диалекталь *күргәз* фигылендә.

Бу кушымча күпчелек очракта *-гыр*/*-гер* (*-кыр*/*-кер*) кушымчасының диалекталь варианты буларак килә: *менгер – менгез, җиткер – җиткез, яткыр – яткыз.* Әмма кайбер очракларда аның *-гыр*/*-гер* варианты булмыйча, мөстәкыйль кушымча буларак кулланыла: *тор+гыз.* Кушымча фигыльләргә ялгана: *кер+гез* (диал.), *тор+гыз.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Бу кушымча фигыльләргә ялганып, ясаучы нигез тәгъбир иткән көчемсез эш-хәрәкәтне көчемле эш-хәрәкәткә әйләндерә.

Кайчакта ясаучы нигезе морфологик яктан аерылмый да: *тер+гез* (диал.)

**Нигез + *-гар*/*-гәр* (*-кар*/*-кәр*)$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-гар* (*-кар*), нечкә нигезләргә *-гәр* (*-кәр*)кушымчалары ялгана. *-кар*/*-кәр* вариантлары саңгырау тартыклардан соң килә. Н.К. Дмитриев, Э.В. Севортян *-гар* ны *-ра* дан килеп чыккан дип аңлаталар, *-ар* кушымчасы үз чиратында *-гар* дан килеп чыккан.

Ул исемнәргә (*җил+гәр, су+гар, ис+кәр, кот+кар, баш+кар, ат+кар* (диал.), фигыльләргә (*үт+кәр*), рәвешләргә (*соң+гар*) кушы-

ла. Аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә. Кайбер фигыльләрнең нигезе ачык түгел: *төткәр, түңкәр.*

I. Исемнәргә ялганып, нигез белдергән нәрсәгә тәэсир итүне, эшләтүне тәгъбир итә: *җилгәр, сугар, аңгар, эшкәр.*

II. Фигыльләргә ялганып, нигездә бирелгән күчемсез фигыльләрдән аермалы буларак, нинди дә булса объект белән эш-хәл башкаруны белдерә: *үткәр.*

III. Рәвешләргә ялганып, нигездәге билгеләрне күрсәтүне белдерә: *соңгар.*

Кайбер фигыльләр метафорик мәгънәгә ия: *коткар, башкар.*

**Нигез + *-гын/-ген* (*-кын/-кен*)$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-гын* (*-кын*), нечкә нигезләргә *-ген* (*-кен*) ялгана. *-кын/-кен* варианты саңгырау тартыкларга ялгана.

Берничә фигыльдә генә очрый. Нигез тәгъбир иткән эш-хәл башкарырга омтылуны белдерә: *ашкын, җилкен.*

Бу фигыльләрнең нигездә бирелгән төп мәгънәләрен югалтып, метафорик мәгънәне белдергәннәре дә очрый: *аткар, башкар.*

**Нигез + *-ан/-ән, -н*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ан,* нечкә нигезләргә *-ән* кушымчасы ялгана.

Ул бары берничә сүздә генә очрый. Э.В. Севортян *-ан* кушымчасын кайтым юнәлеше күрсәткеченә кайтарып калдыра. Бу формант кайчандыр телдә сүзьясагыч буларак та кулланылган. Ул борынгы кушымчалар рәтенә керә, шуңа күрә аның чын этимологиясен билгеләве кыен. Борынгы телдә ул бәлки структур кисәкләргә *көсә+н* (*күсә=кәсә* 'теләү') моделе кебек аерылган: *көчә+н* (*күчә= көчә* 'көч куллану').

Исемнәргә (*көч+ән*), сыйфатларга (*төз+ән*) ялгана.

I. Исемнәргә ялганып, нигез тәгъбир иткән нәрсә белән эш итүне белдерә: *көчән.*

II. Сыйфатларга ялганып, нигез белдергән сыйфатны алуны тәгъбир итә: *төзән.*

Нигезләре мөстәкыйль кулланылмаган *-ан* кушымчалы фигыльләр дә бар: *куан, тайан, җирән, өшән, кизән, кинән, йуан, казан, уян.*

**Нигез + *-на/-нә*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-на,* нечкә нигезләргә *-нә* кушымчасы ялгана.

Этимологиясе ачык түгел. Шулайда аны *-ла* кушымчасының варианты дип карарга мөмкин. Мәсәлән, әдәби телдә *-лә* кушымчасының мәгънәсе тулысынча *-на* кушымчасының мәгънәсенә туры килгән *тешлә* дигән фигыль, сөйләм телендә *тешнә* дигән фигыль очрый.

Бу кушымча исемнәргә (*ис+нә, кат+на, чат+на, теш+нә*), фигыльләргә (*җый+на, ау+на*), ияртемнәргә (*гыж+на, кыт+на, мыш+на, чи+на* (*чый+на*)) ялгана.

I. Исемнәргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсә белән эш итүне: *теш+нә.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәне хасил итүне: *чат+на.*

II. Фигыльләргә ялганып, ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтне күп мәртәбә башкаруны белдерә: *ауна.*

III. Ияртемнәргә ялганып, ясаучы нигез тәгъбир иткән авазларны якынча чыгаруны белдерә: *мышна, кытна, чина.*

Кайбер фигыльләр бүгенге көндә мәгънәле кисәкләргә аерылмыйлар: *чорна, тырна.*

**Нигез + *-ыз*$_{3}$ кушымчасы.** Генетик яктан бу кушымча *-ыр* кушымчасы белән бәйләнгән булса кирәк. Әмма ул мөстәкыйль кушымча булып тора, чөнки *-ыз* кушымчасының шул ук ясаучы нигезләрдән *-ыр* кушымчасы белән ясалган параллель фигыльләре юк: *тамыз, кабыз.*

Аны йөкләтү юнәлеше кушымчасы дип тә карап булмый, чөнки аңарда йөкләтү мәгънәсе күренми. Бу кушымча гадәти төп юнәлеш мәгънәсен бирә. Ул фигыльләргә ялгана: *агыз, тамыз.*

Чыганак тел ягыннан караганда аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыльләргә ялганып, ясаучы тәгъбир иткән күчемсез эш-хәрәкәттән аермалы буларак, берәр объект белән күчемле эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *агыз, кабыз, тамыз.*

**Нигез + *-пе*$_{3}$ кушымчасы.** Нечкә нигезләргә ялгана. Берничә фигыльдә генә күзәтелә. Ияртемнәргә ялганып, нигез белдергән билгене чагылдыруны тәгъбир итә: *җилпе.*

*Сирпе* сүзендә нигез мөстәкыйль кулланылмый.

**Нигез + *-ала/-әлә* кушымчасы.** Бу кушымчаның килеп чыгышы турында махсус тикшеренүләр юк. Кайбер грамматикаларда һәм

хезмәтләрдә аның этимологиясен билгеләү омтылышлары күренә. Э.В. Севортян фикеренчә, *-ла* кушымчасында кабатлау мәгънәсе бар. Биредәге *-ла* кушымчасы *эшлә, ташла* фигыльләре составында килгән фигыль ясаучы гадәти *-ла* кушымчасыннан берни белән дә аерылмый. Китерелгән фигыльләрдәге *-ла* кушымчасында кабатлау, күплек мәгънәсе күзәтелми. Шуңа күрә кабатлау мәгънәсен *-ла* кушымчасына кайтарып калдыру өчен җитәрлек нигез юк. Кабатлау мәгънәсе кушымчаның беренче өлешенә *-а* элементыннан килә.

Бу кушымча фигыльләргә (*ку+ала, у+ала, чүг+әлә*), сирәк кенә сыйфатларга (*саг+ала*)ялгана. Ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

I. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтне күп мәртәбәләр башкаруны белдерә: *куала, уала, өтәлә, чүгәлә.*

II. Сыйфатларга ялганып, ясаучы нигез тәгъбир иткән сыйфатны даими чагылдыруны белдерә: *сагала.*

*-ала* кушымчалы кайбер фигыльләрнең ясаучы нигезләре ачык түгел: *табала, тәбәлә* (бәлки *табала* фигыленең нечкә варианты).

**Нигез + *-дар/-дәр* (*-тар/-тәр*) кушымчасы.** Калын нигезләргә *-дар* (*-тар*), нечкә нигезләргә *-дәр* (*-тәр*) ялгана. *-тар/-тәр* варианты саңгырау тартыкларга ялгана.

Бу кушымчаны йөкләтү юнәлеше итеп карарга ярамый, чөнки ул андый мәгънәне белдерми.

Фигыльләргә ялганып, нигез тәгъбир иткән күчемсез фигыльләрдән аермалы буларак, нинди дә булса бер объект белән күчемле эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *аудар, түнтәр.*

Бу кушымча *актар* фигылендә очрый. Аның нигезе мөстәкыйль кулланылмый. Борынгы төрки телдә *аг* фигыле «күтәрелергә» мәгънәсен белдерүче мөстәкыйль сүз буларак кулланылган.

**Нигез + *-лык/-лек*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-лык,* нечкә нигезләргә *-лек* кушымчасы ялгана. Бу кушымча фигыльләргә (*җит+лек, ат+лык, чөй+лек*), исемнәргә (*ут+лык*), сыйфатларга (*тар+-лык*) кушыла. Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләр булып саф татар сүзләре килә.

I. Фигыльләргә ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә омтылуны яки аңа бәйләнешле эш-хәрәкәтне: *җитлек, атлык, йотлык, тотлык.*

2. Ясаучы нигездә тәгъбир ителгән мәгънәне: *тарлык.*

Кайбер фигыльләрнең мәгънәсе семантик үсеш вакытында метафорик үзенчәлек алганнар: *өзлек, утлык.*

*-лык* кушымчалы бер өлеш фигыльләрдә хәзерге көндә ясаучы нигезләр мөстәкыйль кулланылмыйлар: *карлык, пышлык, сөрлек.*

**Нигез + *-җы/-җе* кушымчасы.** *-җы* калын нигезләргә, *-җе* нечкә нигезләргә ялгана. Бары тик татар сүзләрендә генә очрый. Ияртемнәргә ялганып, нигездә бирелгән тасвирлы хәлләрне чагылдыруны аңлата: *кымырҗы.*

Кайбер фигыльләрдә нигез мөстәкыйль кулланылмый: *мәлҗе, алҗы.*

**Нигез + *-ма/-мә*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ма,* нечкә нигезләргә *-мә* ялгана. Бары татар сүзләренә генә кушыла.

Ияртемнәргә ялганып, нигездә бирелгән авазларны чыгарып, эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *тукма* (хәзерге көндә ул метафорик мәгънә алган).

Күп кенә фигыльләрнең нигезләре ачык түгел (үле нигезләр): *юрмә, яма, ялма, сирмә, карма.*

**Нигез + *-маш* кушымчасы.** Калын нигезләргә ялгана. Бары тик ике фигыльдә генә күзәтелә.

Фигыльгә ялганып, нигез белдергән мәгънәгә якын күчемсез фигыль ясый: *алмаш, укмаш.*

**Нигез + *-тай*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезгә ялгана. Бары тик ике сүздә генә очрый. Исемгә ялганып, нигез белдергән мәгънәгә якын булган эш-хәрәкәтнең башкарылуын аңлаткан фигыль ясый: *янтай, мурт(?)ай.*

**Нигез + *-сәт* кушымчасы.** Нечкә нигезгә ялгана. Бер сүздә генә очрый. Фигыльгә ялганып, нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә бәйле күчемле эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *күрсәт.*

**Нигез + *-рай/-рәй* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-рай,* нечкә нигезләргә *-рәй* кушымчасы ялгана.

Сыйфатларга ялганып, нигез белдергән билгене алуны белдерә: *кечерәй, сәлперәй, салпырай* (диал.).

**Нигез + *-кай/-кәй* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-кай,* нечкә нигезләргә *-кәй* кушымчасы ялгана. Бу кушымча бары тик берничә сүздә генә очрый.

Исемнәргә ялганып, нигез тәгъбир иткән мәгънәгә бәйле кимчелекле эш-хәрәкәт белдергән фигыльләр ясый: *аңкай* (диал.), *иңкәй.*

*-кай* кушымчасы *туңкай, чүңкәй* (диал.) фигыльләрендә дә бар.

**Нигез + *-кет* кушымчасы.** Нечкә нигезләргә ялгана.

Бу кушымча ике өлештән тора: сүзьясагыч *-ке,* фигыль юнәлеше күрсәткече *-т* кушымчасыннан. Хәзерге татар телендә бер кушымча буларак кулланыла.

I. Ияртемнәргә ялганып, нигез тәгъбир иткән авазларны чыгарып эш-хәрәкәт башкаруны белдерә: *зеңкет, деңкет.*

II. Саннарга ялганып, нигез тәгъбир иткән хәлгә китерүне белдерә: *беркет.*

**Нигез + *-тан* кушымчасы.** Калын нигезгә ялгана. Бу кушымча бер генә фигыльдә очрый. Ияртемгә ялганып, метафорик мәгънә белдерә: *офтан.*

Бу кушымча ияртемнәрдән фигыль ясаучы *-та* һәм фигыль юнәлеше күрсәткече *-т* кушымчасыннан гыйбарәт булса кирәк. Телдә *офта* дигән фигыль булмаганлыктан *-тан* элементын бердәм кушымча дип карарга туры килә.

**Нигез + *-ак/-әк*$_4$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-ак,* нечкә нигезләргә *-әк* кушымчасы ялгана. Нигездәге күчемле фигыль мәгънәсеннән аермалы буларак, күчемсез эш-хәрәкәтне башкаруны белдерә: *эл+әк. Олак* фигылендә нигез аерылмый.

**Нигез + *-чын/-чен*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезләргә *-чын,* нечкә нигезләргә *-чен* кушымчасы ялгана. Бу кушымча ике өлештән тора: *-чы* элементы фигыль ясагыч, *-н* элементы фигыль юнәлеше күрсәткече, *-чын* комплексы мөстәкыйль кушымча тәшкил итә, чөнки бу фигыльләрнең *-чы* белән генә ясалган вариантлары юк.

Ияртемнәргә ялганып, нигездә күрсәтелгән билгесе булган эш-хәрәкәтне башкаруны аңлаткан фигыльләр ясый: *тыпырчын.*

*-чын/-чен* кушымчалары *чемчен, тиберчен* фигыльләрендә дә очрый.

Ләкин бу сүзләрнең нигезләре хәзерге телдә мөстәкыйль кулланылмыйлар.

**Нигез + *-чан*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезгә ялгана һәм бер генә сүздә очрый. Фигыльгә ялганып, нигез тәгъбир иткән мәгънәгә якын эш-хәрәкәтне белдерә: *тайчан.*

**Нигез + *-пыл/-пел* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-пыл,* нечкә нигезләргә *-пел* кушымчасы ялгана.

Фигыльләргә ялганып, нигез тәгъбир иткән мәгънәгә якын эш-хәрәкәт башкаруны аңлата: *тайпыл, сирпел.*

**Нигез + *-сар*$_2$ кушымчасы**. Калын нигезгә ялгана һәм бер фигыльдә генә очрый. Фигыльгә ялганып, мәгънәсе белән нигез белдергән мәгънәгә якын эш-хәрәкәтне тәгъбир итә: *япсар.*

**Нигез + *-лай*$_2$ кушымчасы.** Калын нигезгә ялгана. Исем белән килеп, ясаучы нигез тәгъбир иткән сыйфатны, билгене алуны белдерә: *очлай.*

**Нигез + *-пай/-пәй* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-пай,* нечкә нигезләргә *-пәй* кушымчасы ялгана.

Исемнәргә ялганып, нигездә күрсәтелгән сыйфатны алу мәгънәсен белдергән фигыль ясый: *үрпәй.*

*-пай* кушымчалы кайбер фигыльләрнең нигезләре ачык түгел: *җәлпәй, ярпай.*

**Нигез + *-пын/-пен* кушымчасы.** Калын нигезләргә *-пын,* нечкә нигезләргә *-пен* кушымчасы ялгана.

Бу кушымча фигыль ясагыч *-пы,* кайтым юнәлеше *-н* кушымчасыннан гыйбарәт. Хәзерге көндә бер кушымча булып килә: *җилпен, талпын.*

Ияртемнәргә ялганып, нигез белдергән билгене чагылдыруны тәгъбир итә: *җилпен.*

### *Нигездән аерылмый торган кушымчалар*

Татар телендә үле, ягъни нигездән аерылмый торган фигыль ясагыч кушымчалар да очрый. Бу фигыльләрнең ясаучы нигезләре аерым кулланылмыйлар. Мәгънәләре дә хәзерге заман күзлегеннән караганда ачык түгел. Алар түбәндәгеләр:

*-ган/-гән* (*-кан/-кән*)$_2$ *сискән, кызган, чиркан, сызган, яскан* (*диал.*), *казган* (диал.)

*-мык/-мек*$_2$*: каймык* (чагыштыр: *кай+ыр*)

*-тыл/-тел: омтыл*

*-ны/-не: айны, әрне, пырны*

*-тык/-тек: интек*

*-вар: ялвар*

*-мыр/-мер$_2$: тилмер*
*-ты/-те: тенте*
*-чыра/-черә: былчыра*
*-җыра/-җерә: бәлҗерә*
*-ча/-чә: үлчә*
*-гәш: өлгәш*
*-жай: ыржай*
*-май/-мәй: елмай*

### 9.6.3. Кушма фигыльләр ясалышы

Татар телендә тезүле һәм ияртүле бәйләнештә булган компонентлар кушылып кушма фигыльләр ясала.

#### Тезүле бәйләнештә булган компонентлар кушылып кушма фигыльләр ясалышы

Бу очракта кушма фигыльләрнең бер төре – куш (парлы) фигыльләр барлыкка килә.

Хәзерге татар әдәби телендә куш фигыльләр ясалышының бер генә тибы бар: фигыль$_1$+фигыль$_2$. Семантикасы ягыннан алар ясауда катнаша торган компонентларның конкрет мәгънәсенә туры килеп бетми, гадәттә гомумиләштерү килеп чыга, хәтта, кайчак абстракция барлыкка килә. Бу мәгънә куш фигыльне китереп чыгара иде. Мәсәлән, *кагу-сугу, киенү-ясану, яну-көю, әйләнү-тулгану, бөгелү-сыгылу, елау-сыктау, ару-талу, ялыну-ялвару.*

Башка сүз төркемнәренә кергән, беренче компонентлары кушымча алмый торган куш сүзләрдән аермалы буларак, куш фигыльләрнең беренче компонентлары грамматик формантлар алырга мөмкин: *ардык-талдык, янды-көйде, киенде-ясанды* һ.б.

#### Ияртүле бәйләнештә булган компонентка кушылып кушма фигыльләр ясалышы

***Фигыль булмаган сүзләрдән фигыльләр ясалышы***

Фигыль булмаган сүзләрдән кушма фигыльләр ясалышы турында беренче мәгълүматны без А. Казимбәктә очратабыз. Ул аларны тезмә

фигыльләр дип атый: «Исемнәрдән һәм ярдәмче фигыльләрдән яки башка фигыльләрдән ясалган фигыльләр тезмә фигыльләр булалар».

«Алтай теле грамматикасы»нда да кушма фигыльләр турында кыскача мәгълүмат бирелә, М. Терентьев, А. Архангельский шулай ук төрки телләрдә кушма фигыльләр булуын искәртеп китәләр (*ант итмәк*). В.А. Гордлевский кушма фигыльләрнең *масдар*+ярдәмче фигыль моделендә ясалуын әйтеп, ярдәмче фигыльләрне күрсәтә: *әйлемекь, кылмакъ, олмакъ.* А.Н. Кононов үзенең грамматикаларында кушма фигыльләрнең тулы структур-семантик картинасын бирә. Н.П. Дыренкова, кушма фигыльләр структурасында ярдәмче фигыльләр үзләренең реаль мәгънәсен югалта, дип саный. Х. Байлиев төрекмән телендә, Ә.Ә. Юлдашев, гомумән төрки телләрдә фигыль булмаган сүзләрдән ясалган кушма фигыльләр шактый урын алып тора, дип раслыйлар. Ә.Н. Нәҗип бу модельдәге кушма фигыльләрне тезмә фигыльләр дип атый. Аның фикеренчә, мондый фигыльләрнең беренче компонентлары булып гарәп-фарсы алынмалары килә. А.Г. Алекперов, кушма фигыльләрнең беренче һәм икенче компонентлары арасында реаль логик-синтаксик бәйләнеш юк, шуңа күрә аларны синтаксик сүзтезмәләр дип карап булмый, ди. К.М. Мусаев, караим телендә *сал, эт, бер, бол, ал* ярдәмче фигыльләре кушма фигыльләр ясый, беренче компонентлары булып гарәп, фарсы, рус, украин һәм борынгы яһүди телләре алынмалары килә, дип күрсәтә. А.И. Искаков казакъ телендәге кушма фигыльләрнең типларын китерә, аларның ирекле сүзтезмәләрдән аермалы булуының критерийларын билгели. В.А. Исенгалиева үзенең тикшеренүендә алынма нигезләрдән кушма фигыльләр ясалышының тулы картинасын бирә, аларның структур-семантик үзенчәлекләрен күрсәтә.

Төрекмән теле грамматикасында «кушма фигыльдә төп сүз ярдәмче фигыльдән алда килә» диелә. М.М. Текуев карачай-балкар телендә кушма фигыльләр ясый торган ярдәмче фигыльләрнең исемлеген бирә (*эт, бол, бер, сал, кет, ат*).

Татар теленең беренче грамматикаларында кушма фигыльләр турында мәгълүмат бик кыска бирелә. И. Гиганов белән А. Троянский кушма фигыльләргә мисаллар китерәләр һәм, алар татар телендә күп түгелләр, дип әйтәләр. К. Насыйри кушма фигыльләр турында шактый киң мәгълүмат бирә. Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, Ш. Рамазанов һәм

В. Хангилдин кушма фигыльләр турында төгәл мәгълүмат бирәләр, ярдәмче фигыльләр буларак *итү, кылу, булу, килү* сүзләрен күрсәтәләр. Д.Г. Тумашева, *итү, булу, килү, кылу* ярдәмче фигыльләре ярдәмендә регуляр ясалган кушма фигыльләр белән беррәттән индивидуаль ясалган кушма фигыльләргә дә туктала.

Тюркологиядә һәм татар тел белемендә кушма фигыльләрне өйрәнү тарихы күрсәткәнчә, бүгенге көндә фигыль булмаган сүзләрдән кушма фигыль ясый торган ярдәмче фигыльләр билгеләнгән, нигездә компонентларның лексик-грамматик үзенчәлеге һәм аларның чыганаклары ачыкланган, индивидуаль ясалыштагы фигыльләр барлыгы да әйтелгән.

Фигыль түгел + фигыль тибындагы кушма фигыльләр төрки телләргә генә түгел, башка телләргә дә хас. Бу тип фигыльләр, мәсәлән, рус телендә дә бар, әмма анда алар күп түгел. Рус теленең академик грамматикасында фигыль түгел + фигыль тибындагы кушма фигыльләргә түбәндәге мисаллар китерелә: *полузакрыть, полулежать, самовоспламеняться, самоустраниться, трудоустроить, взаимодействовать.* Грамматикада бу кушма фигыльләрдә компонентлар ияртүле бәйләнеш белән килгән диелә.

Бу типтагы кушма фигыльләр һинд, алман телләрендә күп очрый.

Татар телендә фигыль булмаган сүзләрдән кушма фигыльләрнең даими ясалышында *итү, булу, кылу, килү, ясау* кебек ярдәмче фигыльләр катнаша, ә *бирү, китерү, алу* ярдәмче фигыльләре белән ясалган кушма фигыльләр телдә күп түгел.

Компонентлары ияртүле бәйләнеш белән кушылып ясалган фигыль түгел + фигыль тибындагы кушма фигыльләр татар телендә бик күп. Аларның беренче компонентлары булып исемнәр, алмашлыклар, саннар, рәвешләр, ымлыклар, ияртемнәр киләләр. Бу типтагы кушма фигыльләрнең икенче компонентлары затланышлы фигыльгә хас барлык формаларда килә.

Фигыль түгел + фигыль кушма фигыльләр ясалышының түбәндәге типлары бар.

**Нигез + *итү* фигыле тибы.** *Итү* ярдәмче фигыле борынгы *ир* фигыленнән *-т* кушымчасы белән ясалган. Күп кенә белгечләр аерым очракларда нигез белән кушылып китә дип саныйлар: *зур ит – зурайт, тар ит – тарайт, күп ит – күбәйт, матур ит – матурайт, кара ит – карайт* (диал.)*, шәп ит – шәбәйт.*

*Зур+айт* кебек фигыльләрдәге *-айт* элементы сүзьясагыч *-ай* кушымчасыннан һәм кайвакыт сүз ясау функциясе була торган йөкләтү кушымчасы *-т* дан гыйбарәт ике компонентлы морфема тәшкил итә. Шуңа күрә *-айт* (*әйт*)элементын *-ит* фигыленнән турыдан-туры килеп чыккан дип санап булмый.

*Итү* ярдәмче фигыле белән килгән кушма фигыльләрнең беренче компонентлары булып саф татар сүзләре дә, алынма сүзләр дә килә ала. Беренче компонент буларак татар телендә *итү* фигыле белән алынма сүзләр шактый күп кулланыла.

Инкыйлабка кадәр гарәп һәм фарсы сүзләре беренче компонент булып килгәннәр: *сәүдә итү, хәбәр итү, тәэсир итү, тәэмин итү, хөкем итү.*

Бүгенге көндә *итү* ярдәмче фигыле ярдәмендә сөйләм телендә рус теленең инфинитив формасындагы фигыльләрдән кушма фигыльләр ясала: *мобилизовать итү, реализовать итү, гулять итү, зубрить итү.* Әмма әдәби тел бу төр ясалыштан качарга тырыша. Бары *танцевать итү* фигыленә генә урын бирә.

Бу типның беренче компоненты булып, әйтеп үтелгәнчә, саф татар сүзләре, бигрәк тә ымлыклар һәм ияртемнәр килә: *ялт-йолт итү, бүләк итү, киңәш итү, көн итү, елт-елт итү, аһ итү, уф итү тек-тек итү.*

Мондый кушма фигыльләр ясалышының түбәндәге модельләре бар.

Исем + *итү* моделе. Бу модельдә беренче компонент бәйле дә, бәйсез дә (мөстәкыйль) булырга мөмкин.

Бәйсез (мөстәкыйль) беренче компонент белән *итү* ярдәмче фигыль нигезендә ясалган кушма фигыльләр: *ант итү, хәбәр итү, хәл итү, хөкем итү, хөрмәт итү, кунак итү.*

Бәйле беренче компонент белән *итү* ярдәмче фигыле нигезендә ясалган кушма фигыльләр: *тәрәккый итү, тәэмин итү, тәшкил итү, кабул итү, фаш итү, исбат итү, бәян итү, җөрьәт итү, кәшеф итү, хур итү* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу модельдәге кушма фигыльләр күчемле дә (*исбат итү, хөрмәт итү*), күчемсез дә (*ант итү, җөрьәт итү*) булырга мөмкиннәр. Әмма күчемле фигыльләрнең күчемсезләргә караганда шактый күп булуын әйтеп китәргә кирәк.

Исем + *итү* фигыле моделенең ике төре бар.

1. Билгесез төшем килешендәге исем+*итү: өмет итү, киңәш итү, хикәя итү, гомер итү, тәэсир итү.* Биредә *итү* ярдәмче фигыле саф деривация (сүзьясагыч) функциясен үти, ул исемне фигыльгә әйләндерә, беренче компонент белдергән эш-хәрәкәтне яки процессны башкару дигән мәгънәне тәгъбир итә.

2. *-лык/-лек* кушымчалы исем+*итү: шпионлык итү, патрульлек итү, күрәзәлек итү.* Кушма фигыль ясалышының бу төре түбәндәге мәгънәләрне белдерә: 1) беренче компонент тәгъбир иткән эшчәнлекне башкаруны: *рәислек итү, дирижёрлык итү, укытучылык итү, патшалык итү;* 2) беренче компонент тәгъбир иткән сыйфатны чагылдыруны: *яхшылык итү, өстенлек итү, залимлык итү, корткычлык итү.*

Сыйфат + *итү* моделе. Бу модельдәге кушма фигыльләр күп түгел. Әлеге модельдәге тезмәләр еш кына иректе сүзтезмә тәшкил итәләр: *хатынлы итү, ирле итү, әдәпле итү, сыерлы итү.*

Шулай да бу структурада кушма фигыльләр дә ясала: *әрәм итү, мәҗбүр итү, кызык итү, куш итү.* Беренче компонент – сыйфат тәгъбир иткән билгене чагылдыруны белдерә.

Сан + *итү* моделе. Телдә бу модель белән ясалган кушма фигыльләр очрый: *ике итү, өч итү, дүрт итү.* Беренче компонент – сан белдергән санча ясау дигән мәгънәне тәгъбир итә.

Хәбәрлек сүз + *итү* моделе: *юк итү, бар итү.* Беренче компонент – хәбәрлек тәгъбир иткән нәрсәне «башкару» дигән мәгънәне белдерә.

Ымлык + *итү* моделе. *Итү* ярдәмче фигыле аерым ымлыклардан кушма фигыльләр ясый: *аһ итү, ыһ итү, уф итү.* Беренче компонент тәгъбир иткән ымлыкны әйтү дигән мәгънәне белдерә. Аларның кайберләре күчмә мәгънә дә тәгъбир итәргә мөмкин.

Аваз ияртеме + *итү* моделе. *Итү* ярдәмче фигыле аваз ияртемнәреннән һәм ымлыклардан кушма фигыль ясый торган универсаль чара булып тора.

Мәгълүм булганча, аваз ияртемнәре бер компонентлы һәм ике компонентлы булалар. Күп компонентлы да булырга мөмкин. Әмма алар лексик берәмлек булып тормыйлар, бары ике компонентлы аваз ияртеменең варианты гына булып торалар. Бер компонентлы аваз ияртемнәре, кагыйдә буларак, бер мәртәбә тавыш барлыкка китерүне

белдерсә, ике компонентлы аваз ияртемнәре күп мәртәбә тавыш чыгаруны тәгъбир итә. Шуңа бәйләнешле рәвештә бер компонентлы аваз ияртемнәреннән ясалган кушма фигыльләр, кагыйдә буларак, бер мәртәбә тавыш барлыкка китерүне белдерәләр: *гөмберт итү, шарт итү, чылт итү, доңк итү, дөңк итү, шак итү, дөп итү.* Әгәр аваз ияртеме, бер компонентлы булуына карамастан, озын тавыш яки күп мәртәбә тавыш барлыкка китерүне белдерсә, ул вакытта кушма фигыль дә озын тавыш яки күп мәртәбә тавыш барлыкка китерүне чагылдыра: *чер итү, чыш итү, чеӊ итү.* Ике компонентлы аваз ияртемнәреннән ясалган кушма фигыльләр күп мәртәбә яки озын тавыш барлыкка китерүне белдерә: *керт-керт итү, кетер-кетер итү, пычтыр-пычтыр итү, тек-тек итү, голт-голт итү, торыйк-торыйк итү, тыпыр-тыпыр итү, шарт-шорт итү.*

Образ ияртеме + *итү* моделе. Бу модельдәге кушма фигыльләр образ ияртеме белдергән образны чагылдыру мәгънәсен бирә. Бер компонентлы образ ияртеме белән ясалган кушма фигыльләр образны бер мәртәбә чагылдыруны белдерә: *елт итү, гөлт итү, ялт итү.*

Ике компонентлы образ ияртеме белән ясалган кушма фигыльләр образның күп мәртәбә чагылуын тәгъбир итә: *ялт-йолт итү, елт-елт итү, җем-җем итү, ялтыр-йолтыр итү, мелт-мелт итү.*

Рус теле инфинитивы + *итү* моделе. Татар әдәби телендә бу модель белән ясалган кушма фигыльләр, кагыйдә буларак, кулланылмыйлар. Сөйләм телендә алар байтак: *дежурить итү* (әдәби телдә: *дежур тору*), *фальцевать итү* (әдәби телдә: *фальцовкалау*), *вербовать итү* (әдәби телдә: *вербовкалау*), *конфисковать итү* (*конфискацияләү*). Бу модельдәге кушма фигыльләрдә рус фигыленеӊ инфинитивы исем фигыль буларак килә, ярдәмче фигыль инфинитивны кушма фигыльгә әйләндерә, ә аңа затланышлы фигыль үзенчәлеген бирә.

**Нигез + *килү* фигыле тибы.** Бу типтагы кушма фигыль ясалышы татар телендә еш очрый. Кушма фигыльләрнең бу төре барсы да күчемсез фигыль тәшкил итәләр. Аларның түбәндәге модельләре бар.

Юнәлеш килешендәге исем + *килү* ярдәмче фигыле моделе. Алар үзләренең тышкы структурасы ягыннан тулысынча иреклe сүзтезмәләренә туры киләләр, ләкин кушма фигыльләргә хас үзенчәлекләр белән сүзтезмәләрдән аерылалар: *барлыкка килү, искә килү, дөрескә килү.*

Бу кушма фигыльләр беренче компонент белдергән нәрсәнең башкарылуын тәгъбир итә.

Рәвеш + *килү* ярдәмче фигыль моделе. Бу модельдәге кушма фигыльләр күп түгел: *туры килү, рас килү, чәлпәрәмә килү, тәңгәл килү.* Алар беренче компонент – рәвеш белдергәнчә *булу* дигән мәгънәне тәгъбир итәләр.

Аваз ияртеме + *килү* ярдәмче фигыль моделе. Һәр аваз ияртеменнән, кагыйдә буларак, *килү* ярдәмче фигыле белән кушма фигыльләр ясала. Беренче сүз бер компонентлы да, ике компонентлы да булырга мөмкин: *чый килү, чупыр-чупыр килү, гөж килү, чымыр-чымыр килү, чылтыр-чылтыр килү, без-без килү. Килү* ярдәмче фигыле белән ясалган кушма фигыльләр якынча беренче компонент белдергән авазларны барлыкка китерү мәгънәсен белдерәләр.

Образ ияртеме + *килү* ярдәмче фигыле моделе. *Килү* ярдәмче фигыле белән шулай ук образ ияртемнәреннән дә кушма фигыльләр ясала. Кушма фигыльнең беренче компоненты бер элементлы да, ике элементлы да булырга мөмкин: *мыж килү, мәш килү, елтыр-елтыр килү, әлҗе-мөлҗе килү, кыймыл-кыймыл килү.* Алар беренче компонент белдергән образны чагылдыру дигән мәгънәне тәгъбир итәләр.

**Нигез + *булу* фигыле тибы.** Бу типта кушма фигыльләр ясалышы татар телендә бик продуктив. Кушма фигыльләрнең бу төрендә беренче компонент бәйсез (мөстәкыйль) һәм бәйле дә булырга мөмкин. Бәйле компонентлы кушма фигыльләр: *кабул булу, пәйда булу, дучар булу, тар-мар булу.* Бәйсез компонентлы кушма фигыльләр: *риза булу, юк булу, тиң булу, бар булу.*

Исем + *булу* ярдәмче фигыль моделе. Бу модельдәге кушма фигыльләр күп түгел: *кәфил булу, тәмам булу, һәлак булу.* Болар беренче компонент – исем белдергән эш-хәрәкәтнең башкарылуын тәгъбир итә.

Сыйфат + *булу* ярдәмче фигыле моделе. Бу модельдәге кушма фигыльләр шактый күп: *гашыйк булу, өстен булу, яраклы булу, ап-ак булу, риза булу, хәйран булу.* Бу кушма фигыльләр беренче компонент – сыйфат белдергән билгенең, нәрсәнең чагылуын, башкарылуын тәгъбир итәләр.

Рәвеш + *булу* ярдәмче фигыль моделе. Кайбер рәвешләрдән дә *булу* ярдәмче фигыле кушма фигыльләр ясый: *шым булу, әвәрә булу, каршы*

*булу, тап булу.* Алар эш-хәрәкәтнең беренче компонент – рәвеш белдергәнчә булуын тәгъбир итәләр.

Хәбәрлек сүз + *булу* ярдәмче фигыль моделе. Бу модель белән ясалган кушма фигыльләр беренче компонент белдергән эш-хәрәкәтнең яки процессның барлыкка килүен, чагылуын тәгъбир итәләр: *бар булу, юк булу, тиеш булу, кирәк булу.*

**Нигез + *кылу* фигыле тибы.** *Кылу* ярдәмче фигыле исемнәрдән кушма фигыльләр ясый. *Кылу* ярдәмче фигыле ндә беркадәр архаиклык төсмере булганлыктан, аның нигезендә ясалган кушма фигыльләрдә дә беркадәр архаиклык төсмере чагыла: *хата кылу, карар кылу, гөнаһ кылу, һибә кылу, бәхәс кылу, хәл кылу, тәүбә кылу, тамаша кылу.*

Бу фигыльләр беренче компонент – исем белдергән нәрсәне, эшне башкару мәгънәсен тәгъбир итәләр. Алар күчемле дә (*хәл кылу, һибә кылу*), күчемсез дә (*хата кылу, карар кылу*) булырга мөмкиннәр.

**Нигез + *ясау* фигыле тибы.** *Ясау* ярдәмче фигыле белән кушма фигыльләр ясала, алар беренче компонент-исем белдергән эш-хәрәкәтне башкаруны тәгъбир итәләр: *бойкот ясау, манёвр ясау, репетиция ясау.* Бу комбинацияләр ирекле сүзтезмәләр белән кушма фигыльләр арасында торалар. Эчтәлеге һәм лексик-грамматик үзенчәлеге ягыннан алар кушма сүзләргә якынраклар.

**Нигез + *бирү* фигыле тибы.** *Бирү* ярдәмче фигыле шулай ук кушма фигыльләр ясауда катнаша. Алар беренче компонент – исем белдергән нәрсәне, эш-хәрәкәтне башкаруны тәгъбир итәләр: *санкция бирү, комментарий бирү, хәбәр бирү, карар бирү.* Кайбер кушма фигыльләр метафорик мәгънә белдерергә мөмкин: *тавыш бирү.* Бу типтагы күп кенә тезмәләр ирекле сүзтезмәләрен тәшкил итәләр: *бүләк бирү, премия бирү.*

**Нигез + *алу* фигыле тибы.** Мондый типтагы бары берничә кушма фигыль генә бар: *хәл алу, имтихан алу.* Боларны сүзтезмәләр кушма фигыльгә күчкән дип санап булмый, алар барлыкка килгәндә үк сүзтезмә буларак түгел, кушма сүз буларак формалашканнар.

### 9.6.4. Тезмә фигыльләрнең фигыльләрдән ясалуы

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә кызыклы һәм үзенчәлекле күренеш – фигыльләрнең фигыльләрдән барлыкка килүе. Күпчелек тюркологлар мондый фигыльләрне тезмә фигыль дип атыйлар.

Алар турында беренче мәгълүматны И. Гиганов, А. Троянский, А. Казимбәк, М. Иванов грамматикаларында очратабыз. Тезмә фигыльләр турында мәгълүмат Ә. Максуди, Г. Нугайбәк, Г. Сәгъди грамматикаларында да бирелә. Инкыйлабтан соң татар теленең грамматик төзелешен тикшерү шактый көчәеп китә. Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров хезмәтләрендә тезмә фигыльләргә теге яки бу күләмдә анализ ясала. Г. Алпаров фикеренчә, ярдәмче фигыльләр төп фигыльгә өстәмә мәгънә бирү өчен кулланылалар. Р. Газизов тезмә фигыльләрне лексик берәмлекләр рәтенә кертеп карый. В. Хангилдин, ярдәмче фигыльләр кушма фигыльләр ясаганда төп фигыльнең семантикасына йогынты ясыйлар, дип саный.

А.Н. Кононов, В.М. Насилов, Н.А. Баскаков, Д.М. Насилов үзләренең хезмәтләрендә төрки телләрдәге тезмә фигыльләрнең үзенчәлекләрен ачып салалар. А.Г. Алекперов азәрбайҗан телендә, Н.О. Оралбаева казакъ телендә, М.М. Текуев карачай-балкар телендә тезмә фигыльләр мөстәкыйль фигыль тәшкил итә һәм алар грамматик төр мәгънәсен белдерми дип санайлар.

Тезмә («кушма») фигыльләр бер телдә (мәсәлән, рус телендә) юк, икенче телләрдә (мәсәлән, япон һәм һинд телләрдә) киң таралган. Икенче тип телләргә шулай ук төрки телләр дә, шул исәптән татар теле дә керә.

Тюркологиядә тезмә фигыльләр, соңгы вакытка кадәр диярлек, грамматик төр категориясен белдерә дип саналды.

Татар телендә тезмә фигыльләр *-п* га яки *-а, -ә, -й* гә беткән хәл-фигыльләргә аларны модификацияләүче кайбер фигыльләр кушылып ясала. Әмма шундый ук конструкцияләр ирекле сүзтезмәләр дә тәшкил итәргә мөмкин. Шуңа күрә аерым очракларда мондый тезмәнең ирекле сүзтезмәме яки тезмә фигыльме булуын билгеләве авырга туры килә.

Мондый конструкцияләр түбәндәге очракларда ирекле сүзтезмә тәшкил итәләр: 1) хәл фигыль җөмлә кисәге булган хәлне белдереп, аның артыннан килгән фигыль төп эш-хәрәкәтне тәгъбир иткәндә; 2) хәл фигыль белән аның артыннан килгән фигыльләр эзлекле яки параллель мөстәкыйль эш-хәрәкәтне белдергәндә.

Хәзер бу очракларны карап китик.

Беренче очракта хәл фигыль җөмләдә рәвеш, сәбәп хәлләре булып, аның артыннан килгән затланышлы фигыль – башка җөмлә кисәге, гадәттә хәбәр булып килергә мөмкин: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак а п т ы р а п  у т ы р д ы к .* Г. Бәширов. *Тойгыларны җиңә алмыйча, ул бер минут чамасы бусага төбендә т а п т а н ы п т о р д ы .* И. Газый. *Өйдә а в ы р ы п  к а л д ы м . Юлда е г ы л ы п к а л д ы м .*

Китерелгән конструкцияләрдә (ирекле сүзтезмәләрендә) хәл фигыль белән килгән фигыльләр җөмләдә өченче бер мөстәкыйль сүз белән аерыла алалар. Мәсәлән, *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап утырдык* җөмләсендәге тезмә фигыльгә охшаш комбинациягә кергән сүзләрне җөмләдә өченче мөстәкыйль сүз белән аерырга була: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап, уйланып утырдык.* Күренгәнчә, комбинациягә кергән сүзләрне аерудан җөмләнең бөтенлеге юкка чыкмый. Бу комбинациядә хәл фигыль бөтенләй булмаса да, җөмләнең бөтенлегенә зыян килми: *Бу хатны ничек башларга белмичә озак... утырдык.*

*Аптырап утырдык* комбинациясендә ике фигыль дә мөстәкыйль җөмлә кисәкләре булып килгән. Димәк, ирекле сүзтезмәләр (биредә хәл фигыль белән хәбәр тезмәсе), тышкы күренеше ягыннан тезмә фигыльләргә охшаса да, бер төркем билгеләре аларны тезмә (кушма) фигыльләрдән аера: 1) комбинациягә кергән сүзләрнең өченче мөстәкыйль сүз белән аерыла алу мөмкинлеге; 2) хәл фигыльне төшереп калдырудан җөмләнең бөтенлеге югалмау; 3) һәр ике фигыльнең дә мәгънәләренең мөстәкыйльлеге һәм бөтенлеге; 4) җөмләдә һәр икесе аерым җөмлә кисәге булып килүе. Тезмә фигыльләргә бу сыйфатлар хас түгел.

Икенче очракта хәл фигыль белән аның артыннан килгән фигыль эзлекле яки параллель эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Ул җилтерәп кенә чыгып, сыерын ябып, ю ы н ы п  к е р д е .* Г. Бәширов. *Бала тудыру йортына к е р е п  ч ы к т ы .* Г. Әпсәләмов. *Шәһәргә барып кайттым. Айсылу... сәхнәдәге кызыл япмалы озын өстәл артына м е н е п  б а с т ы .* Г. Бәширов.

Китерелгән мисалларда хәл фигыль+затланышлы фигыль тезмәләре тышкы күренеше белән тезмә фигыльләрне хәтерләтә, әмма үзләренең эчтәлеге ягыннан алардан тамырыннан аерыла. Чөнки бу

комбинацияләрдә фигыльләр бердәм мәгънә барлыкка китермиләр, ә эзлекле яки параллель ике мөстәкыйль эш-хәрәкәтне белдерәләр. Өстәвенә, бу комбинацияләргә кергән сүзләр өченче сүз белән аерыла ала. Мәсәлән, *барып кайттым* тезмәсенә кергән сүзләрне *Шәһәргә барып кайттым* җөмләсендә өченче мөстәкыйль сүз белән аерырга мөмкин: *Шәһәргә барып әйберләр сатып алып кайттым.* Өченче мөстәкыйль сүз белән бу комбинациянең аерыла алуы бу тезмәнең фигыльләренә үзара мәгънә кереше һәм үзара бәйләнгәнлек хас булмавын күрсәтә. Алар бу яктан мөстәкыйльләр, бөтенләй төрле мәгънә белдерәләр, болар исә кушма фигыль булу принцибына каршы киләләр. Димәк, бу тезмәләр тезмә фигыльләргә охшасалар да, ул охшашлык тышкы яктан гына булуы ачыклана.

Тезмә фигыльләрне шулай ук фигыльләрнең кушма формаларыннан (заман, модаль формалардан) аерырга кирәк. Чөнки татар телендә аналитик заман формалары яңа сүз тәшкил итмиләр. Мәсәлән, *барган иде, бара иде* заман формалары, аналитик (кушма) булсалар да, икенче элемент бернинди дә лексик мәгънә кертмәгәнлектән, бары грамматик мәгънә белдергәнлектән, аларны кушма сүзләр дип карап булмый.

Татар телендә фигыльләрнең модаль формалары тезмә (кушма) фигыльләр тәшкил итмиләр. *Яза алу* формасында икенче компонент бары грамматик функциягә генә – модальлек функциясенә генә ия. Күренгәнчә, ике сүздән торган заман формалары да, модаль формалар да татар телендә кушма сүз тәшкил итмиләр. Чөнки «фигыльнең кушма формасы әле кушма фигыль түгел» (А.Г. Алекперов).

Кушма формалар ясалышы рус телендә дә очрый: *самый хороший, буду писать* һ.б. Ләкин бу формаларны кушма сүзләр дип карап булмый, чөнки компонентларның берсе реаль мәгънәгә ия түгел, бары грамматик мәгънә генә белдерә.

Тезмә фигыльләр түбәндәге үзенчәлекләр белән тасвирланалар. Беренчедән, тезмә фигыльләр бер лексик мәгънә белдерәләр һәм бәйләнешле рәвештә җөмләдә, барыбер, җөмлә кисәге буларак кына киләләр. Мәсәлән, *Мин китапны укып чыктым* җөмләсендә тезмә фигыль бер эшне белдерә һәм мөстәкыйль җөмлә кисәге – хәбәр булып килә. Ә ирекле сүзтезмәләр исә, формалары ягыннан кушма фигыльләргә охшаса да, ике төрле эш-хәрәкәт белдерәләр, җөмләдә ике

җөмлә кисәге булып киләләр, яки эзлекле, яки параллель эш-хәрәкәт белдерәләр.

Кайбер тезмә фигыльләрнең мәгънәсе аларны тәшкил итә торган компонентларның гади суммасына тигез. Мәсәлән, *язып бетерү, ашап бетерү* тезмә фигыльләренең мәгънәсе аларны тәшкил итә торган компонентларның мәгънәләре суммасына тигез. Ләкин күпчелек тезмә фигыльләрнең мәгънәләре күчмә була, ягъни аларның мәгънәләре аларны тәшкил итә торган компонентларның мәгънәләреннән турыдан-туры чыкмый, мәсәлән, *укып чыгу, каушап төшү, карап алу* һ.б. Икенчедән, тезмә фигыльләрнең компонентлары җөмләдә ирекле сүтезмәләрдәге кебек аерым кулланыла алмый. Тезмә фигыльләрнең компонентларын, мәгънәгә зыян китермичә, өченче мөстәкыйль сүз белән аерып булмый. Фигыльле тезмәләргә кергән сүзләрнең өченче сүз белән хәтта потенциаль аерылу мөмкинлекләре дә аларның мөстәкыйльлекләре, тезмәнең ирекле сүз булуы турында сөйли. Мәсәлән, *барып кайтырга* комбинациясе мөстәкыйль сүз белән аерылырга мөмкин. Мәсәлән, *Шәһәргә барып, авылга кире кайтты* дип әйтергә була, *барып* һәм *кайт* фигыльләре үзләренең мөстәкыйльлекләрен саклыйлар, лексик яктан үзара бәйләнмәгәннәр, үзара мәгънә кереше юк. Алар эзлекле барган эшхәрәкәтне белдерәләр. Рус телендә аларга тиңдәш хәбәрләр туры килә.

Тезмә фигыльләрнең компонентлары арасына мәгънәне бозмыйча яңа мөстәкыйль сүз куеп булмый. Телнең синтаксик нормаларына хилафлык кылмыйча түбәндәгечә сөйләп булмый: *Бу китапны укып мин чыктым* яки *Укып бу китапны мин чыктым. Бу хәбәрдән каушап мин төштем. Мин каушап бу хәбәрдән төштем.*

Татар телендә тезмә фигыльләрнең компонентлары бары мөстәкыйль булмаган сүзләр белән генә, атап әйткәндә көчәйткеч кисәкчәләр *да/дә* (*-та/-тә*) һәм чикләүче кисәкчәләр *гына/генә* (*кына/кенә*) белән аерылырга мөмкин. Мондый очракларда көчәйткеч кисәкчәләр тезмә фигыльгә тизлек, интенсивлык мәгънәсен бирә: *Наташа... сәхнәгә менеп тә җитте.* Чикләүче кисәкчәләр тезмә фигыльгә чикләү мәгънәсен һәм эш-хәрәкәтнең әле генә башкарылуын белдерә: *Китапны укып кына чыккан идем, иптәшем килде.*

Өченчедән, тезмә фигыльләрдә компонентлар, арасында ирекле сүтезмәләрдәге кебек, үзара синтаксик бәйләнешләр табып булмый. Мәсәлән, *укып чыкты* дигән тезмә фигыльдә бернинди дә синтак-

сик мөнәсәбәт билгеләп булмый, ә *аптырап утырдык* дигән сүзтезмәдә ачыктан-ачык синтаксик бәйләнеш күзәтелә (хәл белән хәбәр бәйләнеше).

Дүртенчедән, тезмә фигыльләрнең компонентлары арасында үзара мәгънә кереше һәм шартлы бәйлелек бар, чөнки тезмә фигыльләрнең икенче компоненты төп фигыльнең мәгънәсен модификацияли, конкретлаштыра, бары аңа гына бәйле, аңардан башка җөмләнең бөтенлеген бозмыйча яши алмый. Мәсәлән, *Мин бу китапны укып чыктым* җөмләсендә *чыктым* компоненты *укып* сүзеннән башка мөстәкыйль яши алмый. Мәсәлән, мәгънәне яки җөмләне бозмыйча *Бу китапны чыктым* дип әйтеп булмый. Бу хәл компонентлар арасындагы мәгънә кереше һәм шартлы бәйлелектән килеп чыга. Тезмә фигыльләргә охшаш ирекле сүзтезмәләрдә мондый хәл күзәтелми. Ирекле сүзтезмәләрендә затланышлы фигыль (сүзтезмәнең икенче сүзе) җөмлә кисәге булганлыктан һәм җөмләнең башка кисәкләре белән бәйләнгәнлектән, хәл фигыльгә генә карамыйча, ул бөтен җөмләгә карый һәм ул хәл фигыльсез дә, мөстәкыйль кулланылырга да мөмкин. Бу – хәл фигыль белән аннан соң килә торган фигыль арасында сүзтезмәләрдәге кебек мәгънә кереше һәм шартлы бәйлелек булмаганлыктан килеп чыга. Мәсәлән, *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап утырдык* җөмләсендә ирекле сүзтезмәдәге хәл фигыльне төшереп тә калдырырга мөмкин. Бу вакытта җөмләнең бөтенлеге бозылмый, тезмә фигыльләрдә исә моны эшләп булмый.

Бишенчедән, тезмә фигыльләрнең бердәнбер басымы була, аларның компонентлары беренче компонентка төшкән гомуми төп басым белән үзара беркетелә: *укы́п чыгу, кауша́п төшү*.

Гомумән шуны әйтергә кирәк, югарыда китерелгән билгеләрнең берсе дә абсолют түгел, күрсәтелгән үзенчәлекләр бары бергә генә тезмә фигыль китереп чыгара, тел фактлары күрсәткәнчә, татар теленең лексик берәмлеген тәшкил итә.

Тюркологиядә тезмә фигыльнең төп мәгънәсе беренче компонент (хәл фигыль) белән белдерелә, ә модификацияләүче фигыль өстәмә мәгънә бирә, беренче фигыльнең мәгънәсен конкретлаштыра дигән традицион караш яшәп килә.

Татар теле фактлары күрсәткәнчә, беренче һәм икенче компонентлар арасында үзара бәйләнеш үзгәрергә дә мөмкин, төп мәгънә

кайвакытта икенче компонент – фигыльнең затланышлы формасы белән дә, өстәмә мәгънә – хәл фигыль формасы белән дә белдерелергә мөмкин. Мәсәлән, *алып бару, алып килү, алып кую, алып бирү, алып чыгу, алып калу, алып китү* тезмә фигыльләренең тулысынча семантикасы саклануын, төп мәгънәне белдерүен, беренче компонентлар исә, модификацияләүче фигыльгә әйләнеп, икенче компонентларның мәгънәләрен конкретлаштыруын күрсәтә. Шул сәбәптән сөйләм телендә беренче компонентлар сүз формасын югалтып префиксоидка әйләнгәннәр: *алып бару → аппару → апару, алып килү + апкилү, алып кую → апкую, алып бирү → аппирү → апирү, алып чыгу → апчыгу, алып калу → апкалу, алып китү → апкитү, алып керү + апкерү.*

Шулай итеп, тезмә фигыльдә кайбер вакыт хәл фигыль формасы модификацияләүче фигыль, ә икенче компонент – төп фигыль тәшкил итәргә мөмкин. Бу хәл теләсә нинди структур берәмлектә, кагыйдә буларак, беренче чиратта икенче дәрәҗәдәге элемент үзгәрүгә дучар булуы белән аңлатыла. Шундый хәл *алып кит* тибындагы тезмә фигыльләрдә күзәтелә.

Югарыда китерелгән мисалларда *ап* элементы *алып* фигыленең матди сүз формасын югалткан кыскарма формасын тәшкил итә, ул инде сүз дәрәҗәсендәге структур берәмлек булып тормый, шуңа күрә аларны сүзләр кушылуга нигезләнгән сүзьясалышка кертеп булмый.

Тезмә фигыльләрнең компонентлары арасында, һичшиксез, тере синтаксик бәйләнеш юк, шуңа карамастан бәйләнешләрнең шартлы рәвештә сүзтезмәләренә туры килүеннән чыгып, алар арасында ияртүле бәйләнеш күзәтелә дип әйтергә мөмкин. Тезмә фигыльләр, нигездә, сүзләр кушылу юлы белән барлыкка килгәннәр һәм киләләр. Мәсәлән, барлык неологизм булган фигыльләр шунда ук ярдәмче фигыльләр белән кушылып тезмә фигыльләр ясыйлар: *күзаллап чыгу, автоматлаштырып бетерү, анализлап тору, абстракцияли төшү.*

Татар телендә тезмә фигыльләр ясалышының түбәндәге типлары бар:

хәл фигыль + алу
хәл фигыль + *ату* (ташлау)
хәл фигыль + *бару*
хәл фигыль + *башлау*
хәл фигыль + *бетү*

хәл фигыль + *бетерү*
хәл фигыль + *бирү*
хәл фигыль + *йөрү*
хәл фигыль + *калу*
хәл фигыль + *карау*
хәл фигыль + *керү*
хәл фигыль + *килү*
хәл фигыль + *китү*
хәл фигыль + *кую*
хәл фигыль + *салу*
хәл фигыль + *тору*
хәл фигыль + *төшү*
хәл фигыль + *узу*
хәл фигыль + *утыру*
хәл фигыль + *чыгу*
хәл фигыль + *чыгару*
хәл фигыль + *язу*
хәл фигыль + *яту*
хәл фигыль + *үтү*
хәл фигыль + *җибәрү*
хәл фигыль + *җитү*
хәл фигыль + *җиткерү*

Бу типтагы тезмә фигыльләрнең икенче компонентлары модификацияләүче фигыльләр тәшкил итәләр. Аларны тюркологиядә ярдәмче фигыльләр дип йөртәләр. Бер үк модификацияләүче фигыль (ярдәмче фигыль), контекстка бәйләнешле рәвештә һәм нинди хәл фигыль белән килүеннән чыгып, берничә мәгънә белдерә ала.

Түбәндә ярдәмче фигыль белән ясалган тезмә фигыльләрнең мәгънәләре бирелә.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *алу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр.

1. Кыска вакыт эчендә эш-хәрәкәт башкаруны: *Күз кырыен төшереп алды*. И. Газый.

2. Тәкрарлы, әмма озак бармаган эш-хәрәкәтне: *Карт... таягын тукылдатып алды*. Г. Бәширов.

3. Аз вакыт эчендә башкарылган өзлексез эш-хәрәкәтне: *Сәлим бераз йоклап алды.*

4. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Фәрихә үзенең ялгышын сизеп алды.* Ш. Камал.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *ату* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр тиз башкарылган нәтиҗәле эш-хәрәкәтне белдерә: *Туганыма хат язып аттым.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *бару* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр.

1. Көчәя, арта барган эш-хәрәкәтне: *Тормыш яхшыланып бара.*

2. Үзенең ахырына, чигенә таба барган эш-хәрәкәтне: *Запаслар бетеп бара.*

3. Даими башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Газетларны укып бара.*

4. Билгеле бер юнәлештә башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Тауга менеп барабыз.*

5. Даими башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Укытучы әйтеп тора, мин язып барам.*

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *бару* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр.

1. Эш-хәрәкәтнең көчәя, арта баруын: *Эш кыза барды.*

2. Даими башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Без суны түгә бардык.*

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *башлау* ярдәмче фигыленнән ясалган тезмә фигыльләр эш-хәрәкәтнең башланып китүен белдерә: *Яз җитеп, карлар эри башлады.* Г. Тукай.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *бету* ярдәмче фигыленнән ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын: *Хис тиз янып бетте. Эш эшләнеп бетте.*

2. Эш-хәрәкәтнең ахыр чиккә җитүен, соң дәрәҗәдә булуын: *Көтә-көтә зарыгып беттем.* Һ. Такташ.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *бетерү* ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне, эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын: *Ул тәмәкесен т а р т ы п  б е т е р д е*. М. Гафури.

2. Эш-хәрәкәтнең ахыргы чиккә, соң дәрәҗәгә җитүен: *Күчереп т и н т е р ә т е п  б е т е р д е л ә р*. Ш. Камал.

3. Күп предметларга яисә берәр нәрсәнең өслегенә тулысынча таралган эш-хәрәкәтне: *Йомыркаларны в а т ы п  б е т е р г ә н. Стенага рәсемнәр я б ы ш т ы р ы п  б е т е р г ә н*.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *бирү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр. Берәр объект яки субъект юнәлешендә, мәнфәгатендә башкарылган эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Өйгә кайткач, картына бөтен нәрсәне с ө й л ә п  б и р д е*.

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *бирү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр бернәрсәгә карамастан башкарыла торган эш-хәрәкәтне белдерә: *Үз хәлен кешегә белдермичә й ө р и б и р д е*.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *йөрү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр өзлексез, субъект өчен чагыштырмача даими булган эш-хәрәкәтне белдерә: *Бик һәйбәт кенә тырышып у к ы п  й ө р и л ә р*. Г. Ибраһимов. *Рәхәт-рәхәт к ү ч е п  й ө р и л ә р  иде*. Г. Ибраһимов.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *калу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Йөрәк ярасыннан күңелгә моң у т ы р ы п  к а л а. Иптәшем т ы н ы п  к а л д ы*.

2. Субъектны тулысынча чолгап алган эш-хәрәкәтне: *Туташ а п т ы р а п  к а л д ы*. Г. Ибраһимов.

3. Беркадәр дәвамлы хәл барлыкка килеп, тәмамланган эш-хәрәкәтне: *Өчесе дә т ы н ы п  к а л д ы л а р*. Г. Гобәй.

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль+*калу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр башкаручының эш-хәрәкәтне тәмамламый калуын белдерә: *Морат я з а  к а л д ы*.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *карау* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр эш-хәрәкәтне сынапкарауны яки башкарырга омтылуны белдерә: *Мәкалә я з ы п  к а р а д ы м*.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *керү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр берәр нәрсәнең эченә юнәлгән эш-хәрәкәтне

белдерә. Кайбер очракларда кинәтлек төсмере дә чагыла: *Шул арада әни кайтып керде.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *килү* ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Берәр урынга яки сөйләүчегә юнәлгән эш-хәрәкәтне: *Зиннәт авылына кайтып килә.* Г. Бәширов.

2. Үзенең чигенә, соңгы дәрәҗәсенә акрынлап якынлашып барган эш-хәрәкәтне: *Көн караңгыланып килә.* Һ. Такташ.

3. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Бүләк алып килделәр.*

4. Тәкрарлы (регуляр) башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Аны кисәтеп килделәр.*

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *килү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр билгеле бер вакытка кадәр башкарыла торган тәкрарлы эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Аңа мин әйтә килдем.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *китү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр.

1. Берәр чыгыш урыныннан яки сөйләүчедән ераклаша барып башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Мәктәптән кайтып китте.*

2. Югарырак дәрәҗәдә берәр үзенчәлек, сыйфат алуны: *Эш чыгырында яңадан дусланып киттеләр.* Ш. Камал.

3. Эш-хәрәкәтнең башланып китүен: *Алмаев кабинеты буйлап йөреп китте.* И. Газый.

4. Кинәт яки тиз башкарылган эш-хәрәкәтне: *Караңгы зал кинәт яктырып китә.* Һ. Такташ.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *кую* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Кинәт яки тиз бер кат башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Гыйльманов баскан урынында сикереп куйды.* И. Газый.

2. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Утынны күп итеп ярып куйдылар.* Г. Бәширов.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *салу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр кинәт яки көтелмәстән башкарылган эш-хәрәкәтне: *Ул иптәше белмәгәнне әйтеп салды.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *ташлау* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Бөтен тулылыгы белән башкарылган нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Бер үзе өч-дүрт эскерт куеп ташлады*. Г. Бәширов.

2. Кинәттән яки көтмәстән башкарылган эш-хәрәкәтне: *Ни өчендер ул моны әйтеп ташлады*.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *тору* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешсез бара торган эш-хәрәкәтне: *Вак яңгыр сибәләп тора*. Ш. Камал.

2. Тәкрарлы (регуляр) эш-хәрәкәтне: *Мин эшемнең һәр үрнәген язып тордым аларга*. М. Җәлил.

3. Предмет өчен даими яки гадәти булган эш-хәрәкәтне: *Миләш тәлгәшләре асылынып тора*. Г. Бәширов.

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *тору* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Озак дәвам итә торган яки тәкрарлы (регуляр) эш-хәрәкәтне: *Эшелоннар китә тордылар*. Ш. Усманов.

2. Өлешчә башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Алар бара торсыннар*.

-*п* га тәмамланган хәл фигыль+*төшү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Субъектны яки предметны тулысынча чолгап алган эш-хәрәкәтне: *Хәдичә каушап төште*. Г. Бәширов.

2. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Ботак бөгелеп төште*.

3. Кинәт яки тиз башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Кичкырын килеп төште*. Ш. Камал.

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *төшү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Берәр урын яки вакыт аралагында бара торган өлешчә эш-хәрәкәтне: *Түргә уза төште*.

2. Эш-хәрәкәтнең өлешчә көчәюен яки кимүен: *Үләннәр яшелләнә төште. Ул агара төште*.

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *узу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Берәр нәрсә аша яки барышлый башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Айсылу ниләр язуын белешеп уза*. Г. Бәширов.

2. Тулысынча (тулаем) башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Ул бу хәлләрне сөйләп узды.*

*-п га* тәмамланган хәл фигыль + *утыру* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр дәвамлы, өзлексез бара торган эш-хәрәкәтне белдерәләр. *Мичкә агып утыра. Су кайнап утыра.*

*-п гә* тәмамланган хәл фигыль + *чыгу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Берәр нәрсәнең эченнән, уртасыннан читкә таба бара торган эш-хәрәкәтне: *Корт алманы тишеп чыккан.*

2. Билгеле бер вакыт аралыгында тулысынча бара торган эш-хәрәкәтне: *Төн буе* (*мич*) *ягып чыгалар.* М. Гафури.

3. Предметның барлык өслегенә таралган эш-хәрәкәтне: *Идәнне буяп чыктык.*

4. Башыннан ахырына кадәр башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Кулымдагы хатны тагын бер кат укып чыктым.* М. Гафури.

5. Бик күп затларга һәм предметларга караган эш-хәрәкәтне: *Киткәндә барыбызны да үбеп чыкты. Сарыкларны санап чыктылар.*

6. Көтелмәгән яки кинәттән башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Түрәгә охшаган бер адәм килеп чыкты.* Г. Ибраһимов.

7. Билгеле бер урын аралыгында башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Бөтен авылны әйләнеп чыктык. Рәис үзенең хуҗалыгын йөреп чыкты.*

8. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Без җиңеп чыгачакбыз.*

9. Берәр урын, предмет аша башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Бүрәнәне атлап чыктылар. Елга аша йөзеп чыктык.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *чыгару* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр нәтиҗәле эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Әни бер армый-талмый байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.* Г. Тукай. *Нәфисә үзе исәпләп чыгара.* Г. Бәширов.

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *язу* ярдәмче фигыле кушылып тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Башкарылмый калган эш-хәрәкәтне: *Хәлим авылга китә язды.*

2. Берәр эш-хәрәкәтнең чигенә җитә язып тукталып калуын: *Гали үлә язган.*

-*п* га тәмамланган хәл фигыль+*яту* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Билгеле бер вакыт дәвам иткән эш-хәрәкәтне: *Комиссия бодаеңны сугып ята.* Г. Бәширов.

2. Предметның гадәти хәлен: *Дала көзге кебек җәелеп ята.*

-*п* га тәмамланган хәл фигыль + *үтү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Барышлый яки берәр нәрсә аркылы башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Бөтен безнең юл сөйләшеп үтте.*

2. Тулысынча (тулаем) башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Укытучы моның турында сөйләп үтте.*

-*п* га тәмамланган хәл фигыль + *җибәрү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Кинәтлек төсмере белән башланып киткән кискен эш-хәрәкәтне: *Бала кычкырып җибәрде. Урманов сызгырып җибәрде.* Г. Ибраһимов.

2. Эш-хәрәкәтнең гомумән башлануын: *Кызый елап җибәрде.* Ә. Еники.

-*п* га тәмамланган хәл фигыль + *җитү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр. Алар түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. Билгеле бер объектка, урынга җитә торган эш-хәрәкәтне: *Ак-түш көймәне бик тиз куып җитте.* Г. Гобәй.

2. Билгеле бер хәлгә, чиккә җитә торган эш-хәрәкәтне: *Ул хәлне тәмам аңлап җитә.* Г. Ибраһимов.

-*п* га тәмамланган хәл фигыль + *җиткерү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр билгеле бер урынга, объектка җиткерелә торган эш-хәрәкәтне белдерә: *Китапны аңа илтеп җиткер.*

### 9.6.5. Лексик-семантик ысул белән фигыльләр ясалышы

Татар телендә фигыльләр лексик-семантик ысул белән дә ясалалар. Бу вакытта фигыльнең мәгънәсе киңәя барып, фигыль нигез фигыль белән үзенең лексик-семантик бәйләнешен тулысынча өзә, һәм, шулай итеп, яңа матди лексик берәмлек – элекке фигыльнең омонимы барлыкка килә.

Мәдәният, җәмгыять, җитештерү белән бәйләнгән мәгънәләр, кагыйдә буларак, табигать, кеше белән бәйләнгән мәгънәләргә карата икенчел булалар.

Лексик-семантик ысул белән фигыльләр ясалышының түбәндәге типлары бар.

1. Эш-хәрәкәт фигыле → абстракт процесс фигыле: *из → из* (халыкны изү), *кыс → кыс* (*халыкны кысу*), бас → бас (*халыкны басу*).

2. Хәрәкәт фигыле → эш фигыле: *чайка → чайка* (*кер чайкау*).

3. Конкрет процесс фигыле → эш фигыле: *озат → озат* (*җепне озату*), *көт → көт* (*көтү көтү*), *чират → чират* (*җепне бөтерү*)

4. Конкрет процесс фигыле → торыш фигыле: *ое → ое* (*аяк ою*), *төнә → төнә* (*шәраб турында*).

## 9.7. СЫЙФАТЛАР ЯСАЛЫШЫ

### 9.7.1. Фонетик ысул белән сыйфатлар ясалышы

Хәзерге көндә фонетик ысул белән сыйфатлар ясалышы күзәтелми. Телебезнең тарихи үсеш процессында бу ысул белән сыйфатлар ясалган.

1. Аваз төшеп калу юлы белән сыйфатлар хасил булган: хәзер – әзер. Бу эшне хәзер эшләргә кирәк. Әзер эшләрне тапшырырга вакыт.

2. Нигезләрнең нечкәрүе (палатальләнүе) шулай ук сыйфатлар барлыкка китергән. Бу юл белән сыйфатлар ясалганда кайбер авазлар чиратлашырга да мөмкин: *балакай – бәләкәй, тау – дәү, шалама – сәләмә.*

3. Сыйфатларның тарихи ясалыш процессында авазларның чиратлашуы да билгеле бер урын тоткан: *шума – шома, биек – бөек.*

4. Басымнарның күчүе дә сыйфатлар барлыкка китерергә мөмкин: *ко́ры – коры́, кы́зык – кызы́к, я́бык –ябы́к, ә́че – әче́, ө́лгер – өлге́р.* Биредә сүзләрнең беренчеләре фигыль нигезләрен тәшкил итә.

### 9.7.2. Кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышы

Хәзерге татар телендә кушымчалар белән сыйфатлар ясалышы иң продуктив ысулларның берсе булып тора. Бу ысул беренче төрки грамматикаларда ук күрсәтелә. Кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышы турында А.М. Казимбәк, О. Бётлингк, Алтай миссиясе,

М. Терентьев, Н.И. Ашмарин, Н.Ф. Катанов грамматикаларында мәгълүмат бар.

Инкыйлабтан соң чыккан грамматикаларда сыйфатлар ясый торган кушымчаларга шулай ук игътибар бирелә. В.А. Гордлевский, Г.В. Архангельский, А.Ш. Караханов, С.В. Ястремский, Н.К. Дмитриев, Н.А. Баскаков, Н.П. Дыренкова, А.Н. Кононов, Н.Г. Домажаков, Л.Н. Харитонов, Т.И. Грунин, Ф.Г. Исхаков, Т.М. Гарипов, Ә.Н. Нәҗип, А.М. Щербак, Б.О. Орузбаева, Л.А. Покровская, М.А. Хабичев хезмәтләрендә һәм коллектив грамматикаларда кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышы карала.

Татар теле белемендә бары гомуми грамматикаларда гына кушымчалар белән сыйфатлар ясалышы китерелә.

Инде И. Гиганов, М. Иванов, Г. Мәхмүдов, Х. Фәйзханов, К. Насыйри, Ал. Архангельский грамматикаларында ук сыйфатлар ясый торган кушымчалар турында мәгълүматлар бар. XX гасыр башында чыккан грамматикаларда да кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышына урын бирелә.

Инкыйлабтан соң М. Корбангалиев, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, Х. Бәдигый грамматикаларында сүзьясалышка, шул исәптән сыйфатлар ясалышына да шактый нык игътибар ителә.

Соңгы елларда В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева һәм коллектив грамматикаларда кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышы карала.

Әмма бу грамматикаларда, кагыйдә буларак, кушымчаларның мәгънәләре ясаучы нигезләргә бәйләмичә күрсәтелә. Бу исә кушымчалар ярдәмендә сүзьясалышны системасыз һәм структур яктан дөрес булмаган юл белән аңлатуга китерә. Күп кушымчаларның, әлбәттә, барлык мәгънәләре һәм төсмерләре ачылмый, сыйфат ясаучы кушымчаларның саны 2–3 мәртәбәгә ким булып чыккан.

Сүзьясалышка бернинди катнашы булмаган элементларны (кушымчаларны) сүз ясаучы кушымча итеп карау очраклары да бар. Мәсәлән, рус телендә басылып чыккан, «Хәзерге татар әдәби теле» дигән грамматикада (1969) *-ик, -ив, -ль, -он, -ар* элементлары сүз ясаучы буларак карала.

Шулай ук *-лы*/*-ле, -сыз*/*-сез* кушымчалары турында зур бәхәсләр бара: бер тикшеренүчеләр аларны бөтенләй һәм тулысынча сүз ясаучы, икенчеләр – грамматик кушымчалар дип саныйлар.

Сыйфатлар хасил иткән кушымчаларның ясаучы нигезләре булып, алмашлыклардан һәм ымлыклардан кала, барлык мөстәкыйль сүз төркемнәре килә ала. Сыйфатлар ясаучы күп кушымчалар бер сүз төркеме сүзләренә түгел, ә берничә сүз төркеме сүзләренә ялганып киләләр. Шуңа күрә сыйфат ясаучы кушымчаларны аларның ясаучы нигезләренең лексик-грамматик характеры (сүз төркеме) буенча анализлау отышлы түгел, чөнки сүзьясалыш картинасы системасыз, кабатлаулы һәм катлаулы булыр иде.

Структурасы ягыннан кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясауда ясаучы нигезләр булып тамыр сүзләр (*тәм+ле, ямь+ле, сүз+чән, ит+ләч*), кушымчалы сүзләр (*уң+дырыш+лы, күч+ем+сез, аңла+т+ма+лы, тук+лык+лы*), кушма сүзләр (*кайгы-хәсрәт+ле*) һәм шулай ук синтаксик сүзтезмәләр дә (*туры почмак+лы, кыска буй+ лы, ак чәч+ле*) килергә мөмкин.

## Хәзерге көндә сыйфатлар ясый торган кушымчалар

**Нигез + *-лы/-ле* кушымчасы.** Бу кушымча хәзерге татар телендә иң күп сүз ясаучы кушымчаларның берсе. Ул, фактлар күрсәткәнчә, полифункциональ кушымча булып тора: исемнәр ясауда да (*уфалы, бөгелмәле*), сыйфатлар (*сәләтле, акыллы*) ясауда да катнаша. Шуның белән бергә Н. Исәнбәт, М. Зәкиев, Д. Тумашева кебек галимнәр аның грамматик функция белдерә алуын да күрсәтәләр.

Бу кушымча нинди шартларда грамматик мөнәсәбәтне, бер сүзнең икенче сүзгә булган бәйләнешен белдерә, ә нинди вакытта сүзьясагыч кушымча булып килә дигән сорау туа.

Тел материалын тикшерү *-лы/-ле* кушымчасы, абстракт исемнәргә ялганганда, сыйфат ясаучы кушымча буларак килүен күрсәтә: *тәм+ле, күңел+ле, сизем+ле.*

Конкрет исемнәргә ялганганда ул, кагыйдә буларак, грамматик мөнәсәбәт белдерә: *сыерлы хуҗалык, атлы гаилә.* Бу кагыйдәдән чыгармалар булырга мөмкин. Беренчедән, конкрет исем үзенең туры мәгънәсендә түгел, абстракт мәгънә белдергәндә, *-лы/-ле* кушымчасы грамматик мәгънә белдермичә, мөстәкыйль лексик мәгънәле сыйфатлар ясый: *йөрәкле егет, башлы кеше.* Икенчедән, *-лы/-ле* кушымчасы берәр нәрсәгә гади ия булудан тыш нинди дә булса өстәмә семантик билге белдерсә, ул сүзьясагыч булып килә. Мәсәлән, *детекторлы ал-*

*гыч* сүзтезмәсендә *детекторлы* сыйфаты гади ия булудан элек «детектор ярдәмендә эшли торган» дигән мәгънәне белдерә. Күпчелек галимнәр бу кушымчаның килеп чыгышын *-лык* кушымчасы белән бәйли. Бу караш дөрес булса кирәк, аларны тел тарихында бер үк сүздә, бер үк мәгънәдә параллель куллану очраклары булган: *казанлык – казанлы, бохаралык – бохаралы.*

Шуның белән бергә бүгенге көндә дә аларның төп мәгънәләре бер үк: алар «бар булу, күп булу» мәгънәсен аңлаталар: *каенлык* – каеннар күп булган урын, *каенлы* – каеннар булган урын.

Сүзьясагыч кушымчасы *-лы/-ле* исемнәргә, чикләнгән күләмдә сыйфатларга, саннарга, фигыльләргә, рәвешләргә һәм хәбәрлек сүзләргә ялгана.

Ясаучы нигезләре булып күпчелек очракта абстракт исемнәр килә: *шатлык+лы, кешелек+ле, ачу+лы, игътибар+лы, хис+ле, акыл+лы.*

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып сыйфатлар үзләре дә килергә мөмкин: *ак+лы, нык+лы, зәңгәр+ле, күк+ле.*

Ул шулай ук саннарга да ялгана: *биш+ле, өч+ле, ун+лы, кырык+лы* (үлчәүгә караган сүзләр).

Исем фигыльләр дә бу кушымчаның ясаучы нигезләре була ала: *түшәү+ле, кайгыру+лы, киңәю+ле, кадау+лы.*

Кушымча хәбәрлек сүзләр белән дә килә: *кирәк+ле, тиеш+ле.* Кайбер очракларда бу кушымчаның ясаучы нигезләре хәзерге телдә мөстәкыйль кулланылмый, шуңа карамастан ул ачык сизелә: *җентек+ле, сөйкем+ле.*

Татар сүзләре дә, алынма сүзләр дә кушымчаның ясаучы нигезләрен тәшкил итәләр: *көч+ле, ачу+лы, кешелек+ле* (татар сүзләре). Алынма булган ясаучы нигезләр: 1) гарәп һәм фарсы сүзләре: *мәгърифәт+ле, файда+лы, гайрәт+ле, хәйлә+ле, дәрт+ле;* 2) рус сүзләре: *смена+лы, запас+лы, почёт+лы;* 3) рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләр: *нерв+лы, гармония+ле, стихия+ле, стадия+ле, эмоция+ле, авторитет+лы, рентабель+ле, стандарт+лы, лента+лы.*

Мәгълүм булганча, рус теленнән *продуктивный* кебек сыйфатларны алганда, аның *-ный* өлеше төшереп калдырыла, татар телендә *продуктив* формасында кулланыла. Әмма кайбер очракларда андый

сүзләрне *продуктивлы, радиоактивлы* дип йөртү бар, моны дөрес дип булмый.

*Исем+-лы/-ле* моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән даими эчке билге белән тасвирлана торган затны: *инсафлы, әдәпле, белемле, кешелекле, мәрхәмәтле, шәфкатьле.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән вакытлы билге белән характерлый торган затны яки предметны: *шатлыклы, ачулы, кайгылы, ярсулы.*

3. Ясаучы нигез тәгъбир иткән авыру белән чирләүче затны: *туберкулёзлы, чехоткалы, тимрәүле, бизгәкле.*

4. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәгә күп дәрәҗәдә ия булган билге мәгънәсен: *көчле, мускуллы, итле, сөтле, сөякле, кылчыклы, җилле, яңгырлы, буйлы, гәүдәле, ташлы.*

5. Ясаучы нигез белдергән корал, җайланма, әсбап ярдәмендә эшли торган дигән мәгънәне: *детекторлы, турбовинтлы, транзисторлы.*

6. Ясаучы нигездән эшләнгән яки әзерләнгән дигән мәгънәне: *сөтле* (аш), *итле* (аш), *эремчекле* (сумса).

7. Ясаучы нигез тәгъбир иткән матдәгә дучар ителгән яки аның белән капланган дигән мәгънәне: *хромлы, никельле, эмальле, бронялы, эмульсияле.*

8. Ясаучы нигез тәгъбир иткән яки бирә торган мәгънәне: *керемле, чумаралы, керешле, табышлы.*

9. Ясаучы нигез предметы белән бизәлгән яки ясалган дигән мәгънәне: *челтәрле, чуптарлы, орнаментлы, чачаклы.*

10. Ясаучы нигез тәгъбир иткән шәкелле (формалы) дигән мәгънәне: *гофрлы, өчпочмаклы, ажурлы, квадратлы, кузаклы.*

11. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәне үз эченә алган, шуннан гыйбарәт дигән мәгънәне: *сагынулы, фаҗигале, һәлакәтле.*

12. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эшкә-хәрәкәткә сәләтле дигән мәгънәне: *җыелмалы, алынмалы, күтәрелмәле.*

13. Ясаучы нигез тәгъбир иткән тавышны чыгара торган дигән мәгънәне: *гөрелдәвекле, чылтыравыклы.*

Фигыль + *-лы/-ле* моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән билге мәгънәсен: *бөрүле, бәйләүле, чигүле, төшәүле, ямаулы, буяулы.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә билгеләнгән дигән мәгънәне: *җигүле, сөрүле, түләүле, шартлаулы.*

Сыйфат + *-лы*/*-ле* моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән төскә ия дигән мәгънәне белдерә: *зәңгәрле, күкле, аклы, сарылы.*

Сан + *-лы*/*-ле* моделе предметның берәр микъдар ягыннан билгесен тәгъбир итә: *кырык икеле* (аяк киеме), *җиделе* (лампы), *унлы* (лампы).

Хәбәрлек *сүз* + *-лы*/*-ле* моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсә белән характерлана торган дигән мәгънәне белдерә: *кирәкле, тиешле.*

**Нигез + *-сыз/-сез* кушымчасы.** Бу кушымча татар телендә полифункциональ кушымча тәшкил итә. Ул, беренчедән, сүзьясагыч кушымча булып тора. Шуның белән бергә ул грамматик мөнәсәбәтне дә белдерергә мөмкин. Мәсәлән, *атсыз калу* сүзтезмәсендә ул грамматик мәгънә тәгъбир итә.

Сүзьясагыч кушымча буларак *-сыз*/*-сез* кушымчасы *-лы*/*-ле* кушымчасының антонимы булып тора.

Бу кушымчалар бер үк ясаучы нигезгә ялганып антонимик мәгънә белдерәләр: *перспективалы – перспективасыз.* Ләкин кайбер очракларда бер үк ясаучы нигездән бу кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр үзара антоним булмыйлар. Бу хәл сыйфатларның берсе күчмә мәгънә алганда була. *Вакытлы, җирле* сүзләре *Вакытлы хөкүмәт* һәм *җирле сөйләш* дигән сүзтезмәләрдә антоним булмыйлар.

Кушымчаның килеп чыгышы турында тюркологиядә берничә гипотеза бар. Кайбер галимнәр аның килеп чыгышын *сын* (төрки сүз), *сарни* (монгол теле сүзе), *сир* (чуваш теле сүзе) фигыльләре белән бәйлиләр. Н.А. Баскаков *-сыз* кушымчасын ике кисәктән тора дип саный. Чыннан да, бу кушымча *сы+к, сы+н* кебек татар фигыльләренең гипотетик тамыр кисәге белән генетик бәйләнеше бар. *-сыз* кушымчасы исемнәргә, фигыльләргә һәм хәбәрлек сүзләргә ялгана.

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып конкрет исемнәр дә, абстракт исемнәр дә килә: *чыбык+сыз, йөрәк+сез* (биредә тамырлар күчмә мәгънәдә киләләр), *кайгы+сыз, тәрбия+сез, оят+сыз, күңел+ сез.*

Исем фигыльләр дә аның ясаучы нигезләре булып килергә мөмкин: *түләү+сез, тыңлау+сыз, туктау+сыз.*

Сыйфатлар үзләре дә кайбер вакытта ясаучы нигез булып киләләр: *җыйнак+сыз, кыю+сыз, кызык+сыз.*

Сирәк кенә хәбәрлек сүзләр дә кушымчаның ясаучы нигезләре буларак киләләр: *тиеш+сез, кирәк+сез.*

Кайбер очракларда хәзерге татар әдәби телендә *-сыз* кушымчасы нигездән аерылмый, әмма кушымча үзе ачык сиземләнә: *сөм+сез, эшлек+сез, күренек+сез.*

Бу кушымча татар сүзләренә дә, алынма сүзләргә дә ялгана.

Саф татар сүзләре ясаучы нигезләр булып килә: *түзем+сез, оят+-сыз, йокы+сыз.*

Алынма сүзләр дә ясаучы нигезләр буларак кулланыла: а) гарәп һәм фарсы сүзләре: *мәгърифәт+сез, мәгънә+сез, миһербан+сыз;* б) рус сүзләре: *предмет+сыз, грамота+сыз;* в) рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләр: *логика+сыз, идея+сез, конфликт+сыз, форма+сыз, инициатива+сыз.*

Исем + *-сыз*/*-сез* моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. а) ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәнең затта булмаган эчке билгене: *әдәпсез, гөнаһсыз, миһербансыз, кешелексез, идеясез, илтифатсыз;* б) ясаучы нигезнең күчмә мәгънәсе күрсәткән нәрсәнең затта булмаган эчке билгене: *башсыз, мисез, тешсез, телсез.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән сыйфатның предметта булмаган билгене: *системасыз, логикасыз, түләүсез.*

3. Ясаучы нигез тәгъбир иткән коралсыз яки җайланмасыз эшли торган дигән мәгънәне: *чыбыксыз, канатсыз, детекторсыз.*

4. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәне бирми торган яки ул килеп чыкмый торган дигән мәгънәне: *табышсыз, файдасыз, керемсез.*

5. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәгә ким, аз дәрәҗәдә ия дигән мәгънәне: *сөтсез* (сыер), *көчсез.*

Сыйфат + *-сыз*/*-сез* моделе ясаучы нигез белдергән сыйфатның, билгенең юк булуын белдерә: *кыюсыз, сәләтсез, кызыксыз, майсыз* (ит).

Хәбәрлек сүз + *-сыз*/*-сез* моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсә белән характерланмый торган дигән мәгънәне белдерә: *тиешсез, кирәксез.*

**Нигез + *-лык*/*-лек* кушымчасы.** Бу – полифункциональ кушымча, ул исемнәр ясауда да, сыйфатлар ясауда да катнаша. Шуның белән бергә аңарда форма ясау функциясе дә бар. Мәсәлән, *-ган, -р* кушымчаларына тәмамланган сыйфат фигыльләргә ялганып, аларның икенчел

формаларын ясый: *барган – барганлык, килгән – килгәнлек, барыр – барырлык.* Бу кушымчаның кайсы сүз төркеменә караган сүз ясавын билгеләгәндә, ул сүзнең лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләрен ачыклау төп шарт булып тора. Әгәр сүз бара торган кушымча грамматик мәгънәдәге предметны белдерә торган сүз ясаса, килеш катерогиясе белән төрләнсә һәм исемнең типик синтаксик функциясен үтәсә, әлбәттә, ул сүз исем булып тора: *күлмәклек* (күлмәклек сатып алдым), *айлык* (айлыкны бүген бирәләр). Әгәр бу кушымча предметның билгесен белдерә торган сүз хасил итсә, төрләнмәсә һәм сыйфатка хас синтаксик функцияне үтәсә, ул сүз, һичшиксез, сыйфат була: *айлык эш, айлык эшнең, күлмәклектукыма.*

Кушымчаның ясаучы нигезләре булып исемнәр, фигыльләр һәм саннар килә.

Ясаучы нигезләре исем булган сүзләр: *бишмәт+лек* (материал), *итек+лек* (күн), *бүрек+лек* (мех), *ярма+лык* (карабодай), *койма+лык* (агач), *капка+лык* (такта), *атна+лык* (эш), *юл+лык* (акча).

Фигыльләр дә ясаучы нигезләр булып киләләр: *сат+лык* (ашлык), *чәчү+лек* (орлык).

Кайбер очракларда саннар да ясаучы нигез булалар: *йөз+лек* (акча), *йөз мең+лек* (акча), *биш+лек* (акча).

Генетик яктан *-лык/-лек$_1$* кушымчасының ясаучы нигезләре булып, татар сүзләре белән беррәттән, алынма сүзләр дә килә.

Ясаучы нигезләрне тәшкил иткән татар сүзләренә мисаллар: *көз+лек* (ашлык), *кыш+лык* (печән), *түбә+лек* (калай).

Ясаучы нигезләр булып килгән алынма сүзләргә мисаллар: *минут+лык* (эш), *папирос+лык* (акча).

Бу кушымча сыйфат ясагыч буларак та күп мәгънәле.

Исем + *-лык/-лек$_1$* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. а) «Ясаучы нигез тәгъбир иткән кием-салым, аяк киеме, аларның детальләре өчен билгеләнгән яки яраклы» дигән мәгънәне: *чабулык* (тукыма), *юрганлык* (мамык), *оеклык* (йон); б) «ясаучы нигез тәгъбир иткән корылма, җайланма, корал яки әсбап өчен билгеләнгән яки яраклы» дигән мәгънәне: *лапаслык* (материал), *ишеклек* (яңак), *дугалык* (агач).

2. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән вакыт өчен билгеләнгән» дигән мәгънәне: *кышлык, җәйлек, көзлек, язлык.*

3. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән вакыт эчендә бара торган яки килеп чыккан» дигән мәгънәне: *атналык* (эш), *айлык* (эш), *көнлек* (эш).

Сан + *-лык/-лек$_1$* моделе ясаучы нигез белдергән кыйммәткә ия дигән мәгънәне белдерә: *йөзлек* (акча),*меңлек* (акча).

Фигыль + *-лык/-лек$_1$* моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән дигән мәгънәне: *көтүлек* (болын), *сатлык* (товар).

**Нигез + *-чыл/-чел* кушымчасы.** А.Н. Кононов бу кушымчаны *-чан* кушымчасының варианты дип саный (*н* → *л*). А.Г. Голәмев «тарихи яктан *-л,* мөгаен, көчәйткеч кушымча булып тора» дип яза. Бу кушымча исемнәргә, сыйфатларга һәм саннарга ялгана.

Ясаучы нигезләре исем булган сүзләр: а) конкрет исемнәр: *балчык+чыл, сүс+чел;* б) абстракт исемнәр: *ярдәм+чел, хыянәт+чел, һөнәр+чел.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган сүзләр: *вак+чыл, сак+чыл.*

Кайбер очракта ясаучы нигезне саннар тәшкил итә: *бер+ен+чел, ике+н+чел.*

Ясаучы нигезләре булып, татар сүзләре белән беррәттән, алынма сүзләр дә килә. Ясаучы нигезләре татар сүзләре: *кунак+чыл, он+чыл.*

Ясаучы нигезләре алынма булган сүзләр: 1) гарәп һәм фарсы сүзләре: *дәгъва+чыл, гайбәт+чел;* 2) рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләр: *капитулянт+чыл.*

Исем + *-чыл/-чел* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәне яратучы» дигән мәгънәне: *хакыйкатьчел, хезмәтчел, халыкчыл.*

2. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсә белән характерлана торган» дигән мәгънәне (зат турында): *сакчыл, вакчыл, җыйнакчыл;* (предмет турында): *сүсчел, балчыкчыл, ончыл.*

3. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән сыйфатка, үзенчәлеккә ия» дигән мәгънәне: *капитулянтчыл.*

4. Ясаучы нигез тәгъбир иткән тышкы билгене: *күкрәкчел.*

**Нигез + *-чан/-чән$_2$* кушымчасы.** Г.И. Рамстедт кушымчаның килеп чыгышын кытай сүзе *чан* ‘оста’ белән бәйли. Татар теле материалы бу фикерне билгеле бер дәрәҗәдә раслый булса кирәк: *сүзчән.*

Ясаучы нигезләре булып исемнәр һәм исем фигыльләр килә.

Ясаучы нигезләре исемнәр булган сүзләргә мисаллар: *дау+чан, тел+чән, кунак+чан, сүз+чән, халык+чан, хәрәкәт+чән.*

Ясаучы нигезләре исем фигыль булган сүзләргә мисаллар: *өркү+чән, кызу+чан, йогу+чан, үрчү+чән.*

Татар сүзләре дә, алынма сүзләр дә ясаучы нигезләр булып киләләр.

Татар сүзләре булган ясаучы нигезләр: *талым+чан, сөзешү+чән, сукрану+чан, оныту+чан.*

Гарәп һәм фарсы сүзләре дә ясаучы нигезләр булырга мөмкин: *хисап+чан.*

Исем + *-чан/-чән*$_2$ моделе түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәгә әвәс» дигән мәгънәне:*сүзчән, даучан, йокычан.*

2. «Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән характерлана торган» дигән мәгънәне: *уйчан, халыкчан, җиңүчән, сугышчан.*

Исем фигыль + *-чан/-чән*$_2$ моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә яки процесска дучар булучан дигән мәгънәне белдерә: *сынучан, янучан, шартлаучан, черүчән, таркалучан.*

**Нигез + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$ кушымчасы.** Исемнәргә, рәвешләргә һәм фигыльләргә ялгана.

Ясаучы нигезләре исем булган сүзләргә мисаллар: *яз+гы, көз+ге, кич+ке, эч+ке, тыш+кы.*

Ясаучы нигезләре рәвеш булган сүзләргә мисаллар: *бүген+ге, иртән+ге, көндез+ге, быел+гы, түбән+ге.*

Сирәк кенә ясаучы нигезе фигыль булырга мөмкин: *мен+ге.*

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Исем + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$ моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәгә караган дигән мәгънәне белдерә: *төнге, тышкы, читке,кышкы, кичке.*

Рәвеш + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*)$_1$ моделе вакыт яки урын күзлегеннән булган билгене белдерә: *иртәнге, кичәге, күптәнге, көндезге, аскы, өске, югарыгы.*

Фигыль + *-гы/-ге* (*-кы/-ке*) моделе ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган дигән мәгънәне белдерә: *менге*.

**Нигез + *-малы/-мәле* кушымчасы.** Ул, төзелеше ягыннан, мөстәкыйль кушымчаларга барып тоташа торган *-ма+лы* кушымчаларыннан гыйбарәт катлаулы кушымча булып тора.

*-малы* кушымчасын мөстәкыйль кушымча дип санау өчен нинди нигезләр бар соң? *-малы* кушымчасы белән килгән сүзләрнең лексик-семантик һәм структур үзенчәлекләре *-малы* кушымчасын аерым мөстәкыйль кушымча дип санарга җитәрлек нигез бирә.

Беренчедән, хәзерге татар телендә *-малы* кушымчасы белән килгән күпчелек сыйфатларның *-ма* кушымчасына тәмамланган нигезләре юк. Мәсәлән, *искитмәле, сизелмәле, теленмәле, әверелмәле* сүзләрендәге *искитмә, сизелмә, теленмә, әверелмә* кисәкләре аерым кулланылмый. Аларның фигыль өлешләре мөстәкыйль кулланыла. Икенчедән, тикшерелә торган сүзләрнең мәгънәсе аларның фигыль кисәкләреннән килеп чыга: *кисел+мәле, кыскарт+малы, сызыл+малы, ябыл+малы.* Мәсәлән, *киселмәле* сыйфатында «киселмә»гә ия булу турында сүз бармый, ә *киселү* белән характерлана торган билге турында сүз бара.

Ясаучы нигезләрен фигыльләр тәшкил итә: *сүтел+мәле, киңәй+мәле,* кушымча тик татар сүзләре белән генә килә.

Фигыль + *-малы/-мәле* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә сәләтле» дигән мәгънәне: *киңәймәле, теленмәле, киселмәле.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган билгене: *сизелмәле, асылмалы, җигелмәле.*

**Нигез + *-ма/-мә*$_1$ кушымчасы.** Аның ясаучы нигезләре булып бары фигыльләр генә килә: *ясал+ма.* Мәгълүм булганча, *-ма*$_1$ кушымчасы исемнәр ясауда да катнаша. Шуңа күрә сорау туа: *-ма*$_1$ кушымчалы барлык сыйфатлар да кушымчалау ысулы белән ясалганмы яки алар исемнәрнең сыйфатка күчү юлы (конверсия) белән барлыкка килгәннәрме? Фактлар күрсәткәнчә, әгәр *-ма*$_1$ кушымчалы сыйфатлар гомумән исем буларак кулланылмасалар, алар, әлбәттә, сыйфат булып торалар: *башкарма, уйланма.* Әгәр дә сыйфатларның шундый ук исем формалары булса, аларны конверсия юлы белән ясалган сыйфатлар дип карарга туры килә: *чагыштырма* (исем) һәм *чагыштырма* (сыйфат), *уйдырма* (исем) һәм *уйдырма* (сыйфат).

Фигыль + *-ма*/*-мә*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган билгене: *телмә, уйланма, сыйланма, ясалма.*

2. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән» дигән мәгънәне: *башкарма, тагылма.*

3. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган» дигән мәгънәне: *кырма, акма, бәрмә, чатнама* (суык).

**Нигез + *-ынкы*/*-енке* кушымчасы.** Кушымча *-ын* һәм *-кы* элементларыннан гыйбарәт катлаулы кушымча булып тора. Фигыльләргә ялгана, ясаучы нигезләре булып, татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-ынкы*/*-енке* моделе «ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә хасил булган хәлгә килгән» дигән мәгънәне белдерә: *батынкы, ятынкы, басынкы, җәенке.* Бу кушымча белән ясалган кайбер сыйфатлар телнең үсеш процессында икенче күчмә мәгънә алганнар: *күтәренке, төшенке, киеренке.*

**Нигез + *-вык*/*-век* кушымчасы.** Бу кушымча, кагыйдә буларак, сузык авазларга тәмамланган нигезләргә ялгана. Фәнни анализ күрсәткәнчә, кушымча үзенең чыгышы ягыннан *-ык* кушымчасына барып тоташа, «в (w)» элементы татар теле өчен гадәти булмаган сузык авазга тәмамланган нигез белән *-ык* кушымчасы арасында барлыкка килгән хиятусны (ике сузык арасын) юкка чыгару өчен кулланылган **интерфикс** булып тора. Шуңа да карамастан, биредә *-вык* кушымчасы, тюркологиядәге бу кушымчага караган традицияне бозмас өчен, аерым, мөстәкыйль кушымча итеп карала.

Кушымча ияртемнәрдән ясалган фигыльләргә ялгана: *чәр+ елдә+век, елт+ыра+вык.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-вык*/*-век* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә әвәс» дигән мәгънәне: *лыгырдавык, ләңгелдәвек.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт, хәл белән характерлана торган билгене: *ялтыравык, хырылдавык, яңгыравык.*

**Нигез + *-ык*/*-ек, -к*$_1$ кушымчасы.** *-ык*$_1$ кушымчасы исемнәр ясауда да, сыйфатлар ясауда да катнаша. Сыйфатлар ясаганда фигыльләргә ялгана: *сүт+ек, җимер+ек.* Ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-ык/-ек, -к*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә дучар ителгән» дигән мәгънәне: *ертык, ватык, сынык, ачык, бозык, төзек.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган билгене: *йөгерек, тонык, безелдек, бакылдык, дөңгердек.*

Бу кушымча хәзерге татар әдәби телендә структурасы бик үк ачык булмаган сыйфатларда да очрый: *суы+к, тер+ек, яб+ык.*

**Нигез + *-гыч/-геч* (*-кын/-кеч*)$_1$ кушымчасы.** Ул, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана: *черет+кеч, бөлдер+геч.* Ясаучы нигезләре булып тик татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*) кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә сәләтле, эш-хәрәкәтне булдыра ала торган» дигән мәгънәне: *бөлдергеч, дәртләндергеч, биздергеч, тончыктыргыч.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган билгене: *ышандыргыч.*

**Нигез + *-ча/-чә*$_1$ кушымчасы.** Кайбер тюркологлар, мәсәлән, П.М. Мелиоранский, Н.К. Дмитриев, М.А. Хабичев һ.б. бу кушымчаны *чак* (үлчәм) сүзе белән бәйлиләр. Ләкин бу сүз белән *-ча*$_1$ кушымчалы сыйфат арасында бернинди бәйләнеш күзәтелми. Сыйфат ясаучы *-ча*$_1$ кушымчасы этимологик яктан борынгы кечерәйтү кушымчасы *-ч* белән бәйләнгән. Аның мәгънәсе тулысынча сүз барган кушымчага туры килә.

*-ча*$_1$ кушымчасы сыйфатларга ялгана: *салкын+ча, озын+ча, якын+ча* һ.б.

Сыйфат + *-ча/-ча*$_1$ кушымчасы ясаучы нигез тәгъбир иткән сыйфаттан ким сыйфатка ия дигән мәгънәне белдерә: *кыскача, җиңелчә, кызылча, кызмача, салкынча.*

**Нигез + *-даш/-дәш* кушымчасы.** Бу кушымча, исемнәр ясау белән беррәттән, сыйфатлар да ясый: *аһәң+дәш, мәгънә+дәш.*

Исемнәргә ялгана. Исем + *-даш/-дәш* кушымчасы «ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсә белән нигездә уртак» дигән мәгънәне белдерә: *аваздаш.*

## Хәзерге көндә сыйфатлар ясауда продуктив булмаган кушымчалар

**Нигез + *-лач/-ләч*$_2$ кушымчасы.** Исемнәргә ялгана, ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

Исем + *-лач/-ләч*$_2$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. Ясаучы нигез белдергән нәрсәнең күп булган билгесен: *итләч, йонлач.*

2. Ясаучы нигез белдергән нәрсә белән характерлана торган билгене: *урләч.*

**Нигез + *-сыл/-сел* кушымчасы.** Бу кушымчаның генетик яктан кимлекне белдергән *-су* кушымчасы белән бәйләнеше бар.

Кушымча исемнәргә (*су+сыл, ком+сыл*)һәм сыйфатларга (*күк+сел*) ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

Исем + *-сыл/-сел* моделе «ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәне билгеле бер дәрәҗәдә үз эченә алган» дигән мәгънәне белдерә: *комсыл, сусыл, балчыксыл.*

Сыйфат + *-сыл/-сел* моделе ясаучы нигез белдергән сыйфатның аз дәрәҗәдә булган билгесен тәгъбир итә: *аксыл, күксел, чисел* (диал. сүз).

**Нигез + *-тык/-тек*$_2$ кушымчасы.** Бу кушымча генетик яктан кимлекне, охшашлыкны белдерә торган *-сыг* кушымчасы белән бәйләнгән. Ул сыйфатларга ялгана. Ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Сыйфат + *-тык/-тек*$_2$ кушымчасы «ясаучы нигез белдергән сыйфатка аз яки тулы булмаган дәрәҗәдә ия» дигән мәгънәне тәгъбир итә: *юантык, кечкентек, кечтек* (диал.).

**Нигез + *-дык/-дек* (*-тык/-тек*)$_3$ кушымчасы.** Бу кушымча ияртемнәрдән ясалган фигыль составында очрый. Әмма ул биредә мөстәкыйль кушымча тәшкил итми, *-давык* кушымчасының гадиләшүеннән килеп чыккан: *чәр+ел+дек, чыр+ыл+дык.* Әмма ул аерым кушымча буларак та килә һәм сыйфат ясауда катнаша: *селкен+дек, юын+тык.* Аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре генә килә.

Фигыль + *-дык/-дек* (*-тык/-тек*)$_3$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган» дигән мәгънәне: *селкендек, йөремтек.*

2. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган» дигән мәгънәне: *казылдык, сайландык, юынтык, кыйтык.*

**Нигез + *-дыклы/-декле* кушымчасы.** Бу кушымча ике кисәктән торган катлаулы кушымча тәшкил итә: *-дык+-лы. -дык* элементы борынгы атрибутив формага кайтып кала булса кирәк. Әмма бүгенге көндә андый формалар булмаганлыктан, аны *-дыклы* кушымчасының кисәге итеп карарга туры килә. Кушымча фигыльләргә ялгана: *бел+декле.*

Фигыль + *-дыклы/-декле* кушымчасы «ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган» дигән мәгънәне тәгъбир итә: *булдыклы, белдекле.*

**Нигез + *-ым/-ем, -м*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча исем ясауда да катнаша, ягъни исемнәр өчен дә, сыйфатлар өчен дә уртак кушымча булып тора. Фигыльләргә ялганып килә.

Фигыль + *-ым/-ем, -м*$_1$ кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән» дигән мәгънәне: *аерым.*

2.»Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган» дигән мәгънәне: *чыдам, түзем.*

**Нигез + *-ынте/-енте* кушымчасы.** Бу кушымча *-тык* кушымчалы борынгы атрибутив формаларыннан килеп чыккан булса кирәк. Моны хәзерге татар телендә *юынтык* һәм *юынты* сыйфатларының параллель кулланылуы күрсәтә.

Фигыльләргә ялгана, бары татар сүзләре белән генә килә. Фигыль + *-ынте/-енте* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән характерлана торган» дигән мәгънәне: *сөренте.*

2. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән» дигән мәгънәне: *юынты.*

**Нигез + *-чак/-чәк* кушымчасы.** Бу кушымча *-нак/-нәк* кушымчасыннан килеп чыккан. Моны аларның сүзьясалыш мәгънәләренең тулысынча туры килүе раслый.

*к/ч* чиратлашуы *к* авазының борын авазларыннан соң кулланылуыннан килеп чыккан булса кирәк: *тартыначак.* Кагыйдә була-

рак, кушымча кайтым юнәлешендәге фигыльләргә ялгана. Кайвакыт ясаучы нигездә көтелә торган «*-н*» авазы урынына *«-м»* авазы күзәтелә: *сөйләмчәк.* Ул *н/м* чиратлашуы нәтиҗәсендә хасил була. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-чак/-чәк* «ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган дигән» мәгънәне тәгъбир итә: *онытчак, җирәнчәк, иренчәк, оялчак, ялынчак.*

**Нигез + *-чык/-чек*$_2$ кушымчасы.** Генетик яктан ул *-чак* кушымчасына барып тоташа, чөнки аларның, җисмәни кыяфәте охшаш булу белән беррәттән, сүзьясалыш мәгънәсе, ясаучы нигезләренең структурасы бер үк. Кайтым юнәлеше фигыльләренә ялгана: *сайлан+чык.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы «ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган» дигән мәгънәне тәгъбир итә: *болганчык, мактанчык, буталчык, бәйләнчек.*

**Нигез + *-ыч/-еч* кушымчасы.** Фигыльләргә ялгана: *куркын+ыч, тын+ыч.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Фигыль + *-ыч/-еч* кушымчасы түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтне яки хисне китереп чыгара торган мәгънәне: *кызганыч, чирканыч.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсә белән характерлана торган мәгънәне: *ашыгыч, әйләнеч, тыныч.*

**Нигез + *-гак/-гәк* (*-как/-кәк*)$_2$ кушымчасы.** Фигыльләргә ялгана: *сөзешкәк.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә. Бу тип түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә әвәслекне: *тибешкәк, сөзешкәк.*

2. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәт белән тасвирлана торган мәгънәне: *тайгак, ябышкак, очкак.*

3. Ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсендә килеп чыккан нәтиҗәне: *тузгак, күпкәк* (диал.).

**Нигез + *-гыр/-гер* (*-кыр/-кер*)$_1$ кушымчасы**. Ул, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана: *сиз+гер, ал+гыр.* Кайбер очракларда аның ясаучы нигезләре булып башка сүз төркемнәренең сүзләре дә килергә мөмкин: *тиз+гер, җил+гер. Җил* сүзе биредә элек аның фигыль булуын аңлата булса кирәк.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән эшхәрәкәткә сәләтлелек мәгънәсен тәгъбир итә: *тапкыр, сизгер, үткер, откыр.*

Бу кушымча тагын башка сүзләрдә дә очрый, әмма бүгенге көн күзлегеннән аларның нигезләре аерылмый: *елгыр, өлгер, кыңгыр, очкыр.*

**Нигез + *-гын/-ген* (*-кын/-кен*)$_1$** кушымчасы. Күп кенә тикшеренүчеләр (В. Банг, Н.К. Дмитриев, Э.В. Севортян) бу кушымчаны сыйфат фигыль *-ган* кушымчасына кайтарып калдыралар. Ул фигыльләргә ялгана: *үт+кен, аз+гын.* Аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез тәгъбир иткән эшхәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне белдерә: *талгын, койгын, кискен, азгын.*

**Нигез + *-гач/-гәч* (*-кач/-кәч*) кушымчасы.** Бу кушымча сирәк сүзләрдә генә очрый. Аның этимологик яктан *-гыч* кушымчасы белән бәйләнеше бар.

*-гач* кушымчасы фигыльләргә ялгана: *кый+гач.* Борынгы татар телендә башка сүз төркем сүзләре дә ясаучы нигез булып килгәннәр: *ялан+гач.*

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән эшхәрәкәтнең нәтиҗәсен тәгъбир итә: *кыйгач, бөтеркәч.*

Диалектларда *-гач* кушымчалы башка сүзләр дә очрый. Мәсәлән, себер татарлары диалектында *йәт+кәч* (хәтерле) дигән сыйфат очрый, анда *йәт* сүзе «хәтер» дигән мәгънәне белдерә.

**Нигез + *-гай/-гәй* (*-кай/-кәй*) кушымчасы.** Бу кушымча, этимологиясе ягыннан, *-гак* кушымчасына барып тоташа. Фигыльләргә ялгана: *яла+гай.* Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән фигыль белән характерлана торган дигән мәгънәне тәгъбир итә: *яла+гай.* Кайбер сүзләрдә аның ясаучы нигезе аерылмый: *елмагай, комагай* (борынгы төрки телдә *комы* «теләү» дигән мәгънәне белдергән).

**Нигез + *-макай/-мәкәй* (*-магай/-мәгәй*) кушымчасы**. Фигыльләргә (*ю+макай*), исемнәргә (*тел+мәгәй*) ялгана.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә.

**Нигез + *-ый* кушымчасы.** Кушымча сыйфатка ялгана, ясаучы нигезе булып татар сүзе килә: *йомык+ый.*

Бу сыйфат ясаучы нигез белдергән сыйфат белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә.

**Нигез + *-ак/-әк, -к$_3$* кушымчасы.** Этимологиясе ягыннан *-гак* кушымчасына барып тоташа булса кирәк. Сыйфатларга һәм фигыльләргә ялгана.

Фигыль + *-ак/-әк, -к$_3$* моделе ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *аксак, утрак, уйнак, өлтерәк* (*өлтерәк ир – олтырак ир*). *Тупак* сыйфатында ясаучы нигез аерылмый, аның мәгънәсе дә бик үк ачык түгел.

Сыйфат + *-ак/-әк, -к$_3$* кушымчасы ясаучы нигез белдергән сыйфат белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *ялгызак, тәбәнәк.* Кушымча тагын диалектларда *тәпәшәк* сүзендә очрый.

**Нигез + *-ан/-ән, -н$_1$* кушымчасы.** Э.В. Севортян фикеренчә, бу кушымча *-ган* кушымчасыннан килеп чыккан. Ул, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана: *кыс+ан.*

Бу кушымча белән килгән сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *кысан, сузан.* Бәлки *тирән, сүрән* сүзләре дә бу кушымча белән ясалгандыр.

**Нигез + *-ын/-ен, -н$_2$* кушымчасы.** Э.В. Севортян бу кушымчаның этимологиясен *-ган/-аган* кушымчасы белән бәйли. Ул – фигыльләргә (*тыг+ын*) исемнәргә (*өст+ен, чит+ен*) ялгана.

Бу кушымча белән килгән сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *яшерен, тыгын.* Кушымча хәзерге көн күзлегеннән структур кисәкләргә аерылмый торган сүзләрдә дә очрый: *акрын, бөтен, кыйын* (орф. *кыен*).

**Нигез + *-ы/-е$_1$* кушымчасы.** Бу кушымчаның этимологиясе турында төрле фикерләр бар. Бер тикшеренүчеләр аны *-гы* кушымчасына, икенчеләре *-га* кушымчасына, өченчеләре *-ан* кушымчасына кайтарып калдыралар. Э.В. Севортян кушымча турында яшәп килгән фикерләргә җентекле рәвештә анализ ясый. Ул тикшерелә торган кушымчаның *-ык* кушымчасыннан килеп чыгуын, яки кайбер вакытларда ул *-ык* кушымчалы сүзнең тарихи үсеш этабы булып торуын исбатлый. Э.В. Севортян фикере татар теле материаллары белән дә раслана. Мәсәлән, *олы, тере, кече* сыйфатларының *олуг, терек, кечек* кебек диалекталь яки искергән вариантлары бар, бу исә сүзнең дә, кушымчаның да эволюция кичерүен ышандырырлык итеп раслый.

Кушымча фигыльләргә ялгана: *кат+ы.*

*-ы*$_1$ кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән мәгънәне тәгъбир итә: *тулы, коры, аеры, үле, каты.*

Хәзерге татар телендә нигезләре аерылмый торган башка *-ы* кушымчалы сыйфатлар да очрый: *ачы, җылы, җете.*

**Нигез + *-а/-ә*$_2$ кушымчасы.** Э.В. Севортян аны, *-ы* кушымчасы белән бергә, гомуми кушымча булып тора, дип раслый. Әмма татар теле материалы мәгънәсе буенча да, лексик-грамматик үзенчәлеге буенча да күп вакытта аның *-ы* кушымчасы белән бәйләнеше булмавын күрсәтә. Әгәр алар генетик яктан, мәсәлән, бәйләнгән булсалар да, телнең хәзерге торышында җитәрлек дәрәҗәдә аерылганнар. Чөнки *-ы* кушымчасының, кагыйдә буларак, ясаучы нигезләре фигыльләр булса, *-а* кушымчасының ясаучы нигезләре булып сыйфатлар килә.

*-а*$_2$ кушымчалы сыйфатлар нигез белдергән сыйфаттан үзгәргән билгене тәгъбир итә: *ала.* Бу мәгънәгә шулай ук *коба* сүзенең мәгънәсе якын булса кирәк. Аның ясаучы нигезе *кау,* бәлки, *кау* төсендәге дигән мәгънә белдергән. Сүзьясалыш процессында ул шулай үзгәреп киткән.

*-а/-ә* гә тәмамланган кайбер сыйфатлар борынгыда шул ук кушымчалардан ясалган булырга мөмкин: *бөдрә* (*бөтер* фигыль + *ә*), *кара, кола.*

**Нигез + *-нак/-нәк* кушымчасы.** Мәгънәсе һәм төзелеше буенча бу кушымча, мөгаен, *-ганак/-гәнәк* кушымчасыннан килеп чыккан булса кирәк. Бу кушымча белән ясалган сыйфатлар телдә бик аз. Ул фигыльләргә ялгана: *тый+нак.*

*-нак* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *җыйнак, тыйнак.*

**Нигез + *-ры/-ре* кушымчасы.** Фигыльләргә ялгана: *бөк+ре.*

*-ры* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *бөкре.*

Хәзерге татар телендә *-ры* кушымчасына тәмамланган башка сыйфатлар да бар. Ләкин аларның структурасы телнең бүгенге көнге торышында аерым кисәкләргә бүленми: *кәкре, тугры.*

**Нигез + *-ыр/-ер, -р*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча бары берничә сүздә генә очрый. Фигыльләргә ялгана: *кыс+ыр, болга+в+ыр* (биредә *в* интерфикс тәшкил итә).

*-ыр* кушымчалы ясаучы нигез белдергән нәрсә белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә. Әмма аларның туры мәгънәсе югалып, икенче мәгънә барлыкка килгән: *кысыр, авыр.*

*Такыр, чуар* сүзләрендә ясаучы нигезләр инде аерылмый.

**Нигез + *-дам/-дәм* кушымчасы.** Бу кушымча фигыльләр һәм саннар белән килә.

*-дәм* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *бер+дәм, күн+дәм, ел+дам* (*ел* – тиз бару).

**Нигез + *-су* кушымчасы.** *-су* кушымчасы охшашлык белдерә торган борынгы *-сыг* кушымчасы белән бәйләнгән булса кирәк (*колсыг* ‘колга охшаш’).

Исемнәргә (*моң+су*)*,* сыйфатларга (*киң+су*)*,* фигыльләргә (*уй+су*) ялгана.

Исем + *-су* моделе ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган яки шуңа охшаган дигән мәгънәне тәгъбир итә: *көлсу, моңсу, төтенсу, алтынсу.*

Сыйфат + *-су* кушымчасы ясаучы нигез белдергән сыйфатка аз дәрәҗәдә ия дигән мәгънәне тәгъбир итә: *күксу, көрәнсу, кызылсу, зәңгәрсу.*

Фигыль + *-су* кушымчасы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсендә барлыкка килгән дигән мәгънәне тәгъбир итә: *уйсу.*

**Нигез + *-мса/-мсә* кушымчасы.** Мәгънәсе һәм структурасы ягыннан караганда бу кушымча ике кисәктән тора *м+са. -са* элементы генетик яктан охшашлыкны белдерә торган борынгы *-сыг, су* кушымчасы белән бәйләнгән булса кирәк.

*-м* элементы турында бер нәрсә дә ачык итеп әйтеп булмый, мөгаен, ул интерфикс.

Кушымча сыйфатларга ялгана.

*-мса* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән сыйфатка аз дәрәҗәдә ия дигән мәгънәне тәгъбир итә: *тилемсә, җылымса.*

**Нигез + *-тын/-тен* кушымчасы.** Бу кушымча фигыльләр белән килә: *яшер+тен.*

*-тын/-тен* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *яшертен.* Бу кушымча шулай ук *аст+ыр+тын, урын+тын* кебек сүзләрдә очрый.

**Нигез + -*шы*/-*ше*$_1$ кушымчасы.** Исемнәргә ялгана: *кытыр+шы*. -*шы* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *кытыршы*.

Хәзерге татар телендә -*шы* га тәмамланган башка сыйфатлар да бар, ләкин алар структур яктан аерым кисәкләргә бүленми: *купшы* (чагыштыр: *купай*), *шакшы, яхшы*.

**Нигез + -*ыш*/-*еш*$_1$, -*ш*$_1$ кушымчасы.** Бу кушымча фигыльләргә ялгана, сузыклардан соң -*ш* кушымчасы килә.

-*ыш*/-*еш*, -*ш*$_1$ кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән тасвирлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *авыш, таныш, охшаш, чалыш*. Бу кушымча шулай ук *юаш, юеш* сүзләрендә очрый, әмма алар мөстәкыйль морфемаларга аерылмый.

**Нигез + -*шак*/-*шәк* кушымчасы.** Бу кушымча фигыльләргә ялгана: *куп+шак*.

-*шак* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *купшак*. Кушымча тагын *көпшәк* сүзендә очрый, әмма ул сүз мөстәкыйль кисәкләргә аерылмый.

**Нигез + -*шык*/-*шек* кушымчасы**. Ул – фигыльләргә ялгана: *кыйшык*.

-*шык*/-*шек* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *кыйшык, җепшек* (җебе), *ямьшек* сүзендә морфемалар сизелсә дә, бүгенге көндә мөстәкыйль кисәкләр булып тормыйлар.

**Нигез + -*шел* кушымчасы.** Кушымча сыйфатка ялгана.

-*шел* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән сыйфатның аз дәрәҗәдә булуын тәгъбир итә: *күкшел*.

**Нигез + -*ка*/-*кә*$_2$ кушымчасы.** Кушымча бары берничә сыйфатта гына очрый. Этимологиясе ягыннан ул -*как* кушымчасының фонетик үсеше булып тора. Бу фикерне бер үк ясаучы нигезнең бер үк мәгънәдә -*ка* кушымчасы белән дә, -*как* кушымчасы белән дә килүе раслый: *кыска* һәм *кыскак* (диал.). Кушымча фигыльләргә ялгана: *кыс+ка*.

-*ка* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *кыска*.

Кайбер -*ка* кушымчалы булган сыйфатларда нигезләр аерылмый: *юка* (диал. *юкак*), *кыл+ка*(*?*), *нечкә*.

**Нигез + *-кү* кушымчасы.** Фигыльләргә ялгана.

*-кү* кушымчасы сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *иңкү.* Татар телендә *-кү* кушымчалы тагын бер сыйфат бар. Биредә борынгы төрки телдә очрый торган *бөр*(*т*) фигыле ясаучы нигез булып тора. *Бөркү* сыйфатының мәгънәсе структурасыннан чыгып караганда, «сизелә, тоела торган» дигән мәгънәгә кайтып кала (*һава турында*).

**Нигез + *-ам*/*-әм* кушымчасы.** Бу кушымча телдә бик сирәк очрый. Исемнәргә ялгана: *күрк+әм* (күрек – матурлык).

*-ам*/*-әм* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән сыйфатка ия дигән мәгънәне белдерә: *күркәм.*

**Нигез + *-ыз*/*-ез, -з* (*-аз*/*әз*)$_1$ кушымчасы.** Татар телендә *-ыз*/*-ез, -з* кушымчасы (киң варианты *-аз*/*-әз*) бары берничә сүздә генә очрый. Фигыльләргә ялгана: *тыг+ыз.*

*-ыз* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *тыгыз.* Бу кушымча белән килгән кайбер сыйфатларның ясаучы нигезләре бүгенге көндә ачык түгел: *буаз* (буу – чорнау, төенләү?), *айаз* (орф. аяз), *тигез.*

**Нигез + *-ас*/*-әс* кушымчасы.** Исемнәргә ялгана.

*-әс* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *җиләс.* Сыйфатлар ясалышының бу тибына *тупас* (нигез *туп?*)*, иләс* сүзләре дә керә булса кирәк.

**Нигез + *-чу* кушымчасы.** Исемнәргә ялгана: *тын+чу.* Мөгаен, ул генетик яктан *-кү* (*бөркү*) кушымчасы белән бәйләнгән. *-чу* кушымчалы сыйфат нигез белдергән үзенчәлек белән бәйләнгән дигән мәгънәне тәгъбир итә: *тынчу.*

**Нигез + *-пы*$_2$ кушымчасы.** Этимологик яктан ул *-пак* кушымчасы белән бәйләнгән. Фигыль белән килә: *сал+пы.*

*-пы* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *салпы.*

**Нигез + *-ел*/*-әл* кушымчасы.** Ул – сыйфатка ялгана: *яш+ел.* Бу сүзнең мәгънәсе беркадәр метафорик характер алган. Бу кушымча тагын *җиңел, төгәл* кебек сыйфатларда очрый.

**Нигез + *-кыл*/*-кел* кушымчасы.** Кушымча саннарга һәм исемнәргә кушылып сыйфатлар ясый: *өч+кел, дүрт+кел, төп+кел.*

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *өч+кел.* Сүзләрнең мәгънәсе туры мәгънәсеннән беркадәр читкә киткән. *Кучкыл* сүзендә ясаучы нигез аерылмый.

**Нигез + *-ай/-әй* кушымчасы.** Исемнәргә (*кул+ай, уң+ай*), сыйфатларга (*тул+ай=тулы+ай*) ялгана. Бу сыйфатларның мәгънәләре метафоралашкан.

**Нигез + *-дар/-дәр* кушымчасы.** Алынма кушымча булса кирәк. Исемнәргә ялгана: *тәҗ+дар, тел+дәр.*

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән нәрсәгә, үзенчәлеккә ия дигән мәгънәне тәгъбир итә: *тәҗдар, телдәр.*

**Нигез + *-ач/-әч* кушымчасы.** Фигыльләр белән килә.

*-ач/-әч* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган дигән мәгънәне тәгъбир итә: *көләч, кырач.*

**Нигез + *-мыр/-мер* кушымчасы.** Фигыльләргә ялгана.

*-мыр/-мер* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *кысмыр, түзмер.*

**Нигез + *-сар/-сәр* (*-сыр/-сер*)$_2$ кушымчасы.** *-м* авазына тәмамланган сүзләргә ялгана: *елам+сыр.* Бәлки биредә *-м* элементы интерфикс тәшкил итә: *ела+м+сыр.*

Бу кушымча белән килгән сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *көлемсәр, еламсыр, майымсыр* (орфографиядә маемсыр).

**Нигез + *-сә* кушымчасы.** Кушымча шулай ук *-м* авазына тәмамланган сүзләргә ялгана.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *көлемсә, җылымса.*

**Нигез + *-гысыз/-гесез* (*-кысыз/-кесез*) кушымчасы.** Кушымча фигыльләргә ялгана: *алыштыр+гысыз.* Татар теле үсешенең билгеле бер этабында бәлки *-гы* кушымчалы сүзләр булгандыр (*карагы+сыз, бирге+сез*). Ләкин хәзерге вакытта кушымча тулысынча үзгәреп, катлаулы кушымча буларак кабул ителә: *кузач+кысыз.*

Бу сүзләр ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә туры килми дигән мәгънә аңлата.

**Нигез + *-галак/-гәләк* (*-калак/-кәләк*) кушымчасы.** Ясаучы нигезләре булып фигыльләр (*таш+калак, сең+гәләк, туң+галак*) килә.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *тайгалак, сеңгәләк.*

**Нигез + *-лҗым/-лҗем* кушымчасы.** Кушымча сыйфатларга ялгана.

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән сыйфатка ким дәрәҗәдә ия дигән мәгънәне тәгъбир итә: *каралҗым, күгелҗем.* Биредә *-ыл/-ел* элементы интерфикс тәшкил итә.

**Нигез + *-сык* кушымчасы.** Кушымча ияртемгә һәм фигыльгә ялгана: *кыбыр+сык, тан+сык.*

*-сык* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә. *Тансык* сүзендә *тан* фигыле кайчандыр *ярату, белү* мәгънәсен белдергән.

**Нигез + *-анак/-әнәк* кушымчасы.** *-анак* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *очанак.*

**Нигез + *-канак* кушымчасы.** *-канак* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган мәгънәне тәгъбир итә: *катканак.*

**Нигез + *-рәк* кушымчасы.** Сыйфат ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә әвәс дигән мәгънәне белдерә: *көйрәк.*

**Нигез + *-мәкәр* кушымчасы.** Сыйфат ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән үзенчәлеккә ия дигән мәгънәне тәгъбир итә: *телмәкәр, эшмәкәр.*

**Нигез + *-тәс* кушымчасы.** Сыйфат ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән үзенчәлеккә ия дигән мәгънәне тәгъбир итә: *йөнтәс.*

**Нигез + *-мтәл* кушымчасы.** *-мтәл* кушымчасы белән килгән сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә әвәс яки бирешүчән дигән мәгънәне тәгъбир итә: *йөремтәл, өшемтәл.*

**Нигез + *-тәй* кушымчасы**. *-тәй* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән нәрсә белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *йөнтәй.*

**Нигез + *-әләк* кушымчасы.** *-әләк* кушымчасы белән килгән сыйфат ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә бирешүчән дигән мәгънәне тәгъбир итә: *өшәләк.*

**Нигез + *-макай* кушымчасы.** *-макай* кушымчалы сыйфат ясаучы нигез белдергән үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *ау+макай.*

**Нигез + *-ау/-әү* кушымчасы**. *-ау/-әү* кушымчалы сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлеккә ия дигән мәгънәне белдерә: *тешәү, кәкшәү.* Бу типка *җәмшәү* сыйфаты да карый булса кирәк.

**Нигез + *-гылт/-гелт* (*-кылт/-келт*) кушымчасы.** Бу кушымча белән килгән сыйфатлар ясаучы нигез белдергән билгенең ким дәрәҗәдә булуын тәгъбир итә: *саргылт, ачкылт, әчкелт.* Кушымча шулай ук аерым мөстәкыйль морфемаларга аерылмый торган сыйфатларда да очрый: *кызгылт, яшькелт.* Сөйләм телендә *-гылтым/-гелтем* (*-кылтым/-келтем*)кушымчалары белән килгән сыйфатлар да бар: *әчкелтем, төчкелтем.*

**Нигез + *-сак/-сәк* кушымчасы.** Ясаучы нигезләре булып фигыльләрдән ясалган, *-м* авазына тәмамланган сүзләр килә: *ашамсак.*

Сыйфатлар ясалышының бу тибы ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә әвәс дигән мәгънәне белдерә: *йөремсәк, ярамсак. Талымсак* сүзендә ясаучы нигез булып исем килгән.

## Нигездән аерылмый торган кушымчалар

***-пак/-пәк* кушымчасы.** Аның ясаучы нигезләре бүгенге көндә мөстәкыйль морфемаларга аерылмыйлар: *җәлпәк, ялпак, кырпак* (*кыр* фигыле?).

***-берек* кушымчасы.** Бүгенге татар телендә ул бер сүздә генә очрый: *нәзберек.* Ясаучы нигезенең, ихтимал, *нәзек* сүзенең беренче кисәге белән бәйләнеше бар.

***-пан/-пән* кушымчасы.** Бары аерым сүзләрдә генә очрый: *сүлпән* (ясаучы нигезе *сүл*нең, ихтимал, *сүл* фигыле белән бәйләнеше бар). Бу кушымча тагын *чулпан* сүзендә бар.

***-кыш* кушымчасы.** *Тыңкыш* сүзендә очрый. *Тың* сүзе борынгы төрки телдә аваз мәгънәсен белдергән.

***-так/-тәк* кушымчасы.** Ул түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *тинтәк, кылтак, бортак* (диал.), *ялтәк* (диал.).

***-ләк* кушымчасы.** Бу кушымча *мүкләк* сүзендә очрый. Аның ясаучы нигезе *мөгез* сүзендәге *мөг* кисәге белән бәйләнгән булса кирәк.

***-рый* кушымчасы.** *Томрый* (диал.), *тусрый* (диал.) сүзләрендә очрый.

***-гай* кушымчасы:** ябагай, комагай (комсыз).

***-мак* кушымчасы:** *салмак.*

***-дыр* кушымчасы:** *чандыр.*

***-быр* кушымчасы:** *ялбыр, салбыр* (диал.), *ласбыр.*

***-пач* кушымчасы**: *ярпач.*

***-ый* кушымчасы:** *кылый.*

***-чәләк* кушымчасы:** *чәүчәләк.*

***-ыс*/*-ес* кушымчасы:** *кырыс, тирес* (*кире*).

***-рау*/*-рәү* кушымчасы:** *саңгырау, миңгерәү.*

## Алынма кушымчалар турында

Хәзерге татар телендә сыйфат ясаучы түбәндәге алынма кушымчалар бар дип санала: *-аль, -ль, -ив, -он, -ар, -ый, -и* һ.б.

Ләкин, фактлар күрсәткәнчә, югарыда китерелгән кушымчалар татар теле нигезендә сыйфатлар ясамыйлар. Бу кушымчалар башка телләрдән үзләренең ясаучы нигезләре белән бергә алынганнар. Шул кушымчалар белән килгән барлык сыйфатлар чыганак телдә ул телнең сүзьясалыш закончалыклары нигезендә һәм структур үзенчәлекләренә ярашкан рәвештә ясалганнар. Татар телендә ул алынма сыйфатларның кушымчалары йә бөтенләй алып ташлана, йә кыскартыла: *коммуникационный – коммуникацион, объективный – объектив* һ.б. Мондый алынма сыйфатларның кушымчаларын кыскарту алымнары бөтен бер система тәшкил итә һәм закончалыклы булып тора.

-*ический* кушымчасының (*демократический*) -*еский* элементы төшереп калдырыла, *ч* авазы к авазына күчә: демократик.

-*ивный* кушымчасының (*объективный, субъективный*) -*ный* элементы алып ташлана: *объектив, субъектив.*

-*льный*, -*альный* кушымчаларының (*социальный, экспериментальный*) -*ный* кушымчасы төшереп калдырыла: *социаль, эксперименталь.*

-*онный* кушымчасының (демонстрационный) -*ный* кисәге алып ташлана: демонстрацион.

*-арный кушымчасының* (*элементарный, популярный*) *-ный* кисәге төшереп калдырыла: элементар, популяр.

*Гарәп* һәм *фарсы* телләреннән алынган сыйфатларда гадәттә *-ый/-и* кушымчалары була. Әмма бу кушымчалар татар теленеке түгел, чыганак телнеке. Алар үзләренең ясаучы нигезләре белән бергә татар теленә килеп кергәннәр: *рәсми, вәхши, сыйнфый.* Шуңа күрә алар татар теленең сүзьясалыш системасына карамыйлар. Шулай итеп, татар телендә сыйфат ясаучы алынма кушымчалар юк. Сыйфатларны башка телләрдән алганда, кушымчаларны тулысынча яки өлешчә төшереп калдыру кушымчалар ярдәмендә сүзьясалышны тәшкил итми. Бу хәл чит телләрдән сүзләр алу алымы итеп каралырга тиеш.

### 9.7.3. Кушма сыйфатларның ясалышы

Татар телендә кушма сыйфатлар өч төрле ысул белән ясала: 1) нигезләр кушылу; 2) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 3) сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчүе.

Нигезләр кушылу ике төрле юл белән бара: 1) компонентлары тезүле бәйләнештә булган нигезләрнең кушылуы; 2) компонентлары ияртүле бәйләнештә булган нигезләрнең кушылуы.

#### Компонентлары тезүле бәйләнештә булган сыйфатларның ясалышы (куш сыйфатлар ясалышы)

Бу ысул белән татар телендә куш сыйфатлар ясала. Аның түбәндәге типлары бар.

**Исем + исем тибы.** Исем$_1$+исем$_1$ моделе. Бер үк исем кабатланып килеп, куш сыйфат ясарга мөмкин: *уем-уем, тугай-тугай, тимгел-тимгел, дулкын-дулкын, кат-кат, буй-буй, юл-юл, баскыч-баскыч.* Бу модельдәге кайбер куш сыйфатларның мәгънәсе шул ук нигездән *-лы/-ле* кушымчасы ярдәмендә ясалган сыйфатка туры килә: *тимгел-тимгел=тимгел+ле, тугай-тугай=тугай+лы.* Әмма куш сыйфатларның мәгънәләре шул ук нигездән кушымча ярдәмендә ясалган сыйфатлар белән чагыштырганда образлырак, конкретрак була.

**Сыйфат + сыйфат тибы.** Аның берничә моделе бар.

Сыйфат$_1$+сыйфат$_2$ моделе: *ак-кара, ала-кола, кызыл-яшел, кызыл-кара.* Куш сыйфатлар ясалышының бу моделенең компонентла-

ры булып тамыр сыйфатлар гына түгел, кушымчалы сыйфатлар да килергә мөмкин: *таулы-чокырлы, карлы-буранлы, ылыслы-яфраклы, ботаклы-чатаклы, керентеле-чыгынтылы, кабарынкы-батынкы, язгы-көзге, эленке-салынкы, салпы-салмак, ач-ялангач, утлы-ялкынлы.*

Беренче компоненты исемнән ясалган сыйфат булган, икенче компоненты төс белдерә торган сыйфатлар тәшкил иткән *-лы* кушымчалы куш сыйфатлар кызыклы: *утлы-сарылы, утлы-кызыллы* кебекләре бер төсне белдерә. *Аклы-күкле, аклы-каралы, аклы-кызыллы, күкле-яшелле* кебек куш сыйфатлар бер төсне түгел, ә ике төсне белдерәләр.

Бу типтагы куш сыйфатлар арасында төсне белдерә торган сыйфатлар гына түгел, башка мәгънә белдерә торган сыйфатлар да бар: *ераклы-якынлы, эреле-ваклы, әчеле-төчеле, караңгылы-яктылы, чиле-пешле.* Боларның семантикалары ике компонентның дә мәгънәләренең йә уртасын (*караңгылы-яктылы, чиле-пешле*), йә булмаса ике мөстәкыйль мәгънә (*эреле-ваклы*) тәшкил итә.

Хәзерге көндә татар телендә *ераклы, якынлы, эреле, ачлы, туклы, суыклы, эсселе* кебек сыйфатлар очрамый. Алар тик куш сыйфатларда гына күзәтелә. Әгәр дә куш сүзләрнең телнең борынгы торышында барлыкка килүен исәпкә алсак, югарыда китерелгән формаларның телнең элекке торышында хасил булуы ачыкланыр. Димәк, татар теленең үсеш тарихында *-лы* кушымчасы сыйфатларга да ялгана алган. Хәзерге көндә исә бу хәл күзәтелми.

Хәзерге татар телендә фәннең һәм мәдәниятнең нык үсүенә бәйләнешле рәвештә куш сыйфатлар тәшкил иткән калькалар һәм ярым калькалар барлыкка килә. Бу калькалар һәм ярым калькалар *сыйфат*$_1$+*сыйфат*$_2$ моделендә ясалалар: *иҗтимагый-сәяси, мәдәни-тәрбияви.* Кайбер вакытларда мондый куш сыйфатларның компонентларын кыскарган сыйфатлар тәшкил итә: *территориаль-административ, лирик-драматик*, *аграр-индустриаль, чагыштырма-тарихи, чагыштырма-генетик* һ.б.ш. Китерелгән куш сыйфатларның компонентлары тезүле бәйләнеш белән килгәннәр һәм аларның арасында *һәм* теркәгече куеп була.

*-сыз* кушымчалы сыйфат$_1$ + *-сыз* кушымчалы сыйфат$_2$ моделе. Мисаллар: *иксез-чиксез, йортсыз-җирсез, җилсез-давылсыз, очсыз-кырыйсыз, тавышсыз-тынсыз, эзсез-хәбәрсез, кайгысыз-хәсрәтсез, исәпсез-хисапсыз, кайгысыз-гамьсез.* Бу төрдәге күпчелек куш

сыйфатларның исемнәрдә тәңгәл парлары бар: *иге-чиге* (*иксез-чиксез*), *җил-давыл* (*җилсез-давылсыз*), *кайгы-хәсрәт* (*кайгысыз-хәсрәтсез*). Шуңа карамастан, аларны компонентлары тезүле бәйләнештәге куш сыйфатлар дип карарга була, чөнки телдә ике компонентның *-сыз* кушымчалы нигезләре бар.

*-лы* кушымчалы сыйфат$_1$ + *-сыз* кушымчалы сыйфат$_2$.

Антоним сыйфатларның редупликациясе (кушылуы) шулай ук куш сыйфатлар китереп чыгара: *юньле-юньсез, кирәкле-кирәксез, сыңарлы-сыңарсыз, нигезле-нигезсез.* Еш кына ике компонентның да мәгънәләре саклана.

Сыйфат$_1$+сыйфат$_2$ моделе. Бу модельдә кабатлаулы куш сүзләр барлыкка килә: *ак-ак, озын-озын, сары-сары, вак-вак, биек-биек, йомры-йомры, катлы-катлы, парлы-парлы, күзле-күзле, кытырлы-кытырлы, кырлы-кырлы, сырлы-сырлы, төрле-төрле, өзек-өзек*. Мисаллардан күренгәнчә, бер үк сыйфатлар кушылганда билгенең көчәюе күзәтелә һәм күплек мәгънәсе барлыкка килә: *озын-озын кешеләр, биек-биек таулар, өзек-өзек тавышлар, йомры-йомры ташлар.*

Икеләтелгән сыйфатларның бер төре лексик берәмлекләргә якын торалар: *катлы-катлы, өзек-өзек.* Икенчеләре, лексик-грамматик үзенчәлекләре күрсәткәнчә, сыйфатларның үзенчәлекле күплек формалары буларак грамматикага якын торалар.

Сыйфат + кабатлы яңгырау сүз моделе. Телдә бу төр куш сыйфатлар да очрый: *артык-портык, чалыш-полыш, озын-мозын, кыек-мыек, иләс-миләс, тиле-миле, ярты-порты.* Бу төр кабатлаулы куш сыйфатларның икенче компоненты сүзгә стилистик мәгънә – кимсетү, түбәнсетү төсмере бирә. Шуңа күрә аларны кабатлаулы стилистик куш сүзләр дип атарга мөмкин. Мондый куш сыйфатлар арасында этимологиясе ачык булмаган сүзләр дә очрый. Әмма, һичшиксез, аларның компонентларының тарихи яктан караганда реаль мәгънәләре булган.

**Фигыль + фигыль тибы.** Аның түбәндәге модельләре бар.

Фигыль$_1$нең үткән категорик заман формасы + фигыль$_2$ нең үткән категорик заман формасы моделе: *килде-китте* (*килде-китте кеше*), *керде-чыкты.*

*-лы* кушымчалы фигыль$_1$нең үткән категорик заман формасы + *-лы* кушымчалы фигыль$_2$нең үткән категорик заман формасы моделе: *килделе-киттеле, керделе-чыктылы.*

Сыйфат фигыль$_1$ + сыйфат фигыль$_2$ моделе: *узган-барган, туган-үскән, күргән-белгән, килгән-киткән, ашаган-эчкән, азган-тузган.* Аерым очракларда мондый куш сыйфатларның компонентлары урыннарын алыштырырга мөмкин: *белгән-күргән, күргән-белгән.*

*-лы* кушымчалы предикатив сүз$_1$ + *-лы* кушымчалы предикатив сүз$_2$. Бары бер сүздә генә күзәтелә: *барлы-юклы*. Компонентлары урыннарын алыштырырга да мөмкин: *юклы-барлы*.

**Рәвеш$_1$ + рәвеш$_2$ тибы.** Бу типка түбәндәге куш сыйфатлар керә: *русча-татарча (русча-татарча сүзлек*), *немецчә-татарча, татарча-русча, казакъча-инглизчә* һ.б.ш.

## Компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сыйфатлар ясалышы

Компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сыйфатлар ясалышы. Хәзерге татар телендә компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сыйфатлар бик күп. Ләкин аларның байтагы сүзтезмәләрнең кушымча алып кушма сүзгә күчү юлы белән барлыкка килгәннәр: *күп кат+лы, озын аяк+лы, ике том+лы, күп буын+лы, тулы хокук+лы* һ.б.ш.

Кушма сыйфатның сүзтезмәне кушымчалау юлы беләнме яки сүзләр кушылу юлы беләнме ясалганын аеру критериен телдә тәңгәл сүзтезмәнең булуы тәшкил итә. Телдә тәңгәл ирекле сүзтезмәнең яшәве кушма сыйфатның кушымча алып кушма сыйфатка күчүенә дәлил булып тора. Югарыда китерелгән кушма сыйфатларның телдә ирекле сүзтезмәләре бар. Шуңа күрә дә кушма сыйфатларның ясалыш моделен ирекле сүзтезмә + *-лы* кушымчасы моделе тәшкил итә.

Шулай да татар телендә компонентлары атрибутив мөнәсәбәттә булган кушма сыйфатларның сүзләр кушылу юлы белән ясалу үрнәкләре бар. Бу хәлне андый кушма сыйфатларның телдә тәңгәл ирекле сүзтезмәнең булмавыраслый.

**Исем + исем тибы.** Аның исем$_1$ + исем$_2$ моделе бар. Бу модельдә кушма сүзләр аз: *дөньякүләм, союзкүләм* (*җилаяк, капкорсак*).

**Исем + сыйфат тибы.** Ике моделе бар.

*Ярым* + сыйфат моделе. Беренче компонент, кагыйдә буларак, бу төр кушма сыйфатларда гына була: *ярымрәсми, ярымколониаль,*

*ярымкыргый, ярымҗимерек, ярымялангач.* Кайбер очракта икенче компонент булып сыйфат мәгънәсендә кулланылган исем дә килергә мөмкин (*ярымйон*). Бу кушма сыйфатлар нигезләр кушылу ысулы белән барлыкка килгәннәр, чөнки телдә аларга тәңгәл ирекле сүзтезмәләр юк.

Конкрет исем + төс белдерә торган сыйфат моделе: *алмачуар, чиякызыл, шомырткара, әфлисунсары.*

**Исем + бәйлек тибы.** Татар телендә аның шулай ук ике моделе бар:

Исем+*ара* бәйлеге моделе: *районара, планетаара, континентара, союзара, халыкара, шәһәрара, йолдызара, милләтара, күзәнәкара, заводара, цехара, ведомствоара.* Мисаллардан күренгәнчә, бу төр кушма сыйфатларның күпчелеге тиешле рус сүзләренең калькалары булып торалар, телдә соңгы вакытта гына барлыкка килгәннәр.

Исем + *төсле* бәйлеге моделе. Икенче компонент булып, кагыйдә буларак, *төсле* бәйлеге килә, беренче компонент булып ачык төстәге үсемлек, җимеш белдерә торган исем килә: *чия төсле, кәстәнә төсле, шомырт төсле, җитен төсле, әфлисун төсле.*

**Сыйфат$_1$ + сыйфат$_2$ тибы.** Аның бер моделе бар.

Сыйфат$_1$ + сыйфат$_2$ моделе. Телдә бу модель белән ясалган кушма сыйфатлар еш очрый: *каракүк, каракызыл, караяшел, күкселкара, аксылкүк, аксылсоры, сарыяшел, сарыкызыл* һ.б. Яшәп килгән орфография буенча югарыда китерелгән кушма сыйфатларның компонентларын дефис аша язалар, сирәк кенә аларны кушып язу очраклары да күренә. Компонентларның үзара бәйләнешләрен һәм семантикасын тикшерү алар арасында мөнәсәбәтләрнең тезүле булмыйча, ияртүле, атрибутив булуын күрсәтә, шунлыктан бу кушма сыйфатларны дефис аша язу фәнни яктан дөрес түгел.

**Алмашлык + исем тибы.** Сыйфатлар ясалышының бу тибында *үз* билгеләү алмашлыгы беренче компонент булып килә: *үзбаш.* Бу кушма сыйфат рус сүзенең калькасы булып тора һәм аңа тәңгәл сүзтезмә юк.

**Алмашлык + сыйфат тибы.** Телдә аның ике моделе бар.

*Үз* дигән билгеләү алмашлыгы + сыйфат: *үзбелдекле, үзирекле, үзйөрешле, үзсүзле, үзэшчән.* Бу кушма сыйфатлар нигезләр кушылу

ысулы белән барлыкка килгәннәр, телдә аларга тәңгәл ирекле сүзтезмәләр юк: *үз белдек, үз ирек.*

*Һәр* дигән билгеләү алмашлыгы + сыйфат: *һәртөрле, һәрвакыттагы, һәрьяклы. Һәртөрле* дигән кушма сыйфатлар нигезләр кушылу ысулы белән ясалган, чөнки, *һәртөр+ле* түгел, *һәр+төрле* структурасы биредә табигыйрак. Семантик яктан *һәр* алмашлыгы сыйфатның мәгънәсен көчәйтә.

**Сан + сыйфат тибы.** Беренче компонент буларак нигездә *бер* саны кулланыла: *бертөрле, берсекөнге, бертөсле, бертигез.* Китерелгән мисалларда *бер* саны сыйфат мәгънәсен (*бертөрле, бертөсле*) белдерә. Фактлар күрсәткәнчә, югарыда китерелгән кушма сыйфатларның телдә тәңгәл ирекле сүзтезмәләре юк. Хәзерге вакытта бу төр кушма сыйфатларның икенче компонентлары мөстәкыйль кулланылмыйлар (мәсәлән, *берсекөнге* кушма сыйфаттагы *көнге* сүзе).

Бу структурадагы кайбер кушма сыйфатлар нигезләр кушылуның нәтиҗәсе булып тормыйлар. Мәсәлән, *бермәгънәле, бертактлы, бермөгезле* һ.б.ш. тиешле ирекле сүзтезмәләрдән (*бер мәгънә, бер такт, бер мөгез*) *-лы* кушымчасы белән ясалганнар, ягъни алар сүзтезмәләрнең, кушымча алып, лексикалашуын тәшкил итә.

**Сан + сан тибы.** Беренче компонент *бер* сүзенең чыгыш килеш формасын ала: *бердәнбер.* Бу сүз сүзтезмәнең лексикалашуы булып тормый, чөнки телдә андый сүзтезмә юк.

**Кисәкчә + сан тибы.** Беренче компонент булып *һич* кисәкчәсе, икенче компонент булып *бер* саны килә: *һичбер.*

**Рәвеш + сыйфат тибы.** Беренче компонент булып үзе белән кулланылган сүзгә бәйләнешле алынма сүзләр килә: *ультра, мета, архи* һ.б.: *ультракыска, ультрамиләүшә, метафәнни* (*ультракыска дулкыннар*). Татар телендә бу модельгә караган архаик сыйфатлар да бар: *бивакыт, бигамь* һ.б. Алар тулысынча гарәп һәм фарсы теленнән алынганнар, нигезләр кушылу татар телендә түгел, ә чыганак телдә булган.

## Сүзтезмәләрнең лексикалашу ысулы белән кушма сыйфатлар ясалышы

Атрибутив сүзтезмәләр дә, объект һәм хәл сүзтезмәләре дә лексикалашып кушма сыйфат ясарга мөмкин.

### *Компонентлары атрибутив бәйләнешендә булган сүтезмәләрнең кушма сыйфатларга күчүе*

**Исем + бәйлек тибы.** Кайбер исемнәрнең бәйлек белән килүе кушма сыйфат китереп чыгара: *көмешсыман* ← *көмеш сыман* (көмешсыман чәчләр), *чатырсыман* ← *чатыр сыман* (чәчәкнең чатырсыман таҗы), *шарсыман* ← *шар сыман* (шарсыман яшен), *дагасыман* ← *дага сыман* (дагасыман салават күпере).

Атрибутив сүтезмәдән килеп чыккан кайбер кушма сүзләр хәзерге телдә үзләренең структурасын югалтып, гадәти тамыр сүзгә әйләнгәннәр: *бүген* (*бу көн*), *быел* (*бу ел*). Алар бары этимологик яктан гына кушма сүз дип саналырга тиеш.

### *Компонентлары объект бәйләнешендә булган сүтезмәләрнең кушма сыйфатларга күчүе*

**Исем + сыйфат фигыль тибы.** Аның ике моделе бар.

Туры объект функциясендәге исем + *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль моделе: атказанган, данказанган. Бу структурадагы кушма сүзләр топонимнарда һәм антропонимнарда очрый: *таштапкан, бүретоткан, малтапкан,* ләкин болар исем тәшкил итәләр.

Туры объект функциясендәге исем + *-р* кушымчалы сыйфат фигыль моделе (барлыкта һәм юклыкта): *сусөяр, җылысөяр, колгасар, башимәс.*

Юнәлеш килешендәге исем + *-лы* кушымчалы сыйфат моделе. Бу типтагы сүтезмәләрнең кушма сыйфатка әйләнүе соңгы чорда терминнар ясауда активлашты: *максатка ярашлы, эшкә яраклы, эшкә сәләтле, түләүгә сәләтле, кышка чыдамлы.* Аларның күпчелеге рус телендәге сүзләрнең калькалары булып торалар.

### *Компонентлары хәл бәйләнешендә булган сүтезмәләрнең кушма сыйфатларга күчүе*

**Рәвеш + сыйфат фигыль тибы.** Берничә моделе бар.

Рәвеш + *-р* кушымчалы сыйфат фигыль моделе: *тизатар*.

Урын рәвеше + *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль моделе. Мисаллар: *югарыда күрсәтелгән, түбәндә китерелгән, югарыда китерелгән, югарыда сөйләнгән.* Болар хәзерге көндә телдә кушма лексик берәмлекләр буларак күз алдына киләләр. Ихтимал, рус теленнән аларны тәрҗемә итү моңа этәрә.

Вакыт рәвеше + *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль моделе. Телдә мондый ясалышлар күп түгел: *тумыштан килгән, электән килгән, борыннан калган.* Семантикаларына анализ ясау аларның сүзтезмә булмыйча, кушма сыйфат булуын күрсәтә.

Тасвир (саф) рәвеше + *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль моделе. Бу модельдәге сүзтезмәләр еш кына кушма сыйфатлар функциясендә кулланылалар. Алар, ихтимал, кушма сүзгә күчү процессын кичерәләр: *яңа туган, күп сөйләнгән, аз өйрәнелгән.* Болар рус теленең кушма сыйфатларын калькалаштыру юлы белән килеп чыкканннар, шуңа күрә дә алар татар телендә дә кушма сыйфат буларак күз алдына киләләр.

**Сүзтезмәләренең, кушымча алып,**
**кушма сыйфатларга күчүе**

Бу ысул белән татар телендә бик күп сыйфатлар ясала.

**Сүзтезмә + *-лы* кушымчасы тибы.** Г. Ибраһимов грамматикасыннан тыш, татар теле грамматикаларында мондый ясалыш гомумән күрсәтелми. Бу ясалышның сүзләр кушылу белән бернинди дә уртаклыгы юк. Биредә сүзтезмә, кушымча алып, кушма сыйфатка әйләнә. Предметның яки затның үзенчәлекле билгесен белдерә торган сүзтезмәләр бигрәк тә җиңел лексикалашалар, ягъни кушма сүзгә күчәләр: *күккүзле, сарычәчле, озынкуллы, озынаяклы.*

Мондый типтагы кушма сыйфатлар сүзтезмә белдергән нәрсә яки үзенчәлек белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *кан коюлы, кара күзле, сары чәчле, күпмилләтле, күпбалалы, күпбуынлы.*

Бу типтагы ирекле сүзтезмәләр лексикалашканда аларның ясаучы нигезләре булып беренче компонентлары сыйфат яки сан тәшкил иткән сүзтезмәләр килә: *өчфаза+лы, берьяк+лы, икеяк+лы, күпбала+лы, зәңгәр күз+ле, ак йөз+ле.*

*Кырык икеле* (аяк киеме) кебек кушма сыйфат сүзтезмәдән түгел, ә кушма саннан ясалган.

**Сүзтезмә + *-гыч/-геч* (*-кыч/-кеч*) кушымчасы.** Кайбер тотрыклы әйләнмәләрдән *-гыч* кушымчасы ярдәмендә кушма сыйфатлар ясалырга мөмкин: *таңкалдыргыч, эчпошыргыч.* Мондый сыйфатлар сүзтезмә белдергән халәт белән тасвирлана торган мәгънәне тәгъбир итә. Бу тип сыйфатлар кушма фигыльләрдән дә ясала: *хәлит+кеч, искит+кеч, шаккат+кыч.*

**Сүзтезмә + *-малы/-мәле* кушымчасы.** Бу ясалыштагы кушма сыйфатлар ясаучы нигез белдергән халәт белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *сусал+малы, утәкүрен+мәле, сукой+малы.* Бу кушма сыйфатлар *су койма, утә күренмә* кебек сүзтезмәләрдән ясалмаганнар, чөнки телдә андый реаль сүзтезмәләр юк.

**Сүзтезмә + *-чы/-че*$_1$ кушымчасы.** Күпчелек очракта бу типта кушма исемнәр ясала. Әмма кайвакыт кушма сыйфатлар да ясалырга мөмкин: *эш сөюче, дым яратучы.* Сүзтезмәләрнең компонентлары үзара объект бәйләнешендә.

**Сүзтезмә + *-лык/-лек* кушымчасы.** Сүзьясалышның бу тибы буенча исемнәр генә түгел, сыйфатлар да ясала: *күпьеллык, өчатналык, бишайлык* һ.б.

Татар телендә бу типтагы башка кушма сыйфатлар да бар, ләкин алар, фәнни анализ күрсәткәнчә, сүзтезмәләрнең лексикалашуының нәтиҗәсе булып тормыйлар. Алар кушма исемнәрнең кушма сыйфатка күчүе сәбәпле барлыкка килгәннәр: *бишьеллык* (исем) → *бишьеллык* (*бишьеллык план*), *ункөнлек* (исем) → *ункөнлек* (*ункөнлек азык*), *бишкөнлек* (исем) → *бишкөнлек* (*бишкөнлек ял*).

Бу типтагы кушма сыйфатларның ясалышын билгеләү шактый авыр. Әгәр аларның исем мәгънәләре юк икән, димәк, алар, һичшиксез, сүзтезмәләрнең лексикалашуы нәтиҗәсендә килеп чыкканнар. Әгәр дә исем мәгънәсе дә, сыйфат мәгънәсе дә булса, аларны сүзтезмә дип түгел, ә кушма исем кушма сыйфатка күчкән дип карарга туры килә.

**Сүзтезмә + *-чан/-чән* кушымчасы.** Ясаучы нигезләре булып фигыль сүзтезмәләре килә. Бу типтагы кушма сыйфатлар затның яки предметның сыйфатын белдерәләр: *җиңел ышану+чан, ояла белү+чән, җиңел эрү+чән, нык тору+чан, күп сөйләү+чән.*

### 9.7.4. Конверсия ысулы белән сыйфатлар ясалышы (адъективизация)

Конверсия ысулы белән сыйфатлар ясалышы татар телендә киң таралган. Барлык сүз төркемнәренең дә диярлек сүзләре һәм сүз формалары сыйфатларга күчәләр.

Рус һәм Европа телләреннән, кушымчалары төшереп калдырылып алынган сыйфатларны конверсия ысулы белән ясалган сыйфатлардан

аеру шактый авыр санала. Телдә конверсия ысулы белән ясалган сыйфатларга охшаган, әмма ул юл белән ясалмаган сүзләр очрый: *дежур укучы, демократ язучы, тропик урман.* Беренче караштан биредәге беренче компонентларны конверсия ысулы ясалган сыйфатлар дип танырга мөмкин. Ләкин чынбарлыкта алар исемнәрнең конверсия ысулы белән сыйфатка күчүе нәтиҗәсендә түгел, ә рус теленнән, кушымчалары төшереп калдырылып, алынган сүзләр булып торалар.

Шундый ук аеруы авыр булган очраклар башка кушма сүзләрдә дә, ярым тотрыклы тезмәләрдә дә күзәтелә. *Ир бала, кыз бала, бала кош, ата каз, ана каз* кебек тезмәләрдә беренче компонент билгене белдерсә дә, алар конверсия нәтиҗәсен тәшкил итмиләр, кушма сүзләрнең һәм ярым тотрыклы тезмәләрнең компонентлары булып торалар.

**Исемнәрнең сыйфатларга күчүе**

Исемнәрнең сыйфатларга күчүе регуляр булырга һәм регуляр булмаска мөмкин.

I. Киң мәгънәдә материал белдергән исемнәр сыйфатларга күчәләр. Аларны тематикасы буенча түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин.

1) Төрле тукыма белдергән исемнәр:

*бәрхет* → *бәрхет* (*бәрхет кәләпүш*)
*ефәк* → *ефәк* (*ефәк күлмәк*)
*киндер* → *киндер* (*киндер алъяпкыч*)
*алача* → *алача* (*алача күлмәк*)
*китән* → *китән* (*китән букча*)
*постау* → *постау* (*постау бишмәт*)
*макмал* → *макмал* (*макмал кәләпүш*)
*ситсы* → *ситсы* (*ситсы яулык*)
*чыпта* → *чыпта* (*чыпта капчык*)
*велюр* → *велюр* (*велюр эшләпә*)
*габардин* → *габардин* (*габардин костюм*)
*марокен* → *марокен* (*марокен күлмәк*)
*бостон* → *бостон* (*бостон чалбар*)
*поплин* → *поплин* (*поплин тышлык*)
*тукыма* → *тукыма* (*тукыма кием*)
*тула* → *тула* (*тула оек*)

Бу төр сыйфатлар нигез сүз белдергән материалдан тегелгән, ясалган дигән мәгънәне белдерә. Мисаллар: *Әни этинең... искереп беткән т у л а  ч и к м ә н е н бирде*. М. Гали. *Балалар шул арбага ч ы п т а  җ и л к ә н корганнар*. Г. Гобәй. *С и т с ы  т о в а р магазинда тәмам беткән*. Г. Камал. *Алга ябу өчен кызыл с и т с ы  ю р г а н да куелган иде*. М. Гали.

2) Төрле асылташларны, металларны, файдалы казылмаларны белдергән исемнәр:

| | | |
|---|---|---|
| *алтын* | → | *алтын* (*алтын сәгать*) |
| *көмеш* | → | *көмеш* (*көмеш алка*) |
| *тимер* | → | *тимер* (*тимер көрәк*) |
| *бакыр* | → | *бакыр* (*бакыр савыт*) |
| *точ* | → | *точ* (*точ таз*) |
| *бронза* | → | *бронза* (*бронза һәйкәл*) |
| *ахак* | → | *ахак* (*ахак алка*) |
| *кургаш* | → | *кургаш* (*кургаш ядрә*) |
| *алмаз* | → | *алмаз* (*алмаз кискеч*) |
| *мәрмәр* | → | *мәрмәр* (*мәрмәр һәйкәл*) |
| *корыч* | → | *корыч* (*корыч пычак*) |
| *гранит* | → | *гранит* (*гранит стена*) |

Бу төр сыйфатлар ясаучы нигез белдергән материалдан ясалган дигән мәгънәне белдерә.

Мисаллар: *Гөлсем апа... кәгазь өстенә а х а к  к а ш л ы йөзек, бик кечкенә а л т ы н  с ә г а т ь,  а л т ы н  ч ы л б ы р л ы медальон чыгарып тезгәч, игътибар итми калмады*. Г. Гобәй. *Аның каршысында м ә р м ә р  б а г а н а л ы ак таш йорт*. Г. Минский.

Югарыда китерелгән сүзтезмәләрнең беренче компонентлары билге белдерәләр, теләсә нинди ситуациядә *нәрсә?* дигән сорауга түгел, *нинди?* дигән сорауга җавап бирәләр. Бу очракта бер генә сорау туарга мөмкин: «Нинди сәгать сатып алдың?».

3) Ясалма материал белдерә торган исемнәр:

| | | |
|---|---|---|
| *резин* | → | *резин* (*резин итек*) |
| *пыяла* | → | *пыяла* (*пыяла савыт*) |
| *победит* | → | *победит* (*победит кискеч*) |
| *кирза* | → | *кирза* (*кирза итек*) |

Бу сыйфатлар ясаучы нигез белдергән материалдан гыйбарәт яки шуннан ясалган дигән мәгънәне белдерә.

Мисаллар: *Ул аякларына яңа резин галошлар белән матур гына ботинкалар кигән.* Ш. Камал. *Илдар... машинаның биек резин тәгәрмәчләренә басып, борт такталарына ябышып кузовка менеп китте.* Г. Гобәй.

4) Төрле агачларны, үсемлекләрне һәм алардан ясалган эшләнмәләрне белдергән исемнәр:

| | | |
|---|---|---|
| *агач* | → | *агач* (*агач өй*) |
| *бамбук* | → | *бамбук* (*бамбук таяклар*) |
| *туз* | → | *туз* (*туз савыт*) |
| *чаган* | → | *чаган* (*чаган чаңгылар*) |
| *чыбык* | → | *чыбык* (*чыбык читән*) |
| *салам* | → | *салам* (*салам эшләпә*) |
| *чүп* | → | *чүп* (*чүп үлән*) һ.б. |

Бу сыйфатлар «ясаучы нигез белдергән нәрсәдән гыйбарәт яки ясалган» дигән мәгънәне тәгъбир итә.

Мисаллар: *Сәхнәгә кызу атлап, кулына җиләк җыя торган туз савыт тоткан Сафура килеп керә.* А. Әхмәт. *Яланаякка агач башмак өстерәп, тезенә төшкән күк күлмәгенең изүен чишеп җибәргән иде.* И. Газый.

5) Хайваннарны яки аларның ясалган материалны белдергән исемнәр:

| | | |
|---|---|---|
| *йон* | → | *йон* (*йон оек*) |
| *сөяк* | → | *сөяк* (*сөяк тарак*) |
| *күн* | → | *күн* (*күн куртка*) |
| *мех* | → | *мех* (*мех бүрек*) |
| *бүре* | → | *бүре* (*бүре толып*) |
| *мутон* | → | *мутон* (*мутон тун*) |
| *камчат* | → | *камчат* (*камчат бүрек*) |
| *каракүл* | → | *каракүл* (*каракүл тун*) |

Бу төр сыйфатлар ясаучы нигез белдергән нәрсәдән ясалган, тегелгән дигән мәгънәне тәгъбир итә: *Монда ни генә юк! Өр-яңа күн итекләр, бүре толыплар, кама туннар.* И. Газый.

*Өч-дүрт к а е ш  й ө г ә н н е бергә бәйләп аркага аскан килеш, ялкау гына атлап килүче бер яшь егет әйтте бу сүзне.* М. Әмир.

Исемнәрдән конверсия ысулы белән сыйфатлар ясалу – үсештәге процесс. Кеше тарафыннан ясалган материалларны белдерә торган исемнәр даими барлыкка килеп тора: *поролон, полимер, кримплен, лавсан, полиэстр, сентипон* һ.б. Бу исемнәрнең барысы да конверсия юлы белән сыйфатларга күчтеләр: *поролон түшәк, полимер матдәләр, кримплен күлмәк, лавсан күлмәк.*

Бу сыйфатлар ясаучы нигез белдергән материалдан ясалган, тегелгән дигән мәгънәне тәгъбир итә.

Тел фактлары күрсәткәнчә, материал белдерә торган теләсә нинди исем сыйфатка күчә ала.

II. Берәр төрле үзенчәлекле формалы предметны, оригиналь тышкы кыяфәтле нәрсәне белдерә торган исемнәр шулай ук сыйфатларга күчәргә мөмкин:

*ябалак* → *ябалак* (*ябалак кар*)
*күбәләк* → *күбәләк* (*күбәләк кар*)
*гармун* → *гармун* (*гармун итәк*)
*буй* → *буй* (*буй бүрәнә*)
*багана* → *багана* (*багана умарта*)
*бөртек* → *бөртек* (*бөртек чәй*)
*бөдрә* → *бөдрә* (*бөдрә чәч*)

Югарыдагы исемнән ясалган сыйфатлар ясаучы нигез белдергән формалы дигән мәгънәне тәгъбир итә: *Тышта бик матур булып эре-эре я б а л а к  к а р ява.* М. Җәлил. *Г а р м у н  и т ә к л е күлмәк.* Сөйләм теле.

III. Пространствоны, аның төрле якларын белдергән исемнәр сыйфатларга күчәргә мәмкиннәр:

*ара* → *ара* (*ара күренеш*)
*ас* → *ас* (*җир*)
*өс* → *өс* (*өс як*)
*ян* → *ян* (*ян капка*)
*якын-тирә* → *якын-тирә* (*якын-тирә районнар*)
*көнбатыш* → *көнбатыш* (*көнбатыш өлкәләр*)
*көньяк* → *көньяк* (*көньяк регионнар*)

*арт* → *арт* (*арт як*)
*ал* → *ал* (*ал як*)
*күрше* → *күрше* (*күрше авыллар*)
*төньяк* → *төньяк* (*төньяк елгалар*)

Конверсия ысулы белән ясалган бу төр сыйфатлар «ясаучы нигез белдергән пространство мөнәсәбәте белән тасвирлана торган» дигән мәгънәне тәгъбир итә: *А р т я к т а кухняга чыга торган ишек.* Ш. Камал. *А р т я к н ы ң такта арасына караса,... тонык кына ут яктысы күренә.* Ш. Камал. *Бу – Чкалов, Т ө н ь я к к о т ы п аша очып үтә Америкага.* Ф. Кәрим.

IV. Кешенең рухи сыйфатын яки дәрәҗәсен белдергән исемнәр шулай ук сыйфатларга күчәргә мөмкин:

*батыр* → *батыр* (*батыр егет*)
*каһарман* → *каһарман* (*каһарман сугышчы*)
*хаким* → *хаким* (*хаким сыйныф*)
*ялкау* → *ялкау* (*ялкау хатын*)
*мөнафикъ* → *мөнафикъ* (*мөнафикъ дус*)
*галим* → *галим* (*галим кеше*)
*залим* → *залим* (*залим патша*)
*башбаштак* → *башбаштак* (*башбаштак түрә*)

Исемнән конверсия ысулы белән ясалган бу төр сыйфатлар ясаучы нигез белдергән үзенчәлек, билге белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *Бу бүләгем б а т ы р е г е т л ә р г ә !* М. Җәлил. *Архангельский чынлап та к а һ а р м а н г е р о й тәэсире бирерлек иде.* Ш. Камал. *Теге б а ш б а ш т а к е г е т ялгыз килгәнме?* М. Җәлил.

Кайбер сыйфатлар, мәсәлән, хайван яки киек исемнәре үзләренең күчмә мәгънәләре белән сыйфатка әйләнәләр. Мәгълүм булганча, кайбер хайван атамаларының кешеләрне тасвирлаучы күчмә мәгънәләре бар: *арыслан* 1) киек, 2) кыю кеше; *төлке* 1) киек, 2) хәйләкәр кеше; *ишәк* 1) хайван, 2) аңгыра кеше; *аждаһа* 1) елан, 2) явыз кеше; *елан* 1) елан, 2) усал (мәкерле) кеше.

Бу сүзләрнең күчмә мәгънәләре сүзлекләрдә күрсәтелгән.

Бу исемнәр сыйфатларга күчкәндә, аларның күчмә мәгънәләре кешенең характерлы билгесен белдерә: *арыслан ир, төлке карт, аждаһа күрше, елан хатын.*

Бары характерлы үзенчәлекне белдергән хайван исемнәре генә сыйфатка әйләнә ала. Аларның кайберләре телдә түгел, бары сөйләмдә генә конверсияләнергә, окказиональ күчеш кенә булып торырга мөмкин.

V. Аерым урынны белдергән исемнәр дә сыйфатка күчәләр:

| | | |
|---|---|---|
| *ялан* | → | *ялан* (*ялан урын*) |
| *дала* | → | *дала* (*дала җир*) |

Кешенең эш-гамәлләренә караган исемнәр шулай ук сыйфатларга күчәргә мөмкин:

| | | |
|---|---|---|
| *азап* | → | *азап* (*азап эш*) |
| *хата* | → | *хата* (*хата фикер*) |
| *ялган* | → | *ялган* (*ялган сүз*) |
| *гаеп* | → | *гаеп* (*гаеп эш*) |
| *гайбәт* | → | *гайбәт* (*гайбәт хәбәр*) |

Исемнәрдән конверсия ысулы белән ясалган бу төр сыйфатлар ясаучы нигез белдергән билге белән характерлана торган мәгънәне тәгъбир итә: *Бик зур хата эш кылдым шул.* Ш. Мөхәммәдев. *Гаяз үзенең хата фикерен минем дөрес фикеремнән өстен чыгара алды.* М. Әмир. *Бу ялган исемне ирексез кабул итәргә мәҗбүр булдым.* А. Шамов. *Ялган вәгъдәләр белән, ташламам, үлсәм дә онытмам, дип аерылып китте.* М. Гафури.

Биредә шуны әйтеп китәргә кирәк: кайбер исемнәр конверсия юлы белән ясалган сыйфатларга охшасалар да, чынында исә сыйфат булып тормыйлар, татар телендә исем буларак аныклагыч тәшкил итәләр, рус телендә приложениегә туры киләләр. Алар гадәттә эш урынын, социаль хәлне һ.б.ш. белдерәләр.

*абитуриент егет – парень-абитуриент*
*администратор хатын – женщина-администратор*
*батрак кыз – девушка-батрачка*
*патриот шагыйрь – поэт-патриот*
*сукбай малай – мальчик-бродяга*

Конверсия ысулы белән фигыльләрдән ясалган исемнәр, яисә исем фигыльләр исемнәргә әйләнеп сыйфатларга күчәләр:

*кызу* (фигыль) → *кызу* (исем) → *кызу* (сыйфат)
*авыру* (фигыль) → *авыру* (исем) → *авыру* (сыйфат)
*калку* (фигыль) → *калку* (исем) → *калку* (сыйфат)
*сорау* (фигыль) → *сорау* (исем) → *сорау* (сыйфат)
*ярсу* (фигыль) → *ярсу* (исем) → *ярсу* (сыйфат)

Мисаллар: *кызу һава, авыру кеше, калку урын, сорау җөмлә, ярсу атака.*

*-у* кушымчалы исемнәрдән ясалган сыйфатлар ясаучы нигез белдергән кебек, шундый сыйфатка ия дигән мәгънәне белдерә: *Шул чагында йөрәкләрдә ярсу дәрт кайный. Калку җирләр бөтенләй кибеп бара.* Ш. Камал. *Калку басулардан борыннарга аңкый җир исе.* Ш. Маннур.

Тел фактлары күрсәткәнчә, кайбер фигыль формалары тышкы яктан исемнәргә генә түгел, ә сыйфатларга да охшашлар, аларны бер үк вакытта исемнәрнең дә, сыйфатларның да ясаучы нигезләре итеп кабул итәргә була:

*кызу* (фигыль) → *кызу* (исем)
*кызу* (фигыль) → *кызу* (сыйфат)

*авыру* (фигыль) → *авыру* (исем)
*авыру* (фигыль) → *авыру* (сыйфат)

*сорау* (фигыль) → *сорау* (исем)
*сорау* (фигыль) → *сорау* (сыйфат)

*ярсу* (фигыль) → *ярсу* (исем)
*ярсу* (фигыль) → *ярсу* (сыйфат)

Чынында исә күпчелек очракта фигыль формаларының сыйфатларга күчүе турыдан-туры түгел, баскычлы булган, төгәлрәге – *-у* кушымчалы фигыльләр башта исемнәргә, исемнәрдән сыйфатларга күчкәннәр:

*кызу* (фигыль) → *кызу* (исем) → *кызу* (сыйфат)
*авыру* (фигыль) → *авыру* (исем) → *авыру* (сыйфат)

Моны тикшерелә торган сыйфатларның сүзьясалыш мәгънәсе фигыль семантикасы белән бәйләнмәгән булуы күрсәтә. Мәсәлән, *кызу* сыйфатының мәгънәсе ясаучы нигез белдергән билге (үзенчәлек) белән характерлана торган, ягъни кызулык белән характерлана торган мәгънәгә туры килә, фигыльдәгечә «кызуга әйләнү» дигән процесска туры килми. Исемнәр төп формада да, кыек килеш формаларында да сыйфатларга күчәргә мөмкин:

*баш табиб*
*баш механик*
*баш фәнни хезмәткәр*
*баш геолог*
*баш инженер*
*башка кеше*
*башка караш*
*башка шәһәр*

*Мисаллар: Сәлигаскәрова б а ш к а к ы з л а р д а н , ничектер, күзгә күбрәк чагыла.* М. Җәлил. *Синең шул пыскытып утырудан б а ш - к а э ш е ң булмас.* Ф. Бурнаш. *Б а ш к а к а й б е р иптәшләрнең күп кенә эшләрендә ярдәмче тавышлардан башка кинәт көчүләр урын алганын күрәбез.* М. Җәлил.

Сыйфатларга кушымчалар белән ясалган исемнәр дә, ягъни кушымчалы исемнәр дә күчәләр. Мондый күчешләр шактый регуляр күренеш һәм тулы бер система тәшкил итә.

-*чы* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*эшче* → *эшче* (*эшче корт*)
*ярдәмче* → *ярдәмче* (*ярдәмче тәгәрмәч*)
*хәерче* → *хәерче* (*хәерче карт*)

Мисаллар: *Минә ичмасам, безнең э ш ч е х а л ы к н ы әйтсәң дә ярый, алтын бит алар.* Ш. Камал. *Исемең э ш ч е и л д ә дан алсын.* Һ. Такташ.

Югарыда китерелгән сыйфатларның ясаучы нигезләре итеп исемнәрне санарга кирәк, чөнки, беренчедән, -*чы* кушымчасы грамматик предметлык белән бәйләнгән; икенчедән, ул сүзләрнең беренчел мәгънәсен исемнәр тәшкил итә.

*-лык* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*читәнлек* → *читәнлек* (*читәнлек чыбык*)
*чаршаулык* → *чаршаулык* (*чаршаулык тукыма*)
*чапанлык* → *чапанлык* (*чапанлык ефәк*)
*өйрәлек* → *өйрәлек* (*өйрәлек ярма*)
*бишмәтлек* → *бишмәтлек* (*бишмәтлек материал*)
*өчтомлык* → *өчтомлык* (*өчтомлык сүзлек*)

Мисаллар: *Биш-ун аршин күлмәклек, бишмәтлек кызыл мал бирде.* Г. Ибраһимов. *Күлмәклек сатиннар, пилмәнлек ит...* Ш. Камал.

*-ма* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*күрсәтмә* → *күрсәтмә* (*күрсәтмә әсбап*)
*кыскартма* → *кыскартма* (*кыскартма сүз*)
*чагыштырма* → *чагыштырма* (*чагыштырма метод*)
*өстәмә* → *өстәмә* (*өстәмә материал*)
*язма* → *язма* (*язма ядкарьләр*)
*уйдырма* → *уйдырма* (*уйдырма сүзләр*)

Мисаллар: *Сыеклыкларның чагыштырма авырлыкларын билгеләү өчен ареометрдан файдаланалар.* Химия дәреслеге. *Абсолют хатаның якынча санга чагыштырмасы чагыштырма хата дип атала.* Арифметика дәреслеге. *Сыерларыбызга менә дигән өстәмә азык булыр иде.* Ә. Еники. *Хәзер фронт фондына өстәмә ашлык ташыйбыз.* Г. Әпсәләмов. *Үзенең качуын аклар өчен әллә нинди уйдырма хәбәрләр сөйләгән.* Ш. Усманов.

Мәгълүм булганча, *-ма* кушымчасы исемнәр дә ясый. Шуңа күрә сорау туа: *-ма* кушымчалы барлык сыйфатлар да, кушымчалар белән ясалганмы яисә алар конверсия ысулы белән исемнәрдән күчкәннәрме? Тел фактлары күрсәткәнчә, исемнәр булып кулланылмаган мондый сүзләр кушымчалы сыйфатлар булып торалар: *башкарма* (*башкарма комитет*).

Әгәр дә сыйфатларның тәңгәл исемнәре бар икән, алар конверсия ысулы белән ясалган дип каралырга тиеш: *чагыштырма* (исем) → *чагыштырма* (*чагыштырма ысул*), *уйдырма* (исем) → *уйдырма* (*уйдырма хәбәр*).

-*гыч* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*башваткыч* → *башваткыч* (*башваткыч табышмак*)
*беркеткеч* → *беркеткеч* (*беркеткеч матдә*)
*башлангыч* → *башлангыч* (*башлангыч мәктәп*)
*йөзгеч* → *йөзгеч* (*йөзгеч куык*)
*бозваткыч* → *бозваткыч* (*бозваткыч корабль*)

Мисаллар: *Нинди генә башваткыч мәсьәләләр чишәсе булмасын, Нәфисә барысына да әзер иде.* Г. Бәширов. *Үзенең башлангыч әсәрләрендә үк инде Г. Камал, әхлак сатучы булудан бигрәк, тәнкыйтьче булып мәйданга чыга.* М. Гали.

-*гыч* кушымчасы исемнәр дә, сыйфатлар да ясый ала. Китерелгән сыйфатның кушымча белән ясалганмы яисә ул конверсия юлы белән килеп чыкканмы икәнен билгеләү критериен аңа тәңгәл исемнең булуы тәшкил итә. Әгәр мондый сыйфатка тәңгәл исем бар икән, ул конверсия юлы белән ясалган дип каралырга тиеш.

-*р* авазына тәмамланган исемнәр → сыйфатлар:

*субүләр* → *субүләр* (*субүләр тау*)
*башкисәр* → *башкисәр* (*башкисәр фашистлар*)
*чокыр* → *чокыр* (*чокыр урын*)

Мисаллар: *Башы бозык, башкисәр кеше*. Ш. Усманов. *Сулары чокыр җиргә ага башлар.* М. Гафури.

-*ык*/-*ек,* -*к* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*яңгыравык* → *яңгыравык* (*яңгыравык тавыш*)
*бозлавык* → *бозлавык* (*бозлавык җир*)
*киртек* → *киртек* (*киртек яка*)
*шалтыравык* → *шалтыравык* (*шалтыравык кеше*)

Мисал: *Яңгыравык тавыш ишетелде.* Ш. Усманов. Биредә -*вык* комплексы бердәм кушымча түгел, ул ике элементтан -*в*+*ык* тан тора.

Татар телендә ике сузык рәттән килә алмаганлыктан, алар арасына интерфикс килеп керә. Бу очракта сузыкка тәмамланган ясаучы нигез белән сузыкка башланган кушымча арасында «в» (w) интерфиксы кулланыла.

-*чык* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*өйрәнчек* → *өйрәнчек* (*өйрәнчек эш*)
*өстерәлчек* → *өстерәлчек* (*өстерәлчек ир*)
*сөйрәлчек* → *сөйрәлчек* (*сөйрәлчек хатын*)

Мисал: *Менә шул вакытларда өйрәнчек язучы сыйфатында төрле жанрларда язып үзенең каләмен сынап карый*. М. Гали.

-*ым*/-*ем* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*өем* → *өем* (*өем болытлар*)
*явым* → *явым* (*явым көннәр*)
*савым* → *савым* (*савым сыер*)

Мисаллар: *Савым сыер симерә*. М. Җәлил. *Явым көннәр башланды*. Сөйләм теленнән.

-*дак* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*буйдак* → *буйдак* (*буйдак ир*)
*куырдак* → *куырдак* (*куырдак ит*)

Мисал: *Буйдак кешегә ярый ул*. Г. Ибраһимов.

-*ыш*/- *еш, -ш* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*белеш* → *белеш* (*белеш рус*)
*кереш* → *кереш* (*кереш сүз*)
*таныш* → *таныш* (*таныш кеше*)
*чыгыш* → *чыгыш* (*чыгыш нокта*)

Мисаллар: *Минем монда бер дә белеш кеше юк*. Г. Камал. *Таныш йөзен күреп кыз елмайды*. М. Җәлил.

-*гак*/-*гәк* (-*как*/-*кәк*) кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*баткак* → *баткак* (*баткак юл*)
*күпкәк* → *күпкәк* (*күпкәк бала*)

Мисал: *Баткак юлда көпчәкләр күмелә башлагач, кучерлар арбаларын ташлап, атка атланып күчеп киттеләр*. Ш. Усманов.

-*кә* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*бөтеркә* → *бөтеркә* (*бөтеркә чәч*)
*сөяркә* → *сөяркә* (*сөяркә хатын*)

-*ыч* кушымчалы исемнәр → сыйфатлар:

*юаныч* → *юаныч* (*юаныч хәбәр*)
*куркыныч* → *куркыныч* (*куркыныч хәл*)
*алдавыч* → *алдавыч* (*алдавыч сүз*)

Мисаллар: *Нәгыймә... берәр ю а н ы ч х ә б ә р чыгарыр дип, сабырлык белән тыңлап торды.* Г. Ибраһимов. *К у р к ы н ы ч в ә ш о м л ы х ә б ә р л ә р тарала башлады.* Г. Ибраһимов. *К у р к ы н ы ч т ө н, кап-кара.* Һ. Такташ.

### Фигыльләрнең һәм фигыль формаларының сыйфатларга күчүе

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, фигыльләрнең һәм фигыль формаларының сыйфатка күчү очраклары бар. Бигрәк тә сыйфат фигыльләр сыйфатларга еш күчәләр.

Саф фигыль тамырлары сыйфатка күчәләр:

*тын* → *тын* (*тын урын*)
*туң* → *туң* (*туң җир*)
*уң* → *уң* (*уң як*)

Бу күренеш борынгы синкретик сүзләрнең икегә аерылуыннан, фигыльләргә һәм сыйфатларга бүленүеннән килеп чыккан булса кирәк. Мондый сорау туа: аларның кайсысының морфологик мәгънәсе беренчел?

Монда Вундт, Маутнер, Бреаль, Пос һ.б. күтәреп чыккан, императивның беренчел булуы теориясе мәсьәләгә ачыклык кертә. Бу турыда О.С. Ахманова болай дип яза: «Императивны беренчел дип тану телнең беренчел формасы итеп «императив телне» тануны санарга кирәк, әмма ул тел фигыльләрдән тора дигән сүз түгел. Бу беренчел билге үзенең функциясе буенча «императив» дип атала»[1].

Кайбер күп иҗекле сүзләр борынгыда синкретик булганнар, алардан сыйфатлар барлыкка килгәндә басым беренче иҗектән соңгы иҗеккә күчкән:

---

[1] Ахманова О.С. Проспект работы «Основные вопросы общего языкознания». М., 1959. С. 37.

*ко́ры* → *коры́* (*коры́ һава*)
*кы́зык* → *кызы́к* (*кызы́к хәл*)
*я́бык* → *ябы́к* (*ябы́к сыер*)
*ә́че* → *әче́* (*эче́ катык*)[1]

*-у* га тәмамланган кайбер фигыль формаларыннан шулай ук сыйфатлар ясалалар:

*тынчу* → *тынчу* (*тынчу һава*)
*җитү* → *җитү* (*җитү кыз*)

Мондый сыйфатлар ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе булып торган билгене тәгъбир итәләр: *Мунча эченнән җылы т ы н ч у  һ а в а  бөркелде*. Г. Гобәй. *Ак җиңсәләр кигән җ и т ү  к ы з л а р ... ак тырмалар белән печән җыярлар*. Г. Ибраһимов. *Арада европача киенгән җ и т ү  ч ә ч л е  интеллигентлар да, кәләпүшле сәүдәгәрләр дә бар*. А. Расих.

*-ган* кушымчалы сыйфат фигыль формалары да конверсияләнеп сыйфатларга күчәләр:

*туган* → *туган* (*туган сеңел*)
*булган* → *булган* (*булган егет*)
*укыган* → *укыган* (*укыган кеше*)
*булмаган* → *булмаган* (*булмаган хатын*)
*җебегән* → *җебегән* (*җебегән кыз*)
*пешмәгән* → *пешмәгән* (*пешмәгән хатын*)
*уңган* → *уңган* (*уңган ир*)

Бу төр сыйфатларның семантикасына анализ ясау аларда *-ган* кушымчалы фигыльләрдә бөтенләй булмаган яңа, метафорик мәгънә булуын күрсәтә. Әгәр дә сыйфат булып килгән сыйфат фигыль формаларында, төп фигыль белән чагыштырганда, яңа мәгънә булмаса, аларны сыйфат фигыльдән барлыкка килгән сыйфат дип карап булмый, *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең сыйфатларга күчүенең төп шарты булып фигыльдә булмаган яңа мәгънәнең барлыкка килүе

[1] Ганиев Ф.А. Фонетическое словообразование в татарском языке. Казань, 1973. С. 35, 36.

тора. Яңа семантика сыйфат фигыльләрнең сыйфатка күчүенең һәм шартын, һәм билгесен тәшкил итә.

Югарыда китерелгән мисалларны чыганак фигыльләр белән чагыштырып караганда, аларда яңа мәгънәләр барлыкка килгән һәм алар, сыйфатларның лексик-семантик һәм формаль-структур билгеләрен алып, сыйфатларга күчкәннәр. Алар затның яки предметның статик билгесен белдерәләр һәм, кагыйдә буларак, чагыштыру дәрәҗәсенә ияләр.

Мисаллар: *Син дан торткан туган илдә.* Ә. Ерикәй. *Тел ясалмас гәр туган сүз ятмаса үз ибенә.* Дәрдмәнд. *Ләкин җыентыкка кергән җырларның бик күбесе чын мәгънәсе белән пешмәгән җырлар.* М. Җәлил. *Бу пешмәгән бай белән шүрәле эшедер.* Д. Аппакова. *Уңган кыз Камилә чәй дә кайнатып куйган.* Г. Минский.

*-р* кушымчалы сыйфат фигыль конверсия юлы белән шулай ук сыйфатка күчәргә мөмкин:

*кайнар* → *кайнар* (*кайнар йөрәк, кайнар сәлам, кайнар хис*).

Китерелгән мисалларда чыганак фигыльдәге мәгънә юк, бөтенләй яңа семантика барлыкка килгән.

Шулай итеп, сыйфат фигыльләр сыйфатларга күчкәндә фигыльнең барлык лексик-морфологик билгеләрен югалталар. Иң мөһиме – аларда, чыганак фигыль белән чагыштырганда, яңа мәгънә, яңа семантика барлыкка килә.

Тәңгәл фигыль формаларына мисаллар: *Егылып уңган чөгендер, тик җыеп кына өлгер.* Ә. Ерикәй. *Авыл буйларында бодай уңган.* Н. Баян.

Сыйфатка әйләнгән формаларга мисаллар: *Уңган хатын кар өстендә казан кайната дип сөйлиләр.* Г. Әпсәләмов. *Уңган килен булып чыкты.* М. Әмир.

### Рәвешләрнең сыйфатларга күчүе

Телдә күп булмаса да кайбер рәвешләрнең сыйфатларга күчүе күзәтелә:

*кыңгыр* → *кыңгыр* (*кыңгыр эш*)
*кырын* → *кырын* (*кырын юл*)

*ким* → *ким* (*ким кеше*)
*күп* → *күп* (*күп китап*)
*тулаем* → *тулаем* (*тулаем уңыш*)
*аерым* → *аерым* (*аерым эш*)

Мисаллар: *К ы ң г ы р  э ш  кырык елдан соң да беленә*. Мәкаль. *Кыз кара күзләре белән Хәлимгә бер к ы р ы н  к а р а ш  ташлады*. И. Газый. *К и л е н  к е ш е  – к и м  к е ш е* . Әйтем. *«Көтүчеләр»дәге каһарман – сөйләүче дә хикәянең к ү п  җ и р е н д ә ярты хыялый тормыш эчендә яши*. Г. Нигъмәти.

Югарыда китерелгән сүзләрнең ничек ясалганын билгеләве бик кыен: рәвеш сыйфатка күчкәнме, сыйфат рәвешкә күчкәнме? Бу очракта кайсы сүз төркеменең мәгънәсе беренчел, мәсьәләне шул хәл итә. Ясаучы нигезнең семантикасы ясалма сүзгә караганда һәрвакыт киңрәк була. Күрсәтелгән мисалларда рәвеш мәгънәсе беренчел. Моны кайберләренең формалары да күрсәтеп тора. Мәсәлән, *кырын* сүзе борынгы килеш формасын тәшкил итә һәм ничек? нинди юл белән? дигән сорауга җавап бирә: *кырын яту. Тулаем* сүзе *-ым* кушымчасы белән ясалганда, беренче чиратта, рәвеш булып тора.

### Саннарның сыйфатларга күчүе

Телдә кайбер очракларда саннарның сыйфатларга күчүе очрый:

*бер* → *бер* (*бер теләк*)
*икенче* → *икенче* (*икенче як*)
*өченче* → *өченче* (*өченче дәрәҗәдәге*)

Китерелгән мисалларның сыйфат мәгънәләре сүзлекләрдә күрсәтелә.

Мисаллар: *Сезнең белән минем б е р  т е л ә к* . Д. Аппакова. *Әллә бик кызу баралар шунда, әллә и к е н ч е  я к к а р а к  борылдылыр*. Г. Бәширов.

### Хәбәрлек сүзләрнең сыйфатларга күчүе

Кайбер вакытта хәбәрлек сүзләр дә конверсия ысулы белән сыйфатка әйләнергә мөмкиннәр:

*кирәк* → *кирәк* (*кирәк китап*)

*юк* → *юк* (*юк сүз*)
*мөмкин* → *мөмкин* (*мөмкин юл*)

Мисал: *Азымбай к и р ә к  а д ә м н ә р н е күреп, көн-төн чапты.* Г. Ибраһимов.

#### 9.8. РӘВЕШЛӘР ЯСАЛЫШЫ

### 9.8.1. Фонетик ысул белән рәвешләр ясалышы

Телнең үсеш процессында фонетик үзгәрешләр, һичшиксез, рәвешләр ясалышын да китереп чыгарганнар. Әмма бүгенге көндә бу ясалышларны ачыклау шактый авыр. Мәсәлән, басымның күчүе (*яңа́ – я́ңа*) сыйфаттан рәвеш барлыкка китергән: *Әхмәт безгә я́ңа килде.* Шулай ук сүздә авазның төшеп калуы да сыйфаттан рәвеш ясарга мөмкин (*хәрәм – әрәм*)*: Безгә вакытны әрәм үткәрергә туры килде.*

### 9.8.2. Кушымчалар ярдәмендә рәвешләр ясалышы

Тюркологиядә рәвешләрнең ясалышы тиз генә тикшерү объекты булып китә алмады. Инкыйлабка кадәр төрки телләрнең бары аерым грамматикаларында гына ул күрсәтелде. Шулай рәвешләрнең кушымчалар рәвешендә ясалышы А. Казимбәк, О. Бётлингк, Н.И. Ашмарин хезмәтләрендә искә алына.

Тик XX гасырның 40 нчы елларыннан гына грамматикаларда рәвешләр ясалышы турында аерым бүлек бирелә башлады. Рәвешләрнең кушымчалар белән ясалышы Н.П. Дыренкова, Л.Н. Харитонов, Н.К. Дмитриев, Л.А. Покровская һ.б.ның хезмәтләрендә бирелде.

Үзбәк, казакъ, төрекмән, азәрбайҗан телләренең коллектив грамматикаларында кушымчалар белән рәвешләр ясалышы шактый урын алып тора. Алардан башка төрки телләрдә рәвешләр ясалышы, шулай ук, сүзьясалышка багышланган гомуми хезмәтләрдә карала. Мондый хезмәтләрдән А.Г. Голәмев, С. Джафаров, А.И. Искаков монографияләрен күрсәтергә була.

Тюркологиядә рәвешләр ясалышына багышланган махсус хезмәтләр дә бар.

Татар телендә кушымчалар ярдәмендә рәвешләр ясалышы инде басылып чыккан беренче грамматикаларда ук искә алына. Ул турыда

мәгълүматлар И. Гиганов, Ал. Троянский, М. Иванов, Г. Фәйзханов, Ал. Архангельский грамматикаларында бар.

XX гасыр башында басылып чыккан грамматикаларда рәвешләр, аларның ясалышы турында аерым мәгълүмат бирелми. Мәсәлән, Ә. Максуди, Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди һ.б.ның грамматикаларында. Бу аңлашыла да. Югарыда күрсәтелгән авторлар үзләренең хезмәтләрендә билгеле бер дәрәҗәдә гарәп грамматикасы схемасына иярделәр, анда исә гомумән рәвешләр каралмый.

Инкыйлабтан соң дөнья күргән барлык грамматикаларда рәвешләр, аларның ясалышы турында бүлек бирелә. Мәсәлән, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Алпаров грамматикаларында рәвешләр, аларның ясалышы җентекле карала. Соңгы унбиш ел эчендә басылып чыккан грамматикаларда рәвешләр шактый киң бирелә.

### Хәзерге вакытта рәвеш ясый торган типлар

**Нигез + *-ча/-чә*$_2$ кушымчасы.** Кушымчаның этимологиясе турында тюркологиядә каршылыклы фикерләр яшәп килә. Мәсәлән, Н.К. Дмитриев, А.И. Искаков, А.Н. Кононов, *-ча* кушымчасы *чаг* ‘вакыт’ дигән сүзгә барып тоташа, диләр. Л. Җәләй фикеренчә, бу кушымча *чаг* ‘шундый, охшаш’ сүзе белән бәйле. Ике караш та хакыйкатькә туры килә. Эш шунда, рәвеш ясый торган *-ча/-чә* кушымчасы бер түгел, ә омоним булган ике кушымча тәшкил итә. Аның берсе, Л. Җәләй фикеренчә, борынгы *тик – тәк – чак* ‘шундый’ дигән сүзгә барып тоташа (*иске+чэ, яңа+ча*). Икенчесе исә, А.Н. Кононов һәм башкалар раслаганча, этимологик яктан *чак* ‘вакыт, чик’ дигән сүз белән бәйләнгән (*хәзергә+чә, гүргә+чә, озакка+ча*).

*-ча/-чә*$_2$ кушымчасының ясаучы нигезләрен күмәклек исемнәре дә (*грузин+ча, кеше+чә, фән+чә*), ялгызлык исемнәре дә (*кавказ+ча, мәскәү+чә*) тәшкил итә. Бу кушымча, еш кына, күплектәге исемнәргә дә ялгана: *егетләр+чә, хатыннар+ча, балалар+ча.* Бу хәл кушымчаның мәгънәсе белән бәйләнгән. Рәвеш ясаганда барлыкка килгән билге затларның һәм предметларның барысына да карый. Әгәр дә исем берлектә тагын да гомуми мәгънә белдерсә, кушымча шул ук берлектәге исемгә дә ялганырга мөмкин: *кеше+чә, бала+ча.*

Ясаучы нигезләре сыйфат булган сүзләр: *элекке+чә, башка+ча, көзгә + чә, бүтән+чә.*

Ясаучы нигезләре алмашлык булган сүзләр: *безнең+чә, сезнең+чә, синең+чә, минем+чә.*

Ясаучы нигезе фигыль формасы булган сүз: *аеру+ча.*

Кайвакытта ясаучы нигез белән *-ча*$_2$ кушымчасы арасында *-н* интерфиксы барлыкка килә: *кирəсе+н+чә, тулысы+н+ча, тиеше+н+чә.* Бу хәл ясаучы нигез ахырында тартым кушымчасын тәшкил иткән сузык аваз килгәндә була: *гадәт+е+н+чә, үз+е+н+чә.*

Зат алмашлыкларыннан бу кушымча белән рәвешләр ясалганда (*алар* алмашлыгыннан башка), ул алмашлыклар иялек килеш формасын алалар: *теге+нең+чә, сез+нең+чә.*

Чыганак тел ягыннан караганда *-ча*$_2$ кушымчасы татар сүзләренә (*аеру+ча, сукырлар+ча, безнең+чә, кыргыйлар+ча, иске+чә, кеше+чә*), гарәп һәм фарсы телләреннән алынган сүзләргә (*кадим+чә, гашыйклар+ча, шәригатъ+чә, китап+ча*), рус теленнән алынган сүзләргә (*обывательләр+чә, мәскәү+чә, закон+ча, ударниклар+ча, рус+ча*), рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләргә (*буржуаз+ча, материалистлар+ча, патриотлар+ча, натуралистлар+ча*) ялгана.

Рәвешләр ясалышының бу тибы түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез тәгъбир иткән затка яки предметка хас булганны: *балаларча, хәрбиләрчә, егетләрчә, шәһәрчә, авылча, сезнеңчә.*

2. «Ясаучы нигез белдергән телдә» дигән мәгънәне: *чувашча, гарәпчә, фарсыча, удмуртча, немецча.*

3. «Ясаучы нигез таләп иткәнчә» дигән мәгънәне: *шәригатьчә, гадәтчә, фәнчә, заманча.*

4. Ясаучы нигезгә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең тасвирын: *тулысынча, башкача, яңача.*

Кайбер тикшеренүчеләр *-ча* кушымчасы белән ясалган рәвешләргә мисал итеп *меңнәрчә, уннарча* сүзләрен китерәләр. Бу сүзләр рәвеш түгелләр, чама саннарын тәшкил итәләр: *Анда у н н а р ч а чакрымнарга сузылган тубылгы болыннары күренә.* Ш. Камал.

**Нигез + *-ча/-чә*$_3$ кушымчасы.** Бу кушымча югарыда тикшерелгән кушымчага карата омоним булып тора.

Ул – юнәлеш килеш форманты алган рәвешләргә һәм исемнәргә ялгана: *озакка+ча, әлегә+чә, бүгенгә+чә.*

М.З. Зәкиев фикеренчә, бу кушымча килеш кушымчасы булып тора. Бу карашның реаль нигезе бар. Чыннан да, юнәлеш килешендәге

исемнәргә ялганганда, ул – килеш мөнәсәбәтен белдерә: *урманга+ча, мәктәпкә+чә.* Күренгәнчә, биредә килеш мөнәсәбәте икеләтә формант белән тәгъбир ителгән.

Ләкин *-ча/-чә*$_3$ кушымчасы килеш категориясе хас булмаган сүз төркемнәренә кергән сүзләргә ялганганда, аны ничек карарга? Мәсәлән, бу кушымчаның ясаучы нигезләре булып, кагыйдә буларак, рәвешләр килә. Мәгълүм булганча, рәвешләр килеш белән төрләнмиләр. Шуңа күрә килеш белән төрләнми торган сүзләргә кушылган *-ча/-чә*$_3$ кушымчасын рәвеш ясый торган кушымча дип карау табигыйрак һәм дөресрәк булыр: *озакка+ча, хәзергә+чә.*

Чыганак тел ягыннан караганда кушымчаның ясаучы нигезләрен, гадәттә, татар сүзләре тәшкил итә, сирәк кенә гарәп, фарсы сүзләре килергә мөмкин (*хәзергә+чә*).

Рәвешләр ясалышының бу тибы «ясаучы нигез белдергән вакытка кадәр» дигән мәгънәне тәгъбир итә: *бүгенгәчә, хәзергәчә.*

**Нигез + *-лата/-ләтә* кушымчасы.** Бу кушымча исемнәргә (*икмәк+ләтә, акча+лата, иген+ләтә*), сыйфатларга (*чи+ләтә, коры+лата, бөтен+ләтә*), саннарга (*ике+ләтә, өч+ләтә, ун+лата*), фигыльләрнең аерым формаларына (*күрә+ләтә*) ялгана.

Ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Нигез + *-лата/-ләтә* кушымчасы түбәндәге рәвешләрне ясый:

1. Ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә бәйле тасвир рәвешләрен: *акчалата, әйберләтә, игенләтә, тереләтә, чиләтә, күрәләтә.*

2. Ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә бәйле урын рәвешләрен: *кырлата, буйлата.*

3. Ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә бәйле күләм-чама рәвешләрен: *икеләтә, өчләтә, бишләтә.*

**Нигез + *-лап/-ләп* кушымчасы.** Төзелеше ягыннан бу кушымча фигыль ясаучы *-ла* һәм хәл фигыль кушымчасы *-п* дан гыйбарәт, әмма ул бер кушымча булып килә.

*-лап* кушымчасы белән ясалган рәвешләр тышкы формалары ягыннан *-ла* кушымчалы фигыльләрнең хәл фигыль формаларын хәтерләтә. Өстәвенә, тел үсеше процессында мондый хәл фигыль формаларының кайберләре рәвешкә күчкәннәр *вакла+п, акрынла+п.*

*-лап* кушымчасы белән килгән сүзләрнең асылын билгеләү өчен нинди критерийлар бар соң? Алар нинди сүз төркемнәрен тәшкил

итәләр? *-лап* кушымчасы белән ясалган рәвешләрме; фигыльләрнең хәл фигыль формаларымы; рәвешләргә күчкән хәл фигыль формаларымы?

Әгәр *-лап* кушымчалы сүзнең телдә реаль фигыль формасы булмаса, ул, һичшиксез, рәвеш тәшкил итә. Мәсәлән, телдә *чиләкләп* сүзе бар, әмма *чиләкл*ә фигыле татар телендә юк, димәк, *чиләкләп* сүзе рәвеш булып тора.

Әгәр бу форманың рәвеш мәгънәсе булса, ул, әлбәттә, хәл фигыль формасының рәвешкә күчүе нәтиҗәсе. Мәсәлән, *ваклап* сүзе рәвеш мәгънәсен белдерә, телдә *ваkларга* фигыле булганлыктан, бу сүз *-лап* кушымчасы белән ясалган рәвеш түгел, ә шул форманың рәвешкә күчүен күрсәтә.

*-лап* кушымчасының ясаучы нигезләре булып исемнәр (*мыскал+лап, данә+ләп, чирек+ләп, метр+лап, килограмм+лап*), сыйфатлар һәм рәвешләр (*бергә+ләп, татарча+лап, җыйнау+лап*), җыю саннары (*өчәү+ләп, дүртәү+ләп, җидәү+ләп*) килергә мөмкин.

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләрен татар сүзләре (*алмаш+ лап, икәү+ләп, күнлек+ләп*), рус теленнән алынган сүзләр (*смена+лап*), рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләр (*грамм+лап, минут*+лап) тәшкил *итә.*

*Нигез+-лап/-ләп кушымчасы* түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән күләмдә яки күләм белән» дигән мәгънәне: *граммлап, метрлап, чиләкләп, чиреkләп.*

2. «Ясаучы нигез тәгъбир иткән вакыт эчендә яки арасында» дигән мәгънәне: *атналап, айлап, сәгатьләп.*

3. Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең тасвирын: *вәземләп, тәмләп, чүпләмләп, гозерләп.*

4. Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең көчле тасвирын: *бергәләп, татарчалап, җыйнаулап, ныклап.*

5. Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең сан ягыннан билгесен: *икәүләп, бишәүләп, унлап.*

**Нигез + *-латып/-ләтеп* кушымчасы.** Бу кушымча бары берничә сүздә генә очрый. Нигездә ул рәвешләргә ялганып килә: *русча+латып, кыргызча+латып.*

Мондый рәвешләр нигез белдергән мәгьнәне тагын да көчлерәк итеп тәгъбир итәләр: *татарчалатып, казакъчалатып.*

*-латып/-ләтеп* кушымчасы *кечләтеп, кыеклатып* кебек рәвешләрдә очрый. Әмма, телдә *кечләтү, кыеклату* кебек фигыльләр булганлыктан, аларны хәл фигыльләрнең рәвешкә күчүе дип карарга туры килә.

## Хәзерге көндә күп санда рәвешләр ясамый торган типлар

**Нигез + *-лай/-ләй*$_3$ кушымчасы.** Бу кушымча исемнәргә (*урта+лай*), алмашлыкларга (*шушы+лай*), саннарга (*икенче+ләй*), сыйфатларга (*тере+ләй, коры+лай*) ялгана.

Ясаучы нигезләре булып тик татар сүзләре генә килә. Рәвешләр ясалышының бу тибы түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигезләрнең мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең тасвирын: *урталай, ягалай* (диал.), *тереләй, бушлай, тегеләй, шушылай, бөтенләй.*

2. Ясаучы нигезләрнең мәгънәсенә ярашлы рәвештә берәр нәрсәне санаудагы чиратлылыкны: *беренчеләй, икенчеләй, өченчеләй.*

**Нигез + *-лый/-ли* кушымчасы.**

Бу кушымча исемнәргә (*күз+ли, түгәрәк+ли, узыш+лый*), сыйфатларга (*тоташ+лый*), фигыльләрнең аерым формаларына (*үтә+ли*) ялгана.

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Рәвешләр ясалышының бу тибы түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең вакытын: *язлый, көзли, яшьли, китешли.*

2. Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең урынын: *түгәрәкли, тирәли, буйлый, әйләнәли.*

3. «Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең тасвирын»: *тоташлый, яшелли.*

4. Ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә эш-хәрәкәтнең максатын: *юрамалый.*

**Нигез + *-тын/-тен* кушымчасы.** Бу кушымча сыйфатлар ясауда да катнаша: *яшертен эш. -тын* кушымчалы кайбер рәвешләрнең ясаучы нигезләре телдә аерым кулланылмый: *акыртын, уртын* (диал.).

Ясаучы нигезләре булып, кагыйдә буларак, татар сүзләре килә, сирәк кенә алынмалар да ясаучы нигез булырга мөмкин: *әүвәл+тен.* Рәвешләр ясалышының бу тибы ясаучы нигез мәгънәсеннән көчлерәк мәгънәне белдерә: *әүвәлтен, түбәнтен, югартын, тирәнтен.*

Кайвакыт бу кушымча бәйлек тә ясарга мөмкин: *тиңентен.*

**Нигез + -*ла*/-*лә*$_3$ кушымчасы.** Бу кушымча үзенең чыгышы ягыннан *илә* бәйлегенә барып тоташа булса кирәк. Рәвеш ясаучы бу кушымча азәрбайҗан телендә киң таралган. Кушымча исемгә ялгана (*төн+лә*), ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә вакыт рәвешен ясый.

**Нигез + *-ма/-мә*$_3$ кушымчасы.**

Басымсыз *-ма*/*-мә*$_3$ кушымчасы бары берничә генә рәвеш ясый. Ул фигыльләргә (*мөлдерә+мә*) һәм рәвешләргә (*лыч+ма*) ялгана. Аның ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә. Ул түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Фигыльләргә ялганып, ул ясаучы нигезләрнең мәгънәсенә ярашлы рәвештә, эш-хәрәкәтнең тасвир мәгънәсен: *мөлдерәмә, түбәләмә.*

2. Тасвир рәвешләренә ялганып, аларга караганда көчлерәк мәгънәне: *лычма, лыкма.*

**Нигез + *-ым*$_1$ кушымчасы.** Сыйфатка ялганып тасвир рәвешен ясый: *тулай+ым* (орфографиядә *тулаем*).

**Нигез + *-лаш/-ләш*$_2$ кушымчасы.** Бу кушымча исемнәргә (*ярты+лаш, чат+лаш*), сыйфатларга (*каршы+лаш*), рәвешләргә (*кыйа+лаш=кыялаш*) ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Кушымча исемнәргә ялганып, ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә ярашлы рәвештә, күләм рәвешләре ясый: *ярты+лаш.*

Исемнәргә һәм сыйфатларга ялганып, ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә ярашлы рәвештә, урын рәвешләре ясый: *чатлаш, башлаш, каршылаш.* Мондый рәвешләрнең кайберләре бәйлеккә күчәргә мөмкин: *безгә каршылаш.*

**Нигез + *-гынак/-генәк* кушымчасы.** Бу кушымча рәвешләргә ялганып, аларның мәгънәсен тагын да көчәйтә төшә: *кичә+генәк, бая+гынак.*

**Нигез + *-чан/-чән*$_3$ кушымчасы.** Бу кушымча юнәлеш килеш форманты *-тан*/*-тән* гә кайтып кала. Ул – *т* авазының *ч* авазына күчүеннән барлыкка килгән, исемнәргә ялгана: *күлмәк+чән, итек+чән.*

Өс киемен яки аяк киемен белдерә торган исемнәргә ялганып, ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә ярашлы рәвештә, тасвир рәвешләрен ясый: *оекчан.*

**Нигез + *-чы/-че$_4$* кушымчасы.** Бу кушымча генетик яктан *-ча/-чә$_4$* кушымчасы белән бәйләнгән булса кирәк, чөнки аларның мәгънәләре тулысынча туры килә. Кушымча алмашлыкларның кайбер формаларына ялганып, вакыт рәвешләрен ясый: *шуңар+чы, моңар+чы, аңар+чы.*

**Нигез + *-ала* кушымчасы.** Бу кушымча этимологик яктан *илә* бәйлеге белән бәйләнгән.

Исемгә ялганып, дәрәҗә рәвешен ясый: *баш+ала* (диал.).

**Нигез + *-ата* кушымчасы.** Сыйфатка ялганып, ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә, дәрәҗә рәвешен ясый: *аерата.* Ясаучы нигезнең ахыргы сузык авазы (*аер+ы*) элизиягә дучар була.

**Нигез + *-бәгәй* кушымчасы.** Бу кушымча *җилбәгәй* рәвешендә очрый, биредә *җил* сүзе *җилфердәү* мәгънәсендәге борынгы фигыль булып тора.

**Нигез + *-дез* кушымчасы.** Кушымча исемгә ялганып, ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә, вакыт рәвешен ясый: *көндез.*

**Нигез + *-а/-ә$_4$* кушымчасы.** Кушымча бары берничә рәвештә генә очрый: *иртә, яңа, кичә.* Ул бары бер сүздә генә мәгънәле структур кисәкләргә аерыла: *кич+ә.*

Исемгә ялганып, ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә вакыт рәвешен ясый: *кичә.*

**Нигез + *-әшә* кушымчасы.** Кушымча бары бер урын рәвешендә генә очрый: *янәшә.* Бу рәвеш *янаша* сүзенең йомшаруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән булса кирәк.

**Нигез + *-әк$_5$* кушымчасы.** Бу кушымча *кинәт* мәгънәсендәге *кисәк* рәвешендә очрый. Аның ясаучы нигезе бүгенге көндә мөстәкыйль кулланылмый, борынгы телдә ул *тиз* дигән мәгънәне белдергән.

**Нигез + *-ыл/-ел, -л$_3$* кушымчасы.** *-ыл/-ел* кушымчасы тартыкка, *-л* кушымчасы сузыкка тәмамланган нигезләргә ялгана. Аның ясаучы нигезләре булып фигыльләр: *төгә+л* (*тәгә* – тәмамлану мәгънәсендәге борынгы фигыль), рәвешләр: *кап+ыл* (*кап* – нәкъ дигән мәгънәдә) килә.

## Рәвеш ясаучы килеш кушымчалары

Хәзерге татар телендә үзенең составында килеш кушымчалары булган ике тип рәвешләр бар. Беренче тибы – составында хәзерге вакытта кулланылмый торган үле килеш кушымчалары булган рәвешләр. Аларның өч төре бар: 1) борынгы корал килеш кушымчасы белән килгән рәвешләр: *кич+ен, кыш+ын;* 2) борынгы урын-вакыт килеш кушымчасы белән килгән рәвешләр: *соң+ра;* 3) борынгы юнәлеш килеш кушымчасы белән килгән рәвешләр: *тыш+кары, эч+кәре.*

Икенче тибы – составында бүгенге көндә кулланыла торган килеш кушымчалары булган рәвешләр. Бу тип рәвешләрнең шулай ук өч төре бар: 1) юнәлеш килеше кушымчасы алган рәвешләр: *озак+ка, буш+ка, көч+кә;* 2) чыгыш килеш кушымчасы алган рәвешләр: *тоташ+тан, арт+тан, ян+нан;* 3) урын-вакыт килеше кушымчасы алган рәвешләр: *ерак+та, кайчак+та.*

Югарыда китерелгән рәвешләрне сүзьясалыш күзлегеннән ничек карарга дигән сорау туа: адвербиализация (рәвешләшү) ысулы белән барлыкка килгән рәвешләрме яки кушымчалар ярдәмендә тиешле ясаучы нигезләрдән ясалган рәвешләрме?

Тюркологиядә бу проблеманың бер төрле генә чишелгәне юк. Мәсәлән, Н.К. Дмитриев, А.Н. Кононов, А.И. Искаков, А. Җамалетдинов, В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева әйтеп үтелгән рәвешләрне лексик-грамматик ысул белән ясалган рәвешләр дип карыйлар. Бу карашка нигезләп, Н.К. Дмитирев болай дип яза: «Башкорт телендә, барлык телләрдәге кебек, рәвешләр төркеме берәр сүз төркеменең тулы төрләнеш схемасыннан аерылып калган, катып калган яки үлегә әйләнгән формалар исәбенә дә арта. Бу вакытта шундый процесс күзәтелә. Берәр исемнең килешләр белән тулы төрләнеш схемасы була, һәм аларның һәрберсе бу исемнең төрләнеш формасы буларак кулланыла. Махсус (гадәттә семантик-синтаксик) сәбәпләр аркасында килешләрнең берсе төп сүз белән бары бик ерак бәйләнгән, аерым мәгънә ала, тулы схемадан аерыла, аңардан бүленеп чыга. Нәтиҗәсе төп исем белән этимологик яктан гына бәйләнгән яңа сүз барлыкка килә» [Дмитриев Н.К., 1948, 117].

Тюркологиядә югарыда китерелгән рәвешләрнең кушымчалар ялганып ясалуы хакында да караш бар.

Килеш кушымчалы рәвешләр телдә лексика, грамматика һәм сүзьясалыш белән диахроник планда укмашкан катлаулы күренеш тәшкил итә. Мондый рәвешләрнең бер өлешенең ясаучы нигезләре булып төрләнми торган сүз төркемнәре сүзләре (сыйфатлар һәм рәвешләр) торалар: *бире+гә, мәңге+гә.*

Әгәр килеш кушымчалы рәвешләрнең ясаучы нигезләре булып төрләнә торган сүз төркемнәре сүзләре килсә, ул вакытта аларны тиешле сүз төркемнәре формаларыннан рәвешкә күчкән дип карау табигыйрәк һәм дөресрәк булыр. Бу очракта лексик-грамматик сүзьясалыш (конверсия) күзәтелә, һәм алар бу ысулны тикшергәндә каралырга тиешләр.

Әгәр дә килеш кушымчалы рәвешләрнең ясаучы нигезләре төрләнми торган сүз төркемнәренең сүзләре булса, ул вакытта бу рәвешләрне, ясаучы нигезләрнең төрләнүеннән килеп чыккан, дип карап булмый, чөнки алар гомумән төрләнмиләр. Биредә аларны кушымчалар ярдәмендә ясалган, ә кушымчаларның үзләрен сүзьясагыч кушымчалар дип карау логикага ныграк туры килә.

Пространство килешләре (*-га* – юнәлеш килеше, *-да* – урын-вакыт килеше, *-дан* – чыгыш килеше) кушымчалары гына төрләнми торган сүз төркемнәре сүзләреннән рәвешләр ясый. Кушымчалар төрләнеш парадигмасына ярашлы рәвештә ялганалар.

Төрләнми торган сүз төркемнәреннән рәвешләр ясый торган һәм тулы төрләнеш парадигмасындагы пространство килешләре кушымчаларын бер үк чыганактан килгәнгә, омоним кушымчалар дип санап булмый.

**Нигез + *-га/-гә,* (*-ка/-кә*)кушымчасы.** Рәвешләр ясый торган кушымча буларак, бу кушымча сыйфатларга (*буш+ка, аркылы+га, каршы+га, коры+га, сул+га*), рәвешләргә (*бүген+гә, бире+гә*), хәбәрлек сүзләргә (*юк+ка*) ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

1. Бу кушымча сыйфатларга, хәбәрлек сүзләргә, саннарга ялганып, урын рәвешләрен (*сулга, уңга*), вакыт рәвешләрен (мәңгегә), тасвир рәвешләрен (*корыга, бергә*), сәбәп һәм максат рәвешләрен (*юкка, тикмәгә*) ясый.

2. Рәвешләргә ялганып, ул вакыт һәм урын чикләрен белдергән рәвешләр ясый: *бүгенгә, озакка* (вакыт рәвешләре), *бирегә, арыга* (урын рәвешләре).

**Нигез + *-дан/-дән,* (*-тан/-тән*) кушымчасы.** Кушымча сыйфатларга (*каршы+дан, ирексез+дән, ерак+тан*), рәвешләргә (*соң+ы+н+нан, күптән+нән, кайта+дан, яңа+дан*), алмашлык формаларына (*шушы+н+нан, теге+н+нән*), хәбәрлек сүзләргә (*юк+тан*), саннарга (*бер+дән, беренче+дән, икенче+дән*) ялгана. Борын авазларына тәмамланган нигезләрдән соң бу кушымчаның *-нан/-нән* фонетик варианты килә (*якын+нан*).

Мисаллардан күренгәнчә, кайвакыт кушымча белән ясаучы нигез арасында тартым кушымчасы һәм интерфикс күзәтелергә мөмкин: *соң+ы+н+нан, теге+н+нән.*

Ясаучы нигезләре булып гадәттә татар сүзләре килә.

1. Бу кушымча сыйфатларга, хәбәрлек сүзләргә, саннарга ялганып урын рәвешләре (*уңнан, тегеннән, сулдан, каршыдан, ерактан*), вакыт рәвешләре (*борыннан*), сәбәп һәм максат рәвешләре (*аңсыздан, юктан*), күләм рәвешләре (*уртактан*) ясый.

2. Вакыт рәвешләренә ялганып, ул рәвешләрнең мәгънәсен көчәйтеп – яңа вакыт рәвешләре (*күптәннән, электән*), тасвир рәвешләренә ялганып, ул рәвешләрнең мәгънәсен көчәйтеп яңа тасвир рәвешләрен ясый: *кисәктән, кайтадан.*

3. Тәртип саннарына ялганып, ясаучы нигезләргә ярашлы рәвештә санаудагы чиратлылыкны белдергән рәвешләр ясый: *беренчедән, бишенчедән.*

**Нигез + *-да/-дә,* (*-та/-тә*) кушымчасы.** Кушымчаның ясаучы нигезләре булып сыйфатлар (*ерак+та, якын+да, уң+да*), рәвешләр (*бире+дә, соң+ы+н+да*), алмашлыклар (*теге+н+дә, шушы+н+да, кайчак+та*) килә. Кайчак кайбер рәвешләр ясалганда ясаучы нигез белән кушымча арасында интерфикс барлыкка килергә мөмкин: *теге+н+дә, шушы+н+да, соңы+н+да.*

Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

1. Бу кушымча сыйфатларга, алмашлыкларга ялганып, ясаучы нигезләрнең мәгънәләренә ярашлы рәвештә, урын рәвешләре (*ерακта, каршыда, шушында, тегендә*) һәм вакыт рәвешләре (*электә, көзлектә*) ясый.

2. Рәвешләргә ялганып, ул яңа урын һәм вакыт рәвешләре ясый: *биредә, соңында.*

**Нигез + *-ын/-ен$_4$* кушымчасы.** Үле *-ын/-ен* килеш кушымчасы хәзерге татар телендә бары берничә рәвештә генә күзәтелә. Кушымча рәвешләргә һәм ияртемнәргә ялгана: *көндез+ен, лып+ын, төннәр+ен.*

1. Кушымча рәвешләргә ялганып, шул ук мәгънәдәге яңа рәвешләр ясый, әмма аларның мәгънәсе беркадәр көчәя төшә: *көндезен, тиген.*

2. Ияртемгә ялганып, ул ясаучы нигез мәгънәсенә ярашлы рәвештә тасвир рәвешен ясый: *лыпын.*

Бу кушымча тагын мәгънәле кисәкләргә аерылмый торган *акрын* сүзендә күзәтелә.

### 9.8.3. Кушма рәвешләр ясалышы

Кушма рәвешләр, башка сүз төркемнәренең кушма сүзләре кебек үк, өч төрле ысул белән: 1) сүзләр кушылу, 2) сүзтезмәнең лексикалашуы, 3) сүзтезмәнең, кушымча ялганып, кушма сүзгә күчүе юлы белән ясалалар.

Кушма рәвешләр ясалганда компонентлар тезүле бәйләнеш белән дә, иртүле бәйләнеш белән кушылырга мөмкин.

#### Тезүле бәйләнештәге компонентлар кушылып куш рәвешләр ясалышы

Хәзерге татар телендә куш рәвешләр ясалышының типлары бик күп, аерым типларның модельләре дә бар.

**Исем + исем тибы.** Тамыр кушымчалы һәм исемнәрнең аерым формалары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып рәвеш мәгънәсендәге куш рәвешләр ясыйлар.

Исем$_1$ + исем$_2$ моделе: *ара-тирә, җан-фәрман, көн-төн, яз-көз, иртә-кич.* Бу модельдә тезүле бәйләнеш белән төп формадагы ике исем кушылып, рәвеш семантикасына ия булалар, шул юл белән куш рәвешләр хасил итәләр. Дөрес, телдә мондый рәвешләр күп түгел.

Исем$_1$ + исем$_1$ моделе: *уйдык-уйдык, рәт-рәт, вакыт-вакыт, утрау-утрау, бөрчек-бөрчек, бөртек-бөртек, йомгак-йомгак*. Бер үк исемнең тезүле бәйләнеш нигезендә кушылуы күплек мәгънәсендәге рәвешләр ясый.

Исем$_1$ *-ы* + исем$_2$ *-ы* моделе: *көне-төне, әүвәле-ахыры.*

Исем$_1$ *-лы* + исем$_2$ *-лы* моделе: *язлы-көзле, иртәле-кичле, уенлы-чынлы, ачлы-туклы, йокылы-уяулы, аллы-артлы, этле-мәчеле*. Биредәге куш рәвешләрнең компонентлары аерым яшәмиләр: *ачлы яши, иртәле булуы, аллы бару* дип сөйләмиләр.

Телдә тагын мондый рәвешләр дә бар: *уңлы-суллы, арлы-бирле. Арлы, бирле* компонентларының нигезләре гипотетик *ар* һәм *бир* сүзләре булса кирәк.

Исем$_1$ *-сыз* + исем$_2$ *-сыз* моделе: *эзсез-хәбәрсез, кулсыз-аяксыз.*

Исем$_1$ *-ма* + төп формадагы исем$_2$ моделе: *башма-баш, сүзмә-сүз, эзмә-эз.* Биредә *-ма* элементы комбинациянең структурасы һәм мәгънәсе буенча борынгы килеш кушымчасын хәтерләтә.

**Фигыль$_1$ + фигыль$_2$ тибы.** Бу ясалыштагы рәвешләрнең берничә төре бар. Бу – редупликация – куш рәвешне тәшкил итәме яисә тиешле нигездән ясалган кушма фигыль формасы булып торамы? Кайвакыт моны билгеләве кыенлык тудыра.

*-п* кушымчалы хәл фигыль$_1$ + *-п* кушымчалы хәл фигыль$_2$ моделе: *атылып-бәрелеп, уйнап-көлеп, тирләп-пешеп, елап-сыктап, качып-посып, борычлап-тозлап.* Бу модельдәге куш рәвешләр фигыльләрнең кушма формасы дип карала алмыйлар, чөнки телдә *уйнау-көлү, борычлау-тозлау, кыру-себерү кебек* куш фигыльләр юк. Кагыйдә буларак, алар затланышлы формаларда кулланылмыйлар. *Борычлады-тозлады, кырды-себерде* дигән куш фигыльләр телдә юк. Затланышлы формаларда алар икесе дә мөстәкыйль фигыльгә әйләнә.

- *а* кушымчалы хәл фигыль$_1$ + *-а* кушымчалы хәл фигыль$_2$ моделе: *бара-тора, абына-сөртенә, ава-түнә, элә-сала, йөгерә-атлый.* Бу комбинацияләр, шулай ук, тиешле куш фигыльләрнең хәл фигыль формалары булып тормыйлар, чөнки мисал итеп китерелгән куш рәвешләрнең төп куш фигыль формалары юк: *бару-тору – барды-торды, абыну-сөртенү – абынды-сөртенде, аву-түнү – ауды-түнде, элү-салу , – элде-салды, йөгерү-атлау – йөгерде-атлады.*

Үткән категорик заман фигыль формасы$_1$ + үткән категорик заман фигыль$_2$ формасы: *ордым-бәрдем. Мисал: Завод кечкенә түгел. Ордым-бәрдем генә салып булмый.* Г. Ахунов.

*-а* кушымчалы хәл фигыль$_1$нең юклык формасы + *-а* кушымчалы хәл фигыл$_2$нең юклык формасы: *тукми-чәчми*. Бу комбинацияне шулай ук тиешле куш фигыльнең хәл фигыль формасы

дип карап булмый, чөнки аның телдә затланышлы куш фигыль формасы юк.

-*а* кушымчалы хәл фигыль + шул ук тамырдан булган сыйфат: *кара-каршы*.

Телдә тагын сыйфат фигыльләрнең барлыкта һәм юклыкта кабатланган (асиндетик) формалары бар: *туяр-туймас, килер-килмәс, сөйләр-сөйләмәс*.

Бу куш формалар структурасы ягыннан куш рәвешләрне хәтерләтсәләр дә, алар куш рәвеш түгелләр. Мондый формалар татар телендә һәр фигыльдән ясала, алар тиешле фигыльдән даими рәвештә ясалган хәл фигыль формалары булып торалар.

**Сыйфат$_1$ + сыйфат$_2$ тибы.** Бу типның түбәндәге модельләре бар.

-*лы* кушымчалы сыйфат$_1$ + -*сыз* кушымчалы сыйфат$_2$ моделе. Кушымчалар белән ясалган антоним сыйфатларның кушылуы куш рәвешләр ясый: *вакытлы-вакытсыз, урынлы-урынсыз, irekле-ireксез, ихтыярлы-ихтыярсыз, җирле-җирсез*. Антоним сыйфатларның кушылуы икенче компонент белдергән инкарь итүне йомшарта.

-*лык* кушымчалы сыйфат$_1$ + -*лык* кушымчалы сыйфат$_2$ моделе. Бу структурадагы куш рәвешләр телдә күп түгел: *ипилек-тозлык, икмәклек-тозлык*.

-*лы* кушымчалы сыйфат$_1$ + аның -*м* авазы алган варианты: *икеле-микеле (икеле 'шикле'), кыеклы-мыеклы*. Бу модельгә *кирле-морлы* куш рәвеше дә карый булса кирәк.

-*ма* кушымчалы сыйфат$_1$ + сыйфат$_2$ моделе: *тиңмә-тиң*.

**Рәвеш + рәвеш тибы.** Бу типның берничә төре бар.

Рәвеш$_1$ + рәвеш$_2$ моделе. Бу модельдәге куш рәвешләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: тасвирны (*алай-болай, яшерен-батырын*), вакытны (*язын-көзен, җәен-кышын*), урынны (*тегендә-монда, анда-монда, аннан-моннан*), юнәлешне (*ары-бире*).

Рәвеш$_1$ + рәвеш$_1$ моделе: *бергә-бергә, өстән-өстән, көчкә-көчкә, борын-борын, еш-еш, бәйнә-бәйнә*. Мисаллардан күренгәнчә, рәвешләрне редупликацияләү аларның мәгънәләрен көчәйтүгә китерә.

Рәвеш$_1$ + -*дан* кушымчалы рәвеш$_1$ моделе: *элек-электән, әүвәл-әүвәлдән*. Бу төр куш рәвешләр телдә бик аз. Биредә рәвешләрне кушу шулай ук аларның мәгънәләрен көчәйтә.

*-дан* кушымчалы рәвеш$_1$ + рәвеш$_1$ моделе: *ашадан-аша, үтәдән-үтә*. Биредә шулай ук мәгънәнең нык көчәюе сизелә.

Рәвеш$_1$ + аңа якын яңгыраш моделе: *аз-маз, аркылы-торкылы, алмаш-тилмәш, юрый-мырый, сирәк-мирәк, берәм-сәрәм*.

Этимологиясе (структурасы) төгәл анык булмаган сүз$_1$ + этимологиясе (структурасы) төгәл анык булмаган сүз$_2$: *элке-салкы, алпы-салпы, алпан-тилпән* (биредә *тилпән* тилпенү сүзеннән, ә борынгы төрки телдә *алп* ‘авыр’ дигән мәгънәне белдергән). Күренгәнчә, югарыда китерелгән куш рәвешләрнең компонентлары хәзерге телдә очрамый, әмма тел үсеше тарихында алар, һичшиксез, тиешле мәгънәле мөстәкыйль сүзләр булганнар.

Этимологиясе (структурасы) төгәл анык булмаган сүз$_1$ + аның якынча яңгырашы: *өге-җөге* (борынгы төрки телдә *өгер* сүзе ‘шатлану’ мәгънәсен белдергән), *такы-токы* (*такыр* сыйфаты белән чагыштыр), *әпен-төпен* (*әп* сүзе диалектта ‘тиз’ дигән мәгънәне белдерә).

***-га* (*-ка*) кушымчалы хәбәрлек сүз$_1$ + *-га* (*-ка*) кушымчалы хәбәрлек сүз$_2$:** *юкка-барга.* Хәбәрлек сүзләрнең формаларының кушылуы рәвеш хасил иткән.

### Хәл сүзтезмәләренең лексикалашуы юлы белән кушма рәвешләр ясалышы

Аерым очракларда хәл сүзтезмәләре кушма рәвешләргә күчәргә мөмкин. Бу күчешнең татар телендә түбәндәге типлары бар:

**Исем + рәвеш тибы.** *Йөзтүбән, башаркан, баштүбән* рәвешләре *исем+рәвеш* сүзтезмәсеннән барлыкка килгәннәр. Биредә төп сүзнең – рәвешнең мәгънәсе беренче компонент – исем белән конкретлаштырыла.

**Исем + бәйлек тибы.** Аның түбәндәге модельләре бар.

Исем + *белән* бәйлеге моделе. Кайбер очракларда *белән* бәйлеге белән килгән исем лексикалашырга, кушма рәвешкә әйләнергә мөмкин: *көтүе белән, башы белән, яны белән, көч-хәл белән, көч-дәрт белән.* Мондый кушма рәвешләрнең семантикасы еш кына үзгәрә, алар тасвир рәвешләрен тәшкил итәләр.

Исем + *тыш* бәйлек сүзе моделе. Бу модель белән *чиктән тыш, чамадан тыш, көчтән тыш* кебек кушма рәвешләр ясала. Алар тасвир рәвешләре төркеменә керәләр.

**Сыйфат + *килеш, рәвештә, төстә, көе* кебек бәйлекләр (бәйлек сүзләр).** Бу төр сүзтезмәләр бик еш кушма рәвешләргә күчәләр: *тере килеш, ач килеш, тук килеш, ашыгыч рәвештә, ашыгыч төстә, ярашлы рәвештә, ирексез рәвештә, буш көе, тәртипле рәвештә* һ.б.ш. Хәзерге татар телендә бу комбинацияләр композит үзенчәлеген алганнар һәм кушма рәвешләр буларак киләләр.

**Сыйфат + *итеп* хәл фигыле тибы.** Татар телендә кайбер очракта сыйфат+*итеп* хәл фигыль сүзтезмәләренең кушма рәвешкә күчүе күзәтелә: *тигез итеп, матур итеп, шәп итеп, кытыршы итеп.* Хәзерге вакытта бу комбинацияләр бердәм мәгънәле кушма рәвешләр буларак кабул ителәләр һәм аларда хәл фигыль деривация элементы буларак килә: *шулай итеп, алай итеп, болай итеп, тегеләй итеп.*

Бу комбинацияләрне тиешле кушма фигыльләрнең хәл фигыль формалары дип карау дөрес түгел, чөнки алар семантик яктан тәңгәл түгелләр, бөтенләй яңа сүз булып торалар.

**Аваз ияртеме + *итеп* хәл фигыле тибы.** Бу төр сүзтезмәләр шулай ук кайбер вакыт рәвеш семантикасы алып лексикалашалар: *чалдыр итеп, шарт итеп, лап итеп.*

**Хәл фигыль + рәвеш тибы.** Бу тип сүзтезмәләр шулай ук кайчак бердәм мәгънә алып кушма рәвешкә күчәргә мөмкин: *узып барышлый, үтеп барышлый, үтеп китешли.*

### Сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма рәвешкә күчүе

Кайбер атрибутив сүзтезмәләр, кушымча алып, кушма рәвешкә әйләнергә мөмкиннәр:

**Сүзтезмә + *-лап* кушымчасы:** һәрьяклап, бишкуллап, икекуллап, дүрткуллап.

**Сүзтезмә + *-сыз* кушымчасы: *берсүзсез.***

## 9.8.4. Конверсия ысулы белән рәвешләр ясалышы (адвербиализация)

Күренгәнчә, татар телендә рәвешләр кушымчалау ысулы һәм лексикалашу юлы белән ясалалар. Бу ысуллар белән беррәттән, татар телендә рәвешләр конверсия ысулы, яки бер сүзнең бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү юлы белән ясалалар. Сүзләр үзләренең төп формаларыннан тыш, кыек формаларында да конверсияләнергә

мөмкин. Рәвешләргә исемнәр, сыйфатлар, фигыль формалары һәм саннар күчәргә мөмкин. Рәвешләшү турыдан-туры булмыйча, берничә баскычлы да булырга мөмкин.

### Исемнәрнең рәвешләргә күчүе

Күп кенә исемнәр һәм аларның аерым формалары үзләренең тарихи үсеш процессында рәвешләргә күчкәннәр.

I. Вакыт белдерә торган исемнәр вакыт рәвешенә күчәләр.

1 нче модель: вакыт белдерә торган исемнең төп формасы →вакыт рәвеше:

*кич* → *кич (кич бару)*
*кыш* → *кыш (кыш кайту)*
*иртә* → *иртә (иртә килү)*
*җәй* → *җәй (җәй китү)*
*соң* → *соң (соң кайту)*
*яз* → *яз (яз кайту)*
*көз* → *көз (көз китү)*

*Кыш, җәй* кебек рәвешләрдә бәлки *-ын* (*-ен*) кушымчасы төшкән булса кирәк, алар эллипсис кичергәннәр.

Мисаллар: *Үткән ел җ ә й без төрлебез төрле җирдә эшләп йөргән идек.* М. Гафури. *Быел к ы ш та Габделбасыйр үзенең мәгъшукасының йөзен бер генә мәртәбә булса да күрә алмады.* Ф. Әмирхан.

2 нче модель: вакыт белдерә торган исемнең кыек килеш формасы → вакыт рәвеше:

*кичтән* → *кичтән (кичтән сөйләшеп кую)*
*ахырдан* → *ахырдан (ахырдан искә төшү)*
*баштан* → *баштан (баштан ук исәпләү)*
*башта* → *башта (башта риза булу)*
*ахырда* → *ахырда (ахырда нәтиҗәгә килү)*
*кичкә* → *кичкә (кичкә томан җәелде)*

Мисаллар: *Мәрьям т у м ы ш т а н ук артык шау-шуны, көтү-көтү балалар белән... уйнап йөрүне яратмый.* Г. Ибраһимов. *Ләкин вакыт чамадан тыш тар булганга аларны и р т ә д ә н к и ч к ә,*

*кичтән таңга кадәр йөгерттеләр*. Г. Әпсәләмов. *Ахырда аның бу дөрес уе җиңде*. А. Шамов.

II. Пространство мәгънәсен белдерә торган исемнәр урын рәвешләренә күчәләр:

*алда* → *алда (алда күренү)*
*алдан* → *алдан (алдан бару)*
*алга* → *алга (алга чыгу)*
*өскә* → *өскә (өскә күтәрелү)*
*өстән* → *өстән (өстән төшү)*
*өстә* → *өстә (өстә эшләү)*
*яннан* → *яннан (яннан карап тору)*
*читтән* → *читтән (читтән карап тору)*
*кырыйдан* → *кырыйдан (кырыйдан күренү)*

Мисаллар: *Артта да күзләр, алда да күзләр*. Д. Аппакова. *Алга омтылып барган атлар*. М. Гафури. *Бу абзацны күчер өскә. Б. Рәхмәт. Кичке кояш шәүләсе ашыга-ашыга өскә үрмәли*. Г. Бәширов.

**Сыйфатларның рәвешләргә күчүе**

Сыйфатларның рәвешләшүе рәвешләр ясалышының продуктив ысулы булып тора Татар телендә бары рәвешләргә генә күчә торган сыйфатлар бар. Шуның белән бергә һәм рәвешләргә, һәм исемнәргә күчә ала торган сыйфатлар да бар.

Рәвешләргә дә, исемнәргә дә күчә торган сыйфатлар:

*якты* → *якты (көн яктысы)*
*якты* → *якты (якты яна)*

*салкын* → *салкын (гыйнвар салкыннары)*
*салкын* → *салкын (салкын карау)*

*җылы* → *җылы (мич җылысы)*
*җылы* → *җылы (җылы сөйләшә)*

*эссе* → *эссе (июль эссесе)*
*эссе* → *эссе (мунчаны бик эссе ягу)*

*караңгы* → *караңгы (караңгы төште)*
*караңгы* → *караңгы (караңгы булды)*

*бай* → *бай (байга хезмәт итү)*
*бай* → *бай (бай яшәү)*

*туры* → *туры (бер турыны икенче туры белән кистерү, мат.)*
*туры* → *туры (туры карау)*

Мисаллар: *Якты я н а маякларда моряк кабызган утлар*. Г. Хуҗи. *Вәлиулланың кулына налог кәгазен сузып, с а л к ы н гына елмайды*. А. Шамов.

Бары рәвешләргә генә күчә торган сыйфатлар:

*дөрес* → *дөрес (дөрес сөйләү)*
*азат* → *азат (азат яшәү)*
*акрын* → *акрын (акрын сөйләшү)*
*анык* → *анык (анык әйтү)*
*алама* → *алама (алама киенгән)*
*озын* → *озын (озын язу)*
*начар* → *начар (начар сөйләү)*
*кире* → *кире (кире кайту)*
*яхшы* → *яхшы (яхшы яшәү)*
*таза* → *таза (таза эшләнгән)*
*тирән* → *тирән (тирән сулау)*
*авыр* → *авыр (эш авыр бара)*
*җиңел* → *җиңел (җиңел киенү)*
*ерак* → *ерак (ерак тору)*

Бу рәвешләрнең күбесен тасвир (*яхшы, җиңел*), кайберләрен урын рәвешләре (*ерак*) тәшкил итә.

Мисаллар: *[Хат] шактый т у л ы язылган.* Ш. Камал. *Аңа Тукай поэмасының эчтәлеген дөрес һәм т и р ә н аңлап, либреттосын... төзәтү кирәк булачак.* М. Җәлил.

Рәвешләргә тамыр сыйфатлар гына түгел, кушымчалы сыйфатлар да күчәргә мөмкин:

*йомшак* → *йомшак (йомшак сөйләшү)*
*вакытлы* → *вакытсыз (вакытсыз килү)*
*ваемсыз* → *ваемсыз (ваемсыз яшәү)*
*кыска* → *кыска (кыска гына сөйләшү)*
*кискен* → *кискен (кискен әйтү)*
*ясалма* → *ясалма (ясалма елмаю)*
*ачык* → *ачык (ачык әйтү)*
*тыныч* → *тыныч (тыныч яшәү)*

Мисаллар: *Й о м ш а к сөйли, й о м ш а к мөгамалә кыла.* Г. Ибраһимов. *Бу вакыт й о м ш а к к ы н а сызгырган тавыш ишетелә.* М. Фәйзи. *Кайгы кешене в а к ы т с ы з картайта.* Мәкаль. *Пәрдәне в а к ы т с ы з төшерергә мәҗбүр булдык.* М. Әмир. *Шунлыктан бөтен... сыйфатларны бер кешегә бирү я с а л м а чыга.* М. Җәлил. *Т ы н ы ч тора сезнең сафыгыз. Һ. Такташ. Кыз шикләнерлек бернәрсә дә күрмәгәч, т ы н ы ч кына басып торуында дәвам итте.* А. Шамов.

### Фигыль формаларының рәвешләргә күчүе

Кайбер фигыльләр үзләренең аерым формаларында рәвешләргә күчәләр. Күпчелек очракта фигыльләрнең хәл фигыль формалары конверсияләнәләр.

-*п* кушымчалы хәл фигыль → рәвеш:

*каерып* → *каерып (ишекне каерып ачу)*
*читләтеп* → *читләтеп (читләтеп әйтү)*
*киерелеп* → *киерелеп (киерелеп сугу)*
*чәчрәп* → *чәчрәп (чәчрәп сикереп тору)*
*йотылып* → *йотылып (йотылып тыңлау)*
*акыртып* → *акыртып (акыртып талау)*
*үлеп* → *үлеп (үлеп йоклау)*

Мисаллар: *Акылы аның менә шуны сөйли, ул тыңлый т ы н ы п , й о т ы л ы п .* М. Җәлил. *Шәрифҗан арбадан төште дә, җил капканы к а е р ы п ачып, атны ишек алдына алып керде.* И. Газый. *Мин аларны яңадан югалтмас өчен, аларга ч а т ы р д а п ябыштым.* М. Әмир.

Аерым очракларда кушма хәл фигыльләр дә рәвешләргә күчәргә мөмкин: *бара-бара* (акрынлап мәгънәсендә), *килә-килә* (шул ук мәгънәдә). Мисал: *Б а р а - б а р а барысы да рәтләнер.*

Барлык хәл фигыльләр дә рәвешләргә күчмиләр, бу күренеш аларның семантикасына бәйләнгән. Хәл фигыль формалары рәвешләргә бары хәл фигыль моңа кадәр фигыльдә булмаган бөтенләй яңа мәгънә алганда гына күчә. Бу – хәл фигыль формасының рәвешкә күчүенең төп шарты булып тора. Әгәр дә хәл фигыль формасында, төп фигыль белән чагыштырганда, яңа мәгънә булмаса, ул хәл фигыль яңа сүз тәшкил итми, ә бар фигыльнең бер формасы гына булып тора.

-*ганчы* кушымчалы хәл фигыль → рәвеш:

*чәнчелгәнче* → *чәнчелгәнче (чәнчелгәнче эчү)*
*үлгәнче* → *үлгәнче (үлгәнче көлү)*
*шартлаганчы* → *шартлаганчы (шартлаганчы ашау)*

Күренгәнчә, китерелгән хәл фигыль формаларында төп фигыльдә булмаган яңа мәгънә күзәтелә, бу үзенчәлек аның рәвешкә күчүен китереп чыгара.

Мисаллар: *Башка кешеләрнең Халикъка сүз тидерүләренә аз гына түземлелек күрсәтә алмый, ү л г ә н ч е тиргәшергә әзер тора*. Ш. Камал. *Ш а р т л а г а н ч ы ашаттылар да, тагын капчыкка да төяп җибәрделәр*. И. Гази.

-*рга* кушымчалы инфинитив → рәвеш:

*көтәргә → көтәргә (көтәргә акча алу)*

*Көтәргә* дигән төп фигыльдә «бурычка акча алырга» дигән мәгънә юк, шуңа күрә ул рәвеш тәшкил итә, чөнки «бурычка» дигән мәгънә бу фигыльдә бөтенләй яңа булып тора. Мисал: *Кайберләре башкалардан унар тиенләп к ө т ә р г ә алып, аны да оттырдылар*. М. Гали.

Сыйфат фигыльләрнең кыек килеш формалары → рәвеш:

*көтәсегә* → *көтәсегә (көтәсегә акча алу)*
*көтәчәккә* → *көтәчәккә (көтәчәккә мең сум алу)*
*көтмәстән* → *көтмәстән (көтмәстән бу хәл килеп чыкты)*
*көтелмәстән* → *көтелмәстән (көтелмәстән куна килде).*

Мисаллар: *Мәскәү һәм Варшава фабрикантлары... к ө т ә с е г ә ничә миллион мал саталар*. Ш. Мөхәммәдев. *Орлыгың аз булса, к ө т ә ч ә к к ә бирермен*. М. Җәлил. *К ө т е л м ә г ә н д ә килеп төшкән үги килен бөтен мәҗлес вакытында гаҗәп дәрәҗәдә кирәкле кул булып китте.* Г. Ибраһимов.

Мисалларның семантикасын тикшерү аларда, төп фигыль белән чагыштырганда, яңа мәгънә барлыкка килүен күрсәтә һәм ул фигыль формасының рәвешкә күчүен китереп чыгара.

Фигыль формалары рәвешкә күчкән вакытта семантик-морфологик үзгәрешләр килеп чыга. Алар тулысынча фигыльләргә хас үзенчәлекләрне юнәлеш, барлык-юклык категорияләрен, башкару сәләтен югалталар.

## Алмашлыкларның рәвешләргә күчүе

Алмашлыкларның кайбер формалары шулай ук рәвешләргә күчәргә мөмкин:

*анда* → *анда (анда яшәү)*
*монда* → *монда (монда тору)*
*шулай* → *шулай (шулай килешү)*
*болай* → *болай (болай кылану)*
*алай* → *алай (алай булма)*
*кайчак* → *кайчак (кайчак сөйләшеп алалар)*

Мисаллар: *Бик тиз арада ул анда үзен эшлекле, булдыклы кыз итеп танытып өлгерде.* А. Шамов. *Киленнең якты чыраен, үзе өчен чын күңелдән борчылуын күргәч, алай каты бәрелергә теле бармады.* Г. Бәширов. *Кайчак минем белән исәнләшергә дә теләмиләр.* Т. Гыйззәт. *Кайчак үзара каты гына әйткәләшеп тә алалар.* А. Шамов. *Кара әле, гармунны ничек биетә кулында.* М. Фәйзи.

## Саннарның рәвешләргә күчүе

Аерым саннар конверсия юлы белән рәвешләргә күчәләр, әмма алар күп түгел:

*өчәү* → *өчәү (өчәү килделәр)*
*бишәү* → *бишәү (бишәү бардылар)*
*икәү* → *икәү (икәү сөйләштек)*
*дүртәү* → *дүртәү (дүртәү киттек)*

Мисаллар: *Шулай итеп, аның янына без өчәү генә киттек.* А. Шамов. *Бер сержант белән икәү фронттан кайтып киләбез.* М. Җәлил.

### Ияртемнәрнең рәвешләргә күчүе

Кайбер аваз ияртемнәре шулай ук рәвешләргә күчәргә мөмкин:

*выжт* → *выжт (бик тиз)*
*шып* → *шып (кинәт)*
*тып* → *тып (кисәктән)*

Мисал: *Тагын т ы п туктады*. М. Гафури.

## 9.9. САННАР ЯСАЛЫШЫ

Татар телендә тамыр саннар күп түгел. Аларның саны, алынмаларны да исәпкә алып, утыздан артык. Алар берәмлекләрдән – *бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз;* унарлыклардан – *ун, егерме, утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан;* йөзәрлекләрдән, меңәрлекләрдән һ.б. – *йөз, мең, миллион, миллиард, триллион* һ.б.

Югарыда китерелгән кайбер саннар элек ясалма саннар булган: *сигез ун = сиксән, тугыз ун = туксан* һ.б.

База тәшкил иткән тамыр саннар ике һәм аннан да күбрәк компонентлардан гыйбарәт бик күп ясалма саннар ясыйлар.

Татар телендә ясалма саннарның компонентлары ике төрдәге бәйләнеш белән кушылалар.

100 гә кадәр булган ясалма саннар компонентларны тезүле бәйләнеш нигезендә кушу юлы белән (сан+сан тәртибендә) ясалалар: *ун+бер, ун+ике, ун+өч, ун+алты, егерме+бер, егерме+биш, сиксән+ике, туксан+алты.*

100 дән югары барлык ясалма саннар компонентларны ияртүле бәйләнеш нигезендә тапкырлау юлы белән (сан х сан тәртибендә) ясалалар: *ун × мең = ун мең, өч × йөз = өч йөз, биш × миллион = биш миллион.*

Ике компоненттан торган саннар кушма саннар дип аталалар.

Компонентлары икедән күбрәк булган саннар тезмә саннар дип атала: *бер йөз ун, биш мең бер йөз утыз алты.*

Тезмә саннарны, компонентлары кушылып ясалган саннар белән бергә, компонентлары тапкырлап ясалган саннар да тәшкил итәргә мөмкин: *җиде × йөз егерме + өч = җиде йөз егерме өч.*

## 9.10. АЛМАШЛЫКЛАР ЯСАЛЫШЫ

Хәзерге татар телендә алмашлыкларның бер өлешен тамыр алмашлыклар тәшкил итә: *мин, син, ул, без, сез, алар, кем, ни.* Кайбер алмашлыклар элек ясалма булганнар, әмма хәзерге көндә алар тамырлашканнар: *ни+ирсә=нәрсә, бу+лай=болай, у*(*л*)*+ай=алай* һ.б.

Алмашлыкларның шактый өлеше сүзьясалыш нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Алар кушымчалау, сүзләрне кушу һәм конверсия ысулы белән ясалалар.

### 9.10.1. Алмашлыкларның кушымчалау ысулы белән ясалышы

Алмашлыкларның кайбер төркемнәре кушымчалау ысулы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Аларның ясаучы нигезләре булып, кагыйдә буларак, алмашлыклар, сирәк кенә рәвешләр һәм хәбәрлек сүзләр килә.

**Сорау алмашлыкларының кушымчалау ысулы белән ясалышы.** Аның түбәндәге төрләре бар:

Нигез + *-сы* кушымчасы: *кай+сы*.

Нигез+ *-а* кушымчасы: *кай+а* (*орф. кая*). Биредә *-а* кушымчасы, һичшиксез, угыз кушымчасы булып тора.

Нигез + *-да* кушымчасы: *кай+да*.

Нигез + *-дан* кушымчасы: *кай+дан, күпме+дән.*

Нигез + *-чан*$_4$ кушымчасы: *кай+чан.*

Нигез + *-ме* кушымчасы: *күп (рәвеш)+ме.*

Нигез + *-чек* кушымчасы: *ни+чек*.

Нигез + *-ча*/*-чә* кушымчасы: *ни+чә.*

Нигез + *-лектән* кушымчасы: *ни+лектән*.

Нигез + *-н* + *-ди* кушымчасы*: ни+н+ди*. Биредә *-н* кушымчасы интерфикс тәшкил итә.

Нигез + *-ләп* кушымчасы: *ничә+ләп, күпме+ләп.*

Нигез + *-н* + *-че* кушымчасы: *ничә + н + че.*

Нигез + *-гә* кушымчасы: *ни+гә, күпме+гә.*

Нигез + *-ш* + *-әр* кушымчасы: *ничә+ш+әр, күпме+ш+әр.* Биредә *-ш* кушымчасы интерфикс булып тора, сузык авазга тәмамланган нигез белән сузык авазга башланган кушымчаны тоташтыра, шул юл белән хиатус юкка чыга.

**Билгесезлек алмашлыкларының кушымчалау ысулы белән ясалышы.** Бу ясалышның бары бер тибы гына бар: сорау алмашлыгы + *-дыр/-дер* кушымчасы: *кем+дер, нәрсә+дер, ни+дер, нинди+дер, кайсы+дыр, күпме+дер, кая+дыр, кайда+дыр, кайдан+дыр, кайчан+дыр, нигә+дер, ничек+тер, ничә+дер* һ.б.

**Билгеләү алмашлыкларының кушымчалау ысулы белән ясалышы.** Бу ясалышның түбәндәге типлары бар.

Нигез + *-лай/-ләй*$_3$ кушымчасы: *теге+ләй, шу+лай*.

Нигез + *-н* + *-ди* кушымчасы: *теге+н+ди, шушы+н+дый.* Бу ясалыштагы сүзләргә хәзерге көндә аерым кисәкләргә бүленми торган *мондый, андый* алмашлыклары да керә. Биредә *-н* кушымчасы, әлбәттә, интерфикс тәшкил итә.

Нигез + *-лык*$_1$ кушымчасы: *бар+лык.*

Нигез + *-ча*$_1$ кушымчасы: *бар+ча*.

Нигез + *-шы*$_1$ кушымчасы: *шу+шы*.

Хәзерге көндә *шу* кисәге *шу+лай* сүзендә очрый.

### 9.10.2. Кушма алмашлыклар ясалышы

Алмашлыкларның кайбер төркемнәре сүзләр кушылу ысулы белән ясала. Кушма алмашлыкларның компонентлары арасында, кагыйдә буларак, ияртүле бәйләнеш күзәтелә. Кайвакыт алар арасында тезүле бәйләнеш тә булырга мөмкин.

#### Компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма алмашлыклар ясалышы

Аның түбәндәге типлары бар.

**Алмашлык + алмашлык тибы.** *Һәр* алмашлыгы+сорау алмашлыгы моделе. Бу модельдә беренче компонент булып билгеләү алмашлыгы, икенче компонент булып сорау алмашлыгы килә. Бу вакытта кушма билгеләү алмашлыклары барлыкка килә: *һәркем, һәрнәрсә, һәркайсы, һәрни, һәрнинди.* Бу алмашлыкларның сүзләр кушылу ысулы белән ясалганлыкларына шикләнеп булмый, чөнки телдә аларда тәңгәл ирекле сүзтезмәләр юк.

*Кай* алмашлыгы+*берәү* алмашлыгы моделе. Бу модельдә беренче компонент булып *кай* дигән сорау алмашлыгы, икенче компонент бу-

лып күплек санда *берәү* алмашлыгы килә: *кайберәүләр → кай* компоненты алмашлыкның билгесезлек мәгънәсен көчәйтә.

**Алмашлык + сан тибы.** Ике моделе бар.

*Һәр алмашлыгы+бер саны.* Телдә бу модельдәге берничә генә алмашлык бар: *һәрберсе, һәрбер, һәрбере.* Алар билгеләү алмашлыкларын тәшкил итәләр.

*Кай* алмашлыгы+*бер* саны*: кайбер, кайберсе, кайбере.* Бу модельдә билгесезлек алмашлыклары барлыкка килә.

**Сан + алмашлык тибы.** Бу типта беренче компонент булып *бер* саны, икенче компонент булып сорау алмашлыгы килә. Бу вакытта атрибутив бәйләнештәге юклык алмашлыклары хасил була: *беркем, бернәрсә, берни, бернинди, берничек, беркая, беркайда, беркайчан, беркайдан.*

Алмашлыкларның семантикасын тикшерү *бер* сүзенең юклык кисәкчәсе функциясендә килүен күрсәтә. Бу алмашлыклар сүзләр кушылу юлы белән барлыкка килгәннәр, чөнки телдә аларга тәңгәл иректле сүзтезмәләр **юк.**

**Кисәкчә + сорау алмашлыгы тибы.** Телдә бу сүзьясалышының ике моделе бар.

*Һич* кисәкчәсе + сорау алмашлыгы моделе. Бу модельдә кушма юклык алмашлыклары ясала: *һичкем, һичнәрсә, һични, һичнинди, һичкайсы, һичничек, һичкая, һичкайда, һичкайчан*.

Бу алмашлыклар, һичшиксез, сүзләр кушылу юлы белән ясалганнар, чөнки телдә аларның үзләренә тәңгәл иректле сүзтезмәләр юк. Аерым очракларда биредә икенче компонент булып *бере, берсе* кебек саннардан ясалган алмашлыклар килергә мөмкин.

*Әллә* кисәкчәсе + сорау алмашлыгы моделе. Бу модель белән компонентлары атрибутив бәйләнештә булган билгесезлек алмашлыклары ясала: *әллә кем, әллә нәрсә, әллә ни, әллә нинди, әллә ничек, әллә күпме, әллә нигә, әллә кая, әллә кайда, әллә кайчан, әллә кайсы, әллә ничә, әллә никадәр, әллә ничаклы, әллә нихәтле*. Китерелгән билгесезлек алмашлыклары сүзләр кушылу ысулы белән ясалганнар, чөнки телдә аларга тәңгәл иректле сүзтезмәләр юк. Аларның кайберләре ике мәгънә белдерә: *әлләкем* 1) кемдер; 2) күч. мөһим кеше.

**Кисәкчә + сан тибы.** Бу типта беренче компонент булып *һич* кисәкчәсе, икенче компонент булып *бер, берәү* саны килә. Сүзьясалышның

бу тибы белән атрибутив бәйләнештәге кушма юклык алмашлыклары ясала: *һичбер, һичберәү*.

**Алмашлык + бәйлек тибы.** Бу типта сорау алмашлыклары ясала: *никадәр, нихәтле, ничаклы, никадәрле*.

### Компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма алмашлыклар ясалышы

Бу ясалышның ике моделе бар.

Микъдар саны + микъдар саны моделе: *бер-бер*. Бу модель белән билгесезлек алмашлыгы ясала: *Б е р - б е р эш табылмасмы? Булмас ахры, диде, б е р - б е р хәйлә кормый*. Г. Тукай.

Тартым кушымчалы сан + тартым кушымчалы сан моделе: *берсе-берсе*. Бу модель белән билгеләү алмашлыгы ясала: *Йодрыклары б е р с е - б е р с е бишәр потлы герләр хәтле иде, ди*. А. Алиш.

### 9.10.3. Конверсия ысулы белән алмашлыклар ясалышы

Кайбер очракларда аерым саннар һәм аларның формалары алмашлыкка күчәргә мөмкин:

*берәү* (җыю саны) → *берәү* (билгесезлек алмашлыгы = *кемдер*)

*бер* (микъдар саны) → *бер* (билгесезлек алмашлыгы = *билгесез кем*): *Авылга б е р кыз килгән. Яшьрәк кенә б е р кеше*. М. Гали.

*берәр* (аеру саны) → *берәр* (билгесезлек алмашлыгы): *Б е р ә р эш юкмы? Моның астында б е р ә р хәйлә бардыр*. Г. Ибраһимов.

Хәбәрлек сүз дә алмашлыкка күчәргә мөмкин:

*бар* (хәбәрлек сүз) → *бар* (билгеләү алмашлыгы): *Б а р кеше аны мактый. Сафа бер кулын бутап б а р куәте белән кычкырып җырлый башлады*. Ш. Камал.

Югарыда китерелгән алмашлыклар тартым кушымчасы белән дә килергә мөмкиннәр:

*бар* → *барсы (барысы)*
*берәр* → *берәрсе*
*бер* → *берсе*

Мисаллар: *Б а р с ы да килгән. Б е р ә р с е фронттан кайттымы?* Ш. Камал. *Килмәс микән б е р с е ?* Сөйләм теленнән.

Күренгәнчә, тартым күрсәткече алмашлыкларның төркемен үзгәртми, бары алмашлык-сыйфатларны алмашлык-исемнәргә әйләндерә.

## 9.11. ЫМЛЫКЛАР ЯСАЛЫШЫ

Татар телендә тамыр һәм ясалма ымлыклар бар. Ясалма ымлыклар сүзләр кушылу һәм конверсия ысуллары белән ясалалар.

### 9.11.1. Сүзләр кушылу ысулы белән ымлыклар ясалышы

Бу ысул белән компонентлары тезүле бәйләнештә булган ымлыклар, ягъни куш ымлыклар ясала. Мондый юл белән ымлыклар ясалышының бары бер генә тибы бар: *ымлык+ымлык.* Бу төр ымлыкларның компонентлары булып боеру ымлыклары (императив ымлыклар) һәм хис ымлыклары (эмоциональ ымлыклар) киләләр. Аларның түбәндәге модельләре бар.

Хис ымлыгы$_1$ + хис ымлыгы$_1$ моделе: *аһ-аһ, уф-уф, ах-ах, ай-ай* һ.б.

Хис ымлыгы$_1$ + аның яңгырашы моделе: *ай-йәй, ай-һай.*

Боеру ымлыгы$_1$ + боеру ымлыгы$_1$ моделе: *көш-көш, на-на, чип-чип, дөгә-дөгә, лил-лил, бәү-бәү.* Татар телендә күпчелек боеру ымлыклары куш сүзләр булып торалар. Дөрес, боеру ымлыкларында бер компонентны да һәм берничә компонентны да кулланырга мөмкин. Әмма телдә ике компоненттан торган төп вариант файдаланыла. Аларның мәгънәләре нигездә бер үк.

Боеру ымлыгы$_1$ + боеру ымлыгы$_2$ моделе: *әлли-бәлли, бәлли-бәү.*

### 9.11.2. Конверсия ысулы белән ымлыклар ясалышы

Ясалма ымлыклар конверсия юлы белән исемнәрдән, фигыльләрдән, алмашлыклардан, рәвешләрдән, кисәкчәләрдән, ияртемнәрдән ясала.

Түбәндәге исемнәр һәм аларның формалары ымлыкка әйләнгәннәр:

*нәгъләт* *Аллам*
*нәләт* *энекәем*

| | |
|---|---|
| *ләгънәт* | *атакаем* |
| *әтекәем* | *Аллакаем* |
| *ходаем* | *әкәмәт* |
| *тамаша* | *каравыл* |
| *пәрәмәч* | *Раббым* |
| *әтәч* | *шайтан* |
| *бәлеш* | *сәлам* |
| *бәрәкәт* | *ләгыйнь* |

Мисаллар: *Матур да, усал да кыз, н ә г ъ л ә т* . Ш. Камал. *Чирле бит ул, н ә л ә т* . Б. Рәхмәт. *Сорарга өлгермәдем, китеп бардым, ш а й т а н* . К. Тинчурин. *Менә т а м а ш а ..., ахры эчтән терәп өлгерделәр*. Г. Гобәй. *Сираҗетдин: К а р а в ы л ! Талыйлар!* Г. Камал. *К а р а в ы л , мәктәп яна!* Г. Гобәй. *И а л л а к а е м , кызыл келәм түшәгән кебек бит*. М. Фәйзи.

Фигыль формалары, конверсияләнеп, түбәндәге ымлыкларны хасил итәләр:

| | |
|---|---|
| *ташла* | *әйттегез* |
| *җитәр* | *әйдә(гез)* |
| *күрәсең(ме)* | *тукта* |
| *гафу ит(егез)* | *кара* |
| *әйтсәнә* | *җитте* |

Мисаллар: *Т а ш л а инде, зинһар, барсын да әйттермә*. Ш. Камал. *Т у к т а , мин юлдан адашканмын икән, күр әле*. Г. Тукай. *Ә й д ә , тәртә дулап ат була алмас әле*. М. Фәйзи.

Кисәкчәләр шулай ук ымлыкларга күчәргә мөмкин: *менә, менәтрәк*. *М е н ә , әткәй, мин тагы килдем.* Г. Тукай.

Алмашлыклар да, конверсияләнеп, ымлыкка күчәргә мөмкин: *шулшул. Ш у л - ш у л , ди Саматкамы мондый, йорт, ди.* Н.Исәнбәт.

Кайбер рәвешләр шулай ук ымлыкка әйләнергә мөмкин: *алай, шулай. А л а й , ... берни булса, һаман Миңнулла*. И. Газый. *Ш у л а й , Аллага тапшырабыз инде*. М. Фәйзи.

Аерым ияртемнәр дә конверсия юлы белән ымлык булып килергә мөмкин: *тфү* (ияртем) → *тфү* (ымлык) – *Т ф ү , бәла икәнсең син, Галимҗан абзый.* Г. Тукай.

Тотрыклы сүзтезмәләр шулай ук ымлыкларга күчәргә мөмкин:

*рәхмәт төшкере*
*Алла сакласын*
*ай Алла(м)*
*рәхим ит(егез)*
*йә Хода*
*Аллага шөкер*
*шайтан алгыры*
*менә сиңа мә*
*акылдан язарсың*
*хода вәндә*
*булыр сиңа*
*кит аннан*
*ләгънәт төшкере*
*кара син (аны)*

Мисаллар: *Күзлекле кеше: «Рәхим итегез, ни йомыш»,– диде.* Г. Әпсәләмов. *Һаман да укый-укый, рәхмәт төшкере, – дип куйды.* Г. Бәширов. *Бик усал ерткычтыр ул, мур кыргыры!* Г. Тукай. *Әйбәт, шайтан алгыры*. Р. Ишморат. *Алла сакласын... Язмышың булса, әллә ниләр күрерсең.* Г. Камал.

Югарыда күрсәтелгән сүз төркемнәренең сүзләреннән һәм сүз формаларыннан ымлыклар хасил булганда, алар үзләренең лексик-грамматик класс үзенчәлекләрен бөтенләй югалтып, эмоция һәм эмоциональ боеру реакцияләрен генә белдерә башлыйлар һәм тулысынча ымлыкларның лексик-грамматик үзенчәлекләрен алалар.

## 9.12. ИЯРТЕМНӘР ЯСАЛЫШЫ

Татар теле ияртемнәргә бик бай. Аларның күпчелеге компонентларның тезүле бәйләнеш нигезендә кушылуыннан барлыкка киләләр. Ияртемнәр ясалышының бары бер генә тибы бар: *ияртем+ияртем.* Бу тип түбәндәге модельләрдән гыйбарәт.

Ияртем$_1$ + ияртем$_2$ моделе: *чыш-пыш, чыж-пыж, шатыр-шотыр, дөбер-шатыр, ялт-елт.*

Ияртем$_1$ + ияртем$_1$ моделе: *келт-келт, пытыр-пытыр, пышык-пышык, пыш-пыш, мырк-мырк, лүрт-лүрт, кыйгак-кыйгак, зырыл-зырыл, доң-доң, гөр-гөр, чың-чың, чи-чи, елык-елык*.

Бу төр редупликацияләнгән аваз һәм образ ияртемнәре, кагыйдә буларак, лексик берәмлекләр тәшкил итәләр, чөнки аларның, беренчедән, бер компонентлы вариантлары юк, ягъни бер компонент белән кулланылмыйлар, икенчедән, әгәр кулланылсалар да, аларның ике компонентлы вариантлары, бер компонентлы вариант белән чагыштырганда, яңа мәгънәле мөстәкыйль сүз булып торалар.

Ияртем + аның яңгырашы моделе: *чатыр-чотыр, шак-шок*.

Бу кабатлаулы куш ияртемнәрне анализлау – беренче компонентның яңгырашы булып килгән сүздә беренче компонентның беренче иҗегендәге *а* авазы *о* авазына күчкәнлеген күрсәтә. Кагыйдә буларак, китерелгән кабатлаулы куш ияртемнәрнең икенче компоненты телдә аерым кулланылмый, шуңа күрә бу ияртемнәр мөстәкыйль лексик берәмлек булып торалар. Дөрес, кайбер кабатлаулы куш сүзләрнең икенче компонентларын теоретик яктан мөстәкыйль кулланырга мөмкин, әмма бу төр ияртемнәр өчен алар, барыбер, беренче компонентның яңгырашы булып калалар.

Телдә куш ияртемнәр компонентларының өчләтелгән һәм хәтта дүртләтелгән вариантлары очрый. Алар ияртемнең семантикасына бернинди дә яңа мәгънә өстәмиләр, шуңа күрә яңа лексик берәмлек тәшкил итмиләр.

## 9.13. БӘЙЛЕКЛӘР ЯСАЛЫШЫ

Бәйлекләр тамыр һәм ясалма бәйлекләргә аерылалар. Ясалма бәйлекләр – бәйлек сүзләр дип йөртеләләр.

Тамыр бәйлекләр мөстәкыйль сүзләр белән сүзьясалыш мөнәсәбәтләре белән бәйләнмәгәннәр, ә ясалма бәйлекләр, киресенчә, мөстәкыйль сүзләр белән сүзьясалыш мөнәсәбәтләре белән бәйләнгәннәр. Андый мөстәкыйль сүзләрне, кагыйдә буларак, исемнәр, фигыльләр, рәвешләр тәшкил итәләр. Шуңа бәйләнешле рәвештә ясалма бәйлекләр исемнән, фигыльдән һәм рәвешләрдән ясалганнарга бүленәләр.

Бәйлекләр татар телендә ике ысул белән – кушымчалау һәм конверсия ысулы белән ясалалар.

### 9.13.1. Кушымчалау ысулы белән бәйлекләр ясалышы

Аның түбәндәге типлары бар.

**Нигез + -лы/-ле кушымчасы:** *сәбәп+ле, чак+лы, шикел+ле (шәкел+ле), төс+ле.*

Кайбер очракларда *-лы/-ле* кушымчалы бәйлекләр структур кисәкләргә аерылмыйлар: *тикле, бирле*. Мисаллар: *Урманга ч а к л ы бардык. Кырда эшли башлаганнан б и р л е үз алдына бертөрле буыннары ныгып, килеш-килбәтенә т и к л е үзгәреп китте.* Г. Бәширов. *Вакытында яңгыр булмау с ә б ә п л е сабаннар да уңмады*. И.Газый.

**Нигез + *-лаш/-ләш* кушымчасы:** *каршылаш. Өйгә к а р ш ы л а ш кибет урнашкан.*

**Нигез + *-ынтен/-ентен* кушымчасы:** *тиңентен. Тез т и ң е н т е н пычрак иде*. Сөйләм теленнән.

### 9.13.2. Конверсия ысулы белән бәйлекләр (бәйлек сүзләр) ясалышы

Татар телендә бәйлекләрнең күпчелеге конверсия ысулы, ягъни башка сүз төркемнәренә кергән сүзләрнең бәйлекләргә күчүе юлы белән ясала.

Еш кына, татар телендә бәйлек функциясен үти торган исемнәр бар, дип раслыйлар. Бу раслау төгәл түгел, чөнки татар телендә бәйлек функциясен үти торган исемнәр юк. Телдә үзенең парадигмасыннан аерылган һәм бәйлекләргә күчкән исемнәрнең фәкать аерым формалары гына бар. Шуңа күрә сүз исемнең бөтен лексемасы турында түгел, тик исемнәрнең аерым формалары турында гына барырга мөмкин.

#### Исем формаларының бәйлекләргә күчүе

Татар телендә исемнәрнең кайбер формалары гына бәйлекләргә күчәргә мөмкин. Шундый формаларны пространство мәгънәсен белдерә торган исемнәрнең кыек килеш формалары тәшкил итә (*астында, астыннан, астына*). Сирәк булса да вакыт мәгънәсен белдерә торган исемнәрнең дә кыек килеш формалары бәйлекләргә күчәргә мөмкин (*чагында, вакытында*).

Исемнәрнең кыек килеш формалары бәйлекләргә күчкәндә аларның лексик, исем мәгънәсе югала, мәгънә абстрактлаша, теге яки бу грамматик мөнәсәбәтне белдерә.

**Юнәлеш килеш формасы → бәйлек:**

*буена (юл буена)*
*астына (парта астына)*
*өстенә (өстәл өстенә)*
*янына (дусты янына)*
*уртасына (юл уртасына)*
*эченә (өй эченә)*
*алдына (кибет алдына)*
*артына (лапас артына)*
*арасына (кешеләр арасына)*
*турысына (мәктәп турысына)*

Мисаллар: *Атын бөркәүле лапас а с т ы н а кертеп куйды.* М. Гали. *Кода кеше... картның ө с т е н ә һөҗүм итәргә хәзерләнгән кыяфәткә керде.* Ш. Камал. *Кигәвен я н ы н а Нечкәбил килеп җитә.* А. Алиш. *Малик, урыныннан торып, башын чаршау э ч е н ә тыкты.* И. Газый.

**Чыгыш килеш формасы → бәйлек:**

*буеннан (юл буеннан)*
*астыннан (парта астыннан)*
*өстеннән (өстәл өстеннән)*
*яныннан (дусты яныннан)*
*уртасыннан (юл уртасыннан)*
*эченнән (өй эченнән)*
*алдыннан (кибет алдыннан)*
*артыннан (лапас артыннан)*
*арасыннан (кешеләр арасыннан)*
*турысыннан (мәктәп турысыннан)*

Мисаллар: *Җитәрлек ризык булмаганга малның күп гомере яланда кар а с т ы н н а н үлән тибеп үтә.* Г. Ибраһимов. *Яңа яуган йомшак кар ө с т е н н ә н чананы шатырдатып алып китте.* Г. Ибраһимов. *Мәүлиха түти... аш я н ы н н а н кузгалып китә.* Г. Бәширов. *Рамазан бай сүзне утын т у р ы с ы н н а н башкага борып җибәрергә теләде.* М. Гали.

**Урын-вакыт килеш формасы → бәйлек:**

*башында (эш башында)*
*артында (лапас артында)*
*буенда (күл буенда)*
*астында (парта астында)*
*өстендә (өстәл өстендә)*
*янында (өй янында)*
*эчендә (өй эчендә)*
*алдында (мәктәп алдында)*
*уртасында (авыл уртасында)*
*арасында (кешеләр арасында)*
*турысында (эш турысында)*
*нәтиҗәсендә (сугыш нәтиҗәсендә)*
*каршысында (кибет каршысында)*

Мисаллар: *Аннары, яңгыр а с т ы н д а уйланып-нитеп торуның файдасызлыгын абайлап, әлеге ялгыз утка таба китте*. Г. Минский. *Яшел чирәм ө с т е н д ә бер-беренә кырын утырган Нәсимә белән Каликъ арасында барган сүзләрне кешеләр тыңлап утыра*. Ш. Камал. *Боларның ашыкканнарын күреп, бер рәсем я н ы н д а да тукталып тормады*. Г. Гобәй. *Китәрлек булсаң, шушы бер-ике көн э ч е н д ә миңа әйтерсең*. И. Газый. *Бүген яңа тормыш т у р ы н д а бик яхшы доклад сөйләнә*. М.Җәлил.

Бик сирәк очракларда гына исемнәр үзләренең төп формаларында бәйлекләргә күчәләр, еш кына, алар тартым кушымчасы алалар: *тыш, буе.*

Мисаллар: *Шулай ук сәхнә әсәрләреннән т ы ш язган маршлары белән халкына бик нык танылды*. М. Җәлил. *Атналар, айлар б у е туй иттеләр*. Ш. Бабич.

### Сыйфатларның бәйлекләргә күчүе

Кайбер сыйфатлар шулай ук бәйлекләргә күчәләр:

*башка* → *башка (синнән башка)*
*бүтән* → *бүтән (эштән бүтән)*
*аркылы* → *аркылы (юл аркылы)*

Мисаллар: *Галидән б а ш к а сөйләүче кеше юк*. Г. Колахмәтов. *Синнән б ү т ә н кеше юк минем өчен.* Ф. Хөсни. *Шуннан соң хатын-кыз а р к ы л ы Маликка сүз ишеттерделәр*. И. Газый.

## Фигыль формаларының бәйлекләргә күчүе

Фигыльләрнең аерым формалары шулай ук бәйлекләргә күчәргә мөмкин. Бу очракта алар фигыльлекләрен, ягъни фигыль билгеләрен (юнәлеш, барлык-юклык категорияләрен һ.б.ны) тулысынча югалталар. Фигыль формасы лексик мәгънәне белдерүдән туктап, грамматик мөнәсәбәтләр белдерә башлый.

| | |
|---|---|
| *аш+а* | → *аша (елга аша)* |
| *күр+ә* | → *күрә (чиләгенә күрә)* |
| *буйла+п* | → *буйлап (юл буйлап)* |
| *кара+п* | → *карап (шуңа карап)* |
| *кара+мастан* | → *карамастан (шуңа карамастан)* |

Мисаллар: *Чиләгенә к ү р ә капкачы*. Әйтем. *Урам б у й л а п кичкә кадәр Чанасын тартып йөрде*. Һ. Такташ. *Күрсәтелгән җитешсезлекләргә к а р а м а с т а н , «Безнең көннәр» татар әдәбияты тарихында зур урыннарның берсен тотарга тиешле*. Г. Нигъмәти.

## Рәвешләрнең бәйлекләргә күчүе

**6.** Рәвешләрнең бер өлеше шулай ук бәйлек булып килергә мөмкин. Бу вакытта алар рәвеш билгеләрен югалталар, грамматик мөнәсәбәт белдерә башлыйлар, җөмләдә үзләренең урыннары белән бәйлеккә туры киләләр:

| | |
|---|---|
| *элек* | → *элек (аңардан элек)* |
| *соң* | → *соң (җыелыштан соң)* |
| *иртә* | → *иртә (барысыннан иртә)* |
| *алда* | → *алда (синнән алда)* |

Мисаллар: *Карчыкның җавабыннан э л е к , аптыраулы карашын күреп, өйдә чит кеше юклыгын төшенеп алды*. Г. Әпсәләмов. *Аннан э л е к тә бер кыз белән йөргән*. М. Фәйзи. *Бераз паузадан с о ң Гөлзадә килеп керә*. Р. Ишморат. *Минем әби һәммәсеннән и р т ә өлгерә*. А. Алиш.

Бәйлек сүзләрне аларның чыганак сүзләреннән аеру өчен төп критерий булып семантика тора. Башка сүз төркеменә кергән сүзләрнең формалары лексик мәгънә, ә алардан килеп чыккан бәйлек сүзләр грамматик мәгънә, ягъни сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерәләр.

### 9.14. КИСӘКЧӘЛӘР ЯСАЛЫШЫ

Кисәкчәләр тамыр һәм ясалма кисәкчәләргә бүленәләр. Ясалма кисәкчәләр конверсия ысулы белән рәвешләрдән, алмашлыклардан, фигыльләрдән һәм бәйлекләрдән ясалалар. Алар үзләренең структурасы һәм функцияләре буенча үзләре килеп чыккан сүзләрне бик нык хәтерләтәләр, шуңа күрә аларны бер-берсеннән аеру шактый кыен. Бу мәсьәләдә кисәкчәләрнең семантикасы, җөмләдәге урыны төп критерий булып тора.

**Рәвешләрдән конверсия ысулы белән ясалган кисәкчәләр:**

*тагы* → *тагы*
*тагын* → *тагын*
*соң* → *соң*

Мисаллар: *Кая барырга сөйләшкән идек с о ң ?* Ш. Камал. *Ул нәрсә ди с о ң ?* Р. Ишморат. *Гайфетдинов... ярым йоклабрак йөргән күзләрен т а г ы да йома төште.* А. Әхмәт. *Ишнияз: Әй, укымасаң т а г ы н ?* Р. Ишморат.

**Алмашлыклардан конверсия ысулы белән ясалган кисәкчәләр:**

*менә* → *менә*
*әле* → *әле*
*бу* → *бу*
*ул* → *ул*
*нинди* → *нинди*
*шулай* → *шулай*
*алай* → *алай*

Мисаллар: *Б у ни хәл б у ! Г. Ибраһимов. Б у нинди сүз!* Г. Ибраһимов. *Нәфисәнең Сәръян абыйсы ә н ә шундый кеше булган.* Г. Бәширов.

*Ә н ә нинди көч яшеренеп ята икән анда! Г. Бәширов. Н и н д и бәхет!* Ф. Әмирхан. *Н и н д и татлы яшәү! М. Җәлил. Сез үзегез кем б о - л а й ?* Н. Исәнбәт. *Шулай була у л ! Сөйләмәгез ә л е !*

**Фигыльләрдән конверсия ысулы белән ясалган кисәкчәләр:**

*булгач-булгач* → *булгач-булгач*
*булсын-булсын* → *булсын-булсын*
*булып* → *булып*
*бел* → *бел*
*кара* → *кара*
*әйтерсең* → *әйтерсең*
*җитмәсә* → *җитмәсә*
*ди* → *ди*
*дисеңме* → *дисеңме*
*дип* → *дип*
*китче* → *китче*
*кит* → *кит*
*китсәнә* → *китсәнә*

Мисаллар: *Гариф б у л ы п Гариф бу эшне башкара алмады.* А. Шамов. *Җ и т м ә с ә , келәт кырпуыннан шыбырдап су тама иде.* А. Шамов. *Б е л , аңа сүз кайтарудан тик тору артык ласа.* Ш. Бабич.

**Бәйлекләрдән һәм теркәгечләрдән конверсия юлы белән ясалган кисәкчәләр:**

*кебек* → *кебек*
*шикелле* → *шикелле*
*төсле* → *төсле*

Мисаллар: *«Син әле кайтып та өлгердеңмени, улым», – диде ул, Хәлимне яңа гына күреп алган к е б е к .* И. Газый. *Сөйләшкән к е б е к тә булмадык.* Ә. Еники. *Әмма Исмаев сизүенчә, бик аңлашылып бетмәде ш и к е л л е .* Г. Бәширов. *Кич ятсам да, иртә торсам да, Әллә нәрсәм җитми ш и к е л л е .* М. Җәлил. *Ул бүген бармас т ө с л е .*

Кисәкчәләр конверсия ысулы белән исемнәрнең аерым формаларыннан да ясалырга мөмкин (*пычак, пычагым, пычагыма*)*: Заводны күрдем дип уйлый инде бу... күрде, п ы ч а г ы м .* Г.Әпсәләмов.

Мисаллардан күренгәнчә, кисәкчәләр башка сүз төркемнәренең сүз формалары һәм сүзләре исәбенә дә тулылана. Бу сүз формалары һәм сүзләр, конверсияләнеп, тулысынча үзләренең лексик-грамматик билгеләрен югалталар, кисәкчә үзенчәлекләрен алалар.

### 9.15. ТЕРКӘГЕЧЛӘР ЯСАЛЫШЫ

**2.** Кайбер теркәгечләр дә ясалма булырга мөмкин. Алар конверсия ысулы белән ясалалар. Телдә мондый теркәгечләр күп түгел. Теркәгечләргә нигездә, кайбер кисәкчәләр күчәләр: *әле, ...әле; әллә, ...әллә; исә, да/дә* (*та/тә*), *тик.*

Мисаллар: *Һәммәсенә, һәммәсенә ризамын, тик син минем Казимирны коткар.* Г. Ибраһимов. *Әллә кызык юкмы бу тормышта? Әллә яшәү үзе иләмсез?* Ш. Бабич. *Әле анда, әле монда сабан тургайлары сайрый.* М. Гафури. *Боларның куанычы да, кайгысы да уртак иде.* Г. Тукай. *Чебен-черки, чикерткә-фәлән авызына каба да, оясына кайтып балаларын ашата.* Г. Тукай. *Ата чыпчык белән ана чыпчык бергә кавышты исә, аерым оя коруны карый.* Ш. Камал.

## ӘДӘБИЯТ


Азимов П. Префиксация в туркменском языке. Ашхабад, 1947. 24 с.

Аганин Р.А. Повторы и устойчивые однородные парные сочетания в современном турецком языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1954. 17 с.

Адилов М.И. Система повторов в азербайджанском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Баку, 1968. 56 с.

Адилов М.И. Сложные слова в современном азербайджанском языке // Учён. зап. Аз ГУ им. С.М. Кирова, 1956. С. 91–104.

Адилов М.И. Сложные слова в современном азербайджанском языке (имя существительное и имя прилагательное): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Баку, 1958. 21 с.

АкбероваА.Г. Структура и семантика наречий в современном татарском литературном языке: автореф. ... дис. канд. филол. наук. Казань, 1997.

Алиева З.И. Сложные глаголы в современном азербайджанском языке // Тр. Ин-та лит. и языка им. Низами АН СССР. Серия языкознания. Баку, 1957. Т. VII. С. 129–160.

Архангельский Г.В. Грамматика казахского языка. Ташкент, 1927. 63 с.

Ахманова О.С. К вопросу об отличии сложных слов от фразеологических единиц // Тр. Ин-та языкознания АН СССР, 1954. Т. 4. С.50–73.

Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке. Казань: Изд-во Казан, ун-та, 1968. 367 с.

Баранников А.П. Синонимические повторы в ново-индийских языках // Зап. коллегии востоковедов при Азиатском музее. Л.. 1928. Т. 3, вып. 2. С. 249–266.

Баскаков Н.А. Каракалпакский язык: фонетика и морфология. Ч. 1. М.: Изд-во АН СССР, 1952. 544 с.

Баскаков НА. Порядок и иерархия аффиксов в основе слова в тюркских языках // Морфологическая типология и проблема классификации языков. М.: Наука, 1965. С. 121–128.

Бердыев Р. Сложные слова в современном туркменском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1955. 16 с.

Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. 2-е изд, испр. и доп. Казань: Татгосиздат, 1953. 250 с.

Бурганова Ю.Ф. Интерфиксы в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2012. 31 с.

Валиуллина З.М. Сопоставительная грамматика русского и татарского языков. Казань, 1968. 126 с.

Вопросы составления описательных грамматик языков народов СССР. Уфа, 1958. 118 с.

Вопросы грамматики тюркских языков. Алма-Ата, 1958. 252 с.

Газизов Р.С. Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. Казань: Таткнигоиздат, 1959. 308 с; 2-е изд.: Казань, 1966. 368 с.

Гайнутдинова А.Ф. Частеречная транспозиция (субстантивация) в татарском языке в сопоставлении с русским языком: автореф. дис. ... д-ра. филологических наук. Казань, 2010. 43 с.

Гайнутдинова А.Ф. Субстантивные прилагательные в татарском и русском языках. Казань: «Фикер», 2004. 136 с.

Гайнутдинова А.Ф. Субстантивация отглагольных образований в татарском и русском языках. Казань, 2011. 208 с.

Ганиев Ф.А. Современный татарский литературный язык. Словообразование по конверсии. Казань: Дом печати, 2004. 160 с.

Ганиев Ф.А. Современный татарский литературный язык: суффиксальное и фонетическое словообразование. Казань: Дом печати, 2005. 360 с.

Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке. М.: Наука, 1982. 150 с.

Ганиев Ф.А.Функциональное словообразование в современном татарском литературном языке. Казань: Тан Дим, 2009. 264 с.

Ганиев Ф.А.Словообразование в татарском языке. Казань, 2010. 727 с.

Ганиев Ф.А. Словообразование как один из разделов татарского языкознания // Тезисы докладов Итоговой научной сессии за 1970. Казань: ИЯЛИ, 1971. С. 27–29.

Ганиев Ф.А. Словообразовательная структура слов в современном татарском языке // Конференция по татарскому языкознанию, посвященная 50-летию СССР. Казань: ИЯЛИ, 1972. С. 45–47.

Ганиев Ф.А. Суффиксальное образование глаголов в современном татарском литературном языке. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. 108 с.

Ганиев Ф.А. Татарская грамматическая наука за 50 лет // Развитие филологических и исторических наук. Казань: ИЯЛИ, 1969. С. 5–12.

Гарипов Т.М. Башкирское именное словообразование. Уфа, 1959. 224 с.

Гиганов И. Грамматика татарского языка. СПб., 1801. 188 с.

Гочияева С.А. Наречие в карачаево-балкарском языке. Черкесск: Ставроп. кн. изд-во, 1973. 119 с.

Грамматика азербайджанского языка: Фонетика. Морфология. Синтаксис. Баку: Элм, 1971. 414 с.

Грамматика карачаево-балкарского языка: Фонетика, морфология, синтаксис. Нальчик: Эльбрус, 1976. 572 с.

Грамматика ногайского языка: Фонетика и морфология. Черкесск, 1973. Ч. 1. 320 с.

Григорьев В.П. О границах между словосложением и аффиксацией // Вопр. языкознания. 1956. № 4. С. 38–52.

Гулямов А.Г. К некоторым вопросам аффиксации в узбекском языке: Академику В.А. Гордлевскому к его 75-летию. М.: Изд-во АН СССР, 1953. С. 98–107.

Гулямов А.Г. Об аффиксе -даш // Бюллетень Академии наук Узбекской ССР, 1947. № 1. С. 17–20.

Гулямов А.Г. Об аффиксе -ло в узбекском языке // Уч. зап. Ташкент, пед. и учит, ин-ов. Серия общественных наук. Ташкент, 1947. Вып.1. С. 39–50.

Гулямов А.Г. Проблемы исторического словообразования узбекского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Ташкент, 1955. 51 с.

Джавамов Ю.Д. Деепричастия в кумыкском литературном языке. М.: Наука, 1967. 330 с.

Дмитриев Н.К. Глаголы речи в языках тюркской группы // Очерки по методике преподавания русского и родного языков в татарской школе. М.: Учпедгиз, 1952. С. 203–209.

Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка.М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948. 276 с.

Дмитриев Н.К. К изучению турецкой мифологии // Строй тюркских языков. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1962. С. 59–108.

Дмитриев Н.К. О парных словосочетаниях в башкирском языке // Изд. АН СССР. Отделение гуманитарных наук. Серия VII, 1930. № 7. С. 501–522.

Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков. М.: Наука, 1962. 608 с.

Дыренкова Н.П. Грамматика шорского языка. М.-Л., 1941. 308 с.

Егоров В.Г. Словосложение в тюркских языках // Структура и история тюркских языков. М.: Наука. С. 95–107.

Жирмунский В.М. О границах слова // Вопр. языкознания, 1961. № 3. С. 3–21.

Жирмунский В.М. Об аналитических конструкциях // Аналитические конструкции в языках различных типов. М.-Л.: Наука, 1965. С. 5–57.

Заббарова Р.З. Конверсия в татарском языке и проблема её лексикографирования: автореф. дис. ... канд. филологических наук. Казань, 2010. 24 с.

Закиев М.З. К вопросу о категории падежа в тюркских языках // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964. С. 207–219.

Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1963. 464 с.

Зарипов Р.Ф. Категория падежа в башкирском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 1971. 23 с.

Иванов М. Татарская грамматика. Казань, 1842. 311 с.

Исенгалиева В.А. Тюркские глаголы с основами, заимствованными из русского языка. Алма-Ата: Наука, 1966. 248 с.

Искаков А.И. Морфологическая структура слова и именные части речи в современном казахском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Алма-Ата, 1961. 188 с.

Исхаков Ф.Г. Имя прилагательное // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. М.: Изд-во АН СССР, 1956. Ч.2. С. 143–175.

Исхаков Ф.Г., Пальмбах А.А. Грамматика тувинского языка. М., 1961. 472 с.

Катаринский В.В. Грамматика киргизского языка: Фонетика, этимология, синтаксис. Оренбург, 1897. 196 с.

Казем-Бек А.М. Общая грамматика турецко-татарского языка. Казань, 1846. 467 с.

Киэда М. Грамматика японского языка. М.: Изд-во иностр. лит., 1959. Т. 2. 266 с.

Кононов А.Н. Грамматика современного узбекского литературного языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 446 с.

Кононов А.Н. О природе тюркской агглютинации // Вопр. языкознания. 1976. № 4. С. 3–17.

Кубрякова Е.С. О формообразовании, словоизменении, словообразовании и их соотношении // Изд. АН СССР. Отд-ние лит. и яз., 1976. Т. 35. № 6. С. 514–526.

Кумахов М.А. О проблеме сложного слова // Изд. АН СССР. Отд-ние лит. и яз., 1963. Т. 22, вып. 1. С. 41–51.

Лопатин В.В. Способы именного словообразования в современном русском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1966. 20 с.

Лопатин В., Улуханов И. Словообразовательный тип и способы словообразования // Рус. яз. в нац. шк. 1969. № 6. С. 4–13.

Мадалиев Б. Сложные слова в современном узбекском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Ташкент, 1956. 15 с.

Махмудов Г. Практическое руководство к изучению татарского языка. Казань, 1857. 255 с.

Мелиоранский П.М. Краткая грамматика казак-киргизского языка. СПб., 1894–1897.

Мельников Г.П. Теория словоразграничения и морфологический строй языка // Башкирская лексика. Уфа, 1966. С. 67–88.

Муллина Р.М. Сложные слова в языках тюркской системы // Учен. зап. Казах. ун-та, 1950. Т. 13. Вып. 5. С. 27–42.

Муратов С.Н. О тюркских аффиксах -таш, -даш и -турук, -дурук в свете данных других алтайских языков // Проблема общности алтайских языков. Л.: Наука, 1971. С. 331–350.

Муратов С.Н. Устойчивые словосочетания в тюркских языках. М., 1961. 132 с.

Мусаев К.М. Грамматика караимского языка: фонетика и морфология. М.: Наука, 1964. 344 с.

Наджип Э.Н. Современный уйгурский язык. М., I960. 133 с.

Насилов В.М. Грамматика уйгурского языка. М., 1940. 154 с.

Насыри К. Краткая татарская грамматика. Казань, 1860. 80 с.

Оралбаева Н. Аналитические формы глагола в современном казахском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Алма-Ата, 1971.

Орузбаева Б.О. Словообразование в киргизском языке : автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Фрунзе, 1964. 102 с.

Пашковский А.А. Словообразование в современном японском языке: (типы сложных и аффиксальных слов): автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1952. 29 с.

Покровская Л.А. Грамматика гагаузского языка. М.: Наука, 1964. 298 с.

Русское словообразование // Тр. Самарканд. ун-та им. А. Навои, 1975. Вып. 209.

Садвакасов Г.С. Словообразование имен существительных в современном уйгурском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Алма-Ата, 1956. 16 с.

Салахова Р.Р. Омонимичные суффиксы татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.

Самойлович А.Н. Краткая учебная грамматика современного османо-турецкого языка. Л., 1925. 155 с.

Севортян Э.В. Аффиксальное глаголообразование в азербайджанском литературном языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1957. 53 с.

Севортян Э.В. Аффиксы глаголообразования в азербайджанском языке: опыт сравнительного исследования. М.: Изд-во вост. лит., 1962. 643 с.

Севортян Э.В. Аффиксы именного словообразования в азербайджанском языке: опыт сравнительного исследования. М.: Наука, 1966. 438 с.

Севортян Э.В. Грамматические и семантические признаки аналитических конструкций в отличие от свободных словосочетаний в тюркских языках // Аналитические конструкции в языках различных типов. М.-Л.: Наука, 1963. С. 233–239.

Севортян Э.В. К проблеме частей речи в тюркских языках // Вопросы грамматического строя. М.: Изд-во АН СССР, 1955. С. 188–225.

Севортян Э.В. К соотношению грамматики и лексики в тюркских языках // Вопросы теории и истории языка в свете трудов И.В.Сталина по языкознанию. М., 1952. С. 306–367.

Севортян Э.В. К соотношению грамматики и лексики в тюркских языках // Вопросы узбекского языкознания. Ташкент, 1954. С. 60–81.

Севортян Э.В. Морфологическое строение слова в связи с другими его характеристиками (по данным тюркских языков) // Тюркол. сб. М.: Наука, 1972. С. 132–144.

Севортян Э.В. Словообразование в тюркских языках // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч.2: Морфология. Изд-во АН СССР, 1956. С. 314–328.

Серебренников Б.А. Проблема глагольного вида в тюркских языках // Вопросы грамматики тюркских языков. Материалы координационного совещания по проблемам глагольного вида и сложноподчиненного предложения в тюркских языках. Алма-Ата, 1958. С. 12–30.

Смирницкий А.И. К вопросу о слове: (проблема тождества слова) // Тр. Ин-та язык. АН СССР.– М., 1954. Т. 4. С. 3–49.

Современный татарский литературный язык. М.: Наука, 1969. Ч. 1. 350 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. М.: Наука, 1984. 484 с.

Текусв М.М. Сложные глаголы в карачаево-балкарском языке (деепричастия с вспомогательными глаголами) в сравнительном плане: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1973. 27 с.

Тенишев Э.Р. Грамматический очерк древнеуйгурского языка по сочинению «Золотой блеск»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Л., 1953. 16 с.

Тенишев Э.Р. Строй сарыг-югурского языка. М.: Наука, 1976. 308 с.

Тенишев Э.Р. Строй саларского языка. М.: Наука, 1976. 576 с.

Троянский А. Краткая татарская грамматика. СПб., 1814. 199 с.

Тумашева Д.Г. Диалекты сибирских татар: опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

Тыбыкова А.Т. Сложные глаголы в алтайском языке. Горно-Алтайск: Алтайск. кн. изд-во, 1966. 63 с.

Убрятова Е.И. Парные слова в якутском языке // Язык и мышление. М., 1948. Вып. II. С. 297–328.

Убрятова Е.И. Удвоение основы слова в якутском языке // Вопросы грамматики: Сб. ст. к 75 летию акад. Н.П Мещанинова. М.-Л., 1960. С. 211–222.

Улуханов И.С. Словообразовательная семантика в русском языке и принципы ее описания. М.: Наука, 1977. 256 с.

Усманов С. Морфологические особенности в современном узбекском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Ташкент, 1964. 51 с.

Фаттахова Р.Ф. Категория числа в современном татарском литературном языке. Казань: ООО «Алма-Лит», 2004. 152 с.

Фейзханов Х. Краткая учебная грамматика татарского языка. СПб., 1862. 95 с.

Хабичев М.А. Карачаево-балкарское именное словообразование. Черкесск: Ставроп. кн. изд-во, 1971. 302 с.

Хайруллина Э.Ю. Словообразовательные гнезда имен прилагательных в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2006. 17 с.

Халфин И. Азбука и грамматика татарского языка. Казань, 1809. 106 с.

Харитонов Л.Н. Значение глаголов с аффиксом -ла // Доклады на третьей научной сессии // Якут. фил. АН СССР. История и филология. Якутск, 1953. Вып. 1. С. 7–20.

Харитонов Л.Н. Неизменяемые слова в якутском языке. Якутск: Якут. изд-во, 1943. 84 с.

Харитонов Л.Н. Современный якутский язык: фонетика и морфология. Якутск, 1947. Ч. 1. 304 с.

Хасенова А.К. Глагольные основы казахского языка: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Алма-Ата, 1960. 69 с.

Шанский Н.М. Очерки по русскому словообразованию и лексикологии. М.: Учпедгиз, 1959. 246 с.

Шанский Н.М. Фразеология современного русского языка. М.: Высшая школа, 1963. 156 с.

Шипова Е.Н. Состав слова // Сопоставительная грамматика русского и казахского языков. Алма-Ата: Наука, 1966. С. 7–17.

Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков. Л.: Наука, 1977. 192 с.

Юлдашев А.А. Аналитические формы глагола в тюркских языках. М.: Наука, 1965. 276 с.

Юлдашев А.А. К характеристике тюркских сложных слов // Вопр. тюркологии. Баку: Элм, 1971. С. 148–164.

Юлдашев А.А. Лексикализация тюркских грамматических форм как объект словообразовательной морфологии и словаря // Вопросы языкознания, 1977. № 1. С. 62–73.

Юлдашев А.А. Основные типы производных глаголов с аффиксом -ла/-лә в башкирском языке // Исследования по тюркологии. Алма-Ата: Наука, 1969. С. 92–103.

Юлдашев А.А. Система словообразования и спряжения глагола в башкирском языке. М.: Изд-во АН СССР, 1958. 195 с.

Юсипова Р.Р. Границы между словообразованием и формообразованием в зависимости от типа лексической единицы в турецком языке // Тр. Самарканд. гос. ун-та, 1970. Вып.178. С. 242–248.

Языки народов СССР. Тюркские языки. М.: Наука, 1966. Т. 2. 531 с.

Ястремский СВ. Грамматика якутского языка. 2-е пер. изд. М., 1938. 228 с.

* * *

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр: (татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). Казан: Татгосиздат, 1945. 330 б.

Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З. Сәгыйтов М.А. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан, 1972. 206 б.

Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы: төзәт. 3 нче басма. Казан: Мәгариф, 2009. 271 б.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: (синтаксис). Казан: Казан ун-ты нәшр., 1958. 242 б.

Рамазанов Ш.А. Татар теле буенча очерклар. Казан: Татгосиздат, 1954. 200 б.

Тумашева Д.Г. Көнбатыш Себер татарларының теле: грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. 239 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 300 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965. 120 б.

Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы (морфология һәм синтаксис). Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 644 б.

Хангилдин В.Н. Татар телендә сүз ясалышы // Татар телен укыту мәсьәләләре буенча фәнни-практик конференция материаллары. Казан, 1953. Б. 108–125.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2006. 125 б.

Хисмәтуллин Х., Сайкин Ш. Татар теле грамматикасы. Казан: Таткнигоиздат, 1952. 152 б.

Шәрәфетдинова З.Г. Хәзерге татар телендә иялтемнәр. Казан: Дом печати, 2007. 208 б.

Яфаров Л. Татар теле үсештә. Казан: Таткнигоиздат, 1955.
Әхәтов Г., Иргалина Г. Татар телендә парлы сүзләр // Совет мәктәбе, 1974. №6. Б. 28–29.
Җәләй Л. Рәвеш // Совет мәктәбе, 1939. №9. Б. 41–47; 1940. №1. Б. 60–67.
Җәләй Л. Татар диалектологиясе. Казан: Татгосиздат, 1947. 134 б.
Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы. Казан, 1919. 175 б. (гарәп графикасында).
Ибраһимов Г. Татар сарыфы. Казан: Сабах, 1918. 84 б. (гарәп графикасында).
Корбан М. Терминнар һәм атамалар эшләү тәҗрибәләре // Мәгариф, 1935. №12. Б. 41–48. (латин графикасында).
Кәбүтәри Х. Тәртип җәдид мохтасар сарыф төрки. Казан, 1910. 51 б. (гарәп графикасында).
Максуди Ә.Һ. Төрки сарыфы. Казан, 1910. 48 б. (гарәп графикасында).
Мөхәммәдрәхим Ә. Төрки сарыфы. Казан: Милләт, 1909. 54 б. (гарәп графикасында).
Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан, 1895. 86 б. (гарәп графикасында).
Нугайбәк Г. Төрлек. Казан, 1911. 80 б. (гарәп графикасында).
Сираҗетдин Ә. Төрки теле. Казан, 1902. 72 б. (гарәп графикасында).
Чыгътай Г.М. Сарыф. Уфа, 1918. 49 б. (гарәп графикасында).

* * *

Адилов М. Азәрбайҹан дилиндэ синтаксик тәкрарлар. Бакы: Элм, 1974. 233 б.
Адилов М.И. Мурәккәб сөзләрин тәснифи һаггында // Учен. зап. Аз.ГУ им. С.М. Кирова.
Азымов П. Туркмен дили (сөз ясайҗы гошулмалар). Ашгабат: Туркменучпедгиз, 1950. 224 с.
Азымов П. Туркмен дилиндәки фарс сөз ясайҗылары. Ашгабат, 1947. 24 б.
Азымов П. Туркмен дилинде халларың ясалышы. Ашгабат: СССР Ылым акад. Туркм. филиал, нешыр., 1944. 18 б.
Азәрбаjчан дилинин грамматикасы. Ч.1,2. Баку : Изд-во АН Азерб. ССР, 1951–1959.
Бердиев Р. Хәзирки заман туркмен дилинде гошма сөзлер. Ашгабат: ТССР Ылым акад. нешир., 1958. 128 б.
Биишев Ә.Г. Кушма һүззәрзең язылышы // Вопросы башкирского языкознания. Уфа, 1973. Б. 177–181.
Гуломов А. Узбек тилида сүз ясаш йуллары хакида // А.С.Пушкин номидагы Тел ва адабиет институты асарлыди. Тошкент, 1949. Б. 37–87.
Доможаков Н.Г. Хакас телiнiң грамматикасы. Ч.1. Абакан: Хакасоблнациздат, 1947. 164 б.

Журабоева М. Хозирги замон узбек тилида аффиксал омонимия вә аффиксал полисемия ходисаларининг чегаранишига дойр // Науч. тр. Ташкент. ун-та. Ташкент, 1970. Вып. 362. Б. 121–127.

Исрафилова Р.Д. Азәрбајан дилиндә калка јолу илә сөз јарадычылыгы // Учен. зап. АзГУ. Сер. Язык и литература. Баку, 1970. № 5, 6. Б. 101–105.

Кенесбаев С.К. Кос сөздердщ кейбір җасалу җолдары // Учен. зап. Казах. ун-та, 1946. С. 38–45.

Киекбаев Д.Г. Башкорт теленең фонетикалы. Өфө: Башк. кит. нәшр., 1958. 212 б.

Киекбаев Җ.Г. Хәзерге башкорт теленең лексикаһы һәм фразеологияһы. Өфө: Башк. кит. нәшр., 1966. 275 б.

Маладиев Б. Хозирги узбек тилида кушма сузлар. Тошкент: Фан, 1966. 181 б.

Маматов Н. Кушма сузнинг бирикмасидан фарклари // Узб. тили вә адабиети, 1978. №5. Б. 17–20.

Маматов Н. Узбек тилида кушма сузлар. Тошкент: Фан, 1982. 236 б.

Маматов Н. Этимологик мураккаб сузлар // Узбек тили вә адабиети, 1978. № 1. Б. 7–11.

Маъруфов З. Узбек адабий тилида от ясавчи суффикслар // Тр. Узбек. фил. АН СССР. 1940. №6. Б. 38–49.

Псянчин В.М. Хәзерге башкорт телендә яңы һүззәр // Вопросы башкирского языкознания. Уфа, 1972. Б. 140–157.

Хасенова А. Казах тілинде -ла-ле аффиксе турында тубір етістіктер. Алма-Аты: Изд-во АН Каз. ССР, 1957. 83 б.

Хоҗиев А. Узбек тилида кушма, жуфт вә такрорий сузлар. Тошкент: Узбек. ССР фанлар Акад. нәшр., 1963. 148 б.

Хәзирки заман туркмен дили. Ашгабат, 1960. 552 б.

Чәфәров С. Азербајан тилиндә сөз јарадычылыгы. Бакы: АДУ нәшр., 1960. 204 б.

Чәфәров С. Мүасир азәрбајчан дили. Бакы: Азәрнәшр., 1949. 98 б.

Шукуров Ж.Ш. Кыргыз тилиндеги татаал сөздер. Фрунзе, 1955. 79 б.

Ыскаков А. Казіргі казах тили: Морфология. Алма-Ата: Мектеп, 1974. 408 б.

Узбек тили грамматикасы. Тошкент: Фан, 1975. Т. 1. Морфология. 610 б.

* * *

Atalai B. Türk dilinde ekler ve kokler userine bir deneme. İstanbul, 1941. 382 s. (на арабской графике).

Band W. Zur vergleichenden Grammatik der altaischen Sprachen Wiener Zeitschrift fur die Kunde des Morgenlandes, 1895. 9 s.

Bohtlingk O. Uber die Sprache der Jakuten: Grammatik, Text und Worterbuc. St. Pb, 1851. LIV+II+397+184 s.

Gabain F. Ozbekische Grammatik. Leipzig, 1945. 278 s.
Gabain A. Altturkische Grammatik. 2-te Aufl. Leipzig, 1950. 357 s.
Gronbech K. Der turkische Sprachbau. Kopenhagcn, 1936. 182 s.
Deny J. Grammaire de la langue turgue (dialecte osmanli). Paris, 1921. 1216 p.
Meninski F. Linguarum orientalium turcicae, arabicae, persicae, instutiones. seu Grammatika Turcica. Viennae, 1680. 216 s.
Tatar manual by Nicolas Poppe / Indiana University Publications. Vol. 25, of the Uralih and Altaic sevies Publischcd by Indiana University, 1963.
Zajaczkowski A. Suffiksy imienne i czasownikowc w jezyku zachodnikaraimskim. Krakow, 1932. 195 s.

**Сүзлекләр**

Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М.: Советская энциклопедия, 1966. 607 с.
Ахметов Г., Гимадиев М. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге. Казан: Татгосиздат, 1950. 210 б.
Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 272 б.
Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т. Диалектологик сүзлек. Казан: Татгосиздат, 1958. 260 б.
Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т., Садыйкова З.Р., Якупова Г.К. Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 644 б.
Борһанова Н.Б., Якупова Г.К. Диалектологик сүзлек. Казан: Татгосиздат, 1953. 263 б.
Вәлиди Җ. Татар теленең тулы сүзлеге. Т. 1. 2 кис. Казан, 1927–1929 (гарәп графикасында)
Воскресенский А. Русско-татарский словарь. Казань, 1894. 374 с.
Гайнетдинова А.Ф. Татар теленең исемләшкән сүзләр сүзлеге. Казан: ИЯЛИ, 2011. 172 б.
Галеев М.С., Тимергалин АК. Русча-татарча физика терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 176 б.
Ганиев Ф.Ә. Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге. Беренче кисәк (А–К). Казан: Мәгариф, 2009. 375 б.
Ганиев Ф.Ә. Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге. Икенче кисәк (Л–Я). Казан: Паравитта, 2012. 537 б.
Горохов В., Касимов А., Хангилдин В. Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге. Казан: Татгосиздат, 1950. 104 б.
Гыйззәтуллин Н. Әдәбият белеме сүзлеге. Казан: Таткнигоиздат, 1958. 229 б.
Диалектологик сүзлек. Казан: Татгосиздат, 1948. 263 б.
Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с

Закиров В.З., Муртазин З.Г. Русча-татарча математик терминнар сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 203 б.

Кошгарий М. Туркий сузлар девони: (Девону луготит турк): 3 томда. Тошкент: Узбек. ССР ФА нашр., 1960–1963.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий: в 4-х т. СПб., 1893–1905.

Русско-татарский словарь: в 4 т. Казань: Таткнигоиздат, 1955–1959.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 304 б.

Татарско-русский словарь. М.: Советская энциклопедия, 1966. 863 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977–1981.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш. ред. проф. Ф.Ә. Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. Т. 1 (А–Л). Казань: Магариф, 2007. 726 с.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. Т. 2 (М–Я). Казань: Магариф, 2007. 728 с.

Тимергалин А.К., Галиев М.С. Русча-татарча техника терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 216 б.

Хәмзин К.З., Мәхмүтов М.И., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 854 б.

## ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ


Айдар Ә.  297
Алекперов А.Г.  354, 361, 363
Алиш А.  450, 458
Алпаров Г.  7, 10, 93, 213, 218, 269, 354, 361, 375, 425
Аппакова Д.  423, 441
Архангельский А.  354, 375, 425
Архангельский Г.В.  375
Атнагулов С.  98
Ахманова О.С.  420
Ахундов Мирза Фатали  95
Ахунов Г.  178, 239, 436
Ахунҗанов Ә.М.  13
Ашмарин Н.И.  216, 311, 375, 424
Әмир М.  207, 296, 412, 414, 422, 443
Әмирхан Ф.  207, 295–297, 440, 460
Әпсәләмов Г.  178, 301, 362, 417, 422, 441, 453, 458, 460
Әфләтунов Ә.Ш.  12
Әхмәт А.  411, 459
Әхмәтҗанов М.  308
Әхмәтьянов Р.  214
Бабич Ш.  457, 460, 461
Байлиев Х.  354
Байчура Ү.Ш.  12
Бакеева Д.Х.  13
Банг В.  222, 243, 247, 250, 338, 390
Баруди Г.  92
Баскаков Н.А.  134, 216, 219, 222, 232, 234, 235, 240, 244, 247, 250, 252, 253, 309, 311, 333, 335, 339, 361, 375, 379
Батманов И.А.  335
Баян Н.
Бәдигый Х.  361, 375, 425
Бәйрәмова Л.К.
Бәширов Г.  178, 180, 216, 296, 297, 299, 302, 305, 362, 367, 370–373, 418, 423, 441, 445, 455, 456, 459, 460
Беговатов Е.А.  83, 84
Бётлингк О.  245, 311, 374, 424
Богородицкий В.А.  11, 13, 54
Бозиев А.Ю.  217
Борһанова Н.Б. (Бурганова Н.Б)  7
Бреаль  420
Брокельман К.  335
Бурнаш Ф.  213, 297, 416
Вәлиди Җамал  7, 10, 218, 354, 361, 425
Вәлиуллина З.М.  13
Велед С. Вундт  420
А. фон Габен  228, 249, 250, 375
Газизов Р.С.  13, 361
Газый И.  183, 207, 295, 304, 362, 367, 370, 411, 423, 443, 444, 452, 455–458, 460

Галәү М.  213
Гали М.  295, 297, 306, 410, 418, 419, 444, 450, 456
Ганиев Ф.А.  8, 179, 183, 421
Гарипов Т.М.  217, 234, 245, 375
Гафури М.  184, 296–298, 305, 369, 372, 414, 418, 440, 441, 446, 461
Гиганов И.  217, 269, 354, 361, 375, 425
Гобәй Г.  301, 302, 306, 369, 373, 410, 411, 421, 452, 457
Голәмев А.  213, 222, 232, 243, 313, 382, 424
Гордлевский В.А.  216, 311, 354, 375
Грунин Т.И.  375
Грунцель И.  213
Гыйззәт Т.  183, 270, 445
Гыйльман Г. 307, 308
Дәрдмәнд  207, 422
Дегтярева Т.А.  273
Дени Ж.  227, 228, 234, 245, 313
Джафаров С.  217, 225, 234–237, 244, 245, 252, 253, 311, 333, 424
Дмитриев Н.К.  213, 216, 245, 258, 268, 269, 276, 311, 346, 375, 386, 390, 424, 425, 432
Домажаков Н.Г.  375
Дыренкова Н.П.  216, 311, 354, 375, 424
Еники Ә.  178, 304, 417, 460
Җамалетдинов А.  432
Җәләй Л.  13, 213, 425
Җәлил М.  109, 295, 297, 303, 305, 371, 412, 413, 416, 419, 422, 442–445, 457, 460
Зайончковский А.  234
Зәйнуллин З.  307
Зәкиев М.З. (Закиев М.З.)  7, 13, 183, 376, 426
Зиннәтуллина К.З.  335
Зиятдинов Р.  230
Ибраһимов Г.  7, 94, 178, 180, 207, 216, 218, 269, 295, 299, 301, 305, 361, 369, 372, 373, 407, 417, 419–421, 425, 440, 443, 444, 450, 456, 459
Иванов М.  217, 361, 375, 425
Идрисов М.  91
Ильминский Н.И.  100
Исәнбәт Н.  178, 376, 452, 460
Исенгалиева В.А.  311, 312, 326, 354
Исмәгыйлев Н.  87
Искаков А.И.  354, 424, 425, 432
Исхаков Ф.Г.  12, 222, 375
Ишморат Р.  453, 458, 459
Йосыпов Ф.Й. (Юсупов Ф.Ю.)  7, 13
Казаков Е.  79
Казем-Бек А.М. (Казимбәк)  216, 269, 323, 332, 353, 361, 374, 424
Кайдаров А.Г.  268
Камал Г.  178, 296, 301, 303, 305, 410, 418, 419, 453
Камал Ш.  182, 237, 305, 368–371, 411, 413, 415–417, 426, 442, 444, 450, 452, 456, 457, 459, 461
Караханов А.Ш.  311, 375
Катанов Н.Ф.  216, 219, 237, 311, 375
Кашгарый М.  175
Кәрим Ф.  299, 413

Кенесбаев С.К. 268
Ковальский Т. 268
Колахмәтов Г. 458
Кононов А.Н. 216, 239 247, 252, 309, 311, 313, 323, 326, 328, 333, 335, 338, 354, 361, 375, 382, 425, 432
Корбангалиев М. 93, 361, 375, 425
Котвич В. 222, 313
Кочкина А.Ф. 86
Курбатов Х.Р. 7, 13, 86, 91
Латыпов А.М. 7
Ленц Э. 86
Любимов К.М. 269
Максуди Ә. 93, 94361, 425
Малов С.Е. 82
Маннур Ш. 265, 276, 415
Маутнер 420
Мәхмүдов Г. 10, 375
Мәхмүтова Л.Т. (Махмутова Л.Т.) 7, 12, 13
Мәһдиев М. 308
Мелиоранский П.М. 85, 250, 252, 311, 333, 386
Менгес К. 225
Менинский Ф. 269
Минский Г. 308, 410, 422
Миңнуллин Т. 308
Мирхәйдәров Р. 306
Мифтахов Б.М. 13
Моратов С.Н. 225, 239, 240
Мөхәммәдев Ш. 304, 414, 444
Мусаев К.М. 354
Нагаев А. 214
Насилов В.М. 250, 361
Насилов Д.М. 361
Насыйри К. 7, 10, 92, 93, 217, 269, 354, 375
Нәҗип Ә.Н. 354, 375
Нәҗми К. 301, 305
Нигъмәти Г. 423, 458
Нугайбәк Г. 10, 93, 97, 361
Оралбаева Н.О. 361
Орузбаева Б.О. 217, 309, 375
Остроумов Н. 313
Покровская Л.А. 375, 424
Поппе Н. 13
Пос 420
Радлов В.В. 11
Рамазанов Ш.А. 269, 312, 332, 333, 354
Рамстедт Г.И. 219, 227, 228, 232, 233, 237, 239, 242, 243, 247, 249, 252, 253, 313, 333, 341, 342, 382
Расих А. 182, 421
Рәмиев Мөхәммәдзакир 91
Рәмиев Мөхәммәдшакир 91
Рәмиев Сәгыйть 96
Рәхмәт Б. 441, 452
Рясенен М. 222, 239, 141, 252
Сабиров К.С. 7, 212, 214
Садвакасов Г.С. 217, 309
Салахов И. 308
Саттаров Г.Ф. 13, 80
Сәгъди Г. 88, 361, 425
Сәгыйтов М.А. (Сагитов М.А.) 7
Сәйфуллин И. 92
Сәлимов Х.Х. 13

Севортян Э.В. 184, 213, 217, 228, 232, 235, 239, 244, 245, 247, 250, 253, 311, 312, 318, 323, 325, 326, 328, 331, 333, 334, 338, 339, 341, 342, 346, 347, 349, 390–392
Соттаев А.Х. 217
Старостин П.Н. 81–83, 87
Такташ Һ. 114, 303, 368, 370, 416, 420, 443, 458
Таһири Ш. 92
Текуев М.М. 354, 361
Терентьев М. 311, 354, 375
Тинчурин К. 295
Троянский А. 217, 354, 361, 425
Тукай Г. 227, 368, 372, 450, 452, 453, 461
Тумашева Д.Г. 7, 218, 222, 269, 309, 335, 355, 375, 376, 432
Убрятова Е.И. 268
Усманов Ш. 298, 305, 371, 417–419
Фазлуллин М. 98
Фасиев Ф.С. 13, 212, 214, 218, 269, 309
Фахрутдинов Р.Г. 81
Фәйзи Ә. 227
Фәйзи М. 299, 443, 445, 452, 458
Фәйзханов Г. 7, 425
Фәйзханов Х. 375
Фәттах Н. 178, 307
Фой К. 268
Хабичев М.А. 217, 245, 253, 309, 375, 386
Хаков В.Х. 7, 13, 81
Хангилдин В.Н. (Хангильдин В.Н.) 7, 218, 232, 248, 269, 309, 333, 335, 354, 361, 375, 432
Харитонов Л.Н. 216, 250, 424
Харитонов Н. 91, 311, 375
Хасенова А.К. 313, 323, 326
Хәлфин И. 6, 7, 10
Хәсәнов А. 84
Хортен М. 323
Хөснетдинов Р.Р. 81
Хөсни Ф. 458
Хуҗи Г. 442
Һадиев И. 307
Шакирова Ф. 11
Шамов А. 183, 227, 301, 303, 305, 414, 441–443, 445, 460
Шәрәф Г. 11, 91, 94
Шипова Е.Н. 309
Шотт В. 213
Шукуров Ж.Ш. 268
Щербак А.М. 375
Юлдашев Ә.Ә. 13, 354
Янски Г. 323
Ярикәй Ә. 302
Ястремский С.В. 311, 375
Яфаров Л.И. 13

## ТЕРМИННАР КҮРСӘТКЕЧЕ


- аббревиатуралар (кыскартылмалар) 200, 211
    - инициаль кыскартылмалар 200, 201, 211
    - элементлы кыскартылма сүзләр 200, 211
- аббревиация (к. сүзьясалыш ысуллары) 200
- абсолют ачык иҗек (к. иҗек) 23
- абстракт исемнәр белдерә торган кушымчалар (к. кушымчалар)
- аваз 10, 14–42, 69
    - аваз иялтемнәренең редупликациясе 156
    - аваз койнесе 13
    - аваз тезмәләре 13
    - аваз үзгәрешләре 31
        - аккомодация 31, 34
        - ассимиляция 28, 31
        - диссимиляция 31, 34
        - комбинатор 31
        - позицион 31
    - аваз яки авазлар чиратлашу алымы (к. сүзьясалыш ысуллары) 213
    - аваз яки авазларның төшеп калу алымы (к. сүзьясалыш ысуллары) 212
    - авазлар системасы 10
    - авазларның акустик билгеләре 11, 19
        - тон һәм шау катнашу ягыннан 19
        - озынлык 19
        - тембр 19
        - сузыкларның акустик билгеләре 18, 19
        - тартыкларның акустик билгеләре 18, 19
    - авазларның артикуляцион билгеләре 15
    - авазның озынлыгы 11, 17–20

авазның спектры 11, 17–19
авазның тембры 11, 17–19
авазның югарылыгы 11, 18–20
авыл койнесе 106
адвербиализация (к. рәвешләр ясалышы) 439
аерым иске төрки әдәби телләр 96
аз продуктивлы кушымчалар (к. кушымчалар)
академик грамматика 5, 7
аккомодация 31
сузыклар аккомодациясе 31
тартыклар аккомодациясе 31
акустик аспект 14
алгы рәт (к. сузык авазлар)
алломорф 133, 137
аллофон 44–47
комбинатор аллофоннар 46
позицион аллофоннар 45–47
алфавит 69–89
гарәп алфавиты 69, 100
латин алфавиты 69, 95, 97, 100
рус алфавиты 69, 100
алынма кушымчалар (к. кушымчалар)
алынма сүзләр (алынмалар) 108, 178, 262
аналитик (кушма) сүзләр 204
куш (парлы) сүзләр 204, 206, 273, 278
саф кушма сүзләр 204
тезмә сүзләр 204
антонимик мәгънә 277
антонимия 171
аңкау гармониясе (к. сингармонизм)
апокопия 40
артикуляцион аспект (к. биологик аспект) 15
арткы рәт (к. сузык авазлар)

ассимиляция 28, 30–33
акустик ассимиляция 31, 33
арадаш (дистактлы) ассимиляция 31, 33
борын ассимиляциясе 31, 33
диахроник ассимиляция 31, 33
ирен ассимиляциясе 31, 33
кире (регрессив) ассимиляция 30–33
өлешчә ассимиляция 31, 33
синхроник ассимиляция 31, 33, 34
сузыклар ассимиляциясе 31, 33
тартыклар ассимиляциясе 30, 32, 33
тулы ассимиляция 30, 32, 33
туры ассимиляция 30, 32, 33
увуляр ассимиляция 30
янәшә (контактлы) ассимиляция 30
ясалу урыны буенча охшашлану 31
атрибутив бәйләнеш 193, 280, 289
аффикслар (кушымчалар) 129, 153
аффрикатлар (к. тартык авазлар)
ачык иҗек (к. иҗек)
әдәби әйтелеш 105
басма хәрефләр (к. хәрефләр)
басым (к. сүз басымы)
басым күчү алымы (к. сүзьясалыш ысуллары)
басымның вариантивлыгы (к. сүз басымы)
баш хәрефләр (к. хәрефләр)
бер фокуслы (к. тартык авазлар)
биологик аспект 14
борын ассимиляциясе (к. ассимиляция)
борын тартыклары (к. тартык авазлар)
борынгы уртак төрки әдәби тел 88
бөтенлек 207
бугаз тартыгы (к. тартык авазлар)

велярлашу 47
гади кушымчалар (к. кушымчалар)
гади сөйләм 39
гарәп алфавиты (к. алфавит)
гарәп хәрефләре (к. хәрефләр)
гомумхалык теле 88
грамматик категория 173
грамматик кушымчалар (к. кушымчалар)
грамматик күренеш 127, 171
грамматик мәгънә 127, 171
грамматик формалар 127, 180
грамматик формант 174, 195
грамматик чара 173, 183
грамматик эчтәлек 8
грамматика 5
график принцип 74
графика 6, 69
    рус графикасы 100
дәүләт теле – татар теле 101
диалекталь сөйләш 178
диалекталь сүзләр 16, 37, 178
диахроник ассимиляция (к. ассимиляция)
диахрония 144
дистактлы ассимиляция (к. ассимиляция)
диссимиляция 34
    кире диссимиляция 34
    туры диссимиляция 34
дифтонг 23, 26, 28, 70
    күтәрелмә дифтонглар 17, 18, 23, 26, 28
    төшерелмә дифтонглар 26, 28
    ялган дифтонглар 28
дифтонгоид 14, 23
дифференциаль билгеләр 44, 47

сузык фонемаларның дифференциаль билгеләре 44
тартык фонемаларның дифференциаль билгеләре 47
дифференциацияләнгән язылыш 74
диэреза 40
зат исемнәрен белдерә торган кушымчалар (к. кушымчалар)
иҗек 24, 40
абсолют ачык иҗек 24, 41
ачык иҗек 24, 41
иҗек калыплары 41
ябык иҗек 41
ярымачык иҗек 24, 41
ике компонентлы аваз ияртеме 274, 454
ике фокуслы тартыклар (к. тартык авазлар)
инициаль кыскартылмалар (к. аббревиатуралар)
интенсивлык (к. интонация)
интерфикслар 129, 243, 385
интонация 22, 60, 103
коммуникатив аспекты 60
эмоциональ аспекты 60
мелодика 60, 61, 64
интенсивлык 60
озынлык 60, 61
сөйләм темпы 60
паузалар 60, 103
интонация чаралары 60
сүз басымы 60
логик басым 60
фраза басымы 62
ирекле сүзтезмәләр 207, 208
ирен ассимиляциясе (к. ассимиляция)
ирен гармониясе (к. сингармонизм)
ирен-ирен тартыклары (к. тартык авазлар)
ирен-теш тартыклары (к. тартык авазлар)

иренләшү  15, 20, 148
иске азәрбайҗан теле  90
иске имла (к. орфография)
иске татар теле  80
иске төрек теле  82
иске төркмән теле  80
иске уйгур теле  88
иске уртак төрки әдәби теле  80
иске үзбәк теле  80
йомык тартыклар (к. тартык авазлар)
йөкләтү юнәлеше формалары  348
казан диалекты  80, 106
кайтым юнәлеше формалары  271, 389
калтыраулы тартыклар (к. тартык авазлар)
калын нигезләр  16
калын сузыклар (к. сузык авазлар)
калын пар сузыклар (к. сузык авазлар)
калькалашу  286
категория  258, 311
койне  106
комбинатор үзгәрешләр  30, 31, 33
    аккомодация  30, 31, 33
    диссимиляция  30, 31, 33
комплетив бәйләнеш  206
компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы (к. сүзьясалыш ысуллары)
компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы (к. сүзьясалыш ысуллары)
компонентлары объект бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы (к. сүзьясалыш ысуллары)
компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы (к. сүзьясалыш ысуллары)
компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы (к. сүзь-

ясалыш ысуллары)
конверсия (к. сүзьясалыш ысуллары)
конститутив билгеләр  44
    чагыштыргысыз билгеләр  44
    чагыштырмалы билгеләр  44
контактлы ассимиляция (к. ассимиляция)
көнбатыш диалекты  106
көч басымы  54
көчле фонема (к. фонема)
көчсез фонема (к. фонема)
кулъязма хәрефләр (к. хәрефләр)
куш (парлы) сүзләр (к. аналитик (кушма) сүзләр)
кушма кушымчалар (к. кушымчалар)
кушма сүзләр  32, 37
кушма сүзформа  206
кушма сүзләр ясалышы (к. сүзьясалыш ысуллары)
кушма фигыльләр  353
кушымчалар  128, 216
    абстракт исемнәр белдерә торган кушымчалар 218
    алынма кушымчалар 262, 399
    гади кушымчалар  191, 218
    грамматик кушымчалар  173, 179–181
    зат исемнәрен белдерә торган кушымчалар  218
    кушма кушымчалар  191, 218
    нигезеннән аерылмый торган кушымчалар  265, 352, 398
    омокушымчалар  186
    полисемантик кушымчалар  185, 186, 253
    полифункциональ кушымчалар  180, 186, 253, 380
    предмет исемнәрен белдерә торган кушымчалар  189, 218, 387
    продуктив булмаган (аз продуктивлы) кушымчалар  189, 239, 387
    продуктив кушымчалар  189, 313
    синоним кушымчалар  188
    стилистик кушымчалар  178, 180, 228

сүз бәйләгеч кушымчалар 180, 192
сүзьясагыч кушымчалар 128, 179, 180, 191
алмашлык ясагыч кушымчалар 218
бәйлек ясагыч кушымчалар 218
исем ясагыч кушымчалар 186, 218
рәвеш ясагыч кушымчалар 186
сыйфат ясагыч кушымчалар 186, 376
фигыль ясагыч кушымчалар 186
телнең үзенеке булган кушымчалар 262
тере кушымчалар 180
үле (нигездән аерылмый торган) кушымчалар 265
форма ясагыч кушымчалар 180
хәзерге көндә сүз ясамый торган кушымчалар 262, 336, 429
хәзерге көндә сүз ясый торган кушымчалар 219, 262, 336, 425
юнәлеш кушымчалары 129, 153, 238
кушымчалау ысулы (к. сүзьясалыш ысуллары)
кушымчалы сүзләр 204
күләм редукциясе (к. редукция)
күп компонентлы аваз ияртемнәре 274, 453
күтәрелмә дифтонглар (к. дифтонглар)
кыска сузыклар (к. сузык авазлар)
кыскартылма сүзләр (к. аббревиатуралар (кыскартылмалар))
лабиализация (к. иренләшү)
ларингаль тартыклар (к. тартык авазлар)
латин алфавиты (к. алфавит)
лексик берәмлек 174–178
лексик мәгънә 174–178, 183, 207
лексик-грамматик ысул (к. сүзьясалыш ысуллары)
лексик-семантик ысул (к. сүзьясалыш ысуллары)
лексика 174–178
лексикология 5, 171
лингвистик аспект 5
лингвистик дисциплина 174

лингвистика  174
логик басым (к. интонация)
логик-синтаксик бәйләнеш  6
логика  6, 290
мәгънә  10, 11
мелодика (к. интонация)
метатеза  35
метафорик мәгънә  336, 406
минималь дифференциация  35
модальлек  123
модальлек мәгънәсе  123
модификация  366
модификацияләүче (ярдәмче) фигыльләр  310, 361, 365, 366
морф  123, 127
морфема  26, 123, 131
морфемика  6, 123–124
морфологик интерпретация  316
морфологик принцип  73
морфология  5, 123, 171
морфонема  138, 150–151
    морфонема моделе  150–155, 161
    сузык морфонема  148, 150–161
    тартык морфонема  151–161
морфонологик күренешләр  155, 160, 161
    асемантик фонема ялгану  159–161
    нигез кыскару 140, 159–161
    фонемалар керешү 141, 146, 159–161
    фонемалар чиратлашу 139, 141, 148, 159–161
морфонология  6, 137, 138, 160
мөстәкыйль фигыльләр  311
нейтральләшү  16
нечкә нигезләр  16
нечкә пар сузыклар (к. сузык авазлар)

нечкә сузыклар (к. сузык авазлар)
нигез кыскару (к. морфонологик күренешләр)
нигезеннән аерылмый торган кушымчалар (к. кушымчалар)
нигезләр кушылу ысулы (к. сүзьясалыш ысуллары)
нуль фонема 129, 143
нуль форма (нуль морф, нуль кушымча) 129–130
обертон (к. өстәмә тон)
объект бәйләнеше 206
озын сузыклар (к. сузык авазлар)
озынлык (к. интонация)
омограф 186
омокушымчалар (омосуффикслар) (к. кушымчалар)
омонимия 171, 182, 185
ономастика 6, 81
Орхон-Енисей язмалары 79
орфография 72
    иске орфография (иске имла) 73, 91
    рус орфографиясе 73, 100, 101
    татар орфографиясе 73, 100
    яңалиф орфографиясе 73, 96, 97, 100, 101
орфоэпия 103
өлешчә редукция (к. редукция)
өрелмәле тартык (к. тартык авазлар)
өстәмә басым (к. сүз басымы)
өстәмә тон 662, 63
өч компонентлы аваз ияртеме 454
палатальләшү 22, 212, 214
пауза (к. интонация)
позицион аваз үзгәрешләре 38
    апокопия 38
    диэреза 38
    метатеза 38
    протеза 38

редукция 38
сузыкларда позицион үзгәрешләр 38
тартыкларда позицион үзгәрешләр 38
эпентеза 38
эпитеза 38
позицион аллофоннар (к. аллофон)
полисемантик кушымчалар (к. кушымчалар)
полифункциональ кушымчалар (к. кушымчалар)
предикатив (хәбәрлек) бәйләнеш 195, 206, 288
предмет исемнәрен белдерә торган кушымчалар (к. кушымчалар)
продуктив булмаган (аз продуктивлы) кушымчалар (к. кушымчалар) продуктив кушымчалар (к. кушымчалар)
продуктив ысул (к. сүзьясалыш ысуллары)
проклитика 57
просодика 10, 54
интенсивлык 54, 63
озынлык 54, 63
пауза 54, 63
тембр 54, 63
тон югарылыгы 54, 63
протеза 38
регрессив ассимиляция (к. ассимиляция)
редукция 39
күләм редукциясе 39
өлешчә редукция 39
тулы редукция 39
редупликация 155–157, 436
ритмик басым 60
рун язуы 79
рус алфавиты (к. алфавит)
рус графикасы (к. графика)
рус орфографиясе (к. орфография)
сандхи 32, 33

саңгырау тартыклар (к. тартык авазлар)
саф кушма сүзләр (к. аналитик (кушма) сүзләр)
семиотика 6
семасиология 172
сингармонизм 23, 30–33
рәт гармониясе 30, 31
ирен гармониясе 30–32
синонимия 171
синоним кушымчалар (к. кушымчалар)
синтагма 62, 124
синтагма басымы (к. фраза басымы) 62
синтаксис 5, 171
синтаксик бәйләнеш 180, 287
синтетик (гади) сүзләр 203
тамыр сүзләр 203
кушымчалы сүзләр 202, 204
синхроник ассимиляция (к. ассимиляция)
синхрония 144
сонантлар (к. тартык авазлар)
сонор (к. тартык авазлар)
сөйләм аппараты 18
сөйләм темпы (к. интонация)
сөйләм яссылыгы 18
сөйләшү стиле 100
стилистик кушымчалар (к. кушымчалар)
стилистика 172
сузык авазлар 15, 22, 24–30
алгы рәт сузыклары 15–17, 23, 45
арткы рәт сузыклары 15–17, 23, 45
ирен-ирен ярым сузыгы 16
иренләшкән сузыклар 16
иренләшмәгән сузыклар 16
калын пар сузыклар 15–17, 20

калын сузыклар  15, 16, 20
кыска сузыклар  16–19
нечкә пар сузыклар 15–17
нечкә сузыклар  15–17
озын сузыклар  16, 20, 35
түбән күтәрелеш сузыклары  16
урта күтәрелеш сузыклары  16
югары күтәрелеш сузыклары  16
ярым сузыклар  16
сузык морфонема (к. морфонема)
сузылмалы фокуслы (к. тартык авазлар)
суффикслар (кушымчалар)  129
сүз 5, 10, 25, 123, 171
сүз басымы  54, 55
басымның вариативлыгы  54, 55, 57
басымның функцияләре  54, 57
өстәмә басым  54, 55, 57
проклитика  54, 57
энклитика  54, 57
сүз бәйләгеч кушымчалар (к. кушымчалар)
сүзләр кушылу ысулы (к. сүзьясалыш ысуллары)
сүзләрнең сүзьясалыш структурасы  201
сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе (сүзтезмәнең лексикализациясе) (к. сүзьясалыш ысуллары)
сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе (к. сүзьясалыш ысуллары)
сүзформа 124, 180
сүзьясагыч кушымчалар (к. кушымчалар)
сүзьясагыч мәгънә  185
сүзьясагыч чара  179
сүзьясалыш типлары  179, 191
сүзьясалыш типларының модельләре  179, 191, 220
сүзьясалыш ысуллары  179, 192
аббревиация (кыскартылмалар ясалышы)  200

конверсия (лексик-грамматик ысул) 179, 197, 408, 414, 439, 450, 451, 455, 459, 460
кушымчалау ысулы 179, 311, 374, 447, 451, 455
лексик-семантик ысул 197, 200, 309, 373
продуктив ысул 270
сүзләр кушылу ысулы (кушма сүзләр ясалышы) 192
компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы 193, 280
компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы 193, 280, 353, 448
компонентлары объект бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы 194, 286
компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы 193, 286, 353, 450
компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр ясалышы 194, 286
нигезләр кушылу 179, 192, 400
сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе (сүзтезмәнең лексикализациясе) 194, 405, 435, 438
сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе 195, 400, 435
фонетик ысул 10, 179, 310, 374, 424
аваз яки авазларның төшеп калу алымы 179
аваз яки авазларның чиратлашу алымы 179
басым күчү алымы 179, 215
нигез палатальләшүе (нечкәрүе) 179
сүзьясалышы 5, 171
алмашлыклар ясалышы 447
алмашлыкларның кушымчалау ысулы белән ясалышы 447
компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма алмашлыклар ясалышы 448
компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма алмашлыклар ясалышы 450
конверсия ысулы белән алмашлыклар ясалышы 450

бәйлекләр ясалышы 454
конверсия ысулы белән бәйлекләр (бәйлек сүзләр) ясалышы 455
кушымчалау ысулы белән бәйлекләр ясалышы 455
исемнәр ясалышы 212, 268
исемнәрнең фонетик ысул белән ясалышы 212
аваз яки авазларның төшеп калу алымы 212, 213
аваз яки авазларның чиратлашу алымы 212
басым көчү алымы 212, 215
нигезнең палатальләшүе (нечкәрүе) 212, 214
конверсия ысулы белән исемнәр ясалышы 294
кушма исемнәр ясалышы 268
нигезләр кушылу ысулы белән кушма исемнәр ясалышы 268
компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылу юлы белән кушма исемнәр ясалышы 268
ияртүле бәйләнештә булган компонентлары кушылып кушма исемнәр ясалышы 270, 280
атрибутив бәйләнештә булган компонентлар кушылып кушма исемнәр ясалышы 280
объект бәйләнешендәге компонентлар кушылып кушма исемнәр ясалышы 286
хәл бәйләнешендәге компонентлар кушылып кушма исемнәр ясалышы 286
атрибутив сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе 286
компонентлары объект бәйләнешендәге сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе 292
компонентлары хәл бәйләнешендәге сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе 206
предикатив сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе 288
сүзтезмәләрнең, кушымчалар алып, кушма сүзгә күчүе 288
сүзтезмәләрнең лексикалашу юлы белән кушма исемнәр ясалышы 287
кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышы 216, 287
лексик-семантик ысул белән исемнәр ясалышы 309

исемнәрнең фонетик ысул белән ясалышы 268
ияртемнәр ясалышы 453
кисәкчәләр ясалышы 459
конверсия ысулы белән кисәкчәләр ясалышы 459, 460
рәвешләр ясалышы 424
конверсия ысулы белән рәвешләр ясалышы (адвербиализация) 435, 439
кушымчалар ярдәмендә рәвешләр ясалышы 435
сүзтезмәләрнең, кушымча алып, кушма рәвешкә күчүе 435
тезүле бәйләнештәге компонентлар кушылып куш рәвешләр ясалышы 435
фонетик ысул белән рәвешләр ясалышы 424
хәл сүзтезмәләренең лексикалашу юлы белән кушма рәвешләр ясалышы 438
саннар ясалышы 446
сыйфатлар ясалышы 374
компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сыйфатлар ясалышы 406
компонентлары тезүле бәйләнештә булган сыйфатлар ясалышы 400
конверсия ысулы белән сыйфатлар ясалышы (адективизация) 408
кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышы 374
сүзтезмәләрнең кушымча алып кушма сыйфатларга күчүе 407
сүзтезмәләрнең лексикалашу ысулы белән кушма сыйфатлар ясалышы 405
фонетик ысул белән сыйфатлар ясалышы 374
теркәгечләр ясалышы 461
фигыльләр ясалышы 353
ияртүле бәйләнештә булган компонентлар кушылып кушма фигыльләр ясалышы 311
кушымчалау ысулы белән фигыльләр ясалышы 311
лексик-семантик ысул белән фигыльләр ясалышы 373
тезүле бәйләнештә булган компонентлар кушылып (куш (парлы)) фигыльләр ясалышы 353

фонетик ысул ярдәмендә фигыльләр ясалышы 310
ымлыклар ясалышы 451
конверсия ысулы белән ымлыклар ясалышы 451
сүзләр кушылу ысулы белән ымлыклар ясалышы 451
тавышның көче (к. интенсивлык)
тамыр 127, 203
тамыр сүзләр (к. синтетик (гади) сүзләр)
тарихи-традицион принцип 73
тартык авазлар 16–19, 22–27, 114, 115
аффрикат 14, 15, 17–19
бер фокуслы 17–19, 36
борын 17–20, 25–28, 36
бугаз (ларингаль) 14, 17–20, 36, 37
ике фокуслы 17–19, 36, 37
ирен-ирен 16–22, 28, 29, 36, 37, 115
ирен-теш 16–22, 28, 29, 36, 37, 115
йомык 17–19, 115
калтыраулы 17–22, 28, 29, 36, 37
өрелмәле 16–19
саңгырау 16–19, 100, 117
сонант (сонор) 18–23, 27
сузылма фокуслы 18, 19
тел алды 17–20
тел арты 17–20
тел уртасы 17–20
увуляр (кече тел) 17–22, 28, 29, 36, 37
фарингаль (йоткылык) 17–19
шаулы 17–20
ярымйомык 17–20
яңгырау 17–19
тартык морфонемалар (к. морфонемалар) 151, 158
татар орфографиясе (к. орфография) 69
тезмә сүзләр (к. аналитик (кушма) сүзләр) 206

тезмә фигыль  360
тезүле бәйләнеш  193
тел 5, 18–22
тел алды тартыклары (к. тартык авазлар)
тел арты тартыклары (к. тартык авазлар)
тел уртасы тартыклары (к. тартык авазлар)
тере кушымчалар (к. кушымчалар)
тон 19, 20
тон югарылыгы (к. просодика)
төп тон  19, 60, 64
төшем юнәлеш формалары  433
төшерелмә дифтонглар (к. дифтонглар)
трифтонглар  28
тулы ассимиляция (к. ассимиляция)
тулы редукция (к. редукция)
увуляр ассимиляция (к. ассимиляция)
увуляр (к. тартык авазлар)
урта диалект  104
урта имла  94, 99
үле (нигездән аерылмый торган) кушымчалар (к. кушымчалар)
фигыль формалары  304, 353
фикер  5
фольклор  103
фольклор теле  103
фонема  43, 69, 70, 146
    дифференциаль билге  44
    конститутив билге  44
    көчле фонема  43
    көчсез фонема  43
    максималь дифференциация позициясе  44
    минималь дифференциация позициясе  43
    нейтральләшү  43
    чагыштырмалы билге  44

фонемалар керешү (к. морфонологик күренешләр)
фонемалар чиратлашу (к. морфонологик күренешләр)
фонетик принцип 72, 96
фонетик ысул (к. сүзьясалыш ысуллары)
фонетика 6, 10
фонология 10, 138
форма ясагыч кушымчалар (к. кушымчалар)
формант 20, 21
фразеологик берәмлекләр 209
фразеология 209
хәбәрлек 288, 450
хәбәрлек мәгънәсе 288
хәзерге көндә сүз ясамый торган кушымчалар (к. кушымчалар)
хәзерге көндә сүз ясый торган кушымчалар (к. кушымчалар)
хәзерге татар (милли) әдәби теле 104
хәл бәйләнеше 194, 286
хәрефләр 69
басма хәрефләр 69, 75
баш хәрефләр 69, 77
гарәп хәрефләре 69, 91
кульязма хәрефләр 69
хезитация 63
шау 19–21
шаулы тартык (к. тартык авазлар)
шәһәр койнесе 100
элементлы кыскартылма сүзләр (к. аббревиатуралар (кыскартылмалар))
элизия 23
энклитика 38, 57
эпентеза 38
эпитеза 38
этимология 171, 348
этногенез 6
этноним 6

юнәлеш кушымчалары (к. кушымчалар)
ябык иҗек (к. иҗек)
язма-китаби стиль  103
яңалиф орфографиясе (к. орфография)
ярдәмлек морф  127, 131
ярымачык иҗек (к. иҗек)
ярымйомык тартыклар (к. тартык авазлар)

## КУШЫМЧАЛАР (МОРФЛАР) КҮРСӘТКЕЧЕ

Күрсәткечтә бары ясалма сүзләрне хасил итә торган сүзьясагыч морфлар гына бирелә.

Омонимнар булып торган һәм матди яктан туры килә торган кушымчалар аерым күрсәтелә.

Барлык кушымчалар да алфавит тәртибендә бирелә.


| | | |
|---|---|---|
| -а/-ә | ис. | 251 |
| -а/-ә$_2$ | сф. | 392 |
| -а/-ә$_3$ | фг. | 339 |
| -а/-ә$_4$ | рәв. | 431 |
| -а | алм. | 447 |
| -авыл/-выл | ис. | 250 |
| -авыт | ис. | 267 |
| -агай/әгәй | ис. | 253 |
| -аган | ис. | 260 |
| -ай/-әй | ф. | 144 |
| -ай/-әй | сф. | 396 |
| -ай/-әй$_1$ | ис. | 260 |
| -ай/-әй, -й$_2$ | ф. | 341 |
| -ак/-әк, -к$_1$ | ис. | 235 |
| -ак/-әк, -к$_2$ | ис. | 242 |
| -ак/-әк, -к$_3$ | сф. | 391 |
| -ак/-әк$_4$ | фг. | 351 |
| -акса/-әксә | ис. | 253 |
| -ал/-әл, -л | фг. | 342 |
| -ала/-әлә | фг. | 348 |
| -ала | рәв. | 431 |

| | | |
|---|---|---|
| -алак/-әләк | ис. | 252 |
| -ам/-әм | сф. | 395 |
| -ама | ис. | 262 |
| -ан/-ән, -н | ис. | 246 |
| -ан/-ән, $-н_1$ | сф. | 391 |
| -ан/-ән, $-н_2$ | фг. | 347 |
| -ана/-әнә | ис. | 256 |
| -анак/-әнәк | ис. | 252 |
| -анак/-әнәк | сф. | 397 |
| -ар | ис. | 262 |
| -ар/-әр, -р | ф. | 150, 313 |
| -арла/-әрлә | фг. | 342 |
| -ас/-әс | сф. | 395 |
| -ат/-әт | фг. | 336 |
| -ата | рәв. | 431 |
| -ач/-әч | сф. | 396 |
| -ача | ис. | 262 |
| -аш/-әш, -ш | ис. | 266 |
| -ау/-әү | сф. | 398 |
| -әбәт | ис. | 261 |
| -әзә | ис. | 259 |
| $-әк_5$ | рәв. | 431 |
| -әләк | сф. | 398 |
| -әнтә | ис. | 267 |
| -әшә | рәв. | 431 |
| -ба | ис. | 267 |
| -быз | ис. | 267 |
| -бык/-бек | ис. | 267 |
| -берек | сф. | 398 |
| -быр | сф. | 399 |
| -бәгәй | рәв. | 431 |
| -вар | фг. | 352 |
| -вык/-век | ис. | 188 |

| | | |
|---|---|---|
| -вык/-век | сф. | 385 |
| -га/-гә (-ка/-кә)$_1$ | ис. | 123, 244 |
| -га/-гә (-ка/-кә)$_2$ | фг. | 338 |
| -га/-гә (-ка/-кә) | рәв. | 433 |
| -гай | ис. | 253 |
| -гай | сф. | 399 |
| -гәй/-гәй (-кәй/-кәй) | ис. | 253 |
| -гай/-гәй (-кай/-кәй) | сф. | 390 |
| -гак/-гәк (-как/-кәк)$_1$ | ис. | 243 |
| -гак/-гәк (-как/-кәк)$_2$ | сф. | 389 |
| -галак/-гәләк (-калак/-кәләк) | ис. | 240 |
| -галак/-гәләк (-калак/-кәләк) | сф. | 397 |
| -ган/-гән (-кан/-кән)$_1$ | ис. | 247 |
| -ган/-гән (-кан/-кән)$_2$ | фг. | 352 |
| -ганак/-гәнәк (-канак/-кәнәк) | ис. | 240 |
| -гар/-гәр (-кар/-кәр)$_1$ | ис. | 265 |
| -гар/-гәр (-кар/-кәр)$_2$ | фг. | 346 |
| -гач/-гәч (-кач/-кәч) | ис. | 261 |
| -гач/-гәч (-кач/-кәч) | сф. | 390 |
| -гы/-ге (-кы/-ке)$_1$ | ис. | 189, 236 |
| -гы/-ге (-кы/-ке)$_1$ | сф. | 134, 153, 383 |
| -гы/-ге (-кы/-ке)$_2$ | фг. | 337 |
| -гыз/-гез | ис. | 267 |
| -гыз/-гез (-кыз/-кез) | фг. | 346 |
| -гый | ис. | 367 |
| -гыл/-гел (-кыл/кел) | ис. | 189, 259 |
| -гылт/-гелт (-кылт/-келт) | сф. | 398 |
| -гын/-ген (-кын/-кен) | ис. | 245 |
| -гын/-ген (-кын/-кен)$_1$ | сф. | 390 |
| -гын/-ген (-кын/-кен)$_2$ | фг. | 347 |
| -гынак/-генәк | рәв. | 430 |
| -гыр/-гер (-кыр/-кер)$_2$ | ис. | 265 |
| -гыр/-гер (-кыр/-кер)$_1$ | сф. | 389 |

| | | |
|---|---|---|
| -гыр/-гер (-кыр/-кер)$_3$ | фг. | 346 |
| -гыра | ис. | 254 |
| -гысыз/-гесез (-кысыз/-кесез) | сф. | 396 |
| -гыч/-геч (-кыч/-кеч) | ис. | 188, 192, 232 |
| -гыч/-геч (-кыч/-кеч)$_1$ | сф. | 386 |
| -гыш | ис. | 267 |
| -гә | алм. | 447 |
| -гәш | фг. | 353 |
| -да/-дә (-та/-тә) | фг. | 330 |
| -да/-дә (-та/-тә) | рәв. | 434 |
| -да | алм. | 447 |
| -дак/-дәк (-так/-тәк) | ис. | 254 |
| -дам/-дәм | сф. | 393 |
| -дан/-дән (-тан/-тән) | рәв. | 434 |
| -дан | алм. | 447 |
| -дар | ис. | 264 |
| -дар/-дәр | сф. | 396 |
| -дар/-дәр (-тар/-тәр) | фг. | 349 |
| -даш/-дәш (-таш/-тәш) | ис. | 172, 225 |
| -даш/-дәш | сф. | 386 |
| -дез | рәв. | 431 |
| -дыз | ис. | 267 |
| -дык/-дек (-тык/-тек)$_1$ | ис. | 241 |
| -дык/-дек (-тык/-тек)$_3$ | сф. | 387 |
| -дыклы/-декле | сф. | 388 |
| -дыр | сф. | 399 |
| -дыр/-дер (-тыр/-тер) | фг. | 336 |
| -дыр/-дер | алм. | 126, 448 |
| -дырак | ис. | 267 |
| -дырык/-дерек (-тырык/-терек) | ис. | 239 |
| -дә | ис. | 266 |
| -дәл | ис. | 255 |
| -дәмә | ис. | 259 |

| | | |
|---|---|---|
| -ел/-әл | сф. | 395 |
| -жай | фг. | 353 |
| -җа/-җә | ис. | 266 |
| -җы/-җе | фг. | 350 |
| -җын | ис. | 267 |
| -җыра/-җерә | фг. | 353 |
| -задә | ис. | 263 |
| -и/-ый | ис. | 264 |
| -ин | ис. | 264 |
| -ина | ис. | 264 |
| -ка/-кә$_1$ | ис. | 132, 185, 188, 190, 258 |
| -ка/-кә$_2$ | сф. | 394 |
| -кай/-кәй | фг. | 350 |
| -кал | ис. | 267 |
| -канак | сф. | 397 |
| -кет | фг. | 351 |
| -кыл/-кел | сф. | 395 |
| -кым/-кем | ис. | 255 |
| -кыт/-кет | ис. | 267 |
| -кыш | сф. | 398 |
| -кү | сф. | 395 |
| -ла/-лә$_2$ | ис. | 260 |
| -ла/-лә | фг. | 204, 314 |
| -ла/-лә$_3$ | рәв. | 430 |
| -лай/-ләй$_1$ | ис. | 260 |
| -лай$_2$ | фг. | 352 |
| -лай/-ләй$_3$ | рәв. | 429 |
| -лай/-ләй$_3$. | алм. | 448 |
| -лак/-ләк | ис. | 249 |
| -лама | ис. | 262 |
| -лан/-лән$_1$ | ис. | 266 |
| -лан/-лән$_2$ | фг. | 318 |

| | | |
|---|---|---|
| -ландыр/-ләндер | фг. | 322 |
| -лап/-ләп | рәв. | 427 |
| -лар/-ләр | ис. | 231 |
| -лат/-ләт | фг. | 328 |
| -лата/-ләтә | рәв. | 427 |
| -латып/-ләтеп | рәв. | 428 |
| -лаш/-ләш$_1$ | фг. | 324 |
| -лаш/-ләш$_2$ | рәв. | 430 |
| -лаш/-ләш | бәйл. | 455 |
| -лаштыр/-ләштер | фг. | 172, 326 |
| -лач | ис. | 261 |
| -лач/-ләч$_2$ | сф. | 387 |
| -лектән | алм. | 447 |
| -лы/-ле | ис. | 226 |
| -лы/-ле | сф. | 128, 171, 183, 376 |
| -лы/-ле | бәйл. | 183, 455 |
| -лый/-ли | рәв. | 429 |
| -лык/-лек$_1$ | ис. | 172, 173, 181, 221 |
| -лык/-лек$_2$ | фг. | 349 |
| -лык/-лек$_1$ | сф. | 189, 380 |
| -лык$_1$ | алм. | 448 |
| -лылык/-лелек | ис. | 230 |
| -ләк | сф. | 399 |
| -ләп | алм. | 447 |
| -лҗым/-лҗем | сф. | 397 |
| -ма/-мә$_1$ | ис. | 188, 189, 233 |
| -ма/-мә$_1$ | сф. | 384 |
| -ма/-мә$_2$ | фг. | 350 |
| -ма/-мә$_3$ | рәв. | 430 |
| -май/-мәй | ис. | 267 |
| -май/-мәй | фг. | 353 |
| -мак/-мәк | ис. | 247 |
| -мак | сф. | 399 |

| | | |
|---|---|---|
| -макай | сф. | 398 |
| -макай/-мәкәй (-магай/-мәгәй) | сф. | 390 |
| -малы/-мәле | сф. | 384 |
| -ман/-мән | ис. | 256 |
| -мар/-мәр | ис. | 255 |
| -мач/-мәч | ис. | 265 |
| -маш | фг. | 350 |
| -ме | алм. | 447 |
| -мса/-мсә | сф. | 393 |
| -мтәл | сф. | 397 |
| -мык/-мек$_1$ | ис. | 266 |
| -мык/-мек$_2$ | фг. | 352 |
| -мыр/-мер$_1$ | ис. | 255 |
| -мыр/-мер$_2$ | фг. | 353 |
| -мыр/-мер | сф. | 396 |
| -мыш/-меш | ис. | 248 |
| -мәкәр | сф. | 397 |
| -мәт | ис. | 267 |
| -на/-нә$_1$ | ис. | 256 |
| -на/-нә$_2$ | фг. | 347 |
| -нак/-нәк | сф. | 192, 392 |
| -намә | ис. | 263 |
| -нди | алм. | 447 |
| -ндый/-нди | алм. | 448 |
| -нче | алм. | 447 |
| -ны/-не | фг. | 352 |
| -ов/-ев | ис. | 264 |
| -ова/-ева | ис. | 264 |
| -ович/-евич | ис. | 264 |
| -овна/-евна | ис. | 264 |
| -па/-пә | ис. | 189, 261 |
| -пай/-пәй | фг. | 352 |
| -пак/-пәк | ис. | 262 |

| | | |
|---|---|---|
| -пак/-пәк | сф. | 398 |
| -пан/-пән | ис. | 267 |
| -пан/-пән | сф. | 398 |
| -пач | сф. | 399 |
| -пе$_3$ | фг. | 348 |
| -пу | ис. | 261 |
| -пы/-пе | ис. | 191, 267 |
| -пы$_2$ | сф. | 395 |
| -пыл/-пел | фг. | 352 |
| -пын/-пен | фг. | 352 |
| -ра/-рә | ис. | 266 |
| -ра/-рә (-ыра/-ерә)$_3$ | ф. | 337 |
| -рай/-рәй | фг. | 350 |
| -рак/-рәк | ис. | 267 |
| -рау/-рәү | сф. | 399 |
| -ры/-ре | ис. | 267 |
| -ры/-ре | сф. | 392 |
| -рый | сф. | 399 |
| -рәк | сф. | 397 |
| -са/-сә | ис. | 192, 239 |
| -са/-сә (-сы/-се)$_2$ | фг. | 342 |
| -са/-сә (-сы/-се)$_3$ | фг. | 343 |
| -сак/-сәк | ис. | 189, 257 |
| -сак/-сәк | сф. | 398 |
| -сар$_1$ | ис. | 189, 263 |
| -сар/-сәр (-сыр/-сер)$_2$ | сф. | 396 |
| -сар$_3$ | фг. | 352 |
| -ский | ис. | 264 |
| -ская | ис. | 264 |
| -стан | ис. | 189, 263 |
| -су | сф. | 393 |
| -сы | алм. | 447 |
| -сыз/-сез | ис. | 184 |

| | | |
|---|---|---|
| -сыз/-сез | сф. | 171, 183, 379 |
| -сызлык/-сезлек | ис. | 229 |
| -сык | ис. | 267 |
| -сык | сф. | 397 |
| -сыл/-сел | ис. | 260 |
| -сыл/-сел | сф. | 387 |
| -сын/-сен$_1$ | ис. | 259 |
| -сын/-сен$_2$ | фг. | 343 |
| -сыра/-серә | фг. | 344 |
| -сыт/-сет$_1$ | фг. | 343 |
| -сә | сф. | 396 |
| -сәт | фг. | 350 |
| -та/-тә | ис. | 265 |
| -тай/-тәй$_1$ | ис. | 261 |
| -тай$_2$ | фг. | 350 |
| -так/-тәк | сф. | 398 |
| -тан/-тән | ис. | 267 |
| -тан | фг. | 351 |
| -тараш | ис. | 263 |
| -ты/-те$_1$ | ис. | 251 |
| -ты/-те | фг. | 353 |
| -тый/-ти | ис. | 261 |
| -тык/-тек$_2$ | ис. | 242 |
| -тык/-тек$_2$ | сф. | 387 |
| -тык/-тек | фг. | 352 |
| -тыл/-тел | фг. | 352 |
| -тын/-тен | сф. | 393 |
| -тын/-тен | рәв. | 429 |
| -тыш | ис. | 261 |
| -тәй | сф. | 397 |
| -тәс | сф. | 397 |
| -у/-ү (-ау/-әү) | ис. | 253 |
| -ханә | ис. | 189, 263 |

| | | |
|---|---|---|
| -ча/-чә$_1$ | ис. | 185, 227 |
| -ча/-чә$_2$ | ис. | 257 |
| -ча/-чә$_1$ | сф. | 386 |
| -ча/-чә | фг. | 353 |
| -ча/-чә$_2$ | рәв. | 145, 185, 425 |
| -ча/-чә$_3$ | рәв. | 426 |
| -ча$_1$ | алм. | 448 |
| -ча/-чә | алм. | 447 |
| -чак/-чәк | ис. | 189, 249 |
| -чак/-чәк | сф. | 172, 388 |
| -чалар/-чәләр | ис. | 239 |
| -чан/-чән$_1$ | ис. | 266 |
| -чан/-чән$_2$ | сф. | 171, 204, 382 |
| -чан$_2$ | фг. | 351 |
| -чан/-чән$_3$ | рәв. | 430 |
| -чан$_4$ | алм. | 447 |
| -чек | алм. | 447 |
| -чи/-чый | ис. | 262 |
| -чу | сф. | 395 |
| -чы/-че | ис. | 132, 171, 182, 189 |
| -чы/-че$_1$ | ис. | 132, 172, 182, 189, 192, 219 |
| -чы/-че$_2$ | ис. | 132, 172, 182, 189, 258 |
| -чы/-че$_3$ | фг. | 183, 345 |
| -чы/-че$_4$ | рәв. | 431 |
| -чык/-чек$_1$ | ис. | 184, 228 |
| -чык/-чек$_2$ | сф. | 172, 389 |
| -чык$_3$ | фг. | 346 |
| -чыл/-чел | ис. | 258 |
| -чыл/-чел | сф. | 382 |
| -чылык/-челек | ис. | 191, 228 |
| -чын/-чен$_1$ | ис. | 259 |

| | | |
|---|---|---|
| -чын/-чен$_2$ | фг. | 351 |
| -чыра/-черә | фг. | 353 |
| -чәләк | сф. | 399 |
| -ша/-шә | ис. | 189, 257 |
| -шак/-шәк | сф. | 394 |
| -шел | сф. | 394 |
| -шы/-ше$_1$ | сф. | 394 |
| -шы/-ше (-ша/-шә)$_2$ | фг. | 344 |
| -шы$_1$ | алм. | 448 |
| -шык/-шек | сф. | 394 |
| -шын/-шен | фг. | 345 |
| -шыр/-шер | фг. | 344 |
| -шәр | алм. | 447 |
| -ы/-е$_1$ | ис. | 252 |
| -ы/-е$_1$ | сф. | 391 |
| -ы/-е$_2$ | фг. | 340 |
| -ыз/-ез (-аз/-әз)$_1$ | ис. | 259 |
| -ыз/-ез, -з (-аз/-әз)$_1$ | сф. | 395 |
| -ыз$_3$ | фг. | 348 |
| -ый | сф. | 399 |
| -ый | сф. | 390 |
| -ык/-ек, -к$_1$ | ис. | 234 |
| -ык/-ек, -к$_2$ | фг. | 192, 338 |
| -ык/-ек, -к$_1$ | сф. | 385 |
| -ыл/-ел, -л$_1$ | ис. | 260 |
| -ыл/-ел, -л$_2$ | фг. | 332 |
| -ыл/-ел, -л$_3$ | рәв. | 431 |
| -ылда/-елдә | фг. | 143, 172, 329 |
| -ылты/-елте | ис. | 250 |
| -ым/-ем, -м$_1$ | ис. | 203, 236 |
| -ым/-ем$_2$ | ис. | 203, 258 |
| -ым/-ем, -м$_1$ | сф. | 388 |
| -ым$_1$ | рәв. | 430 |

| | | |
|---|---|---|
| -ымта/-емтә | ис. | 238 |
| -ын/-ен, $-н_1$ | ис. | 245 |
| -ын/-ен, $-н_2$ | сф. | 391 |
| -ын/-ен, $-н_3$ | фг. | 333 |
| $-ын/-ен_4$ | рәв. | 435 |
| -ынкы/-енке | сф. | 191, 385 |
| -ынты/-енте | ис. | 238 |
| -ынты/-енте | сф. | 388 |
| -ынтен/-ентен | бәйл. | 455 |
| -ыр/-ер, $-р_1$ | сф. | 392 |
| -ыр/-ер, -ар/-әр, $-р_1$ | ис. | 243 |
| -ыр/-ер, $-р_1$, $(-ар/-әр)_2$ | фг. | 335 |
| -ыр/-ер, -ар/-әр, $-р_3$ | фг. | 335 |
| -ырым | ис. | 267 |
| -ыс/-ес | сф. | 399 |
| -ыт/-ет, -т $(-ат/-әт)_1$ | ис. | 250 |
| -ыт/-ет, $-т_2$ | фг. | 313, 331 |
| -ыч/-еч | сф. | 389 |
| -ыч/-еч, -ч | ис. | 237 |
| -ыш/-еш, $-ш_1$ | ис. | 150, 232 |
| -ыш/-еш, $-ш_1$ | сф. | 394 |
| -ыш/-еш, -ш $(-аш/-әш)_3$ | фг. | 331 |

ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
1. ФОНЕТИКА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
1.1. Татар теленең аваз төзелеше . . . . . . . . . . . . . . . 14
1.2. Авазларның артикуляцион билгеләре . . . . . . . . . 15
1.3. Авазларның акустик билгеләре . . . . . . . . . . . . . 19
1.4. Татар телендә аваз тезмәләре . . . . . . . . . . . . . . 22
1.5. Татар телендә аваз үзгәрешләре . . . . . . . . . . . . . 30
2. ФОНОЛОГИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
3. ПРОСОДИКА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
4. ИНТОНАЦИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
5. ГРАФИКА ҺӘМ ОРФОГРАФИЯ . . . . . . . . . . . . . . 69
5.1. Графика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
5.2. Орфография . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
5.3. Татар язуы тарихыннан кыскача мәгълүмат . . . . . . . . . 79
6. ОРФОЭПИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
6.1. Орфоэпия турында гомуми төшенчә . . . . . . . . . . . 103
6.2. Татар әдәби әйтелешенең төп кагыйдәләре . . . . . . . . 107
7. МОРФЕМИКА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
8. МОРФОНОЛОГИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
9. СҮЗЬЯСАЛЫШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
9.1. Татар тел белеменең бер бүлеге буларак сүзьясалыш . . . . 171
9.2. Хәзерге татар теленең лексик системасының үсеш юллары 174
9.3. Сүзьясалыш ысуллары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
9.3.1. Кушма сүзләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . 192

9.3.2. Конверсия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
9.3.3. Сүзьясалышның лексик-семантик ысулы . . . . . . . . 200
9.3.4. Сүзьясалыш ысулы буларак аббревиация . . . . . . . . 200
9.4. Сүзләрнең сүзьясалыш структурасы . . . . . . . . . . . . . . 201
9.5. Исемнәр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
9.5.1. Исемнәрнең фонетик ысул белән ясалышы . . . . . . . 212
9.5.2. Кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышы . . . . . . . 216
9.5.3. Кушма исемнәр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
9.6. Фигыльләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 310
9.6.1. Фонетик ысул ярдәмендә фигыльләр ясалышы . . . . . 310
9.6.2. Кушымчалау ысулы белән фигыльләр ясалышы . . . . . 311
9.6.3. Кушма фигыльләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . 353
9.6.4. Тезмә фигыльләрнең фигыльләрдән ясалуы . . . . . . . 360
9.6.5. Лексик-семантик ысул белән фигыльләр ясалышы . . . 373
9.7. Сыйфатлар ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 374
9.7.1. Фонетик ысул белән сыйфатлар ясалышы . . . . . . . 374
9.7.2. Кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясалышы . . . . . . 374
9.7.3. Кушма сыйфатларның ясалышы . . . . . . . . . . . . . 400
9.8. Рәвешләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 424
9.8.1. Фонетик ысул белән рәвешләр ясалышы . . . . . . . . 424
9.8.2. Кушымчалар ярдәмендә рәвешләр ясалышы . . . . . . 424
9.8.3. Кушма рәвешләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . 435
9.8.4. Конверсия ысулы белән рәвешләр ясалышы (адвербиализация) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 439
9.9. Саннар ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 446
9.10. Алмашлыклар ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 447
9.10.1. Алмашлыкларның кушымчалау ысулы белән ясалышы 447
9.10.2. Кушма алмашлыклар ясалышы . . . . . . . . . . . . . 448
9.10.3. Конверсия ысулы белән алмашлыклар ясалышы . . . . 450

9.11. Ымлыклар ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 451
9.11.1. Сүзләр кушылу ысулы белән ымлыклар ясалышы . 451
9.12. Ияртемнәр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 453
9.13. Бәйлекләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 454
9.13.1. Кушымчалау ысулы белән бәйлекләр ясалышы . . . . 455
9.13.2. Конверсия ысулы белән бәйлекләр (бәйлек сүзләр) ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 455
9.14. Кисәкчәләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 459
9.15. Теркәгечләр ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 461
Исемнәр күрсәткече . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 472
Терминнар күрсәткече . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кушымчалар (морфлар) күрсәткече . . . . . . . . . . . . . . .

Научное издание

**ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА**

**Том I**

(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *Л.Ш. Давлетшиной*

Подписано в печать:23.12.2015.
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура «Times».
Бумага офсетная, печать офсетная.
Усл.-печ. л. 30. Уч.-изд. л. 22.
Тираж 1000. Заказ №

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, г. Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, г. Казань, ул. Баумана, 20